**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ**

**ДАҺБУ “МУСА ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ МИНЗӘЛӘ ПЕДАГОГИЯ КОЛЛЕДЖЫ”**

**МИЛЛИ КАДРЛАР ӘЗЕРЛӘҮ ҮЗӘГЕ**



*“Без тумыштан Туган телгә гашыйк,*
*Туган җиргә гашыйк күптәннән”*

# ХАЛЫКАРА ТУГАН ТЕЛ КӨНЕНӘ ҺӘМ КАҺАРМАН ШАГЫЙРЬ МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ ТУУЫНА 111 ЕЛ ТУЛУГА БАГЫШЛАНГАН V РЕСПУБЛИКА ФӘННИ-ГАМӘЛИ КОНФЕРЕНЦИЯ МАТЕРИАЛЛАРЫ

**МИНЗӘЛӘ, 2017**

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы
ДАҺБУ “Муса Җәлил исемендәге Минзәлә педагогия колледжы”
Милли кадрлар әзерләү үзәге

# “БЕЗ ТУМЫШТАН  ТУГАН ТЕЛГӘ ГАШЫЙК, ТУГАН ҖИРГӘ ГАШЫЙК КҮПТӘННӘН”

Халыкара туган тел көненә һәм каһарман шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 111 ел тулуга багышланган
V Республика фәнни-гамәли конференция материаллары

МИНЗӘЛӘ
2017

**УДК 37.371**

**377**

**ББК 74**

**Төзүчеләр:**

**Гыйлаҗетдинова Г. М., ДАҺБУ “Муса Җәлил исемендәге Минзәлә педагогия колледжы”ның татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

**Хәйруллина И. М., ДАҺБУ “Муса Җәлил исемендәге Минзәлә педагогия колледжы”ның татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

**Редакторы:**

**Ибраһимов Р. М. ДАҺБУ “ Муса Җәлил исемендәге Минзәлә педагогия колледжы” директоры**

**Техник редактор**

**Гыйлаҗетдинов И. И., ДАҺБУ “Муса Җәлил исемендәге Минзәлә педагогия колледжы”ның информатика укытучысы**

**“Без тумыштан Туган телгә гашыйк, Туган җиргә гашыйк күптәннән”.** Халыкара туган тел көненә һәм каһарман шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 111 ел тулуга багышланган V Республика фәнни-гамәли конференция материаллары. – Минзәлә, 2017. – 552 б.

**ЭЧТӘЛЕК**

**I СЕКЦИЯ** ........ 10

1. Арысланова Р. Р. Якташ язучыларыбыз иҗатында чишмә образы. ........ 10
2. Ахметвалиев И. И. Туган җирем кебек назлы, җырдай моңлы татар теле 12
3. Ахунзянова А. И. Муса Җәлил – талантлы шәхес һәм герой шагыйрь ........ 15
4. Әхмәтшина З. Д. XX-XXI гасыр әдәбиятында кеше һәм табигать проблемасы. ........ 18
5. Бәдртдинов Д. Ф. "Табигать, кеше, әдәбият- үзара бәйләнеш" ........ 20
6. Белянинова К. А. XX-XXI гасырда татар әдәбиятында табигать белән кеше арасындагы бәйләнеш. ........ 22
7. Валиева Э .И. Человек и природа в литературе 20-21 вв. ........ 27
8. Валиуллин А. А. Рафаил Төфәтуллин иҗатында кеше һәм табигать бәйләнеше ........ 29
9. Вәлиев Ә. Н. Югары Стәрле авылының табигый атамалары ........ 31
10. Вәлиева З. Д. "Җидегән чишмә романында экологик тәрбия мәсьәләләре"34
11. ГайнановА. М. Употребление заимствованных слов в современных СМИ и речи молодежи ........ 36
12. Галимова Г. Р. М.Җәлил иҗатында табигать сурәте ........ 38
13. Галимова Г. Ф. Табигать ул – яшәү чыганагы ........ 44
14. Гардисламова Р. Г..Мөхәммәтшинның "Саумысез, аккошлар!" повестендә кеше һәм табигать ........ 46
15. Гатин А. Р. Экологические проблемы татарского языка в современной лингвистике. ........ 48
16. Гарипов А.И. Әхсән Баянов – табигать сакчысы ........ 50
17. Гарифуллин А. М. Лингвоэкология: как спасти родной язык (экологические проблемы языка в современной лингвистике) ........ 53
18. Гәрәева Р.Р. Туган телдә дәшсәм генә, туган җирем мине аңлар ........ 55
19. Гиздатуллина Л. Р. Мин тормышка гашыйк. ........ 58
20. Гыйльманова Д. М. Муса Җәлилнең "Илдар" либреттосында табигать күренешләренең символик образ буларак бирелеше. ........ 60
21. Дәүләтшина Л.Ф. Теле барның- иле бар ........ 62
22. Димухаметова А. Р. Великолепия природы и многогранность человека в литературе XX века. ........ 63
23. Зарипова З. И. Табигать ул үзен яклый алмый,Үч тә ала алмый кешедән…65
24. Зарипова А. М. Ленар Шәех иҗатында кеше һәм табигать бәйләнеше. ........ 68
25. Зәлиева И.И. М.Җәлил иҗатында кеше һәм табигать күренешләренең үзара мөнәсәбәте. ........ 71
26. Ильичёва А. В. Причины разрушения русского языка ........ 73
27. Исхакова Р. Ф.Азнакай районы Таштуган авылы тарихын өйрәнү ........ 75
28. Латипова С. К. Природа и нравственность ........ 77
29. Латыпов И. Э. 20-21 нче гасыр әдәбиятында кеше һәм табигать бәйләнеше79
30. Латыйпова Л. Ә. Әдәбиятта экология проблемасы ........ 81

31.Мавлеев А. И. Катнаш никахның тел язмышына йогынтысы .................... 83
32.Массарова Д. М. Взаимодействие человека и природы в литературе XX-XXI века. ........................................................................................ 86
33.Мельникова А. А. Тел – дәүләт сакчысы ............................................ 88
34.Мирзаянова Н. Гамил Афзал иҗатында урман темасы ........................ 91
35.Мударисов Ф. М. Связь человека и природы в татарской и русской литературе XX вв. ............................................................................... 95
36.Нуриева А. Ф. Ф.Садриевның "Таң җиле" әсәрендәге табигать күренешләренең шәхес белән бәйләнеше............................................ 98
37.Нурмөхәммәтова З. Р. Иркен минем туган илем, матур минем татар телем102
38.Рафагутдинов Р. С. Человек и природа в литературе XX-XXI вв ............ 104
39.Сафина В. Р. 20 нче гасыр татар шигъриятендә кеше һәм табигатьнең үзара бәйләнеше ........................................................................................ 107
40.Сәгъдиева И. Ш. Барча тереклек калсын киләчәк буыннарга.................... 109
41.Сәйфиева Г. Р. Туган телдә җырлый чишмә, туган телдә шаулый таллар111
42.Салахова А. И.Экология человеческих взаимоотношенийв современной литературе........................................................................................ 113
43.Севастьянова Д. А. Человек – это звучит гордо? (по произведениям писателей XX века).............................................................................. 115
44.Серышева А. Д. Взаимодействие человека с природой в повести М.М. Пришвина «Жень-Шень» ..................................................................... 117
45.Сумбаева В. В. Противостояние двух стихий: человека и природы в повести Эрнеста Хемингуэя «Старик и море»........................................ 120
46.Фатыйхова И. И. Роберт Миңнуллин шигъриятендә табигать ................. 122
47.Хәсәнов Д. Р. Без тумыштан туган телгә гашыйк, җиргә гашыйк күптәннән ... 124
48.Хәмзин Р. Р. Кеше белән табигать арасындагы мөнәсәбәт. ...................... 127
49.Хөсәинова А. Р. Ркаил Зәйдулла иҗатында табигать һәм тарих .............. 130
50.Хуснутдинова Л. И. Детское чтение XXI века. «Не стреляйте в любовь!»133
51.Часовская Д. А., Малыхина Э. Е. Проблема «человека и природы» в литературе XX-XXI вв.......................................................................... 136
52.Шиһапов Б. Л. Әтнә төбәгенең табигый матурлыклары әдәби әсәрләрдә.139
53.Яруллина Л. М. Ә. Еникинең "Туган туфрак" әсәрендә кеше һәм табигать бәйләнеше ........................................................................................ 142
54.Ялилова С. Р. Тема статьи: «Человек – царь природы…»......................... 144
**II СЕКЦИЯ** ........................................................................................ 147
1. Айдашева К. Ә. Табигать һәм шәхес.................................................... 147
2. Арсланова С. С. Муса Җәлилнең "Алтынчәч" либреттосында табигать һәи кеше мөнәсәбәте................................................................................. 150
3. Асманова Л. К. Рус балаларын татар теленә өйрәткәндә экологик һәм әхлакый тәрбия бирү. ........................................................................ 153
4. Ахмәтҗанова Л. Р. Серле сөлгеләрдә еллар авазы ................................ 156
5. Әмирова М. Р. Татар әдәбиятында туган ягым. .................................... 160
6. Әмирова Р. К. Халкымның батыр улы Муса Җәлилнең тормышына күзәтү. ............. 164
7. Әхмәтҗанова Л. М. Телне саклау – безнең бурыч.................................. 174

8. Әхмәтшина А. Ф. Татар әдәбияты дәресләрендә экология һәм әхлак тәрбиясенең бирелеше ........................................................................................................ 178
9. Әшрәфуллина Р. И. Габдулла Тукай иҗатында экология темасы ...................... 181
10. Березина Н. Н. А мы должны предугадать, как наше слово отзовется .............. 184
11. Бәдертдинова А. М. Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларының IX сыйныф укучыларына татар теленнән бердәм республика тесты....................... 187
12. Борһанова Г. Ш. Татарларны татарча укытыргамы?.......................................... 195
13. Валиева Р. Н. Татар әдәбияты дәресләрендә экологик һәм әхлакый тәрбиянең чагылышы......................................................................................................... 197
14. Валиуллина Э. Т. «Экологическая проблема лесов в произведениях А.П. Чехова»200
15. Вафина А. М. Әмирхан Еники. “Матурлык” хикәясенең тәрбияви роле........... 202
16. Ваһапова З. М. Әхлакый-экологик белем һәм тәрбия бирүдә әдәби әсәрләрнең әһәмияте........................................................................................................... 204
17. Вәлиева Г. Д. Нәбирә Гыйматдинова иҗатында табигать образлары ................ 207
18. Вәлиева З. Н. Ыкта сал агызып буламы? ........................................................... 209
19. Вәлиева Л. М. «Татар әдәбияты дәресләрендә Муса Җәлилнең шигырьләре аша балаларны әхлаки һәм экологик яктан тәрбияләү»................................. 212
20. Габтунурова Н. Н. Туган телен кадерләгән халык кадерле булыр”.................... 215
21. Гадршина А. М. Матур әдәбият битләрендә табигатьне саклауга өндәүче авылдашым....................................................................................................... 218
22. Гайфуллина Р. А. Творческий проект как одно из средств воспитания духовно-нравственных качеств личности школьника (Из опыта работы) ....................... 219
23. Галәветдинова Л. Р. Рус телле студентларга татар телен укытуда әхлак тәрбиясе222
24. Ганиева А. С. Алар һаман күңелдә ..................................................................... 226
25. Гарипова Р. Г. Варваризмы. Нужно ли с ними бороться? ................................... 229
26. Гарифуллина Д. Р. “Уйларым кәгазьгә түгелә...”................................................ 230
27. Гафурова Д. М Татар теле һәм әдәби уку дәресләрендә экологик һәм әхлак тәрбиясе ........................................................................................................... 233
28. Гомәрова Л. М. Тукай әсәрләрендә экологик тәрбия. ........................................ 235
29. Гыйззатуллина А. И. Ел фасылы буенча шагыйрь бәйрәмен истә калдыру ....... 237
30. Гыйлфанова Л. М. Тикшерү эшенең темасы: Ф.Садриев иҗатында күтәрелгән әдәп-әхлак мәсьәләләре. ................................................................................... 240
31. Гыйльметдинов И. М. Г.Тукай шигырьләрендә табигать темасы. .................... 243
32. Гимадиева А. Ф. Минзәлә төбәге әдәби киңлегендә экологик проблемалар һәм аларны чишү юллары. ...................................................................................... 246
33. Гыймалетдинова Н. М. Әдәбият дәресләрендә экологик һәм әхлак тәрбиясе. ............ 249
34. Данилова З. С. Экологик һәм әхлаклылык сыйфатлары тәрбияләүдә Нәҗип Мадьяров поэзиясен файдалану үзенчәлекләре. ................................................ 255
35. Дәүләтова Г. М, Башлангыч сыйныфта әдәби уку дәресләрендә әхлакый һәм экологик тәрбия. .............................................................................................. 258
36. Дәүләтова Р. Ф. Әдәбият дәресләрендә әхлакый-экологик тәрбия бирү. ........... 262
37. Ермолева Э. С. Габдулла Тукай ижатында экология темасы ............................. 265
38. Җиһангәрәева Т. Р. Экологик тәрбиядә төбәк үзенчәлекләре ............................ 270
39. Закирова Л. М.Туган телне ничек саклап калырга?............................................ 273

40. Закирова Р. А., Муллагалиева Х. М. Нәбирә Гыйматдинованың “«Ак торна каргышы» әсәрендә күтәрелгән әхлак мәсьәләләре........................................... 274
41. Зәйнәгова С. Г. “…Без тумыштан Туган телгә гашыйк, Туган җиргә гашыйк күптәннән”.................................................................................................... 277
42. Зәйнуллина Э. Т. Галимҗан Гыйльманов иҗаты аша укучыларга әхлакый һәм экологик тәрбия бирү .............................................................................. 280
43. Зиннәтова Л.М. Әдәбият дәресләрендә укучыларга экологик һәм әхлак тәрбиясе бирү ............................................................................................................ 283
44. Зиязиева Р. Ш. Татар теле дәресләрендә экологик белем һәм тәрбия бирү........ 286
45. Ибрагимова В. Ә. Татар әдәбияты дәресләрендә экологик тәрбия..................... 289
46. Ильдарханова Ф. М. Экологические проблемы языка в татарской медицинской терминологии ........................................................................................... 290
47. Имаметдинова Р. Г. Әйләнә-тирәлекне өйрәнү дәресләрендә матур әдәбият аркылы экологик тәрбия бирү............................................................................ 293
48. Исмәгыйлова Г. Ф. Әдәби укуда экологик проблема чагылышы ....................... 297
49. Ишмөхәммәтов И. Ш. М.Җәлилнең “Моабит дәфтәрләре” циклын өйрәнүнең кайбер үзенчәлекләре ............................................................................................. 298
50. Камалиева Д. В. Яшә син, туган телем! ............................................................. 301
51. Камбеева Г. Г. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә кече яшьтәге укучыларга экологик белем һәм тәрбия бирү ......................................................................... 303
52. Кашапова Г. Х. “Мин тумыштан гашыйкмын телемә, туган җиремә”................ 307
53. Кәримова Р. Г. Әдәбият дәресендә әхлак тәрбиясе ............................................. 315
54. Латыйпова Н. Н. Балаларда табигатькә сакчыл караш тәрбияләү ...................... 318
55. Мельникова Л. С. Татар әдәбияты дәресләрендә экологик проблема................. 321
56. Минһаҗева Р. М. Габдулла Тукай иҗатында әхлак тәрбиясе. ............................ 324
57. Минһаҗева Р. Ә., Кәрамова А. Җ. Якташыбыз Амур Фәләх иҗатында XXI гасыр проблемалары ........................................................................................................ 327
58. Минһаҗева Р. Ә. Г. Ибраһимовның «Диңгездә» хикәясен өйрәнү тәҗрибәсеннән330
59. Мифтахова Э. Ф. Әхлакый –экологик тәрбия – күңел хәзинәсе ........................ 333
60. Мортазина Л. Г. Туган телне ничек саклап калырга. .......................................... 336
61. Мусина Л. З. Духовно-нравственное воспитание на уроках литературы ........... 340
62. Муханова М. Г. Әдәбият дәресләрендә әхлак тәрбиясе........................................ 344
63. Набиуллина Л. З. Габдулла Тукай иҗатында экологик тәрбия .......................... 347
64. Насыйрова З. Ш. Татар теле һәм әдәбият дәресләрендә әхлакый һәм экологик тәрбиянең актуальлеге ........................................................................................... 350
65. Насыйрова М. С. Кабатланмас шәхесләр тәрбиялик........................................... 357
66. Нәҗмиева Г. Л. Дәрья суы сыман минем уйлар.................................................... 360
67. Низамбиева Р. Р., Дәүләтбаева Р. Н. М. Җәлил иҗатында әхлак һәм экологик тәрбиянең чагылышы ............................................................................................. 363
68. Нургалиева Х. Ә. Туган телебезне, аның сафлыгын саклыйк!............................ 365
69. Нуриева Л. Ф. Татар әдәбияты дәресләрендә әхлакый тәрбия бирү.................... 373
70. Нуриева Ф. Б. Әдәби уку дәресләрендә экологик һәм әхлак тәрбиясе................ 376
71. Нуруллина А. Ә. Әдәбия дәресләрендә әхлакый-экологик тәрбия .................... 378

72. Переина М. Т. «Памяти никакой не стало, вся износилась…Господи, как легко расстается человек с близкими своими, как быстро он забывает всех»............ 381
73. Постовая В. В. Обучение нравственности на уроках литературы ...................... 382
74. Рамазанова Д. Ф. Күңелдә былбыллар сайрармы? ............................................ 386
75. Романова В. Г. Татар әдәбияты дәресләрендә рус балаларына экологик һәм рухи-əхлакый тәрбия бирү.................................................................................... 389
76. Солтанова Г. М. Гарәфи Хәсәнов иҗатында экологик тәрбия ........................... 392
77. Сабитова З. А. Нравственное воспитание личности средствами татарской и русской литературы............................................................................................ 395
78. Сабитова С. Ә. Теле юкның – иле юк................................................................ 399
79. Салихова Р. В. Телебезне, тәрбиябезне, милләтебезне югары дәрәҗәгә күтәрергә омтылыйк. .................................................................................................. 403
80. Сәгйтова Э. Р. Татат теле һәм әдәбияты дәресләрендә экологик тәрбия бирү… 409
81. Сәлимова Г. И. Табигать һәм без...................................................................... 412
82. Сәхабетдинова Р. Г.Нәбирә Гыйматдинова әсәрләрендә табигать һәм кеше ..... 416
83. Сәхәбиева Г. Х. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә экологик һәм рухи-әхлакый тәрбия бирү ......................................................................................... 419
84. Сорокина Р. Ф., Фатыйхова Г. Ф. Әхлак – милли тәрбиянең нигезе ................ 423
85. Сөләйманова Н. Н. Татар әдәбияты дәресендә экологик һәм әхлакый тәрбия... 426
86. Тимереева Ә. В. Татар телендә лингвоэкологик проблемалар (туган тел сагында).430
87. Тимерова Л. Н. Фәүзия Бәйрәмованың "Болын" әсәрендә күңел экологиясе бирелеше.......................................................................................................... 432
88. Титова Г. А. «Место, где ты родился, должно быть всегда»............................ 436
89. Трифонова Е. И. Проблемы экологии современного русского языка ............... 440
90. Фаррахова Р. Г. Экологическое и нравственное воспитание на уроках литературы в 5 классе ...................................................................................... 444
91. Фаррахова Р. Р. Әйдәгез, туган табигатебезне саклыйк, чаң сугыйк! ............... 447
92. Фархутдинов И. М., Габдуллина Г. М. Абдулла Алиш иҗатында экология темасының яктыртылышы.................................................................................. 450
93. Фәттахова Р. М.Табигать һәм шәхес бердәмлеге............................................... 452
94. Хабирова Ф. З. Шәхес үсешендә әхлакый экологик тәрбиянең роле.................455
95. Хәйруллина Р. А. Татар әдәбияты дәресләрендә әхлакый һәм экологик тәрбия.458
96. Хамматова Г. Г., Мөхәмәдева А. Б. Балаларга әдәбият дәресләрендә әхлакый тәрбия бирү ...................................................................................................... 461
97. Ханова А. И. Уку дәресләрендә табигать һәм аны саклау, әхлак темасы .......... 464
98. Ханова Н. В. Г. Исхакыйның “Кәҗүл читек” хикәясендә тәрбия мәсьәләсенең бирелеше.......................................................................................................... 468
99. Хасаншин И. Ф. Газиз, туган телем! ................................................................. 471
100. Хафизова И. М. Рус гимназиясе шартларында әхлак тәрбиясе бирү тәҗрибәсеннән ................................................................................................... 475
101. Хафизова Р. Р. Башлангыч сыйныфларда әдәби уку дәресләрендә экологик һәм әхлакый тәрбия ................................................................................................. 479
102. Хәйретдинова Г. М., Шәрипова Г. М. Татар әдәбияты дәресләрендә фазыл туйкин эшчәнлеген һәм иҗатын өйрәнү ............................................................ 481

103. Хайрутдинова З. Р. Муса Җәлил иҗатында– табигать, кеше һәм тәрбия ........... 485
104. Хайруллина С. И. Татар теле  һәм әдәбияты дәресләрендә экологик һәм рухи-әхлакый тәрбия бирү ........................................................................................ 488
105. Хәлиуллина Р. Х. «Тукай иҗатында экология һәм әхлак мәсьәләләре” ............. 491
106. Хәсәншина З. З. Татар әдәбияты дәресләрендә социаль-мәдәни компетенция формалаштыру ........................................................................................ 504
107. Хөсәенова Г. Х. Г.Тукай иҗатында табигать темасы. .......................................... 507
108. Шайхатарова Э. Г. Милли тел язмышы  - милләт язмышы. ................................ 513
109. Шәйдуллина Ф. К., Шәйдуллина Р. Ә. Әдәбият дәресләрендә балаларга әхлакый-экологик белем һәм тәрбия бирү ........................................................................ 517
110. Шәйхелмәрдәнова Ч. Т. Әдәби уку дәресләрендә  әхлакый-экологик   тәрбия.. 520
111. Шәйхуллина З. Н. Фоат Садриевның “Таң җиле”  әсәрендә  ана образлары аша әхлак тәрбиясенең бирелеше ............................................................................ 523
112. Шәмиева Ф. М. Экологик белем һәм тәрбия бирүнең әһәмияте ......................... 527
113. Шәрипова И. Н. Харрас Әюп шигырьләре аша балаларда әхлаклылык тәрбияләү530
114. Шәфигуллина Н. М. Муса Җәлил шигырьләренең тел һәм стиль үзенчәлекләре535
115. Шибаева Р. Р. Чишмәләр җыры тынмасын ........................................................ 538
116. Якупова Г. Ш. Матур әдәбият аша әхлакый-экологик белем һәм тәрбия бирү.. 541
117. Яппарова Р. Б. Башлангыч сыйныф укучыларына татар теле дәресләрендә экологик тәрбия бирү ........................................................................................ 546
118. Ясавиева Г. М. Татар әдәбияты дәресләрендә экологик тәрбия.......................... 549

## I секция
## Якташ язучыларыбыз иҗатында чишмә образы.

***Арысланова Регина Ринат кызы,***
***7б сыйныфы укучысы.***
***Кыямова Алия Мулләхмәт кызы,***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы.***

Тоз тозлы, шикәр, кәнфит баллы, лимон белән суган әче була. Ипи, сөт, бәрәңге тәмнәре дә безгә таныш. Суның тәмен татып караганыгыз бармы? Аны баллы, тозлы яисә әче дип әйтеп булмы? Юк , булмый. Чиста суның тәме булмый. Ә иң чиста су кайда була? Билгеле , чишмәдә. Эссе көннәрдә , печән вакытларында челтерәп аккан чишмәгә ятып, аның салкын суын эчсәң, аннан да тәмле әйбер юк дөньяда.

Минем эшем-тормыш чыганагы булган, җаннарга илһам, күңелләргә дәрт биргән чишмәләргә багышлана. Фәнни эшем “ Көмеш чишмәләр җыры” дип атала.

Мин бу эшне бик актуаль дип саныйм, чөнки һәр кеше үзенең ягының чишмәләренең тарихын белергә ,аны киче буынга җиткерергә тиеш .

Баулы ягы елга-чишмәләргә бай як. Юкка гына авыл кешеләре үзт чишмәләре белән горурланып яшәмиләр, чишмәләренә яратып ягымлы исемнәр кушмыйлар, мәсәлән :"Гомер чишмәсе" ,"Ак чишмә" "Шәвәли","Бәллүр чишмә","Шәйхевали" ,"Такыя","Бакыр тау чишмәсе","Бәллүр чишмә",”Һади чишмә”с е”. Бүгенге көндә Баулы районында 125 чишмә исәпләнә, шуларның 12 се шәһәрнең үзендә.

Авыруга дәва була торган чишмәләр дә бар бездә .

Туган якның чишмәсеннән тәмле сулы чишмә юк.

Авылыбыз чишмәләре... Безгә таныш та, якын да, кадерле дә. Халкыбызның кыю йөрәкле улларына каһарманлыкны алар биргән инде! Баулы якларының челтерәп акккан чишмәләре кемнәрне генә илһамландырмаган...Ык буе авыллары татар иленә күренекле әдипләр үстереп биргән. Елга Татарстан җиренә килеп кергән урында Габдрахман авылы урнашкан. Бу авылда тарихи романнар остасы,Тукай премиясе лауреаты , язучы Мөсәгыйт Хәбибуллин туып үскән. Ыкның Баулы районындагы беренче кушылдыгы –Кандыз елгасы буенда трибун шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов туган.

Безнең якларда сүз байлыгы туплаган бөек әдәбиятчы Владимир Даль суны кодрәтле сыеклык дип атаган. Әйе, табигать безгә чынлап та гаҗәеп бүләк әзерләгән. Җир шарының үзенең дә дүрттән өч өлешен су биләп тора.Кеше организмын да судан аерып карап булмый.

Туган йортын, туган авылын, туган ягын чын күңелдән яраткан кеше генә Ватанын ярата һәм кирәк вакытта аны саклау өчен үз-үзен аямыйча көрәшкә күтәрелә. Аны исә чишмәләрдән, елга-күлләрдән башка күз алдына китереп тә булмый.

Минем сезгә "Салкын чишмә" турында сөйләп китәсем килә. Оренбург- Казан юлындагы чишмә бу.  Бу исем чишмә җисеменә шундый туры килә, башкасын күңел кабул итә алмас иде. Аның суы шулкадәр чиста ки, хәтта зәңгәрләнеп , кояш нурларында җемелдәп, ялтырап тора. Менә нәрсәләр сөйләде минем әбием бу чишмәнең барлыкка килүе турында.

Безнең бабайларыбыз бер урында төпләнер өчен бик озак уңайлы урын эзләгәннәр.Аларны Баулы ягының матур табигате, күп санлы чишмәләренең

тәмле суы үзенә җәлеп иткән.Юлларында куәтле, матур чишмәгә тап булгач,алар ял итәргә, сусауларын басарга туктыйлар.Ә чишмәнең суын авыз итеп карагач, тагын да ныграк аптыраште калалар.Чишмәнең суы тешне сындырырлык, сап-салкын була.Күпләренең бер-ике йотым су эчү белән хәтта тамаклары да шешеп чыга.Нәкъ менә чишмәнең шушы сыйфаты өчен аны бабаларыбыз "Салкын чишмә"дип атыйлар.Урыны бик матур булганга ,уратып алып төпләнәләр.

" Салкын чишмә" һәркемнең игътибарын җәлеп итә.Сабантуй вакытларында чишмә буе кайткан кунаклар һәм авыл кешеләре белән тула.Берсе дә чишмә суын татып карамыйча калмый.Авыл халкы чишмә буен бервакытта да пычратмый,улакларын  чистартып тора.Чөнки чишмә-сәламәтлек нигезе.

Читкә китеп гомер иткән кешеләр олыгайгач: " Үз чишмәмнең суын эчсәм,тәнем сихәтләнер"- дип юкка гына әйтмиләр.

Эзләнү барышында шулай ук Баулы районы белән бәйле  бик күп  җырлар , әсәрләр, шигырьләр таптык.

Авылымнын чишмәләре турында өйрәнгән вакытта якташ язучыларыбыз иҗатында чишмә,су нинди чагылыш табуын беләсе килеп эзләнү эшемне дәвам иттем. Үзебезнең яктан чыккан  Садыйкова Фикия Мәҗит кызы шигырьләрен   оператор булып эшләгән вакытта яза башлый.Хәзерге вакытта ул "Ватаным Татарстан"гәҗитенең актив корреспонденты. Райондашыбыз  Рәшит абый Әхмәтҗановның  шигырьләрен яратып укыйбыз. Туган авылы Кандыз   чишмәләренә багышлап язган шигырьләре аеруча күңелгә якын. Кызыл- Яр авылында туып үскән Фәнис абый Яруллин турында онытырга ярамый.Ул безгә Баулы ягының серле , аһәңле чишмәләре турында бик күп шигырьләр,  әсәрләр язып калдырган.

Алсу Хисамиева башкаруында "Эх, Баулы таулары"  җыры. Мин бу җыр тарихының туган  ягым белән бәйле булуы белән бик горурланам.

Булат Дәүләтов башкаруында “ Исергәп чишмәләре”җыры үзе ни тора.Сүзен һәм көен Исергәп авылында яшәп ятучы Ленар абый Бакиров язган.

Чишмәне савыктыру, иң башлап, күңелләребезне савыктыру ул.Чөнки чишмә- су чыганагы гына түгел, рухыбыз көзгесе.Чишмә суларыбыз алдагы буыннарга аларны яңартучыларның рух җылысын алып барыр.Көмеш агымнар авыруларны сихәтләндерер,хезмәт кешесенә көч-куәт бирер, милләтнең рухын ныгытыр.Чишмәләрне яңартып без аларның бәхиллеген алабыз.

Безнең өйрәнүләрдән, тикшеренүләрдән күренгәнчә, җирлегебездәге чишмәләрнең санитар торышы бик үк начар түгеллеге ачыкланды, ләкин күпчелек чишмәләр файдаланылмый һәм аларга безнең ярдәм кирәк. Алга таба да үз авылымның, районымның чишмәләре тарихын өйрәнүне дәвам итәрмен дип уйлыйм, чөнки бу - бик кызык, мавыктыргыч һәм шул ук вакытта файдалы шөгыль. Ә туган якны төрле яктан өйрәнеп, без үзебезнең тамырларыбызны беләбез.

Туган җирнең пакъ сулары уй-ниятләребезнең чисталыгына үлчәм булсын.

Син күзен ачкан чишмә һәрчак догада булыр...

**Файдаланылган әдәбият:**

1.Баллы елга буенда.На медовой реке: очерки.-Казань:Татарское газетно-журнальное издательство,1996.

2. Бавлы, ты сердцу милый уголок. Очерки, рассказы, стихи, песни ветеранов НГДУ «Бавлынефть»/ Сост. Ф. Садыкова.- М.: РадиоСофт,2001.

3. Көмеш чишмәләр җыры.Издательство “Рухият”,1998

4.Мирсәй Гариф “Тымызык кына Ык ага”.Еллар,юллар язмалары.Баулы ,2004

## Туган җирем кебек назлы, җырдай моңлы татар теле

***Ахметвалеев И.И.,***
***Спас күптармаклы технологияләр техникумы,***
***1курс студенты***
***Җитәкче- Хәбибуллина Р.Г.***

Туган җирең Идел буе,
Һәр телнең бар Туган иле.
Туган җирең кебек назлы,
Җырдай моңлы татар теле.

Әйе, Туган як, Туган ил, Туган җир һәркем өчен дә якын һәм кадерле. Юкка гына Туган җирне газиз ана белән тиңләмиләр.

Туган җир ! Әби – бабаларның әкият – кыйссалары , гыйбрәтле нәсыйхәтләр , риваятьләр булып күңелгә , йөрәккә кергән күпме вакыйгалар шаһиты ул! Ана теленең бар матурлыгы шул кыйссалар аша сеңгәндер хәтергә! Кемгә дә газиз,якын һәм кадерле бит алар ! Ә туган якның һәр карыш җире, чишмә , урман , болын исеме әллә никадәр истәлекләр саклый. Кеше язмышлары, авыл, ил тарихы белән бәйле күпме мәгълүмат аларда?! Бу темага багышлап шагыйрьләребез шигъри әсәрләр , композиторларыбыз күңелне кузгатырлык матур көйләр , рәссамнарыбыз гүзәл сәнгать әсәрләре иҗат иткәннәр. Әйе, һәркем үз ягын матур итеп , аны үз мәхәббәте белән , шигъри бизәкләргә төреп , ямьләндереп күрә. Татарстанның яки Туган җиребезнең сокландыргыч урыннары чыннан да бик күп. Яшел тугайлы болыннарга , балыклы , кош – кортлы агымсуларга, түгәрәк күлләргә бай ул. Сөекле Тукаебыз да бит “ Туган авыл” шигырендә : [ 1,20б]
“Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә, хәтеремдә мәңге калыр туган җирем”, - дип юкка гына язмаган. Һәркемнең туган төбәге , туган теле бер генә була. Минем туган җирем – Татарстан, туган телем – бөек татар теле.

Минемчә, туган телне яратуны шагыйребез Г.Тукай тулысынча аңлатып биргән. “Туган тел” шигыре кешене тормышның бөтен чорларына алып кайта. Сиңа гомер бүләк иткән әти-әниеңнең теле аша син дөньяны таныгансың. Башка телләр үзләренчә матур булса да, үз телеңнең яңгырашы ук башка. Ул сиңа үгет-нәсыйхәт булып та, иркәләп-сөеп тә ишетелә.Туган телең аша җирдәге, кешедәге матурлык бөтен тулылыгы белән аңлашыла.Җырларыбызга моңлылык хас булган кебек, телебезгә дә моңлылык хас. Ә моң кешенең йөрәгендә, күңел түрендә туа. Моңлы халык начар була алмый. Моң ул – халык рухының ышанычлы сакчысы. Шуны онытмасак, телебез һәрвакыт моңлы, ягымлы, аһәңле булыр.

Мин үзем бик матур Чәчәкле исемле татар авылында туып үстем.Туган авылымның табигате бик матур. Минем туган телем – татар теле. Ул миңа бик якын тел, чөнки минем телем татар телендә ачылган. Мин кечкенәдән бу телдә иркен сөйләшәм. Әнием миңа татар телендә бишек көйләре көйләгән, татар әкиятләрен сөйләгән. Анам телендә тугыз ел белем алдым, соңгы елларда туган авылымда мәктәп ябылгач,күрше Иске Рәҗәп мәктәбендә укыдым.9 нчы сыйныфны тәмамлагач ,Болгар шәһәрендәге техникумга укырга кердем һәм хәзерге вакытта шунда белем алам.

Хәзер, зур үсеп җиткәч тә, мин татар эстрадасы артистлары җырларын рәхәтләнеп тыңлыйм. Татар халкының кызыклы, бөек шәхесләре, театр дөньясы, сәнгате турында күбрәк

белергә тырышам. Мәктәп тормышындагы туган телемә кагылышлы чараларда катнаштым һәм хәзер дә катнашырга тырышам .

Татар халкы гасырлар буе нинди генә сынауларга дучар булса да, барлык авырлыкларны җиңеп, үз телен, үз милләтен, үз гореф-гадәтләрен саклап килгән халык. Мин үземнең татар булуым, милләтем белән горурланып яшим. Татар телендә сөйләшү күңелемне иркәли, татар җыры, татар моңы авыр кичерешләрдән арындыра, рухи биеклекләргә күтәрә. Шушы телдә сөйләшә,аралаша,укый-яза,фикер йөртә,аңлаша алуыма чын күңелдән горурланып яшим.Татар моңы-җыры җир шарының төрле почмакларында яңгырый. Халкымның гасырлар буена җыелган тәҗрибәсе: мәкальләре, әйтемнәре тәрбия баскычыннан җитәкләп югарыга күтәрә, ниндидер бер илаһи рәхәтлек хисләре кичерергә мәҗбүр итә. Телебез- иң бай, иң матур телләрнең берсе. Татар теле, татар теле дөньясы – үзе бер тылсымлы дөнья. Без тел аша чын йөрәктән чыккан матур хисләребезне, күңел түрендә яткан тирән кичерешләребезне, хыялыбызда гәүдәләнә торган изге теләкләребезне белдерәбез.

Әйе, ана теле бер булыр. Ул безгә әнкәбезнең күкрәк сөте аша керә. Сабыйга иң якын кеше - анын әнисе. Беренче сүзләрне дә ул анадан ишетә. Баланың теле дә "әннә" дип ачыла. Һәр халык үз телен яратып "Ана теле" дип атый.

Ана теле һәрвакытта беренче урында торырга тиеш, анын аша дөньяга, аң-белемгә юл ачыла. Безнең төп бурычыбыз - үз халкыбызның мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, иң күркәм йолаларын, халкыбызның тарихын хөрмәт итәргә өйрәнергә тиешбез һәм киләчәк буынны да шуңа өйрәтергә бурычлыбыз.

Әйе, милләт буларак сакланып калу бүген безнең һәрберебездән тора. Беркемгә, бернәрсәгә карамыйча, үз ана телебездә сөйләшергә, үз динебезне тотарга, үзебезчә яшәргә безгә беркем комачау итәргә тиеш түгел. Халыкның рухи байлыгы бервакытта да саекмасын, кимемәсен, милләт үткәнен хөрмәт итсен, кеше үзенең туган җирен, туган телен, гореф-гадәтләрен, йолаларын онытмасын дигән сүз. Менә шушы рухи хәзинәне саклап калу максатыннан, татар язучыларыбыз гаҗәеп гүзәл әсәрләр иҗат иткәннәр һәм итәләр.Телебезне саклауда республикабыз татар театрларының да өлеше зур.Телевизордан “Башваткыч”,”Аулак өй” тапшыруларын,спектакльләрне,татарча киноларны татарлар гына түгел , руслар да яратып карый.Танылган җырчыларыбызның концертлары да тамашачыларны үзенә тартып тора. Язмамны яраткан шагыйрем Х.Туфан шигыреннән өзек белән тәмамлыйсым килә.

Син –минем тере тарихым,
Син -минем киләчәгем,
Тик синдә ,газиз туган тел,
Бәхеткә җитәчәгем...[2,3б]

**Кулланылган әдәбият**

1.Ф.М.Мусин,Ә.М.Закирҗанов,И.Г.Гыйләҗев,Р.С.Шәвәлиева.Татар әдәбияты:рус телендә төп гомуми белем бирү мәкт.7нче с-фы өчен д-лек(татар балалары өчен).-5 нче басма-Казан:Татар.кит.нәшр.,2011-175б.

2.З.Н.Хәбибуллина.Татар әдәбияты:рус телендә төп гомуми белем бирү мәкт.9 нчы с-фы өчен д-лек(татар балалары өчен).- Казан:Мәгариф,2005-239б.

## Муса Җәлил – талантлы шәхес һәм герой шагыйрь

*Ахунзянова Айгуль Ириковна, студентка 2 курса*
*Гильфанова Рафина Рафкатовна, научный руководитель,*
*ГАПОУ “Камский государственный автомеханический техникум имени Л.Б. Васильева”*

“Жырлап уттем данлы корэш кырын,
Жырлап килдем тормыш язымa..."
М. Жэлил

Дөнья поэзиясе кугендэ якты йолдызлардай балкыган шагыйрьләр аз тугел. Әмма алар арасында азатлык көрәшенең ялкынлы жырчылары шул көрэштә батырларча һәлак булган легендар геройлар – инглиз шагыйре Джордж Байрон, венг шагыйре Шандор Петефи,испан шагыйре Гарсиа Лорка,болгар шагыйре Никола Вапсаров,чех язучысы,публицист Юлиус Фучик хем татар шагыйре Муса Җәлил исемнәре бар.

Патриот - шагыйрь Муса Җәлилнең шигъри таланты, сугышчан батырлыгы һәм хәрби оештыру осталыгы фашизмга каршы аяусыз көрэштә бөтен тулылыгы белән ачылды. Анын исеме дөньяда үзенең Ватанына, үз халкына турылыклы булуныү гузәл символына әйләнде. Муса халыклар дуслыгы җырчысы буларак җир йөзендә зур соклану тудырды. Муса Җәлил поэзиясе тау елгасы кебек көчле һәм ярсу да, кырыс һәм шаян да, дәртле һәм сагышлы да.

М.Җәлил 1942 нче елның февралендә Төньяк Көнбатыш фронтка жибәреле. М. Җэлил фронтка жибәрелгәч тә ижат эшеннән аерылмый. 1942 нче елның февраленнән 1944 нче елның февраленә кадәр шагыйрь каләмен ташламый. 1944 нче елның февралендә Җәлил һәм җәлилчеләрнең гомере өзелә. Муса Җәлил үзенең кыска, әмма якты поэтик юлында батырлыкка һәм үз каны белән дэ расланган иҗади батырлыкка дан җырлады, безгә киләчәк буыннар да хөрмәт белән искэ алырлык, мәңге сүнмәс васыять һәм наказ калдырды.

Җәлилнең һәр шигырь юлы канга манчып язылган.Хәтта шаян, күңелле, шук шигырьләре дә кан түләп алынган. Алар – көрәшче шигырьләр. Батыр шигырьләр. Алар

тоткынлыкта да батыр булып тудылар һәм шунда ук көрәшкә ташландылар. Мин алар алдында баш иям.

Үзе үлсә дә, шигырьләре илгә кайтыр, илдә аның батырларча һәлак булуын белерләр дип өметләнә ул. 1956 нчы елнын 2 нче февралендә СССР Верховный Совет Президиумы Указы белән М. Җәлилгә Советлар Союзы Герое исеме бирелә, чөнки илгә "Моабит дәфтәре" җыентыгы кайта. Анын исеме дөньяда узенең Ватанына, үз халкына тугрылыклы булуның гүзәл символына әйләнде. Муса халыклар дуслыгы жырчысы буларак җир йөзендә зур соклану тудырды.

Муса Җәлил үзенең кыска ,әмма якты поэтик юлында батырлыкка һәм уз каны белән дә расланган иҗади батырлыкка дан җырлады, безгә киләчәк буыннар да хөрмәт белән искә алырлык, мәңге сүнмәс васыять һәм наказ калдырды. Милли сүз сәнгатендә бай ижади мирас калдырган Муса Җәлил шигъриятен тәнкыйть шартлы рәвештә ике чорга булә: 20 - 30 нчы еллар һәм сугыш дәвере. Шагыйрьнең 20-30 нчы еллар иҗатын Р. Бикмөхәммәтов "яшьлекнең көч сынавы" дип бәяли. Эзләнүләр чорында М. Җәлил көрәш һәм гражданнар сугышы ялкыныннан күәт алган революцион романтизм белән мавыга.

Җәлил аерым әсәрләрендә символик образлар аркылы чынбарлыкка, яшәп килүче системага мөнәсәбәтен белдерергә отмыла. Мәсәлән, "Язгы юлда" (1933) шигырендә язгы кар образы аркылы илдәге хәл-халәткә бәя бирелә. Язгы карнын "тузган чикмәнгә" тиңләнүе ярлылык, хәерчелек символы иске чикмәннең күпме генә ямасаң да сутеләчәгенә, язгы кар кебек ышанычсыз булуына, илдәге хәерчелекнең дәвамлыгына ишарә ясый, шигырьдәге сызлану, газаплы кичереш тә шуңа бәйләнеп усэ.

Туган илгә тугрылыгын саклаган, дөресрәге, мәҗбур булган хәлдә, хакимиятнең милләтләргә карашында сүз белән гамәл арасындагы аерымлыкны күреп уянган хәвефле уйланулары М. Җәлилнең "Алтынчәч" (1940) либреттосында Тугзак ана ыругының тарихы белән бәйләнештә үстерелә. Муса Җәлил ижатының гына түгел, гомумән татар поэзиясенең алтын фондына керерлек бу әсәр аерым образларын символик югарылыкка күтәрелүе.

Моңа кадәр Туган илгә тугрылыгын раслаган ант һәм ышаныч образлары шагыйрь шәхесе белән Туган ил арасындагы мөнәсәбәтне ачуда төп чарага әверелә. Муса Җәлил поэзиясе бу елларда эчтәлек ягыннан гына түгел, форма җәһәтеннән дә яңа үрләр яулый: шигырьләрен төзүдә төп композицион алымнар булган кабатлаулар, көчәйтүләр хиснең дәрәжәсен арттыруга хезмәт итә ("Ышанма", 1943; "Җырларым", 1943 һ.б.), интонация узгәреше (салмак интонация үлемгә тыныч мөнәсәбәт тәрбияләүгә юнәлтелә: "Дуска"), хәтта сүз – сүрәт тә шул максатта кулланыла, батырлык культы, илгә тугрылыкны раслау югары стиль, пафос ("Жырларым", 1943; "Чәчәкләр", 1943) аша да уткәрелә. Ай, кояш, таң, чишмә, гөл, чәчәк, сандугач, яулык, күлмәк кебек татар шигърияте өчен традицион символик

образлар Муса Җәлил поэзиясендә, ачкыч сүзләр буларак кулланылып, яңа мәгънә төсмерләренә байый. Шигырьләрдәге якты хыял, якты гомер, ал таң, акбуз ат, зэнгэр томан, ак дулкыннар кебек тосне белдеруче эпитетлар лирик герой күңеленең матурлыгын, керсезлеген ачуда ярдәм итү.

Муса Җәлил мирасы- бүгенге күпмилләтле әдәбиятның аерылгысыз өлеше. Милли традицияләрне, Шәрык моңнарын эченә алган, шул ук вакытта рус һәм бөтендөнья әдәбиятының игелекле йогынтысында үскән Җәлил иҗаты безнең әдәбиятта яңа адым булды. Җәлил татар шигъриятендәге гражданлык яңгыраешын баетты, аңа каһарманлык сулышы өрде.

Шагыйрьнең гомере, чыннан да, чәчәк аткан чорында өзелде. Еллар узган саен, анығ купкырлы иҗаты яңа яклардан ачыла. Җәлил әсәрләре һәр тарихи чорда заманча яңгырый. Бу асыл кеше бүген дә безнең арада кебек.Анығ шигырьләре, публицистикасы халыкка хезмәт итү үрнәге булып тора, ватандашларыбызны яңадан-яңа күркәм эшләргә рухландыра, туган җиребез белән горурлану хисләре тудыра. Муса Җәлил – татар халкының аерым бер горурлыгы, какшамас милли рух символы ул. Һичшиксез, ул безнең йөрәкләребездә халкыбызның батыр улы булып мәңге яшәр!

Шулай ук табигать, яшәеш символикасын, көрәш, ут, язмыш, дошман, буре, батыр егет, чишмә, сандугач кебек сүзләрне ачкыч итеп алган, символика, табышмак, серлелек, юл асты агымы, икенче, өченче мәгънәви төсмерләр эстетик юнелешен билгели. Җәлилнең хис-кичереш, уй-фикер дөньясы кабатланмас матурлыгы, илахи байлыгы белән ачыла, XX гасыр татар поэзиясенә тәэсире ачыгырак күренә. Муса Җәлил, зур, талантлы шагыйрь буларак, тормышны, дөньяны, оста рәссамнар кебек, бөтен тулылыгы, матурлыгы белән төрле төсләрдә сүрәтләп тасвирлап бирә алган. Анын иҗатында ак-кара, я булмасы кызыл-ак кебек капма-каршы төсләр генә түгел, бәлки калейдоскоптагы кебек, бик күп төрле төсләр һәм аларның төрле төсмерләре дә киң кулланылган. Мәсәлән, акбуз, җирән, зөбәржәт, энҗе, җәүһәр, яхуд, алтын, көмеш кебек төсләрне белдерүче сүзләр халык авыз иҗатында да киң кулланыла башлый.

Анығ әсәрләрендәге эстетик матурлык, батырлык, романтик күтәренкелек, иленә, халкына тугрылык, үлем һәм яшәү фәлсәфәсенең төрле яссылыкларда бирелүе, гомумкешелек идеаллары булып яңгырый һәм шуның белән дөнья халыкларының күңелен яулый. Әмма Җәлил иҗаты бервакытта да милли җирлектән аерылмый. Әдипнең гаҗәеп бай сүрәтле, аһәңле теле, фольклордан, мифологиядән килүче образлар, символлар, традицион шигырь калыплары, үзенчелекле шигъри хатлар, аларда якыннарына мөрәҗәгать иту алымнары, ижатында халыкнын киләчәге өчен борчылуы, тирәнтен уйлануы һ.б. - болар барысы да әлеге бай мирасның милли асылын, халыкчан рухын билгели.

Кулланылган әдәбият:

1. Татар урта мәктәпләре өчен әдәбият программасы (5-11 сыйныфлар) Төзүзеләре Ф.Хатипов, А.Әхмәдуллин.-Казан: Мәгариф,2000ел.

2. Муса Җәлил. Әсәрләр.-Казан: Мәгариф, 2004._271 б.

3. Муса Джалил:творчество и подвиг. Взгляд из 20 века/ Сост.Х.Ю. Миннегулов, Н.М. Юсупова.- Казань: КФУ, 2006.-150с.

## **XX-**XXI гасыр **әдәбиятында кеше һәм табигать проблемасы.**

***Әхмәтшина Зәлия Динар кызы,***
***җитәкчесе-Хәйруллина Рәдисә Ахун кызы,***
***I курс, ЛД-9-11 төркеме,***
***ДАҺББМУ "Казан төзелеш көллияте"нең***
***"Бакча-парк һәм ландшафт төзелеше"белгечлеге.***

Кеше белән табигать аерылгысыз. Язучыларыбыз болай гына ниндидер фаҗигале яки шатлыклы вакыйгаларны, кешенең күңел халәтен, кәефен сурәтләгәндә табигатькә мөрәҗәгать итмиләрдер инде. Табигать күренешләре кеше кичерешләренә я тәңгәл китереп, яисә капма-каршы куеп тасвирлана. Табигать куренешләре әсәрләрне тулыландыра һәм баета. Моңа ирешү өчен язучыда күзәтүчәнлек, сүз-буяуларны дөрес куллану, табигатьне әсәрнең бер кисәге итеп бирә алу сәләте булырга тиештер. Татар әдәбиятында һәрбер язучы үзенчәлекле. Мин үз алдыма XX-XXI гасыр язучыларының иҗатында табигать темасыны чагылышын өйрәнү, кызыклы мәгълүматлар туплау максатларын куйдым. Шул максатка ирешү өчен фәнни китаплар, дәрсеслек, газета-журналлардан материаллар тупладым.

Өйрәнү объекты итеп мин язучыларның әсәрләрен алдым. Ә өйрәнү предметы итеп язучылар иҗатында табигать темасының чагылышын сайладым.

Татар әдәбиятында кеше белән табигать мөнәсәбәтләрен күрсәткән әсәрләр куп. И.Юзеевның "Бакчачы турында баллада"сында бакчачы башта матурлык тудыра, ә аннары ялгышлык эшли, еланнарны үтерәм дип табигатькә төзәлмәслек яра сала. Ә.Баянов, үзенең "Сәяхатнамә" әсәре белән табигатьне, авылны һәм халык әхлагын, гореф-гадәтләрен яклап, аваз салып, җәмәгатьчелекне сискәндереп җибәрде. Ул, беренчеләрдән булып, яңа шәһәрләр, ясалма диңгезләр төзүнең, тирәлекне пычратуның киләчәк өчен нинди куркыныч алып килүен искәртте, шигъри йөрәге белән шул афәтләргә каршы күтәрелде. Менә шул вакыттан соң инде кешеләр аңында һәм үз-үзләрен тотышында табигатькә карашларын узгәртә, сәясәтчеләр табигатьне саклауга кагылышлы законнар кабул итә башлый.

Шәүкәт Галиев исә, табигать турындагы шигырьләрендә гел эзләнүдә. Әгәр элегрәк нигездә табигатьнең серләрен ачу, аны танып-белү, өйрәнү игътибар үзәгендә торса, хәзер

инде автор мондый карашны ачкан шигырьләр белән генә чикләнми. Ул табигатькә сак караш тәрбияли торган шигырьләр иҗат итә. “Нефть таптык”, “Тургайлар министрына хат” – әнә шундыйлардан. Яр читеннән агып яткан нефтьне күргәч, бала иң элек, “нефть таптым!” дип уйлый. Тик бу олыларның саксызлыгы аркасында аккан җир мае булып чыга. Шундый саксызлык аркасында табигать күпме зыян күрә:

Балык та юк, бака да юк.

Елга өсте тынып калган.

Керәшәләр китkән ярдан,

Елга ялгыз торып калган.

Ә менә самолеттан басуларга агу сипкәч, кырда тургайлар юкка чыга. Шуңа борчылып “тургайлар министына хат” яза. Автор баланы кешелекне борчыган олы, тирән каршылыкларына да алып керә, шулар турында уйланырга этәрә, кечкенәдән үк табигатьне саклаучы, аны яратучы кешелекле кеше тәрбияләргә омтыла.

Г.Нәбиуллин иҗатында пейзаж лирикасы зур урын тота, ул табигатьне хезмәт белән бәйләп карый. Бу хәл аңлашыла да, чөнки автор авылда яши, шуңа аның кечкенә героеның язмышы да туган туфрактан аерылгысыз. Автор Татарстанның урман-елгалары, тау суларының шигъри картинасын рәсемләп, баллада, авыл җиренә мәхәббәт тәрбияли.

Табигать - иң борынгы һәм киң урын алган темаларның берсе. Ул фольклорның барлык төр жанрларында диярлек бар . Табигать, аны саклау, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы турында татар халык авыз иҗатында үрнәкләр бик куп. Бу темага карата мәкаль һәм әйтемнәрнең генә дә саны дүрт меңгә якын. Моннан күренгәнчә, һәртөрле хуҗалык эшчәнлегендә кеше табигать белән тыгыз бәйләнештә торган , табигать хисабына яшәгән, аның мул – имин һәм сау-сәламәт тормышы табигатьнең тормышына һәм яхшы саклануына бәйле булган. Димәк, халык борынгыдан ук табигать белән игелекле, якын бердәмлек, мул - имин тормышның беренче шарты булуын аңлаган. Ягъни яшәү өчен, кеше дә изге хисләр тәрбияләү өчен табигать кирәк. Шуңа күрә үзен белә башлаганнан бирле кеше табигатьне өйрәнгән, һәм шул нигездә аның бу өлкәдә авыз иҗаты педагогикасы, гореф –гадәтләре барлыкка килгән.

Еш кына әсәрләрнең конфликты да геройларның табигатькә төрлечә карауларына нигезләнә. Фәнни эшебездә әнә шул мәсьәләләр тикшерелде. Без максатыбызга ирештек тә.

Ахырдан сүзне Заһид Фәйзи сузләре белән тәмамлыйсы килә: “Комсызланып табигатьне талау, башкалар өлешенә кереп баерга тырышу - бик зур җинаять ул. Табигатьтә һәр җан иясенә тереклек итәрлек һәм үзенең дәвамын калдырырлык кына байлык һәм мөмкинлек бар. Шуңа күрә, һәр җирдә кеше аннан үзенә кирәк кадәр генә алырга һәм

башкаларны да шуңа өйрәтергә тиеш. Табигатьтән берне аласың икән, аңа икеләтә кайтарырга кирәк. Шулай гына саклап калып була аны.

Кулланылган әдәбият:

1. Урманчеев Ф.И. Развитие татарского фольклора в контексте «Запад-Восток». Очерки по истории татарской культуры. – Казань: Фикер, 2004. – 624б.

2. Рус мәктәбендә татар балаларына  әдәбият укыту. – Казан: Мәгариф, 2007. -112б.

3. Әдәбият, 11нче класс өчен дәреслек. –Казан: Мәгариф, 2005, - 397б.

## “Табигать, кеше, әдәбият- үзара бәйләнеш”

***Бәдртдинов Динис Филюс улы***
***“Нефть химиясе һәм нефть эшкәртү техникум”***
***1нче курс студенты.***
***Зәйнәгово Солтания Газизҗан кызы***
***Татар-әдәбият укытучысы***

Соңгы унъеллыкларда “экология” дигән сузе күбрәк фән гыйбарәсенә кергән дип санала. Хәзер “экология” сузе барлык массакүләм мәгълүмат чараларында еш кына очраша. Инде күптән табигать проблемалары галимнәрне генә түгел, язучыларны да борчый.Табигатьнең матурлыгы электән бирле хәзерге вакытка кадәр язучыларны шигырьләр һәм прозалар язарга мәҗбүр итте. Язучылар табигатне исән дип саныйлар.

Үз шигырьләрендә язучылар табигатьнең матурлыгы турында гына түгел, ә табигатне сакларга кирәген һәм сакламасаң нәрсә булырга мөмкинлеген сөйлиләр. Табигать ул - безнең әйләнә –тирәбез, туган җиребез, туган ягыбыз, суларын эчеп туймаслык чишмәләребез, су коенган инешләребез, җиләкле аланнарыбыз, урман – кырларыбыз. Җәнлекләр, үсемлекләр, кошлар дөньясы.

Табигать, кешегә бөтен кирәкле нәрсәне бирә. Тик еш кына без аның кадерен белмибез, уйлап та тормыйча, берни дә алмашка бирмичә, чәчәкләрне җирдән өзәбез. Бу вак-төяк кенә диеп безгә тоела,  чөнки яңа үсәр уйлыйбыз без. Якларга карасак, сизергә авыр түгел- ничек табигать бик гүзәл булганын. Безгә аның кадерен белергә генә кирәк ! Ә менә без шушы матурлыкның кадерен беләбезмени? Соклана беләбезме без табигать матурлыгына? Мөгаен, юктыр. Чөнки язга чыккач, кар эри башлауга, кыш буе теләсә кая ташланган чүп-чар күренә башлый. Бу бит кешеләрнең әхлаксыз, шапшак булуын күрсәтә.

Табигать безне үзенең искиткеч заманнары белән сөендерә. Салкын кыш, яшел яз, кояшлы җәй, алтын көз. Булары барсы да табигать ярдәмендә гүзәл.

Туган җирне саклау - ул һәр кешенең бурычы. Без табигать балалары, ә табигать безнең хуҗабыз! Моны беркайчан да истән чыгармыйк һәм табигатьнең кагыйдәләренә,

кануннарына каршы килмичә аңа буйсыныйк!Табигатьнең шигъри образы бала күңелендә бик озак саклана шуңа күрә кечкенәдән үк ата-аналар балаларын табигатьне яратырга икәнлеген өйрәтергә тиешләр.

Электән үк кешеләр, -табигать телен яхшы аңлаган, күзәтүләр нигезендә табигать серләрен ачыклый алган. Бу белемнәр атадан балага, бер буыннан икенче буынга мирас итеп калдырылган. Шул белемнәрне язучылар җыр, шигырь, мәкаль булып язганнар. Мәсәлән:

1)Урманда агач күп, сайлый башласаң яраклысы юк.

2)Яңгыр үткәч, артыннан ябынча белән йөгермиләр.

3)Чык суы матур булса да, сусын кандыра алмассың.

Табигатне ана дип чагыштырасы килә, чөнки әниләр бөтен мәхәббәтләрен, байлыгын балаларына бирә. Табигать тә шулай бит. Табигать безгә матурлык кына бирми. Без аның байлыкларыннан күп кулланабыз.

Кайбер шагыирьләр табигатьнең ел фасыллары турында шигырьләрдә язалар.Бу җәһәттән Лилия Салахутдинованың “Табигатнең матурлыгы” дигән шигыре үрнәк булып тора:

Минем өчен матурлык ул:
Көзнең төсле яфрагы,
Чишмәләрнең чылтыравы,
Каеннарның шаулавы!
Миләшләрнең кызыл чагы-
Көзнең октябрь ае.
Кырау төшеп, иртән, җирне
Каплап торган бозлары.
Яңгырның шыбырдавы —
Көзнең төп матурлыгы!
Бармы икән, табигатьтә,
Матур чак моннан ары!?

Бу шигерне укыгач, салкын яңгырлы көннәр дә табигатнең матурлыгы ярдәмендә гүзәл булганын, әйтергә мөмкин.

Кешегә туу белән табигать изге-хисләр бүләк итә. Мәхәббәт, ватанны саклау, мәрхәмәт хисләр әти-әниләрдән, бәлки үстергән кешеләрдән бәйле. Гаилә нинди тәрбия бирүдән, кешенең шундый хисләре булачак. Мәхәббәт ул — сөю, ярату. Ләкин ул хисләр гаиләдән дә башка килергә мөмкин. Мәсәлән, мин мәктәптә укыган дәвердә матурлыкны күрергә һәм мәхәббәт хисләрен тоярга өйрәндем.

Кайбер кешеләр үз хисләрен кәгазьгә ашыралар, аларны язучылар дип йөртәләр. Шигырьләр язырга ул авыр эш, язар өчен күп белем кирәк. Мин үзем дә шигырьләр язганым бар:

Яратам бугай мин сине, яратам.
Сине генә уйлыйм,сиңа гына карыйм
Синең зәңгәр күзләреңне,
Синең кара чәчләреңне,
Күз алдымда йөртәм
Төшләремдә күрәм
Яратам бугай мин сине,яратам!

Табигать, кеше, әдәбият- бербөтен.

Табигать, кеше, әдәбият- бер тулы. Табигать кешене барлыкка китерткән, ә кеше әдәбиятны. Ул бөтенесе дә үзара бәйле.

## XX-XXI гасырда татар әдәбиятында табигать белән кеше арасындагы бәйләнеш.

***Белянинова Ксения Александровна***
***ученица 8 класса***
***МБОУ “ Николаевская ООШ”***
***Руководитель: Фуреева И.Р.***
***учитель татарского языка и литературы***

“Табигать кеше белән авырый.
Кеше Җирне газанланучы тере
җан иясе дип күрә белмәде.”

Табигатьнең пычрануы турындагы сүзләрне безгә еш ишетергә туры килә.Чыннан да планетабызның экологик торышы көннән-көн начарая.Җирдә төче су запасы кими,ә без эчә торган суның ,сулый торган һаваның сыйфаты бик түбән. Зур шәһәрләрне завод-фабрикалар, машиналардан чыккан газлар каплаган. Кешеләр үзләре эчкән суларны,сулаган һаваны пычраталар.Табигатьтә еш кына экологик бәла-казалар булып тора.Аларны булдырмас өчен,кешелек дөрес юлны сайлап алырга һәм бу эшне һәркем үзеннән башларга тиеш.

Татар теле дәресләрендә без төрле хикәяләр,текстлар,әкиятләр укыйбыз һәм без ул текстлардан,хикәяләрдән яңа мәгълүматлар үзебез өчен алабыз. Безнең дәреслекләребездә зур урын бирелгән кайбер шәхесләребезне аерым әйтеп китү кирәктер:Г.Тукай, А.Алиш, Ш.Галиев, һәм башкалар шигырьләрендә җәнлекләрне, кошларны, бөҗәкләрне яратырга, аларга мәрхәмәтле, шәфкатьле булырга өнди, нәфис сүз, сәнгать чаралары ярдәмендә Җир-

анага игелек, хөрмәт хисләрен уяталар, шигъри бизәкләре белән табигатьнең гүзәллеген ачып, кешелекнең экологик һәлакәт каршында торуын да искәртәләр.Күптән тугел мин бик матур әкият укыдым.Әкиятнең исеме "Безнең өй".Бу әкияттә бөтен җанварлар дус һәм тату яшиләр, алар бергә бер зур өй төзегәннәр, бөтен эшләрне бергәләп эшләгәннәр.Ләкин бергә яши башлагач, һәр җәнлек үзенчә яши башлый, үзенә кирәк әйберләр ташый башлый, өйнең эче чүпләнә..Өйләре авырлыктан җимерелә һәм җаварнлар төрле якка чабалар .Мин уйладым ни өчен аларның өйләре җимерелгән икән? Өйләре яңа һәм әйбәт булган, ләкин һәр җанвар үзенә кирәкле эшләр генә эшләгән.Бакалар үз бүлмәләренә су тутырганнар, кондызлар бүрәнәләрне кимергәннәр, куяннар үзләре торган җиргә кишер тутырганнар.Алар үзләре өчен генә әйбәт булсын дигәннәр, калган җанварлар турында уйламаганнар.Минем уйлавымча, үзең турында гына уйларга кирәкми , җир шарында без бергә яшибез. Җир шары-ул безнең өй .Әгәр җир шарын без бергәләп сакламасак, бергә аны җыештырмасак, чүпләмәсәк , өебез җанварларның өйләре шикелле җимереләчәк. Мин күз алдыма китердем ниһәтле күп чүп-чар безнең җиребез өстендә ята, нинди генә калдыклар заводлар һәм фабрикалар ташлыйлар.Һәр кеше уйлый табигатебез үзе –үзен саклый һәм чистарта ала. Ләккин яшел бишегебез – Җир анабыз үзенең табигый тотрыклыгын мәңге саклар дип ышану, хаталы фикер.

Безнең дәреслекләребездәге материалларда елдан ел экологик проблемалар күбрәк күтәрелә башлый, без бит табигать белән бик тыгыз элемтәдә яшибез, шуңа күрә табигатьнең язмышын кеше дә хәл итә, ул экологик тотрыклылыкны саклап калырга бурычлы.Әдәбияттәге булган әсәрләр җир-анага игелек, хөрмәт хисләрен уяталар, шигъри бизәкләре белән табигатьнең гүзәллеген ачып, кешелекнең экологик һәлакәт каршында торуын да искәртәләр.

Безнең табигатьнең чыдамлылыгы күпмегә җитәр? Җир күпмегә түзәр? Моны беркемнең дә уйлаганы юктыр, беркемнең дә исәпләгәне юктыр. Без дәресләрдә бергәләп сөйләшәбез һәм барыбыз да бер уйга киләбез " Ә мин ничек табигатькә булыша алам? " Мин моның турында уйлыйм да , минем исемә төшә И. В. Мичуринның " Без табигатьтән мәрхәмәт көтәргә тиеш түгел, безнең бурыч – аңардан тартып алу". Ә хәзер киресенчә "Без табигатькә мәрхәмәтле рәвештә үзебез бирергә тиешбез". Без табигать патшасы, ә патша мәрхәмәтле булганда гына озак яши, хезмәт итә ала.

Табигать – безнең бүгенге байлыгыбыз гына түгел, киләчәгебез дә. Аның байлыгын бездән соңгы килгән буыннарга да калдыру безнең уртак бурычыбыз.

Кулланылган әдәбият.

*1.Билалова Ә.Г., Гыймадиева Н.С. Әдәбият дәреслекләре буйлап. – "Яңалиф" нәшрияты. – 2006*

*2.Голованова Г.Н. Защищай, береги, умножай. Москва. Молодая гвардия.1999г*

*3.Хәйдарова Р.З. "Татар теле" 7 нче класс дәреслеге.*

*4.Фадеева Е.О., В.Г.Бабенко Экология. Москва.2002г.*

*5.Ягодин.Г.Н. Проблемы экологического образования.. Вестник высшей школы. 1991г.*

## Человек и природа в повести Ч. Айтматова «Плаха»

*Билалова Анастасия Тагировна*

*Рук-ль: Янова Юлия Александровна*

*1 курс, ГАПОУ «Мензелинский педагогический колледж им. М. Джалиля»*

Тему взаимоотношений человека и природы поднимали многие авторы на протяжении всего существования литературы. И 19-20 века, когда связь человека и природы обострилась уже до экологического кризиса, также не обошли эту проблему. Но увы, нередко ухудшение экологической ситуации продиктовано человеческой жадностью, корыстью и материальной выгодой.

Одним из замечательных писателей 20 века, который затрагивал в своих произведениях вечные вопросы добра и зла, человека и общества и, конечно же, человека и природы, является Чингиз Айтматов. С предельной глубиной интересующую нас тему поднял Чингиз Айтматов в своём произведении «Плаха». В этом произведении автор показал не только радость за удивительный мир природы, который живёт по своим законам, но и боль, переживания, которые невольно вызывают люди своим варварским отношением к природе [3, с. 35].

Итак, основная тема многосюжетной повести «Плаха» - это проблема экологии и взаимоотношений человека с природой. Посмотрим, как показаны в повести эти отношения, и о чём хочет предупредить нас автор.

С огромным увлечением и в то же время с щемящей болью мы наблюдаем в повести жизнь двух диких животных, волка Ташчайнара и синеглазой волчицы Акбары, которые живут в степи своей жизнью и по своим законам. Именно они олицетворяют собой природу в романе. Очень интересно,

как Айтматов показывает нам, что животные тоже мыслят и чувствуют, имеют между собой определённые отношения, хотят иметь продолжение своего рода…Всё больше и больше узнавая внутренний мир этой преданной волчьей пары, поневоле испытываешь к ней неподдельный интерес, а в определённых ситуациях даже сердце сжимается.

Скитания волков начинаются с того, что они вынуждены покинуть свои степи и уйти в горы, что уже является нарушением законов природы, ведь волки в горах не живут. Более того, такое решение пара принимает вследствие того, что они в числе сайгаков попадают в облаву, которую на них устраивают люди. Очередное нарушение природного равновесия – человек и зверь поменялись местами, теперь для животных человек – враг. Далее беда, которая постигла трёх волчат Ташчайнара и Акбары, а именно они были забиты людьми в погоне за выполнением продовольственного плана. Но это снова нарушает законы природы. Животные должны продолжать свой род! В конце концов совершается третье преступление, которое и привело к столь трагичной развязке, в центре которой оказался уже сам человек. После того, как волки наелись мяса убитого яка, они возвращаются в нору, где уже в третий раз оказываются похищенными их волчата. Снова мечты волков оказываются разбитыми, и снова в эпицентре их трагедии – человек! И, пожалуй, неудивительно, что начинается война не на жизнь, а на смерть. Волки решают своим жестоким «кровавым возмездием» восстановить справедливость в столь жестокой борьбе за продолжение своего рода [2, с. 52].

Эта трагическая история волчьей пары предупреждает человечество о том, что жестокость и неразумное отношение человека к природе, ко всему живому рано или поздно приведёт к беде. Сжигая степи, мы сжигаем свой дом, а убивая животных, мы убиваем прежде всего самих себя и своих детей [4].

Пара волков отомстила людям, похитив ребёнка Бостона. Акбара думала, может быть, дитя человеческое заменит ей её дитя? Но и ребёнка не успевают спасти. Финал повести известен – Бостон стреляет в волчицу, которая на спине уносила его сына всё дальше и дальше, попав при этом и в мальчика. Далее

убивает Базарбая, действия которого и повлекли за собой эту плачевную цепочку событий.

Такова нравственная цена, которую человек платит за нарушение нравственных норм.

Таким образом, вспомнив и проанализировав повесть Ч. Айтматова «Плаха», рассмотрев в ней одну из линий взаимоотношений человека и природы, мы пришли к следующим выводам. Во-первых, автор доказывает нам, что, когда люди уничтожают природу, они уничтожают человеческое в себе самом. Достаточно вспомнить впечатление Акбары, когда при облаве она увидела лицо человека, которое «явилось так близко и так страшно, что она ужаснулась» [1, с. 43]. Это был страшный зверь с бессмысленной жаждой убивать! Во-вторых, природа мстит человеку – из-за жестокости одних страдают ни в чём не повинные люди.

«Плаха» - не только затягивающее читателя своим необычным сюжетом произведение, но и очень актуальное. Страшное. Здесь Чингиз Айтматов призывает нас как можно скорее и увереннее встать на путь истины, чистоты и добра во всех их проявлениях - будь то природа, любовь или отношения между людьми.

Список литературы

1. Айтматов, Ч. Т. Восторжествует разум / Ч. Т. Айтматов // Трезвость и культура. - 2004. - №7. - С. 43.

2. Обсуждаем роман Ч. Айтматова «Плаха» // Студенческий меридиан. - 2003. - №10. - С. 48-53.

3. Чубинский В. И снова о «Плахе» / В. Чубинский // Нева. – 2006. - №8. – С. 35-36.

4. http://www.km.ru/referats/0788E9484F564065A121B34947984003

## Человек и природа в литературе 20-21 вв.

***Валиева Элиза Ильдусовна***
***Синагатуллина Люция Абдулхатовна***
***8 класс МБОУ «Матвеевская ООШ»***

Природа… Это слово у каждого человека вызывает свои определенные ассоциации. Для кого-то природа – это уютные семейные посиделки у берега реки, для кого-то это прогулки по густой чаще леса, наслаждение пением птиц и журчанием ручья, а для кого – то сбор грибов-ягод, рыбалка, охота. Каждый относится к природе по-разному, но, как мне кажется, нет ни одного человека, который был бы к ней равнодушен.

Природа испокон веков играла важную роль в жизни человека. Наши предки были тесно связаны с природой, они не отделяли себя от природы, они полностью зависели от нее. Первобытные люди возводили явления природы в ранг богов, в древнем мире лишь занятия собирательством, земледелием и охотой позволили людям выжить. По мере совершенствования социальной жизни людей менялось отношение человека к природе. Люди все больше изолировались от влияния окружающей среды, взаимоотношение между природой и человеком стало опосредованным.

Значение природы в жизни человека трудно переоценить. Без воздуха, воды, растений и животных существование человека было бы невозможным. Человек использует природные ресурсы для удовлетворения своих материальных потребностей, в частности занимается добычей полезных ископаемых, использует природный газ, руду, уголь, нефть и металлы для промышленных целей.

Велика роль природы и для духовного развития общества. Окружающая среда благоприятно влияет на психологическое состояние человека, дарит душевное спокойствие, поднимает настроение, позволяет отвлечься от шумных мегаполисов, служит источником вдохновения для творческих личностей. Много произведений искусства посвящено природе.

Особую роль в литературе занимают произведения, посвященные взаимодействию человека и природы. Примером служит произведение Бориса Васильева «Не стреляйте в белых лебедей». Главным героем данного произведения является Егор Полушкин, который от чистого сердца любит природу, относится с ней с глубоким признанием и уважением. Он умеет чувствовать природу, понимает ее, любуется ею, делая это без потребительских целей. Он не только сам стремится сберечь природу, сохранить ее в первозданном виде, но и передает свои знания о природе своему сыну Коле, учит его оберегать окружающую среду. Егор считал, что человек является не царем природы, а лишь старшим ее сыночком. Но не

все разделяли его положительное отношение к природе, осуждали его стремление не вторгаться в живой мир, считали, что Егор не приспособлен к жизни. Его друзья- шабашники даже били его за излишнюю, на их взгляд, порядочность по отношению к природе. Но Егор не таил ни на кого обиду, лишь приговаривал «Стало быть, так, раз оно не этак». [1, с. 134]

В противовес положительному образу Егора Полушкина автор приводит образ Федора Бурьянова, который уничтожает природу, истребляет рыбу тоннами, убивает лебедей ради наживы и материального обогащения. Бурьянов, совершая ужасные поступки, черствеет душой, становится равнодушным к своей работе, к природе, окружающим людям, становится способным даже поднять руку на человека. В завершении повести главный герой Егор Полушкин погибает от рук тех, кто относится к природе потребительски. К счастью, подрастающий сын Егора Колька сможет заменить отца, будет уважать и любить природу, выполняя заветы отца. Борис Васильев в данном произведении предупреждает нас, читателей, что равнодушные к природе люди опасны и жестоки. Их варварское отношение к природе является следствием их духовной неразвитости. Действия людей, считающих себя властелинами окружающего мира, ведут к уничтожению всего живого. И только уважение к природе, желание благоприятно на нее воздействовать приводит к гармоничному развитию окружающей среды, доставляет радость человеку, приносит душевное спокойствие. Автор подводит нас к мысли о том, что человек и природа тесно взаимосвязаны, являются частями одного целого, взаимно влияют друг на друга.

Примером положительного взаимодействия человека и природы является произведение В. Шукшина «Старик, солнце и девушка». Дед, проживающий в деревне, учил молодую девушку-художницу, приехавшую из города, видеть прекрасное в природе. Внуки старика разъехались, сын и невестка лишь «терпели» его Единственное, что согревало душу старика, была любовь к природе. Каждый вечер старик приходил на одно и то же место, чтобы полюбоваться заходом солнца. Он с восторгом описывал меняющиеся краски заката. Благодаря старику и девушка научилась подмечать, что солнце было необыкновенно большим, а речная вода в лучах заходящего солнца была похожа на кровь. Девушка очень удивилась, узнав, что все необыкновенные красоты природы ей описывал слепой человек. Просто он настолько любил родную природу, что, даже ослепнув, продолжал приходить «любоваться» ее красотой и «видел» ее. И не просто видел, а раскрывал красоту природы и другим людям. Автор данным рассказом показывает нам, что природа прекрасна, нужно лишь научиться видеть ее. А люди, наделенные особым чутьем и любовью к родной природе, могут помочь нам подмечать ее красоту.

Обобщая все вышеизложенное можно прийти к выводу, что человек и природа неразделимо связаны друг с другом. Связь с природой позволяет человеку развиваться

духовно. Природа – дом для каждого человека, а для литературы – это ценность, которую призывают сохранять великие мастера слова.

Список литературы

1.Васильев, Б.Л. ««Не стреляйте в белых лебедей»/ Б.Л.Васильев.- Марийское книжное издательство, 1982.- с.416

2.Шукшин, В. «Рассказы» / В.Шукшин. - Ленинград: Детская литература,1979.-381 с.

## Рафаил Төфәтуллин иҗатында кеше һәм табигать бәйләнеше

***Валиуллин А.А. 1 курс ГБПОУ "Мензелинский сельскохозяйственный техникум"***
***руководитель: Шайхатарова Э.Г.***

2017 ел Татарстанда Экология һәм иҗтимагый киңлекләр елы буларак игълан ителде. Бу хакта Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Дәүләт Советына еллык юлламасы вакытында җиткерде. Республикада табигатькә мөнәсәбәт, аны төрле яклап саклау, яклауның дәүләт тарафыннан төрле программалар, чаралар ярдәмендә тормышка ашырылуы әйләнә - тирәгә мөнәсәбәтнең уңай якка үзгәрәчәгенә ышаныч һәм өмет уята.

Ә бит бу үткен актуаль мәсьәлә, гомумән, бүген генә тумады. Сәнәгать тармагының үсүе Җирнең тереклек дөньясына зур йогынты ясый: табигать байлыклары кими бара, үсемлек һәм хайваннарның күп төре юкка чыга. Экологик белемнең җитәрлек булмавы әйләнә - тирәлектә күрелмәгән үзгәрешләргә китерә. Россия Федерациясенең "Әйләнә-тирәне саклау турында"гы Законы өзлексез экологик белем бирү системасын булдыруны күз алдында тота. Аның максаты - җәмгыятьтә һәр кешенең, халыкларның экологик культурасын үстерү. Кешелек дөньясы мәдәниләшүнең югары биеклегенә күтәрелде. Инде кеше табигатьтән файдаланып кына кала алмый, ул аның яклаучысы, яңадан тууда, күтәрелүдә булышчысы да булырга тиеш. Бүген кеше табигатькә бәйле дип әйтү генә дөрес булмас иде, чөнки табигатьнең язмышын кеше дә хәл итә, ул экологик тотрыклыкны саклап калырга бурычлы. Язучылар, әдипләр тарафыннан кеше һәм табигать арасында үзара мөнәсәбәт, бәйләнеш, адәм баласының табигатькә йогынтысы инде күптән әдәбиятта актив яктыртыла. Табигать һәм шәхес бердәмлеге, гигант төзелешләр, җир асты ятмаларын табу - экологик тема туугa этәргеч булып, рухи ярлылыкның табигатьне юкка чыгаручы көч булуы XX – XXI гасыр татар әдәбиятында үзенчәлекле урынны алып тора. Язучылардан Нур Әхмәдиев, Рафаил Төхфәтуллин, Фәүзия Бәйрәмова, Нәбирә Гыйматдинова, Гомәр Бәширов, Аяз Гыйләҗев, Радик Фәизов, Эдуард Касыймов үз әсәрләре аша кеше һәм табигать

арасында үзара мөнәсәбәтне, адәм баласының табигатькә йогынтысын төрле вакыйгалар белән бәйләп укучыларга җиткерергә омтылдылар.

Илдар Юзеевның “Сандугачлар килгән безгә” пьесасында урманчы Хәмзинның табигатькә мәхәббәте, табигать һәм кешенең бербөтен булып яшәвен исбатларга омтылыш күзәтелә, “табигать матурлыгы” һәм “кеше күңеленең сафлыгы” төшенчәләре янәшә куела. Әхсан Баяновның “Сәяхәтнамә” поэмасында туган туфракка, гореф-гадәтләргә, телгә адәм баласының мөнәсәбәте, яңа шәһәр, ясалма диңгез төзүнең киләчәк өчен куркыныч булуы, лирик геройның шул афәткә каршы көрәше темасы алгы планга чыга. Поэмада кеше һәм табигать мөнәсәбәтен фәлсәфи тирәнлек белән сурәтләү, табигатьне саклау мәсьәләләре үткен итеп куела. Равил Фәйзуллинның “Куян ату”, Мөдәрис Әгъләмовның “Сөйли ак каен”, ”Учак урыннары”, ”Тагын бер кош”, Роберт Миңнуллинның “Нигә елый каен?” шигырьләрендә битарафлык һәм саксызлыкның табигать дошманнары булуына басым ясала.

Мин үземнең чыгышымда Р.Төфәтуллин иҗатында кеше һәм табигать темасына киңрәк тукталасым килә. Табигать һәм кеше... Алар гел янәшә булган. Табигать кешенең холык – фигылен үзгәрткән, түзем булырга өйрәткән. Шушы шартларда җиргә, әйләнә – тирәгә гашыйк кешеләр формалашкан. Р.Төфәтуллин да шундыйлардан. Ул табигатьнең гүзәллеген түбәннән күтәреп чыгара, кешене җиргә карарга өйрәтә. Хикәяләрнең исемнәре үк бу турда сөйли: “Шомырт нигә елый?”, “Тиен белән сөйләшү”, “Елга аръягындагы йорт”, “Кыңгырау чәчәк”, “Алсу болытлар”, “Бөтнек үләне исе” һ.б. “Шомырт нигә елый?” хикәясендә төп фикер кешеләрнең табигатькә карата төрле мөнәсәбәтләре турында. Кешелек табигатьнең матурлыгыннан, байлыгыннан файдалана. “Җәй азакларына таба без шомыртыбызга кунакка киләбез. Дустыбыз безне, авызны бөрештерсә дә, чем кара җимешләре белән сыйлый” ди автор. [2,168б.] Ләкин кешеләр үзләре үк шул матурлыкка зыян да салалар: агачларны сындыралар, матур – матур чәчәкләрне өзәләр, елга – күлләрне пычраталар. “Юк, чәчәкләрен коймаган шомырт, аны талаганнар. Ботагы – ботагы белән сындырып алып, кул җитәрдәй бөтен чәчәкләрен урлап киткәннәр.” [2, 168б.] “Бу юлы шомыртның канатын каерып кына калмаганнар, аның бугазына ук ябышканнар. Инде ике канаты да каерылган, бөтен тәне әрнүле шомыртның. Агачның һәр ботагында җемелдәгән тамчылар шомыртның күз яше иде.” [2, 170б.] Кеше табигать байлыкларын талаучы гына булып калмасын иде дигән фикер уздырыла хикәядә, автор җитди проблемалар турында уйланырга чакыра. Күләм ягыннан зур булмаган “Тиен белән сөйләшү” хикәсендә автор урман серләренең тирәнлегенә төшенә. Бөдрә каеннар, нечкәбил усаклар, зифа миләшләр, чикләвек куаклары – алар бер гаилә бит. Ипләп кенә лепелдәп пышылдашалар, күз җитүгә моңланалар. Р. Төхфәтуллин иҗатында әйләнә – тирәлек, табигатьнең төрле яктан ачылуын күзәтеп, мин язучыны Иван Сергеевич Тургенев (“Аучы язмалары”) белән чагыштырдым.

Табигатьне тирән аңлаган, маңгай күзе генә түгел, ә күңел күзе дә күрә алган кешеләр генә мондый нечкәлекләрне тоя ала дигән фикергә килдем.

Табигатьнең ярлылана баруына кем гаепле соң? Кемнән сорасаң да, мин түгел, диячәк һәм иңсәләрен сикертәчәк. Туган җиребез – барыбызныкы да. Туган туфрак та үзебезнеке. Аның урманнары да, елга – күлләре дә, кошлары да, җәнлекләре дә үзебезнеке. Туган җир безне тудырган, үстергән, тәрбияләгән икән, без дә аның алдында бурычлы түгелмени?! Табигать – Ана кебек ул. Якын иткәнне, хөрмәт иткәнне, үз иткәнне ярата. Табигать – Бала кебек ул. Кадерләгәнне, назлаганны ярата. Аның һәр каены, һәр талы, һәр торнасы, кыр казы, һәр былбылы исәптә. Аны саклау безнең намуска бәйләнгән. [1, 6б.] Әлеге юллар Роберт Миңнуллинныкы, аның “Сөнне сагыну”дигән публицистик хикәясеннән. Ничек килешмисең әлеге фикер һәм тирәннән ярылып чыккан җан авазы белән?!

Әдәбият исемлеге

1. Р.Миңнуллин Шагыйрь генә булып калалмадым. Публицистика, әдәби тнкыйть: - Казан: 1998.

2. Р.Төхфәтуллин Зәңгәр җилкән: - Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1988 – 176 б.

3. Р.Төхфәтуллин Сайланма әсәрләр. Ике томда . Хикәяләр, повестьлар: - Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1982 – 400 б.

## Югары Стәрле авылының табигый атамалары

***Вәлиев Ә.Н., Габдуллинн И.И. II курс, ГФ-151б төркеме;***
***Хайруллина З.В., Камалова З.Ә. татар телчеләре***

Татар әдәби теле бай һәм күпкырлы. Анда тормышның төрле якларын, күренешләрен бәяли, тасвирлый торган сүзләр, сүзтезмәләр бик күп. Ә менә туган җиребез, аның табигате, аны саклау, яклау өлкәсенә караган сүзләр һәм сүзтезмәләр бигрәк тә үзенчәлекле. Үземнең туган ягым тарихы, аның табигатен яктыртуга багышланган язмамны әзерләгәндә мин дә шактый кызыклы атамалар белән таныштым.

Стәрле авылына 1650-1670 нче еллар тирәсендә нигез салынган. Кайбер мәгълуматларга караганда Стәрлегә Алатырь, Чистай якларыннан күчеп килүчеләр нигез салган. «Үрганчар һәм Чертуш авылы татарлары (мишәрләре) 1660 нчы елларда служилый сословие булу сәбәпле (казаклы) Алатырь авылларыннан, Каргалы, Питрәксе авылларыннан үзләренең сотный князьләре белән күчеп утыртылганнар. Күчерелүнең сәбәбе – Минзәлә, Яңа чишмә арасында ныгытма төзүгә сәбәпче, Кама аръягында тынычлыкны саклау

максатыннан алар яңадан Алатырь тирәсенә хәзерге Рязань өлкәсе Касыйм шәһәре тирәсеннән күчерелеп утыртылганнар.

Ул вакытта Стәрлетамак волосте, Бөгелмә өязе, Самара губернасына караган. Кайбер язмалар Стәрле сүзенең килеп чыгышын ачып бирә сыман: «Стәрле сүзе яки елгасының исеме бүтәнчә «Стерляжья» дип аталган. Борынгыдан ук бу якларда балык тотканнар. Русчалап әйткәндә «стерлядь» чөгә балыгы, ә безнең елгага балык тотучылар үзләренчә «эстәрле» дип атамадылар микэн? Ягъни рус сүзе «стерлядь» элек болгардан яки төрки төркидәге бүтән халык теленнән алынмадымикән?»

Шушы бай табигатьле төбәгебезнең һәр аршин җире бүген дә безгә бик кадерле һәм якын. Шуңа да аларның атамаларының тарихын авылда олысы-кечесе белә һәм алдагы буыннарга өйрәтеп калдырырга тырыша. Шуларның берсе Малминка чокыры. Малминка чокыры исеме кайдан калган соң? Бу урында бер бай бикә яшәгән. Аның маллары бик күп булган, күп булып үрчегән. Шуңа күрә бу чокырны малбикә чокыры дип, ә халык телендә малминка чокыры дип йөртә башлаганнар.

Мәрдәнша хуторы. Бу хуторда Мәрдәнша хаҗи торган. Рус кырыннан алып Стәрле елгасына кадәр аның җире сузылган. Бик күп аты, сыеры, сарыгы булган. Шунда балалары белән ирләр, хатын-кызлар хезмәт иткәннәр. Монда хезмәт итәргә бик ерак җирләрдән килгәннәр. Шуңа күрә бу хуторны Мәрдәнша хуторы дип атаганнар. Бу хуторга күчү 5-елгы Сталыпин реформасыннан соң була. Рашайма басуы. Рашайма басуы исеме кайдан килеп чыккан соң? 1928 нче елда Казаннан Петр Борисов дигән инженер җибәрелә. Ул билгеләгән план буенча яшелчә сугару өчен корылган. Ю.Стәрледән Сөендек авылына хәтле сузылган бу 5 км каналны читтән китереп тә, авыл кешеләренең кул көче белән дә казылган. Сөендек янындагы басуны шул еллардагыча әле һаман «рашайми» басуы дип йөриләр. Дукшит җире. Дукшит исемле бояр белән, ә Баһау җире – Баһаутдин исемле бай белән бәйле. Моратбакый күле. Бу күл кырында балыкчы Моратбакый яшәгән. Күлнең балыгы күп булган, суы ярларыннан чыгып торган. Шуңа күрә бу күлне Моратбакый күле дигәннәр. Кантун бай җире. Монда Кантун исемле бай яшәгән. Ул Стәрле елгасына тегермән корган. Аның утырткан өянкеләре әле дә исән. Хәзерге сабантуй була торган агачлык та Кантун бай тарафыннан утыртылган. Ул Кантун байдан калган өянке агачлары. Шуңа күрә дә бу урынны Кантун җире дип йөртәләр. Мелиорация каналы. Бу каналны 1927-1929 елларда Мелиорация колхозы казыткан була. Канал Рашайма басуыннан алып Малминка чокырына кадәр сузылган. Шуңа күрә бу каналны колхозның исеме Мелиорация каналы дип йөртә башлаганнар. Николай тегермәне. Николай тегермәне. Монда Николай бай торган. Ул үзенә тегермән салдырган. Шуңа күрә бу урын Николай байның исеме белән Николай тегермәне дип аталган. Шırияздан җире. Монда Шırияздан исемле бай яшәгән. Ул бик күп җирләр

биләгән, аның җирләре кара туфраклы, бик уңдырышлы булган. Шуңа күрә бу урынны аның исеме белән Ширияздан җире дигәннәр.

Әйткәнемчә, авылыбыз табигате бик бай. Аны әйләндереп алган урман-күлләрне авылдашларыбыз белән бергәләп карап, чистартып, җыештырып торабыз. Исем-атамалары белән сезне дә таныштырып китүне артык булмас дип уйлыйм, чөнки алар, чын мәгънәсендә авылыбызның тарихи һәйкәлләре булып торалар.

Сөлекле күл исеме кайдан калган соң? Элекке вакытта бу күлдә сөлекләр күп булган һәм үрчегән. Шуның өчен бу күлне Сөлекле күл дип йөртә башлаганнар. "Аккошлы күл" исеме яғз көне аккошлар килүе, оя ясап, бала чыгарулары белән бәйле. Ык елгасына якын гына авылның көньяк-көнчыгышында бер күл урнашкан. Бу күлне Аяз күл дип йөртәләр. Чөнки аның төбе чиста, ташлары күренеп тора.  Зирекле күл буенда бик зур булып зирек агачлары үскән булган. Шуның өчен аны "Зирекле күл" дип атаганнар. Зирекле күлгә бик күп акчарлаклар килгән. Аның суы тирән, чиста булган. Күлле куак. Күл буенда кура җиләге куаклары күп булган. Алар җиләккә бик бай булганнар. Шуңа күрә бу куаклыкны күл буенда урнашканга күрә "Күлле куак" дигәннәр. Ике сырт арасында бер чокыр булып, анда бик күп ташлар булган. Шуңа күрә бу сыртны "Ташлыкүл сырты" дигәннәр. Мукшы күленең исеме анда мукшы милләтеннән булган кеше батып үлү белән бәйле. Бәди күле исеме кайдан калган соң? Совет хөкүмәте урнашканчы Таллыкта Стәрле елгасы буенда Николай исемле бояр торган. Ул байның йортлары булган. Ул тегермән тоткан. 1917 елда Бәдигөлҗамал исемле карчык Николай тегерменең паёк онын тартырга барган. Онны барып тарткан. Ул бәләкәй чана белән булган. Чана тартып кайтырга чыккан, бу яз көне буран булган. Ул адашып авылны үтеп көньякка менеп киткән, күлдә адашып үлгән. Шуның өчен бу күл "Бәди күле" дип аталган.

2010 нче елның октябрендә авыл җирлеге башлыгы Төхбәтуллин Дамир Нурулла улы сайлана. Аның тәкъдиме белән авылыбызда инде традиөиягә әйләнеп баручы күп төрле чаралар үткәрелә. Авыл урамнарын, урманнарны, елга-күлләрне, зиратларны чистарту-җыештыруга багышланган өмәләрдә читтә яшәүче авылдашларыбыз да бик теләп катнаша. Ә инде “Шәҗәрә”,”Урам”,”Чишмә юлы-яшьлек хатирәм” кебек бәйрәмнәр үткәргәндә авылыбыз гына түгел, ә район, республика дәрәҗәсендәге кунаклар да катнаша.

Чал тарихлы, тырыш халыклы, матур табигатьле шушы авылның бер баласы булуым белән мин чын күңелдән горурланам.

1. Галләмов Р.Ф. Русча-татарча тарих терминнарының аңлатмалы сүзлеге/ Р.Ф. Галләмов – Казан: Мәгариф, 2006

## “Җидегән чишмә романында экологик тәрбия мәсьәләләре”

***Башкарды: Вәлиева Зөбәрҗәт Динар кызы***
***Җитәкчесе: Шаһиева Дилә Габбас кызы***
***Курс: 3***
***Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте***

Табигатьне саклау, аны ярату, чистарту - бүгенге көндә дә актуаль темаларның берсе. Табигатькә карата битараф булу бүгенге көндә дә күренә. Шушы фаҗигане яктыртырга омтылган Гомәр Бәшировның “Җидегән чишмә” романы татар әдәбиятында күренекле әсәрләрдән санала. Туган җиргә, табигатькә, халыкка аның рухи хәзинәләренә чиксез мәхәббәт белән сугарылган әлеге әсәрдә табигать, милләт, әхлак мәсьәләләре күтәреләРоманда табигать һәм кеше арасындагы мөнәсәбәтләр социаль-әхлакый проблемалар арасында яктыртыла. Вакыйгалар Ык елгасы буендагы колхозларның берсендә бара. Колхоз рәисе Чурмантаев гасырлар буе тыныч кына яткан, авыл халкының туендыручысы да , җылытучысы да булган Алтынбикә тугаен, җимеш бакчасын сөрдерергә,Җидегән чишмәгә торбалар тоташтырырга тели. Бер төркем авыл кешеләре аның бу эшенә каршы чыгалар.

Әдип табигать образын традицион рухта, ягъни табигый дөнья мәгънәсендә генә яктыртмый. Ул табигатькә рухи мирас итеп тә карый, әсәрнең әдәбиятка алып килгән яңалыгы да шунда: “ Инешнең аргы ягыннан Ыкка кадәр җәелеп яткан әрәмәле , җиләк-җимешле, түгәрәк күлле зур болынны борынгы бабаларынча “ Алтынбикә тугае” дип йөртәләр.

Табигатьне ярату ул табигать күренешләренә соклану, аннан ләззәт алу гына түгел. Кешенең табигать серләрен аңларга омтылуы - үзе генә дә изге эш. Ул, кеше рухын тормышның вак-төяк ыгы-зыгысыннан, мәгънәсез буш хыяллардан, үз шәхесеңне генә кайгыртудан һәм башка җанлылык күренешләреннән арындырып, бөек максатларга әйди. Романда сурәтләнгән әрәмәлек , тугай , Җидегән чишмә - ата-бабаларыбызның рухи мирасы. Аларда халыкның моңы, күңеле, җаны, хәтере саклана. Шуңа күрә роман бүгенге көндә гаять актуаль һәм әһәмиятле мәсьәләләр күтәрә, дибез. “Җидегән чишмә” романында Г. Бәширов әхлак мәсьәләсен дә табигать образы аша бирә. Шуннан чыгып, персонажларны да өч төркемгә бүлеп карарга мөмкин. Аларның берсенә табигать сөючеләр, туган җирнең киләчәге өчен борчылучы чын патриотлар керә. Алар – яшь егет Гайнан , умартачы, сугыш ветераны Минһаҗ карт, сыер савучылар: Җәүһәрия, Язидә, район газетасы редакторы Дәрҗия, партоешма җитәкчесе Идрис, язучы Камил Дусаев. Гайнан - тормышка әле яңа гына яак баскан, җирне яратучы яшь буын вәкиле. Икенче төркемгә бүгенге көн белән яшәүче,

табигатьне бозучы, аны сакларга тырышмаучы бары матди чыганак кабул итүче, автор фикеренчә, әхлак ягыннан да түбән торган Чурмантаев , авыл советы рәисе Фәхриевлар керә. Әсәрдә Ризван Чурмантаевның шактый катлаулы, каршылыклы характеры яктыртылган, аның үзенчәлекле эчке дөньсы чагылдырылган.Әсәрдә бу ике образ арасында каршылык туа. Каршылыкның төп сәбәбе: аларның табигатьне төрлечә кабул итүе белән бәйләнгән. Табигатькә мөнәсәбәттә тагын бер төркем персонажларын аерып карарга мөмкин: кибетче Равил, агроном Фәйрүзә, комсомол секретаре Дилбәр шул рәткә керә. Алар табигатьне яраталар, әмма аны саклау өчен берни дә эшләмиләр. Аңлаган кешегә "Җидегән чишмә" җыры үзе генә дә бик зур рухи байлык бит. Минемчә, болар хәзерге тормышны да бизиләр.

Табигать әсәр сюжетына геройлар белән беррәттән катнашып бара. Биредә табигать юмарт, риясыз, ләкин үзен саклау мөмкинлекләреннән мәхрүм булган, кешеләр ярдәменә мохтаҗ булган яшәү нигезе матурлык һәм рухи байлык чыганагы итеп карала. Шуңа күрә персонажларының табигатькә мөнәсәбәте бер үк вакытта аларның, гомумән, яшәешкә мөнәсәбәтен дә билгели. Шулай итеп, табигать язмышы, тирә-юнь күркәмлеге әсәрдә фәлсәфи-әхлакый планда карала. Гомәр Бәширов хезмәт төшенчәсен дә табигать белән бәйли. Аның әсәрендә хезмәт һәм табигать бүленмәс берлек хасил итәләр. Әсәрдән күренгәнчә, табигать язмышына уйламый-нитми күпләр йогынты ясый, ә аңа китеререлгән зыян өчен конкрет берәү дә җавап бирми. Шуңа күрә колхозчыларда сорау туа: "Кем хуҗа соң безнең җиргә? Җидегәнгә аяк та басмаган әллә кайдагы профессормы, әллә без үзебезме?"-диләр.[1;б.473]Әсәрнең иң беренче уңышы, минем уйлавымча, әле татар әдәбиятында бер мәртәбә диярлек күрелмәгән проблеманы-табигать саклауны зур итеп, кызыклы, тере кешеләр, җанлы характерлар аша сурәтләп бирүендә. Без барыбыз да табигать балалары. Табигать безне тудырган, яшәү чыганагы биргән. Аннан башка яшәеш мөмкин түгел. Шуңа күрә һәр кеше табигатьне саклау, аны яңарту-яшәртү турында кайгыртырга бурычлы.

Соңгы елларда экологик тәрбия бирүгә шактый игътибар ителә башлады, чөнки ул-мөһим проблемаларның берсе. Әйләнә-тирәнең төрле чуп-чар белән пычрануы, машиналарның гадәттән тыш күбәеп, алардан чыккан газның кеше сәламәтлегенә генә түгел, кош-корт, хайваннар дөньясына да куркыныч янавын, чишмәләрнең коруы, кышлаучы кошларның азык юклыктан иза чигүен бала кече яшьтән үк белеп үссә, ул табигатьне яратачак һәм аны сакларга омтылачак.

Табигатьне саклау - ул үзебезне, киләчәгебезне, өебезне саклау дигән сүз. Һәр гамәлне акыл белән башкарырга кирәк, шул чакта гына без матурлыкны, табигатьне коткара алырбыз.

Кулланылган әдәбият:

1)Бәширов Г. Сайланма әсәрләр.- Казан: Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшр., 2006.- 511б.

## Употребление заимствованных слов в современных СМИ и речи молодежи

***Гайнанов Азат Маратович, студент 1 курса***
***ГБПОУ «Альметьевский профессиональный колледж»***
***Землянцева Светлана Валентиновна,***
***преподаватель русского языка и литературы***

В 1957 году в статье «Сокровищница мудрости» М.Шолохов писал: «Величайшее богатство народа – его язык. Тысячелетиями накапливаются и вечно живут в слове несметные сокровища человеческой мысли и опыта»

Русский язык изменялся на протяжении многих веков и в результате определённых языковых явлений, и в результате реформ, и благодаря заимствованиям, упрощениям. Эти перемены всегда связаны с тем, что язык – развивается вместе с обществом и «подстраивается» под него.

Технический и информационный взрыв конца XX века сделал неизбежным международный обмен информацией, таким образом, потребность в словесном обозначении новых понятий и явлений действительности и отсутствие в русском языке адекватных наименований привели к заимствованиям интернациональной лексики, которая в большей своей части представляет прямые заимствования из английского языка.

Однако одновременно с этим всплыло много словесного хлама, ненужного, засоряющего язык. Иностранное слово стало не только необходимым, нужным, но и привлекательным, престижным. В таком случае мера и избирательность в применении иноязычной лексики начинает утрачиваться. Побеждает общий настрой, мода, желание быть «наравне с веком».

В наши дни газета - самый чуткий регистратор новых слов, значений, словосочетаний. Она значительно быстрее всех других жанров письменной речи отражает сдвиги, которые

происходят во всех сферах жизни общества, и в большинстве случаев является первым письменным источником, фиксирующим появление новых слов, значений и выражений, претендующих на вхождение в общеупотребительную лексику.

Анализируя современную прессу, нетрудно заметить, что проблема заимствований в СМИ актуальна, как никогда. Газетные статьи написаны "птичьим" языком - красивым, но абсолютно непонятным. Вот только названия статей из местной газеты «Знамя труда» города Альметьевск: «Хедлайнеры тура», «В Альметьевске впервые прошел брейн-ринг с журналистами по профилактике сердечно-сосудистых и онкологических заболеваний», «Стартап отцов прошел в Альметьевске», «В Альметьевске названы победители интеллектуального баттла «Мастер риска».

Ненужные заимствования употребляют сейчас все: политики, дикторы радио и телевидения, предприниматели, студенты. Проведя наблюдение, мы установили, что обучающиеся нашего колледжа часто используют заимствованные слова в своей речи.

Для того, что бы выявить особенности, а самое главное причины использования студентами иноязычных слов в их повседневной речи, мы провели социальный опрос.

В исследовании приняло участие 115 человек – обучающиеся 1-2 курсов ГБПОУ «Альметьевский профессиональный колледж». Ребятам предлагалось ответить на вопросы, относительно того, используют ли они в своей речи англицизмы, если да, то, как часто и почему. А так же участникам опроса нужно было дать определение нескольким всем известным, часто употребляемым заимствованным словам.

Ответив на все вопросы, учащимся нужно было привести в качестве примера 10 наиболее часто используемых ими заимствованных слов.

Полученные нами результаты были сведены в начале в общую схему: .

Обучающиеся 1-х курсов используют английские слова в своей речи потому, что они помогают им ясно, чётко и быстро выразить значение описательного оборота (58%), либо, чтобы конкретизировать значение слова из русского языка (21%). И ни один из первокурсников не счёл, заимствованные слова как более учёные (0%). А всего 3% участников опроса заявили, что англицизмы более выразительны, чем слова родного языка.

Обучающиеся 2-х курсов используют иноязычные слова в своей речи, т.к. в первую очередь, по их мнению, в русском языке нет такого понятия (30%), а во вторую очередь, чтобы объяснить значение описательных оборотов (24%) или конкретизировать значение русского слова (26%).

О чрезмерной тяге к «чужому» слову свидетельствует современная тенденция к использованию вместо русского слова - иноязычного. Хорошей иллюстрацией служат вывески города. Обычный магазин или универмаг сменили названия шоп (shop),супер-шоп,

появились не только супермаркеты, гипермаркеты, мини-маркет (к ним мы уже привыкли), в нашем городе есть уже и напитки-маркет, и алко-маркет.

Мы считаем, что для того, чтобы защитить русский язык, необходимо более глубоко изучать его в образовательных учреждениях; кроме того, надо ввести цензуру в СМИ; ввести запрет на использование ненормативной лексики в общественных местах; правильно говорить в семье; прививать любовь к русскому языку детям; больше читать русскую литературу; запретить искажения русских слов; как можно меньше использовать иностранные слова.

Язык необходимо оберегать, за чистоту языка нужно бороться всеми доступными средствами.

Русский язык остается и будет оставаться надежным каналом, связывающим живущие сегодня поколения россиян с богатейшим культурным наследием наших предков. Благодаря открытости, восприимчивости к влиянию как восточной, так западной культур на протяжении тысячелетий сложилось самобытная, многослойная, глубокая русская культура, которая нашла отражение в нашем богатейшем и красивейшем языке. Замечательно сказал русский мыслитель И.Л.Ильин: « Пусть мир познает наш язык и через него впервые коснётся нашей Родины. Ибо тогда, и только тогда он услышит не о ней, а ЕЁ».

## М.Җәлил иҗатында табигать сурәте
(Җир образы мисалында)

***Галимова Гөлгенә Раушан кызы***
***Г.Тукай исемендәге***
***Арча педагогия көллиятенең 1 нче курс студенты.***
***Төхфәтуллина Әлфия Госман кызы***
***филология фәннәре кандидаты, Г.Тукай исемендәге***
***Арча педагогия көллиятенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы.***

Герой-шагыйрь М.Җәлил иҗаты табигать образларына бай булуы белән аерылып тора. Аның кошчык, йолдыз, таң, гөл, эт, бүре, һ.б. образларны символик югарылыкка күтәреп иҗат иткән шигырьләре татар поэзиясенең алтын фондына кертелерлек әсәрләр [1; 3 ]. М.Җәлил иҗатында урын алган шундый сурәтләрнең тагын берсе – җир образы.

“Җир” татар халкында киң семантик кырга ия, лексик төсмерләргә бай, күпмәгънәле төшенчәләрнең берсе. Милли мәдәният берәмлеге буларак ул кадерләп сакланырга тиешле изге урын, байлык. Игътибар итсәк, җир образы М.Җәлил иҗатының да буеннан-буена сузылган. Әйтик, башлангыч чор иҗатындагы “Күңелемә”, “Истәлек” һ.б. шигырьләрендә җир төшенчәсе җир өсте, дөнья, яшәү, тереклек итү урынын белдерсә; якты киләчәккә

омтылу мотивы белән язылган “Бәйнәлмиләл”, “Янчы дөнья...” шигырьләрдә ул җирнең өске катламын аңлата.

Билгеле булганча, җир туып-үскән ил мәгънәсендә дә йөри; түбәндәге мисалда шагыйрь аның нәкъ менә шул мәгънәсен алга сөргән: Бик яшисем килә, сизми илләр, Бик яшисем килә җиремдә. (“Мескенлектә”)

М.Җәлилнең сугыш чоры иҗатында җир төшенчәсе тагын да калкурак чагылдырыла: аның мәгънәсе катлауландырыла, эчтәлеге байый. Мәсәлән, публицистик поэзиянең югары үрнәге булган “Җырларым” шигырендә җир чиксезлек, яшәү мәгънәсе төсмере алган: Күпме булса сездә көч һәм ялкын, Шулкадәрле җирдә хаккыгыз! (“Җырларым”)

Алдагы шигырьдә дә шуңа охшаш хәл: җир биредә киләчәк мәгънәсендә килгән: Сынган күңел, наздан мәхрүм булып, Сүнәр ялгыз, җирдән йотылыр. .(“Син онытырсың”)

Туган җир гыйбарәсе телдәге традицион сурәт. М.Җәлилдә без аның да матур үрнәкләре белән еш очрашабыз. Шагыйрь күзаллавында ул барлык кыйммәтләрдән дә өстен булган изге урын. Дошманга нәфрәт белән сугарылган “Моабит дәфтәрләре” циклына кергән шигырьләрендә җир җанлы, кодрәтле, илаһи көч буларак та гәүдәләндерелә: Җир сыкрыйдыр кебек ул басканга...Җир күтәрмәс иде бу кешене ... (“Сакчы”)

Кайбер шигырьләрдә җир сугышка протест белдерүче ролендә: ул я елый, я котырына, яки үз баласын юатырлык чаралар эзли: Жир йөрәкне минем җылытмакчы Анам төсле өреп сулышын. (“Хөкем алдыннан”)

Җир образы мифопоэтик укылышта ана мәгънәсендә килә, яңадан туу, рухи үсеш, яңарыш, үз асылыңа кайтуны символлаштыра. М.Җәлил дә Җир-ананы тудыручы, саклаучы; яшәүнең, тормышның, кеше рухының бөеклеген раслаучы изге зат итеп сурәтли: Алар бит изге Җир-ананың Сөекле кызлары, уллары. (“Чәчәкләр”)

Күргәнебезчә, җир-ана нәкъ әниләр төсле юмарт та, сизгер дә, назлы да. Һәркемнең күңелен тетрәндерерлек “Вәхшәт” шигырендә Җир-ана хәсрәт, кайгы дулкыны эчендә бирелә, аның чарасызлыктан җаны әрни. Шагыйрьнең шигъри фәлсәфәсендә Җир-ана җиһанда тереклекне бар итүче һәм шул тереклекнең иминлеге өчен җаваплылык алган образ буларак ачыла.

Җир әдәби телдә, әдәбиятта җир йөзе әйтелмәсе рәвешендә дә йөри. Тормыш, яшәеш мәгънәсен бирүче бу гыйбарәне М.Җәлил үзенең “Төрмәдә төш”, “Аерылу” шигырьләрендә яктылык, матурлык кебек сыйфат-билгеләр белән янәшә куя. Ә “Соңгы җыр” шигырендә автор аны, төрмә образы белән янәшә биреп, яшәү һәм үлем фәлсәфәсен; дөнья матурлыгының бәясен, кыйммәтен ача; ирекнең кеше өчен ни дәрәҗәдә кадерле булуын күрсәтә:

М.Җәлилнең “Вәхшәт” шигырендә хәтта җир әсәр тукымасындагы төп образларның берсенә әверелгән. Ул, шушы вакыйгаларның шаһите буларак катнашып, бер үк вакытта берничә төрле вазыйфа башкара: беренчедән, ул - вәхшилек башкарылган урын (Ауды җиргә бергә ике тормыш), икенчедән, бу хәлгә каршылык белдереп газапланучы (җир ярсыды, Җир елады кысып тешләрен), өченчедән, мәңгелек йорт (Палач тереләй җиргә күммәсен), дүртенчедән, бу хәлләр өчен җавап тотучы, гаепле затларның берсе (Нишләдең, син, җирем, нишләдең?).

Нәтиҗә ясап әйткәндә, М.Җәлил иҗатында урын алган җир образы гадәти сурәт кенә түгел, ә тормыш, яшәеш чыганагы булган милли, әхлакый кыйммәтләрнең берсе. Ул кеше яшәешенең нигезен билгеләүче таяну ноктасы, аны төрле бәла-казалардан саклаучы, яклаучы, рухи таяныч. Күп кенә әсәрләрендә шагыйрь аны символ дәрәҗәсенә күтәреп, идея-эстетик вазыйфа йөкли. Еш кына ул, образ буларак, лирик геройның уй-кичерешләре белән фикердәш. Н.М.Йосыпова билгеләп үткәнчә, мондый мифологик сюжетлар, символ буларак, яшәешкә мөнәсәбәтле уйлануларны, кешелек җәмгыятенең киләчәгенә кагылышлы фаразларны, иҗтимагый кануннарга мөнәсәбәтне, заманча фәлсәфи фикерләрне ассызыклый [5; 104].

**Кулланылган әдәбият**


1.Галиуллин Т. Керсез йөрәк монологы. / Т.Галиуллин // Җәлил М. Әсәрләр. – Казан: Мәгариф, 2004. – Б. 8-9.

2. Җәлил М. Әсәрләр. / М.Җәлил. – Казан: Мәгариф, 2004. – 271 б.

3. Закирҗанов Ә.М. Рухи Таяныч: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. /Ә.Закирҗанов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 287 б.

4. Заһидуллина Д.Ф. XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек. /Д.Ф.Заһидуллина, Н.М. Йосыпова. – Казан: Казан ун-ты, 2011. – 1 нче китап: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 230 б.

5. Йосыпова Н.М. XX гасыр татар шигъриятендә символлар. /Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан. Ун-ты, 2011. – 120 б.

Кашшаф М. Муса Җәлил./М.Кашшаф // Җәлил М. Әсәрләр. Дүрт томда. 1 нче том. – Казан: Татар. Кит. Нәшр., 1968. – Б. 7-26.

6. Мостафин Р. Чәнечкеле тимерчыбык белән. / Р.Мостафин // Җәлил М. Әсәрләр. – Казан: Мәгариф, 2004. – Б. 258-260.


## Туган як табигате - якташ шагыйрьләр иҗатында


Гайсина Гөлия Наил кызы, 3 Г курс студенты

җитәкчесе Шаһиева Нәсимә Миргарифҗан кызы,

татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә «Табигать – билгеле бер урынның җир сулары, үсемлек, хайваннар дөньясы кеше эшчәнлегеннән башка барлыкка килә торган һәммә нәрсә» диелә. XX йөзнең икенче яртысыннан табигатьне, тирә-як мөһитне өйрәнүдә экология фәне аерым урын алып тора.

Нәрсә ул экология? «Экология» сүзен беренче тапкыр 1886 нчы елда Эрнст Геккель үзенең «Гомуми морфология» дигән хезмәтендә кулланган. Ул грек сүзе «ойкос» һәм «логос» - фән дигәнне аңлата, ягьни яшәгән урының, йортың турындагы фән.

Кеше туганнан алып гомеренең соңгы көннәренә кадәр табигатьтән аерылгысыз. Табигатькә чыгып, ял итәләр, кошлар җырын тыңлыйлар, җиләк-җимешләр, дару үләннәре, гөмбә җыялар, күңелләрен сафландыралар. Мәрхәмәтлелек тамыры табигатьтән башлана. Ә мәрхәмәтлелек ул – мәхәббәт, ярату. Димәк, җәнлекләрне, кошларны, бар табигатьне ярату, саклауны мәхәббәт сүзе белән аңлату дөрес булыр.

Бүгенге әдәбияттә туган якка мәхәббәтне аңлату, аның матурлыгына мәдхия җырлау көннән-көн киңрәк кулланыш таба. Бу фикер якташ шагыйрьләребезнең шигырьләре белән танышкач тагы да көчәйде. Шуңа күрә җирле шагыйрьләребезнең иҗатын барлау, өйрәнү, алар белән әдәби кичәләр үткәрү әдәбиятны тирәнтеп өйрәнүгә генә түгел, ә туган ягыбызга мәхәббәтне тагы да арттыра, аны саклауга чакыра.

Минзәлә төбәге язучыларга, шагыйрьләргә бай як. Без бу очракта игътибарны танылган шагыйрьләр (мәсәлән, Рәшит Гәрәй, Марс Шабаев, Фәннүр Сафин һ.б.) иҗатларына түгел, ә ТАТМЕДИАның Минзәлә филиалы басмаханәсендә чыккан җирле шагыйрьләрнең китапларына юнәлттек. Аларның иҗатында тирә-юнь гүзәллеген ачучы шигырьләр шактый күп. Эзләнү шушы максаттан чыгып эшләнде. Якташ шагыйрьләребез иҗатларына күзәтү ясалды. Туган як образын сурәтләгән мисаллар китерелде. Азат Мәрдән, Гөлназ Вәлиева, Фәрит Миргалимов, Нәкирә Лутфрахманова, Энҗе Усманова, Флюра Садретдинова, Зөлфия Равилова шигырьләрендә Минзәләнең иксез-чиксез тугайлары-кырлары, урманнары, Минзәлә елгасы буйлары искиткеч матур һәм кабатланмас итеп сурәтләнә.

Үз җиремдә үзем хуҗа,  
Туган туфрак – тәхетем.  
Баксаң, авыл җирлегендә  
Булган икән бәхетем.(Ф. Миргалимов, “Бәхет туган туфракта”)

Шул ук автор туган як табигате турында “Күңелемә инде яз кирәк” шигырендә менә нинди сүзләр язган:

Хәтфә үлән әллә битен юган,

Иртәнге чык һаман кипмәгән.

Яшь киленнәр таңны ашыктырып,

Су алсыннар челтер чишмәдән.

Аның хәтта “Экологлар чаң кага” дигән шигыре дә бар:

Төрле агу, химикатлар

Кулланабыз кырларда.

Шул сәбәпле кош-корт кими,

Аз калды тургайлар да.....

.... Үпкәләтмик табигатьне,

Ул дуласа куркыныч.

Тирә-як мөхитне саклау-

Безнең иң изге бурыч.

Минзәлә буйлары ямьле –

Куаклыклар, таллыклар.

Кичләрен айга сикерә

Көмеш тәңкә балыклар.(Ф.Садретдинова “Ямьле дә соң Минзәләм”)

Нинди моңлы, нинди серле

Табигатьнең кочагы.

Авылымда табигатьнең

Иң-иң гүзәл почмагы (Г.Вәлиева “Мин авылга гашыйк”), дип сокланалар шагыйрьләр. Шушы ук автор кышкы салкыннарда кошларга ярдәм итү кирәклеген искәртә:

Чүп үләне төше белән генә

Яшәү кыен салкын кышларда.

Эх, ичмасам, берсе ялгыш кына

Җимлек элсә иде кошларга.( “Кызылтүш”)

Табигатьне саклар өчен илдә тынычлык булырга, бөек акылга ия кешеләр алтын-көмешкә түгел, ә табигатькә табынырга тиешлеген искәртә:

Тургайлар мәңге яшәсен,

Башаклар торсын тулып.

Табигатьне саклар өчен

Илдә тынычлык булсын!(“Каенкай”)

Кеше - табигатьнең бер баласы,

Бары аңа бөек акыл хас.

Тик нигәдертабигать- анага

Ярдәм кулы сузган кеше аз.

Әй, син. Кеше,тирән акыллы син,

Күмелгәнсең алтын бәллүргә.

Тик шул акыл да өйрәнсен иде

Табигатьне саклый белергә.

“Тегермән тарихы” шигырендә бу фикерен үстереп:

....Ул чакларда елгаларның

Сулары чиста булган.

Яр буйлары яшел чирәм

Әйтерсең хәтфә юрган.

...Ул хәтфә үләнне әрем,

Кычыткан каплан киткән.

Яр буйлары да сазланып,

Суы саегып беткән.

Шул күңелсез тирәлектә

Калдырган аны заман.

“Табигатьне саклагыз!”- дип

Безгә ул дәшә сыман.

Күргәнегезчә, безнең төбәк авторлары дөньяның ямьле бер төбәге - Минзәләне ярата, аны сакларга өнди. Безгә калса, “Табигатьне саклагыз!” дип турыдан -туры кычкыруга караганда, кеше күңеленә шигъри юлларның тәэсире көчлерәк.

Мин дә китеп карыйм...

Сагышларга талып, тагын урап кайтам...

Газиз Минзәләм, син!( Нәкирә Лутфрахманова “Китә алмыйм синнән, Минзәләм!)

Әдәбият исемлеге

1.Валиева Г. Нарат-Кичү кызы мин. ”Минзәлә” газетасы китапханәсе. – Минзәлә, 2006. – 56 б.

2.Лутфрахманова Н. Сине эзлим. ”Минзәлә” газетасы китапханәсе. – Минзәлә, 2004. – 80б.

3. Миргалимов Ф. Мин язларга гашыйк. ”Минзәлә” газетасы китапханәсе. – Минзәлә, 2004. – 96 б.

4.Садертдинова Ф. Алтын көзем-моң бишегем. ”Минзәлә” газетасы китапханәсе. – Минзәлә, 2002. – 100 б.

5.Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда.III том.Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1981, 832 б.

## Табигать ул – яшәү чыганагы

***Галимова Гүзәл Фәндәс кызы,***
***җитәкчесе: Хайрутдинова Зөлфия Рафик кызы,***
***3 нче курс, ТПД-2 төркеме,***
***ДАҺБУ “Түбән Кама эретеп***
***ябыштыру - монтажлау көллияте”***

Табигать-безнең туган йортыбыз. Балыклар сусыз, җәнлекләр урмансыз, урманнар агачларсыз була алмаган кебек, кешеләр дә табигатьсез яши алмый. Адәм баласы кая гына яшәмәсен, шәһәр, авыл, ул һәрвакыт үсемлекләр, хайваннар, кошлар, бөҗәкләр белән әйләндереп алынган. Шуңа күрә дә кеше табигатьнең аерылгысыз бер кисәге дип әйтер идем мин.

Әйе, кешелек дөньясы табигатьтән башка яши алмый. Бу турыда бик күп шагыйрьләр һәм язучылар үзләренең иҗатларында чагылдыра. Мөхәммәт Мәһдиев та шуны дәлилли: «Кеше никадәр табигатькә якынрак булса, аның серләрен никадәр нечкәләбрәк өйрәнсә, шулкадәр әхлаклы була». Шулай ук «Кистем каен, кистем каен» язмасында болай дип яза: «Агачлар кешеләр кебек җанлы. Алар безне таныйлар, күрәләр, аңлыйлар. Тик табигать аларга тел генә бирмәгән. Хәер, үзара аңлашалар, сөйләшәләр алар, әмма безнең телне белмиләр...». «Торналар төшкән җирдә» повестен гына карыйк. Урманны карап, чистартып, яңартып торсаң гына урман була ул. Язучы урманның киләчәге өчен дә борчыла. «Утынга кисеп юкка чыгармаслармы сезне?» – дип дәшә ул агачларга.

Гомәр Бәшировның “Туган ягым – яшел бишек” әсәрен укымаган кеше бик аздыр. Язучы бу әсәре белән борынгыдан килгән гореф-гадәтләргә ихтирам тәрбияләргә, табигый байлыкларга сакчыл булырга, кадерен белергә, өлкәннәргә хөрмәт белән карарга чакыра. Табигать кешеләрнең кәефе белән дә идарә итә. Беренче күк күкрәүгә, кыр казлары кайтуга, шаулап аккан ташуга кешеләрнең куанычы да, шатлыгы да - сабыйларча саф, алар да табигать белән керешеп үк киткәндәй итеп чагылдыра язучы.

Татар әдәбиятында кеше белән табигать мөнәсәбәтләрен күрсәткән әсәрләр байтак. Нәбирә Гыйматдинованы язучы итеп таныткан әсәре “Сихерче” повестен генә алыйк. Төп герой Сәвиләнең прототибы – Аксубай районы Үзи авылыннан, бөтен тирә – якка даны

таралган, Шәрифҗамал әби. Автор бу әсәрендә табигать турында, кешенең аннан башка яши алмавын, табигатьтән аерылып, матди байлык артыннан гына кууычыларның җаннары коруын һәм шул җаннарны үләннәр шифасы, чишмә сулары, урман һавасы белән дәвалап булуын мавыктыргыч сюжет аркылы ачып бирә.

Нәбирә Гыйматдинованың "Сихерче", "Каракош", "Торна каргышы", "Күке төкереге", "Болан", "Бүре каны" әсәрләрендә уртак сыйфатлар бар. Сәвилә, Онык, Акчәч табигать балалары, аларда язмышны алдан күрә белү, табигатьнең үз дарулары – үләннәр белән дәвалый белү сәләте дә бар.

Шагыйрьләребездә үзләренең иҗатында табигатькә дан җырлый. Кеше һәм табигать, аларның үзара мөнәсәбәте – Ринат Харис иҗатындагы төп темаларның берсе. Табигать образы аша кеше кичерешләрен тасвирлауга багышланган шигырьләр аның иҗатында аз түгел: "Яфракларың гәрәбә...", "Коела яшел яфрак", "Җир – чәчәк", - дигәч...", "Яктылык төшә", "Өянке" һәм башкалар. Табигатьтә җәмгыять өчен, кешеләр өчен гыйбрәтле хәлләрне күп таба әдип. Еш кына андый шигырьләрнең төп идеясен, асыл мәгънәсен символик характердагы шигъри образ аша бирергә тырыша.

Чишмәләр... Кемнең генә күңеленә илһам салмый да, кемгә генә канат куеп, хыялларын үстерми икән соң алар?! Шагыйрь Равил Фәйзуллин туган ягы, туган йорты турында күп яза. «Туган ягым» дигән шигырендә ул болай ди:

*Минем дә бар үзем өчен*
*шундый як — Туган ягым:*
*Дога иңгән һәр төшеннән*
*чишмәләр чыга аның!*

Хәсән Туфанның 16 ел гомере читтә үтә. Туган җиренә мәхәббәте, сагыну хисләре иҗатына күчә.

*Ак каеннар азмы далаларда,*
*Яландагы олы юлларда...*
*Беркайда юк, ләкин сезнең сыман*
*Сагындырган каен, — беркайда! —*

дип өзгәләнә ул.

Табигатьне пычрату, аңа саксыз карау иманлы кешеләрдә борчылу уята. Табигатьне саклау проблемасы Әхсән Баяновның «Сәяхәтнамә» поэмасында күтәрелә. Автор кешелек дөньясын саклап калырга чакыра. Сәяхәтнамәнең ахырын ул болай тәмамлый:

*Чаң кагам мин:*
*— Бар халыклар!*
*Барлык теләк-гадәтләрне*

*Буйсындырып бары акылга,*

*Кул бирегез бер-берегезгә*

*Җир хакына, яшәү хакына!*

Без кешеләр! Әйдәгез әле, табигатькә карата бераз мәрхәмәтлерәк булыйк! Аны саклап калу өчен бар көчебезне кызганмыйк! Табигатьне саклау – барлык кешеләрнең изге бурычы!

**Кулланылган әдәбият**


1. Билалова Ә.Г., Гыймадиева Н.С. Әдәбият дәреслекләре буйлап. – “Яңалиф” нәшрияты. – 2006
2. Заһидуллина Д.Ф. Образлар системасын анализлау //Әдәби әсәргә анализ ясау, Заһидуллина Д.Ф., Ибраһимов М.И., Әминова В.Р. – Казан. 2005
3. Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов Ә.М., Гыйләҗев Т.Ш. – Татар әдәбияты. Теория. Тарих . – “Мәгариф” нәшрияты. – 2004


## Г.Мөхәммәтшинның “Саумысез, аккошлар!” повестендә кеше һәм табигать


***Р.Гардисламова, “М.Җәлил исемендәге Минзәлә педагогия колледжы” студенты. Җитәкчесе И.М.Хәйруллина, “Минзәлә педагогия колледжы”ның татар теле һәм әдәбияты укытучысы***


Табигать темасы - татар әдәбиятында мәңгелек темаларның берсе. Табигать – ул эчәр суларыбыз, сулар һавабыз, безне туендыручы туфрак, хайваннар һәм кошлар дөньясы. Шушы матурлыкны шигырь юлларына салучыларыбыз, әсәрләр иҗат итүчеләребез шактый. Шундыйларның берсе – Газиз Мөхәммәтшин. Мин аның “Саумысез, аккошлар!” повестен генә искә алып китәргә уйлыйм.

Кешелеккә куркыныч янаган проблемаларның берсе - яшәешебезнең нигез ташы булган табигатькә карата мөнәсәбәт, аңа сакчыл караш бүгенге көндә дә иң әһәмиятле проблемаларның берсе булып калуын дәвам итә. Инде ничәмә-ничә еллар... Ничә буыннар... Ә бу проблеманы кешеләр үзләре тудыралар бит. Дөрес, кеше яхшы тормыш төзү, уңайлыклар булдыру, механикалаштыру, компьютерлаштыру кебек заманча технологияләр

булдыру өчен тырыша. Ләкин күп очракта түбән тәгәрәвен сизми дә кебек ул. Кешелекнең күңел күзе бөтенләй күрми башлады. Матурлык, табигый матурлык, безгә Ходай тарафыннан бирелгән матурлык, әкренләп, безнең гаеп белән юкка чыгып бара түгелме?!

Повестьта Газиз Мөхәммәтшин Минзәлә, Актаныш, Тукай районнарының тарихында узган гасырның 60-70 елларында булып узган, күп кенә авылларының, шуның белән бергә тарих битләренең юкка чыгуына сәбәп булган Түбән Кама сусаклагычын төзү аркасында килеп чыккан фаҗигале хәлләрне тасвирлый.

Повесть «Карт имәнне кискәннәр,» - дигән хәвефле хәбәр белән башланып китә. Карт имән Кояшлы авылының тарихы, авыл яшьләренең очрашу, вәгъдәләр бирешү, эшләп, уйнап арганнан соң аның күләгәсендә рәхәтләнеп ял итү урыны да.

“Авыл гына түгел – барысы да, әфсен укып өргәндәй, юкка чыга: болын-әрәмәләре дә, урман – күлләре дә. ...”

Аның бер очында каен һәм нарат урманнары, икенче очында кош-корт яратып оя ясаган зирек, имән һәм усак катыш бик матур әрәмәлек. Әрәмә уртасында ел саен сабантуйлары була торган ямь-яшел ашъяулык шикелле тигез алан. Әз генә арырак, елгага төшкән иңкүлектә, ак чәчәкле чиялек белән күгәнлек бар иде.

Авылның өченче ягында без көненә уникешәр мәртәбә су кона торган төнбоеклы күлләр, сыер-сарык умырып ашый торган хуш исле печән котырып үскән, кара карлыган, кызыл бөрлегән пешкән, еракларга, еракларга сузылып киткән яшел болыннар бар иде. Болын читендә тирә-якта атаклы урман.”

Ләкин беркөнне шул матурлык юкка чыга. Урманны кисәләр, әрәмәлекләрне тракторлар белән таптыйлар, ваталар, сыталар, ә күгәнлеккә көтү кертәләр.

Әйе, яңа салынып ята торган электр станциясенең платинасы күтәрелеп килә. Кояшлы авылы урман-күлләре, елгалары белән су астында калачак. Бу очракта кешеләр нишләргә тиеш? Беришe кешеләр моменттан файдаланып калырга, баерга омтылалар. Икенче берәүләр шушы матурлыкны, байлыкны мөмкин булган хәлдә саклап алып калырга тырышалар.

Әлеге повесть Вәкил исемле малай авызыннан сөйләнә. Вакыйгалар бала күзлегеннән, күңеленнән кичергән, олылардан ишеткән вакыйгалар белән үрелеп бара. Алар дусты Флүн белән табигатьне, Кояшлы авылын саклауда үзләреннән өлеш кертергә тырышалар. (Поши атучы браконьерларны тотарга телиләр). Малайлар тәрбияләгән Бүләк исемле эт тә табигатьнең бер бөртеге бит. Шул эт баласын тәрбияләүдә күпме наз, ярату, тырышлык, тугрылык күрәбез.

Автор туган як табигатенең һәр карышына гашыйклар күзе белән карый белә, хәтердә мәңге сакланырлык буяулар белән тасвирлый. “ Тармаклы- тармаклы, чуклы – чуклы ак каеннар, шул каеннар арасында ямь- яшел утраулар шикелле калкып торган төз наратлар

үскән куе урман.” “... Бүре сазлыгы... Ул атаклы сазлык озын чәкәнле торналардан һәм челәннәрдән алып йодрык кадәр шөлдиләргә кадәр меңнәрчә кошлар кайнап торган үзенә бер кайнап торган патшалык булган... Кошлар шунда берәүдән дә курыкмыйча чыр-чу килеп рәхәтләнеп гомер итәләр иде... .” “Урманыбызга кергәч, күңелләр күтәрелеп китте. Кышкы урман – әкият бит ул. Матур, серле әкият! ”

Табигатьне саклау олыларның да, кечеләрнең дә намус эше булып китә. Авылның исеме дә үзенчәлекле бит. Кояшлы! Димәк җылы, нурлы, кояш кебек озын гомерле булырга тиеш ул.

Повестьның соңгы бүлеге “Кояшлыда яңа “Кояшлы” дип атала. Ирбулат, Мөфаздал абыйлар кебек туган җирен яратучылар авылны, табигатьне кабат яңарту өчен тырышалар. Авыл бөтенләе белән диярлек күчеп бетсә дә, Вәкил һәм Флүннәр, Ирбулатлар, студентлар ярдәмендә ял йорты торгызалар, киселгән урман урынына яңа яшь агач үсентеләре утырталар, ә киселгән карт имән урынында яше үсә. “Киләчәктә элеккедән дә куе, элеккедән дә матур урман шаулап үсәчәк. Алан уртасындагы элекке мәрхүм Карт имән янына да бер бәләкәй имән утырттык. Киләчәктә ул үзенең бабасы шикелле зур һәм мәгъруур булыр. Аның төбенә тагын егетләр һәм кызлар килер, җиләс күләгәсендә печәнчеләр ял итәр.”

Автор «Карт имәнне кискәннәр!» дип бәгырьне кисә торган үтә хәвефле сүзләр белән башлаган повестен тирән мәгънәле якты өметле, күтәренке рухлы: «Әни Аккошлар килгән!.. Ике пар!.. Олы күлгә кабат аккошлар кайткан, әни!» — дип тәмамлый.

Әйе, бу — авторның иң изге теләге. Карт имәннәр киселгән якларның күлләренә дә аккошлар кайтсын иде! Теләсәк, теләгәнебезне эшләрбез. Тик моның өчен барыбыз да көрәшчеләр булырга тиеш. Шул чакны без җир матурлыгын саклап кала алачакбыз!.. Бүген малай гына булган Вәкилләр, Флүннәр үсеп җитәр, алар баш очында да карт имәннәр шауларлык булсын!

## Экологические проблемы татарского языка в современной лингвистике.

***Автор - Гатин Айзат Ринатович***
***Руководитель - Шайсуварова Лейля Хамисовна***
***2 курс, специальность «Монтаж, наладка и эксплуатация электрооборудования промышленных и гражданских зданий»***
***ГБПОУ «Мензелинский сельскохозяйственный техникум»***

Эколингвистика – это одно из молодых перспективных научных направлений языкознания, сформировавшееся на стыке социального, психологического и философского направлений в лингвистике.

Эколингвистика как научное направление, объединяющее экологию и лингвистику, изучает взаимодействие между языком, человеком как языковой личностью и его окружающей средой, представляющее собой как влияние внешней среды через человека и социум на язык, так и влияние языка на нравственный и духовный уровень общества. Язык при этом рассматривается как неотъемлемый компонент цепи взаимоотношений между человеком, обществом и природой. Функционирование и развитие языка представляется как экосистема, а окружающий мир – как языковой концепт.

**Словосочетание «экологические проблемы» в нашем понятии в первую очередь ассоциируется с кризисным состоянием природы. Но применительно к языку также используется понятие экология -** это такое направление в лингвистике, которое, с одной стороны, связано с изучением факторов, негативно влияющих на развитие и использование языка, а с другой стороны, с изысканием путей и способов обогащения языка и совершенствования практики речевого общения. По общему справедливому определению, татарский язык в настоящее время находится в кризисном состоянии. В чем же причина такого «кризисного состояния» татарского языка? Давайте попробуем в этом разобраться.

В первую очередь, современная молодежь абсолютно ничего не знает о своей истории. Как же молодые люди могут стать истинными гражданами республики и страны, хорошо знать свой родной язык, ведь они мечтают куда-нибудь уехать. Полностью погруженные западной роскошью, молодые люди стремятся найти себя на чужбине. Современная СМИ искажает всю правду о реальной зарубежной жизни; не всегда молодые люди, уехав заграницу, могут реализоваться как граждане той или иной страны.

Во-вторых, многие татары, говоря на своем родном языке, часто используют русские слова, хотя татарский язык очень богатый язык, имеющий все возможности для выражения любой мысли... Поскольку преподавание всех предметов в подавляющем большинстве школ нашей республики ведется на русском языке, то, конечно, немало местных татар использует свой родной язык далеко не в полной мере. В такой ситуации, когда нет достаточных условий для развития татарского языка, не приходится говорить о его полноценном использовании на территории Татарстана... И в настоящее время татарских школ, к сожалению, очень мало, как в отдельно взятом городе, так и по всему Татарстану.

Нужно сказать, что политика нашего федерального государства направлена на русификацию: все должно быть только на русском... Потому в Татарстане, например, практически очень ограничено ведение документации на татарском языке. И при

поступлении в вузы экзамены должны сдаваться опять же лишь на русском... Такое положение вещей, естественно, не способствует использованию и развитию татарского языка. Однако сознательная часть татарского народа прекрасно говорит на этом языке, употребляя очень ограниченное количество заимствованных слов, в том числе, из русского языка...

Все это приводит к кризисному состоянию языка. Что же нужно делать, как спасти родной язык??? Как говорил Щеглов, «Упор нужно делать на сбережение татарского именно среди фактических и потенциальных носителей языка, а также всячески содействовать желающим не-татарам изучать татарский язык. Помогать, а не заставлять. У меня и к русским есть претензии, что соплеменники от своих идеалов, героев, традиций отвернулись, и тут мы могли бы с татарами найти общее». Я полностью согласна с предположениями Щеглова. Язык должен жить и развиваться и впитывать в себя, синтезировать достижения всех. Если он это может делать – он живет.

**Литература**

1.Haugen, E. The ecology of language: Essays by E. Haugen / E. Haugen / Stanford, CA: Stanford University Press / Originally published in W. Bright (Ed.).1966. - P. 159-190.
2. Зимурова Ксения, студентка группы ХТОВ - 04 Руководитель: Грошева Татьяна Михайловна, преподаватель русского языка и литературы *ГБПОУ «УХТК», г. Губаха, Пермский край* - 280 с.
3. Иваницкий, В.В. Лингвоэкология и «Дом бытия» / В.В. Иваницкий // Социальные варианты языка: материалы междунар. науч. конф., 25-26 апр. 2002 г., Нижний Новгород / Нижегор. гос. лингв, ун-т им. Н.А. Добролюбова. Филол. фак. / - Н.Новгород, 2002.

4. Сковородников А.П. Лингвистическая экология: проблемы становления /А.П.Сковородников// Филологические науки: Выпуск 6, - М.:Высшая школа, 1996. – с. 5-9

## Әхсән Баянов – табигать сакчысы

***Гарипов Альберт Илгиз улы***
***Рафигуллина Миляуша Марвановна***
***IV курс, 41 стм***
***Дәүләт бюджет һөнәри белем учреждениесе***
***"Әлмәт һөнәри көллияте"***

Бүгенге көндә табигатьнең кеше белән бәйләнешле проблемасы кискен тора, чөнки кеше җирдә җимергеч эш-гамәлләр кыла. Аларны ничек булдырмый калырга?

Гомумән, кеше табигать белән ярашып яши аламы, кеше табигать белән бербөтенме, әллә кеше табигатьнең патшасымы? Күп кенә язучылар шушы сорауларга җавап эзли.

Элек-электән үк кеше белән табигать аерылгысыз булган. Кеше үзен беркайчан да табигатьтән өстен куймаган. Татар әдәбиятында кеше белән табигать мөнәсәбәтләрен күрсәткән әсәрләр байтак.

Табигатьне саклау проблемасы Ә. Баяновның «Сәяхәтнамә» поэмасында күтәрелә. Әсәрнең герое Кама буйлап сәяхәткә чыга. Кама буендагы авыллар югалган. Яшьләр булмагач, авылның киләчәге булмый. Авыл бетсә, табигать тә ярлылана. Кама буенда кыр казлары күренми, кыр үрдәкләре кычкырмый. Су буе мәет чыккан йортны хәтерләтә. Автор үзенең бала чагын хәтерли. Яланаяк йөргән болыннарны сагынып искә ала. Тик бу болыннар аша хәзер торбалар узган. Бик күп зиратлар аша дамбалар үткәрелгән. Милли аң көннән-көн югала бара. Халык иманыннан яза, телен оныта. Заманга ияреп, көйләр дә үзгәрә. Шул көйләр тавышы астында сыкрап, бик күп урманнар җиргә ава.

Елларга сәяхәт» китабына кереш сүздә Сибгат Хәким: «Бүген бөтен кешелекне борчыган проблема: табигать һәм кеше. Хәзер бу хакта язмаган бер генә газета, бер генә жур¬нал да юк. «Сәяхәтнамә» (Кама этюдлары) — татар әдәбия¬тында шушы темага багышланган беренче әсәр. Авыр,

чете¬рекле тема», — дип яза.

Чыннан да, Ә. Баянов, «Сәяхәтнамә»дә авылны, гореф - гадәтләрне, милли әхлагыбызны, аның нигезе булган тирә¬лекне, табигатьне саклап калу мәсьәләләрен күтәреп, алт¬мышынчы еллар ахырында, җитмешенче еллар башында бөтен җәмәгатьчелекне уйга салган икән.

Поэманың башында ике төрле җәмгыять, ике ил галименең сүзләре китерелә. Берсе — укучыны кисәтү, икенчесе опти¬мизм хисләрен саклау вазифасын үти. Әйе, без җирне бетерәбез, әмма бетермәскә була, дип әйтергә тели Ә. Баянов та.

Нефть табылу чорында табигатьнең нәҗесләнүен күреп, чын йөрәктән борчылып язылган әсәр ул — «Сәяхәтнамә».

Илдә барган зур үзгәрешләрне масштаблы тасвирлауга ире¬шә шагыйрь. Әлеге төзелешләр авылларны йота, краннар шәһәргә чакырып кул изи. Кеше гаилә, авыл кабыгыннан чыга, әмма шушы чакта ул уртак байлыкка битарафланмаска, без җирдә вакытлыча гына яшибез дигән уйны үзенчә шәрехләп, ни эшләсәң дә була, димәскә тиеш.

Әсәрдә җимерү символы булган җил образы бар. Язучы аны гамьсезлек, өметсезлек янәшәсенә куя һәм өчесен бергә исереп йөргән кешеләр кебек бәяли. Авыл таркала, аңа әнә шундый ямьсез күренешләр килеп керә. Исереклек — әх¬лакны туздыручы бер көч, ди Ә. Баянов. Без моңа күпкат¬ламлы абстракцияләр аша киләбез.

Вакыт һәм җил әллә нәрсәләрне, әллә нинди рәвешләргә китереп бетерсә дә, кеше Кеше булып калса гына, Җир ша¬рының киләчәге бар.

Шагыйрьнең тагын бер кызыклы фикере — кешедә ыша¬ныч тойгысын табигать аша гына тәрбияләп була. Таби¬гать — Бөек Республика. Табигать — тынлык. Кеше тын калса, уйлана.

Табигать — Ана. Димәк, ул — кешелек сагында, ул йокы¬сыз, ул ризыклар ашата, ул җыр бүләк итә. Шагыйрь әнә нинди төшенчә-символлар белән эш йөртә!

Авылларның эреләнүе, күчерелүе ул елларда бер генә ке¬шене дә сөендермәгәндер дип уйлыйм. Поэмадагы бер әби дә яуда калган иренең рухы каршында гаеп хисләре кичерә.

Кеше, матур киенү хакына, хайваннарның тиреләрен ту¬ный, ә үзе аларны яратуы белән мактана.

Ә. Баянов «Сәяхәтнамә»дә шартлы алымнар, төрле янә¬шәлекләр, эндәшләр, детальле сурәт һәм башка алымнарны куллана. Аңа метафоралар тыгызлыгы хас. Ул алтмышынчы елларда яңарган ирекле шигырь алымы белән язылган, шул сәбәпле дә чор өчен яңалык буларак бәяләнгән.

«Сәяхәтнамә» поэмасы бүген Яшелләр партиясе күтәргән проблемалар хакында яза түгелме? Юк, язмый, Җир-ананы саклау эшенә бердәм күтәрелегез, дип чаң кага:

Чаң кагам мин:

— Бар халыклар!

Барлык теләк-гадәтләрне

Буйсындырып бары акылга,

Кул бирегез бер-берегезгә

Җир хакына, яшәү хакына!

Әдәбият:


1. Баянов Ә. Сайланма әсәрләр. Ике томда. I том. – Татарстан китап нәшрияты, 1993. – 480 б.

2. Галимуллин Ф. Г. Әхсән Баянов // Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. VI том. – Казан: Раннур, 2001. – Б. 200-216.

3. Мусин Ф. Проза // Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. VI том. – Казан: Раннур, 2001. – Б. 49-96.

# Лингвоэкология: как спасти родной язык (экологические проблемы языка в современной лингвистике)

***Автор:Гарифуллина Адиля Марселевна***
***Руководитель: Янбарисова Наиля Галиевна***
***ГАПОУ " Нижнекамский политехнический колледж им. Е.Н.Королева" 1 курс***

Добрый день, уважаемые члены жюри и гости конференции.

Сегодня проблемы экологии волнуют всех и каждого. В первую очередь, речь идет о катастрофическом состоянии природной среды обитания человека, о загрязнении воды и воздуха, рек и морей, лесов и полей. В наши дни формируется новое направление – это экология культуры речи.

Я хочу напомнить высказывание Ивана Сергеевича Тургенева о русском языке: « Во дни сомнений, во дни тягостных раздумий о судьбах моей родины,- ты один мне поддержка и опора, о великий, могучий, правдивый и свободный русский язык! Не будь тебя – как не впасть в отчаяние при виде всего, что совершается дома? Но нельзя верить, чтобы такой язык не был дан великому народу!» Язык – это среда обитания любого человеческого коллектива, данного народа и каждого человека.

Язык не может развиваться в самоизоляции, и в языке всегда появляются заимствования, однако нашествие иноязычной лексики на русский язык в последнее время приняло размеры национальной катастрофы.

Что такое экология слова — определить не просто ввиду широты и юности этого понятия. Экология слова:

это сохранение родного языка, его словесного богатства, чистоты, здоровья;

это наука о целостности языка, о его связи с культурой своего народа и с земной семиосферой;

это наука об энергетике слова, о его творящей силе, о его отношениях с биосферой, с языком живой природы;

это, наконец, понятие о духовном значении слова, о глубокой взаимосвязи с личностью, с характером и судьбой народа, с высшими духовными сферами.

На данный момент выделяется три аспекта экологии языка:

Интралингвальный (связан с культурой речи, стилистикой, риторикой и включает исследования нарушений правильности, ясности, логичности, выразительности и других коммуникативных свойств речи).

Интерлингвальный (связан с полиязычием как средой обитания отдельного этнического языка и с проблемой исчезновения языков, а значит, и с уменьшением лингвистического разнообразия на Земле).

Транслингвальный (связан с использованием единиц, средств, реалий одного языка, одной культуры в контексте и средствами иного языка, принадлежащего другой культуре в художественной литературе, фольклоре, публицистике).

Важнейшее условие хорошей речи – логичность. Речь – это связанное целое, и каждое слово в ней, любая конструкция должны быть уместны и обоснованы. Не для всякой социальной группы, не для всякой ситуации уместен один и тот же стиль, но в каждом случае, так же как и в жизни, надо всегда иметь в виду, что уместно. Соблюдение уместности предполагает хорошее знание стилей литературного языка.

Подобно тому, как экология изучает взаимодействие живых организмов между собой, экология языка изучает влияние языков друг на друга и их взаимодействие с внешними факторами. Термин «экология» по отношению к языку был применен Джоном Тримом и случилось это относительно недавно. Но языки в мире всегда находились во взаимодействии и равновесии друг с другом. И с одной стороны это приводит к их взаимному развитию, с другой стороны к ущемлению одного языка другим. Данный факт мы можем наблюдать при проникновении и замещении понятий одного языка другим языком.

Культура речи в ее традиционном понимании – это степень владения литературным языком (его нормами, стилистическими, лексическими и грамматико-семантическими ресурсами) в целях наиболее эффективного общения в различных условиях коммуникации.

Экологический подход к вопросам культуры речи, речевого общения предполагает ответственное отношение к национальным языковым традициям, воспитание действенной любви к родному языку, заботу о его прошлом, настоящем и будущем.

Все это и составляет существо экологического аспекта культуры речи.

Итак, русская речь переживает сегодня состояние острого кризиса. Избавить её от неоправданных заимствований, просторечий и вульгаризмов в одночасье невозможно, невозможно одномоментно изменить психологические приоритеты народа России. Сказанного же здесь достаточно для того, чтобы возрастающую тревогу за судьбу среды нашего обитания, питающую разные направления экологии, распространить и на нашу речевую среду, чтобы то, что мы говорим, и особенно то, как мы говорим, перестало быть только личным делом каждого отдельного человека, а стало бы предметом организованных целенаправленных общих усилий по устранению "речевого мусора".

Литература:

1. Кислицына Н.Н. Эколингвистика - новое направление в языкознании [электронный ресурс]. - Режим доступа: http://www.crimea.edu/tnu/magazine/ culture/culture37

2. Нурушева Д.А. Эколингвистика как раздел языкознания // Фундаментальные исследования. -2014. - № 5-4. - С.890-893.

3. Пылаева. Е.М. К вопросу об эколингвистике в свете современных эколого-эволюционных исследований [электронный ресурс]. - Режим доступа: http://vestnik-rzi.ru/2014/02/1367

4. Потеряхина И.Н. Экологические проблемы языка в современной лингвистике. языкознании [электронный ресурс]. - Режим доступа: http://www. nop-dipo.ru/ru/node/346

## Туган телдә дәшсәм genә, туган җирем мине аңлар

***Автор: Гәрәева Резеда Рамис кызы,***
***Минзәлә медицина училищесының беренче курс студенткасы***
***Фәнни җитәкче: Илдарханова Флүсә Мөхәммәтхаҗи кызы***

Яши минем туган авылым
Биек таулар итәгендә.
Чана шудым шул тауларда,
Чаңгы шудым кичә генә.
Сагынып кайтам,
Киткән идем.
Әйтерсең лә кичә генә.
Балачагым яши монда-
Биек таулар итәгендә
Иске Җияш авылында.
*Диләрә Хуҗина “Туган авыл”*

Татарстанның искиткеч гүзәл табигатьле, саф татар районы булган, татар иленә, халыкка гаҗәеп талантлы шагыйрьләр, җырчылар, фән эшлекләләре биргән Актаныш районында бик кечкенә Иске Җияш авылы бар. Үзе кечкенә булса да, ул зур тарихка ия. Аннан күп кенә танылган шәхесләр чыккан. Шуларның берсе, әлеге шигырь юлларын иҗат итүче - Диләрә Хуҗина. Кайчандыр чем кара чәчле, күзләреннән очкын чәчеп торучы нәни кызчык булса, бүген дә шул ук матурлыгын, илаһилыгын җуймаган әни, дәү әни, шагыйрә.

Язмыш җилләре аны башта Чаллы, аннан Менделеев шәһәренә алып китә. Авылдашымның иҗатында туган тел, туган авыл темасы иң зур урынны алып тора. Үзенең шигырьләре аша туган теленә, туган авылына, туган нигезенә мәдхия җырлый.

Ялагай булалмый шагыйрь

Шагыйрьләр туры була.

Туган җиргә, туган телгә

Сөюдә тугры була.

*"Олы сабый бала без"*

Төрле образлар аша ул туган телнең, туган якның кадерле, изге икәнен җиткерә, туган җир, әти-әни төшенчәләре еш кабатлана, янәшә бирелә.

Гомер буе кайтам, гомер буе

Туган нигез - изге намазлык,

Изгеләрдән-изге сүзләр эзлим

Изге ташларыңа язарлык.

*"Туган нигез"*

Әйе, сокланып туймаслык тугайлары, челтерәп аккан чишмәләре, күңелгә тынычлык бирүче урманнары, мул басулары, шунда гомер кичерүче якыннарыбыз, әткәй-әнкәйләребез булган төбәк ул - туган як. Ярату хисе тәэсирендә туган җиргә багышланган саф татар телендә илаһи әсәрләр языла.

Шагыйрәнең күп кенә шигырьләре туган як табигатенә дан җырлый.

Сарыдан түшәлгән юллары,

Һавада пәрәвез йомгагы.

Дөньяның иң матур чаклары

Урамда- әбиләр чуагы.

*"Әбиләр чуагы"*

Туган авылым Иске Җияш Шәбез елгасы ярларында урнашкан. Елга атамасы- шәп, тиз агучы елга дигәнне аңлата. Кайчандыр авыл халкының төп су чыганагы булган ул. Буалар буылган, су тегермәннәре эшләгән. Ел саен буаларны җибәргәннәр. Язгы ташу бар утырымны агызып алып киткән. Шунлыктан елганың суы тирән, чиста, вак балыкларга бай булган.

80 нче елларда, басуларга су сиптерү максатыннан, барлык уңайлыклары булган дамба төзелә. Басу-кырларны сугару эше туктатылгач елга үзеннән-үзе сула. Хәзер инде ул сай гына инешне хәтерләтә. Зур акчаларга төшереп салынган дамба да җимерек хәлдә. Ә иң аянычы авыл чүплеге Шәбез елгасы ярында урнашкан. Язгы ташулар вакытында елга белән

бергә чүплек тә ага. Авыл чүплегенә нәрсәләр түгелгәнен күз алдына китерә аласыздыр. Шәбез, Шәбездән соң Агыйдел...Шагыйрәбез дә шулар өчен борчыла.

Мин киләчәк язмышымны сәламәтлек сагында эшләүче, шәфкать туташы һөнәре белән бәйләдем. Шушы фәнни эшкә әзерләнгәндә, үземнең һөнәремә бәйле яңалыклар да таптым.Нәкъ шушы Шәбез елгасы ярында үзле, майлы кызгылт балчык барлыгын, аның сөяк-буын, тире авырулары, теш казнасы сихәтләре өчен файдалы булуын белдем. Туган авылыбыз умбы (торф) кебек файдалы казылмага бай булуы белән дә дан тота. Күп кенә чирләрдән дәва бирүче, шифаханәләрдә дәвалау чыганагы буларак кулланылучы күкертле ләм шушы торф чокырлары төбендә ятуы белән таныштым. Элекке заманнарда хәзерге кебек дәвалау чаралары булмаган. Өлкәннәр  сөйләвенчә, җәйге чиллә вакытларында олы яшьтәге әби-бабайлар шушы ләмгә аякларын күмеп утырып, үзләренең сырхауларына шифа таба торган булганнар.

Якташым Диләрә апаның шигырьләре үзләренең тормышчанлыгы, гадилеге, эчкерсезлеге белән күңелне җәлеп итә. Бөек шагыйрьләргә ияреп, ул үзенең туган ягы, аның тырыш халкы, туган телебез - татар теле өчен җан ата. Туган як - ул безнең әби-бабаларыбыз, әткәй-әнкәйләребез яшәгән, безнең кендек каныбыз тамган, без тәүге кат тәпи баскан җир. Туган телебез - татар теле, без беренче аваз-сүзләрне әйткән, бай, ягымлы, иң аһәңле тел. Туган як, туган тел - аларербөтен. Бер-берсен яклаучылар, саклаучылар.

“Туган телдә җырлый чишмә,
Туган телдә шаулый таллар.
Туган телдә дәшсәм генә,
Туган җирем мине аңлар”

*Рәзил Вәлиев*

Кулланылган әдәбият:


1. Йосыф Хуҗин “Уртак язмыш кояшыбыз”, Яр Чаллы Дәүләт Педагогия институты, 2011 нче ел
2. Диләрә Хуҗина “Көзге моң”, Менделеевск, 2008 нче ел
3. Диләрә Хуҗина “Вакыт бар”, Менделеевск, 2010 нчы ел

# Мин тормышка гашыйк.

***Гиздатуллина Ләйсән Рәсих кызы,***
***Минзәлә шәһәренең 11 нче сыйныф укучысы,***
***Фаррахова Резеда Рәҗәп кызы,***
***Минзәлә шәһәренең I нче кв.категорияле***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы.***

Туган авыл дип әйтүгә, минем күз алдыма мәһабәт агачлар, яшел урамнар, матур өйләр килә. Ә мин шәһәрдә тусам да, туган шәһәрем Минзәлә нәкъ менә шундый. Бәлки миңа гына шулай тоеладыр, ләкин минем туган шәһәремнән дә гүзәлрәк, рәхәтрәк җир дөньяда юк. Урман шавы, кошлар аһәңе, күке авазы миңа кечкенәдән үк таныш, чөнки Минзәләне һәряклап урман әйләндереп алган. Саф һавада, урман гүзәллеген тоеп, яшеллеккә күмелеп үстем.

Кайтып киләм урман сукмагыннан,
Шундый рәхәт, җиңел атларга .
Белмим, нинди сихри магнит шулай
Тарта икән туган якларга.
Битләремнән,чәчләремнән сыпырып,
Дәү юкәләр мине иркәли.
Бөтенесен шулай онытырып
Баштан сыйпый иде тик әни.
Әнкәй кочагыдай рәхәт икән
Туган якның бөтен җире дә.
Балачагым кабатлана кебек
Һәр яфракта, һәрбер бөредә.

Бу юллар яраткан язучыбыз Фәнис Яруллинның “Туган як табигате” шигыреннән алынган . Ул 19 яшендә күнегүләр ясаганда имгәнеп, хәрәкәтсез кала.Шулай да үзендә яшәр, иҗат итү өчен көч таба алган. Мондый корыч ихтыярлы язучыны мин батырлык үрнәге дип атар идем.

Ул 55 елга якын урын өстендә ятса да,чын мәгънәсендә тормышны яратып яшәде.Рухи көченә таянып, 51 китап чыгарды. Булмәсендә яткан килеш тә аның күзләре күпне күрә, колаклары күпне ишетә.Тынгыгысыз җаны барысын да тоеп-сизеп тора. Ак кәгазь битенә язылган тылсымлы сүзләрен укыган саен укыйсың, кат-кат укып төрле мәгънә бизәкләре табасың. Заман сулышын тоеп язылган сүзләре безне уйландыра, яңадан алып укырга мәҗбүр итә.

Югары эстетик зәвыкка ия булган күпкырлы талант иясе Ф.Яруллин нинди генә жанрда язмасын үз әсәрләрендә матурлыкны, камиллеккә омтылышны һәм рухи байлыкны иң зур кыйммәтләрдән саный. Үзенең укучыларына да шушы идеяне ирештерергә омтыла. Әдип иҗатында табигать образы еш кулланыла икән, әлбәттә ул фон өчен генә түгел, ә матурлыкны кеше белән табигатьнең гармониясе аша сурәтләү өчен алына. Кеше һәм табигать — living бербөтен. Шушы бөтенлек саега башлаган күңел байлыгын тулыландыра, аңа бизәкләр өсти. Тау, елга һәм чишмәләр, урман-кырлар, чәчәкле болыннар, кояшлы, айлы, йолдызлы күкләр; җил-давыллар, кар-бураннар, болыт һәм яшеннәр; чиксезлек һәм кешенең үзенә генә билгеле булган микродөньясы - болар әдипнең яратып кулланган образлары. Табигать төрле халәттә, төрле төстә булган кебек, әдип әсәрләрендә дә мондый халәтләр җанның бөеклеген яки түбәнлеген, хисләрнең төрлелеген, кичерешләрнең катлаулы яки тирәнгә яшерелгән икәнлеген күрсәтү өчен кирәк.

Автор үзенә иҗат дәрте , яшәү көче биргән туган җире , туган авылы, аның кешеләре белән рухланып яшәде.

Төп девизы “Кыю булу”

Язмыш синең тез астыңа китереп сукса – егылмас өчен якасына ябыш. Утларга салса – үзең аннан да көчле ян, шул вакыт аның кызуын сизмәссең. Суларга ташласа – күбек булып өскә күтәрелмә - асылташ булып төпкә бат, ялтыравыңны күреп, чумып алырлар. Тузан итеп һавага күтәрсә - яңгыр тамчыларына кушылып, җиреңә төш. Карурманнарда адаштырса – кояшка карап юл сайла. Ташлар белән бастырса – чишмәгә әверелеп, иреккә ургы. Җиргә күмсә - орлык шикелле тишелеп чык. Җилкәнеңне җилләр екса – йөрәгеңне җилкән итеп күтәр. Нинди генә очракта да җиңәргә өйрән. Көчле рухлылар гына максатка ирешә алалар, түземнәр генә бәхеткә лаек.

Мәхәббәт белән яшәү, гаилә бөтенлеге Фәнис абыйны бәхетле итә, аның иҗатына дәрт өстәп тора. Аның тормыш иптәше -Нурсия апа шагыйрьнең гомерлек тормыш иптәше, ярдәмчесе.

Фәнис абый үзе: “Минем секретарь-машинисткам да, шоферым да, шәфкать туташым да, сөйгән ярым да – Нурсөя,” – ди бу турыда. Шагыйрьнең лирикасында мәхәббәт темасы зур урын алып тора. Монда,һичшиксез Нурсөя апаның да өлеше зур. Чөнки шагыйрь аңа үзенең иң матур җырларын багышлаган.

“Минем канымда февраль бураннарының уйнаклыгы, күңелемдә Өемташ тавының горурлыгы, җанымда Ык елгасының ярсуы, хисләремдә мең төрле әрәмә чәчәкләренең назы, холкымда дала җилләренең үҗәтлеге, бәдәнемдә тау имәннәренең ныклыгы бар. Шушы сыйфатлар үз шигъри гөлемне үстерергә, үз гөлләремнең орлыкларын кешеләр күңеленә чәчәргә мөмкинлек бирде,” –дип яза.

Миннән кайвакыт “Син бәхетлеме?” – дип сорыйлар. Учларында утлы чәчәкләр үстереп, ул чәчәкләремне күккә йолдыз итеп сибә алган кеше бәхетсез буламыни? Әгәр йөрәгеңдә яшәү өметең сүнмәсә, караңгы-шомлы төннәрдә күңелеңә куркаклык ояламаса, төн артыннан көн туачагына ышанычың бетмәсә, димәк син әле яшәячәксең. Шигърияткә, туган җиргә гашыйк шагыйрь.

**Кулланылган чыганаклар һәм әдәбият исемлеге**

1.Хуҗиәхмәтов Ә., Хәкимова С. Шәхес, шагыйрь, тәрбияче / Мәгариф. - 2003. - №1. - 10б.

2 Яруллин Ф. Яралы язмышлар / Фәнис Яруллин. – Казан : Рухият, 2000. – 439 б.: портр. – Татар, рус һ. ингл. – 3000 д.

## Муса Җәлилнең “Илдар” либреттосында табигать күренешләренең символик образ буларак бирелеше.

***Гыйльманова Динара Марат кызы,***
***“Тәтеш дәүләт гражданнарны яклау колледжы” ДАҺБУ студенты.***
***Җитәкчесе - Арсланова Сәлимә Сәләхетдин кызы.***

Муса Җәлилнең “Илдар” либреттосы алма бакчасында эшләүче кызларның шат җырлары белән башланып китә:

*Без үстергән алмагачның*

*Алмалары бал гына,*

*Алма белән сыйлансыннар*

*Эштә уңганнар гына.*

Әсәрдә алма бакчасы - символик образ. Шагыйрь тыныч, эш сөюче халыкның бәхетле мул тормышын алма бакчасы сурәтендә символлаштырып, гомумиләштереп күрсәтә. Алма җыючы кызлар җыры шул образлылыкны көчәйтә:

*Алмагачның алмасын*

*Ятлар килеп алмасын!*

*Килсә җавап кыска булыр,*

*Юкка хыялланмасын!*

Халык иҗатыннан оста файдаланылган әлеге җырда күмәк хезмәт барышы, оешканлык, рухи күтәренкелек атмосферасы белән, гади һәм җыйнак пафослы итеп, кешеләрнең шатлык тулы тормышы гәүдәләндерелә. Шау чәчәккә күмелгән алма бакчасы

образы драматик поэманың башыннан алып ахырына кадәр үтә. Ул – ватанпарвәр шагыйрьнең туган иле, газиз җире символы.

Вакыйгалар Татарстанның Идел елгасы буендагы матур табигатьле бер татар авылында, Акъярда, бара. Әсәрдә Акъяр - язын шау чәчәккә күмелүче алма бакчалы авыл. Ул алма бакчасы белән генә түгел, ә кешеләренең хезмәт сөючәнлеге, батырлыгы, шаян, җор телле һәм башка шундый бик матур сыйфатларга ия булуы белән дә характерлы. Димәк, либреттист авыл исемен очраклы куймаган, ә авыл атамасына тирән мәгънә һәм образлылык салган.

Ономаст галим Гомәр Саттаров фикеренчә, *Акъяр* сүзе *ак* һәм *яр* сүзләренең кушылмаларыннан тора. *Ак* - төрки-татарча сүз; ак төс татарларда борын-борыннан сафлык, пакълек, якты, нурлы; яхшы теләк, ышаныч, тугрылык, намуслылык һ. б. күркәм сыйфатларның симолы булып саналган. Аның пакъ, керсез, саф, якты, нурлы, күркәм, гүзәл, асыл, бәхет, шатлык һ.б. кебек күчерелмә мәгънәләре булган [1, 29 б.].

“Илдар” – реаль чынбарлыкка корылган әдәби әсәр. Анда Җәлилнең “Алтынчәч “ либреттосындагы Алтынчәч, Җик кебек табигатькә якынайтылган образлар юк. “Илдар” геройларына реаль кешеләргә хас көнләшү, шаяру, курку, икеләнү кебек табигый хисләр дә ят түгел. Урын атамалары да әсәрдә үзләренең беренчел функцияләре – билгеле бер төбәккә беркетү ролен башакаралар. Шулай да либреттист алма бакчалы, Идел буендагы колхозның исемен “Таң” дип атаган. Таң – татар сүзе, ул – матурлык, яшьлек, яңа туар көнгә өмет, бәхет көтү, матур киләчәк символы. Димәк, Акъяр авылы, “Таң” колхозы кешеләре киләчәккә якты өметләр баглап яшиләр. Шулай итеп, шагыйрьгә Ватанга мәхәббәт, тынычлык һәм ирек өчен көрәш, тугры саф сөю идеяләрен үткәрүдә кече ватанының гүзәл табигатен тасвирлау һәм искиткеч матур поэтик эчтәлеккә бай топонимнар хезмәт итә дияргә мөмкин.

Туган табигатебезне чын йөрәге белән тоя белүче шагыйрь аны *тын яланнар, бөдрә таллар, тын камышлар, агым сулар,киң басулар,алсу таң, бәхетле яз, яңа таң* кебек метафорик эпитетлар ярдәмендә тасвирлый. Либреттода табигать күренешләре матурлык, бәхет, ирек символы буларак кулланыла. *Бәхетле яз, данлы яз, матур яз!* Шагыйрь язга мөрәҗәгать итә, аны чакыра, көтә. Нәкъ менә яз яңару, яшәеш, бәхет, татулык , тынычлык ае бит! Әйтерсең, Җәлил алдан күрү сәләтенә ия булган һәм Бөек Ватан сугышындагы Бөек Җиңүнең нәкъ матур яз аенда булачагын пәйгамбәрләргә хас төгәллек белән әйтеп биргән!

Кулланылган әдәбият

1. Саттаров Г. Ф. Ни өчен шулай аталган? (Татарстан топонимнары) – Казан: Тат.кит.нәшр., 1971.-127 б.

# Теле барның- иле бар

***Дәүләтшина  Ландыш Фаилевна***
***(Субаева Миңнегөл  Шамсулловна),***
***3 курс, Казан медицина көллияте***

Туган ил, Туган тел, туган җир, туган авыл... Кешене кеше, халыкны милләт иткән иң изге төшенчәләр шулар бит!

Туган авылым! Арташым! Нинди гүзәл син! Синең гүзәл табигатеңә кемнәр генә сокланмаган. Туган авыл,туган җир, аның үткәне, бүгенгесе,киләчәге – зур һәм тирән мәгънәгә ия төшенчәләр алар.

Бала дөньяга килгәндә үк , беренче тапкыр туган нигезендә үзенең тавышын яңгырата. Бу вакытта әле ул бернәрсә аңламаса да , әни назын тоеп , ата-баба нигезендә яши башлый. Мин дә кечкенәдән ата –ана назын тоеп , аларнын сүзенә колак салып үстем . Әби-бабамның : “Туган –үскән җиреңдә мәрхәмәтле бул,  телеңне онытма,сакла !”  - дигән сүзләре дә хәтеремә бик тирәнтен уелып калды . Ничек соң инде шундый гүзәл табигатьле , газиз туган авылымны , халкымны ,аның телен онытырга мөмкин!?

Безнең Арташ якларына  Аллаһ Тәгалә матурлыкны мулдан биргән. Яшәү чыганагы булган җире, суы иркен, күз күреме иңләп бетерә алмаслык басу- тугайлары күнелгә ятышлы. Матур табигать кочагына кереп  урнашкан авылым чишмәләргә  дә бай.Һәр чишмәнең үз тарихы ,үз моңы, үз юлы бар.Бер ишесе шарлап ага , икенче төрлеләрнең тавышы янына килгәч кенә ишетелә, өченчеләре – җир куеныннан кайнап ,ургылып чыга,әйтерсең лә ул ,җир асты юллары уза-уза ялыккан ,арыган.Аның якты кояш нурларын күрергә зарыккан сулары ашыга-ашыга өскә күтәреләләр,яктылыкка ашкыналар, җир өстенә омтылалар. Аларның һәрберсенең үз исемнәре бар. Мәсәлән: “Сәйфиулла”, “Хәбибулла”, “Җамбай” чишмәләре. “Хәбибулла” чишмәсе минем нәсел шәҗәрәмә барып тоташкан. Бу чишмәләр бүгенге көндәдә яныннан узучылырны чиста, саф суы белән сөендереп тора. Шунысы сөенечле,авылыбыз халкы аларны карап , тәрбияләп тора. Авылыбызның тагын бер гүзәллеге булып , аны уратып алган  елгалары , җиләкле тау битләре , урман-кырлары сузылып ята.Безнең бурыч : җанга рәхәт, тәнгә сихәт биргән  бу гүзәллекне киләчәк буыннарга да чиста килеш ташыру.

Һәр авылның үз үсеш тарихы, үз даирәсе, үз мохите, үзенең данлыклы кешеләре бар. Безнен Олы Арташ авылы  да үзенең үстергән уллары һәм кызлары белән  горурлана ала .Туган ягымда туып үскән кешеләр арасында игенчеләр , укытучылар , табиблар, инженерлар һәм башкалар бар.Авылым тарихи шәхесләргә дә бай .

Алар арасында Татарстаннын атказанган сәнгать эшлеклесе ,сынчы –Кәдим Җәмитов , Татарстан Республикасының атказанган артисты , Муса Җәлил премиясе лауреаты- Шамиль Бариев, Татарстанның атказанган рационализаторы Раиф Бариев ,филология фәннәре докторы, профессор Әбрар Кәримуллин ,музыка белгече, Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе,,профессор Мәхмүт Нигъмәтҗановлар бар. Безнең як халкы үз җиренән чыккан талантларны һәрвакыт ихтирам итә, һәм алар белән хаклы рәвештә горурлана.

Димәк, туган ягыбызның һәр сукмагы , һәр агачы, чишмә сулары белән бер рәттән , аның кешеләре дә күңелгә бик якын.Безнең як халкы үз җиреннән чыккан талантларны һәрвакыт ихтирам итә, алар белән хаклы рәвештә горурлана.

Шундый гүзәл табигатьле һәм талантлы кешеләргә бай булган туган авылым Арташ , һичшиксез, илебез тарихында булырга тиеш. Миңа бу эзләнү эшем авылым турында бик күп мәгълүмат тупларга, халкым тарихын күберәк белергә ярдәм итте. Без әле белеп бетермәгән күпме тарих, мирас яшеренеп ята икән бит ,бер гади генә татар авылында. Мин бу өлкәдә эзләнүемне, аеруча чишмәләргә кагылышлы вакыйгаларны өйрәнүемне киләчәктә дә дәвам итәчәкмен. Чөнки, туган телем белән, туган җирем минем өчен иң газиз, аерылгысыз төшенчәләр.Бу эшемне Нажар Нәҗминең шигырь юллары белән тәмамлыйсым килә:

Туган җирем Идел буе,
Һәр телнең бар туган иле.
Туган җирем кебек назлы,
Җырдай моңлы татар теле.

Кулланылган әдәбият:


1. Саба районы Олы Арташ музееннан алган мәгълүматләр.
2. Ф.Гарипова “Авыллар һәм шәһәрләр тарихы”.
3. С.Г. Исмәгыйлова “Табигать тасвирлары-тәрбия чарасы”


## Великолепия природы и многогранность человека в литературе XX века.


***ФИО автора: Димухаметова Айзиля Рузилевна, студентка 2-курса 0251б группы по специальности 08.01.14Экономика и бухгалтерский учет (по отраслям).***
***ФИО руководителя: Гильфанова Муршида Авхадиевна, преподаватель русского языка и литературы 1-ой квалификационной категории.***


На протяжении столетий писатели и поэты русской литературы поднимают извечную проблему — это взаимосвязь природы с окружающим миром, с человеком. Писатели XX

века продолжили лучшие традиции своих предшественников. В своих произведениях они показывают, какими должны быть отношения человека в бурный век научно-технической революции к природе.

Природа для писателей - не просто среда обитания, она - источник доброты и красоты. В их представлениях природа связывается с истинной человечностью, остановить научно-технический прогресс невозможно, но очень важно задуматься над ценностями человечности.

Мир природы становится для писателя источником вдохновения и художественных замыслов. Некогда увиденные, прочувствованные, а затем преобразованные авторским воображением картины природы органично вписывались в ткань его произведений, служат основой многих сюжетов, участвуют в раскрытии характеров персонажей, вносят в его прозу жизненную достоверность и придают произведениям особый, неповторимо художественный и эмоциональный колорит.

Неповторимую прелесть и многообразие природы родного края раскрывают в своих произведениях многие писатели: И. А. Бунин, А. И. Куприн, К. Г. Паустовский, М. М. Пришвин. Каждая встреча с природой — это встреча с прекрасным, неизведанным, это прикосновение к тайне. С приобщения к миру красоты родной природы начинается любовь человека к Родине.

Творчество Михаила Михайловича Пришвина от начала до конца полно глубокой любви к родной природе. Пришвин был одним из первых, кто заговорил о необходимости сохранения равновесия сил в природе, о том, к чему может привести расточительное отношение к природным ресурсам.

Не зря Михаила Пришвина называют «певцом природы». Этот мастер художественного слова был тонким знатоком природы, прекрасно понимал и высоко ценил ее красоту и богатства. В своих произведениях он учит любить и понимать природу, нести ответственность перед ней за ее использование, причем не всегда разумное.

Одним из продолжателей пришвинских традиций в литературе стал Константин Георгиевич Паустовский. Рассказ Паустовского «Телеграмма» начинается так: «Октябрь был на редкость холодный, ненасытный. Тесовые крыши почернели. Спутанная трава в саду полегла, и все доцветал и никак не мог доцвести и осыпаться один только маленький подсолнечник у забора. Над лугами тащились из-за речки, цеплялись за облетевшие ветлы рыхлые тучи. Из них назойливо сыпался дождь. По дорогам уже нельзя было ни пройти, ни проехать, и пастухи перестали гонять в луга стадо».

Подсолнечник в этом эпизоде символизирует одиночество Катерины Петровны. Умерли все ее сверстники, а она, как маленький подсолнечник у забора, пережила всех. Из

последних сил пишет Катерина Петровна письмо любимой дочери: «Ненаглядная моя! Зиму эту я не переживу. Приезжай хоть на день ... Так тяжело; вся жизнь, кажется, не была такая длинная, как одна эта осень». Через весь рассказ проходит параллель - человек и родная природа, Катерина Петровна «остановилась у старого дерева, взялась рукой за холодную мокрую ветку и узнала: это был клен. Его она посадила давно..., а сейчас он стал облетевший, озябший, ему некуда было уйти от этой беспристрастной ветреной ночи».

Другой рассказ Паустовского «Дождливый рассвет» переполнен гордостью, восхищением красотой родной земли, вниманием к людям, влюбленным в эту красоту, тонко и сильно чувствующим ее прелесть.

Паустовский прекрасно знал природу, его пейзажи всегда глубоко лиричны. Особенностью писателя является его манера недоговаривать, не дорисовывать, он предоставляет читателю завершить в своем воображении ту или иную картину. Паустовский прекрасно владел словом, являясь подлинным знатоком русского языка. Одним из источников этих знаний он считал природу: «Я уверен, что для полного овладения русским языком, для того, чтобы не потерять чувства этого языка, нужно не только постоянное общение с простыми русскими людьми, но также общение с пажитями и лесами, водами, старыми ивами, с пересвистом птиц и с каждым цветком, что кивает из-под куста лещины» [4, с. 16].

Паустовский рассказывает о сокровенной прелести природы людям, еще не понявшим, что «родная земля - самое великолепное, что нам дано для жизни. Ее мы должны возделывать, беречь и охранять всеми силами своего существа».

Сейчас, когда проблема охраны природы находится в центре внимания всего человечества, мысли и образы Паустовского имеют особую ценность и значимость.

Список литературы:

1. Белая, Г.А. Художественная мир современной прозы Текст. - М.: Издательство «Наука», 2011 - 192с.

2. Залыгин С.П. Литература и природа. // Новый мир. 1991. №1. с. 10-17.

3. Липин, С.А. Человек глазами природы: Монография - М.: Издательство «Советский писатель», 1985- 232 с.

4. Шкловский, Е. В поисках гармонии (Пришвин и Паустовский) // Пришвин, М.М. Повести. Рассказы / М.М. Пришвин, К.Г. Паустовский. – М.: ООО «Издательство АСТ»: ООО «Агентство «КРПА «Олимп», 2001. – С.5-16.

## Табигать ул үзен яклый алмый,Үч тә ала алмый кешедән…

***Автор - Зарипова Зөлфия Илфак кызы,***
***II курс, 2А төркем студенты,***
***җитәкчесе – Талипова Гөлназ Фазыл кызы,***
***ДАҺБУ “М.Җәлил исемендәге***
***Минзәлә педагогия колледжы”***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

Күпкырлы талант иясе булган Фәнис Яруллин өчен иң зур кыйммәтләрдән матурлык, камиллеккә омтылыш һәм рухи байлык санала. Нинди генә жанрда иҗат итүенә карамастан, һәрбер әсәрендә әдип матурлыкны кеше белән табигатьнең гармониясе аша сурәтли. Кызганычка каршы, замана алга барып, яңа технологияләр арткан саен, экологик проблема кискенләшә бара. Кешенең эшчәнлеге һәрчак уңай нәтиҗәләр бирми. Киресенчә, күп очракта табигатькә фаҗигале үзгәрешләр алып килә, әйләнә - тирәбезгә зыян сала. Нәтиҗәдә, безнең алга җирдәге бөтен тереклек юк ителү куркынычы килеп басты. Һәм, билгеле, бу проблема Фәнис Яруллинны да битараф калдырмый. Кеше белән табигатьне бербөтен, аерылгысыз ике образ буларак сурәтләгән автор шушы тәгълиматны укучыларына аңлату эшен башкара.

Урман – колак, кыр – күз,
Шулай булган элек:
Урман-кырлар барсын
Торган ишетеп, күреп.
Бермәлне без кинәт
Иркенлеккә чыктык:
Урман колагына
Балта белән сукты.
Чукракланды урман,
Ишетмәде берни.
Бульдозерлар анда
Йөрде бии-бии.
Химиябез белән
Сукырайттык кырны,
Соңгы тургай белән
Җиргә күмдек җырны... дип яза ул кешенең табигатькә тискәре йогынтысы турында.

Экология аша әхлакый тәрбия бирүне без Фәнис Яруллин әсәрләрендә ачык күрә алабыз. Кайбер әсәрләрендә ул укучыларын табигатьнең матурлыгын, анда булган үзгәрешләрне күрергә өйрәтсә, икенчеләрендә экологик проблемаларны сурәтләп бирә, табигатьне сакларга, якларга өнди:

Табигать ул үзен яклый алмый,

Үч тә ала алмый кешедән.

Ул бары тик рәнҗи генә ала,

Куркыйк шушы рәнҗеш төшүдән.

... Рәнҗемәсен, үзенең яклаучысы

Кеше икәнлекне белсен ул.- дип яза автор “Рәнҗемәсен” шигырендә.

Тәрбия бирү эше бит ул характер формалашканчы кече яшьтән үк башкарылырга тиеш. Әдип моны бик яхшы аңлый һәм балалар өчен иҗат иткән әсәрләрендә – әкиятме ул, хикәя яисә шигырьме – автор үзенә кечкенә эчкерсез күңелле укучыларына экологик белем һәм тәрбия бирү, аларда экологик культура формалаштыру, табигатькә кызыксыну уяту, аны саклау проблемаларын дөрес аңлау, табигатьтә үзеңне тота белү күнекмәләре булдыру максатын куя. Шунлыктан, үзенең балалар өчен язган әсәрләрендә Фәнис Яруллын олы кеше буларак үгет-нәсихәт тә бирә (мәсәлән, “Яңа ел төнендә” исемле әкиятендә “...урманга бару кирәк, ләкин биленә балта кыстырып түгел, учларыңа бәйрәм күчтәнәче тотып...Әгәр урманга алып барырга күчтәнәчебез юк икән, һич югы, җылы кулыбыз белән чибәр чыршыларның башларыннан сыйпыйк. Без яратып башларыннан сыйпасак, алар тагын да матурланыр һәм шушы гүзәллеге аларның безгә рәхмәте, бүләге булыр” дип яза автор), кайберләрендә исә табигать элементын җанландырып турыдан-туры ярдәм сорап укучысына мөрәҗәгать итә:

Суыргалар суларымны,

Саегамын эсселәрдә,

Саексам да, ялыксам да,

Үпкәләмим кешеләргә.

Бирешмим мин суыкларга,

Бирешмим мин эсселәргә.

Минем үлемем – пычрануда,

Белсен шуны кешеләр дә! (“Елга монологы”).

Табигатьне якыннан белми торып, экологик проблемаларны күрү мөмкин түгел. Һәм автор үзенә кечкенә укучыларын табигать белән якыннан таныштыру эшен йөкли: әкиятләре аша балаларны флористика, хайваннар дөньясы, күк җисемнәре белән таныштыра, шигырьләрендә табигатьтә булган үзгәрешләрне сурәтли. Кеше – табигатьнең аерылгысыз бер өлеше. Ул табигатьтән башка бер генә көн дә, бер генә сәгать тә, бер генә минут та яши алмый, аңа су, һава, азык-төлек, җылылык һәм яктылык кирәк. Шуңа күрә табигатькә мөнәсәбәт, кешеләргә мөнәсәбәт кебек үк, гуманлы, шәфкатьле булырга тиеш. Кызганычка каршы, җир үзенең табигый тотрыклылыгын мәңге саклый алмый, шуңа да кеше алдында

экологик проблемаларны чишү максаты тора. Киләчәк буынның сау-сәламәт туып үсүе өчен дә табигатьнең, тирә-якның чиста, төзек һәм сәламәт булуы шарт.

Җиребез бер генә, күгебез бер генә

Бергәләп төшеник шуларның серенә.

Җиребез хакына, күгебез хакына

Мәрхәмәт саклыйк без күңелләр түрендә! – ди Фәнис Яруллин. Чөнки әхлакый тәрбия алган, күңелендә мәрхәмәт булган кеше генә рухи байлыкны материаль байлыктан өстен күреп, экологияне саклау эшләре алып барырга мөмкин.

Әдәбият исемлеге

1.Яруллин Ф. Әсәрләр. I том. Татарстан китап нәшрияты. – Казан, 2007. – 496 б.

2.Яруллин Ф. Әсәрләр. III том. Татарстан китап нәшрияты. – Казан, 2008. – 431 б.

## Ленар Шәех иҗатында кеше һәм табигать бәйләнеше.

***Зарипова Алсу Мулланур кызы,***
***җитәкчесе – Тимереева Әлфия валерий кызы,***
***II курс, С-9-22 төркем студенты,***
***ДАҺББМУ “Казан төзелеш көллияте”нең “Биналар***
***һәм корылмалар төзү, кулланышка тапшыру”белгечлеге.***

Татар әдәбиятында кешеләрнең тормыштагы иҗтимагый-әхлакый позициясен ачканда әдипләр аларның табигатькә мөнәсәбәтенә еш игътибар итәләр. “Табигать һәм кеше” мәсьәләсе әдипләрне төрле яклап кызыксындыра. Бу табигый дөньяның рухи-әхлакый мәгънәсе, бөтен җәмгыять һәм аерым шәхес тормышындагы роле турында әле публицистик, әле лирик-фәлсәфи планда фикер йөртелә, табигатьне сакларга кирәклеге белдерелә. Әсәрләрдә кешенең табигатьтән, туган яктан аерылмаска, киресенчә, алар белән органик бәйләнештә яшәргә тиешлеген ачуга басым ясала, шушы идея төрле шигъри алымнар һәм чаралар ярдәмендә гәүдәләндерелә. Аерым очракларда милли-табигый нигездән аерылу кешеләрне нинди зур рухи-әхлакый югалтуларга китерүе дә күрсәтелә.

XXI гасыр татар әдәбиятына бер төркем яшь язучылар, шагыйрьләр алып килде. Аларның көчле бер дулкынына этәргеч булып 2002-2003 елларда Казан дәүләт университетында яңадан эшли башлаган “Әллүки” әдәби-иҗат берләшмәсе торды. Галимҗан Гыйльманов җитәкчелегендә Ленар Шәех, Рифат Сәлах, Йолдыз Миннуллина кебек студентлар шигърият юлына ныклап аяк бастылар. Әлбәттә, алар моңа кадәр дә иҗат иткәннәр, газета-журналларда басылып чыкканнар, әмма университет укытучылары, түгәрәк җитәкчеләре, түгәрәк әгъзалары ярдәме дә аз булмады.

Шушы зур төркем иҗатчылар арасыннан аерып бер шагыйрьне атап үтәсе килә. Казан төзелеш көллиятенең күптәнге дусты, яраткан шагыйребез – Ленар абый Шәех! “Безнең татар шигъриятенә күптән инде Ленар Шәех кебек бер егет кирәк иде. Менә ул килде. Яшенә карата шактый зур багаж белән. Әдәбиятка җитди караучы, өлгергән өлгер шагыйрь булып, чын әдәбият кешесе булып” [1, с.3] дип яза Роберт Миңнуллин аның иҗатына бәя биргәндә. Ленар абый иҗатын карап китсәк, андагы темалар байлыгының зурлыгына игътибар итәсең: туган як, сөйгән яр, яшьлек хисләре, балаларга багышланган темалар... Үзенең хис-кичерешләрен тасвирлау өчен ул еш кына табигать күренешләренә мөрәҗәгать итә. Ә башкача мөмкин түгел? Яшь йөрәкнең ярсып, шашып тибүен, хисләрнең мөлдерәмә ташып торуын яисә үпкә катыш ачу сүзләрен бары тик табигать күренешләре аша гына биреп буладыр, мөгаен.

Ап-ак кышның моңлы көне.

Бөтен җаным гамьгә тарый.

Синсез авыр. Карлар явар,

Илдар абый, Илдар абый...

дип яза автор халык шагыйре, остазы Илдар Юзеев истәлегенә багышлап язылган “Илдар абый” исемле шигырендә. Ленар Шәех өчен И.Юзеев шагыйрь генә түгел, аңа юл күрсәтүче дә, тәүге адымнар ясаганда киңәш бирүче дә иде. Аны югалтуны яшь шагыйрь авыр кичерә.

Табигать һәм кеше! Аларны шагыйрь иҗатында бер-берсеннән аерып алу мөмкин дә түгел. Адәм – табигатьнең бер аерылгысыз өлеше. Тирә-юнебез гөл-чәчәккә төренеп балкып торганда ничек күңелле бит!

Гамьсез яфрак буйлап тәгәрәгән тамчы кебек,

Мин яратам сине...

Тын елганы назлап кыбырсыткан җилкәй кебек,

Мин яратам сине...

Карурманга үтеп кергән кояш нуры кебек,

Мин яратам сине...

Буш түтәлдә шытып чыккан ялгыз гөлкәй кебек,

Мин яратам сине...

“Ленар Шәех сүзләрне ягымлы, ипле, моңлы бер шигъри тәртипкә китерә белә.....шигырьләр сиздермәстән генә моң-сагышка әверелә”. [2, с.4] Укыйбыз да сокланабыз, укыйбыз да горурланабыз: ничек аһәңле яңгырый татар теле, никадәр матур сүзләр бар телебездә.

Шагыйрь үзенең “Җылытасы килә дөньяны!” дип исемләнгән шигырендә дөньяны каплаган проблемеларның авыр, җан өшеткеч булуын искәртеп үтә. Кайсы гына сорауны алсак та, кайсы гына мәсьәләне карасак та, чишелеш тә гади булуына шиге юк икәнлеген белдерә. Уйлап карасаң, бу чыннан да шулай бит: табигатькә янаган гомумэкологик проблемаларны бары тик кеше генә чишә ала.

Мин үзем дә җылы бирә алам,

Тилмермәсен кеше, көтмәсен.

Яфрак хәтле гомер җылы эзләп,

Ялкын эзләп кенә үтмәсен!...

Тагын бер шигырьгә игътибарны юнәлтәсе килә: “Юрау” дип исемләнгән шигырьдә шагыйрь төрле проблемаларга кагылып үтә. Басым ясап әйтмәсә дә укучыга уйланырга җирлек калдыра.

Мең еллык тузанны

Яз җиле актара;

“Бу Казан тыштан ак,

Ә эчтән кап-кара...”

Таш ташка сүтелгән

Тузанын өйләрнең

Мин сиңа, җай чыккач,

Әле бер сөйләрмен...

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: Ленар Шәех иҗаты әле тулысынча тирәнтен өйрәнелмәгән, бу мәкалә безнең беренче адымыбыз булып кына тора. Киләчәктә дә әдип иҗаты белән танышып, аның белән очрашып, әңгәмәләр кору безгә бу эштә зур ярдәм күрсәтер дип ышанып каласы килә.

Кулланылган әдәбият:

1. Шәех Л.М. Дүртенче кат...Бишенче кат...: шигырьләр, поэма / Ленар Шәех; кереш сүз авт.:Р.Миңнуллин.- Казан: Татар.кит.нәшр.,2008.-176б.-2000д.

2. Шәех Л.М. Җылытасы килә дөньяны!..: шигырьләр, поэмалар / Ленар Шәех; кереш сүз авт.:Зөлфәт.- Казан: Татар.кит.нәшр.,2011.-255б.

# М.Җәлил иҗатында кеше һәм табигать күренешләренең үзара мөнәсәбәте.

***Автор:Зәлиева Илсөяр Илсур кызы***
***Җитәкчесе:Кәримова Рәсимә Габделхәй кызы***
***1 курс***
***ДАҺБУ «Түбән Кама индустриаль техникумы»***

Без – яңа гасыр яшьләре! Без- компьтерлар,яңатехнологияләрчорындаяшибез. Мин татар кешесе буларак, үз телемә гашыйк, туган җиремне, әти-әниемне, сеңел һәм энеләремне яратып, кайгыртып яшим. Киләчәктә телебез, иманыбызның нык булуын телим. Яшьтәшләрем үз халкының тарихын, телен, әдәбиятын белеп, татар халкының горур кызлары һәм уллары булып үсүен телим мин.

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә без танылган әдипләрнең әсәрләрен яратып өйрәнәбез. Мин яраткан шагыйрьләремнән Габдулла Тукай, Муса Җәлил, Хәсән Туфан, Разил Вәлиевларны санап китәр идем. Аларның иҗатында татар халкын кайгырту, туган җиргә мәхәббәт чагыла.

Муса Җәлил – минем яраткан шагыйрьләремнең берсе. Ул – татар халкының бөек шагыйре. М. Җәлил язмышы белән безгә батырлык һәм героизм үрнәге калдырган. Безгә килеп җиткән шигырьләре Моабит төрмәсендә, үлемгә хөкем ителгәннән соң, туры мәгънәсендә «палач балтасына башны тоткан килеш» язылганнар. Бу факт үзе генә дә Муса Җәлилне бөтен дөньяхалкы алдында тиңдәшсез батыр итеп таныта.

Муса Җәлилнең иҗаты күпкырлы. Г. Кашшаф Муса Җәлилнең 1935 нче елдагы бер хатыннан алынган мондый юллар китерә:

«Мин тормышта тирән һәм ялкынлы сөя беләм. Мин табигатьне дә, кояшны да, чәчкәне дә, музыканы да һәм намуслы хезмәтне дә, ялкынлы иҗатны да, тиңдәшсез илемне дә шулай ук янып, кайнарланып сөям. Бу минем эчке тирән бер сыйфатым инде».

Чыгышымның төп максаты булып Муса Җәлил иҗатында кеше һәм табигать күренешләрен анализлау тора.М. Җәлилнең сугыш чорында язылган “Сандугач һәм чишмә” балладасына тукталыр идем.

Баллада – нинди дә булса фантастик, фольклор, риваять нигезендә төзелгән сюжетлы лиро-эпик әсәр ул.

“Сандугач һәм чишмә” балладасында җанлы табигать вәкиле – Сандугач һәм җансыз табигать вәкиле – Чишмә катнаша.

Сандугач сөюне, мәхәббәтне тугрылыкны гәүдәләндерә. Таң җырчысы, таң кошы, матурлык билгесе,Чишмә - сафлык, чисталык образын чагылдыра.

Сандугач уянып

Канатын кагына
Һәм карый ашкынып
Тын урман ягына.
Җанландыру күренеше чишмә образында тагын да көчлерәк тоела:
Килде тиз сердәше
Чишмәгә…
Тик аның
Кайгылы моң баскан
Чәчәкле буйларын.
Чишмә тын; ул көлми,
Тибрәнми, селкенми;
Акбүз таш өстендә
Тамчылар сикерми.

Сандугач- табигатьнеңматурлык символы буларактасвирлана.
Иркәлитаңкошын
Зөбәрҗәттамчылар.
Әйтче, букүрнешкә
Сокланмый кем чыдар?!
Сандугач аз гына
Уйланыпторды да
Җанланыпэндәште
Чишмәгә тын гына:
“Кайгырма, күзнурым!
Улкилсәэчәргә,
Коткарам мин үзем,
Мин беләмнишләргә!”

“Сандугач һәм Чишмә” балладасында батыр символы –үзәк символларның берсе. Батырның төп сыйфатыаның үзенең сүзләрен дә ачылып килә:

“Улулыхөрилнең
Һәмбөекатаның,
Ялкынлыйөрәктән
УлсөяВатанын”.

Шулай итеп, Сандугач һәм Чишмә монда үзләренең символик образлары белән Ватан һәмтуган илне, туган якны, туган табигатьне берләштерә:

“Яшәде ул сөеп

Һәм үләр беркөнне

Нәкъ мәгъруր Сандугач

Һәм Чишмә шикелле”.

Шагыйрьнең йөрәгеннән чыккан җырларны без киләчәктә дә яратып укырбыз, яратып җырларбыз.. Татар халкының горур улы – Муса Җәлилне без һәрвакыт олылап һәм ихтирам белән искә алырбыз .

Чыгышымда Муса Җәлилнең иҗатында кеше һәм табигать үзенчәлекләрен күзәттем. Сүземне йомгаклап, шуны әйтәсем килә: Муса Җәлилне батырлык символы итеп беләбез, аның фашизмга каршы көрәшен таныйбыз. Әдипнең шигъри дөньясын, табигатькә сакчыл карашын, һәрнәрсәне яратып, хөрмәт итә белүсыйфатлары әдәбият дәресләрендә тәрбияләнә.

Кулланылган әдәбият

1.Галиуллин Т. Керсез йөрәк монологы // Җәлил М. Әсәрләр. – Казан: Мәгариф, 2004. – Б. 8-9.

2.Җәлил М. Әсәрләр. Дүрт томда. 1 нче том. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1968. – 558 б.

3.Җәлил М. Әсәрләр. – Казан: Мәгариф, 2004. – 271 б.

4. Мостафин Р. Муса Җәлил эзләре буйлап (очерклар). – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1968. – 152 б.

5.Кашшаф Г. Муса Җәлил, тормыш һәм иҗаты турында очерклар. – Казан: Матур әдәбият редакциясе, 1957. – 380 б.

## Причины разрушения русского языка

***Ильичёва Александра Валерьевна, студентка 1 курса ГАПОУ «Тетюшский государственный колледж гражданской защиты», руководитель Трифонова Евгения Ивановна***

Прежде чем говорить об экологии языка, следует, разобраться, что же такое экология. Термин «экология» состоит из двух слов: «oikos» и «logos». Первое из них переводится с латинского как «дом», «родина», «среда обитания», второе – «слово», «понятие», «мысль», «определение», «речь», «учение».

Важнейшая функция языка – коммуникативная, в которой язык выступает универсальным средством общения людей. С помощью языка люди передают друг другу свои мысли, чувства, волеизъявления, душевные переживания, тем самым воздействуя друг

на друга и формируя общественное сознание. Язык – среда обитания любого человеческого коллектива и каждого человека, а сегодня она замусорена до критических показателей.

Среди причин разрушения русского языка можно выделить следующие:

- сетевой сленг - жаргонные слова, при помощи которых общаются люди в сети. Из всех видов такого общения наиболее часто употребляемым в устной речи стал «албанский язык»;

- смайлы – графические символы, заменяющие эмоции или ходовые фразы. С точки зрения лингвистики смайлы оказывают разрушительное влияние на образную систему языка. Человек теряет способность передавать свои эмоции вербальными средствами, потому что выражение эмоций подменяется картинкой с улыбающимся или печальным лицом;

- транслитерация - конверсия систем письма, при которой каждый графический элемент (знак) одной системы письма заменяется одним и тем же графическим элементом другой системы письма. Это тоже стало явлением массовой культуры, т.к. школьникам навязываются такие товары, как тетради и дневники, оформленные буквами, взятыми из 2-х алфавитов. Это ведет к тому, что ребенок, пользуясь каждый день предметами с подобными надписями, усваивает такие образцы написания, в которые заведомо включена ошибка. И эти ошибки он потом переносит в устную и, главным образом, в письменную речь русского литературного языка;

- заимствованная лексика – это слова, «пришедшие» (или «взятые») в определенную эпоху из других («чужих») языков.

Иноязычное слово до тех пор сохраняет статус заимствованного, пока язык, в который это слово попало, его не освоит, т.е. не сделает «своим».

Русский язык, по словам А.С. Пушкина, «переимчив и общежителен», он легко принимает иностранные слова, если они нужны. И в этом нет ничего страшного, когда все делается в меру. А мера утеряна. В нашей речи возникаю «сэндвичи», «ленчи», «дисплеи». Обычно меняются около 20-30 слов в год, а у нас сейчас появляются, может быть, 20 слов в неделю.

Выводы неутешительны. В XXI веке художественная литература уже не является образцом литературного языка. Образцом коммуникации на современном этапе развития общества являются средства масс-медиа. В современном обществе широкое распространение получил деловой стиль общения и следствием этого является насаждение американского способа подачи информации. Профессии, связанные с лингвистическим профилем, не являются приоритетными в современном обществе. Внедрение в русский литературный язык т.н. «албанского» языка, явления транслитерации, необоснованное заимствование слов – все

это ведет к разрушению языка как средства общения. Происходит утрата интереса к языку как носителю духовных ценностей русской нации.

Разрушение языка как средства общения приводит к разрушению русской культуры. Последствия могут оказаться печальными, потому что в конечном итоге люди перестанут понимать друг друга.

Список литературы

1.Толковый словарь русского языка. С.И. Ожегов. Москва. 1997г;

2.Энциклопедический словарь юного филолога. Составитель М.В. Панов. Москва. «Педагогика». 1984 год.

## Азнакай районы Таштуган авылы тарихын өйрәнү

***Исхакова Р.Ф. III курс, ИС-141б төркеме;***
***Хайруллина З.В., Камалова З.Ә. татар телчеләре***

**Туган як,** туган җир, туган авыл! Якын да, газиз дә булган бу сүзләр һәркемнең йөрәк түрендә булырга тиеш. Кендек каны тамган, беренче тәпи баскан, икмәк исен, хезмәт тәмен татыган, тәүге хисләр, шатлык-борчылулар кичергән бу урыннар Һичкайчан истән чыкмый, телдән төшми. Үз җирен, авылын яратмаган кеше юктыр ул. Тик менә бик сирәкләр генә үз авылларының исеме, аның килеп чыгышы, тарихи үткәне, бүгенгесе белән кызыксына. Ә бит халыкта “Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк” дигән бик матур гыйбарә бар. Шуны истә тотып, мин дә үз авылымның исеме, килеп чыгу тарихы белән кызыксынырга булдым.

**Фәнни эшнең максаты:** авыл тарихы турындагы мәгълүматларны җыйнау, барлау һәм аларны бер тәртипкә китереп киләчәк буынга тапшыру.

**Өйрәнү предметы** итеп Азнакай районының Татшуган авылы тарихын алдым.

**Өйрәнү объекты** итеп шушы авыл җирлегендә яшәүче кешеләр, аның табигый үзенчәлекләре, истәлекле урыннары алынды.

**Максатка ирешү өчен түбәндәге бурычлар куелды**:

- авылның өлкән кешеләре сөйләгәннәрне һәм архив материалларын өйрәнү аркылы авыл исеменең тарихын, килеп чыгышын өйрәнү.

- авыл биләмәсендәге елга-күлләр, урман атамаларының килеп чыгышын ачыклау;

- авылдан чыккан күренекле шәхесләрне барлау;

**Туган авылым урамы...**

XVI гасыр урталарында әле Татар Шуганы авылы (Азнакай районы) кеше кулы тимәгән хәлдә була. Урманнарында каен, имән, усак, чикләвек агачлары үсә. Бүре, кабан

дуңгызы, кыр кәҗәләре, төлке, бурсык, куян... кебек җәнлекләр яшәгән. Җәй көне күлләрендә аккош, кыр үрдәкләре бала чыгарган.

Авылның аксакаллары сөйләвенә караганда, Татар  Шуганы авылына Чубар-Абдул авылыннан күчеп килгән Тәмәй исемле кеше нигез сала. Ул  Корчый чокырының көнчыгыш өлешенә урнаша. Аның Ямәй исемле бер генә улы була.  Бары тик биш бабайдан – Тәмәй – Ямәй –Кәчер –Йосыф – Мөәминнән соң гына авылда халык саны арта башлый. XVII гасыр урталарында  Корчыйның көнбатыш  ягына   Казан ягыннан кешеләр килеп урнаша башлый. Авыл халкы игенчелек, терлекчелек белән шөгыльләнә. Элегрәк авыл исеме белән бәйле шундый риваять яшәгән. Имеш, авылда бер татар кешесе өшеп үлгән, шуннан ул Татар өшегән авыл, ягъни Татар Шуганы дип йөртелә башлый. Рәсми документларда да авыл исеме Өшегән сүзе (авылның Өшегән елгасы буенча урнашуы) белән бәйләп аңлатыла. Аның халкын татарлар һәм башкортлар тәшкил итә. Авылда 106 хуҗалык була.  Ир-атлар – 378 кеше (аларның  196сы – башкорт, 182се татар дип язылган). Хатын-кызлар – 309. (153 – башкорт, 156сы татар.) Авылда мәчет һәм училище эшли.

Авыл кешеләре арасында тырышлыгы белән аерылып торган кешеләр була. “Әптерәмән буе” дигән урын бар. Бу элек  Габдрахман карт тоткан җирләр.  “Сәлим буе” дип йөртелгән чирәмлек Сәлим исемле кешенең милке саналган. Урман буендагы  җирләргә Билап исемле кеше хуҗа булган.

Безнең авыл өч яктан да урман белән уратып алынган. Урман буенда Галәү каены дигән каен бар. Аңа багышлап шигырь дә чыгарылган:

Үзәнлеккә җитсәм,
Тарих тагын чигенә кирегә.
Галәү атлы буйдак карт утырткан.
Ялгыз каен үсә биредә. (“Авылым юлы”)

“Таллы кое” турында исә мондый шигырь бар:

Кем утырткан, кайчан утыртылган;
Белүче дә юктыр, тәгаен.
Бөреләре керфек чылатканда,
Авылыбызның кайсы агаен
Искә ала икән бу ялгыз тал -
Зур урамның олы бизәге.
Әнкәм сүзе: сабый чактан күрдек
Нәкъ шушындый итеп без аны.
Куенында, җиләс күләгәдә,
Иске кое, имән буралы,

Тал тамыры, бөдрә толымнардай, Ниргәләргә үскән уралып,- дип яза шагыйрь.

Авыл уңайлы урында ике елга – Өшегән һәм Корчый елгалары арасына, район үзәгеннән 41 километр ераклыкта урнашкан.

Иң борыңгы чишмәләреннән берсе – “Колый чишмәсе”. Авылны “Корчый чокыры” урталай бүлә. “Таш елга”дан кешеләр мунча ташы җыя торган булалар. Тәкәрлекләр оялаган сазлык “Тәкәрлек сазлыгы” дип атала.

Бүгенге көндә авылда мәчет, клуб, урта мәктәп, балалар бакчасы эшли. Халкы игенчелек, терлекчелек, яшелчә үстерү, нефть чыгару эше белән шөгыльләнә. Авылыбыздан күп кенә күренекле кешеләр чыккан. Алар арасында Чаллыда яшәүче язучы Данис ага Хәйруллин, Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрының директор урынбасары Халисә Исмәгыйлева бар. Авылым нык тормыш белән, матур яши.

**Йомгак:** һәр авылның, шәһрнең үз тарихы, йөзек кашы булырдай күренекле шәхесләре, өметле киләчәге бар. Мин дә шушы кечкенә хезмәтемдә авылым тарихын барладым, аның яшәү рәвеше, тормыш-көнкүрешен өйрәндем. Хезмәттән тәм табып, булганын кадерләп саклап, булмаганын булдырырга тырышып яшәгән минем халкым. Тагын шунысы мөһим: авылымның иң зур горурлыгы-аның уңган-булган халкы. Шуңа да авыл халкы бер-берсенең уңышларына сөенеп, борчу-мәшәкатьләрен бүлешеп, иртәгәге көнгә өмет белән карап яши.


1. Галләмов Р.Ф. Русча-татарча тарих терминнарының аңлатмалы сүзлеге/ Р.Ф. Галләмов – Казан: Мәгариф ,2006
2. Фәхретдинов Р.Г. Татар тарихы /Р.Г.Фәхретдинов. – Казан: Мәгариф, 1999. – 111 б.
3. Ибраимов М., Ахметзянов Г., Ибраһимов Г. Иске тел // Казан утлары. – 1978. – № 3. Советмәктәбе №5, 1977ел
4. Ибраимов М., Ахметзянов Г., Ибраһимов Г. Иске тел // Советмәктәбе. – 1977. – № 5.
5. Һилалов. З. Кукурузның файдасы // СоветТатарстаны. – 1957. – № 35
6. Лотфуллин А. Минамедчик хәтирәләре // Маяк. – 1988. – № 23


## Природа и нравственность


***Латипова Сюмбель Кабировна***
***Синагатуллина Люция Абдулхатовна***
***8 класс***

Проблема сохранения окружающей среды сегодня стоит в одном ряду с проблемой сохранения мира. Наше общество предпринимает попытки предотвратить экологическую катастрофу, но большей части человечества до сих пор кажется, что природа неисчерпаема, что она вынесет любое наше деяние.

Теперь, когда проблема взаимоотношений человека и природы встала так остро, писатели не могли остаться в стороне от нее. С призывом задуматься о проблемах экологии выступили такие замечательные писатели, как Ч.Айтматов, В.Астафьев, С. Залыгин, В. Распутин.

На некоторых произведениях мне бы хотелось остановиться подробнее.

Повесть В.Распутина «Прощание с Матерой» рассказывает о затоплении острова, вместе с расположенной на нем деревней Матерой перед пуском крупной электростанции на Ангаре.

Это не рассказ о том, как переселяли жителей подлежащего затоплению острова: необходимость этого действа понятна и нам, и самому автору. Вопрос в том, как эти перемены отзовутся в душе людей, родившихся и проживших здесь практически всю жизнь. Как они коснутся тех сторон жизни, без которых человек не может обойтись, не утратив в своей жизни и в себе самом необходимые духовные ценности. Сюжет повести заставляет читателя испытывать различные чувства: обеспокоенность за судьбы героев, гордость за одних и презрение к другим людям. Чего стоят мужики, глазом не моргнув разоряющие родовое кладбище. Можно ли безоглядно рушить все, не задумываясь, что мы теряем, с чем расстаемся навсегда? И голос Хозяина как бы предостерегает: не забывайте, что накладываете руку на то, без чего жизнь человеческая будет неполной, утратит что-то очень важное и необходимое. Духовный урон не возмещается материальными благами.

Антиподом мужикам-поджегщикам, Жуку является образ Дарьи. Она истинно человечна, она обладает душой. Через этот образ мы понимаем, все ли происходит по совести и чести, по разумной рачительности, свойственной истинным хозяевам жизни. «Прощание с Матерой» напоминает нам, что люди обязаны сохранить духовные и нравственные начала, которые воплощены в таких понятиях, как мать, дом, земля.

Что нужно сделать, чтобы, преобразуя землю, сохранить и приумножить земное богатство; обновляя, спасти и обогатить красоту природы? Это проблема не только экологическая, но и нравственная.

Осознание ее серьезности, по Астафьеву, необходимо каждому, чтобы не «истоптать, не повредить, не ожечь природу и себя огнем бездушия и глухоты». [1, с. 364].

Писатель утверждает: кто безжалостен, жесток к природе, тот безжалостен, жесток и к человеку. Страстный протест вызывает у писателя бездушно-потребительское обращение с природой. В «Царь-рыбе» он описывает образ браконьера, его хищническое поведение на реке.

Мир природы таит в себе и дух справедливого возмездия. Царь-рыба, израненная человеком, мстила ему за причиненное зло. Игнатьич просит прощения за свои проступки. И когда рыба отпускает Игнатьича, он чувствует, что душа его освобождается от греха, который давил на него в течение всей жизни. Природа выполнила божественную задачу: призвала грешника к покаянию и за это отпустила ему грех. Автор не судит даже самых закоренелых браконьеров, он заботится об их душевном исцелении. Велика его вера в торжество добра, в то, что каждый из нас сможет познать себя как человека.

В литературе 20-21 века отражается с разных точек зрения важная проблема наших дней – природа и нравственность. Решение ее подчинено гуманизации человека. Хочется надеяться, что в неистовой борьбе против всего темного, против бездушно-хищнического индивидуализма человек устроит свою жизнь с щедростью и любовью подлинного хозяина.

**Список литературы**

1. Астафьев, В.П. «Царь-рыба» / В.П. Астафьев. Петрозаводск: «Карелия», 1986. – 362 с.

Зубарева, Е. «Несущие тягу земную» / Е. Зубарева.- «Детская литература», 1980.- 59 с.

Распутин, В.Г. «Повести, рассказы» Том 2 / В.Г Распутин.- М: «Дрофа», 2002.- 394 с.

## 20-21 нче гасыр әдәбиятында кеше һәм табигать бәйләнеше

***Латыпов Ильназ Эдуардович***
***Җитәкче: Хафизова Рузилә Рәшитовна,***
***4 нче сыйныф, ТР Мөслим муниципаль районы***
***муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе***
***“Мари Буләр төп гомуми белем бирү мәктәбе”***
***филиалы – Исәнсеф-Чишмә башлангыч мәктәбе***

Мин үземнең бай табигатьле Мөслим районы Исәнсеф-Чишмә авылында туып, шунда яшәвем белән бик бәхетле. Чөнки авылымның гүзәл табигате көн дә саф һава сулата, йомшак җилләре битемне иркәли, тәмле сулы чишмәләре сусавымны баса, телне йотарлык җиләк-җимешләре сәламәтлегемә шифа бирә, гүзәллеккә чумып, рәхәтләнеп уйнап-эшләгәннән соң изрәтеп йоклата да ул. Шуңа күрә җир йөзендәге һәр җан иясе табигатьне сакларга тиеш. Ә яшел бишегебезнең матурлыгы турыдан-туры экологиягә бәйле. Кешеләр элекке заманнардан бирле Җир анабызның табигый тотрыклылыгын саклар дип уйлаганнар

һәм табигатькә үзгәрешләр кертергә тырышканнар, шуның белән табигатькә зыян салуларын күз алдына да китермәгәннәр. Үзен “табигать патшасы” дип исәпләгән адәм баласының эшчәнлеге һәрчак уңай нәтиҗә бирмәгән, ә киресенчә, фаҗигале үзгәрешләр дә алып килгәләгән.

Без, укучылар, җирнең матурлыгын күрә белергә, аның байлыгын сакларга әдәби уку дәресләрендә өйрәнәбез. (Гөлсинә Сәйфуллина, Фәридә Хәсанова. Әдәби уку дәреслеге. 4 нче сыйныф.) Чөнки дәреслегебез кеше һәм табигать темасына язылган әсәрләргә бик бай.

Мәсәсән, Нурия Сәйярнең “Айсылу” әкиятендә Су асты дөньясында яшәүче герой Айсылу җирдә яшәүчеләр тормышына кызыга, чөнки бай табигать кочагында яшәве - кешеләр өчен зур бәхет, дигән фикерне исбат итә автор.

Ә шагырь Зыя Ярмәкинең балаларга теләге түбәндәгедән гыйбарәт:

“Шундый матур, ямьле иртә минутларны,

Йоклап әрәм итү, бала, зур зая”- дип яза “Иртә” шигырендә, чөнки иртә торган кеше генә бар матурлыкны күрергә һәм эшләрен төгәлләргә өлгерә. Вәсимә Хәйруллина “Хәерле көн” шигырендә иртән бар җиһан белән сәламләшергә, табигать белән бербөтен булып яшәргә чагыра.

Язучы Гәрәй Рәхимнең әсәрләрендә кеше һәм табигать бәйләнеше аеруча оста бирелә. Автор табигатьтәге кеше көн дә күреп өйрәнгән күренешләрне дә, бай, үзенчәлекле һәм күңелгә үтәрлек итеп тасвирлый. Мәсәлән, “Көзге урман” шигырендә:

“Песнәк оча, ул ашыга

Тизрәк авылга кайтырга.

Көзен киткән кошлар өчен,

Авыл ямен баетырга”, - дип яза. Әйе, чыннан да песнәкләр һәм башка кышлаучы кошлар булмаса, кышкы салкын көннәрдә безнең күңелләрне юатучы, ямьләндерүче булмас иде. Шулай ук автор песнәк образы аша кешеләр арасында үз бәяңне белергә өйрәтә. Аның “Песнәк” хикәясеннән: “Матурлар арасында ямьсез булып яшәгәнче, ямьсезләр арасында матур булып яшәвең мең артык” өзеге шуңа ачык мисал.

Гәрәй Рәхимнең “Апрель” хикәясе дә табигать һәм кеше мөнәсәбәтләренә нигезләнеп язылган. Автор үз әнисен язгы ай - апрель белән чагыштыра:

“әнинең чәчләре – чалт аяз, чем-кара апрель төннәре,

әнинең тавышы – күңелгә бетмәс-төкәнмәс рәхәтлек бирә торган апрель җилләре” белән тиңли, ә үзен май аена охшата һәм безне, ягъни укучыларны, әниләргә гомеребез буена бурычлы булуыбызны искәртә.

Һәр ел фасылы үзенчә матур булгангадыр инде, язучыларны табигать темасы битараф калдырмый, әсәрләрне кеше күңеленә үтеп керерлек итеп иҗат итәләр. Сөмбел

Гаффарова да “Күз” хикәясендә соңгы яфракның уйланулары аша урмандагы матурлык белән гозурландырып кына калмый, хыялланырга, дөньядан канәгать итә белергә өйрәтә.

Мисаллардан күренгәнчә, табигать һәм кеше темасына язылган әсәрләр исемлеге бай һәм төрле. Әлеге әсәрләр безне табигатьне аңларга, яратырга, аның байлыкларына сакчыл булырга, туган җирнең кадерен белергә өйрәтә. Чөнки кеше табигатькә никадәр якынрак торса, аның күңеле дә шулкадәр сафрак, нечкәрәк була, һәм андый кеше беркайчан да табигатькә зыян салмаячак, дип уйлыйм мин.

Кулланылган әдәбият:


1. Заһидуллина Д.Ф. Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2000.
2. Сәхипова Р.Ә. Халык педагогикасы нигезендә укыту һәм тәрбия бирү. –Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2005.
3. Җәләлиев Ш.Ш. Татар халык педагогикасы. –Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2000.
4. Сәйфуллина Г., Хәсанова Ф. Әдәби уку дәреслеге. 4 нче сыйныф.- Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2014.
5. Сәйфуллина Г., Хәсанова Ф. Әдәби уку. Методик ярдәмлек. 4 нче сыйныф.- Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2012.


## Әдәбиятта экология проблемасы


***Автор: Латыйпова Ләйсән Әнәс кызы,***
***Бикүле төп мәктәбе-***
***нең 5 нче сыйныф укучысы.***
***Җитәкче: Латыйпова Наилә Нәбиулла кызы***


XXI гасырга кешелек глобаль экологик проблемалар белән керде. Бу проб-лемаларны һәркем гади күз белән генә дә күрә ала: уңдырышлы чәчүлек җир-ләр яраксызлана, эчәгә яраклы төче су, җир асты казылмалары кими, һава пычрана, хайваннар, кошлар, балыклар, усемлекләрнең бик күп төрләре “Кы-зыл китап”ка кертелә. Һәм моның сәбәпчеләре бары тик без – кешеләр. “Без хайваннар, кошлар, балыклар, үсемлекләрнең бездән башка да тереклек итә алуларын, ә менә кешенең алардан башка бер генә көн дә яши алмаячагын хә-зер дә аңламыйбыз һәм аңларга да теләмибез,”- дигән рус язучысы В.Астафьев. Бу сүзләр бүгенге көндә һәркемне уйландырырга тиеш.

Адәм баласы үзен һәрвакыт табигатьнең бер өлеше итеп хис иткән. Табигать-кә табынган, аңардан тормыш алган һәм табигатькә сакчыл караштә булган. Бу мәсьәлә динебездә дә каралган. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (с.г.в) : "Сүзләрен, зарларын әйтергә телләре булмаган хайваннарны рәнҗетүдән аеру-ча сак булыгыз!" – дигән. Чөнки һәр җан иясе кешеләр өчен, аларга хезмәт итәр өчен яратылган.

Экология проблемасы халык авыз иҗатында да чагылыш тапкан Татар халкы элек-электән туган җиргә, аның байлыкларына хөрмәт белән карарга, сакчыл эш итәргә тырышкан. Бу халык әйтемнәрендә һәм мәкальләрендә күрсәтелә. Мәсәлән, "*Урман үстер, ачлык күрмәссең", "Бер агач кисәрдән элек ике агач утырт", "Агач утыртканга – оныклар табыныр, агач кискәнне – балалар каргар", "Тирәгең барда , терәгең бар", "Бер агатан унау үскән, ун агачтан урман үскән"* Бу мәкальләр урманның әһәмияте, аларның табигатьтә һәм кеше тормышындагы роле турында.

Беркем дә табигатькә битараф түгел. Табигать, аның матурлыгын макта-маган бер генә язучыны да, бер генә шагыйрьне дә очратып булмас иде.Ләкин алар матурлыкка дан җырлап кына калмадылар, әсәрләрендә кешеләрнең җиргә, туган туфрагына мөнәсәбәтен дә тасвирладылар. Нәфис сүз ярдәмендә Җир-анага игелек, хөрмәт хисләрен уяту, кешелекнең экологик һәлакәт каршында торуын да искәртергә кирәк иде. Равил Фәйзуллин "Кызыл китап шигырендә менә нәрсә ди:

"Димәк яшәр Җиребездә
Хәлләр бар шомланырлык.
Табигатьтән ни алдык та
Аңарга ни калдырдык?"

Г. Тукай күп кенә шигырьләрендә җәнлекләрне, кошларны, бөҗәкләрне яра-тырга, аларга мәрхәмәтле, шәфкатьле булырга өнди. Ул үз иҗатында табигатькә ямь өстәүче, аны җанландыручы кошларга зур урын бирә, аларны гөнаһсыз фәрештәләр белән тиңли. "Карлыгач", "Карга", "Кошларга", "Кошчык", "Күгәрчен", "Фатыйма белән Сандугач" шигырьләре аша шагыйрь балаларны кечкенәдән үк кошларны яратырга, аларга мәрхәмәтле булырга өнди. Кошларның табигатькә бик күп файда китерүенә басым ясый, аларның иркендә генә матур итеп сайрый алуын әйтә.

А. Юнысова, Р. Вәлиева, Р. Фәйзуллин, якташыбыз Г. Сәгыйров һәм башка бик күп шагыйрьләр усемлекләр дөньясын, урманнарны саклау, агачлар утырту һәм хайваннарны кайгырту темасына да әсәрләр язылa. Бу төр әсәрләрдә дә геройлар матурлыкка гашыйк. Алар чәчәкләрне өзмиләр, агачларны, куакларны сындырмыйлар, балыкларны да кызганып кире җибәрәләр. Шулай итеп шагыйрьләребез табигать ямен, аның матурлыгын сиземли һәм аңлый белергә , матурлыкны югалтмаска, тагын да матурайта, үстерә төшәргә,

моннан чыгып экологияне сакларга кирәклеген төшендерергә тырышалар. Чөнки табигатьне бары кеше генә яклый һәм саклый ала. Фәнис Яруллинның "Рәнҗемәсен" шигыре нәкъ шул турыда.

"Табигать ул үзен яклый алмый,
Үч тә ала алмый кешедән.
Ул бары тик рәнҗи генә ала,
Куркыйк шушы рәнҗеш төшүдән."

Экология проблемасы күтәрелгән бу әсәрләрне укысак, безнең табигатькә карашыбыз үзгәрер. Кемдер сыерчык оялары ясар, җимлекләр куяр, куаклар утыртыр, һаваны пычратучы машиналардан баш тартып, велосипедта йөри башлар һәм тагын-тагын бик күп төрле игелекле эшләр эшләр. Бөтенебез булмаса да, күпчелек бу игелекле эшләрне күрер һәм үзе дә кушылыр иде.

Табигать – кешенең яшәү урыны. Без табигатьне яратабыз, аннан җаныбызга ямь, күңелебезгә тынычлык алабыз. Табигатьне саклау – ул үзебезне, киләчәгебезне, өебезне саклау дигән сүз.

Кулланылган әдәбият

1. А. Юнусова "Мин кышны яратам" Казан. ТКН 2002
2. Г. Тукай"Әсәрләр" Казан. ТКН 1985
3. Г. Сәгыйров "Ике кояш" Димитровград."Симбирская книга" 2000
4. Н. Исәнбәт "Татар халык мәкальләре" Казан. 1959

## Катнаш никахның тел язмышына йогынтысы

***Мавлеев Айнур Ильфак улы.,***
***Менделеев шәһәре 4нче номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбенең***
***10 нчы сыйныф укучысы***
***Фәнни җитәкче: Мәүлиева Рәхилә Миргазиян кызы, I квалификацион***
***категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

Татар теленең язмышы – бүгенге көндә иң актуаль мәсьәләләрнең берсе. Татар милләтенең киләчәге бармы? Телебез югалмасмы? Бу сораулар безнең һәркайсыбызны борчый.

Минем тикшеренү эшемнең максаты:

- туган телемнең бүгенге көндәге ролен ачык чагылдыру;

Бүгенге көндә мине борчыган иң төп сорауларның берсе – катнаш никахларның арта баруы. Әйе, инде 20 нче йөз башында ук татар әдипләре Г.Тукай, Г.Исхакый бу проблеманы

күтәрәләр, милләт язмышы аларның әсәрләрендә төп урынны алып тора. Ә милләт язмышы ул – тел язмышы. Катнаш гаиләләр арта бара, татарны үз эченә йота бара.[1, 3б.]

Милләт – шулай ук олы бер гаилә. Әгәр дә без милләтебезне зур бер гаилә, татарның чын мәгънәсендә тату, дус, гореф-гадәтләрен онытмаган олы гаиләсе дәрәҗәсенә күтәрә алабыз икән, берсүзсез, аның ныклыгын арттырачакбыз. Мондый милләт инде чын мәгънәсендә тулы канлы тормыш белән яшәргә лаеклы милләт, бу милләтнең гомере озын булыр дип әйтергә була.

Газета битләрендә әледән-әле катнаш никах, тел, милләт турында мәкаләләр басылып тора. Аларда кайберәүләр катнаш никахны мактап, икенчеләре тәнкыйть күзлегеннән чыгып, үз фикерен белдерә. Күпме генә бәхәсләшсәләр дә, уртак фикергә килеп, мәсьәләнең асылына төшенеп, моңа этәргән сәбәпләрне ачып салмыйлар һәм нәтиҗә дә ясамыйлар. [2, 195б.]Мин дә бүгенге язмам аша үз фикеремне, күргән-ишеткәннәрем аша кайбер татар егет-кызларына дөньяга аек акыл белән карап, тормышта үз парларын сайлауда булышлык итеп, ялгыш адымнан алып калырга ярдәм итә алсам, бик шат булыр идем.

Татар балаларының үз милләтен, телен, кыйбласын югалта башлавы балалар бакчасына беренче адымын ясаган көннән башлана да инде.. Юньләп русча да белмәгән ата-ана вата-җимерә бөек телне өйрәтеп, бала күңеленә маңкортлык орлыклары сала һәм бала әби-бабалары, әти-әниләре сөйләшкән телне бернигә дә ярамый дип инанып үсә. Туган телем көнем, яшәешем өчен кирәк дип, бишек җыры белән балаларның каннарына сеңеп үссә, һичшиксез, киләчәктә татар теле бетәр дип уйлыйсы да булмас иде.

Ачыктан-ачык үз көнеңә, динеңә, халкыңа каршы баруны хыянәт юлы дип саныйм һәм бу бернинди дә хөрмәткә лаек түгел.

Ә катнаш никахка килсәк, безнең мәктәптә барлыгы 80 гаилә, ә районда - 569. Үткән елгы нәтиҗә белән чагыштырганда, катнаш никахлар 24 гаиләгә артып киткән. [7, 10 б.]

Гаиләләр ныклы булганга күрә, милләт бүгенгә кадәр көчен югалтмады. Гаиләнең ныклыгы безнең милләтне бүгенгә кадәр исән-сау китерде. Йә рәсми, йә дини никах белән генә торырга ярамый. Бик нык уйланганнан соң гына өйләнешергә кирәк. Элек гаиләләр зур булган. Хәзер инде әби-бабайларның роле гаиләдә юк кебек, элек гореф-гадәтне алар саклап торган. Кешелек кыйммәтләре кими барган саен, андый очраклар да арта.

Барлык милләт кешеләре белән дус яшәргә кирәк. Әмма дин, милләткә килгәндә, ашы ашка, урыны башка булырга тиеш. Егетләребез, кызларыбыз тормышларында дөрес юл сайлап, милләтебезне үстерер, ныгытыр, дип ышанам. Татар кызлары үзебезнең егетләргә чыксын иде. Безнең халык хисабына башка милләт вәкилләрен арттырмасыннар иде. Үз татарыңа, үз каныңа җитәме соң?

Бүген минем өчен төп сыйфат билгесе – гаиләм, нәселем, туган-тумачаларым. Аннан соң – милләт. Хатын-кызларыбыз башка милләткә

кияүгә чыга икән, милләтебез югалачак.

Алдагы ел белән чагыштырганда безнең районда катнаш никахларның саны 6 процентка арткан. Былтыр бу чорында 21 процент булса, хәзер 27 процент. [7]

Без сөйләргә яратабыз, фәлән җирдә фәләнчә татар яши, дип. Ләкин әнә шул 70-80 яшьлек картлар, аларның 50-60 яшьлек балалары үлеп бетсә, алар урынына кем кала?

Дәүләтебез дә, динебез дә бар, ә телебез бетеп бара – чаң сугарга вакыт җитмәдеме? Бар нәрсәбез дә беткәч, соң булмасмы?

Әти-әниләр барсы да балаларының бәхетле булуын тели. Шуңа күрә иң элек аларга ислам тәрбиясе бирергә кирәк. Бер вәгазьдә: "Балаларыбызның катнаш никахына булдыра алган кадәр каршы торырга кирәк" диелгән. Бүген күпчелек яшьләребезнең гаиләсен, бигрәк тә катнаш гаиләне, ислам кануннары буенча алып барырлык белеме дә, сәләте дә юк. Күп очракта алар агымга эләккән йомычка кебек кенә. Шул агым аларны ярга чыгарып атканчы агып баралар.

Татар милләтен ирекле итеп күрү Г.Исхакыйның төп хыялы булган. Ул үзенең иҗатында татар милләтенең язмышы өчен борчылып кына калмыйча, ничек милләт буларак сакланып калырга икәнлеген дә күрсәтә. Әдипнең милли рух белән сугарылган “Җан Баевич”, “Зөләйха” пьесалары татар драматургиясендә зур роль алып торалар. Зөләйха үзенең намусына тугрылыклы булса, “Җан Баевич” комедиясенең төп герое Шакирҗаннар милләтебезгә хыянәт итәргә торалар. Корсак кануннары буенча яшәүчеләргә Ватан ни дә, туган тел ни – барыбер. Җан Баевичның үз – үзен тотышы да кайбер бүгенге маңкортларга охшый. [4, 75 б.]Алар да исемнәрен үзгәртеп, вата – җимерә урысча сөйләшеп, үзен бик югары культуралы санап, үзенең милли яшәешеннән баш тартучылар юк түгел.

Нәтиҗә: Татарда Исхакыйдай белемле, замана белән бергә атлаучы зыялы яшьләр, акыл – нәсихәт бирә алырдай әдипләребез аз түгел. Аларның әсәрләре безгә, яшь буынга эш сөючән, кунакчыл, белемгә омтылучы, туган төбәгебезне, халкыбызны яратучы, үз халкыбыз белән горурланучы бала булып тәрбияләнергә мөмкинлек бирә. Милли рухлы яшьләребез булганда, аларда гаиләдә үк нигез салынган милли тәрбия, милли үзаң булса, татар дәүләте әле яшәячәк.

И туган телем, син яшәсәң генә татар милләте яшәр, тормышның яме – тәме артыр.

**Кулланылган әдәбият исемлеге**


1. “Аҗаган” газетасы, 2011, сентябрь, 3 б.

2. Ә.Кәримуллин “Тел – милләтнең сакчысы” – Казан: татар китап нәшрияте, 1997, 196 б.

3. Гомәр Саттар Мулилле “Без кемнәр?”, Мирас, 1998, № 2.-76 б.;

4. Г.Саттаров “Туган тел гаме”, Татарстан журналы, июнь, 2007,

43 – 45 б.

5. М.Лотфуллин “Телне саклау калу – халыкны саклау ул” –Казан: Мәгариф, 1998, № 9. -79 б.

6. Туган якны өйрәнү музеennaн алынган материаллар

7. “Фән һәм мәктәп” №2, 2009

## Взаимодействие человека и природы в литературе XX-XXI века.

***Массарова Диляра Миннахметовна***
***ГАПОУ «Нижнекамский сварочно-монтажный колледж» (филиал), Камские Поляны,***
***2 курс,автомеханик;***
***Научные руководители-Хасанова Гульнар Айратовна,***
***Преподователь русского язык и литературы.***
***Набиуллин Рустем Гумерович***
***Мастер производственного обучения***

Принято считать, что взаимоотношения человека и природы стали ухудшаться с развитием науки и техники. Однако история человечества свидетельствует, что наука и техника развивались всегда. Так, примерно с 500 года до н.э. до 500 года н.э. античные техники и инженеры дали сильный толчок развитию производительных сил, расширили ассортимент товаров, повысили их качество и увеличили их количество. Тогда же сформировалась особая техническая терминология, широко применялись чертежи, а математика стала основой технических расчетов. А технические учебники имели не менее широкий спрос, чем художественная или философско-религиозная литература. Достаточно вспомнить имена Ктесибия, Архимеда, Витрувия, Филона Византийского, Герона Александрийского и Кратета.

Но при всем торжестве науки и техники античный человек осознавал, что природа является его колыбелью. На протяжении многих столетий техника была для человека средством. Лишь в новое и новейшее время она стала самоцелью. В результате из равноправных партнеров человек и природа превратились едва ли не в заклятых врагов. Как писал советский поэт В. Федоров, мы говорим: «Покорись!» — и поминутно угрожаем извечной матери своей — природе.

Прогресс — это развитие, а развитие, на мой взгляд, сродни вращению Земли вокруг своей оси, смене времени года, дня и ночи. И если рассудить здраво, то никто не в силах остановить прогресс. Ведь с тех самых пор, как человек появился на Земле, жизнь нашей планеты постоянно изменялась. Эти изменения — результат непрерывного влияния человека на природу на протяжении сотен и тысяч поколений. Но с наступлением буржуазного века это влияние стало возрастать с космической скоростью. С тех пор с каждым годом под угрозой оказывались все новые и новые виды растений и животных. Лишь в 1949 году начался сбор информации для составления списков редких и находящихся под угрозой исчезновения растений и животных. Первый из них был напечатан в 1966 году под названием «Красная книга». За последние сорок лет «Красные книги» появились во всех странах, на всех континентах. Но каждый новый выпуск таких книг не убавляет, а лишь пополняет старые списки новыми названиями.

А всему виной явление, которое принято называть научно-технической революцией. Она началась, когда человек вдруг понял, что может в промышленных масштабах и вполне эффективно применять на практике свои научные знания об окружающем мире. Но как только этот процесс стал набирать скорость, человечество тут, же ощутило на себе его последствия. Оказалось, например, что осушенные полесские болота были «легкими» всей Европы, а вырубаемые влажные тропические леса — «легкими» всей планеты, и без них мир просто задохнется.

Зазвучали голоса протеста, среди которых не последнее место занимают голоса писателей. Призыв «глаголом жечь сердца людей» не одно столетие звучит в русской литературе, и, спасая природу от разрушительной деятельности человека, писатели вновь взялись за свое оружие — слово.

Последняя четверть 20-ого века поставила перед человечеством глобальную проблему – проблему экологии, сохранения природного равновесия. Взаимоотношения природы и человека обострилось настолько, что стало понятно: или человек научится жить как часть природы, по ее законам, или, погубит планету и погибнет сам. Тема отношений природы и человека была новой в русской литературе.

Российские писатели не только выступали с высоких трибун и писали обличительные статьи в центральные газеты и журналы. Защищая реки и озера, леса и поля, они обращались к наглядным художественным средствам — создавали литературные произведения на экологическую тему. Это была реакция на резкую урбанизацию современной жизни, стремительный рост городов и такой же стремительный упадок и разорение деревень.

Среди тех, кто подал свой голос против бездумного покорения природы и предупреждал о той опасности, которую оно сулит, был известный российский писатель В. Астафьев.

Герою повести В. Астафьева «Царь-рыба» природа однажды мстит не только за отношение к себе, но и за все прошлые грехи — то зло, которое он причинил другим людям. Природа приходит к нему в виде огромного осетра. Герой (Игнатьич) решает, во что бы то ни стало выловить гигантскую рыбину, но по неосторожности оказывается в воде, на крючке собственной снасти. Он чувствует, что тонет, а рыбина влечет его за собой на дно. И он не в силах ничего сделать ради своего спасения. Перед лицом неминуемой гибели большая рыбина видится Игнатьичу некоей тварью. Никогда не веривший в Бога, герой обращается к Нему за помощью. И в тот же момент в памяти воскресает то, о чем и о ком он старался забыть: об опозоренной девушке, обреченной им некогда на пожизненное страдание. Вот почему, уже «не владея ртом, но все же надеясь, что хоть кто-нибудь да услышит его, он прерывисто и надорванно засипел: «Гла- а-аша-а-а, прос-ти-и-и…». А когда рыба отпускает его, герой ощущает, как душа его получает освобождение от греха, которым он тяготился всю свою жизнь.

Конец 20-ого и начало 21-ого века дали еще одно понятие – экология человека. Человечество, искалеченное духовно, не имеющее цели, кроме погони за материальными благами любой ценой, калечит природу.

Возможно, эти интонации, однажды уже приковавшие к Себе внимание русской общественности, снова сослужат добрую службу в деле сохранения одного из величайших сокровищ не только нашей Родины, но и всей планеты Земля — величественной Матери-природы.

**Список использованной литературы.**

1. Астафьев В.П. “Царь-рыба”, ИД:Художественная литература, 1984г.

## Тел – дәүләт сакчысы

***Мельникова Алина Андреевна***
***Минзәлә шәһәре 1 нче урта мәктәбенең***
***8 Б сыйныфы укучысы (рус төркеме)***
***Җитәкче:***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы***
***Асманова Люзя Киядим кызы***

Татарстан - суверен дәүләт. Суверен дәүләтнең тигез хокуклы дәүләт телләре бар – рус һәм татар телләре. 1992 нче елдан Татарстан кешеләре татар телен дәүләт теле буларак өйрәнә башладылар.

Җир шарында 6500 дән артык тел исәпләнә. Тел – халыкның гореф-гадәтен, дөньяга карашын, тарихын, күңел байлыгын күп гасырлар буена саклап, аны безнең заманнарга китереп җиткергән зур хәзинә. Тел хәзинәсенә һәр буын үз өлешен керткән. Аны сакларга кирәк.

Бүгенге көндә татар теле – зур үсеш алган телләрнең берсе. Татар телендә 7 млн кеше сөйләшә. Республикабызда төрле милләт кешеләре тату дус яшиләр. Туган телен, дәүләт телләрен белгән, башка халыкларны хөрмәт иткән кеше генә бәхетле була.

Тел турында әйтелгән мәкальләрнең мәгънәсе зур:

Иле барның теле бар.

Тел - күңелнең көзгесе.

Тел Төмәнгә илтә.

Телләр белгән – илләр белгән.

Туган телен кадерләгән халык кадерле булыр. [4,б.12-14]

Күптән түгел мин газетадан бер мәкалә укыган идем. Франциядә “Француз теленең сафлыгын саклап калу турында” закон чыгарганнар. Шул закон нигезендә контракт, рәсми кәгазьләрдә чит тел сүзләрен кулланган өчен, 80нән алып 160 франкка кадәр штраф салыначак икән. Әгәр шундый “җинаять” өч ел эчендә ике тапкыр кабатланса, штраф 5000 франкка җитәчәк. Француз лингвистлары әйтүенчә, бу закон француз телен чит сүзләр, аеруча инглиз сүзләре белән чүпләүдән саклау өчен чыгарылган, ди. [1,б.74] Бу мәкалә мине дәүләт теленең чисталыгы турында уйланырга мәҗбүр итте.

Мин Татарстанның иң руслашкан Минзәлә шәһәрендә яшим. Минем милләтем – рус. Беренче класстан мин дәүләт телен өйрәнәм.

Бүгенге көндә дәүләт теле ни хәлдә? Дәүләт телебезнең киләчәге ничегрәк булыр? Татар милләтеннән булган халыкның күпмесе генә үз туган телендә сөйләшә. Киләчәктә нәрсәгә ул татар теле дип, татарча сөйләшмәгән гаиләләр дә күп. Мин татар телен өйрәнергә тырышам, ләкин шәһәрдә күп кешеләр рус телендә сөйләшәләр. Сыйныфташларым татар телен яхшы белүгә карамастан үзара рус телендә сөйләшәләр. Бүгенге көндә минем белән бергә рус төркемендә татар балалары укый, татар төркемендә укучылар саны кими бара. Алар татарча матур әдәбиятны, әдәби китапларны бөтенләй укымыйлар. Телевидение каналларыннан русча тапшырулар карыйлар. Инглиз телендә музыка тыңлыйлар. Ишек атлап чыккач та рус телендә кайнап торган тормыш башлана.

Хәзерге икетеллелек шартларында тел, сөйләм культурасы, милли телнең чисталыгы мәсьәләләре үзәктә тора. Кирәксезгә рус сүзләре кулланып сөйләшү әдәпсезлек билгесе икәнен истән чыгармаска кирәк. Телнең үзендә кирәкле сүз була торып, аның урынына алынма сүз куллану да  урынсыз, сөй¬ләшкәндә начар сүзләр кушылса, тел паразитлары эшчәнлек итә башлый.

Мин кешеләр белән дәүләт теле, аның чисталыгы турында сөйләшү уздырдым.  10 кеше “Лингвоэкология турында мин нәрсә беләм?” темасы буенча  минем сорауларга җавап бирде:

1. Сез беләсезме: нәрсә ул экология?

2. Сезгә  « тел экологиясе», «лингвоэкология» терминнары танышмы?

3. Сез беләсезме: дәүләт теле  “пычранган”?

4. Сезнеңчә дәүләт теле  нәрсә белән пычранган?

а)  ” паразит сүзләр” кулланам

б)  сүзлек сапасым аз булу сәбәпле, башка тел сүзләрен катыштырам

5. “Тел мөхите пычрану”  нигә куркыныч?

6. Дәүләт теле чистарсын өчен сез нәрсә эшләр идегез?

| | 1сорау | 2сорау | 3сорау | 4сорау | 5сорау | 6сорау |
|---|---|---|---|---|---|---|
| әйе | 10 | 5 | 3 | 2 | җаваплар төрле | җаваплар төрле |
| юк | - | 2 | 7 | 8 | | |
| икеләнәм | | - | 3 | | | |

Димәк, без тупас, ялгыш сөйләшеп, тел экологиясен бозабыз.  Сөйләмдә   ” паразит сүзләр” куллану тагын да куркынычрак -  телне юкка чыгару дигән сүз.

Мин үз алдыма максат куйдым: чынлап та татар теле халыкара тел булып каламы? Татарстанда яшәгән һәр милләт кешесе дә татар телен өйрәнергә телиме? Өч буын кешеләре арасында сораулар үткәрдем (таблицада уңай җаваплар күрсәтелде):

1. Сез татарча яхшы беләсезме?

2. Безнең шәһәрдә татар телен белү кирәкме?

3. Сез татарча өйрәнер идегезме?

| катнаштылар | Кешеләр саны | 1нче сорау | 2нче сорау | 3нче  сорау |
|---|---|---|---|---|
| Олы кешеләр | 7 | 5 | 3 | 2 |
| студентлар | 10 | 6 | 8 | 5 |
| укучылар | 16 | 8 | 6 | 12 |

Социаль белешмә буенча нәтиҗә ясадым:

Руслашкан Минзәлә шәһәрендә дә татар телен өйрәнергә, аны саклап калырга теләүчеләр күп булуын ачыкладым,  димәк татар теле яши. Ул дәүләт теле, халыкара тел булып сакланачак.

Җирдә яшәүче һәркемнең аралашу коралы - тел. Кешеләр бер-берсенә охшамаган күк, аларның сөйләмнәре дә төрле. Фән-техника, элемтә чаралары алга киткән бу дәвердә дәүләт теленең әһәмияте тагын да арта.  Без – яшь буын кешеләре, дәүләт телен саклап калуда зур роль уйныйбыз. Телне өйрәнү төрле милләт халыклары арасында дуслыкны тагын да ныгытыр. Телгә хөрмәт – милләткә хөрмәт ул.

Тел - яшәү коралы. Тел бетсә, милләт тә бетә, дәүләт тә юкка чыга. Тел -дәүләт сакчысы. Татарстан кешеләре дәүләт  теленең чисталыгын саклап калырга, аны  өйрәнергә, шул  телдә аралашырга тиеш.

**Кулланылган әдәбият**


1. Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З.  "Хәзерге татар әдәби теле" Казан "Мәгариф" нәшрияты, 2002.
2. Сборник текстов по татарскому языку для внеклассного чтения. Управление образования г.Набережные Челны, 2004
3. Татар теленнән имтиханга әзерләнәбез. "Мәгариф" нәшрияты, 2006
4. "Татар халык мәкальләре" Яр Чаллы "Идел-йорт" нәшрияты, 1999
5. www.yandex.ru


## Гамил Афзал иҗатында урман темасы


***Мирзаянова Нурзия, "Муса Җәлил исемендәге Минзәлә педагогия колледжы"ның 9 нчы сыйныф укучысы***

***Җитәкче: татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гыйлаҗетдинова Г.М.***


Теге яки бу әсәрнең тематик кыры, ягъни тематик берлеге, андагы аерым бер лексик берәмлекләрнең еш кабатлануы белән бәйле. Андый берәмлекләр, кабатланып килеп, чылбыр барлыкка китерәләр һәм шуның белән бергә тематик челтәр хасил итәләр. Ә монысы үз чиратында әсәрнең төп һәм ярдәмчел темасын, аның тышкы һәм яшерен мәгънәсен аңларга ярдәм итә.

Тематик кырны хасил итүче мондый сүзләрне әдәби чәчмә тексттан гына түгел, ә шагыйрьләрнең тулаем иҗатыннан да билгеләргә мөмкин. Шуларның берсенә – урман темасына тукталып китик. Тикшерү өчен, без татар халкының күренекле шагыйре Гамил Афзал иҗатын сайладык.

Урман – шактый зур урын алып, тоташ күп булып үсеп утырган агачлар төркеме, шулай ук күп булып агачлар үскән мәйдан. "Ак болытлар ага" дип исемләнгән кечкенә

шигъри парчада ул бөтен татар тарихын, татар язмы¬шын, татар гамен, татар сагышын яңарта.

Аңламассың гомер буенча:

Әллә элмәк,әллә муенса,

Казан тирәләре карурман,

Шаһгалиләр килеп хан булган.

Бу инде XX гасыр тарихы гына түгел, монда безнең дәвергә дә ишарә бар. Элмәге дә, муен¬сасы да, Шаһгалиләре дә күп булды безнең га¬сырда. Баскынчылык та, коллык та, изелү, түбәнлекләр дә җитәрлек булды.

Кара тиргә батып җир сөргән,

Авыр ясак түләп көрсенгән.

Тагын бер гыйбрәт: телен, иманын, рухи бөтенлеген, кешелек асылын, иң мөһиме азатлык хисен югалта язды татар бу болгавыр заманда:

Кыю татар ниләр күрмәгән:

Сөргеннәргә киткән төрмәдән,

“Кызыллар” да булган, “аклар” да,

Дөньялар болгавыр чакларда.

Гомумән, шагыйрь табигать образлары белән оста эш итә. Юк, аларга катып калган образ-символ итеп кенә кара¬мый, бәлки, җан өрергә тырыша, хыял көче белән аларның рухын кайтармакчы була. Бу хакта үзе дә ачыктан-ачык яза:

Хыялыңда дөнья йөзең буйла,

Изге хисләр сиңа иярсен.

Табигатьнең җаны — мин, дип уйла,

Биек-биек тауга менәрсең.

Тарих карурманы уртасында калган «татар авылы» (ил, халык, милләт) күз алдына килә. Карурман (имансыз, рухи терәкләрсез, өметсез-хыялсыз гасыр) артында ак болытлы, зәңгәр күкле ТАУ шәйләнә, әмма аңа бик тә ерак, хәтта бөтенләй дә юл юк кебек.

Биек таулар итәгендә күксел рәшә,

Әллә кайдан серле вәхи миңа дәшә:

Заман белән бәхәсләшә -бәхәсләшә,

Ялган белән якалашып, йөз ел яшә!

(«Нигез ташы».)

Менә шулай итеп әдип дөньялыкта үзенең урынын билгели. Ә бу дөньялыкның, образлы чалымнарын, төп персонажларын без беләбез инде — Зәңгәр күк, Ак болыт катындагы Хыял тавы, Киләчәк, ләкин аңа кадәр Урман бар, ул әле яшел төсмерләр ала, әле

шомлы карурман рәве¬шенә керә. Аның адашкан бер аланында авыл, ил яши. Татар авылы, татар иле. Ул әлегә бик авыр хәлдә; юллар-сукмаклар югалган, кыйбла билгеләнмәгән, иман зәгыйфьләнгән.

И офыклар ерак, таулар биек,
Хисап сорый үтәлмәгән эшләр.
Карурманда – Сак-Сок моңы кебек,
Үкенечләр.

Карурманга керәбез. Нәрсә бар анда? Нинди афәтләр, нинди явыз һәм изге рухлар сагалап тора анда адәм баласын?

Тарих юлы - кара урмандыр ул,
Пәйгамбәрләр тамга куйгандыр.
(“Тарих юлы — кара урмандыр ул”.)

Кайда синең кагъбәң, кайда нурлы кыйблаң?
Күзге яңгыр ява, шаулый кара урман.
(“Яңгырлы көз”.)

Кемдер алга киткән, кемдер дошман булган,
Ямьле чорлар үткән, шомлы шаулый урман.
(“Яңгырлы көз”.)

Үткәнем яшел урмандай,
Киләчәк кара урман,
Урманга карап торам.
(“Сүрелде күзләр, сүрелде”)

Яисә:

Синең атаң чын коммунист булган,
Аны да алдаган карурман,
(“Хәтер диварьы”.)

Илгә каршы явызлык та этлек —
Сихерләнгән кара урман кебек.
(“Архивларда яшерен күрсәтмәләр”.)

Шагыйрь авылга эндәшә:

Оныттылар диеп үпкәләмә,
Карурманнар үскән илләрдә,
(“Авыл”.)

Ә менә бу юллар бүгенге көндә дә актуаль:

Гомер юлы – кыргый кара урман,

Ничек итеп җайларга икән?

Баштан сыйпап кына көлеп торган

Яхшы патша кайларда икән?

(«Яхшы патша».)

Карурманның эчтәлеге ачыклана бара:

Үткән заман кара байлар булган,

Хәзер үсеп чыкты кызыл байлар.

Политика сүзе — кара урман,

Шомлы еллар килә, шомлы айлар.

(“Үткән заман кара байлар булган”.)

Үткәннәрне мактап тормам инде,

Сугыш утларында дуслар янды,

Без үткән юл — кара урман инде.

(“Үткәннәрне хурлап тормам инде”.)

Боларның барысы да үткән заманнар хакында. Карурманның барлык почмакларын да күреп, өйрәнеп, аңлап һәм аңлатып бетереп булмый. Тик менә бүгенге сәясәт да үз чоры кешеләре өчен кара урман булып кала:

Анда өйрәт, монда өйрәт,

Политика — кара урман.

Хуҗаларга холуй кирәк,

Койрык болгап йөри торган.

(“Анда өйрәт”.)

Урман символы, бераздан кинәя, дөресрәге, тирәнәя барып, өр-яңа мәгънә ала башлый:

Һәр кешенен күңеле — кара урман,

Мин — бәләкәй, диеп кимсенмә!

(“Кимсенмә”.)

Шагыйрь, кеше шәхесен беренче урынга куеп, аны үз-үзенә ыша-ныrга чакыра, киләчәккә өмет белән карарга куша. Өмет — зур көч. Ул хәтта урманның төсен дә үзгәртеп куярга сәләтле.

Яшел урманнар өстендә,

Җәйнең кәккүкле кичендә

Шатлыклы шәфәкълар янсын.

(“Балыклар уылдык чәчә”.)

Өмет иманга барып ялгана:

Бар икән ул сынмый торган иман,

“Сыйнфый көрәш” диеп көчләүсез.
Яшел урман булып шаулый
Диңгез суы кебек үлчәүсез.
(“Күңел яктысы”.)

Шагыйрьнең өмете нигезсез түгел икән:
Кыю жаннар хокук даулый икән,
Давыл көтеп урман шаулый икән.
(“Оптимизм”.)

Өметнең тагын бер таянычы:
Яшел болыннарда хәтфә юрган,
Мең ел шаулап үскән бу урман.
Утта янмый, суда батмый торган:
Ватаным бар, диеп горурлан!
(“Яшел болыннарда”.)

Ләкин шагыйрь урманның ни икәнен белеп, аның һәр авазына, һәр шавына сискәнеп, шом¬ланып яши:

Урманнар шауласа, күңелләр шомлана,
Ниндидер авырлык иңнәрдә.
Дерт итеп уянам караңгы төннәрдә:
Нинди хәсрәт килә, кемнәргә?

Гамил Афзал шигырьләрендә чагылган темалар болар белән генә бетми билгеле. Әлеге тикшерелгән тематик кырлар – шагыйрь иҗатында күтәрелгән төп мәсьәләләр, һәм алар теләсә-кайсы татар шигырь сөючесе өчен бик якын һәм кадерле нәрсәләр.

## Связь человека и природы в татарской и русской литературе XX вв.

***Мударисов Фазил Мансурович, студент III курса филиала №2 ГАПОУ «Арский агропромышленный профессиональный колледж»***
***Ахатов Нияз Фаритович, преподаватель***

XX век внес большие изменения в жизнь человека. Творения человеческих рук вышли у него из-под контроля. Цивилизация стала развиваться такими сумасшедшими темпами, что человек не на шутку испугался. Теперь ему грозит гибель от своего же детища. Да и природа стала показывать, «кто в доме хозяин», - участились всевозможные природные катаклизмы и бедствия. Таким образом, для существования Вселенной необходима гармония, как в природном, так и в человеческом мире. Пожалуй, никогда ещё проблема взаимоотношений

человека и природы не стояла так остро, как в наше время. И это не случайно. «Нам не привыкать к потерям, - писал С. Залыгин, - но только до тех пор, пока не настанет момент потерять природу, - после этого терять уже будет нечего».

"Счастье - это быть с природой, видеть ее, говорить с ней" - так писал более ста лет назад Лев Николаевич Толстой. Вот только природа во времена Толстого и даже гораздо позже, когда детьми были наши бабушки и дедушки, окружала людей совсем другая, чем та, среди которой мы живем сейчас. Реки тогда спокойно несли в моря и океаны свою прозрачную воду, а в голубом небе ничто, кроме птичьих песен, не нарушало тишину. А совсем недавно мы поняли, что всего этого чистых рек и озер, дикого леса, нераспаханных степей, зверей и птиц становится все меньше и меньше. Безумный 20 век принес человечеству вместе с потоком открытий и множество проблем. Среди них очень и очень важная - охрана окружающей среды.

Отдельным людям, занятым своей работой, порой трудно было заметить, как беднеет природа, как трудно было когда-то догадаться, что Земля круглая. Самые разные книги, на любые темы, для большого круга читателей можно найти сейчас на книжных полках магазина. Но почти каждого человека интересуют книги на нравственную тему, которые содержат в себе ответы на извечные вопросы человечества, которые смогут подтолкнуть человека к их разрешению и дать ему точные и исчерпывающие ответы на эти вопросы.

Говоря о литературе советского периода, следует рассуждать преимущественно об экологических проблемах, возникших на нашей планете. Примечательно, что еще А.П. Чехов, размышляя о причинах несчастливости, «недотепистости» человека, считал, что при нынешних взаимоотношениях между человеком и природой человек обречен быть несчастным при любой социальной системе, любом уровне материального благополучия. Чехов писал: «Человеку нужно не три аршина земли, не усадьба, а весь земной шар, вся природа, где на просторе он мог бы проявить все свойства и особенности своего свободного духа».

Евгений Базаров, устами которого Тургенев выразил мысль определенной части общества о том, что “природа не храм, а мастерская, и человек в ней работник”, и доктор Астров, один из героев Чехова, сажающий и выращивающий леса и думающий о том, как прекрасна наша земля, - вот два полюса в постановке и решении проблемы “Человек и природа”.

А в модернистской и, в особенности, постмодернистской литературе происходит отчуждение от природы, оно принимает радикальный характер: «природа уже не природа, а «язык», система моделирующих категорий, сохраняющих только внешнее подобие природных явлений». Но эта ветвь литературной жизни нашего времени далеко не

исчерпывает того, что сделано и делается писателями и поэтами второй половины XX столетия: образы природы — неустранимая, вечно насущная грань литературы и искусства, исполненная глубочайшего смысла.

В основе художественной реальности натурфилософской прозы лежит единство и многообразие бытия всего существующего. Мир социума как порождение искусственного, неестественного и хаотичного чужд той среде, которая сформировалась природно. Планетарный масштаб всего живого поглощает техносоциум, уничтожающий порождённую экосистему, вносящий хаос в жизнь флоры и фауны, а также человека как её представителя. И возникают в русской литературе зловещие образы “архаровцев”, “браконьеришек”, “туристов-транзисторщиков”, которым “сделались подвластны необъятные просторы”. “На просторах” они так резвятся, что за ними - сожженные леса, загаженный берег, дохлая от взрывчатки и отравы рыба. Люди эти потеряли связь с землей, на которой они родились и выросли. Творчество Ю.П. Казакова, А.А. Кима, Л.М. Леонова, В.Г. Распутина отражает естественный порядок: сосуществования Вселенной и личности, где последняя вынуждена подчиняться законам логоса, иначе может погибнуть. Природные ресурсы, воспринимаются людьми как материальное богатство, например, в произведении С.П. Залыгина «Экологический роман». Такое отношение к природе ведёт к гибели самого человека. Натурфилософская проза второй половины XX века создаёт неповторимый образ многомерного человека, созидающего своё бытие в природе. Он не только близок ей, но и ощущает себя её частицей — атомом.

Литература.


1. Великанов А., Скоропанова И.С. Русская постмодернистская литература: Учебное пособие. М: Издательство «Наука», 1999.

2. Гапон Е.С. Художественная концепция личности в творчестве В.Г. Распутина 1990-х- 2000-х. - Армавир, 2005 – 167 с.

3. Гончаров П.А.. Творчество В.П. Астафьева в контексте русской прозы 1950-1990 годов. - М.: Издательство «Высшая школа», 2003-385 с.

4.Смирнова А.И. Актуальные вопросы изучения современной натурфилософской прозы. // Природа и человек в художественной литературе: Материалы Всероссийской научной конференции. Волгоград: Издательство ВолГУ, 2001, с. 5-13

# Ф.Садриевның “Таң җиле” әсәрендәге табигать күренешләренең шәхес белән бәйләнеше

***Эшләде: X сыйныф укучысы***
***Нуриева Алсу Фагыйлҗан кызы***
***Фәнни җитәкче:Даутова Гөлчәчәк Минсалих кызы.***

Татар әдәбиятының мактанычы һәм горурлыгы булган каләм ияләре арасында Фоат ага Садриев лаеклы урын тота. Ул талантлы прозаик, драматург, публицист, үткен телле сатирик һәм юмор остасы булып танылды.

Фоат Садриевның әсәрләрен өйрәнә башлагач ук, төрле образларны иҗат итүдә кулланылган сәнгатьчелек алымнары, аларның үзенчәлекле булуы күзгә ташлана. Язучы геройларының эчке кичерешләрен ачуда, аларның рухи дөньясын сурәтләүдә зур уңышларга ирешә, күпьяклы тел остасы булуы һәрдаим күзгә ташланып тора.

Язучы үзенең әсәрләрендә сәнгатьле сурәтләү чараларын файдаланган. Автор сәнгатьле сурәтләү чарасы буларак чагыштыруларны, метафораларны, эпитетларны бик яратып куллана. Бигрәк тә алар пейзажны тасвирлауда бик оста файдаланганнар. Фоат Садриев иҗатында фразеологиянең стилистик кулланылышы да бар. Бигрәк тә алар пейзажны тасвирлауда, образларны ачуда биреләләр. Аның әсәрләрендә диалектлар да очрый. Сурәтләү чарасы буларак табигать күренешләренең бирелеше киң яктыртылган.

Бу иҗади эшемдә мин “Таң җиле” әсәренә тукталып китәм. Теманың актуальлеге: әдипнең чынбарлыкта яшәгән проблемаларны, образларны оста итеп ачуда табигать күренешләрен куллануы. Хәзерге көн укучысын әсәр табигать күренешләре, образларның бирелүе аша һәрьяклап тәрбияли. Шушы юнәлеш- бүгенге көн күзлегеннән чыгып карау- эшемнең яңалыгын билгели. Шуңа күрә мин бу теманы сайларга булдым. Эшнең максаты:

1. Әсәрдәге табигать күренешләрен өйрәнү.
2. Аларның үзенчәлекләрен билгеләү.
3. Әсәрнең бүгенге көндә актуальлеге.

Ф.Садриевның барлык әсәрләре татар авылы, татар кешесе язмышы өчен борчылу хисе белән сугарылган, чөнки коммунизм төзергә маташу дәверендә халкымның ун гасыр дәвамында тупланган рухи байлыгын туздыру – әдәп-әхлак кагыйдәләрен сызып ташлау, милләт сакчысы булган динен оныттыру - нәтиҗәсендә милләттәшләр күңеленең карала баруы әдипнең йөрәген яндырган. Татар авылының бүгенгесен уйлап көйгән, милләтнең киләчәге өчен кайгырып язган ул бу әсәрләрен.

Ф.Садриевның “Таң җиле” әсәре таң ату күренеше белән башланып китә. Нуриасма һәр көнне иртән торып, таңны каршылый. Ул тауларны күзәтә, табигатьнең һәр ноктасын карап чыга. Хәтта хәтер төпкелләрен актара. Җир шарын үзенең нурлары белән сөендергән кояшны сәламли. Без менә шулай төп образ белән танышабыз. Табигатьнең гүзәллеге, яшәрү һәм яңару, чисталык һәм сафлык кебек күренешләре иң матур хисләр генә тудыра ала, гүзәл хыяллар дөньясына алып керә. Бернинди борчуларсыз, мәшәкатьсез генә яшәүче кешеләрнең күңел күтәренкелеген, бәхетен, алдагы тормышларының болытсыз көн кебек булырга тиешлеген укучы табигать аша сиземли. Таң ату күренеше күңелне кузгата. Без Нуриасманың табигать баласы булуына шикләнмибез. Автор аны илаһи бердәнбер зат итеп тасвирлый. Аның һәр иртәне кояшка табынуы, Ык белән сөйләшүе безнең күңелләрне кузата. Табигатьнең тормыш белән бәйләнеше ачык чагыла. Авыл карчыклары үзләрен тышкы дөньядан аерылгысыз итеп сизгәннәр һәм табигать балалары итеп кабул иткәннәр. Бу хәләт исә аларның җанына кечкенәдән үк уй-хыял сафлыгын, игелек кылырга әзер булу теләген сеңдергән. Язучы әнә шул йөзьяшәр акъәбиләр –халыкның сөекле ул-кызлары хакында диңгез күк киң хатирәләрен күңеле түрендә саклап йөрткән һәм җан җылысын салган, киләчәк буыннар өчен түкми-чәчми теркәп калдырган.

Туган җирдән дә кадерле бер җир дә юк шул дөньяда. Автор егерме еллап Донбасс шахталарында эшләгән Фәритнең кайту вакыйгасын тасвирлый.”Нишләп бу кадәр йөрәккә якын соң син, туган җир?! Һәммәсе дә ялтыравыксыз, тәртипсез бит югыйсә: агач өйләрең дә, яшел бәрәңге бакчаларың да, кәкре-бөкре урамнарың да.” Үзенең сагыну тойгыларын капма-каршы уйлары белән дә баса алмый.“Синнән ераклашкан саен, якыная гына барабыз”,- ди ул. [108б].Фәрит кайчан кайтса да, авылны күрүгә үк, моң чишмәсенең ургый башлавын тоя, аның кайнарлыгы бөтен тәненә тарала, һәр күзәнәген били, теле сүз әйтергә дә әйләнми, елап та, елмаеп та булмый.

Әйе, геройларның эчке дөньясын ачуда пейзажның роле зур.

Ә Марат сон? Шәһәрдә яшәгәндә Марат бик нык авырый, берсеннән берсе начар чирләр өстәлеп кенә тора. Соңгы вакытта врачлар бертөрле диагноз да куя алмыйлар, бары тик урынны һәм климатны үзгәртергә кушалар. Алар балаларын авылга әниләренә кайтарып куялар.”Фәритнең колагына баланың кайнар сулышы бәрелде, борынына үлән, туфрак, май исе керде”, -дип яза автор.Кояшта каралган тәненең ялтырап торуына, табан аслары кара чутырга әйләнгән, ялантәпи йөргән малайларына ушлары китеп карыйлар.Авылның шифалы һавасы, иртәнге чык, туган җир туфрагы, авылдагы бала эшләрлек хезмәт - аны сәламәт яшәү рәвешенә керткәннәр. Бала әбисе белән иртән бергә торып, мал-туарны, кош-кортларны карарга булыша. Кайбер эшләрне мөстәкыйль үзе дә башкара. Баланың җиргә төшкән

әйберне, әллә сөртеп, әллә сөртмичә, авызына кабып ашавы да кызык.”Алар туфракта аунап өйрәнгәннәр инде”,- ди Нуриасма.

“Тирләгән,  арыган тәннәргә Ык суы көч өстәр иде. И, гомерләр! Ык сулары шикелле менә шулай сиздермичә генә ага шул. Җилнең әсәре дә юк, су өсте көзге кебек тигез иде. Әгәр анда-санда күбекләр акмаса, басма янындагы судан чыгып торган яшел түмгәкнең бөгелеп төшкән күрәнен агым туктаусыз селкетмәсә, Ыкның мәңгелек хәрәкәте бөтенләй сизелмәс тә иде.Зәңгәр күк үзенең анда-санда йөзүче болытлары белән Ык өстенә төшкән”. Автор шушы матурлыкны тасвирлаганнан соң, йомгак та ясап куя.”Бу яшеллекләр, бу сулар, бу зәңгәр күкләр-һәммәсе дә кешенең тормышын ямьләү өчен генә яратылганнардыр”,- ди ул [166б]. Ләкин шул ук вакытта үз әйткәннәренә каршы килеп, иртә таңнан ук Ык суына бетчәле Фәритне алып төшеп, берничә тапкыр юындырганнан соң бетчәләренең бетүен исбатлый. Димәк Ык суы ниндидер дәвалы үзлеккә дә ия дигән сүз. Шулай да ачлык еллары вакытында иң беренче чиратта туендыручы да булган. Автор Ык елгасына мәдхия укый. Ф.Садриев табигатьне күрә белергә өнди, елгасына да, чишмәләренә дә хөрмәт тәрбияли.

Мәхәббәттә аңлашу да табигать күренешләреннән башка була алмый. Бөтенесе дә табигый: нарат ылыслары, мәтрүшкә исләре, тирә-юньдәге биек абага яфраклары, күкне тулысынча каплап торучы нарат ябалдашлары арасыннан сирәк-мирәк җемелдәгән йолдызлар, зәңгәрсу яктылык эчендә чебен-черкиләрнең туктаусыз бөтерелүләре...

Мәсьәләнең бу ягына тукталып китик. Пейзажны сурәтләгәндә Ф.Садриев берничә максатны күздә тоткан.

Беренчесе – табигать тасвирларының геройлар күңелендә билгеле бер хис-тойгыларны, күренеш-вакыйгаларны ныграк ачу өчен дә файдаланылган. Зөбәрҗәтнең башында кайнаган коточкыч билгесезлек уйларын чагылдыра. ”Шомлы итеп берничә мәртәбә ябалак кычкырып куйды, агачлар арасыннан ниндидер кош шаулап очып узды. Агарып, бөрешеп калгандай ай шары, агачлар арасыннан чыгып, буш күктә йөзә башлады”. Зөбәрҗәтнең аңлашмый-нитми китеп баруын сурәтли. Ябалакның хәвефле сигнал биргәндәй, урманны яңгыратып ике тапкыр кычкыруын әйтә.

Фәритнең җир-туфрак белән бәйләнеше кыр-басуларга баргач кабат яңара. ”Басу өстеннән офык буйлап рәшә йөгерә, камыллар арасыннан бoҗыр балалары күренеп ала да юкка чыга, аяк астында гына чикерткәләр сайрый, камыл, туфрак исе сеңгән йомшак җил битләргә, муеннарга гына түгел, йөрәкләргә кагылып үтә” [229б]. Язучы авыл баласының җирдән аерылгысыз икәнен кат-кат раслый. Үзенең ныклы дәлилләрен китерә.

Фоат ага Садриев яшәү мәгънәсен табигать күренешләре белән бәйли. Кеше тормыштан туйгач та, соңгы минутларында табигать сулышын, аның көчен, яшәешен тоемлый. Кошларның яшәү шатлыгына сөенеп сайраулары Нуриасманы соңгы сулышын

кисүдән алып кала. Ул таң нурларында коенган табигатьне беренче күргәндәй, кошларның бәхетле җырларын тәүге тапкыр ишеткәндәй исе китеп тыңлый.”Мең төрле кош тавышын тыңлаган саен аның йөрәге ныграк, ешрак типте һәм ул карынындагы бала йөрәгенең дә нәкъ шулай тибүен сизде.Үзеңә бер мәртәбә бирелән шушы якты дөньядан баш тарту-түбәнлек, куркаклык иде”.Әйе, без монда табигатьнең яшәргә көч, ныклык бирүен күрәбез.

Нуриасма апа балаларны җиләк җыярга, җыйган чакта бер җиләк тә капмаска, савытын тутыргач, әниләре өчен җир җиләген сабагы белән җыярга, аннары гына җиләктән авыз итәргә, ягъни сабырлыкка, хезмәт сөяргә өйрәткән. Ә бит ул үз балаларын гына түгел, ә оныкларын да шул җир кануннары белән тәрбияли. Бу күренеш утызынчы-илленче еллар татар авылында буыннар арасындагы дәвамлылыкның яшәүчәнлеге турында сөйли, димәк, әле ул чакта гадәтләр нык булган. Димәк, әсәр геройларының көн дә күргән тирәлек матурлыгыннан –авыл табигате гармониясеннән –башка шәхес булып өлгерүләре һич мөмкин түгел. Нуриасма апа –дару үләннәре буенча белгеч: җәен җыеп киптергән каен һәм кура җиләген, шомырт, гөләп җимешен (шиповник), бөтнек, валериан, кура яфракларын салкын кыш көннәрендә суык тигән авылдашларына өләшкән һәм шул үләннәрнең шифалы төнәтмәсен эчкәч, ни гаҗәп, бик тиз сихәтләнгәннәр. Моңсулык, гомумән, Ф.Садриев әсәрләренә хас төп билгеләрнең берсе. Аның повестьлареннан ана теленең аһәңе, халкымның моңы, йомшак һәм моңсу юморы күңелгә язгы ташкындай агыла да агыла. Җаныңның әллә кай төшләре актарылып сыкрый, сызлый, йөрәгең хисләр өермәсе белән тулып, салкын сулы саф чишмәдәй, ташый башлый.Садриев каләменең сихри көче сине Ык елгасы буйларына, андагы гаҗәеп авылларга алып кайта, бәбкә үләнле урамнарында йөртә, таллыклы су буйларына алып төшә, чишмәләренең тешеңне сындырырдай салкын суын эчертә, авыл урманының җиләкле аланнарына алып бара, Чия тавында кызарып пешкән каен-кура җиләгеннән, чем кара эре шомырттан, өлгергән чикләвектән, карлыганнан, бөрлегәннән авыз иттерә.Күңелеңне шашкын хис биләп ала, бугазыңа төер утыра, күз төпләрең ачы күз яшьләреннән дымлана, эчтән генә әдипнең моңсу сүзләрен кабатлыйсың һәм иреннәрең ирексездән акрын гына пышылдыйлар: “Сагынулар, саргаюларны юкка гына җырламый шул татар кешесе.Биек тау башларындагы кайбер ташлар да җирне сагынып елый, диләр.Ташның күз яшьләре ага торгач гәрәбә төсле ката.Аны мумиё дип атыйлар. Сагыну җырлары да туган җиреннән милләтеннән нәсел-нәсәбеннән аерылган бәндәләрнең күңелләреннән озак дәверләр буе сыгылып чыккан күз яшьләре.

Ф.Садриев кешенең табигать баласы булуын дәлилли. ”Таң җиле” әсәре моның ачык мисалы булып тора. Ә бит кеше матурлыкны күңел күзе белән күрә белсә, аны тойса, рухи яктан бай, әхлаклы була.

Файдаланган әдәбият исемлеге.

1.Заһидуллина Д.Ф.Әдәбият белеме /Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге/-Казан: Мәгариф, 2007.

2.Садриев Ф.М. Таң җиле/-Казан нашире ШЭ Р.Х.Корбанов, 2011.

3.Хатипов Ф.М. Әдәбият теориясе/ -Казан: Мәгариф, 2000. 4.Яхин А.Г. Әдәбият/ – Казан: Мәгариф, 2001.

## Иркен минем туган илем, матур минем татар телем.

***Нурмөхәммәтова Зилә Рәил кызы***
***Әгерҗе шәһәре 2 санлы гомуми урта белем бирү мәктәбенең 8 а сыйныфы укучысы***

И данлы ил, и матур ил,

Син минем туган илем.

Әнкәемдәй бик кадерле,

Син минем туган телем.

Г. Кутуй.

Үз туган җирендә яшәп, туган телендә сөйләшеп яшәү – бу олы бәхет!

Кечкенә чагымдә әнием мине гел бишек җырларын җырлап йоклаткан, чөнки ул бик матур җырлый. Без гаиләбез дә гел туган телебездә, саф татарча сөйләшәбез.

Мин шәһәрдә туып-үстем. Әти-әнием авылдан, менә шуңа күрә дә мине кечкенә чагымнан ук инде авылга, әбиемнәргә кайтаралар, җәйге каникулларым да авылда уза. Авылга кайтуны мин әкият дөньясына кайткандай көтеп алам. Шәһәрнең кырыс режимыннан соң, кыш буена мәктәп белән үзем яшәгән йорт арасыннан башка дөнья күрмәгән бер кыз бала өчен авыл ул могҗиза! Мин анда чын татарча рәхәтләнеп сөйләшәм, дус кызларым белән аралашам.

Туган җир, аның матур, искиткеч табигате, бай татар теле. Әйе, горурланам мин татар булуым белән, татар илендә, туган җиремдә яшәвем белән горурланам. Үзебезнең татар язучыларының китапларын яратып укыйм. Гомәр Бәшировның “Туган ягым - яшел бишек” повесте аеруча да матур язылган. Гариф Гобәйнең “Маякчы кызы” повестендагы “Агыйделдә таң ата” бүлегендәге табигать күренеше бигрәк матур тасвирланган. Түшен тәккәбер киереп, шул ук вакытта бик сакланып йөзгән аккош, ана үрдәкнең бак-бак килеп балаларын йокыдан уятуы, күктәге соңгы йолдызларның сүнүе күз алдына килә. Безнең Әгерҗе районы Кичкетаң авылында да Татарстан тыюлыгы бар. Анда да һәр ел 50 дән артык аккошлар кайта, кыр казлары, кыр үрдәкләре бәбкә чыгара, аю, поши, куян һәм төлкеләр турында да күп язалар анда эшләүче апа-абыйлар. Тыюлык хезмәткәрләре мәктәп

укучылары белән һәрдаим очрашулар оештыралар, без нәни дусларыбыз кошларга җимлекләр ясыйбыз, әтиләребез сыерчык оялары ясап бүләк итәбез. Алар оештарган экологик бәйгеләрдә катнашабыз.

Туган як табигатенә сокланмый мөмкин түгел! Башакларын тутырып килүче игеннәр, алар арасында үсеп утыручы күкчәчәкләр, урманнар, Иж елгасы, саф һава, чәчәкләр, җиләк исе... Монысы җәй! Ә язы, язы тагын да хислерәк. Күңеләрне иләсләндереп җиргә яз килүе. Кар сулары йөрәк ярсуын басарга тырышыпмы, әллә инде тизрәк агып китәселәре килепме, гөрләвекләр булып, язгы ташкын суларга ошарга тырышып, юл буйлап каядыр чабулары. Шул чакта кечкенә чакта ясаган кәгазь көймә күз алдына килә. Эх, шуңа утырып йөзеп китсәң иде. Кая илтеп ташлар иде микән ул мине? Җылы яккамы, әллә инде күз күрмәгән, колак ишетмәгән чит-ят җирләргәме? Юк! Туган ягымнан кая китим инде тагын!? Шушы җирне сайлап тудым, шушы җирне яратам бит мин. Туган ягымның кояшы да җылы, җилләре дә саф, һавасы да, чишмә сулары да шифалы, татлы.

Әйе, туган як... Кечкенә генә кошчыгыңа да кадерле бит син. Шул кошларның күктә талпынып шатланулары, язгы суларның челтерәп агулары, җилләрнең йомшак шавы әллә нинди моңлы көйгә әверелә кебек. Беркайчан, беркайда ишетмәгән моңлы бер җыр төсле.

Көзләре алтынга манчылган, кышлары аклыкка төренгән табигать бары бездә генә шул.

Иркен, бик иркен минем туган илем. Әмма аның табигате бүгенге көндә куркыныч астында. Табигать-безнең туган йортыбыз. Балыклар сусыз, җәнлекләр урмансыз, урманнар агачларсыз була алмаган кебек, кешеләр дә табигатьсез яши алмый. Адәм баласы кая гына яшәмәсен, шәһәр, авыл, ул һәрвакыт үсемлекләр, хайваннар, кошлар, бөҗәкләр белән әйләндереп алынган. Шуңа күрә дә кеше табигатьнең аерылгысыз бер кисәге дип әйтер идем мин.

Мәктәптә дә, аеруча татар теле һәм татар әдәбияты дәресләрендә,

табигатьне саклау турында бик күп чараларда катнашабыз, әдәби әсәрләр бик күп укыйбыз, төрле конференцияләр, диспут-дәресләр үткәрәбез.

Табигатьне саклау турындагы экологик проблемалар элек-электән әдипләребез тарафыннан күп әсәрләрдә күтәрелгән. Әмма кеше барыбер үзенекен итә. Табигатьне пычрата, агулый һәм шулай итеп, аңлы рәвештә, юкка чыгара. Әйе, аңлы рәвештә, чөнки Аллаһы Тагәлә тарафыннан кешегә, хайваннардан аермалы, акыл, зиһен бирелгән. Шуңа күрә кеше табигатьне аңлы рәвештә һәлакәткә илтә дип әйтер идем мин. Аннан башка яши алмаганын да белә ул. Чөнки адәм баласы табигатьтән башка бер көн дә яши алмый. Табигать-безнең яшәү чыганагыбыз.

Елдан-ел суларыбыз пычрана, очсыз-кырыйсыз урманнарыбыз бер мәгънәсезгә киселә, химия заводларының агулы газлары белән чиста һавабыз бозыла. Болар әле кешелек дөньясының табигатебезгә салган зыянының бер өлеше генә. Без-киләчәк буын. Ә киләчәк буынның яшәеше табигать белән бәйле. Табигатьне, туган йортыбызны, зарарланудан без туктатмасак, ни булыр соң? Уйлавы да куркыныч. Берничә дистә елдан соң, бөтен тереклек көеп, чүл уртасында калмабызмы? Менә шул турыда, һичшиксез, һәрбер кешегә уйларга кирәк, минемчә. Адәм баласы иртәгә нәрсә буласы турында уйламаганга күрә, табигатькә карата шундый рәхимсез мөнәсәбәттә, минемчә. Һәрберебез, булдыра алганча, үзебездән өлеш кертик. Агачлар утыртыйк, яшеллекне саклыйк, тирә-ягыбызны чүп-чарлардан чистартыйк.

Туган җиребезнең газиз булуы, татар телебезнең бетмәве, табигатебезнең пычранмавы да барысы да үзебездән тора! Яшәүнең кадерен белик!

*Кулланылган әдәбият:*


1. *Гомәр Бәширов “Туган ягым –яшел бишек” -2014*
2. *Фәүзия Бәйрәмова “Болын” - 1986*
3. *Гадел Кутуй “Сайланма әсәрләр” - 2003*
4. *Гаиф Гобәй “Маякчы кызы” - 1988*
5. *Әгерҗе төбәгендә иҗат итүче “Күңел чишмәләре” әдәби –иҗат берләшмәсе әгъзаларының язмаларыннан өзекләр. -2012*
6. *“Чишмә - халкымның күңел бизәге” (Әгерҗе районы чишмәләре тарихы китабы) - 2008*
7. *Интернет челтәрдән электрон ресурслардан кулланылды.*


## Человек и природа в литературе XX-XXI вв


***Рафагутдинов Ренат Саубанович***
***студент ГБПОУ «БППК», 5 курс***
***Туганова Насима Бариевна,***
***преподаватель татарского языка и литературы,***
***ГБПОУ «ББПК»***


Взаимоотношения человека и природы стали ухудшаться с развитием науки и техники. Собственно, наука и техника развивались всегда, этому свидетельствует история человечества.

Но с какими темпами не развивались бы наука и техника, человек прямо понимал, что природа вершит весь полученный результат, является основоположником. На протяжении

многих веков техника была для человека средством, не более. Что в результате? Такие партнеры как человек и природа превратились едва ли не во врагов.

Проблема взаимоотношения человека с природой никогда еще не стояла так остро, как в наше время. «Нам не привыкать к потерям, - писал С.Залыгин, - но это так, пока мы не потеряем саму природу, - после этого терять уже будет нечего».

Тема взаимоотношения человека и природы во всех временных промежутках истории, является очень актуальной, а в современном мире превращается в глобальную проблему. Актуальность находит свое отражение в произведениях писателей: В.Астафьева, В.Распутина, С.Залыгина, Ч.Айтматова, В.Белова, Б.Васильева и другие. Именно они первыми выступили с требованиями решения экологической проблемы.

Сегодня художественная литература, в частности В. Распутин в повестях «Прощание с Матерой» и «Пожар», рассказывает нам об огромном вреде природе, человеку, нанесёнными вековыми стройками, кампаниями против неперспективных деревень, которая пожаром пронеслась по стране. В.Распутин показывает, что безжалостное отношение к среде обитания ведет к упадку нравственности. Голос В.Распутина в повести «Пожар» звучит громко в сторону людишек, которые не помнят своего родства, корней, жизни. Пожар как возмездие, как сжигающий подряд огонь, уничтожающий на скорую руку все постройки человека. Склады горят в деревне Сосновка, здесь и проявилась вся ущербность души человеческой именно в таких экстремальных условиях как пожар. Повесть показывает нам всю тревогу по поводу утраты жителями Сосновки многих человеческих качеств, норм, которые формировались столетиями труда человеческого на их земле.

Реальная опасность конца, катастрофа мира пронизывается в романе Ч.Айтматова «Плаха». Роман начинается темой волков, в последствии чего перерастает в гибель Моюнкумской саванны. Гибель возникает по вине человека, который врывается туда как хищник, палач уничтожающий все живое. Естественная среда обитания волков предопределяет Айтматов в завершении борьбы синеглазой волчицы Акбары с человеком. Убив волчицу, несчастный Бостон убивает и сына, и для него наступает конец света. Разрушая и уничтожая природу, человек лишает жизни поколение, а ведь это и его конец. Роман Ч.Айтматова как громкий крик, призыв к каждому одуматься, понять свою ответственность за все.

В повести В.Астафьева «Царь-рыба» природа мстит не только за отношение к себе, но и за прошлые грехи. Природа приходит к герою в виде огромного осетра. Герой повести Игнатьич решает выловить гигантскую рыбу любыми способами, и оказывается в воде, на крючке собственной снасти по своей неосторожности. Он тонет, а рыба влечет его за собой на дно, и он не в силах спасти себя от гибели. Герой не веривший в Бога, вдруг решил

обратиться к Нему за помощью. В этот момент в его памяти воскресает то, о чем и о ком он пытался забыть: об опозоренной девушке, обреченной им на пожизненное страдание. Надеясь на помощь, что хоть кто-нибудь услышит его, он прерывисто заговорил: «Глаа-а-аша-а-а, про-с-с-тии-и…». Когда рыба отпускает его, герой чувствует, как душа его освобождается от греха, которым он тяготил всю свою жизнь.

Художественная и научная литература по проблемам взаимоотношения человека с природой показывает, что культура, человек и природа тесно взаимосвязаны: культура влияет на человека, а через человека на природу; человек влияет на природу и тем самым на культуру; природа в свою очередь является домом человека, и через него влияет на культуру. Любые чувствительные перемены сторон оказывают сильнейшее влияние на друг друга. Настолько сильное, что трудно найти выход из ситуации. А человеку стоит больше заботиться о своей душе, в этому во многом может помочь литература.

Список использованных источников

1. Агеносов А.Русская литература XX век.Учебник. "Русская литература". Большой учебный справочник для школьников. – М., Дрофа, 2015.

2. Агеносов В. В. Человек и мирозданье в лирико-философском романе В. Астафьева «Царь-рыба» // Агеносов В. В. Советский философский роман. – М., 2013

3. Бадиков В.В. и др. Русская литература ХХ века: Писатель и эпоха. Учебник. Для 11 класса естественно-математического направления общеобразовательных школ с русским языком обучения / Сост.: В.В.Бадиков, Л.В.Сафронова, И.Б. и др. Издание 2-ое, дополненное и переработанное. – Алматы: Жазушы, 2014.

4. Жуков И. «Царь-рыба»: человек, история, природа – тема произведения В. Астафьева. – В кн.: Жуков И. Рождение героя. – М., 2013. – 301с. – с. 202-213

5. Карпинская Р.С. Философия природы: коэволюционная стратегия. -М:Интерпракс, 2014

6. Курбатов В. Миг и вечность: Размышления о творчестве В. Астафьева. – Красноярск, 2012

7. https://infourok.ru – «Инфоурок»

8. http://iessay.ru/ - Электронный сайт лучших материалов по литературе

9. http://bigreferat.ru – Каталог лучших собрании рефератов, сочинений и др.

# 20 нче гасыр татар шигъриятендә кеше һәм табигатьнең үзара бәйләнеше

***Сафина Венера Рамил кызы, 10 нчы сыйныф,***
***Алабуга шәһәре, 2 нче мәктәп.***
***Фәнни җитәкчесе: Сәхәбиева Альбина Мансур кызы***

Кеше тормышы һәрвакыт табигать белән бәйле. Элек-электән кеше үзен табигать белән бербөтен итеп тойган, аның бер өлеше, баласы дип санаган. Табигать - кешенең сәламәтлек, туклану, гомумән, яшәеш чыганагы. Табигать дигәч, иң беренче чиратта, калын яшел урманнар, саф сулы чишмәләр, бай тарихлы елгалар, күлләр, иксез-чиксез җәелеп яткан далалар күз алдына килә. Кеше нинди генә катлаулы машиналар уйлап чыгармасын, барыбер, туу, тереклек итү өчен җир, су, һава, кояш кирәк. Безнең борынгы әби-бабаларыбыз табигатьне бөек дип санаганнар, аңа табынганнар, кайгыртканы өчен зурлаганнар. Цивилизация үсеше белән кеше табигатькә хуҗа була, кулланучы буларак аннан файдалана башлый. Элек-электән үк, кеше белән табигать арасында көрәш бара. Күренекле шагыйрьләребез, рус әдәбиятыннан А.С.Пушкин һәм М.Ю.Лермонтов, бөек Габдулла Тукаебыз үзләренең иҗаты аша укучыларны кеше табигатьсез яши алмый, кеше һәм табигать – бербөтен икәнен ассызыклыйлар.

Әлеге бердәмлек балачаклары һәм яшьлекләре авылда узган татар шагыйрьләрендә аеруча сизелә. Минем, кеше һәм табигатьнең бер-берсе белән бәйләнешен өлкән буын шагыйрьләрнең шигъриятенә нигезләнеп күрсәтәсем килде. Н.Арсланов, Г.Афзал, К.Сибгатуллин иҗатларын өйрәнеп, кеше һәм табигаьнең бердәмлеген ачыкладым. Кеше табигатьтән башка бер генә минут та яши алмый икәненә төшендем.

Күп кенә өлкән буын шагыйрьләре яздан көзгә кадәр яланаяк йөреп үскән кешеләр бит. Бөек Ватан сугышы елларында табигать аларны ачлыктан коткарган; алар – һәрбер күзәнәкләре белән җир - ананың, ак каенның, сулыкларның хис-кичерешләрен тойганнар. Еш кына кеше белән табигатьнең бәйләнеше шагыйрьләрнең иҗатында тиңдәшлек дәрәҗәсендә тора. Мәсәлән, Н.Арслановның “Бик беләм” шигырендә лирик герой иң элек табигатьнең үзгәрешле булуын тасвирлый:

Я яңгыр, я кар ява,

Бер- кояш карый көлеп,

Бер- болыт китә күмеп.

Диңгез, баксаң, бер тына,¬¬¬¬¬

Бер шауларга тотына...

Шигырьнең соңгы юллары да игътибарга лаек, чөнки лирик герой үзен табигать кочагында кебек хис итә.

Кадыйр Сибгатуллин иҗатыннан күренгәнчә шагыйрь табигатьне тасвирлап,үзенең философик фикерләрен җиткерә. Автор фикеренчә, табигать ул – безнең тирә - ягыбыз гына түгел, ә безнең тормышыбыз, сулышыбыз, без – үзебез дә. Шагыйрь болай дип яза:

Һәр тузаны яши, һәр ташы,

Урын юктыр монда үлемгә.

Яшел үлән булып- без булып

Әтиләрем кайта бүгенгә.

Әлеге шигырьдә шагыйрь – әтиләре сугышта, туган җирләрен яклап, һәлак булып калган буынның вәкиле буларак тасвирлый. “Яшел килеш яфраклар коела” дигән башка бер шигырендә фаҗигале нота яңгырый. Яшел килеш коела торган яфраклар шагыйрь яшь егетләрнең авыр сугышлардагы батырлыклар кылган вакытларын күрсәтә. Шагыйрь үлемсезлек турында да сөйләми, чөнки изге сугышка, ирекленкә урын юк, тик халыклар, милләтләр үлә торган сәяси уеннар гына барлыгын ассызыклый.

Автор “Иргә чыкмый калган апалар” поэмасында, сугышка һәм соңгы юлга озаткан, сөйгән ярларына тугъры булып калган илле яшьлек авыл хатыннарына игътибар итә. Тугърылык – татар хатын кызының гүзәл сыйфаты. Кыюсыз үбешүдән башка берни дә булмаган дустыңа тугъры булып калу дөрес һәм мәҗбүри дә түгел, ләкин табигать геройларны әлеге адымга чакыра. Урылырга өлгермәгән басулар символик образга ия: ул егетләрнең тавышы белән сөйләшә; үләннәр дә яшь парлар шикелле, бер-берсенә уралып үсәләр. Бу басу – авыл хатыннарының бердәнбер сөенече. Беркем дә аларның күз яшьләрен күрми, алар беркемгә дә зарланмыйлар, бары тик монда гына үзләренең хис- кичерешләренә иркенлек бирә алалар.

20нче гасырның тагын бер танылган татар шагыйре – Гамил Афзал, шулай ук табигатькә мөрәҗәгать итә. “Яшьтәшләр” шигырендә лирик герой җирнең һәрбер кисәге өчен сугышкан кыю һәм батыр яшьтәшләренең үлеме турында кайгыра:”Алар үзләренең күкрәкләре белән туган җирне каплап сугышны җиңделәр” дип яза ул. Автор үзенең башка шигырендә дә бар дөньяның бәхетен тау итәгендәге имәннәрнең шаулавы, басуларның пышылдавы белән бәйли.

Әлеге чыгышымда, 20 нче гасырның 60-90 нчы еллардагы әдипләрнең иҗаты буенча, кеше һәм табигатьнең бәйләнешен, мин бары тик берникадәр өлешендә генә карадым. Чынлыкта әлеге тема зур күләмле һәм тирәнрәк өйрәнүне таләп итә. Минем, табигатьне татар шагыйре өчен, яшәү символы, алар бер- берсеннән аерылгысыз икәнен күрсәтәсем килде. Бу хәзерге буынга кисәтү булып яңгырый, чөнки безнең алдагы тормышыбыз һәм киләчәгебез табигатькә карата булган мөнәсәбәтебездән бәйле.

Кулланылган әдәбият исемлеге

1. Арсланов Н. Сайланма әсәрләр / кереш сүз авт. Р.Әхмәтҗанов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – 351 б.

2. Афзал Г. Сайланма әсәрләр: лирик һәм юмористик-сатирик шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. – 398 б.

3. Сибгатуллин К. Бер ноктада: шигырьләр. поэмалар. Баллада. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 559б.

## Барча тереклек калсын киләчәк буыннарга...

***Сәгъдиева Илсөя Шәфкать кызы ,***
***Чистай медицина училищесының II курс студенткасы***
***Җитәкчесе: татар теле һәм әдәбияты укытучысы***
***Цыганова Елизавета Михайловна***

Туган як, туган туфрак кеше тормышында иң мөһим урынны алып тора. Туган ягыбызның табигате-безнең туган йортыбыз. Балыклар сусыз, җәнлекләр урмансыз, урманнар агачларсыз була алмаган кебек, кешеләр дә табигатьсез яши алмый. Адәм баласы кайда гына яшәмәсен, ул һәрвакыт үсемлекләр, хайваннар, кошлар, бөҗәкләр белән бербөтен. Шуңа күрә кеше табигатьнең аерылгысыз бер кисәге дип әйтер идем мин.

Табигать темасы һәрчак бик актуаль. Элек- электән халык табигать белән бәйләнештә торган. Тик бүгенге көндә табигать безнең ярдәмгә мохтаҗ. Ул яралы, сагышлы. Шуңа да эзләнү эшемне әлеге темага багышларга булдым һәм, эшемнең максаты итеп, табигать проблемасын тикшерүне алдым. Максатыма ирешү өчен, түбәндәге бурычларны үтәргә тиешмен:

- табигатькә янаган проблемаларны өйрәнү;
-табигатьнең кеше белән бәйләнеше проблемасын ачыклау;
- аңа ярдәм итү турындагы материаллар туплау.

Эзләнү эшен түбәндәге юнәлештә алып барырга булдым:

- мәктәп һәм шәһәр китапханәләренә мөрәҗәгать итеп, табигать проблемаларын күтәргән авторларыбызның әсәрләрен өйрәнү;
- шул темага караган материаллар туплау.

Теманың өйрәнелү дәрәҗәсе: Бүген табигатьне, кешелекне, гомумән, Җир шарын саклап калу – иң мөһим проблемаларның берсе. Аны өйрәнү сорала.

Тикшеренү объекты булып, табигатьне саклау проблемасы тора.

Эшемнең актуальлеге – Җир – ананы рәнҗетмәү, аны бәлалардан коткару.

Бу фәнни эшем эзләнү ягыннан зур әһәмияткә ия дип улыйм, чөнки

бүген табигатьне, кешелекне, гомумән, Җир шарын саклап калу – иң мөһим проблемаларның берсе.

Бүгенге көндә табигать безнең ярдәмгә мохтаҗ. Табигать юкка чыкса, кешелек тә юкка чыгачак. Ә без, ягъни яшьләр, моның турында уйламыйбыз да, заман итәгенә чытырдатыпябышып, ычкындырмыйча, аның артыннан йөгерәбез, табигать турында уйлап та карамыйбыз. Кайларга барып җитәрбез −Ходай бер үзе белә.

Табигатьне саклау турындагы экологик проблемалар элек-электән Г.Тукай, Х.Туфан, Г.Зәйнәшева, Г.Бәширов, Г.Ибраһимов, Ә.Фәйзи, С.Хәким, Г.Кутуй, И.Юзеев, Н. Гыйматдиноваларның күп кенә әсәрләрендә күтәрелгән. Алар табигать белән кешене бергә бәйләп күрсәтәләр. Аларча, хәзерге кешенең фаҗигасе − табигатьтән аерылу, аны санга сакмау, хәтта аны каһәрләү аркасында. Әмма кеше барыбер үзенекен итә. Елдан – ел суларыбызны пычрата, очсыз-кырыйсыз урманнарыбызны бер мәгънәсезгә кисә, елга-күлләребезне киптерә, чишмәләребезне челтерәүдән туктата, табигатьне пычрата, агулый һәм, шулай итеп, аңлы рәвештә, юкка чыгара. Әйе, аңлы рәвештә, чөнки Аллаһы Тагәлә тарафыннан кешегә, хайваннардан аермалы, акыл, зиһен бирелгән. Шуннан чыгып, кеше табигатьне аңлы рәвештә һәлакәткә илтә дип әйтер идем мин. Табигатьне, туган йортыбызны, зарарланудан туктатмасак, ни булыр соң? Уйлавы да куркыныч! Менә шул турыда, һичшиксез, һәрбер кешегә уйланырга кирәк, минемчә,чөнки табигать-безнең яшәү чыганагыбыз. Дөресен әйткәндә, кеше табигатькә карашын үзгәртмәсә, безне әллә нинди куркыныч сынаулар көтәчәк.

Фәнни эшне эшләү дәверендә куелган максатыма өлешчә ирештем дип саныйм, чөнки туган як, табигать проблемасының актуальлеге дәлилләнде. Адәм баласы табигатьне - җир ананы сакларга, кадерләргә, кендек каны тамган туган җирен ихтирам итәргә тиеш. Моның шулай булуы әдәби әсәрләр мисалында тагын бер кат исбатлана.

Йомгаклап шуны әйтәсем килә: Г.Бәширов туган як гүзәллеген тасвирлаган кебек, без дә бик күп еллар буена үз ягыбызның табигате белән соклансак иде, хәлебездән килгәнчә аңа ярдәм кыла алсак иде. Кеше туганым! Әйдә туган табигатебезне саклыйк! Һәрберебез, булдыра алганча, үзебездән өлеш кертик. Агачлар утыртыйк, яшеллекне саклыйк, тирә-ягыбызны чүп-чарлардан чистартыйк! Бер-беребезнең сүзләренә колак салып, изге эшләргә тотынсак, табигатебез дә безгә карата мәрхәмәтлерәк булыр иде. Пычратмыйк, зарарламыйк, агуламыйк аны. Акылыбызга килеп, үзебезнең барлык борчуларыбызны онытып, мәкерле байлык артыннан кууыбызны ташлап, Табигатькә, аның үксеп елавына колак салыйк! Рәнҗетмик Җир – ананы.

Көтелгән нәтиҗә: табигатьне саклау – барлык кешеләрнең изге бурычы. Кеше белән табигать бербөтен булганда гына, тормышыбыз ямьле, һавабыз чиста булыр.

Кулланылган әдәбият

1. Бәширов Г. Әсәрләр. 2 том.Туган ягым- яшел бишек.-Казан, Татарстан кит.нәшр., 1982.

2. Галимуллин Ф. Халыктан һәм халыкныкы. Эзләнү вакыты. 1994.

3.Гыйматдинова Н. “Сихерче”.

3. Исхакый Г. Сайланма әсәрләр. Казан: Татарстан Республикасы ”Хәтер” нәшрияты.

## Туган телдә җырлый чишмә, туган телдә шаулый таллар

***Автор: Сәйфиева Гөлнара Рәис кызы,***
***Минзәлә медицина училищесының беренче курс студенткасы***
***Фәнни җитәкче: Илдарханова Флүсә Мөхәммәтхаҗи кызы***

Кешең бар нәрсәсе дә

Гүзәл булырга тиеш:

Йөзе дә, киеме дә,

Йөрәге дә, уйлары да.

Мин–авыл баласы. Кечкенәдән җырлы, моңлы, гәҗәеп гүзәл табигатьле авылда үстем. Авылымның челтерәп аккан чишмәләре, бормалы инешләре, шаулап торган серле урманнары, игеннәргә бай басу-кырлары, газиз кояшның беренче нурларын каршылаучы мәчет манарасы - болар минем йөрәгем түрендә. Чөнки мине балачактан ук туган якның матурлыгын аңлый белүче, туган телен яратучы, аңа гашыйк булган кеше итеп тәрбияләделәр.

Мин үземнең туган җиремә чын-чынлап гашыйк. Туган җиреңдә яшәү - зур бәхет ул. Шул бәхетне тоеп, минем бик озак яшисем килә. Безнең авыл яныннан гына зур катнаш урман башалана.

Урман... Урман һәр ел фасылында узенчә матур, үзенчә сөйкеме, үзенчә сихри, үзенчә серле. Ә җәйге урман миңа аеруча кадерле: килгән саен яңа ягы белән ачыла ул.

Агач һәм куакларны сындыручыларны  яратмый иде бабам. Аларны устерү җиңел түгел шул. Таптау нәтиҗәсендә төрле үләннәр, агачлар корый. Әгәр дә урманнар булмаса, без инде күптәннән тончыгып үләр идек.

Көлтә-көлтә чәчәк бәйләмнәре дә җыярга кушмый иде бабам. ”Карагыз, сокланыгыз һәм саклагыз!”-ди. Кешенең саксызлыгы аркасында республикабызның ”Кызыл китабы” калыная бара. Димәк, күпме үсемлек, кош-корт, хайван юкка чыга бара дигән сүз. Боларның

шулай булуына төп гаеп - кешеләр. Чөнки урманга төрле максат белән йөргән кешеләрне очратасың. Берәуләр, ярамаса да, ауга чыгалар; берәүләр “әйбәтләп” ял итәләр, артларыннан чүп өемнәре калдыралар: көлтә-көлтә чәчәк бәйләмнәрен җыеп ташлыйлар, агачларны сындыралар, учак ягалар. Гектарлаган урманнар да кеше аркасында яна. Бер утыруда калдырып киткән чүп-чар өеме урманга никадәр зыян китерә.

Күп кенә елга-күлләр дә кешеләрнең битарафлыклары аркасында зыян күрә. Су буйлары, чишмә яннары, чиста булса, үзебезгә дә күңелле бит.

Чишмәләр-барлык төр сулыкларның башлангычы, тукландыра торган чыганаклары. Чишмә яшәүдән туктаса, елга-күлләрдә су бетәчәк, авылда ямь калмаячак. Аларны чистартып, саклап калу өчен күңел кирәк, туган төбәгеңне ярату кирәк. Ә туган төбәгеңне ярату туган телеңне яратудан башка була алмый.

Гомеремдә җыйдым гыйлем-

Мөгалимнәр бирде белем.

Күңелемдә якын итеп

Алган сабак - туган телем.

Кеше дөньга беренче аваз салуга, аны тудырган ана аңа туган телендә “балам” дип эндәшә. Баланың беренче әйткән сүзе дә туган телендә яңгырый. Кеше үзенең иң саф хисләрен бары тик туган телендә генә белдерә ала. Бөек Тукай юкка гына үзенең иң кадерле кешеләре әти-әнисенә рәхмәт сүзләрен, алар рухына багышланган догаларын туган телендә белдермәгән:

И туган тел! Синдә булган

Иң элек кылган догам:

Ярлыкагыл, дип, үзем һәм

Әткәм-әнкәмне, Ходам!

Галимнәр фикеренчә, үз туган телендә белем алу балага җиңелрәк бирелә һәм үзләштерү, аңлау дәрәҗәсен арттыра икән. Үз туган теленең кешегә тәэсир көче дә көчлерәк. “Халыкның иң зур байлыгы, иң кадерле рухи хәзинәсе - һичшиксез, аның теле”,-дип яза Гомәр Бәширов. Шуңа күрә дә безнең галимнәребез, язучыларыбыз һәм шагыйрьләребез туган телгә зур игътибар бирәләр.

Мин Гадел Кутуйның танылган табиб Галия турында язган “Тапшырылмаган хатлар” повестен берничә тапкыр укыдым. Галия - танылган табиб. Үзе эшләгән районда медицина эшен югары дәрәҗәгә күтәрә. Ул моңа белемле булуы, тырышлыгы, сизгерлеге, авыруларга игътибарлыгы аркасында ирешә.

Галимҗан Әпсәләмовның “Ак чәчәкләр” романы безне бөтенләе белән табиблар дөньсына алып кереп китә. Әбүзар Гиреевич, Гөлшаһидә - минем иң яраткан образларым.

Мәдинә Маликованың “Шәфкать” романы кулларына диплом алып, хезмәт юлын башлаган яшь табиблар турында. Яшь белгечләргә профессор Җәмилә Закировна болай ди: “Без сезгә белем бирдек, табиб исемен үзегез яулагыз. Кешеләрнең газапларын җиңеләйтүдән куаныч табыб яшәгез, бәхетнең иң зурысы шул.”

Аның сүзләрен хуплап, минем дә болай диясем килә: “Бу бәхет миңа да елмайсын иде. Үз илемдә туган телемдә сөйләшеп, тәмле телемне кызганмыйча, мохтаҗларга, авыруларга ярдәм кулы сузсам иде. Амин!”

Кулланылган әдәбият:

1 Әпсәләмов Г. Ак чәчәкләр: роман. - Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1965. - 523 б.

2 Маликова М.Г. Тылсым. Шәфкать: романнар. - Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2008. - 400 б.

3 http://kitaphane.tatarstan.ru/ Национальная библиотека Республики Татарстан . Электронная библиотека. Татарская электронная библиотека.

## Экология человеческих взаимоотношенийв современной литературе

***Салахова Алина Ирековна***
***(руководитель Фатрахманова Сария Рафаиловна),***
***1-й курс, ГАПОУ «Казанский строительный колледж»***

С давних времен люди и природа – это одно единое целое. Человек неразрывно является частью природы, венцом ее творения. Трудолюбие, уважение, преклонение – это те чувства, которые должны присутствовать в каждом из нас по отношению к природе. Люди – это дети природы, и каждый человек индивидуален.

Мы приходим в это мир такие разные, со своими интересами, талантами, способностями, суждениями и мыслями. Очень важно правильно выстроить отношения в экологии культуры, не нарушив человеческих взаимоотношений.

На сегодняшний день проблема культуры экологии человеческих взаимоотношений является весьма актуальной. К сожалению, люди привыкли только брать у природы, активно эксплуатировать, не отдавая ничего взамен. Понятие экология человеческих взаимоотношений – это часть общей культуры как общества в целом, так и каждого отдельного человека. Ненависть к ближнему человек испытывает с первобытных времен, но развитие культуры превращает это чувство в любовь, сопереживание, сострадание ко всему живому.

Нельзя не согласиться с автором статьи «Экология человеческих отношений». Каждый человек должен любить. Человеческие взаимоотношения основаны на взаимопонимании

между людьми, на совершенствовании своего духовного мира. Любовь помогает видеть и слушать душу человека, заставляет задуматься о равнодушии, безразличии, низости. Все начинается с любви. Каждый человек сталкивается в своей жизни с благородством и подлостью, радостью и горем. В его духовной жизни бывают времена торжеств и страданий. Размышлять о любви, о человеческих взаимоотношениях всегда очень трудно.

Любить другого человека всегда трудно. Это огромный душевный труд, это умение принять его таким, какой он есть.

В произведении «Дочь Бухары» Людмила Евгеньевна Улицкая стремиться донести до своего читателя всю значимость культуры взаимоотношений. Автор учит нас понимать ценность жизни в любых её проявлениях и беречь свою уникальность, сохранять в неприкосновенности важнейшие нравственные принципы, табу, свою неповторимость, считая это актуальными проблемами, стоящими перед обществом.

Два женских образа в рассказе Улицкой - мать и дочь являются ярким примером того, что каждый человек имеет право на счастье, в независимости от внешности, диагноза, жизненной ситуации. Образ Али «красавицы с туманно-черными глазами», «женщины Востока» учит нас никогда не сдаваться, не опускать руки и никогда не предавать. Любовь матери к своему особенному «солнечному» ребенку способна творить чудеса…

Бухара смогла достойно воспитать Милу, она водила ее в специальную школу для дефективных детей, куда и сама устроилась работать. Мать сопровождала дочь везде, старалась научить ее как можно более разнообразным вещам: готовить, держать иголку в руках, шнуровать ботинки. Такие дети – это, ни в коем случае, не горе, не приговор и не наказание для настоящей матери. Их называют светлыми или солнечными, потому что они улыбаются чаще других. Они способны любить и жить полной жизнью, хотя рождены совершенно не приспособленными для этого мира. «Дети – даунята» невероятно добрые, отзывчивые и веселые…

Что можно требовать от общества, когда родной отец Мили постоянно думал «о невообразимом ужасе происшедшего» и о том, «каким чудным ребенком могла бы быть эта девочка, какая обаятельная личность похоронена в дефектной телесности». А ребенок рос улыбчивым и спокойным, никак не заявляющим о себе, общество практически и не знало об ее существовании. Девочка жила и «смотрела на мир за забором в щелку, на улицу не выходила…».

Читая произведение, обращаешь внимание на то, что и в минуту радости, и в трудную минуту жизни героини тесно связаны с природой, есть некая незримая нить. Мила росла «в счастливом одиночестве», но окруженная природой: «железная бочка с дождевой водой, окруженная разнообразными запахами и мелкими движениями насекомых вокруг нее и

внутри, старый дуб в углу сада, тоже весь наполненный мелкой животной жизнью, осыпающий красивые желуди в шершавых шапочках, жесткие резные листья и хрупкие веточки». В трудные минуты смертельной болезни Бухара тоже обратиться за помощью к природе. Поездка домой, на родину, впервые за многие годы. Бухара вернется с огромным мешком трав, которые помогут ей продлить жизнь еще на 6 лет. Непрерывная связь с природой «ела только одну еду – вареный рис и сушеные абрикосы, привезенные с родины». Природа не предаёт, как люди, а принимает их такими, какие они есть, и помогает им жить.

Мировая статистика показывает, что каждый 700-ый ребенок во всем мире рождается с синдром Дауна. В нашем обществе мало говорят о таких людях. Не принято обсуждать, а принято замалчивать. Как будто и нет их вовсе. Окружающие не видят в них личности полноценного человека. Восемь из десяти малышей с этим диагнозом растут без родителей. И каждый прожитий день «солнечного» ребенка – это победа. Такие дети могут стать вполне успешными в жизни, в обществе — они всему обучаются, социализируются. Они могут освоить профессии и даже жить самостоятельной жизнью!

Список литературы

1. Экология человеческих отношений <a href="http://pandia.ru/user/profile/prirrrod">КаналПрирода</a>, персональный сайт

## Человек – это звучит гордо? (по произведениям писателей XX века)

***Севастьянова Д.А.,***
***ГБПОУ «Спасский техникум отраслевых технологий»,***
***студентка 1 курса***
***Руководитель – Стрелова Т.Г.***

О проблемах экологии сегодня говорят повсюду: в печати, по телевидению, в интернете, на автобусной остановке, в метро. Интересно, кто же заговорил об этом первым, кто обратился к этой теме еще в 19 веке, кто заметил начало этой губительной тенденции уже тогда, когда круг экологических проблем ограничивался необоснованной вырубкой рощи? И первыми здесь были «голоса народа» - писатели.
В 20 веке к этой теме обращались Ч.Айтматов, В.Астафьев, В.Распутин. «Прощание с Матерой» - книга о том, что связь с природой глубоко психологическая, а возможно, и нравственная. Образ Родины связан с образом земли. Утрачивая связь с землей, человек теряем самое святое. Повесть В.Распутина «Прощание с Матерой» получила свое продолжение в «Пожаре». Сам писатель сказал об этом на одной из встреч со своими читателями, «на Матеру вернуться нельзя -остров затопило. Очевидно, придется вместе с

жителями деревни, которые мне дороги, перебраться в новый поселок и посмотреть, что стало с ними там…»

Там «возле безобразного хаоса затухающего пожарища» одиноко стоит целехонький, нарядный магазин. Он стал символом разрушенной человеческой нравственности, стяжательства и жестокости

Так потеря “малой родины” оборачивается временным жильем, так проблема экологии превращается в проблему нравственную. О нравственном уроне, который понесла наша жизнь, говорит и “Печальный детектив” В. Астафьева. Почитателям писателя дорог пафос его произведений: любовь к родной земле и родному дому, удивительная одухотворенность природы — леса, трав, рек, рыб. И вдруг — унылая картина бесцветного, бесхозяйственного провинциального Вейска. Серые будни. Улицы, покрытые мусором “окурками, раскисшими коробками, трепыхающимся на ветру целлофаном”. Памятны читателю и герои, созданные воображением писателя (охотники, рыболовы, крестьяне), — люди поразительной душевной чистоты, носители народного идеала традиционного уклада жизни (“Царь-рыба”, “Последний поклон”). И вдруг рядом с ними — милиционер Леонид Сошнин. Это тоже человек, умеющий добротой своей предотвращать зло. Но иногда, по мнению писателя, это добросердечие превращается во всепрощенчество. А оно помогает процветать жестокости и бесчеловечности.

Не может оставить равнодушным читателя произведение Чингиза Айтматова “Плаха”. Автор позволил себе высказаться по самым болевым, злободневным вопросам современности. Это роман-крик, роман, написанный кровью, это отчаянный призыв, обращенный ко всем и к каждому. В центре “Плахи” конфликт человека и пары волков, потерявших своих детенышей по вине человека. По вине людей гибнет естественная природная среда обитания волков. Волчица Акбара после гибели своего выводка встречается с человеком один на один. Она сильна, а человек бездушен, для него прибыль и нажива важнее всего. В “Плахе” волчица и ребенок погибают вместе, и кровь их смешивается, чем доказывается единство всего живого на Земле.

Человечество наивно думает, что оно – царь природы… А между тем, в фильме «Война миров», снятом по книге Герберта Уэлса, марсиан победила не сила человеческого оружия или разума, а бактерии. Те самые бактерии, которых мы не замечаем, которые творят свою маленькую жизнь без нашего ведома и совершенно не собираются спрашивать, хотим мы того или иного…

В свое время большой общественный отклик вызвала повесть Бориса Васильева “Не стреляйте в белых лебедей”. Для лесника Егора Полушкина лебеди, которых он поселил на

Черном озере, — это символ чистого, высокого и прекрасного, символ единения человека с природой

“Не стреляйте в белых лебедей”, — умоляет он.

В древности охотники приходили, вооруженные стрелами, потом стали появляться с бабахающими ружьями. Но пришло время, и “человеко-боги” стали устраивать облавы на машинах, прилетать на вертолетах. Не охотники, а “расстрельщики”, косящие все живое, “как будто сено на огороде”. Писатели утверждают, что человек, способный обидеть “мураша” сдать на живодерню преданного Бима, убить в орешнике “просто так” дятла, расстреливать из карабина с вертолета стаю волков, может убить и человека.

Впрочем, убить человека может и бездушие наших чиновников от экономики, и карьеризм наших ученых, не “ждущих милости от природы”. Литература учит, что жестокость к животным и к природе оборачивается для самого человека серьезной опасностью для его физического и нравственного здоровья. Но если бы все люди Земли задумались о своем будущем, то они смогли бы изменить к лучшему нынешнюю экологическую ситуацию. Все в наших руках!

Литература

1. Распутин В.Г. Прощание с Матёрой. – М. “Молодая гвардия”, - 1980.
2. Егорова Н.В., Золотарёва И.В. Поурочные разработки по русской литературе XX века. 11 класс 2 полугодие, - М.: ВАКО, 2008.
3. Афанасьев В.А. Печальный детектив. Собрание сочинений в пятнадцати томах. Том 9. - Красноярск: Офсет, 1997.
4. Айтматов Ч.Т. Плаха. – М: Азбука-классика, 2004.

## Взаимодействие человека с природой в повести М.М. Пришвина «Жень-Шень»

***Серышева Алиса Дмитриевна, I курс ГАПОУ «НИТ»***
***Постовая Виолетта Витальевна, преподаватель русского языка и литературы***

Михаил Михайлович Пришвин широко известен своими произведениями о природе, рассказами и повестями для детей. Его творчество от начала до конца полно глубокой любви к окружающему миру. В произведениях Михаила Михайловича отчетливо видно как человек неразрывно связан с природой. Автор учит любить и понимать природу, нести ответственность перед ней за ее использование, причем не всегда разумное.

Повесть «Жень-Шень» не стала исключением среди произведений М.М. Пришвина. Основное действие происходит в Манчьжурии. Герой-рассказчик оказывается там, убежав от войны, пытаясь спастись от ее бессмысленности и жестокости. Знакомство с китайцем Лувеном изменяет жизнь охотника. Приютивший его искатель женьшеня впоследствии открывает герою тайну «корня жизни».

Взаимоотношения человека с природой в повести показаны с нескольких сторон. Во-первых, перед нами столкновение «человека цивилизации» с «человеком естественным». Во-вторых, взаимоотношения человека и природы показаны буквально через отношения охотника с природой, и в частности, с самкой пятнистого оленя, Хуа-лу.

Рассмотрим подробнее. Главный герой, «человек цивилизации» пытается найти убежище в мире природы. При этом он является носителем европейской культуры.  Он сам себя именует «обученным европейцем» и видит в этом некое превосходство над местными жителями: «В смысле истинной человеческой культуры я угадывал в нем старшего и относился к нему почтительно. Он, вероятно, видел во мне светлого европейца и относился ко мне с тем радостным удивлением и теплой дружбой, как относятся многие китайцы к европейцам, если только бывают уверены, что европейцы не хотят их насиловать и обманывать»[3]. Так пришвинский герой определяет свои взаимоотношения со стариком Лувеном, «естественным человеком», являющимся в произведении и представителем китайской культуры. В образе Лувена автор соединяет все свои представления о специфике восточного образа жизни.

Многие востоковеды в качестве объединяющего фактора различных азиатских цивилизаций в единый тип выдвигают их неподвижность, устойчивость, традиционализм. С. П. Мамонтов отмечает: «Для восточного человека, в отличие от европейца, характерны: большая интроверсия, т. е. сосредоточенность на самом себе и собственной внутренней жизни; меньшая склонность к восприятию противоположностей, которые нередко отрицаются; большая вера в совершенство и гармонию окружающей Вселенной, а отсюда и ориентация не на её преобразование, а на приспособление к некоему «космическому ритму» [1, с. 167]. Нужно отметить, что именно этим качествам соответствует жизненное кредо Лувена.

Как естественный человек Лувен относится ко всему живому с родственным вниманием. Ему, в отличие от рассказчика, не нужно вырабатывать понимание жизни.

Первая встреча главного героя с природой в лице Хуа-лу дала толчок к изменениям в душе «человека цивилизации»: «Я как охотник был себе самому хорошо известен, – признается герой, – но никогда я не думал, не знал, что есть во мне какой-то другой человек, что красота, или что еще там еще, может меня, охотника, связать самого, как оленя, по рукам

и ногам. Во мне боролись два человека. Один говорил: "Упустишь мгновение, никогда оно к тебе не возвратится, и ты вечно будешь о нем тосковать. Скорей же хватай, держи, и у тебя будет самка Хуа-лу, самого красивого в мире животного". Другой голос говорил: "Сиди смирно! Прекрасное мгновение можно сохранить, лишь не прикасаясь к нему руками»[3].

В Хуа-лу героя поражают глаза, которые охотник представляет то в качестве женских, то на стебельке, как цветок. Тогда герою становится понятным и прозвище «олень-цветок».

Дальнейшие отношения охотника с Лувеном и природой исцеляют героя, ему удается приручить природу. Китаец-врачеватель, являющийся и искателем корня жизни, углубляет знакомство охотника с природой, приближает его к ней. Своим примером Лувен учит искать корень жизни «с чистой совестью и никогда не оглядываться назад, в ту сторону, где все уже измято и растоптано. А если чистая совесть есть, то никакой завал не испортит пути»[3]. Лувен не только показывает герою священный корень женьшеня, не просто направляет охотника, говоря, что «его корень жизни еще не вырос», но и открывает герою тайну этого корня.

Являясь абсолютно разными людьми с разным мировоззрением, Лувен и охотник сумели обрести себя в ежедневном труде и любви к первозданной природе. Несмотря на то, что первая встреча с Хуа-Лу всю дальнейшую жизнь оставалась в мыслях рассказчика, и даже через 10 лет он жалел о том, что не поймал ее, увидев впервые, герою всё-таки открылось истинное понимание корня жизни: «Мало-помалу, углубляясь с другом в пережитое, вы постепенно и бессознательно начинаете как будто кому-то прощать, становится очень легко на душе, и наконец происходит желанная встреча: под напором возвращенной радости жизни оба друга для себя становятся такими же молодыми, как были. Я так понимаю действие корня жизни Жень-шень. Но бывает напряжение корневой силы жизни так велико, что вы любимого человека, раз навсегда утраченного, находите в другом и начинаете нового любить, как утраченного»[3].

Таким образом, Михаил Михайлович Пришвин своим произведением учит не только видеть и слышать природу, но и глубоко вслушиваться и всматриваться в нее, ценить, тонко её чувствовать.

Список литературы

1. Мамонтов, С. П. Типы культурных общностей в пространстве [Текст] / С. П. Мамонтов // Основы культурологии. – М.: Олимп, ИНФРА-М, 2001.

2. Меркульева Н.А. «Священная прямая» Михаила Пришвина [Текст] / Н.А. Меркульева // Вестник КемГУКИ, 2015. - №32. – С. 90-96.

3. Пришвин М.М. Жень-шень [Электронный ресурс] – Режим доступа: http://profilib.com/chtenie/48278/mikhail-prishvin-zhen-shen.php, свободный. (Дата обращения: 1.02.17г.).

4. Трубицына, Н.А. Культурный неомиф Михаила Пришвина (на материале повести «Жень-Шень») [Текст] / Н.А. Трубицына // ФИЛОLOGOS. - Елец: ЕГУ им. И. А. Бунина, 2011. – Выпуск 9. – С. 78-90.

## Противостояние двух стихий: человека и природы в повести Эрнеста Хемингуэя «Старик и море»

***Сумбаева В.В***
***Гарипова Г.А.***
***4 курс, ГАПОУ «Арский педагогический колледж им.Г.Тукая»***

Незыблемая тема «Взаимодействие природы и человека» нашла и продолжает находить свои отклики в творчествах многих писателей XX-XXI вв. Одной из самой эпохальной стала повесть выдающегося американского писателя Эрнеста Хемингуэя «Старик и море».

По сути, что это за повесть. Эта история про старика Сантьяго и его борьбу с огромной рыбой. 84 дня старый кубинский рыбак Сантьяго выходит в море и не может ничего поймать, поэтому его начинают считать, самым что ни на есть невезучим. И только его маленький друг Манолин продолжает ему помогать, хотя отец запрещает ему рыбачить со старым Сантьяго и велит ходить в море с удачливыми рыбаками. Мальчик часто навещает старика в его хижине, помогает относить снасти, готовить еду, они часто разговаривают об американском бейсболе и их любимом игроке Джо Ди Маджио. Сантьяго говорит Манолину, что на следующий день он выйдет подальше в Гольфстрим, к северу от Кубы во Флоридский пролив, уверенный, что его полосе невезения должен наступить конец.

Однако не всё так просто. В литературоведении жанр этого произведения определяется как новелла. Новелла – это повествовательный прозаический жанр, для которого характерны краткость, острый сюжет, нейтральный стиль изложения, отсутствие психологизма, неожиданная развязка. Давайте проследим, присущи ли эти признаки рассматриваемому произведению.

<u>Краткость</u>. Минимализм во всём: ограниченность художественного пространства (море), персонажей-героев (старик), времени, художественных средств. И при этом выразительность пронзительная, глубина необыкновенная. Человек – венец природы, лучшее её творение. Даже несмотря на его возраст и то, что он один. Рыба царственна, великолепна, вызывает восхищение своими размерами и формами. Борьба, на основе которой построен

художественный мир рассказа-новеллы, не вызывает отторжения у читателя. Она захватывает, держит в напряжении. Краткость писателя компенсируется художественной и философской ёмкостью, подводным течением повествования.

Нейтральный стиль изложения. В произведение повествование ведется от лица автора. В книге американского классика нет захватывающего развития событий. В произведении почти отсутствует динамика, зато оно насыщено внутренним драматизмом. Кому-то может показаться, что повествование Хемингуэя скучное, но это совсем не так. Если бы писатель не уделял столько внимания деталям и так подробно не расписывал мучения старика в море, то читатель не смог бы в полной мере почувствовать страдания моряка собственным нутром. Другими словами, если бы не было этой «вязкости и клейкости» текста, то «Старик и море» не было таким проникновенным сочинением.

Отсутствие психологизма. В повести практически нет размышлений старика, потому что главное – событие. В новелле как бы таится внутренний психологизм, который передается каждому читателю, который внимательно читает и вникает во все детали.

Неожиданная развязка. Авторская развязка, также на наш взгляд неожиданна. Вполне логичные развязки могли бы иметь такой вид. Во-первых, вроде бы полосе неудач должен прийти долгожданный конец. счастливый рыбак с огромным уловом должен был бы причалить в берегу и доказать всем, что «есть еще порох в пороховницах». Во-вторых, мы предполагаем, а Бог располагает – к сожалению, полоса неудач затянулась, и старику вновь не везло, несмотря на интуицию и предчувствие, и 85 день в море ничем не отличался бы от предыдущих 84. В-третьих, море могло бы уничтожить Старика, и рыбак нашел бы последний приют в своей родной обители. Но мастер Хемингуэй не так прост в своем повествовании. Главная задача автора быть на волне двух стихий: с одной стороны, он любуется человеком, который всё может, всё ему подвластно, он приручил природу, научился ее понимать и чувствовать. С другой стороны, писатель как бы и на стороне природы – вот она неразгаданная стихия, мощная, непредсказуемая, таинственная и завораживающая. Отправляя своего Старика вновь в Море, Хемингуэй создает своего рода определенное спортивное соревнование двух достойных соперников. Хотя Старик стар и слаб уже, а Море вечно остается молодым и сильным. Борьба, описанная автором, завораживает своей точностью, подробностью: мы чувствуем вкус соленой воды Моря и пота, усталость рыбака, тяжесть рыбы, натянутость лески, радость от предвкушения улова, разочарование от акульей погони и т.д. В этой схватке не проигрывает ни один, все честно, ничья: Природа позволила поймать самую большую в истории рыбацкой жизни Старика рыбу, но сохранить ее не разрешила, потому что Море сильный соперник и так просто не сдается. Старик, несмотря на свою уже немощность, оказался способным перехитрить

большую рыбу, которая во что бы ни стало хотела сорваться, и доказать всем, что теперь удача на его стороне и что он еще чего-то может.

Борьба двух стихий, Человека и Природы, нашла в рассказе свой неожиданный, но логический ответ: они могут сосуществовать вместе, но всегда это будет борьба – честная и настоящая.

## Роберт Миңнуллин шигъриятендә табигать

***Фатыйхова Илзия Илшат кызы***
***КФУның Алабуга институты студенты.***
***Фәнни җитәкче:Габидуллина Фәридә Имаметдин кызы,***
***ф.ф.к. , КФУның Алабуга институты доценты.***

Әйләнә-тирәдәге кояш, җир, урманнар һәм сулар, кошлар һәм хайваннар, чәчәкләр һәм куаклар – безнең өчен болар барысы да табигать. Табигать кеше өчен генә тугел, һәрбер җан иясе өчен изге һәм якын җир. Төгәлрәк итеп әйткәндә ул безнең йортыбыз, ягъни яшәү урыныбыз. Шуңа күрә дә ул һәрвакыт тәртиптә булырга тиеш. Урман-сулар чиста, кошлар һәм хайваннар сәламәт булырга тиеш дигән сүз бу. Димәк, һәр кешегә дә табигатьне сакларга һәм якларга кирәк.

Халыкара Андерсен бүләге иясе, Алиш, Җәлил, Тукай премияләре лауреаты, Татарстанның һәм Башкортстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, балалар шагыйре Роберт Миңнуллинның иҗатында да табигатьне саклау, аның кеше белән мөнәсәбәте, бигрәк тә балаларда кечекенәдән үк табигатькә карата ярату һәм хөрмәт хисләре тәрбияләү зур урын алып тора. Ул үзенең тормышчан, уен- көлкеле шигырьләре белән укучы күңеленә тагын да якыная. Шагыйрьнең Сөн буенда туып-үсүе аның иҗатына зур йогынты ясый һәм киләчәктә табигать турындагы шигырьләре тууга зур юл ача. Аның поэзиясе тын гына,үз җаена агып ятучы, чирәм түшәлгән яр буйлары булган Сөн буеның гүзәллегеннән башланып китә. “Туган илем, газиз җирем!” шигырендә түбәндәге юллар бар:

Кошлардагы туган җирне сөю
Һәм сагыну миңа, аһ, таныш.
Мин Сөн кошы! Ике канатымның
Берсе- Илеш, берсе- Актаныш!
И Актаныш! Күпме җырларымны
Талларыңа кунып сайрадым.
Туган җирне сайлап алмыйлар да,

Сине мен үзем сайладым[6].

Күрәсең, шагыйрьнең күңелендә сабый чагыннан ук туган җиренә тирән мәхәббәт хисләре бөреләнә башлый, табигатенең һәрбер байлыгы белән горурлану һәм аларны чын йөрәгеннән саклау изге бурычына әверелә. Чөнки шагыйрь туган җиренең табигый хәзинәләренә, туган җире тудырган гүзәл әсәрләргә табынып үсә. Һәр кеше өчен дә туган төбәге якын булырга тиеш.  Андагы куак, чәчәк, урман-кырлар, сулар һәм хайваннар яшәеше өчен кайгыру һәм аларны сакларга омтылу –  һәрберебезнең дә бурычы. Туган җир безне тудырган, үстергән, тәрбияләгән икән, без дә аның алдында бурычлы түгел мени [4, с. 6]?!

Роберт Миңнуллинның табигать, туган җир тематикасына язылган һәрбер шигырендә дә табигатьне ярату, кайда булуына да карамастан аны сагыну, һәрбер байлыгына игътибар белән карау күзәтелә. Мәсәлән, аның “Исәнмесез“ шигырендә дә бу тематика ачык сизелэ:

Исәнмесез, җилләр, туган җирләр!

Кайтып килә сезнең улыгыз.

Һәммәгез дә, шөкер, исән икән,

Моннан соң да исән булыгыз[5, с. 13].

Шигырьдәге һәрбер юл туган җирнең табигатенә карата хөрмәт хисләре белән сугарылган, аның төзек булуына шатлану исә укучыда тагын да көчлерәк тойгылар уята. Нәкъ менә шагыйрьнең табигать белән кеше арасындагы мөнәсәбәтләр турында язылган шигырьләре укучыда да табигатьне ярату, зурлау, аның байлыклары белән горурланып калу кына тугел, ә аларны саклауда да үз өлешеңне кертүгә яңа мөмкинлекләр ача. Туган як табигате кешенең күңелен иркәли, яшәргә шартлар тудыра, кешене рухи яктан баета, тирә-яктагы матурлыкны күреп, эстетик ләззәт алуга этәргеч бирә. Шулай ук аның “Көзләр белән бергә”, “Күңелләр нечкәргәндә”, “Җәй хатирәсе” шигырьләрендә дә табигать тематикасы бик отышлы күтәрелә[3, с. 257]. Ул җиңел аңлаешлы тел белән язылган, шул ук вакытта тормышчан шигырьләре белән укучыга тагын да якыная.

Димәк, Роберт Миңнуллин иҗатында табигатькә, аның байлыкларына багышлап язылган шигырьләр бик күп. Алар һәрберсе үзгә бер ягы белән аерылып тора: кайбер шигырьләрендә ул бик оста итеп җанландырулар  куллана, мәсәлән “Шундый минем туган ягым” шигырендә “ак чәчәкләр чыңлап тора”, “ак каеннар төшеп китә Сөн буена”, “ ак чәчәкләр җырлап тора” кебекләрне, ә башкаларында исә табигатькә сокланырга чакырга[2, с. 195]. Мисал булып “ Кайтыйк ла үзебезгә!” шигыре тора. Әйе, Роберт Миңнуллин шигъриятте үз буразнасына тугрылыклы булып яши[1, с. 390]. Үзенең эчтәлекле шигырьләре белән укучының күңеленә үтеп керергә сәләтле.

Бүгенге көндә табигать, аны саклау һәм яклау турында уйламасак, нәтиҗәләр бик аянычлы булачак. Шуңа күрә балалар күңелендә кечкенәдән үк табигатькә карата мәхәббәт

хисләре уятырга, әйләнә-тирәдәге һәрнәрсәгә соклану һәм хөрмәт белән карарга, бүген генә тугел, ә киләчәктә дә табигать байлыкларын сакларга өндәргә кирәк. Яшь һәм өлкән буыннар берләшкәндә генә табигатьне саклау юнәлешендә башкарылган эшләр үз уңышларын китерерләр.

Әдәбият.


1. Әдәбият (XX йөзнең 30-90 нчы елларында әдәбият): татар телендә урта гомуми белем бирү мәкт. 11 нче с-фы өчен д-лек / [А. Г. Әхмәдуллин һ.б. ; А. Г. Әхмәдуллин ред.]. – Төзәт. 4 нче басма. – Казан : Татар. кит. нәшр, 2011. – 399 б.

2. Миңнуллин Р. Айның татлы яктысы. – Казан: “Рухият” нәшрияты, 2001. – 384 б.

3. Миңнуллин Р. Сайланма әсәрләр: Лирик шигырьләр, тәрҗемәләр, иҗат портретлары, мәкаләләр: IV китап. – Казан: Мәгариф. 2004. – 511 б.

4. Миңнуллин Р. Шагыйрь генә булып калалмадым... Казан: “Матбугат йорты” нәшрияты. – 1998. – 416 б.

5. Миңнуллин Р. Дорога Уфа-Казань (на татарском языке). – Казан: Татар. кит. нәшр, 1998. – 298 б.

6. www.kitap.net.ru


## Без тумыштан туган телгә гашыйк, җиргә гашыйк күптәннән


***Хәсәнов Д.Р.. II курс, МЕХ-151б төркеме;***
***Хайруллина З.В., Камалова З.Ә. татар телчеләре***


Татар теле... Тугач та иң газиз кешеңнән ишетә башлаган, күп гасырлык тарихы булган, Каюм Насыйрилар, Тукайлар нигез салган, Җәлилләр дәвам иткән, 7 миллион халык сөйләшкән, дөньядагы иң дәрәҗәле 14 тел исәбенә кергән, чит илләрдә дә өйрәнелә торган, бүгенге көндә җитлеккән, камилләшкән, теләсә нинди катлаулы фәнне өйрәтергә мөмкинлеге булган, Моабитның таш диварлары эчендә дә тынмыйча, аның калын стеналарын тишеп чыгып, бөтен дөньяга яңгыраган, утларга- суларга салсалар да, чукындырсалар да, ассалар-киссәләр дә исән калган, иң-иң авыр кимсетүчеләргә дә түзгән, сынмаган- сыгылмаган, баш имәгән горур татар теле!

Туган тел - Ватан, туган җир, ата-ана сүзләре белән белән бер үк дәрәҗәдә торучы бөек, изге һәм кадерле сүз, аңарга тирән мәгънә салынган. Туган телем татар теле дип әйтү белән дә син үзеңне мең еллык тарихы булган бөек халык вәкиле булуыңны дәлиллисең.

Хәзерге вакытта җир шарында 5500 тел бар дип исәпләнелә. ЮНЕСКО билгеләве буенча, шулар арасына кергән 14 телдә (гарәп, рус, немеө, инглиз, француз, итальян, испан, португал, кытай, япон, татар, урду, бенгал, һинд) дөнья халкының 70 проценты сөйләшә.

Тел ярдәмендә шәһәрләр төзелә, халыкларның культурасы үсә. Тел ярдәмендә кешеләр бер-берсе белән аңлашалар, шатлык-сөенечләрен уртаклашалар, сөю-мәхәббәт хисләрен белдерәләр. Менә шуңа күрә дә дөньяда телдән дә яхшы бер нәрсә дә юк!

Әгәр тарихка мөрәҗагать итсәк, шундый кызыклы гына фактларга тап булабыз. 16-17 гасыларда татар теле Россиядә рус теле белән беррәттән халыкара әһәмияткә ия булган.Безнең гасырларга кадәр үк дөнҗя картасында Тартария дигән ил калын хәрефләр белән күрсәтелгән булган.

Татар теле үзенең үсеш дәверендә төрле кыенлыкларны, киртәләрне үтте. Халык күпме изелсә дә, ана телен саклап калды. Ә милләтнең саклануы турыдан –туры телгә бәйле. Чөнки гыйлем алу, аңны үстерү, дөньяны танып белү һәм аралашу туган тел аша тормышка ашырыла. Әгәр милләтнең теле кулланылмый башласа, ул юкка чыга. Аның өчен сугыш та, кан кою да кирәкми. Телен бетерден исә, үз халкыңның әдәбияты да, мәдәнияте дә, гореф-гадәтләре дә юкка чыга. Тел өчен көрәш – милләт өчен көрәш ул. Бары син  яшәсән  генә татар милләте яшәр, дөнъя – галәм гүзәллерәк күренер.

Мисалга бөек әдип Тукай, батыр Җәлилне генә алыйк.  Алар бит үз милләтен ихластан яраткан, татар булулары белән горурланган. Телне  әлеге шәхесләр  тышкы ямь бирү чарасы, матур сүзләр җыелмасы итеп кенә карамаган, аны иң элек аралашу, “туган тел”, “әткәм-әнкәмнең теле” дип атаган.Татар теленең бөтен тирәнлеген белеп,иҗатлары белән сугарып аны янә бер кат бөеклеккә күтәргәннәр.

Күп гасырларны узган татар теленең  бүгенге хәле ничек соң? Без , бүгенге яшь буын үзебезгә тапшырылган бу хәзинәне ничек саклыйбыз, гомумән саклыйбызмы яки бозабызмы?

Безнең татар яшьләре арасында үз телен белмәгәннәре биниһая күп. Бәлки, үз телебезне белмәгәнгә чит телләрне тиз өйрәнә алмыйбыздыр? Бу җәһәттән Каюм Насыйри йөз тапкыр хаклы: “Кеше... үзенең телен кагыйдәсез дә белер һәи һич тә ялгыш әйтмәс һәм хата сөйләмәс. Ләкин башка телне телгә төшенә алмас, тик бик озак вакытлардан соң гына аңа күнегә алыр”.

Һәр халыкның туган теле- аның мәдәнияте, тарихы көзгесе. Шуңа да телебез сафлыгы, матурлыгы, әһәңлелеге өчен барыбызга да армый-талмый көрәшергә кирәк.

Составында йөз меңләгән сүзләре булган телебезгә әкренләп югалу, бетү, өй теленә генә әверелеп калу куркынычы яный башлады. Бу хәл милли горурлыгы булган бер генә

кешене дә битараф калдырырга тиеш түгел.Татарча аралашудан оялу- үзеңнән йөз чөерү, ваз кичү ул.

Туган тел акыл үсешенең нигезе һәм белем хәзинәсе ул. Туган телне үзләштергәндә бала сүзләренә генә түгел, ә хисапсыз күп төшенчәләрне, күп фикерләрне, тойгыларны, телнең логикасын, филологиясен дә үзләштерә. Менә шундый ул халык педагогы- бөек туган тел!

Югары культуралы булуга туган телеңне яхшы белү дә кирә. Үз халкына ана телендә хезмәт күрсәтә алырлык хәзерлеге булмаган кешене, ул нинди генә дәрәҗәле эштә эшләмәсен, һич тә югары культуралы кеше дип әйтеп булмый.

Соңгы вакытта милли телләргә, шул исәптән татар теленә дә игътибар арту, аңа йөз белән борылу-бик күпләрне куандырырлык вакыйга. Республикадан читтә яшәүче кардәшләребезнең активлашуы, хәтта Америкада, Австралиядә, Финляндиядә гомер итүче милләттәшләребезнең туган телдә аралашуга, татар халкының гореф-гадәтен, сәнгатен, җырларын күңелгәсеңдерергә ашкынып, сагынып, күрешергә килүләре бик үрнәк алырдай, гыйбрәтле мисал.Америкада туып –үскән егет үз туган телен белә, Әлмәт егете исә ике сүзне ялгый алмый.Татар телендә белем алу яшь кешнең киләчәгенә аяк чала дигән сүз белән дә килешмим. Бер тел урына ике,яки өч тел белү киресенчә, бик яхшы.

Татар теленә дәүләт теле буларак игътибар арту да күңелләрне сөендерә. Әлеге үзгәрешләр Әлмәт муниципаль районында да сизелә. Күптән түгел генә урам исемнәре язылган алтакталар алмаштырылды, җирле телевидениядән татарча тапшыруларның вакыты озынайтылды, даими рәвештә төрле чаралар уздырыла.

Дәүләте булган халыкның гына киләчәге бар. Татарны яклаучы дәүләт Татарстан булырга тиеш. Төп максат- Татарстан чәчәк атсын, ныгысын, мөстәкыйль булсын. Шундый дәүләт барлыкка килсә генә дөньяның теләсә кайсыягында яшәүче татарларга җиңеллек булыр. Безгә төп йортыбызның хуҗалары булырга, үзебез эшләп тапкан байлыклардан үзебез файдаларга, бер йордыкка тупланып яшәргә кирәк.

Без татар яшьләрнең бурычы - халкыбызда милли аң, милли горурлык уяту, телебезне саклап калу.

Җыр булырлык сүзләр биргән

Матур телем, туган телем,
Рәхмәт сиңа! Туган телем – киңдер
Сиңа күңелем түрем.
Халыкларга хөрлек биргән Туган илем
Сине җырлап, итәгеңә башым идем.
Җырла диеп бирде миңа туган илем

Туган телен,Такташ телен, Җәлил телен.

*Кулланылган әдәбият*

7. Фәхретдинов Р.Г. Татар тарихы /Р.Г.Фәхретдинов. – Казан: Мәгариф, 1999. – 111 б.

8. Ибраимов М., Ахметзянов Г., Ибраһимов Г. Иске тел // Казан утлары. – 1978. – № 3. Советмәктәбе №5, 1977ел

## Кеше белән табигать арасындагы мөнәсәбәт.

***Хәмзин Рәфис Ришат улы***
***“Алексеевский аграр көллиятенен” Яңа Чишмәдәге***
***2 нче номерлы филиалының 2 нче курс укучысы,***
***Сөләйманова Нурзия Нуртдин кызы җитәкчесе;***

Мин сезгә Ф.Зиятдинованың бер шигырен укып китәм.

Җиргә килгән… Кем китергән аны?
Берни дә юк үзенең исендә…
Нәрсә эзли, нәрсә югалткан ул?
Нәрсә кирәк Җирдә кешегә?
Тигез җирдә таулар өеп куя,
Елгаларны бора кирегә.
Ник кирәген белми, үзе төзи,
Төзегәнен тагын җимерә…
Бәргәләнә ике ут эчендә,
Яхшы белән Яман бутала…
Ахырзаман галәмәте микән —
Бар дөньяны, әнә, ут ала.
Илләр генә түгел, ут эчендә
Дөрләп яна кеше җаннары.
Җирне чолгап алган ут-ялкыннан
Бер адәм дә читтә калмады.
Ниятләре изге булгандыр да…
Ниләр киртә куйган Кешегә?
Каян килгән, нәрсә эзли Җирдә —

Берни дә юк үзенең исендә…

(Бу шигырьдә кешеләрнең табигатьне үзгәртүләре нәтиҗәсендә килеп чыккан аянычлы хәлләр тасвирлана.)

Бүгенге көндә кешенең Табигать биргән байлыкларны дөрес кулланмавы нәтиҗәсендә Җир-ана, табигать куркыныч астында. Мондый халәтне дөньякүләм экология кризисы дип атыйлар.

Кеше, җәмгыять, табигать үзара бик тыгыз бәйләнгән. Башта бары тик табигый дөнья гына булган, соңрак аннан кеше аерылып чыккан, һәм күп вакытлардан соң ул, үзе ишеләр белән бергәләп, җәмгыять төзегән.

Җир планетасында кешеләрнең яшәп китү тарихын карасак, аларның хуҗалык эшчәнлеге табигатькә ничек тәэсир иткәнен, бу тәэсирнең үсә барганын һәм нинди нәтиҗәләргә китергәнен күрәбез. Тарихның башлангыч этапларында хуҗалык итү та¬бигать байлыкларын үзләштерүдән гыйбарәт була. Кеше бу чорда табигатькә җайлаша, аңа житди зыян салмый.

Без кечкенәдән үк шигырьләр, хикәяләр тыңлыйбыз. Укыганнарыбыз табигать дөньясы, тормыш, кешеләр, без белмәгән кызыклы хәлләр, вакыйгалар белән таныштыра. Безне куандыра, шатландыра, тормышны яратырга өйрәтә. Язучы дигән бөек исемне һәрбер кеше дә йөртә алмый. Минемчә, аның өчен табигать биргән зур илаһи көч, сабырлык, зирәклек һәм акыл тирәнлеге, өмет, ышаныч, ныклы иман һәм үз иманыңа тугрылык кирәк. Язучының иҗатын җаның-тәнең белән тоеп, аңлап укысаң, әсәреп китәсең. Гомумән, язучыларның әсәрләре кешене дулкынландыра да, шатландыра, куандыра да һәм зур киңлекләргә очыра. Язучы булган кеше хисчән, мәрхәмәтле, искиткеч матур күңелле һәм уйчан буладыр.Язучыларның төп бурычлары − яхшылыкны исбат итеп, яманлыкны инкарь итеп, дөньяның матурлыгын җырлау.

Тематика һәм проблематика буенча да, сәнгатьлелек ягын¬нан да М.Җәлил шигърияте күптармаклы һәм бай. Язучы аерым бер тема яки тормыш материалы, бер характер¬дагы геройлар белән генә эш йөртми. Монда аның иҗат прин¬циплары торган саен ачыклана. М. Җәлилнең туган як табигате, аны саклау, кош-корткa һәм хайваннарга мәхәббәт темалары да чор рухы һәм патриотизм белән үрелеп китә. Язучынын иҗатында Йолдыз, Корыч, Сандугач, Чишмә, Чәчәк образлары белән еш очрашырга мөмкин. Шигърияттендә ул шулай ук чагыштыру, гипербола, эпитет, һәм күчерелмә мәгънәдәге сүзләргә дә еш мөрәҗәгать итә, тәрбия бирүнең яңа кызыклы формаларын табарга омтыла.

Табигать – безнең туган йортыбыз. Аны яратырга һәм сакларга кирәк. Табигатьтә бөтен нәрсә үзара бәйләнгән. Әгәр дә без урманнарны һәм табигатьне пычратсак, андагы кош-кортлар барсы да үлеп яки качып бетәрләр. Аларсыз табигатьне күз алдыгызга китерегез

әле: бөтен агачлар корыган, чәчәкләр сулган, кошлар сайрамый. Ошармы инде бу безгә, әлбәттә, юк. Кешенең саксызлыгы аркасында республикабызның "Кызыл китабы” калыная бара. Димәк, күпме үсемлек, кош-корт, хайван, бөҗәкләр юкка чыга бара дигән сүз. Мондый хәлгә калмас өчен, безгә табигатьне сакларга кирәк.

Кайчан гына урманга барсак та, теләсә кайда чүп-чар аунап ята, агач ботаклары сынып беткән күренешләргә тап булабыз. Беркемнең дә ял итәргә килгәч, андый пычрак урынны сайлыйсы килмәс бит. Кемнәр шулай табигатьне авыр хәлдә калдыра икән? Мондый кешеләрнең табигатькә карата битарафлылыгы шуннан күренә дә инде. Экологик хәл көннән көн кискенләшә. Шулар турында уйлангач, минем күңелемдә шигырь туа:

«Табигать- туган йортыбыз» дип
Юкка гына әйтмиләрдер.
Кайберәүләр бу сүзләрне
Бөтенләй белмиләрдер.
Бу сүзләрне белмәс бары,
Итагатьсез кешеләр.
"Табигатьсез нишләрбез?” дип
Уйламаучы кешеләр.
Табигатьсез кош-кортлар да
Булмаслар бу дөньяда.
Табигатьсез матур кошлар
Сайрамаслар болында.
Кемнең генә яшисе килер
Табигать булмаса әгәр дә.
Сагынырлар табигатьне
Намуссыз кешеләр дә.
Үкенер алар, табигатьне
Сакламаганы өчен.
Көрәшә башларлар алар
Куеп барлык көчен.
Ләкин инде соң булыр,
Табигать булмас инде.
Мондый начар хәлләрне
Күрәсегез килерме?
Уйланыгыз, кешеләр,
Табигатьсез нишләрсез.

Табигатьне яратмаган
Нинди кешеләр соң сез?
Ничек саклыйк табигатьне –
Утыртыйк күп урманнар.
Елга-суларны чистартыйк,
Исән калыр балыклар.
Гөлчәчәкләрне өзмик без,
Агачларны сындырмыйк,
Кош һәм урман җәнлекләрен
Беркайчан кыерсытмыйк.
Шул чагында табигать
Юмарт булыр безгә дә.
Җиләк-җимеш, гөмбәләрен
Бирер ул һәркемгә дә.

Озакламый җәй җитәр, кешеләр, ял итәргә табигать кочагына чыгарлар. Минем барлык кешеләргә дә табигатьтә булганда, кайбер кагыйдәләрне истә тотарга кирәклеге турында искәртеп китәсем килә: урманда беркайчан да, учак ягарга дип, агачларны сындырмагыз; учакны сүндермичә кайтып китәргә ашыкмагыз; ял иткән җирегезне чүп-чардан арындырыгыз. Менә боларны барыбыз да истә тотсак табигать беркайчан да пычранмас һәм матур булыр, безгә үпкәләмәс. Кешеләр, "Зинһар!” дип әйтәм, табигатьне саклагыз! Табигать безнең туган йортыбыз икәнен беркайчан да онытмагыз!

Кулланылган әдәбият:

1. Әхмәдуллин А.Г., Ганиева Ф.Ә. Унберьеллык урта мәктәпнең 8нче сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия.- Казан: Мәгариф,1993
2. Ганиева Ф.Ә., Гыйләҗев И.Г., Ф.Ф. Исламов. Татар урта гомуми белем мәкт. 6нчы сыйныф өчен дәреслек-хрестоматия
3. Даутов Р., Нуруллина Н. Совет Татарстаны язучылары: библиографик белешмә.- Казан: Татар. Кит.нәшр.,1986
4. Мустафин Р. Муса Джалиль- детский поэт// Детская литература.-1983

## Ркаил Зәйдулла иҗатында табигать һәм тарих

***Хөсәинова Алия Рәфид кызы, III курс***
***Җитәкче – фил.фән.канд. Минһаҗева Р.Ә.***

Ркаил Зәйдулла – язучылар Н. Фәттах, М. Хәбибуллин, В. Имамов, Ф. Бәйрәмова, З. Зәйнуллин кебек, төркиләр тарихын үзлегеннән өйрәнеп, тарихи темаларга кыю мөрәҗәгать итүче, каләменең барлык жанрларында да тарихка дикъкать итүче әдипләрдән.

Аның 2006 нчы елны «Мәйдан» журналында басылып чыккан «Ашина» драмасы нигезендә ата-бабаларыбыз күз карасыдай саклаган югары әхлак сыйфатларыбызның җуела баруына әрнү һәм гасырлар буе кадерләп тоткан җирләребезнең су төбендә калу ачысыннан туган сагыш хисе ята.

Табигать сагында торучы хайван, кош-кортның, басу-кырларыбызның, гомумән, әйләнә-тирә табигатьнең кадерен белмәгәннәр үз-үзен һәлакәткә дучар итә. Бүгенге заманда халыкның вәхшиләнүе, кыргый хисләрне, явызлыкны алга сөрүе дә табигатьне танымыйча, каланың таш диварлары арасына кереп качудан килә. Автор фикеренчә, хәзерге инсанның фаҗигасе – үзен табигать көчләреннән югары куеп, аннан ераклашу, табигый кануннары белән исәпләшмәү, аны санга сукмауда.

Әсәрдәге вакыйгалар Түбән Кама сусаклагычы төзелеше барышында елганы диңгез өсте тигезлегеннән 68 метр биеклеккә күтәртеп, аның буенда урнашкан җирләрнең су астында калуы белән бергә, 1960-1980 елларда республикабызның йөзләгән авылларының юкка чыгу һәлакәтен бәян итә. Куйбышев, Түбән Кама сусаклагычлары сафка басканда, Кама Тамагы, Актаныш, Минзәлә, Әгерҗе, Башкортстан һәм Удмуртиянең күпме гүзәл татар авыллары таркатылды, күпме туган нигезләр су астында калды, аның белән бергә милләт тә саегайды.

Автор, Чулман төбәгендә яшәп, авыллары су астында калырга тәкъдир ителгәннәрнең тирән хәсрәтле кичерешләрен сурәтли: «Ибраһим. Хе-хе, дөрес әйтәсең, карчык. Үләргә хәтта түшәгем дә юк. Өем дә юк, илем дә юк. Хәер, анда менгәндә берни дә кирәкми» [1, 108 б.].

Йорт-җирләрен туздырып, туган илен калдырып, иң мөһиме – берничә буын ата-бабалары күмелгән каберләрне дә җир белән тигезләү – ул тарихыбызны җую, милләтебезне эзсез югалтуга тиң.

Әсәрдә хәлләр бик аянычлы тәмамлана. Совет системасында өстән боерык белән яшәргә күнеккән Сәхәү, Сабах, Хәмдүнә, милиционер, хәтта Римма, Ибраһимнар, чапкан печән кибәннәрен калдырырга куркып, эш урыныннан китүне дезертирлыкка санап, машина көтеп, мәңгелеккә су астында калалар. Бары тик Мирза исемле бала гына исән кала.

Сабах. «Аңга килеп торып карасам, этме, бүреме шунда, аксый-аксый Мирзаны теге ярга сөйрәп менә иде...

Ибраһим. Ашина! Коткарган ул аны!» [1, 111 б.].

Иң ахырда, ятим калган Мирзаның милләтебезгә булган мөрәҗәгатен ишетәбез. «Ау-у! Ай-у! Бабай, бабакай! Әби! Сез кайда, ау?! (залга.) Монда татарлар бар иде, кайда алар» Су тавышы... [1, 111 б.].

Билгеле булганча, легендаларда, риваятьләрдә төркиләр нәселенең башлангычы Ак бүрегә барып тоташа дип, бездә бүре аерата хөрмәт ителгән. Татар кешесе өчен бүре – изге җан иясе, горурлык, ныклык билгесе. Шул рәвешле, бүрегә бәйләнешле мотив-сюжетлар төрки әдәбият әсәрләрендә калку чагылыш такан.

Р.Зәйдулланың «Ашина» драмасының исеме дә, күрүебезчә, бүрегә килеп тоташа. Төп каһарман Ибраһим үзенең оныгы, 10-12 яшьләрдәге Мирзага бер риваятьне сөйли. Аның үзенә бу хакта Нугайбәк бабасы хикәяләп калдырган: «Бик борынгы заманда булган хәл... әллә мең ел элек, әллә ике мең... «...» Борын-борын заманда безнең халык зур тау тирәсендә яшәгән. Бервакыт аларның иленә дошман бәреп кергән дә олысын-кечесен кырып чыккан. Бер малай гына исән калган. Аны бер бүре тау куышына алып кайткан, яраларын дәвалаган, ашарына биргән. Бераздан бу малай егет булып үсеп җиткән. Ә бүре – ана бүре икән! – егеткә тугыз бала табып биргән. Безнең халык үрчеп, күбәеп җир йөзенә таралган. Шул бүренең – ерак әнкәбезнең! – исеме Ашина булган. Ашина – мәңгелек!» [1, 138-147 б.].

Фольклорчы Ф. Урманчеевның да Ашина хакындагы өйрәнүләренә күз салыйк. Асана – Ашина династиясе төрле төрки дәүләтләрдә 300 ел буе хакимлек итә. Аның исеме түбәндәгечә аңлатыла: А. – кытай телендә изгелек, ихтирамны белдерүче префикс; шино – бүре. Башкача әйткәндә, Ашина – шул ук Ак бүре, әмма башкача әйтелештә генә» [2, 62 б.]. Бу өйрәнүләрдән чыгып, шуны әйтик: Ашина – кайчандыр илаһи алла дәрәҗәсендә торган хайван. Ул иң борынгы ата-бабалар культы белән аваздаш.

Күренүенчә, биредә дә без язучы тарафыннан бик борынгы мифның профессиональ әдәбият традицияләре белән бәйле яңа шәрехләмәсен иҗат итү белән очрашабыз. Ул да, Н. Гыйматдинова «Болан», Г. Гыйльманов «Албастылар» әсәрләрендәге тенденцияләрне дәвам итеп, бүре образына мөрәҗәгать итә, ата-бабаларыбыз чорыннан мөһим саналган табигать культын раслый.

Изге бүре образын автор табигать белән бербөтен итеп карый. Инде кабиләң маңкортка әверелгәндә дә, афәт белән күзгә-күз калганда да, котылу юлы бар – ул синең Табигатең. Ибраһим белән Мирзаның бердәнбер таянычлары, ышанычлы дуслары – изге бүре. Әмма әсәр персонажлары Сәхәү белән Сабах, бүре аткан өчен күп акча бирәләр дип, бүрене мылтыктан имгәтәләр. Әмма бүре качып өлгерә. Ул бүре Мирзаның төшенә дә өч мәртәбә кергән. Төшләр, белүебезчә, булачак вакыйгаларның алхәбәрен җиткерүчеләр. Нәкъ бу Ашина-бүре Нугайбәк нәселеннән чаккан Ибраһимның бердәнбер нәсел дәвамчысын, (улы, оныгының әтисе Чулманда батып үлгән), оныгы Мирзаны коткарачак та.

Ибраһим нәселенең дәвамчысы Мирзага ана бүре-Ашинаның ярдәм итүе – милләтебезне саклап калуда табигатьнең дә роле зур булуын ассызыклый. Табигый җирлегебезне югалту – тарихыбызны югалту ул.

Әдәбият


1. Зәйдулла Р. Ашина // Мәйдан. – 2006. – № 1–№2.

2. Урманче Ф.И. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: 1 т. (А–Г). – Казан: Мәгариф, 2008.


## Детское чтение XXI века. «Не стреляйте в любовь!»


***Хуснутдинова Ландыш Ильшатовна***
***студентка 1 курса ГАПОУ «Мензелинчский педагогический колледж имени Мусы Джалиля»,***
***руководитель Галиева И. М.***
***преподаватель русского языка и литературы***


Сам человек только
в зеркале природы может
увидеть своё настоящее лицо
М.Пришвин

Детская литература пришла в упадок, когда отказалась в пользу развлекательных задач от проблем современности. Бизнессообщество по своей воле открывало и закрывало темы детской литературы. Так исчезла школьная повесть, реалистический рассказ и размножились веселые сказки и игровые стихи.

Но слухи о кончине детской литературы сильно преувеличены. Новые детские писатели у нас есть! Они умны, и оттого грустны. Имитируют легкомыслие. Они играют смыслами. Не пытаются кого-нибудь чему-нибудь учить. Напротив, умеют повредничать и подразниться, местами – смешно.

Они не стремятся воспитывать, но именно это у них отлично получается!

В замечательном ряду писателей, создающих проблемные произведения для детей и подростков, можно назвать имя Елены Габовой. Елена Васильевна Габова (Столповская) родилась 7 июня 1952 года в Сыктывкаре. Она дебютировала как поэт в 1967 году, опубликовав стихотворение «Ветер» в журнале «Пионер». Позже ее рассказы и повести печатаются в журналах «Юность», «Костер», «Слово», «Наш современник», «Путеводная звезда» и др. С 1989 года она - член Союза писателей СССР, с 1992 - литературный консультант Союза писателей Коми. Сегодня Е.В. Габова – автор более десяти книг для

детей и подростков, изданных в Москве, Киеве, Сыктывкаре, Токио. Ее произведения переведены на английский, немецкий, украинский, финский, венгерский, норвежский, языки народов России. Две книги («Шалун Антон и сыщики-девчонки», «Гришуня на планете Лохматиков») вышли в Японии в издательстве «Gakken». Елена Габова чаще всего пишет о первой любви, о просыпающихся желаниях и о том, как порой взрослые не хотят понимать, что творится в душе подростков. Мир в ее повестях и рассказах узнаваем, романтичен, наполнен тонким психологизмом. Как истинный патриот своего края, она много пишет на экологические темы.

Сегодня о проблемах экологии говорят повсюду: в печати, по телевидению, в интернете, на автобусной остановке, в метро. Но кто же сказал первым, кто обратился в этой теме ещё в XIX веке, кто заметил начало этой губительной тенденции уж тогда, когда круг экологических проблем ограничивался необоснованной вырубкой помещичьей рощи? Как это часто случается, первыми здесь были «голоса народа» — писатели.   И в XX веке, и в XXI  веке интерес к этой теме не исчезает.

Недавно я прочитала замечательную повесть Елены Габовой «Беличья шкурка».Герои повести – обыкновенные школьники, подростки Натка Сергеева и её одноклассник Юра Кобрин. Живут они в небольшом северном городке.Юра романтически воспитанный юноша, любящий музыку, чтение классической литературы. В душе у Натки и у Юрки возникли первые хрупкие чувства. Он сравнивает её с Татьяной Лариной, Наташей Ростовой.

Натка очень любит лес. Любовь к лесу, уединенности от городской суеты воспитал в ней отец. Он заядлый охотник, научил Натку стрелять.

Е. Габова показывает столкновение человека с природой, Натки и ее отца. Природа выступает как пробный камень человеческого духа, его нравственности. Контакты их с природой носят насильственный характер, враждебный природе, они ломают силы природы своей не знающей меры силой. Перед нами возникает проблема красоты и пользы. Красота леса, белок, хрупкий и ранимый живой организм погибает от хищнического вторжения охотников. Красивых зверьков - белок убивают, чтобы сшить из шкурок Натке шубу.

В финале повести Натка отправляется с Юрой в лес, приготовила ружье к охоте на белок.

«Неужели ты будешь стрелять? Зачем? — спросил Юрка»— «Юра, мой отец — охотник»—«Но ведь не ты?»Юрка не успел больше ничего сказать, Натка выстрелила… Ей так хотелось удивить Юру, показать какая она ловкая, меткая… Натка не узнала его. Лицо у Юрки стало необычным. Оно было немного удивленное, но удивление на нем постепенно пропадало, и оно каменело… словно ни на что больше не хотел смотреть… «Я не хочу, чтобы ты стреляла»

Зачем она это делает? Натка, конечно, думает, что Юрка оценит выстрел, что он будет восхищаться её меткостью, ведь не каждый подросток умеет стрелять. Но, к своему изумлению, Натка видит, что он её осуждает. Да и правильно. Убить беззащитного зверька только ради того, чтобы покрасоваться перед мальчиком? Это жестоко, да и глупо, пожалуй. Как сказал Наткин папа, «человек убивает, если он один в лесу и голоден… или надо кормить семью». Разве была она голодна или ей угрожала опасность? Нет. Безжалостно выстрелила она в белку ради… Ради того, чтобы показать, «что она не простая девчонка, её есть за что уважать»

В этой повести автор доказывает нам, как важны в жизни такие качества, как доброта, искренность, понимание, доверие, любовь. По мнению Елены Габовой, о человеке можно судить и по его отношению к природе.. Девочка любит природу, но в то же время губит её. Ведь истинная любовь к природе не в наблюдении над ней, а в её сохранении. Отец привил Натке любовь к природе, но не научил бережно к ней относиться. А вот Юрка восхищается природой, ценит её, хотя и не так близок к ней.

Любовь – это доверие. А разве можно доверять тому, кто убивает беззащитную жизнь, вместо того чтобы сберечь её? Юрка был поражён поступком Натки. Он-то думал, что она белок любит, кормит, ухаживает за ними. А она их убивает. Он разочаровывается в ней. Для Юрки нарушить красоту природы – это грех. Он уверен, что, истребляя природу, мы губим свою душу. Белка в этой повести – символ любви, красоты и мудрости. Главная героиня одним выстрелом в белку убила её, а значит, убила и свою, и Юркину любовь.

Когда читала повесть, то просто удивлялась Натке. Бессмысленный поступок. Мне кажется, девочка в её возрасте должна понимать, «что такое хорошо и что такое плохо». Ведь есть же другие способы обратить на себя внимание мальчика, заслужить его уважение, понравиться ему.

«На твоё плечо белка не сядет» – Юркины слова запали в душу Натке. Этими словами и заканчивается повесть. И мне хочется верить, что девочка поняла свою ошибку, что больше никогда не станет она обращать на себя чьё-либо внимание таким образом. Поучительная история… И я надеюсь, что всё будет хорошо у Натки Сергеевой.

Познакомившись с замечательным произведением Елены Габовой, я по-новому взглянула на мир, в чём-то переосмыслила жизнь. Мне кажется, в наше время детская книга – уникальное средство общения между поколениями. Мир меняется и вечные ценности должны вновь и вновь выдерживать проверку временем, доказывая свою значимость.

# Проблема «человека и природы» в литературе XX-XXI вв

***Часовская Дарья Альбертовна,***
***Малыхина Элеонора Евгеньевна,***
***1курс ГАПОУ «БМТ»***
***Преподаватель русского языка и литературы***
***Шавалеева Илюся Мухаметовна***
***преподаватель татарского языка и литературы***
***Бубекова Ильмира Сибгатуловна***

В литературе XX в., особенно в лирической поэзии, образ природы доминирует над ее предметностью, так как пространственность исчезает. В стихотворениях А. Блока пейзаж теряется в сумеречной мгле. Это наблюдается и в творчестве Б. Пастернака 1910-1930-х годов. Так, в стихотворении «Волны» из «Второго рождения» образы лучезарных явлений природы поглощаются в глубине изображения. Для первых лет после революции характерно стихотворение В.В. Маяковского «Портсигар в траву ушел на треть» (1920), где труд и искусство воспринимается ярче, чем природный мир. Литература воспринимала события в природе и жизни людей.

Загрязненная природа кричит о помощи. Наш век порождает все больше и больше проблем экономического и морального направления. Но все же, важнейшей проблемой является - экологическая. Будущее молодого поколения в целом находится во власти определения этой задачи. От состояния экологии зависит наша жизнь. Многие регионы РФ находятся в запущенном состоянии. Великие русские реки загрязняются промышленными отходами и стоками. Чудовищной для природы была авария на Чернобыльской АЭС. Люди уничтожают свою историю, истоки. Тот, кто забывает свое прошлое, не имеет будущего. Многие ради прибыли забывают о том, что, истребив свои корни, автоматически превращаются в чудовища. Чья вина в этом? Эту проблему глубоко освещают известные писатели Чингиз Айтматов и Валентин Распутин. "Плаха" Айтматова заставляет задуматься о насущных вопросах общества. Этот роман не оставляет без внимания каждого из нас.

Взаимодействие человека и природы, уничтожение деревень раскрывается в повести Распутина «Прощание с Матерой».

Персонаж повести Бабка Дарья горестно принимает известие о затоплении деревни. Всю жизнь она работала, жила, страдала, мучилась, -теперь все это будет уничтожено. Все это близко, больно и обидно. Что же будет дальше? Это произведение не дает покоя не только героям писателей, но и читателям.

Остро освещается экологическая проза 60-90-х годов в татарской литературе. Роман «Жидегән чишмә», повесть «Туган ягым - яшел бишек» Г.Баширова, повесть «Юл буенда зәңгәр чәчәк» Р.Батуллы, повесть «Болын» Ф.Байрамовой- обращение внимания к важной проблеме. Это является частью национальной политики, так как экологический кризис угрожает всему человечеству. Если в русской прозе взаимоотношение человека и природы изображается с точки зрения философии, то творения татарских писателей накладывают свой отпечаток на экономические факторы. Татарские писатели с пятидесятых годов двадцатого века наблюдают, интересуются тем, как развитие экономического роста влияет на судьбы людей. Яркий пример явной связи добычи «черного золота» и жизни татарской деревни, её жителей находят отражение в романах: «Гади кешеләр» И. Гази, «Хәзинә» и «Хуҗалар» Г. Ахунова, «Каты токым» Ш.Бикчурина. Следует отметить, что авторы умалчивают «нефтяную проблему» природы. В поэме «Сәяхәтнамә» А. Баянова осмысление взаимодействия человека и природы раскрываются в широком плане. Поэт выступает в защиту природы, которой грозит большая опасность со стороны НТП. Экологическая проза-проблема, которая волнует всех писателей. Под воздействием своего же детища - научно-технического прогресса он духовно черствеет, что порождает в нем безразличие ко всему сущему на Земле и особенно к естественной среде.

Природа очень сильно влияет на человека: дает ему силы, приоткрывает тайны, отвечает на многие вопросы. Творческие люди черпают вдохновение, глядя на простые, и в то же время, идеальные картины природы. Писатели и поэты практически всегда обращаются к проблеме человека и природы, поскольку чувствуют связь с ней. Природа - неизменная часть почти каждого прозаического творения.

Литература

1.Белая, Г.А. Художественная мир современной прозы Текст. - М.: Издательство «Наука», 1983 - 192с.

2. Васильева, Т. Философия и поэзия, перед загадкой природы. О природе вещей. М.: Издательство «Художественная литература», 1983.

3. Панкеев, И.А. Валентин Распутин: По страницам произведений. - М.: Издательство «Просвещение», 1990- 144 с.

4. Смирнова, А. И. Русская натурфилософская проза второй половины XX века: А. И. Смирнова Учебное пособие – [Электронный ресурс]

5. Спивак, Р.С. Русская философская лирика. 1910-е годы. И.Бунин, А. Блок, В. Маяковский: Учебное пособие. - М.: Издательство «Флинта»; «Наука», 2005 - 408 с.

# Әтнә төбәгенең табигый матурлыклары әдәби әсәрләрдә.

***Шиһапов Булат Ленар улы (1 курс, 012 төркем укучысы***
***Габдулла Тукай исемендәге Әтнә авыл хуҗалыгы техникумы)***
***Җитәкчесе: Галимҗанов Шамил Әһли улы.***

,

Әй язмыш, язмыш,
Читтә сулырмын
Сусыз гөл кебек
Кайгыдан - моңнан;
Аерма мине
Өй түрендәге
Миләшләремнән,
Каеннарымнан. [3,с.16 ]
Сибгат Хәким.

Табигать - кешене һәрьяклап тәрбияләү көченә ия. Гүзәл хисләр үзләренең тамырлары белән балачакка тоташырга тиеш, ә яхшылык, ягымлылык әйләнә - тирәдәге матурлык турында кайгыртканда туа.

Әгәр табигать кочагында йөргәндә кешедә кайгыртучанлык сыйфатлары тәрбияләнмәсә, димәк аны беркайчан да тәрбияләп булмый.

Табигатьтә булганда укучы әйләнә - тирә дөньяны җанлы, ачык итеп таный белергә өйрәнә. Табигатьнең матурлыгын кабул итеп иҗади сәләтләре ачылырга, рәсем ясау осталыгын үстерергә, рухи яктан үсәргә, тирән мәгънәле фикерләү сәләтен үстерүгә ярдәм итә.

Заманыбызның күренекле педагогы В.А. Сухомлинский табигатьне, әйләнә - тирә мохитне һичкайчан саекмас белем чишмәсе, матурлык, бәхет чыганагы дип атады.

Ләкин хәзергесе көндә әйләнә - тирә мохитне пычратучы бик күп проблемалар бар. Бу проблемаларга һәр кеше төрлечә карый. Татар әдәбияты белән тыгыз элемтәдә торучы шәхесләр табигатьне яклап күп кенә шигырьләр, сынамышлар, табышмаклар, әйтемнәр, әкиятләр яза.

Тыюлык хезмәткәрләре әйләнә - тирә мохитне саклауда икенче яктан катнашалар. Алар тыюлыклар ясый.

Сезгә үземнең туган авылым турында сөйләп китәсем килә. Минем туган авылым Күәм бик матур җирдә урнашкан. Мөхәммәт Мәһдиевнең "Торналар төшкән җирдә" дигән повестеннән бер өзек китерәсем килә:

"...Безнең авылдан бер генә герой да, космонавт да чыкмаган. Гап - гади, иң гадәти бер авыл... Бөтен булган байлыгы - урман, чишмәләр һәм кешеләр". [1,с.5 ]Авылыма кергәндә ике яклап каен полосасы, авылым эчендә ике сусаклагыч һәм күп кенә чишмәләр.

Мин яшәгән якта да Татарстан республикасындагы зур тыюлыкларның берсе - Ашыт тыюлыгы урнашкан. Әлеге тыюлык республикабызда 1997 елда урнаша. Әгәр җәй айларында безгә кунакка килсәгез, Ашыт буенда йөзгән пар аккошларны күрә алырсыз. Элек яшәгән кешеләр сүзләренә колак салсак, Ашыт елгасы тирән, мул сулы булган. Кайбер урыннарында тирәнлеген үлчәгәндә ике ат дилбегәсе буе да җитми торган булган . Елганың озынлыгы 89 чакырым. Ашыт Илләт елгасының сул як кушылдыгы булып тора. Ләкин бу гүзәллекне бозучы кешеләр дә табыла. Кайбер дорфа кешеләр елга буена чүп-чарларын ташлап калдыралар.

Авылыбызның һавасы саф, чиста. Габдулла Тукай әйтмешли "ак күмәчкә ягып ашарлык".

Авылыбызда күп кенә кешеләргә мөһим булган "Изгеләр" чишмәсе дә бар. Ә безгә күрше урнашкан Күлле Киме, Ары Һәм башка авыллар урманнарга бик бай. Шул Ары авылының чигеннән соң Мари иленең иксез - чиксез урманнары башлана. Безнең як кешеләре, яңа йорт, каралты - кура җиткерергә уйласалар, шул якларга барганнар. Урманнары күп булгангамы, бу якларның һавасын сулап туеп булмый. Әгәр зифа буйлы булып үскән нарат араларына керсәң, бар булган чирләреңне онытып кайтып китәсең. Бу сүзләргә дәлил булып, Сибгат ага Хәкимнең "Җырларымда телим..." дигән шигъри юлларын китерергә мөмкин. Ул болайрак яза:

... Авыруыма врач кирәк түгел,
Йөрәгемнең беләм дәвасын.
Һәр ел саен кайтып иснәп киләм
Авылыбызның чиста һавасын. [3,с.27 ]

Ләкин нәрсә генә дисәң дә, экология проблемасы бүгенге көндә иң зур проблемаларның берсе. Авылларда һава чиста булса да, зур шәһәрләрдә һава икенче, пычрак. Чөнки зур шәһәрләрдә бик күп кенә завод - фабрикалар бар. Аларның торбаларыннан һавага пырак күтәрелә һәм без шуны суларга мәҗбүр булабыз.

Ә хәзер сезнең игътибарга табигать турында үзем иҗат иткән бер шигыремне тәгъдим итәм.

Туган ягым – яшел бишегем.
Хәтфә үлән, зәңгәр елгаларың
Иксез - чиксез иген кырларың.
Каз – үрдәкләр, пар аккошлар синең
Йөрәккә наз биргән язларың.

Һәр сукмагың миңа таныш, якын
Туган ягым – яшел бишегем.
Сихри матурлыгың ник югала
Чит – ят керә ачып ишегең?

Пар аккошны ялгыз калдырдылар,
Сөйгән ярын тартып алдылар.
Күл бизәге булган каз - үрдәкне
Казаннарга кемнәр салдылар?

Яшел урманнар да чүптә хәзер
Хәтфә чирәмнәрең агулы.
Матурлыкны кеше үзе боза,
Ник аңламый, кемгә ачулы?

Ә балалар, бездән калган буын
Сабыйларны безнең ни көтә?
Туган якның сихри матурлыгы
Аларга бит калмый, ул бетә.

Без барыбыз, уйланырга тиеш
Табигатьне саклап калырга.
Хәзинәне дөрес кулланырга,
Киләчәккә алып барырга.

Чишмә, күлләр, һава, кояшыбыз
Без тәгәрәп үскән болыннар.
Безгә рәхмәт әйтеп матурлансын
Сокланырлык булсын буыннар.

**Кулланылган әдәбият**

1. М.Мәһдиев.Торналар төшкән җирдә.Казан,Татарстан китап нәшрияты, 2009 ел.
2. С.Хәким.Шигырьләр җыентыгы. Казан,Татарстан китап нәшрияты, 1987 ел.

# Ә. Еникинең “Туган туфрак” әсәрендә кеше һәм табигать бәйләнеше

***Яруллина Ләйлә Мансур кызы,***
***“Казан педагогия көллияте”ДАҺБУ 1нче курс студенты***
***Нуриева Лилия Фаиловна,***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы,***
***“Казан педагогия көллияте”ДАҺБУ***

Кеше тормышы һәрвакыт табигать белән бәйле. Ул – кешенең сәламәтлек, туклану, гомумән, яшәеш чыганагы. Табигать дигәч, иң беренче чиратта, калын яшел урманнар, саф сулы чишмәләр, бай тарихлы елгалар, күлләр, иксез-чиксез җәелеп яткан далалар күз алдына килә.

XX-XXI гасыр әдәбиятында кеше һәм табигать бәйләнешен без  Ә.Еникинең “Туган туфрак” хикәясе мисалында карый алабыз. Әсәрдә  “бөтен хисләрдән дә изгерәк, көчлерәк хис” дип, туган туфрак хисе тәкъдим ителә.

Әсәр васыять образы белән ачыла, һәркемгә якын булырга тиешле туган туфрак хисе – ата-бабаның гомер иткән җире, гомер иткән нигез, ерак бабаларның каберләрен белү булып күзаллана. Үткән һәм бүгенгене чагыштыру нәтиҗәсендә Клараның хис-кичерешләр сызыгы барлыкка килә. Туган туфрак төшенчәсе символлар, әдәби детальләрдән оеша. Мәсәлән, чыра-ут әсәрдә нәселне җыеп торучы учак образының сурәтләнеше буларак тәкъдим ителә.

Вакыйгалар эзлеклелеге кичерешләр чылбырын хасил итүдә хәлиткеч роль уйный. Студент кыз Клара иң җитди вакытта – тормыш юлын сайлар алдыннан бабасының васыятен үтәр өчен юлга чыга, кояш баер алдыннан кечкенә бер станциягә туктый, караңгы төшеп, тәмам күз бәйләнгәч, Зиреклебашка аяк атлый. Яңа кичерешләр сызыгына – Каракошка иртәнге чәйдән соң юл ала, “йөзен кичке тау җиленә куеп” “тансык хисләр дулкынына” – үз асылына кайта.

Урын образына хис-кичерешләр сызыгын укып бару вазифасы йөкләнә. Клараның кичерешләре туган туфракны “Питрәчнең көл балчыклы бәрәңге җирләрен” “бар икән ул туган туфрак дигән кадерле җир” дип кабул итүгә кадәр үсә. Клара килеп төшкән кечкенә станция – Клараның яңа кичерешләр сызыгына аяк басуы турында хәбәр итә. Һәр вакыйгада хис-кичереш белән бергә урын үзгәрә. “Яңа чапкан печән тутырып, өстенә чуар палас бөкләп салган биле сыгылыбрак торган тарантаска утыру” тәүге хисне – “җир якын, үләннәр якын”

дип белдерелгән якынлыкны тоюдан “сагышлы һәм рәхәт күрсенүне” әзерли. Клара беренче тапкыр бабасының җырын искә төшерә, димәк, үзендәге буыннардан килгән хәтерне кабул итүгә әзерләнә. Җиде чакрымдагы Зиреклебашка кыз “туганлык хисен тоймаганга күрә пошынып” калган хәлдә кайтып керә. Бу икенче хис кечкенә өйнең бусагасын (ике – чит һәм үз чынбарлык чиген) атлап керүгә алышына – кыз “югалып кала”. “Өйалдындагы махсус юып җыештырылган ак чоланда” йоклау кызны “беркайчан да татымаган “ хисләр чынбарлыгына – йон кабасы, тәрәш тарак, каен тузыннан теккән кечкенә тубал белән тулы һ.б. “әкәмәт нәрсәләр”гә сокланачак дөньяга алып керә. Өченче хис – таныш түгел бу чынбарлыкны үз итү (“Странно, но мило!”). Тып-тын өйалды дип бирелгән урын ике чынбарлыкны очраштыра. “Киң билбаулы ефәк халат, ак танкеткалар” кигән көяз Клара ишектән чыкканда “чыбык-чабык күтәреп килүче” җиңгәчәсе белән очраша. Дүртенче хис – бу таныш түгел кешеләрнең аңа карата ягымлы була алуына аптырау (Иркә туташ дип эндәшү, сөлге, сабын күтәреп чыгу). Шунда Клара беренче тапкыр хәйран кала.

Бераздан Клара күзәтүче булудан туктый – авылдагы иң кырыйдагы өйдән урманга – сынау юлына аяк басу өчен капка төбенә чыга. Табигыйлек, хөрлек сокландырган Клара юл башында зирәк карт образы кебек аңланган бабайдан хәер-фатиха ала: бәхетле булыр өчен үткәннәрне белү, хөрмәтләү тиешле. Бу изге сүзне дулкынланып кабул иткән кыз урманнан чәчәк бәйләме, сый-нигъмәт җыеп кайта.  Җиңсез ак кофточка, киң итәк, чәчәкләр – Кларaның матурлыкны кабул итүе. Автор Хәсән вакыйгасы аша чын матурлык кешеләр арасындагы ихлас мөнәсәбәтләрдә, бик азга гына шөкер итә белүдә дигән фикерне алга куя. Җиңгәчәсе сөйләгән вакыйга Кларaны гаҗәпкә калдыра – яшәеш, “дөреслек кайвакытта бик рәхимсез булса да, кешеләр аңа тыныч караса” үзгә була икән. Шул халәттә Клара Каракошка – нигезгә кайту өчен тарантаска утыра. Таула менү теләге – Кларада туган кичерешләр нәтиҗәсе. Кызның бу таныш түгел, әмма бик үз һәм якын булган кичерешләрне тагын да тирәнрәк тою теләге уяна. Бабасының сүзләре дә шул кичерешләр кайтавазы буларак искә төшә. Корысазлык турындагы вакыйга шул турыдагы хыялның бөреләнүен искәртә. Клара догадан соң беренче тапкыр “туган туфрак” хисен кичерә. Ләкин тәбәнәк кенә манаралы кәкрәйгән айлы, искергән, тузган, мүк баскан, бүрәнәләре караеп беткән мәчет Кларaны гаҗәпкә калдыра. Мәчет – татар кешесенең бүгенге эчке халәтенең укылышы кебек аңлана. Авылда яшеллекнең аз булуы бу яшәешне үзгәртергә кирәклеге турында искәртү, сызланып белдерү. Клара ап-ак казларны – нәселнең киләчәген күрә, ислекәй, ак әремне исни – дала исен сизә. Кларада беренче тапкыр үткәннәрне белү ихтыяҗы туа. Кояш баер алдыннан Клара яңа чынбарлыкка аяк атлый – тауга менә. Сыерчыклар – кошлар символик укылышта җан, рух белдерелеше Кларадагы “рәхәтлек”нең аталышы. Клара үзгәрә –

эшләпәсен сала, елый. Яңа тормыш юлына аяк баскан кыз буыннардан килгән бәхетле булу юлын кабул итә.

Әмирхан Еники “Туган туфрак” әсәрендә табигать белән кеше бәйләнешен гади һәм аңлаешлы, күңелгә үтеп керә торган итеп ачып сала. Ерактагы “туган туфрак” дигән нәрсәнең башта Кларага ят һәм билгесез булып, тора-бара “туган җиренә, туган халкына, телдән генә сөйләнә торган түгел, ә кан тамырында йөри торган чын якынлык-мәхәббәт хис”енә әверелүе сурәтләнә. Кыскасы, табигать кеше яшәешенең аерылгысыз бер өлеше дигән нәтиҗәгә киләбез.

Кулланылган әдәбият:

1. Еники Ә. Туган туфрак / Еники Ә. Әсәрләр. 3 томда. 3 том. Хикәяләр. – Казан: Татар.кит. нәшр., 1991. – Б.146-175.

## Тема статьи: «Человек – царь природы…»

***Автор статьи: Ялилова Сумбуль Ришатовна***
***Студентка группы № 0161 «т» (I курс)***
***ГАПОУ «Актанышский технологический техникум»***
***Руководитель: Хамматуллина Энже Абулаесовна***
***Преподаватель русского языка и литературы***

XX, XXI века внесли большие изменения в жизнь человека. Цивилизации грозит гибель от природы. Да, природа стала показывать, «кто в доме хозяин», - участились всевозможные природные катаклизмы и бедствия. Ученые начали пристальное изучение не только природы как отдельной системы с ее собственными законами, но и появились теории, рассматривающие всю Вселенную как единый организм. Человек наивно думает, что он - царь природы. «Нам не привыкать к потерям, - писал С. Залыгин, - но только до тех пор, пока не настанет момент потерять природу, - после этого терять уже будет нечего».

Самые разные книги, на любые темы, для большого круга читателей можно найти сейчас на книжных полках. В произведениях В. Астафьева, В. Белова, С. Залыгина, Е. Носова, В. Чивилихина, В. Бочарникова, Ю. Сбитнева ощущается потребность «восстановить» природу в своих правах, напомнить человеку о его первоистоке. В рассказе В.П. Астафьева «Царь-рыба» Царь-рыбой называют осетра, но это и символ непокоренной природы. Борьба человека и царь-рыбы завершается трагически: рыба не сдается, но, смертельно раненная, она уходит, чтобы умереть. Покорение и завоевание природы приводит к ее гибели. Уроженец русского Севера, Астафьев любит и чувствует природу. Человек поддается развращающему влиянию философии потребительства, начинает варварски эксплуатировать природу, не понимая, что уничтожает дом в котором живет.

Конец XX и начало XXI века дали еще одно понятие – экология человека. Человечество, искалеченное духовно, не имеющее цели, кроме погони за материальными благами любой ценой, калечит природу.

Безумный технический прогресс принес человечеству вместе с потоком открытий и множество проблем. Среди них очень и очень важная - охрана окружающей среды. Чернобыльская катастрофа… Время разделилось на то, что было до и после Чернобыля. Воздействие человека на живую природу по губительной силе сравнялось с планетарными стихийными бедствиями. Местные катастрофы перестали быть местными. За тысячи и тысячи километров от Чернобыля в костях животных, птиц и рыб находят радиоактивный стронций. Зараженные воды уже давно влились в Мировой океан. В Антарктиде погибают пингвины, питающиеся зараженной рыбой. То, о чем писал Астафьев, стало страшной реальностью: планета мала, она слишком хрупка для бравых экспериментов. Кто виноват? Человек, забывший о своих корнях, забывший, откуда он родом, человек-хищник, который становился подчас страшнее зверя. Именно этой проблеме посвящен ряд произведений таких знаменитых писателей, как Чингиз Айтматов, Валентин Распутин, Виктор Астафьев.

Я в восторге от произведений Валентина Распутина, это – одно из ярких, запоминающихся среди писателей XX века. В повести «Прощание с Матёрой» писатель размышляет о многом. Предметом описания является остров, на котором раскинулась деревня – Матёра. Матёра – это реальный остров со старухой Дарьей, с дедом Егором, с Богодулом, но одновременно это образ многовекового уклада, который теперь уходит – навсегда? Остров должен уйти под воду, потому что тут строится плотина. То есть это с одной стороны правильно, потому что население страны необходимо обеспечить электроэнергией. А с другой стороны – это грубое вмешательство людей в естественный ход событий, то есть в жизнь природы. Гибель Матёры – это разрушение не просто старого уклада, а крушение целого мироустройства. В произведении Чингиза Айтматова "Плаха" волчица и ребенок погибают вместе, и кровь их смешивается, доказывая единство всего живого, несмотря на все существующие диспропорции.

Таким образом, отношения человека и природы на страницах книг многообразны. Читая о других, мы невольно примериваем характеры и ситуации на себя. И, возможно, тоже задумываемся: а сами-то мы как относимся к природе? Не стоит ли что-то поменять в этом отношении? Ответы мы находим у М.М.Пришвина. В его произведении "В краю непуганых птиц", в книге очерков "Северный лес" и в "Корабельной чаще". А в "Лесной капели" Пришвин пишет о черемухе, которую во время цветения так неразумно ломают горожане, унося охапки белых душистых цветов. Ответы находим и у Бунина И.А. Рассказ "Антоновские яблоки" - это гимн природе, наполненный неудержимой радостью. В рассказе

"Эпитафия" Бунин с горечью пишет об опустевшей деревне. Перестала жить лежащая вокруг степь, замерла вся природа.

В заключение хочу представить Евгения Базарова, устами которого Тургенев выразил мысль определенной части общества о том, что природа не храм, а мастерская, и человек в ней работник, и доктор Астров, один из героев Чехова, сажающий и выращивающий леса и думающий о том, как прекрасна наша земля, - вот два полюса в постановке и решении проблемы Человек и природа – а как это современно!

Литература

1.Белая, Г.А. Художественная мир современной прозы Текст. - М.: Издательство «Наука», 1983 - 192с.

2.Борейко, В.Е. Красота природы и экологическая этика Электронный ресурс.

3.Васильева, Т. Философия и поэзия, перед загадкой природы. О природе вещей. М.: Издательство «Художественная литература», 1983.

4.Великанов А., Скоропанова, И.С. Русская постмодернистская литература: Учебное пособие. М: Издательство «Наука», 1999.

5.Гапон Е.С. Художественная концепция личности в творчестве В.Г. Распутина 1990-х 2000-х. - Армавир, 2005 - 167 с.

## II секция
## Табигать һәм шәхес.

***Алабуга муниципаль районы***
***муниципаль гомуми бюджет***
***белем учреждениесе"4нче гиназия"***
***Айдашева Кадрия Әмирҗан кызы***
***беренче квалификацион категорияле***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

Кеше тормышы табигать белән бәйләнгән. Табигать безгә азык, кием, торыр урын бирә, тормышыбызны бизи. Хәзерге вакытта табигатьне саклау һәм әхлак проблемасы аеруча мөһим, чөнки җирдәге байлыклар кими, тәртипсезлек арта бара Моңа кадәр безнең җәмгыять кеше тәрбияләнүне мораль кодекска, пионер, комсомол, партия оешмаларының уставлары, дәүләт органнарының боерыкларына таянып алып барды. Тәрбия өлкәсендә баланы тыю, кисәтү, гаебен күрсәтү алымнары өстенлек алды. "Алай эшләмә", "тегеләй итмә" кебек кисәтүләр бала колагында даими яңгырап торды. Ә ни өчен алай ярамаганны аңлата алдыкмы икән? Әхлаклылык күрсәткече булган гомумкешелек сыйфатларының (тугрылык, намус, шәфкатьлелек, өмет, ышаныч, сүздә тору, җаваплылык һ.б.) асылын-мәгънәсен ачуга бирә алмадык. Чөнки укытучы кулында андый ысул юк иде. Гаилә дә тәрбияне күбрәк мәктәп өстенә йөкләргә тырышты. Иҗади үсеш технологиясенең атасы, психология фәннәре докторы, профессор Әхмәт Зәки улы Рәхимов әйткәнчә, хәзерге укытучы алдында торган беренчел бурыч – укучыларга әхлак тәрбиясе бирү.

Халкыбызның акыл иясе Риза Фәхретдиннең зирәк фикеренә колак салыйк: "Бала чакта алган тәрбияне соңрак бөтен дөнья халкы да үзгәртә алмас", – дип кисәтә ул. Бу хакта даһи Тукаебыз да еш искәртә. Аның "тырыш яшьләй, зурайгач, җайсыз ул. Картаеп каткач буынныр, эш белү уңайсыз ул!" дигән шигырь юлларын гына да искә төшерү җитә. Ни өчен иртәрәк? Чөнки һәр нәрсәнең үз вакыты бар. Бала мәктәпкә кадәр үз тирә-ягындагы мохит тәэсирендә формалаша. Моны табигать мизгелләре белән чагыштырырга мөмкин: билгеле бер вакытта гына кояш чыга, көн туа, яз килә һ.б. Кеше

аңының, әхлагының формалашуы да эзлекле рәвештә бер вакытка туры килә. Шул моментны үткәрдекме – соңга калуыбыз да бик мөмкин.

Ә аннан соң кеше (8, 12 яшьтән соң) үзен-үзе тәрбияләргә күчә. Үзенең тискәре гадәтләрен җиңә алган кеше генә бөек җәмгыятькә лаеклы шәхес була ала. Ә инде татар теле һәм әдәбияты укытучысының бурычы – милли рухтагы әхлаклы балалар тәрбияләү булырга тиеш.

Әхлакый-экологик белем һәм тәрбия бирүдә әдәби әсәрләрнең әһәмияте зур. Язучыларыбыз, беренчеләдән булып, табигатьне саклау турында чаң сукты. Әйләнә-тирә дөньяны, кеше сәламәтлеген, аның рухын, телен саклау аларны иң борчыган һәм дулкынландырган проблемага әйләнде. Нәфис сүз, сәнгать чаралары ярдәмендә кешедә югалып бара торган иң изге әхлакый-рухи кыйммәтләрне торгызу, Җир-анага игелек, хөрмәт хисләрен уяту, кешелекнең экологик һәлакәт каршында торуында искәртергә кирәк иде.

Табигатьне саклау темасына язылган әсәрләр исемлеге бай һәм төрле. Г. Тукай күп кенә шигырьләрендә җәнлекләрне, кошларны, бөҗәкләрне яратырга, аларга мәрхәмәтле, шәфкатьле булырга өнди, үзенең шигъри бизәкләре белән табигатьнең гүзәллеген ача. Табигатьне саклау – милләтебезне, туган телебезне, гореф-гадәтләрне, рухи һәм тарихи байлыкларны саклау белән тыгыз бәйләнгән. Чөнки туган тел, әдәби һәм тарихи мирас газиз җиребездә барлыкка килгән. Шуңа күрә балаларны татар халкының рухи тамырлары, ерак бабаларыбызның яшәү рәвеше, һөнәрләре белән таныштыру, аларда милли горурлык тәрбияләү мөһим. Табигатьнең матурлыгын, серлелеген Тукаебыз үзенең җаны, саф күңеле, йөрәк җылысы салынган шигъри юллары белән укучы җанына, аның күңеленә салучы, ныгытучы, мәңгеләштерүче.

"Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә,

Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем".

(Г. Тукай. "Туган авыл")

"Су анасы", "Шүрәле" әсәрләрендә баланы гаҗәеп табигать дөньясына алып керә. Матурлык дөньясын тою балаларда гүзәллеккә омтылу хисе уята. Бу әсәрләр аша балаларда кешегә, аның акылына, зирәклегенә, хәйлә катнаш

тапкырлыгына, кыюлыгына, батырлыгына соклану хисе уяна. Ә хисләр, хыяллар дөньяны танып белүнең башлангычы ул.

Хәзерге җәмгыять байлар, урта хәллеләр, ярлыларга бүленде. Патриотик тәрбиягә игътибар да бик нык кимеде. Бу тема элек яктыртылып килсә, хәзер матбугат битләреннән дә төшеп калды. Патриотизм – ул кешеләрне рухи һәм әхлакый сыйфаты: туган йортыңа, җиреңә, телеңә, мәдәниятеңә мәхәббәт, илеңнең героик үткәне һәм хәзергесе белән горурлану. Укучыларда патриотик аң формалаштыру үзеңнән үзе генә түгел, эзлекле алып барылырга тиеш. Ул өйдә башланып, балалар бакчасы, мәктәп һәм кешенең гомере буе ныгытыла.

Патриотизмның иң югары ноктасы – герой-шагыйрь М. Җәлилнең тормышы һәм иҗаты. Укытучының бурычы – герой-шагыйрьнең тормыш юлы үрнәгендә патриотизм хисләре тәрбияләү. М. Җәлилнең әхлак темасын яктырткан шигырьләрен өйрәнү мәслихәт, чөнки патриотизм – әхлак тәрбиясенең алыштыргысыз бер өлеше. "Карак песи", "Ишек төбендә", "Сәгать" шигырьләрендә җәмәгатьчелек урыннарда үзләрен ничек тотарга белми торган балаларга сабак бирелә. Кайбер балаларга урлашу, алдашу, соңга калу кебек кире сыйфатлар хас. Шигырьдә китерелгән тискәре күренешләр мисалында әхлак нормаларына сыймый торган хаталар кисәтелә.

Яңа гасыр, яңа тормыш өчен мөстәкыйль уйларга сәләтле шәхесләр кирәк. Аларның юлында акны – карадан, чынны – ялганнан, вөжданны – намуссызлыктан аерып бирергә өйрәтүче маяк булып – әхлак тәрбиясе тора.

Халыкта Ватан төшенчәсе Ана белән тиңләнә. Ананың тиңсез җылылыгын, табигатьнең чиксез матурлыгын тою – баланы тышкы дөнья белән бәйләүче беренче карлыгачлар. Аналарга, олыларга шәфкатьлелек тәрбияләү – укытучының бурычы. Мәсәлән: күп кенә әсәрләрдә (А.Шамов "Госпитальдә", Г.Әпсәләмов "Ак чәчәкләр", Н.Әхмәдиев " Ана") аналарның балага мөнәсәбәтләрнең изгелеге чагыла.

Кешелек җәмгыятен һәрвакыт борчып килгән табигать, әхлак мәсьәләләре – намус, гаделлек, җирдә дөрес итеп яшәү, әти-әни һәм Ватан алдындагы изге бурычны үтәү кебек төшенчәләр мәңгелек, һәркем өчен уртак.

Аларны үзеңдә булдыру өчен Кеше булу кирәк. Ә укучыларны Кеше итеп тәрбияләү – безнең һәрберебезнең бурычы.

Шулай итеп, бүген татарны милләт буларак саклап калуның бердәнбер юлы – телне саклап калу. Тел сакланса – милләт саклана. Тел югалса, милләт башка милләт тарафыннан йотыла. Татарны ничәмә гасырлар иманлы, гуманлы, көчле рухлы итеп яшәткән нәрсә – ислам дине, шәригать кануннары. Тәрбия кылу ата-бабаларыбыздан килгән гореф-гадәтләр, дини һәм дөньяви йолалар, хезмәт, гаилә һәм милли традицияләребез, җәмгыять тормышында урнашкан әдәп, әхлакый кыйммәтләр, ислам диненә салынган әхлакый һәм гуманистик идеяләр шәригать кануннарына нигезләнгән булырга тиеш.

**Кулланылган әдәбият**


1. Гайсин И.Т. Развитие экологического воспитания в школе.- Казань,2005.
2. Ибраһимова Ф. Җ. Табигат бизәкләре.- Казан: “Мәгариф” нәшрияты,2002.
3. Хуҗиәхмәтов Ә. Н. Тәрбия- мәңгелек фәлсәфә.-Казан: “Мәгариф” нәшрияты,2001.


## Муса Җәлилнең “Алтынчәч” либреттосында табигать һәи кеше мөнәсәбәте


***Арсланова Сәлимә Салаховна,***
***Татар теле һәм әдәбияты укытучысы,***
***“Тәтеш дәүләт гражданнарны яклау колледжы” ДАҺБУ***


Татар халкының бөек шагыйре Муса Җәлилнең күпкырлы иҗатын Нәҗип Җиһанов операсының әдәби нигезен тәшкил иткән “Алтынчәч” либреттосы аеруча бизи. Шагыйрьнең үз халкының тормышын, тарихын, аның мең елларга сузылган бай иҗади мирасын тирәнтен белүе, шушы мираска, үз халкына булган тирән мәхәббәте һәм тугрылыгы романтик рухтагы һәм шул ук вакытта тирән фәлсәфи фикергә ия поэманы барлыкка китерә.

I актның икенче күренеше фантастик картина белән башланып китә: кошлар Җикнең йокысын саклыйлар, аңа бишек җыры җырлыйлар. Тугзак

нәселенең исән калган бердәнбер баласы шулай табигать кочагында, кошлар һәм төрле җәнлекләр тәрбиясендә үсә:

*Кара урман! Мине кочагыңда,*
*Җил-давылдан саклап үстердең,*
*Син су бирдең миңа сусаганда,*
*Сәләт бирдең миңа, көч бирдең.*
*Куяннарың миңа бала чакта*
*Ташыганнар пешкән баланнар,*
*Бөркетләрең, мине җилдән саклап,*
*Канат асларына алганнар.*

Кешенең табигать баласы булуын, үсешенең һәр этабында аңа таянуын һәм, ниһаять, шул табигатьне саклауда үзенең турыдан-туры җаваплылыгын Җәлил фантастик сюжет аша гына бирми. Халкыбызның тел җәүһәрләрен әсәр тукымасына поэтик бизәкләр итеп тезгәндә, либреттист, беренче чиратта, металогик алымнан файдалана. Тел белемендә металогик алым дип образ, сурәт тудыруда, тасвирлауда күчерелмә мәгънәлелеккә нигезләнгән сурәтләү чараларына мөрәҗәгать итүне атыйлар.

Без югарыда карап үткән өзектә автор табигатьне җанландырып, кош һәм хайваннарга кешеләргә хас сыйфатларны салып күрсәтә. Поэтик бизәкнең әсәрдә киң киң кулланыш тапкан бу төре **сынландыру** дип атала. Мондый “терелтүләр” әсәрнең фәлсәфи эчтәлеген, халык көчен тирәнрәк ачарга ярдәм итә: *Кояш дәрт бирде миңа, җир сәләт бирде миңа...*

Текстта шулай ук Алтынчәчнең кояшка, Иделгә мөрәҗәгате бар, һәм ул, халык иҗатындагыча, берничә тапкыр кабатлана. Кыз Җикнең язмышын да Кояш белән Иделгә ышанып тапшыра, аны сакларга куша. Яшьләргә аккошлар да ярдәмгә килә, алар да да либреттода очраклы түгел. Беренчедән, аккош образы әсәрнең нигезен тәшкил итүче “Җик-мәргән “ дастанында очрый, икенчедән, кошларга атап язылган әкиятләр, җырлар халык телендә искиткеч күп.

Әйткәнебезчә, драматик поэмада чынбарлык белән “шигыранә ялган” үрелеп бара. Нәкъ менә шул сәбәпле тел тукымасндагы татар халык иҗатына хас кояш, ай, йолдызлар белән **чагыштырулар** гаять табигый тоела. К*ояш шикелле якты, талдай зифа буйлы, айдай күркәм йөзле* Атынчәч тышкы матурлыгы белән генә түгел, рухи дөньясының сафлыгы, пакълеге белән дә күркәм. Ул – ирек сөюче халыкның матурлыкка, рухи азатлыкка омтылуын чагылдыручы символик образ. Курку белмәс татар егетләренең гәүдәләнеше булган Җик образы аша халыкның сынмас рухына, горур табигатенә ишарә ясаганда да, авторга табигать күренешләрен, хайваннар, үсемлекләр дөньясын киң чагыштыру объекты итеп куллану ярдәмгә килә: *яшен төсле үтегез ялтырап; арслан кебек сугышып үлде; киек казлар кебек тезелеп; карурмандай уйчан;кара таудай буйчан һ.б.*

Әсәрнең төп темасы – халык патриотизмы. Үз геройларының батырлыгын, матурлыгын **эпитетларда** чагылдырганда, шагыйрь еш кына сихри табигать күренешләренә мөрәҗәгать итә: *якты йолдызларым, шаян кондызларым һ.б.* Туган җиренә, аның табигатенә гашыйк ватанпарвәр аларны җанга ятышлы эпитетлар аша күз алдына китереп бастыра: *яшел хәтфә алан, ялгыз янар йолдыз, карагайлы карурман, кар түбәле кара тау һ.б.* Поэмада иркен туган ил, туган йорт образын гәүдәләндерүче дала да күп төрле эпитетлар аша тасвирланган: *ерак дала, киң дала, иркен дала.*

Драматик поэманың теленә образлылык, күтәренке яңгыраш өстәүдә автор алыштырып әйтүләрнең бер төре - **перифразга** өстенлек бирә. Халыкның ирек символын, бәхет кошын гәүдәләндерүче Алтынчәчне, баш имәс халык улы Җикне сурәтләгәндә дә, әйтәсе фикеренә образлылык, теленә сыгылмалылык чараларын җанына якын туган табигатьтән таба ул. Алтынчәч – *таң йолдызы ,гөл чәчәге, асыл кош һ.б*. Җик – *ирекле тау бөркете, кара тауның курыкмас батыры, лачыным...*

Билгеле булганча, **гиперболизм** - халык иҗатында киң таралган алым. Муса Җәлил гиперболик формада кулланган чагыштыру объектлары Җикнең генә түгел, бөтен татар халкының тарихи каһарманлыгын күз алдына китереп

бастыра: *арслан кебек ябырылды бит*! Гиперболалар, бер яктан, халыкның көчен, мораль сафлыгын, мәңгелек булу идеясен ачу өчен хезмәт итсә, икенче яктан, алар дошманның явызлыгын нәкъ әкияттәгечә сурәтли: *куәте Салсалга тиң, алтмыш батман кылычы, ун филгә тора көче...*

Либреттода сурәтләнгән җир, су, кояш, ай, табигать күренешләре, үсемлекләр, хайваннар, кошлар – барысы да образ барлыкка китерүгә, поэтик тасвирлауга һәм, иң мөһиме, фәлсәфи фикер үткәрүгә хезмәт итәләр. Алар табигатьнең матурлыгын, байлыгын, илаһилыгын, көчен күрсәтәләр, мәңгелек булырга тиешлеген искәртәләр. Кеше – табигатьнең бер өлеше, аңлысы, көчлесе. Ул җиребез һәм суыбызны, җан ияләре сулый торган һаваны, үсемлекләр, хайваннар дөньясын якларга һәм сакларга тиеш. Муса Җәлил фикеренчә, Кеше – җирнең, табигатьнең иминлеге өчен җаваплы.

## Рус балаларын татар теленә өйрәткәндә экологик һәм әхлакый тәрбия бирү.

***Минзәлә шәһәре муниципаль бюджет***
***гомуми белем бирү учреждениесе***
***“ 1нче санлы гомуми белем бирү мәктәбе”нең***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы***
***Асманова Люзя Киядим кызы.***

Рус балаларына татар телен укытуның төп максаты - гамәли максат: телне аралашу чарасы буларак үзләштерү өчен, укучыларга гаилә-көнкүрешкә, уку хезмәтенә бәйле сөйләм ситуацияләре кысаларында белем бирү һәм күнекмәләрен үстерү. Шушы максаттан чыгып, тәрбияви бурычлар билгеләнә.

Әхлакый-экологик проблемалар-кешелекнең иң мөһим проблемаларының берсе. Алар белән безнең һәрберебезнең язмышы бәйләнгән. Еш кына “экология” сүзе “табигать” һәм “тирә-як яшәеше” дигән сүзтезмәләр белән бергә тора. Соңгы вакытта бик еш кына “экология” сүзе һәлакәт сүзе белән күбрәк кулланыла башлады.

Экологик культура-шәхескә экологик тәрбия һәм белем бирү. Мәктәп һәм экологик культура – бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә булган төшенчәләр.

Укучыларның дөньяга караш даирәләрен киңәйтү, аларны табигатьне сакларга, аңа мәрхәмәтле, игътибарлы булырга өйрәтү, туган җиребезне ярату, аның белән горурлана белү хисе тәрбияләү - иң төп максатларның берсе. Укучыларга экологик белем һәм тәрбия белән бергә милли, әхлаки тәрбия бирүнең үрелеп баруы мөһим шарт булып кала.

Дәреслекләрдәге әсәрләр балаларны табигатьне аңларга, яратырга, аның байлыкларына сакчыл караш формалаштырырга, туган җирнең кадерен белергә өйрәтә. Г.Тукай, А.Алиш, Х.Туфан, Ш.Галиев, Р.Вәлиева һәм башкалар шигырьләрендә җәнлекләрне, кошларны, бөҗәкләрне яратырга, аларга мәрхәмәтле, шәфкатьле булырга өнди, нәфис сүз, сәнгать чаралары ярдәмендә Җир-анага игелек, хөрмәт хисләрен уяталар, шигъри бизәкләре белән табигатьнең гүзәллеген ачып, кешелекнең экологик һәлакәт каршында торуын да искәртәләр.

Соңгы елларда табигатьне саклау, балаларга экологик тәрбия бирү ин зур проблемаларнын берсе булып тора. Чөнки сулаган һавабыз, эчкән суыбыз пычранып бетә, үстергән җиләк-җимешләребез төрле авырулар китереп чыгара башлады. Табигать, бөтен тереклек зур куркыныч астында калды. Тирән сулы елгалар, яшел болыннар кая китте? Табигатьнең бөтенлеге, киләчәге кеше кулында. Серле табигатьне, зур дөньяны ничек сакларга?

Экологик тәрбия бирүдә хезмәтнең әһәмияте аеруча зур. Шуңа күрә кошларга оялар, җимлекләр ясау, бүлмәдәге гөлләрне тәрбияләү, бакчадагы язгы, көзге эшләр турында сөйләшү бик мөһим. Укучылар җимлеккә очып килгән кошларның рәсемнәрен дә ясыйлар, кышлаучы кошлар, күчмә кошлар, үсемлекләр, дару үләннәре һәм башка табигать темаларына кроссвордлар төзиләр, төрле сюжетлы рәсемнәр буенча хикәяләр язалар. Фәнни-гамәли тикшеренү эшләре дә туган як табигатен саклау, Җир-Анабызга карата ихтирам, сакчылык хисләре тәрбияләү максатыннан чыгып үтәлә.

Табигатьне саклау – ул үзебезне, киләчәгебезне, өебезне саклау дигән сүз ул. Без үзебездән соң килгән буынга кешеләр тарафыннан җимерелгән бушлык түгел, ә шаулап чәчәк атып утырган җир калдырырга тиеш.

Рус телендә сөйләшүче балалар өчен уку-укыту предметының бүленеше темалап бирелгән: “Мәктәп тормышы”, “Мин – өйдә булышчы”, “Минем дусларым, минем яшьтәшләрем”, “Ял итү”, “Өлкәннәр һәм без”, “Бәйрәмнәр”, “Без спорт яратабыз”, “Табигать һәм без”, “Туган җирем – Татарстан”, “Һөнәр сайлау”, “Беренче хисләр”. Нинди тема булуга карамастан, рус балалары белән эшләгәндә дәреснең оештыру өлешендә ел фасыллары, аларның бер-берсеннән аерылып торуы, кабатланмавы, тере һәм тере булмаган табигать арасындагы бәйләнешләр турында ел дәвамында белем бирергә тырышам.

Дәресләрдә табигать күренешләре, ел фасыллары, бөҗәк, кош, җәнлекләр турында әхлакый эчтәлекле табышмаклар, мәкаль-әйтемнәр, сынамышлар, бәйрәм-йолаларны еш файдаланырга мөмкин. Нардуган бәйрәме, Сөмбелә, Карга боткасы һ.б. бәйрәмнәр белән танышу ерак бабаларыбызның табигать белән бер бөтен булып яшәгәннәрен күзалларга ярдәм итә.

Әхлакый-экологик белем һәм тәрбия бирүдә әдәби әсәрләрнең әһәмияте зур. Табигатьне саклау – милләтебезне, туган телебезне, гореф-гадәтләрне, рухи һәм тарихи байлыкларны саклау белән тыгыз бәйләнгән. Чөнки туган тел, әдәби һәм тарихи мирас газиз җиребездә барлыкка килгән. Шуңа күрә балаларны татар халкының рухи тамырлары, ерак бабаларыбызның яшәү рәвеше, һөнәрләре белән таныштыру, аларда милли горурлык тәрбияләү мөһим. Табигатьнең матурлыгын, серлелеген Тукаебыз үзенең җаны, саф күңеле, йөрәк җылысы салынган шигъри юллары белән укучы җанына, аның күңеленә салучы, ныгытучы, мәңгеләштерүче. Хисләр, хыяллар дөньяны танып белүнең башлангычы ул. Г. Сабитов "Ярсулы яз", Г. Бәширов "Туган ягым – яшел бишек” әсәрләрендә кеше һәм табигать мөнәсәбәтләре, табигатьне саклау мәсьәләләре үткен итеп куела.

Татар теле дәресендә дә белем һәм тәрбия бирү бергә алып барыла. Мәсәлән, табигатьне саклауга, табигать байлыкларын кешенең ничек файдалануына багышланган диктант, изложение, иншалар яздыру балаларда табигатькә сак караш һәм кайгыртучанлык тәрбияли, үзләренең дуслары этләр, песиләр турында хикәя язу да уңай нәтиҗәгә китерә. Табигать куренешләрен

тасвирлаган картиналар өстендә эш, газета- журнал материаллары- барысы да экологик тәрбия бирүгә ярдәм итә. Текстлар буенча эшне төрлечә оештырырга мөмкин: текстка исем куй, текст буенча план төзү, текстның ахырын яз, сораулар төзе һ.б.

Әхлакый-экологик тәрбия буенча төрле эш алымнары куллану- табигатькә, тормышка икенче төрле күз белән карарга, җаваплылык хисләрен аңларга ярдәм итә.

Кулланылган әдәбият:

1. А.М. Низамов Милли мәктәп тәрбия нигезләре.- Казан: "Мәгариф" нәшрияты, 2005.

2. Д.Ф. Заһидуллина Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: "Мәгариф" нәшрияты, 2000.

3. И.Ә. Гафаров. Туган як мирасы. – Казан, 2004.

4. Р.Ә. Сәхипова Халык педагогикасы нигезендә укыту һәм тәрбия бирү. –Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2005.

## Серле сөлгеләрдә еллар авазы

***Ахмәтҗанова Рушания Мөниркызы***
***беренче квалификация категорияле***
***технология укытучысы***
***ТР Мөслим муниципаль районы***
***"Түбән Табын сәламәтлекләре чикләнгән***
***балалар өчен мәктәп-интернаты"***

Район үзәгендә әледән-әле авыл көннәре бәйрәм ителә. Анда авылларның хезмәт алдынгылары хөрмәт ителә, алар эшләгән эшләргә йомгак ясала, җыр-бию һәм әлбәттә инде авыл осталарның кул эшләре күргәзмәсе дә куела. Шул күргәзмәләрнең берсендә күңелгә якын, ниндидер җылылык бирә торган нәкышләре белән үзенә җәлеп итә торган чигүле сөлге дә урнаштырылган иде.

Сөлге хуҗасы – 1881 нче елда Тойгелде авылында туган Бибикафия Абдулла кызы. Колхозлашу елларында аның ире - Мөхәммәтзариф колхозга керми. Шул сәбәпле аны сөргенгә җибәрәләр. Үз хезмәт көче белән тормыш иткән гаиләдә тынычлык югала. Бибикафия унбер бала белән авылда кала. Ул инде күптән вафат, ә аның иҗат җимеше, чигүле сөлге, изге ядкарь булып, кызы Зарипова Мәрьям апага күчкән. Шул сөлге районыбызның кул осталары күргәзмәсенә куела һәм нечкә күңелле шагыйрә – Лилия Садриеваның күңел кылларын тибрәтә һәм кәгазь битләренә шигырь булып басыла.

Алтын куллы халкым сынатмаган
Моңайса да авыр кайгыдан...
Күз алдымда олуг тарих ята,
Серле җепләр белән каелган.

Ерак үткәннәрдән истәлек бу
Бер гасырлык тарих кулымда
Авыр еллар аңа уралганнар
Җөйләр өстәгәннәр юлында.

Сугышын да күргән, кайгыларын,
Ачлыкның да тәмен татыган
Төсләренә кадәр саклый белгән
Димәк, сөлге татар затыннан.

...Иңнәрендә булган тормыш йөге,
Тилмерсә дә телем икмәккә
Телләреннән җырлар өзелмәгән
Таң каламын шушы хикмәткә.

Аулагөйле, нурлы ызбаларга
Гармун моңы кергән сызылып
Сөлге чиккән кызлар кич утырып
Берсен-берсе хәтта уздырып...

Нинди булдың соң син, әй гүзәл зат

Күз нурларың түгеп сөлгегә

Күңел назларыңны тояр өчен

Китергәнсең безгә – бүгенгә.

Әй, шушы кызны, гади сөлге өчен

Кулларыннан килде үбәсем.

Бөек тарих сөлгеләре белән,

Кабатланмас үткәннәре белән,

Бик кадерле безгә күрәсең.

Гүзәл җирем минем,

Зәңгәр күзле җирем

Күзләремә карыйсың моң белән

Суларыңның тәмен, чәчәкләрнең ямен

Саклар кеше мәңге, мәңгегә.

Матурлык китә икән ул, сөлгеләр булып тарала икән. Бу матурлыклар әбиләребезнең күңел җылысын саклаган хәлдә киләчәк буыннарга барып ирешсен иде. Шушы сөлгеләрне кулга алгач, күңелдә үткән белән бүгенгенең өзелмәс чылбыры барлыкка килсен иде.

Радиодан җыр агыла. Ул күңелне еराклардан моңландыра. Җыр хатирәләрне яңарта, үткәннәргә алып кайта.

Бер кайтмасам, әнкәй, бер кайтырмын

Утыңны сүндермичә мине көт.

Көттереп тә кайталмасам

Кичер мине, әнкәй, гафу ит.

Мәрьям әби оекбаш бәйләп утырган җиреннән туктап калды. Чал чәчле башын күтәреп, әле нурлары да сүнеп бетмәгән күзләрен тәрәзә аша олы юлга төбәде. Әлеге моң үткәннәрне искә төшереп, агылды да агылды.

Хатирәләр белән шушы җырның моңына җепләр сузылдылар. Җылы нур, дулкынландыргыч минутлар булып искә төштеләр һәм күптән үткән көннәргә алып кайттылар.

1930-1931 нче елларны колхозлашу еллары башлана. 1935 нче елда безнең авылда да колхоз төзелә. Ул колхоз “Кызыл сабанчы” дип аталган . Колхозлашу чорының изге ядкәре булган “Уракчы кыз” җыры хәтергә килә. (Нәкый Исәнбәт шигыре)

Ай урагың салып иңбашыңа,
Кояш нурларыннан нур алдың:
Кояш нурларыннан нур алдың да
Салкын чишмәләрдән су алдың.
Басма өстенә басып су алганда
Кулъяулыгың кемгә болгадың
Талир тәңкәләрең чыңлаганда
Кем исеменә җырлар җырладың.

Зарипова Мәрьям Мөхәммәтзариф кызы 1921 нче елда Мөслим районы Тойгелде авылында туган. Мәрьям апа сөйли: “15 яшьтән урман кисү эшенә йөрдем. Шуран тауларыннан агач кисеп ташыдык. Фермалар элек бик еракта – Түбән Табын авылының шифа чишмәсе тирәсендә иде. Шунда җәй көне җәйләүгә эшкә йөрдек. Әткәй колхозга кермәде. Аны раскулачивать иттеләр. Йорттагы барлык әйберне алып чыгып киттеләр. Әле укуга да юньләп йөртмәделәр. Һәрдаим сәер караш, читкә этәрүне сизеп тордык.

Сугыш чоры барыбыз өчен дә бик авыр еллар булды. Мине бригадир итеп куйдылар. Совхозга көндез эшли идек, үзебезгә төнлә эшләдек. Трактор чанасына утырып кар астында калган саламны эзләп, Балтамакка чаклы чатнама салкыннарда бара идек. Орлык, ягулык алып кайтырга ат җигеп Чаллыга бара идек. Бер юлда 2-3 көн йөреп кайта идек. Атларны ашатырга юк. Төнлә басудан урлап печән алып кайтабыз. Үзебезгә ашарга дип алган бәрәңгеләрне атка ашаттык.

Бер көнне авыл советы җитәкчесе килә. Бер малайны Бөгелмәгә военкоматка илтергә куша. Мин ат җигә белми идем әле:атны җигеп бирделәр. Малайны илтеп тапшырдым военкоматка. Кайтканда квартирага кердем.

Икенче көнне теге малайны урамда очраттым: өстендәге киемен, ашарына төйнәгән төенчеген талап алганнар. Малайны кире авылга алып кайттым.

Ачлык-ялангачлык башланды. Авырулар таралды. Абыем 9 көн буена урын өстендә тиф авыруы белән чирләп ятты да үлде. Гаиләдәге 11 баладан мин берүзем калдым. Әниемне ялгызын калдырасым килмәде, саулыгы да чамалы гына иде. Әниемне олыгайган көнендә тәрбияләдем һәм хасиятләп күмдем".

Хәзер Мәрьям апаның бар теләге – сугышлар булмасын иде. Сугыш аның яшьлеген алды, сәламәтлеген алды, кияүгә дә чыгарга өлгермәгән килеш егетен алды. Кич утырып әзерләгән бирнәлекләре, челтәрләре, чигүле сөлгеләре кулланылмыйча, бүген бәйләгән кебек, сандыкта яталар. Мәрьям апа кияүгә дә чыкмыйча ялгызы калды, гаилә кора алмады, балалары булмады. Гомеренең соңгы елларын район үзәгендә урнашкан картлар йортында тәрбияләнде. Үзен караучыларга, тәрбия итүчеләргә, картлык чорында өлкәннәрне карау урыны булдырган җитәкчеләргә, илебездә булган шушы вәзгыятькә ул бик рәхмәтле булып үзенең мәңгелек йортына китте. Мәрьям әби илебезнең меңнәрчә хатын-кызларыбызның берсе иде.

Үткән еллар онытыла, диләр
Кала, диләр, берчак югалып
Алар яшәр тарих битләрендә
Серле сөлгеләргә уралып.

## Татар әдәбиятында туган ягым.

***Әмирова Миләүшә Рөстәм кызы,***
***Мөслим муниципаль районы муниципаль бюджет***
***белем бирү учреждениесе "Түбән Табын төп гомуми***
***белем бирү мәктәбе"нең татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

Һәркем зурлый үзенең туган ягын
Мактап җырлый аның исемен.
Тик нигәдер иң-иң мактаулысы-
Синдер төсле, газиз Мөслимем.

Л.Садриева.

Безнең туган җиребез- Мөслим районы. Ул Татарстан республикасында иң-иң матур төбәкләрнең берсе.

“Бездә тургайлар яз көннәрендә ак болытларга басып сайрыйлар, җәй көннәрендә рәшәле басу өстендә туй ясыйлар, башак эчләренә кереп бала чыгаралар. Шуңа күрә бигрәкләр дә газиздер бу җирем. Шуңа күрә артык яратамдыр Мөслим якларын”,- дип яза Мөслимдә яшәп иҗат итүче язучы Фоат Садриев.

Укучыларга экологик һәм әхлакый тәрбия бирүдә үзебезнең төбәк турында иҗат иткән язучыларның иҗатын өйрәнүне дә кирәк дип уйлыйм. Шул максаттан чыгып, әсәрләрне класстан тыш уку дәресләрендә, китап укучылар конференцияләре үткәргәндә куллануны кулай дип саныйм.

Минем максатым Мөслим турында язылган һәр әсәргә анализ ясап чыгу түгел, әлбәттә. Шулай да, татар язучыларының Мөслим төбәген яктырткан, аеруча үзебезнең Табын төбәген, ягъни Түбән Табын җирле үзидарәсенә караган авылларны (Тамьян, Түбән Табын, Тугаш авыллары) тасвирлаган әсәрләренә тукталу.

Узган гасырның 60-70 нче елларында татар язучылары, композиторлар, шагыйрьләр һәм артистлар авылларга чыга торган булганнар. Авыл хезмәтчәннәре белән очрашулар, сөйләшүләр ике як өчен дә файдалы булган. Безнең Мөслимебезгә дә (ерак, юлсыз дип тормаганнар) шактый каләм әһелләре, артистлар килеп киткән ул елларда. Шагыйрьләрдән Х.Туфан, И.Юзиев, М.Шабаев, язучылардан Ф.Хөсни, Р.Ишморат, Р.Ишморатова, композиторлардан С.Садыйкова, М.Яруллин, З.Гыйбадуллин һәм башкаларны өлкәннәр әле хәзер дә сагынып искә ала. Шундый делегацияләрнең берсе безнең якларда 1968 нче елда булып китә. Аның составында язучылар Ф.Хөсни, А.Расих, шагыйрь И.Юзиев, язучы-драматурглар Р.Ишморат һәм Р.Ишморатовалар була. Алар турында язма, фотолар мәктәп музеенда саклана.

Ә язучы- галим Атилла Расих “Ык суы буенда” повесте (1961) белән туган ягымның эчкерсез, гади һәм беркатлы, әмма хезмәт сөючэ игенче-

терлекчеләрен, аларның тормыш- көнкүрешләрен яратып тасвирлады. “Партия өлкә комитеты билгеләве буенча, миңа белгеч буларак, алтмышынчы елларда Мөслим районының терлекчелегенә шефлык итәргә туры килде. Мин Ык суы буендагы районның бик күп авылларында булдым, андагы тормышны белгеч күзлегеннән генә түгел, әдәбиятчы буларак та өйрәндем. Повесть исә шундагы тәэсирләр нәтиҗәсендә язылды”,- дип язган А.Расих.

Шушы чараның бер “эзе”, истәлеге булып Ф.Хөснинең “Тау чишмәсе” (1968) хикәясе мисал булып тора. “Минем өемдә, кунак бүлмәсендә, пианино өстендә кышын да, җәен дә төс салмый торган кылган букеты тора. Кайбер җирләрдә (нәкъ менә безнең Мөслимдә дип укырга кирәк) кылганны “әбиләр чәче” дип тә йөртәләр икән. Бу кылган букетын миңа узган җәй башында Мөслим районында әдәбият атналыгы уздырып йөргәндә, истәлек өчен дип, җыеп биргәннәр иде. Ямьле Ык елгасы буенда, кошлар җырына күмелгән тирәкле тугайларда, төннәрен ярда учак ягып, уха пешереп ятучы балыкчылар янында булдык, бай табигать һәм бай күңелле кешеләр күрдек без бу якларда”,- дип башлап китә язучы үзенең әсәрен. Ф.Хөснигә хас җиңелчә юмор да, гади авыл кешесенә, аның кылган гамәлләренә соклану һәм ихтирам да чагыла хикәядә. Хикәя зур түгел. Әмма шушы кечкенә генә хикәядә безнең як, аның кешеләре, безнең табигатебез, атаклы Шифа чишмәбез тасвирланган, шуның өчен кыйммәт ул безнең өчен.

Хикәянең исеменнән күренгәнчә, сүз чишмә, аның даны, дәвалау үзенчәлеге турында. “Ык буендагы бер чишмәгә алып киттеләр безне...Инде чишмәнең үзенә килсәк, ул башка бик күп чишмәләр кебек тауның төбеннән түгел, тауның урта мөешеннән дә түгел, тауның башыннан бәреп чыга. Чыгып түбән таба бераз аккач, бермәл күбекләнеп, ургылып тора, аннары тагы үзе салган борма-борма юлдан. Агач тамырлары һәм ташлар арасыннан, күбекләрен чәчрәтә - чәчрәтә, үзенчә кылана- кылана, түбәнгә - Ык елгасына таба агып китә.

Чишмәнең тагын бер хасияте шунда: бу як кешеләре аны “Шифалы чишмә” дип йөртәләр. Авыру- сырхау тигән кешеләр, бигрәк тә олы- ерак юлны якын итеп шушы чишмәгә килә. Коенып, суын эчеп, әл-хәл ала, имеш”.

Хикәянең геройлары - безнең төбәк кешеләре. Колхоз рәисе Асылгәрәевның прототибы Шәйхрамов Хәкимулла абый. 25 елдан артык районның иң зур хуҗалыгы- М. Вахитов исемендәге колхозны җитәкләгән ул. Бүгенге көндә мәрхүм инде.

Шагыйрь Марс абый Шабаев та 1967 нче елда безнең районда ял итә, дөресен генә әйткәндә, иҗади командировкада була. Гаиләсен дә алып килә ул. Районыбызның иң матур авылларының берсе Нарат Астында Мортаза бабайларда бер айлап яшиләр алар. Марс абый “ял белән хезмәтне бергә бәйләп” алып бара. Нарат Асты авылы, аның тирә-ягы, табигатен, Ык буйларын күзәтә, өйрәнә. Озакламый аның “Салда сәяхәт”(1969) дигән повесте басылып чыга.

Үзләре төзегән “Шыртлака” салына утырып, яшьлек романтикасы белән янган дүрт егет- Сәгыйть, Нәгыйм, Әбелмән- Әпләй, Мәхмүт- Ык елгасы буйлап сәяхәткә чыгалар. Старт нәкъ Мөслим күпере яныннан башлана. Егет-ләр Ык тамагына кадәр агалар, күзәтүләр алып баралар, төрле маҗараларга юлыгалар...

Повестьта географик атамалар, топонимика шул килеш калган. Сәяхәтче егетләрнең юлы безнең авыллар яныннанда үтә. ”Шифа чишмәсенең серләре” бүлегендә әлеге дә баягы атаклы тау чишмәсе турында сүз бара. Чишмә турындагы легенда да китерелә. Тамьян авылын (автор аны Тамиян дип биргән, дөресе- Тамьян- Тәмьян) турында язылган урыннарын кат- кат укыйм. “Биек тау итәге буйлап сузылган яшел дуга- урман. Урманның иң биек җиренә-түбәсенә үк менеп Тамиян якларына карап торган иде бит Сәгыйть. Шундый рәхәт! Беркая барасы да, кузгаласы да килми. Биредә һәрнәрсә гади, аңлаешлы, беркем борчымый. Баһадир урман уртасында син берүзең.

Аргы якта болын юлыннан машина йөгерә, Тамиянга бугай. Тигез юлда ул нәни бер кырмыска шикелле генә булып күренә. Өстән, биектән караганда

шулайдыр инде ул”,-дип тасвирлап бирә М.Шабаев “Салда сәяхәт” әсәрендә. Без дә җәй көне җиләккә чыккан саен шул тау түбәсенә күтәрелеп, Тамьян авылын күзәтәбез, тирә- як табигате белән хозурланабыз.

Мөслим районының төньяк-көнбатышында урнашкан Табын төбәге турында гына да күренекле язучылар язып чыккан икән “юкка түгел, юкка түгелдер!” Әсәрләр аша укучыларда безнең төбәкнең матурлыгын, халкының тырышлыгын күрә белергә өйрәтү. Горурланам мин үзебезнең туган як турында язучыларның иҗат иткән әсәрләре белән.

Кулланылган әдәбият


1. Атилла Расих “Әсәрләр”, I том, Казан, 1986.- 305бит.

2. Әхмәтҗанов М.З. Якташ әдипләребез.- Актаныш. Актаныш типографиясе Дәүләт унитар предприятиесе, 2002ел.- 52 бит.

3. Хөснетдинов Ф. Х. Бер яшьлектә, бер картлыкта: Повестьлар, хикәяләр.- Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1988.- 495 бит.

4. Шабаев М.С. Салда сәяхәт.- Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1977.–170 бит

5. “Мирас” журналы, №7, 2007.


## Халкымның батыр улы Муса Җәлилнең тормышына күзәтү.


***Әмирова Рәзимә Касыйм кызы***
***Алабуга шәһәре 4 нче гимназиясенең татар теле***
***һәм әдәбияты укытучысы.***


Оренбур губернасында бар бер авыл-Мостафа.
Тырышып яшәгән шунда халык, кормаган кәеф-сафа;
Бу авыл шагыйребезнең туган авылы булган,
Шунда, крестьян гаиләсендә, безнең Мусабыз туган.

Габделҗәлил улы Мостафа- Мусабызның әтисе,
Гаиләсе белән шәһәрдә килгән аның яшисе;
Нинди генә кәсеп белми, гади крестьян булса да,
Авылына кире кайткан, аннан ачлык куса да.

Унөч яшь чагында әтисез, Мусабыз, ятим кала,
Башта авылда, аннары мәдрәсәдә белем ала;
Октябрь Революциясе аннан комсомол ясый,
Шушы елларда Мусабыз шигырьләр яза башлый.

Шигырьләрен газетага бастырырга бирсә дә,...
Бастырмыйлар.“Европа сугышына каршы язган.”-дияләр;
Оренбурны акгвардеецлар чолгап алганга күрә,барыбер дә,
Ак бандага нәфрәт тулы ун шигыре дөнья күрә.

Аннан Муса әтисе үлгәч, үз туган авылында
Комсомол оешмасы төзи һәм аның рәисе була;
Шулай итеп “Кызыл йолдыз” оешмасы эшләп китә,
Укучы балалар, авыл халкы аны бик тә хөрмәт итә.

Мең тугыз йөз егерме бер...Каты ачлык. Муса инде
Йөз илле чакрымны җәяүләп шәһәр-калага юл тота;
Шәһәрдә дә тормыш авыр:киемгә, ризыкка кытлык,
Яшәү кайда да бик авыр, һәркемне ач үлем куркыта.

Кайда туры килде шунда ашап-кунып йөргән чакта,
Муса элекке укытучысы-Нургали аганы очрата;
Нургали ага Мусадан тормыш хәлен сораштыра,
Барысын белешкәч, Мусаны хәрби мәктәпкә урнаштыра.

Бу мәктәптә укучылар гаскәри хезмәт үтиләр,
Яшь кенә булсалар да,үзләре, зурларга сер бирмиләр;
Сугышка киткәннәрне алмаштырып,шунда, тылда
Бандаларга каршы көрәшәләр, эшлиләр каравылда.

Бу авыр тормыш Мусаның сәламәтлеген нык какшата,
Ул бик каты авырып, елга якын хастаханәдә ята;
Терелеп чыккач та, яңадан үзе укуга алына,
Мәдрәсәгә түгел, инде, педагогия уку йортына.

Шигырь белән кызыксынып, яңадан шигырьләр яза,
Үзлегеннән Хәйям, Хафизларны  укып белем ала;
Романтик рухта язылган шигырьләре дөнья күрә,
Муса мең тугыз йөз егерме икенең көзендә Казанга килә.

Казанда язучылар белән танышып, иҗат эшенә кереп китә,
Реаль чынбарлыкны күреп, икенче рухта иҗат итә;
Рабфакка укырга керә, редакциядә дә эшли,
Тормыш авыр диеп тормый, бернәрсәгә дә бирешми.

Шигырьләрендә дә Муса реаль тормышны чагылдыра,
Мең тугыз йөз егерме биштә “Барабыз”җыентыгын бастыра;
Аның кулы белән әле бик күп пьесалар да языла,
Кайберләре, хәтта, Казан,Уфа сәхнәләрендә куела.

Яңадан Орск өязенә, Оренбур ягына  кайтып,
Комсомол комитетында эшли ул,үз эшен бик яратып;
Комсомол эше аның тормыш тәҗрибәсен баета,
Мусабызны чыныктыра, дөньяга карашын яңарта.

Мең тугыз йөз егерме җиде,утыз өченче еллар...
Мәскәү дәүләт университетында белем алган вакытлар,
Аннан балалар журналларында ул җаваплы редактор,
“Коммунист”газетасының бүлек җитәкчесе дә тагын.

Мәскәүдә эшләү дәверендә дә иҗаты нык активлаша,
Шигырьләре дә бу чорга аеруча характерлаша;
Оригиналь опералар өчен либреттолар иҗат итә,
Күп кенә рус операларын татарчага тәрҗемә итә.

Мең тугыз йөз утыз тугызның апрель ае.Яз.Матур.
Татар совет язучылар идәрәсе председателе ул;
Муса Җәлил туган якта. Муса Җәлил Казанда.
Депутат итеп сайлана ул шәһәр советына.

Мең тугыз йөз кырык бердә явыз дошман сугыш башлый,
Бу сугышны Муса Җәлил танылган әдип булып каршылый;
Шушы елның июлендә Муса да армиягә алына,
Рядовой кызылармеец булып керә ул сугыш кырына.

Төньяк-көнбатыш фронтның иң алгы сызыгында
“Отвага”исемле газетның корреспонденты була;
Кырык икенче елның июне, Волхов юнәлешендә,
Җәлил каты яраланып, эләгә дошман кулына.

Шушы көннән патриот шагыйрь фашист тоткынлыгында,
Үзенең газаплы һәм героик тормышын башлый шунда;
Каһарман көрәшче буларак яшерен оешма төзи,
Ватанына тугры кала, дошманга һич бирешми.

Язмыш Җәлилгә бер-бер артлы авыр сынау әзерли,
Әмма шагыйрь куркып калмый, сынауларда бөгелми;
Шагыйрь ахырынача ача үзенең рухи байлыгын,

Дошманга каршы юнәлтә нәфрәт тулы шигъри угын.

Муса Җәлил әсирлектә дә язуын һич туктатмый,
Шунда туган “Моабит дәфтәре”аның поэтик иҗаты;
Моңа шаһит тоткынлыкта язган бар шигырьләре,
Батырлык үрнәге ул Муса һәм аның көрәштәшләре.

Кырык дүртнең февралендә Дрезденда суд була,
Гаеплиләр “дәүләткә каршы җимерү эше”алып баруда;
Шул ук елның август ае, Плетцензее төрмәсе...
Шул төрмәдә унбер җәлилченең гомере өзеләсе.

Җәлилдә  һәм иптәшләрендә тиңдәшсез рухи ныклык,
Ватанына бирелгәнлек, көчле сөю, батырлык;
Җәлилгә Советлар Союзы Герое исеме бирелә,
Җыентыгы лаек була Ленин премиясенә.

Ул Җәлил поэзиясенең иң югары ноктасы,
Иҗатыннан күренеп тора, Җәлил -шигърият остасы;
Анда аның кичерешләре, фәлсәфи уйланулары,
Халкына чиксез мәхәббәт,җиңүгә ышанычлары.

Моабит дәфтәре шагыйрьнең лирик көндәлеге ул,
Муса шигырьләрендә өнди: “Илеңә тугрыклы бул!
Дошман каршында бирешмә бернинди сынауларга,
Илең туфрагын таптарга юл куйма дошманнарга!”

Моабит шигырьләре шагыйрьне бөтен дөньяга танытты,
Төрле ил халыкларында алар дуслык, ышаныч тапты;
Эмоциональ эчтәлекләренә зур игътибар бирелде,

СССРдагы барлык милли телләргә тәрҗемә ителде.

Тагын инглиз, француз, испан, немец,гарәп һәм япон,
Венгр, румын, чех, корея халкы өчен дә ул якын;
Бу әсәрләр кешеләрдә гуманистик тойгы уята,
Халкым үзенең батыр улын һич онытмый, ярата!

Муса Җәлил безнең туган, ә без аның туганы,
Мәңгелеккә истә калыр, онытмабыз без аны;
“Безнең өчен үлгән шагыйрь-улы татар иленең”-
Диеп яза, Луи Арагон-бөек француз шагыйре.

Муса Җәлил безнең өчен балкып торган кояш күк,
Аның исеме чуваш халкы өчен дә зур горурлык;
“Чөнки Муса-безнең күрше,ул кандаш халык ире ”,
Горур әйтә Яков Ухсай,чуваш халык шагыйре.
Килеп җитте шигырьләре немец укучысына да,
Үлем көткән хәлдә язган Моабит зинданында;
“Без бу бөек җанлы көрәшче каршында бик бурычлы!”-
Диеп яза Гюнтер Дейка,бөек немец язучысы.

Муса Җәлилне укыганда, батырлыгын уйлаганда,
Аның гомере күз алдына батырлык булып килеп баса;
Таджик шагыйре Турсун-заде бик тә хаклы: “Онытылмас,
Халык үзе батырларының исемнәрен онытмаса!”

Җәлилнең батырлыгын һич онытма! Көрәшкән ул
Тынычлыкта яшәсен дип, мин һәм дә син;
Бөек шәхесләр дә хаклы,бәхәссез,алар бик хаклы,
Батырларның исеме күктәге сүнмәс йолдызларга тиң!

Халык авыз иҗатына нигезләнеп экологик һәм әхлак тәрбияне үстерү.

ТР Минзәлә шәһәре муниципаль бюджет

гомуми белем бирү учреждениесе

“1 нче урта гомуми белем мәктәбе”нең

татар теле һәм әдәбияты укытучылары

Әһлиева Гүзәл Гаптелрәшит кызы,

Гайнуллина Лилия Габделәхәт кызы.

Балаларда табигатькә сакчыл караш тәрбияләү катлаулы һәм дәвамлы педагогик процесс. Экология, фән буларак, мәктәпнең укыту программасына кертелмәгән. Шуңа күрә экологик проблемаларны табигать фәне дәресләрендә һәм түгәрәкләрдә генә түгел, ә башка фәннәрдә дә, аерым алганда татар теле һәм әдәбият дәресләрендә дә өйрәнергә кирәк. Татар теле һәм әдәбияты дәреслекләре экологик темага язылган бөтен әдәбиятны колачлый алмый, әлбәттә. Ләкин ул шактый күләмдәге әсәрләр белән таныштыра, экологик темаларга мөрәҗәгать итү алшартларын, аларның үзенчәлекләрен билгели. Моннан тыш, китаплар укырга мәҗбүр итә. Укучыларга милли, әхлаки тәрбия белән бергә, экологик белем һәм тәрбия бирүнең үрелеп баруы мөһим шарт булып кала.

Кеше табигатькә никадәр якынрак торса, аның күңеле дә шулкадәр сафрак була. Балалар белән эшләүче мөгаллим бу хакыйкатьне һәрвакыт исендә тотарга тиеш. Сабый баланың әйләнә-тирәдәге үзгәрешләргә карап соклануы, кошлар сайравын тыңлап тәэсирләнүе аның табигать белән кызыксынуын күрсәтә. Менә шул матурлыкны күрә, соклана белү сәләтен, нечкә хис-тойгыларны кечкенәдән үк үстерергә, ныгытырга кирәк.

Һәр сыйныфның әдәбият дәреслегендә халык авыз иҗатының нинди дә булса бер жанрына урын бирелә. Халык авыз иҗатында табигать һәм аны саклау – иң борынгы һәм киң урын алган темаларның берсе. Ул фольклорның барлык төр жанрларында диярлек бар. Халыкның тормыш тәҗрибәсе һәм табигатьне өйрәнү нәтиҗәсендә туган кыска, ләкин тирән мәгънәле өйрәтүләре,

тәрбия алымнары бик гыйбрәтле. Алда әйтелгәннәрне исбат итү өчен без татар төркемнәре өчен төзелгән 5-9 сыйныфларның әдәбият дәреслекләрен тикшереп чыктык һәм түбәндәге нәтиҗәгә килдек. 5 нче сыйныфта Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина, М.Я. Гарифуллина тарафыннан Федераль белем бирү стандартларына туры китереп төзелгән дәреслектә халык авыз иҗатыннан әкият жанры урын алган. Дәреслектә "Ак байтал" әкияте бирелгән.Әкият белән танышкач укучылар ат турында фикер алышалар. Ат сүзләрне аңлый, кешенең халәтен тоя, мактаганга, ачуланганга битараф түгел, гаделлекне ярата.Авторлар хәтта атларны ничек атап йөртүләренә хәтле мисаллар китергән: алмачуар, акбүз, бахбай, бия, күккүз, айгыр, байтал, тай, кашка, тулпар, пони, корчаңгы, чабышкы, алаша, елкы, сөлек, чаптар, юртак, колын, ябага.

Дәреслектә халык авыз иҗатының икенче бер төре – мәкальләр дә урын алган.Кыска, ләкин хикмәтле сүзләр белән халык бик тирән мәгънәле фикерләрне бер буыннан икенче буынга җиткергән; шуңа күрә күпчелек аны "ата-баба сүзе" дип йөрткән.Мәкальләр арасында табигатькә багышланган һәм экологик тәрбияне күз алдында тотканнарын сайлап, дәресләрдә куллану, аларның асылын укучыларга җиткерү дәреснең нәтиҗәлелеген күтәрә, аларда игелекле эшләр башкарырга омтылыш уята. Мәсәлән,"Суга сусаган - чишмә әрчегән", "Агач утырткан - ага булган", "Кул пычранса, су белән юарсың,су пычранса ни белән юарсың?" һ.б. шундый мәкальләрдән файдаланабыз. Ә.М.Закирҗанова, Г.Р.Габделхакова тарафыннан 5 нче сыйныф укучылары өчен төзелгән дәреслектә табышмаклар, әйтемнәр дә бар. Халкыбыз төрле табынулар, ырымнар ярдәмендә кешеләрнең табигатьтә үз-үзләрен тоту кагыйдәләрен эшләгән. Мәсәлән, мондый әйтем бар:"Кош оясын туздырсаң, башың авыртыр". Кем инде үз башының авыртуын теләсен. Татар халкының табигать күренешләре, ел фасыллары, бөҗәк, кош, җәнлекләр турында әхлакый эчтәлекле күпме табышмак бар.

1)Җәен соры ,кышын ак,

Кылый күз, озын колак.

2)Бернәрсә тегә белми,

Энәләр тагып йөри.(керпе)

3)Үлән ашый-май ташый.(сыер)

4) Үзе ул бал ярата,

Кыш буе йоклап ята.

5)Башында үсә куак-

Шуны табып куандык.

Бу җәнлек безгә ошый:

Исеме аның-(поши) .

6)Сорыдыр төсе.

Үткендер теше ,

Урманда йөри.

Бозаулар эзли.(бүре)

Ф.Г.Галимуллин, Ф.К.Мифтиева, И.Г.Гыйләҗев тарафыннан тәкъдим ителгән 6 нчы сыйныф өчен дәреслек җыр жанры белән башланып китә. Җыр кешенең эчке дөньясын, аның хис-кичерешләрен чагылдыра. Вакыт үткән саен, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр һәм аларның дөньяга карашлары да үзгәрә бара. Табигатьне ярату, матурлыгына соклану, кеше тормышының табигатькә бәйле булуы җырларда да чагылыш тапкан. Дәреслектә “Кара урман”, “Салкын чишмә”, “Яшә, Республикам”, “Су буйлап” җырларын өйрәнү тәкъдим ителә. “Яшә, Республикам” җырындагы аккош, былбыл, ал гөл сурәтләре – халык иҗатының барлык жанрларында да еш очрый торган гүзәл образлар. Халык үзенең бүгенгесен, бигрәк тә киләчәген әнә шулай матур итеп күрергә тели.

8 нче сыйныф өчен З.Н.Хәбибуллин,Х.Г.Фәрдиева,Ә.Н.Хуҗиәхмәтов төзегән дәреслектә бәетләр урын алган.”Сак-сок” бәете нигезендә яткан вакыйгалар ана каргышының балаларга төзәтеп булмаслык бәхетсезлекләр китерүе хакында. Ана каргышы аркасында балалары кошларга әйләнеп кыргый урманда очып йөри. Нәфис сүз, сәнгать чаралары ярдәмендә кешедә югалып бара торган иң изге әхлакый-рухи кыйммәтләрне торгызу,хөрмәт хисләре уяту мәсьәләсе искәртелгән.

З.Н.Хәбибуллина,Х.Г.Фәрдиева,Ә.Н.Хуҗиәхмәтов төзегән 9 сыйныф дәреслегендә халык авыз иҗатыннан риваятьләр, легендалар урнашкан.

Риваятьләрне тел-авыз иҗаты рәвешендә сакланып калган халык елъязмасы да дип атыйлар. Әлеге жанрда топонимик риваятьләр (географик исемнәрнең ничек барлыкка килүен аңлата) аеруча зур урын алып тора.Мисал өчен,«Елан тавы», «Кабан күле», «Акай күле», «Тамерлан баганасы», «Бакалтай ярминкәсе» риваятьләрләре. Легендаларның тематикасы бай һәм эчтәлеге төрле. Зоогоник (төрле хайван һәм кош-кортларның барлыкка килүе яки аларның теге яки бу ягын тасвирлау), топономик ( географик атамаларның килеп чыгышын уйдырмага нигезләп аңлату) легендалар укучыларда зур кызыксыну уята.

Туган туфракка сабый чакта җибәргән тамырлар гына кешене ватанлы итә, хәерле итә, бәхетле итә. Табигать баласы икәнлегеңне тою нәкъ шул чорда башлана һәм куе урманнардан, киң кырлардан, яшел болыннардан, тирән сулардан килүче кадерле кунак икәнлегең күңелгә мәңгегә берегеп кала. Билгесез даһиларыбыз иҗат иткән мәкаль һәм әйтемнәр, табышмаклар һәм такмазалар, әкият һәм риваятьләр, мәзәк һәм маҗаралы хикәяләр, җырлар һәм дастаннар әсәрләре аша шушы хис-тойгыларны балаларның күңеленә җиткерү, сеңдерү – укытучының изге бурычы.

Кулланылган әдәбият

1.Ф.Г.Галимуллин, Ф.К.Мифтиева, И.Г.Гыйләҗев Татар әдәбияты: Рус телендә төп гомуми белем бирү мәктәбенең 6 нчы сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия. – Казан: Мәгариф, 2010

2. Ә.М.Закирҗанова, Г.Р.Габделхакова.Татар әдәбияты:рус телендә төп гомуми белем бирү мәкт.8 нче сыйныфы өчен дәреслек.Казан:Татар кит.нәшр,2011

3.З.Н.Хәбибуллина,Х.Г.Фәрдиева,Ә.Н.Хуҗиәхмәтов. Татар әдәбияты:рус телендә төп гомуми белем бирү мәкт. 9 нчы сыйныфы өчен дәреслек.Казан:Татар кит.нәшр, 2011

4.Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина, М.Я. Гарифуллина.Татар әдәбияты:рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек. 5 нче с-ф.- Казан:”Мәгариф-Вакыт”нәшр.,2014.

## Телне саклау – безнең бурыч

***Автор: Әхмәтҗанова Лилия Мөхтәр кызы***

Телне кешелек җәмгыяте тудырган, камилләштергән һәм тел дә, үз чиратында, кешене кеше иткән, үстергән. Шул ук вакытта тел кешелек җәмгыятенең ярдәменә мохтаҗ. Тел яшәсен өчен аның иҗтимагый тормышта кулланылышы артырга тиеш. Шул очракта гына ул функциональ үсеш кичерә һәм җанлы тел булып яши ала. Төрле сәбәпләр аркасында тел тормышта торган саен сирәгрәк кулланылса, ягъни функиональ яктан үсмәсә, әкренләп бу телдә сөйләшүчеләр бетә һәм ул үле телгә әйләнә. Тарихта моңа мисаллар күп. Бүген дә юкка чыгу куркынычы алдында торган телләр бар. Әлбәттә, татар телебезне – Юнеско тарафыннан бөтендөнья аралаша ала дип саналган 14 телнең берсе булган телне – үле тел язмышы көтмәс дип ышанасы килә.

Телебез – безнең тарихыбыз да, киләчәгебез дә. Татар теленең чисталыгы, милләтне, телне саклау зарурлыгы XIX-XX гасыр әдипләре Г.Тукай, Дәрдемәнд, Г.Исхакый һәм башка бик күпләрне борчыган сорауларның берсе булган. Бүгенге көндә бу проблемалар ни дәрәҗәдә чишелгән соң?

Бу хезмәтем – әнә шул лингвоэкологик проблема буенча уйлануларымның нәтиҗәсе.

Лингвоэкология (тел экологиясе) - лингвистиканың тел үсешенә тискәре тәэсир итә торган факторларны, телне баета торган алымнарны өйрәнә тоган фән тармагы. “Экология “ һәм “тел” төшенчәләрен берләштереп куллану беренче тапкыр америка лингвисты Э.Хаугенның “Тел экологиясе” дигән хезмәтендә очрый. Т.В. Жеребилоның “Лингвистик терминнар сүзлеге”ндә исә лингвоэкология сүзе “телләрне саклап калу юнәлешендәге сәясәт” дип аңлатыла.

Кешелек үзен чолгап алган тирәлекне – һава, җир-су, урман-кырларны пычратып, табигатьтә зур экологик проблема тууын соңгарак калып булса да аңлады. Ә бит тирә-як табигать һәм иҗтимагый тормыш бер-берсе белән тыгыз мөнәсәбәттә һәм бәйләнештә торган әйбер-күренешләрдән тора. Кешенең яшәеш тирәлегенең мөһим бер өлешен аның теле тәшкил итә. Тел – беренче чиратта аралашу коралы, фикернең көзгесе. Сөйләшүе һәм язуы буенча кемнең кем икәнлеген чамалап була. “Тел дигән дәрья бар, төбендә энҗе-мәрҗән бар, белгәннәр – чумып алыр, белмәгәннәр – коры калыр”, - ди халык мәкале. Әйе, диңгез төбеннән энҗе-мәрҗән эзләве никадәр кыен булса, сөйләү һәм язу өчен дә сүз сайлау шактый четерекле эш. Сүз сәнгатенең, сөйләм культурасының үсеше милләтнең гомуми культура үсешенә, социаль, иҗтимагый-сәяси хәлләргә бәйле. Татарстанда татар телен дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрү мәсьәләсе 20-30 елларда ук җитди рәвештә көн тәртибенә куелган иде. Ләкин ул вакытта бу юнәлештәге эшләр үзен акламады. Язучы Әмирхан Еники "Татар баласына урысча белмәү куркынычы янамый" дигән мәкаләсендә болай ди: “Татар халкының кимендә яртысы уз телен югалтты. Сәбәбе билгеле: большевиклар партиясенең вак халыкларны, аеруча безнең татарны, әкренләп урыслаштыру сәясәте иде... Хрущев вакытында ук Татарстан шәһәрләрендә, шулай ук күрше өлкәләрнең авылларында да татар мәктәпләре ябылып бетте диярлек... Казанда, мәсәлән, татар балаларының 93 проценты урыс мәктәпләренә күчте. Утыз ел буена без балаларыбазны ана телендә укытыдан мәхрүм булып тордык. Шул вакыт эчендә урыс мәктәпләре аша узган берничә буын уз телен онытты, урыс теле генә төп тел булып калды".

Бары тик соңгы вакытта – 80-90нчы елларда гына – тел мәсьәләсен заман таләпләренә җавап бирердәй итеп алып бару мөмкинлеге ачылды. 1992 елда “Татарстан Республикасы халыклары телләре турында”гы Законны кабул итү тел сәясәте үсешенә, татар теленең дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрелүенә яңа этәргеч һәм хокукый нигез бирде.

Бүген дөнья халыклары тормышның төрле өлкәләрендә торган саен ныграк аралашу, үзара якыная бару чорын кичерә. Бү күренеш Татарстан җирлегендә

дә чагылыш таба. Мондагы төрле милләт кешеләренең бердәм яшәеше, хезмәттәшлеге, нигездә, рус һәм татар телләрендә бара. Икетеллелек, ягъни ике телне дими рәвештә куллану кешенең аңын, зиһенен үстерә. Шул ук вакытта ул телләрнең бер-берсенә тәэсир итүенә китерә. Татар теле, шул рәвешле, рус теленең көчле йогынтысына дучар ителгән. Бу йогынтының уңай ягы да, тискәре ягы да бар.Уңа ягы шунда: татар теленә рус теленнән һәм аның аша башка телләрдән сүзләр кабул ителә, яңа лексик берәмлекләр ясала. Ләкин тискәре ягы да бар. Кайбер очракларда туган телнең табигыйлегенә туры килми торган күренешләр дә кереп китә. Нәтиҗәдә телнең үзенә генә хас тәртибе, кагыйдәләре, нормалары бозыла. Менә шушынды икетеллелек шартлары безгә туган телебезнең сафлыгын саклау өчен зур җаваплылык йөкли. Туган телебезне саклап үстерү – төптән уйланылган, киң кырлы, махсус дәүләт программасы белән башкарыла торган зур эш таләп итә.

Мин, татар мәктәбендә эшләүче татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак, укучыларыбызда туган телгә мәхәббәт тәрбияләү максатыннан төрле эш алымнары кулланам. Аларның иң беренчесе - туган як музее белән бәйләнеш. Укучыда үзенең әби-бабасы, гаиләсе, үз авылы тарихы белән кызыксыну уяту – иң беренчел бурыч дип уйлыйм. Икенчедән, укучыны иҗади эшкә тартып тору, газета битендә үз иҗат җимешен күрү сөенеченә ирештерү. Татар мәктәбе буларак, бездә район күләмендә укучыларның “Көмеш каләм” иҗат фестивале уздырыла. Бу чара бик матур, җылы тәэсирләр калдыра. Өченчедән, татар теле һәм әдәбияты белән бәйле төрле заманча чаралар уздыру. Мәсәлән, ТНВ каналында бара торган “Башваткыч”, “Переведи” һәм башка шундый тапшырулар мисалындагы чараларда укучылар бик теләп катнашалар. Тагын бер куанычлы хәл: татар теленә өстәмә сәгатьләр бирелү. Аларны татар теле буенча белемнәрне ныгыту, укучыларның иҗади фикерләү сәләтен үстерү һәм башка максатларда бик рәхәтләнеп кулланабыз.

Безнең, татар теле һәм әдәбияты укытучыларының бурычы – укучыларга туган телебезнең матурлыгын тоярга өйрәтү, бүгенге буын аша киләчәккә тапшыру.

# Татар әдәбияты дәресләрендә экология һәм әхлак тәрбиясенең бирелеше

***Әхмәтшина Айгөл Фаукат кызы***
***Сәхәбиева Альбина Мансур кызы***
***Алабуга муниципаль районы***
***2 нче урта гомуми белем мәктәбенең***
***татар теле һәм әдәбияты укытучылары***

Талантлы шагыйрь Р.Фәйзуллинның кешелек яшәеше нәтиҗләре турында әрнеп язган мондый юллары бар:

Үзгәрешсез – имгәтелгән иман белән
нәҗесләнгән Җир-ана калды [3, 223 б.].

Шагыйрьнең нечкә күңеле яхшы тоеп ала: беренчедән, әхлак тәрбиясе белән экология тәрбиясе икесе бергә аерылгысыз бер бөтен тәшкил итәләр; икенчедән, хәзер, XXI йөз башында экология һәлакәте, әхлакый кыйммәтләр системасындагы үзгәрешләр проблемалары критик ноктага килеп җитеп, тизләтелгән һәм нәтиҗәле чишелеш көтәләр.

Экология һәлакәте шәһәрләшү, фән-техника үсеше, сәнәгатьтә табигать хисабына экономия ясарга омтылыш белән бәйле булуы ачыкланса да, проблемадан чыгу юлы күренми: элек бала табигый шартларда, табигать кочагында диярлек үссә, үзен аның бер өлеше итеп тойса, хәзерге балаларда мондый тойгы юк. Зоопарктагы хайваннар – күңел ачу чарасы, табигать кочагына чыгу гаилә белән урман-аланда ашап-эчеп кайтудан гыйбарәт булганда, балада экологик культура тәрбияләү, әлбәттә, катлаулы эш. Шундый шартларда татар әдәбияты укытучысы, әдәби сүзнең тәэсир көченнән тиешле дәрәҗәдә файдаланмыйча, экология тәрбиясен география укытучысы бурычы итеп карaса, бу аның үз һөнәренә тап төшерү булыр иде.

Гамәлдәге татар әдәбияты программа һәм дәреслекләре экология проблемасына битарафлык күрсәтмәгән кебек, аны артык күтәреп тә чыкмыйлар. Шулай да үтелә торган әдипләр, аларның иҗаты нигезендә экология мәдəниятен һәм әхлак тәрбиясен тормышка ашырырга мөмкин. Бигрәк тә башлангыч сыйныфларда әдәби уку өчен тәкъдим ителгән әсәрләрдә балаларны табигать серләренә төшендерү, табигатькә җан иясенә караган кебек

карарга өйрәтүнең урын алуы сөендерә. Әйтик, 4 нче сыйныфта М.Галиевнең "Аю агачлар белән сөйләшә" хикәясен укыган укучы агачларның ботакларын сындырмаска, урманда учак ягып, табигатькә зыян китермәс, дип уйларга җирлек бар. Чөнки әсәрне укый-укый, дәрестә шуның хакта фикер алыша-алыша, ул каенның ничә ел яшәгәнен дә, кешегә нинди файда китерүен дә, кеше башка агачлардан ничек файдалана – шулар хакында да мәгълүмат ала. Урта звеноның беренче баскычы – бишенче сыйныфта укыганда әдәби әкият жанры темасын үткәндә, А.Алиш әкиятләренә тукталып китү мөмкинлеге бар. Аның "Сертотмас үрдәк", "Нечкәбил", "Чукмар белән Тукмар" әкиятләре балаларга балалар бакчасындагы татар теле шөгыльләре, башлангыч сыйныфта әдәби уку дәресләре инде таныш була. Дәресләрнең берсен әдипнең "Кем көчле?" әкиятен өйрәнүгә багышларга мөмкин. Әлеге әсәрендә А.Алиш, балаларның яшь үзенчәлекләренә һәм психологияләренә ярашлы рәвештә биология фәне буенча башлангыч мәгълүмат бирә, организм һәм тирәлекнең үзара ярашуы, табигатьтә җанлы һәм җансыз предметларның яшәеше билгеле бер максатка юнәлгән булуы, табигый сайланыш законы һәм башкалар турында сөйли. Автор һәр бөҗәкне образ дәрәҗәсенә күтәрә, алар диалогларында үзләренең биологик үзенчәлекләрен ачалар. Әкияттә кырмыскаларның өй туена җыелган бөҗәкләрне генә хәтерлик: кырмыскалар гаять эшчән булулары белән мактаналар, имеш, алар зур-зур өйләр өлгертәләр, шунда әңгәмәгә суалчан килеп кушыла: "Без туфракның уңыш бирүчәнлеген күтәрәбез, без агротехника чараларын үткәрергә кешеләргә ярдәм итәбез. Әгәр без булмасак, җир өстендәге үсемлекләр хәзергедәй гөрләп тормаслар иде. Һәм уңышны да хәзергедәй мул бирмәсләр иде" [2, 261 б.]. Әсәр "җирне тетрәтеп" кемнеңдер килүе белән тәмамлана. Бу – "ташкын елгаларны авызлыклаучы, киң болыннарны, куе урманнарны үз эшенә файдаланучы, бөтен табигатьне баш идерүче кеше һаман атлый бирде" [2, 262 б.]. Дәреснең бер өлешен кешенең табигатьне баш идерүенең уңай яклары гына бармы, әллә тискәре күренешләр дә урын аламы – әнә шул сорауга җавап эзләү, фикерләр белән уртаклашуга багышлау максатка ярашлы.

Әдәбият дәресләренең тәрбияви көче тиешенчә файдалану укытучының дәвамлылык дидактик принцибына тугрылык саклавы-сакламавы белән тыгыз бәйле. Башлангыч сыйныфта укучы М.Галиев, А.Алиш әсәрләрен укып, табигать һәм кеше арасындагы тигезлек, гармонияне күреп соклана; урта звенода табигать байлыгына, тереклек яшәешенә кешенең дорфа хуҗаларча килеп кысылуына шаһит була, әмма моны нефть чыгару шаукумы, илебезнең алга китешен тәэмин итү өчен бирелгән корбан дип кабул итә. Югары сыйныфларда укучыларны Г.Гыйльмановның “Албастылар”, Н.Гыйматдинованың “Болан” әсәрләре белән танышканда, табигать эшенә тыкшыну, аның табигый яшәеш агышын бозуның җәмгыятькә никадәр зыян китерүен, иманлыгы, кешелеклелеге белән дан тоткан авыл кешеләренең битарафлылык, хөсетлек кебек чирләргә бирелүен, табигать белән бергә әхлак, әхлак белән бергә кешелекнең дә юкка чыгуын күрә белергә өйрәтергә кирәк. Сүземне йомгаклап, шуны әйтәсем килә: бары тик дәвамлы рәвештә алып барылган экология һәм әхлак тәрбиясе, укуытучының сыйныфтан-сыйныфка үтелә торган әсәрләр арасында бәйләнешне күрә һәм күрсәтә белүе, әсәрләрдә сурәтләнгән вакыйгалар нигезендә табигатькә, Җир-анага күрсәтелгән рәхимсезлекнең әхлагыбызга, ахыр чиктә, яшәешебезгә зыян салуын аңлату нәтиҗәсендә әдәбият дәресләре көн үзәгенә суккан проблеманы күпмедер дәрәҗәдә чишелешенә ярдәм итә ала, дәүләт табигатьне яклый торган законнар чыгара икән, әдәбият дәресләре шул законнардан читкә китү юлын эзләмәгән, үтәлешен тәэмин итә алган, табигатькә ихтирам белән караган буын тәрбияли ала.

Кулланылган әдәбият исемлеге

1. Ахунов Г. Әсәрләр дүрт томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – II т. - 496 б.

2. Балалар әдәбияты: хрестоматия / Төз. Ф.Ибраһимова. – Казан: Мәгариф, 2004. – 543 б.

3. Фәйзуллин, Р.Г. Яңа гасыр иртәсе: яңа шигырьләр / Р.Фәйзуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 239 б.

## Габдулла Тукай иҗатында экология темасы

***Әшрәфуллина Розалия Илдар кызы***
***беренче категорияле татар теле һәм***
***әдәбияты укытучысы***
***Алабуга муниципаль гомуми***
***белем бирү учреждениесе***
***«10 нчы урта (тулы) гомуми***
***белем бирү мәктәбе»***

Кеше тормышы һәрвакыт табигать белән бәйле. Ул - кешенең сәламәтлек, туклану, гомумән, яшәеш чыганагы. Табигать дигәч, иң беренче чиратта, калын яшел урманнар, саф сулы чишмәләр, бай тарихлы елгалар, күлләр, иксез-чиксез җәелеп яткан далалар күз алдына килә. Табигать безгә азык, кием, торыр урын бирә. Кеше тормыш өчен кирәкле бар нәрсәне табигатьтән ала. Шуңа күрә табигатьне сакларга кирәк. Табигатьне саклау - һәр кешенең изге бурычы.

Безнең эшнең максаты – укучыларга экологик белем һәм тәрбия бирү, аларда экологик культура формалаштыру, табигатькә кызыксыну уяту, аны саклау проблемаларын дөрес аңлау, табигатьтә үзеңне тота белү күнекмәләре булдыру.

Экологик белем һәм тәрбия бирүдә әдәби әсәрләрнең дә әһәмияте зур. Язучыларыбыз, беренчеләрдән булып, табигатьне саклау турында чаң сукты. Әйләнә-тирә дөньяны, кеше сәламәтлеген, аның рухын, телен саклау аларны иң борчыган һәм дулкынландырган проблемага әйләнде. Нәфис сүз, сәнгать чаралары ярдәмендә кешедә югалып бара торган иң изге әхлакый-рухи кыйммәтләрне торгызу, Җир-анага игелек, хөрмәт хисләрен уяту, кешелекнең экологик һәлакәт каршында торуында искәртергә кирәк иде. Табигатьне саклау темасына язылган әсәрләр исемлеге бай һәм төрле. Бөек шагыйребез Г. Тукай күп кенә шигырьләрендә җәнлекләрне, кошларны, бөҗәкләрне яратырга, аларга мәрхәмәтле, шәфкатьле булырга өнди, үзенең шигъри бизәкләре белән табигатьнең гүзәллеген ача.

Фәнни эшемне “Габдулла Тукай иҗатында экология темасы” дип атадым. Халкыбызның улы, бөек шагыйре Г. Тукайның иҗаты турында күп язылды, күп укылды. Әдәбият белгечләребез һаман да аның биографиясенең, иҗатының ачыкланып бетмәгән кайбер фактларын тикшерәләр, барлыйлар. Эш барышында мин дә үземә шундый максатлар һәм бурычлар куйдым: “экология” термины белән танышу; бөек шагыйребезнең экология һәм аның проблемаларына багышлап язылган шигырьләренә күзәтү ясау.

Г. Тукай үзенең шигырьләрендә туган җиребезнең матурлыгына, гүзәл табигатенә дан җырлаган шагыйрь. Табигать темасын һәр язучы үзенчә күрә, тасвирлый, укучыга төрле тел бизәкләре, сурәтләү чаралары, әдәби алымнар аша ачып бирә. Шагыйрьнең пейзажы туган туфрактан, балачагы үткән Кырлай якларыннан аерылгысыз. Пейзаж күп очракта сабыйлык хатирәләре аша үтеп тасвирлана. Тукайның туган як табигатенә балаларча мәхәббәте сизелеп тора. Шигырьләренең исемен дә күңелгә якын, үз итеп «Туган җиремә», «Туган авыл», «Җәйге таң хатирәсе» һ. б. дип атый.

Шагыйребез иҗатында әйберләрне җанландыру, сынландыру, хайваннарны кешеләргә хас аерым билгеләр белән сурәтләү алымы киң файдаланыла. Бу аеруча йорт хайваннарын һәм кош-кортларны бирүдә күзгә ташлана. Ул шигырьләрендә һәрбер җан иясенең индивидуаль портретларын таба, аларны билгеле бер характерда, җанлы тормыш эчендә ача: “Мияубикә”, “Бичара куян”, “Кызыклы шәкерт”, “Бала белән күбәләк”, “Фатыйма белән сандугач”, “Шаян песи”, “Күгәрчен”, “Карлыгач” ,”Карга”, “Кошларга”, “Кошчык”һ.б. шундыйлардан. Г. Тукай үз шигырьләре аша балаларны кечкенәдән үк кошларны яратырга, аларга мәрхәмәтле булырга өнди, аларны гөнаһсыз фәрештәләр белән тиңли. Кошларның табигатькә бик күп файда китерүенә басым ясый, аларның иркендә генә матур итеп сайрый алуын әйтә.

Шагыйрь хайваннарны дуслары, ярдәмчеләре дип саный, һәркемгә билгеле булган “Гали белән Кәҗә” шигыре үзе генә чын дуслыкның, мәхәббәтнең үрнәге булып тора. Табигатьтәге көчсез хайваннарны кызгана шагыйрь, кешеләрне бәгырьсезлектә гаепли. “Бичара куян” әсәрендә бүре

куянның балаларын ашап китә, соңыннан әнкә куянны аучы ата. Ата куян ялгыз кала һәм аның өчен дөньяның яме, яшәүнең мәгънәсе бетә. Автор фикеренчә, явызлык, ерткычлык, бәхетсезлек китерә.

Мифологик сурәтләргә бай “Шүрәле”, “Су анасы” әсәрләре халык әкиятләре стилендә язылган, тирән халыкчанлык белән сугарылган. Биредә табигатьнең бөтен матурлыгы һәм серлелеге сыйдырылган. Шагыйрь үзенә генә хас алым һәм зур осталык белән укучыларны табигать дөньясына алып керә, матурлыкны тоя һәм күрә белергә өйрәтә. Тукай борынгылыкны саклаган, халкының гореф-гадәтләренә нигезләнгән мифларны яхшы белгән.

Г. Тукай үзенең авылының гаҗәеп табигатен, үз вакытын белеп алышынган ел фасылларын, аларның һәрберсенең үзенә хас матурлыгын соклану катыш гаҗәпләнү хисләре белән яза. Кырлай авылы тирәсендәге калын урманнарны, сайрар кошлары, җәнлек-җанварлары, хуш ис бөркегән чәчкәле, кызыл җиләкле аланнары турындагы шигъри юллар кайсы укучыны гына хыял дөньясына алып китми икән?

Габдулла Тукай әйтергә теләгән фикерләре укучыга барып җитсен өчен, әдәби телебезнең төрледән-төрле сурәт-бизәкләрен куллана, төрледән-төрле чагыштырулар куллана. Мәсәлән: «Тәгәридер ул матур кыз —язның алтын фәйтуны»; «Барыбер, күрсәң, качарсың, язны — гөлләр патшасын».

Әйе, кеше табигатьнең аерылгысыз өлеше. Шагыйребезнең шушындый кешелекле, шәфкатьле әсәрләре безне асылыбызга кайтара, табигать дөньясы белән тагын да якынайта. Киләчәк буын вәкилләре дә әлеге әсәрләр аша гүзәллек дөньясын күреп, тоеп, киләчәктә аны кайгыртып яшәсә иде.

Кулланылган әдәбият:

1. Габдулла Тукай. Әсәрләр. Биш томда. 4 том. Проза. Публицистика (1907-1913), - Казан, Тат.кит. нәшр., 1985.
2. Тукай Г. Сайланма әсәрләр: 2 томда. - Казан: Татар.кит. нәшр., 2006.
3. Лаисов Н. Габдулла Тукай. Тат.кит.нәшр.,
4. Нуруллин И. Тукай.-Казан, Тат.кит.нәшр., 1979.

5. Рәсүлова З. Тукай эзләреннән.-Казан,Тат.кит.нәшр., 1985
6. Сайланма әсәрләр. Шагыйрь турында истәлекләр.- Казан: Татарстан Республикасы ”Хәтер нәшрияты” (ТаРИХ), 2002.

## А мы должны предугадать, как наше слово отзовется

***Березина Наталья Николаевна,***
***преподаватель первой квалификационной категории***
***ГАПОУ «Техникум нефтехимии и нефтепереработки»***
***г. Нижнекамск***

*«Природа дала человеку в руки оруж ие — интеллектуальную и моральную силу, но он мож ет пользоваться этим оруж ием и в обратную сторону; поэтому человек без нравственных устоев оказывается существом самым нечестивым и диким, низменным в своих ... инстинктах” .*

Аристотель.

Литература и русский язык в средних специальных учебных заведениях являются предметами общеобразовательного цикла и изучаются всего 2 года. Главным  в учебном заведении становится обучении профессии, развитие трудовых навыков. В этой ситуации люди рабочей профессии могут смело сказать, что литература им никогда в жизни не понадобится.

Мы все прекрасно знаем, кто к нам приходит учиться после школы, с какой целью, и чего от бывших школьников ожидать.

Но и в этих непростых обстоятельствах преподаватель должен найти нужные слова, чтобы правильно настроить обучающихся на учебный процесс.

Никогда не стоит забывать, что кроме профессионального, мы даем основное среднее образование, которое является в нашей стране обязательным.

И поэтому роль русского языка и литературы трудно переоценить.

Литература, изучаемая на I и II курсах,  включает в себя период со второй половины  XIX века по сегодняшний день, т.е. примерно 170 лет. Кто писал в это время, какие поднимал проблемы, был ли понят современниками и как

оценен потомками? Эти непростые вопросы ставит литература перед нынешними обучающимися.

Ответы мы стараемся найти вместе. И, как говорят сегодня: «Интернет вам в помощь».

Так как в профессиональных учебных заведениях мой предмет не ставится во главу угла, я стараюсь найти плюсы даже в такой ситуации.

Современную молодежь не заставишь читать. Какими бы двойками мы их не пугали. Поэтому, если произведение не большое по объему, мы его читаем вслух прямо на паре. А потом обсуждаем прочитанное. Так на первом курсе мы прочитали «Грозу» А.Н.Островского, «Кому на Руси жить хорошо» Н.А.Некрасова, познакомились с творчеством А.А.Фета, Ф.И.Тютчева, вспомнили творчество поэтов золотого века А.С.Пушкина и М.Ю.Лермонтова.

Наш век называют веком скоростей и новых технологий. От этого никуда не денешься. Постарайтесь не становиться рабами гаджетов, а, наоборот, заставьте их служить вам. Мы с ребятами делаем это на уроках литературы.

Интерактивной доской в учебном кабинете сейчас никого не удивишь. Мы начинаем знакомство с новым автором и произведением, конечно же, с беседы. Вопрос-ответ. На доске фамилия, имя, отчество писателя, годы жизни. Мой первый вопрос: «Сколько лет прожил писатель?» (связь с математикой, пусть и на уровне начальной школы). 2. Много это или мало? (связь с анатомией). И только третьим вопросом стоит: «Знаком ли вам данный писатель? Какие его произведения вы читали раньше?» (Ответы «летят» самые разные, обидно, когда ищут информацию в телефоне и выдают за свою. Но тут преподаватель сразу узнает «не свой» ответ и ставит «всезнайку» на место).

Потом рассказываю о жизни и творчестве писателя без включения презентации или фильма о писателе. Я считаю, что живое общение очень нужно ученикам. И, представьте себе, они слушают мой рассказ, не подкрепленный никакими картинками. Я предлагаю им представить семью, имение писателя, письменный стол, трудные условия жизни…

Только потом, когда сказала все, что хотела сказать, ответила на все вопросы, включаю презентацию, листаю слайды, делая короткие комментарии к ним. И не поверите, на следующий урок они рассказывают биографию, отмечая интересные моменты, которые они нашли не в интернете, а я им рассказала.

Как воспитать человека? Этот вопрос всегда стоит перед преподавателем. Как научить его отличать плохое от хорошего, приемлемое от недопустимого.

Этот процесс я начинаю с первых уроков литературы. Не секрет, что наши ученики частенько разговаривают «матом». Уже с 1 сентября строго объявляю, что в кабинете литературы нецензурных слов никто не произносит. Сначала борюсь, а потом они привыкают и сами одергивают того, кто «нечаянно» использовал нецензурную лексику.

Я не могу похвастаться, что после моих уроков ребята рванули в библиотеку и стали зачитываться до утра. Да, на уроках литературы мы смотрим экранизации романов «Обломов» И.Гончарова, «Преступление и наказание» Ф.Достоевского, «Война и мир» Л.Толстого и другие. После просмотра я читаю отрывки из глав, эпилоги, чтобы они хотя бы на слух были знакомы с художественным словом. После просмотра «Бородинской битвы» зачитала главу, и слушали меня, можно сказать, затаив дыхание. Разве это не результат нравственной работы, происходящей у ребят?

Мы часто говорим, что качество образования определяется не только количеством и качеством знаний, но и качеством личностного, духовного, гражданского развития подрастающего поколения.

Поэтому я считаю особо значимой роль преподавателя, целенаправленно и организованно помогающего подросткам «восходить» к культуре современного ему общества и развивать способности жить в этом обществе.

## Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларының IX сыйныф укучыларына татар теленнән бердәм республика тесты

*Бәдертдинова Альбина Мөҗәһитовна*
*Минзәлә гимназиясенең татар теле укытучысы*

**Эшне үтәү өчен күрсәтмә**

Имтихан эше үз эченә 11 биремне алган 3 бүлектән тора. Эшне башкаруга 150 минут вакыт бирелә.

**1 бүлек** 1 биремнән тора Анда 2 тапкыр тыңланган текстның кыскача эчтәлеге (изложение) языла. Ул 2 нче номерлы җаваплар бланкында эшләнә.

**2 бүлек** укучылар үзләре укыган текстка нигезләнеп башкарыла. Ул үз эченә 9 биремне (2-10) ала. Әлеге бүлеккә җаваплар сүз ( яки сүзтезмә), сан, цифрлар эзлеклелеге рәвешендә языла. Җавапны дөрес язмаган очракта , аны сызып, яңа җавапны янына языгыз.

**3 бүлек** тә икенче бүлектә бирелгән текстка нигезләнеп башкарыла. Өченче бүлек биремнәрен эшләр алдыннан сезгә тәкъдим ителгән ике биремнең берсен сайлап алыгыз (11.1 яки 11.2) һәм, үз фикерегезне дәлилләп, киң язма җавап языгыз. Бу эш аерым биттә башкарыла.

Үтәлгән биремнәр өчен куелган баллар бергә кушыла, һәм гомуми балл чыгарыла. Мөмкн кадәр күбрәк биремнәргә дөрес җавап бирергә һәм югарырак балл җыярга тырышыгыз.

**Сезгә уңышлар телибез!**

**I бүлек**

***Текстны тыңлагыз һәм 1 нче биремне 2 нче номерлы җаваплар бланкында эшләгез. Башта биремнең номерын, аннары изложение текстын языгыз.***

Текстны тыңлагыз һәм кыска изложение языгыз. Текстны тыңлагач, микротемаларны билгеләгез. Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп

эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез. Изложениенең күләме **50 сүздән** ким булмаска тиеш. Изложениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

**II бүлек**

| ***Текстны укыгыз һәм 2-10 нчы биремнәрне үтәгез.*** |
|---|

**Экологияне өйрәнү ни өчен кирәк?**

1) Табигатьтә иң көчле һәм иң акыллы җан иясе – Кеше. 2) Билгеле инде, үзе яши торган йортына – табигатькә ул һич тә зыян китерергә теләми. 3) Ләкин кайчакта ул үзе эшләгән эшнең булачак нәтиҗәсен алдан күрә алмый һәм, үзе дә теләмәстән, зур фаҗигаләрнең сәбәпчесенә әйләнә.

4) ...Бервакыт кытайлылар үз илләрендәге барлык чыпчыкларны кырып бетерәләр. 5) Ни өчен дисезме? 6) Бик күп ашлык бөртеге ашап, чыпчыклар иген уңышына гаять зур зыян китерә, дип уйлыйлар алар. 7) Ләкин эш бер дә кытайлылар уйлаганча барып чыкмый. 8) Киресенчә, ике-өч елдан уңыш бик күпкә кими. 9) Чөнки чыпчыклар юкка чыккач, бөҗәкләр шулкадәр күпләп үрчиләр, хәтта алар бөтен игеннәрне ашап бетерәләр. 10) Кешеләр шунда гына үзләренең ялгышларын аңлыйлар. 11) Чыпчыклар үзләре ашлык бөртекләрен бераз чүпләсәләр дә, балаларына һич тә бөртек ашатмыйлар, ә басудагы шул корткыч бөҗәкләрне, аларның личинкаларын ташып ашаталар. 12) Шуның белән иген басуларын корткычлардан саклыйлар икән. 13) Бу бәладән котылу өчен, кытайлылар чыпчыкларны чит илләрдән сатып алып кайтырга мәҗбүр булалар.

14) Тагын бер мисал. 15) Иген басуларына зыян китерүче бөҗәкләргә каршы Кеше агу уйлап таба. 16) Шул агулы порошок сибелгән җирләрдә барлык бөҗәкләр – саранчалар да, чикерткәләр дә, чебен-черкиләр дә, күбәләкләр дә, энә караклары да, алтын камкалар да – файдалысы да, файдасыз күренгәне дә (...) барысы да кырыла. 17) Шул агулы бөҗәкләрне чүпләп, басу-кыр кошлары күпләп һәлак була. 18) Озак та үтми тагын бер бәла килеп чыга: сыер сөтендә әлеге агу табыла. 19) Үлән белән тукланучы сыерга агуның каян килеп эләгүен чамалау кыен түгел.

20) Радиодан һәм телевизордан без көн саен һава торышы турында прогноз тыңлыйбыз. 21) “Прогноз” – “алдан әйтү” дигән сүз. 22) Экологик прогнозлар да була. 23) Кешеләрнең табигатькә йогынтысы нинди нәтиҗәләргә китерәчәген экологлар алдан әйтә ала.

*Ибраһимова Ф.Җ., “Табигать бизәкләре” китабыннан*

***2-10 нчы биремнәрнең җавабы сүз яки сан белән булырга мөмкин. Башта җавапларны текст өстендә язып чыгыгыз, соңыннан 1 нче номерлы бланкка күчерегез. Җаваплар язганда <u>буш ара калдырылмый</u>, <u>тыныш билгеләр куелмый, башка өстәмә символлар язылмый</u>. Хәрефләрне һәм саннарны бланктагы үрнәккә карап языгыз. Һәр символ аерым шакмакка языла.***

**Рәт гармониясе сакланмаган сүз кулланылган җөмләнең санын күрсәтегез:**

1) Киресенчә, ике-өч елдан уңыш бик күпкә кими.

2) “Прогноз” – “алдан әйтү” дигән сүз.

3) Ләкин кайчакта ул үзе эшләгән эшнең булачак нәтиҗәсен алдан күрә алмый һәм, үзе дә теләмәстән, зур фаҗигаләрнең сәбәпчесенә әйләнә.

Җавап: ________________________________________

**Рус теле аша кергән грек алынмасы булган җөмләне билгеләгез.**

1) Кешеләрнең табигатькә йогынтысы нинди нәтиҗәләргә китерәчәген экологлар алдан әйтә ала.

2) Табигатьтә иң көчле һәм иң акыллы җан иясе – Кеше.

3) Шуның белән иген басуларын корткычлардан саклыйлар икән.

Җавап: ________________________________________

**4-9 нчы җөмләләрдән чама санын табып языгыз.**

Җавап: ________________________________________

**7-10 нчы җөмләләрдән кушу юлы белән ясалган күрсәтү алмашлыгын табып языгыз.**

Җавап: ________________________________________

**20-23 нче җөмләләрдән синонимнар кергән җөмләнең санын күрсәтегез.**

Җавап: ________________________________________

**6-9 нчы җөмләләрдән артыклык дәрәҗәсендәге рәвешне табып языгыз.**

Җавап: ________________________________________

**4-9 нчы җөмләләрдән кире сүз тәртибе кулланылган җөмләнең санын языгыз.**

Җавап: ________________________________________

**16 нчы җөмләдә тиңдәш кисәкләр янында нинди тыныш билгесе куела? Сүз белән языгыз.**

Җавап: ________________________________________

0 **14-19 нчы җөмләләрдән аналитик төрдәге иярчен җөмләсе булган кушма җөмләнең санын языгыз.**

Җавап: ________________________________________

**III бүлек**

***2 нче бүлектә бирелгән текстны файдаланып, (11.1 яки 11.2) биремен үтәгез. Яза башлар алдыннан биремнең номерын күрсәтегез.***

**11.1 Табигатьтә иң көчле һәм иң акыллы җан иясе – Кеше. Билгеле инде, үзе яши торган йортына – табигатькә ул һич тә зыян китерергә теләми.** – җөмләләрендә әйтелгән фикер белән килешәсезме? Шул турыда языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укылган тексттан 2 мисал китерегез. Файдаланган җөмләләрнең номерларын күрсәтегез, яки тексттан цитата китерегез.

Сочинениенең күләме **50 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Сочинениены чиста һәм танырлык итеп языгыз.

Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен ноль балл куела.

**11.2 Татар халкында “Үзе утырган агачка балта чабу” дигән әйтем бар. Син аны ничек аңлыйсың? Текстка бәйләп аңлатыгыз.**

*Чыпчыклар үзләре ашлык бөртекләрен бераз чүпләсәләр дә, балаларына һич тә бөртек ашатмыйлар, ә басудагы шул корткыч бөҗәкләрне, аларның личинкаларын ташып ашаталар.* – дигән җөмлә сездә нинди фикер тудыра?

**“Экологияне өйрәнү ни өчен кирәк?”** темасына сочинение языгыз. Фикерегезне раслау өчен укылган тексттан бер мисал, үзегезнең тормыш тәрибәсеннән бер мисал китерегез.

Сочинениенең күләме **50 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Сочинениены чиста һәм танырлык итеп языгыз.

Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен ноль балл куела.

**Җаваплар**

| **Текст буенча эш** | | |
|---|---|---|
| **Төп проблемалар** | **Автор позициясе** | **Укучы нәтиҗәсе** |
| ***11.1 Кеше – көчле һәм акыллы җан иясе. Табигатькә ул һич тә зыян китерергә теләми.*** Кеше кайвакыт, үзе дә уйламыйча, табигатькә зыян китерә. | Табигатькә зыян килмәсен өчен, кешеләр аңа һәрвакыт сак карарга, алдан уйлап эш итә белергә тиеш. | Кеше һәрвакыт акыл белән эш итәргә тиеш. Ул үзенең көчле, акыллы зат икәнен табигать белән эш иткәндә күрсәтергә тиеш. Юкса, кешенең акылы үзенә каршы эшләячәк. |
| ***11.2. "Үзе утырган агачка балта чабу".*** ***"Экологияне өйрәнү ни өчен кирәк?"*** Кеше, табигатькә саксыз карау нәтиҗәсендә, үзе дә зыян күрә. | Кешеләр – табигатьнең бер өлеше. Экологик бәла Кешенең үзенә дә яный. Чөнки Кеше үзен-үзе агулый, киләчәген юкка чыгара. | Табигатьтә бар да тәртип белән яши, чыпчыклар да балаларына агулы ризык ашатмый, ә кеше үзен-үзе агулый. Кешеләр, Җирнең киләчәге хакына, табигать белән бердәм яшәргә өйрәнергә тиеш. Экологлар кешеләргә табигатьне саклауда ярдәм итә алалар. (юлларын күрсәтергә) |

**Җаваплар**

| Бирем саны | **Җаваплар** | аңлатма |
|---|---|---|
| 2 | 3 | фаҗигаләрнең сүзендә беренче иҗектә а – калын сузык аваз, икенче иҗектә и – нечкә сузык аваз. |
| 3 | 1 | Эколог – грек сүзе (oikos - торак, туган ил; logos – сүз). |
| 4 | ике-өч | Парлы саннар чама санына керә |

| | | |
|---|---|---|
| 5 | шулкадәр | Мөнәсәбәтле сүзләр – алмашлык була, шул+кадәр |
| 6 | 21 | “Прогноз” – “алдан әйтү”, тәрҗемәләр синоним булып килә |
| 7 | бик күп | Рәвешләр, сыйфатлар кебек үк, артыклык дәрәҗәсендә килергә мөмкин |
| 8 | 6 | уйлыйлар алар (хәбәр алда, ия – артта килгән) |
| 9 | сызык | Барысы – гомумиләштерүче сүз, ул тиңдәш кисәкләрдән артта килгән |
| 10 | 18 | Озак та үтми тагын бер бәла килеп чыга: сыер сөтендә әлеге агу табыла. |

**Табигать дирижеры**

Сезнең зур концертларда оркестр уйнавын тыңлаганыгыз бардыр. Кайбер оркестрларда дистәләгән, йөзләгән музыкант һәм шулкадәр үк уен коралы була. Алар барысы бергә бер ритмда уйнасыннар өчен, оркестр белән дирижер җитәкчелек итә.

Безне чолгап алган тирәлек – табигатьне дә бик зур оркестр белән чагыштырырга мөмкин. Аның белән җитәкчелек итүче бармы икән, уйлап карыйк.

Ел дәвамында кояшның горизонт өстеннән биеклеге ничек үзгәрүен күзәтик. Җәй көне кояш иртә чыга, көндез югары күтәрелә, кич соң гына бата – көн озын була. Яктылык һәм җылылык күп булганлыктан, һава да нык җылына. Ә кышын, киресенчә, кояшның күктәге юлы кыска. Шуңа күрә көн озынлыгы

да кими, һава җылынмый, көннәр суык була. Димәк, кояш югарырак күтәрелгән саен, аның яктылыгы да, җылылыгы да арта икән.

Ә терек табигатьтәге үзгәрешләр нилектән була соң? Алар терек булмаган табигатьтәге үзгәрешләргә бәйле. Мәсәлән, язын кояшның күктәге юлы кыш көненә караганда озынрак була, көн дә озая бара. Һаваның температурасы күтәрелә. Кар эри. Туфрак йомшара. Су туфрактагы минераль матдәләрне эретә. Үсемлекләрдә сок хәрәкәте башлана. Туфрактагы эремәне суырып, бөреләр бүртәләр. Агачлар, куаклар яфрак яра. Яктыда үсемлекләрдә сок рәвешендәге терек матдә хасил була, һәм үсемлекләр үсә башлый. Үсемлекләрнең согы, нектары, яфрагы белән туенучы бөҗәкләр уяна. Аннан соң бөҗәкләр белән тукланучы кошлар кайта.

Табигатьтәге бу күренешләр, үзгәрешләр белән кем җитәкчелек итә соң? Әлбәттә, Кояш. Туклану өчен азык бирүче дә ул. Барлык үсемлекләрне, шул исәптән яшелчә һәм җиләк-җимешләрне дә ул үстерә. Без ашый торган ипинең, итнең һәр кисәгендә, шикәрдә, майда, борычта һәм шоколадта, аш һәм ботканың һәр кашыгында яшеренгән Кояш нурлары бар. Алар яшәү өчен энергия бирәләр.

... Димәк, Кояш – табигать дирижеры ул.

<u>Микротемалар:</u>

1. Табигать белән кем идарә итә?
2. Терек табигатьтәге үзгәрешләр көн озынлыгына бәйле.
3. Табигать белән Кояш җитәкчелек итә. Кояш – табигать дирижеры.

# Татарларны татарча укытыргамы?

***Борһанова Гөлназ Шәйхенуровна,***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы,***
***Менделеев шәһәре 4нче гомуми урта белем бирү мәктәбе***

Туган тел! Һәркем өчен дә газиз сүз бу. Чөнки иң кадерле, бернәрсә белән дә алыштырмый торган “әти” , “әни”, “әби”, “бабай” сүзләрен туган телдә әйтәбез. Туган – үскән илнең якынлыгын, Ватанның газизлеген тоярга да безгә туган тел ярдәм итә.

Һәр милләт өчен иң моңлы көй – милли көй, иң матур тел – милли тел. Әнә шуны тоеп, ләззәтләнеп яшәгәндә кеше эшләргә һәм укырга сәләтлерәк, бәхетлерәк була. Шундый бәхетне югалтмас өчен генә дә без ана телен камил белергә һәм балаларыбызга өйрәтергә тиешбез.

Туган тел үзенең яңгырашы белән колакны назласа, ягымлылыгы белән исә күңелне юата, кешедә изгелек хисләре уята. Ягымлы ана теле – бигрәк тә балаларга аң – белем һәм тәрбия бирү өчен иң шифалы чишмә. Милләт – халыкның яшәү формасы . Милләтнең төп күрке – тел һәм моң.

Тел милләт белән бергә туа, үсә һәм аның иң ышанычлы һәм кадерле сердәше, юлдашы һәм юанычы булып яши. Күп гасырлар буе телебез үсеп, шомарып килгән һәм шул процесста сүзләр кыскара, җыйнаклана төшкән. Нәтиҗәдә сүзләрнең күпчелеге бер генә иҗекле булып калган (Ә андый сүзләр телебездә бик күп.).

“Без – татарлар, телебез – татар теле, мөстәкыйль һәм төзек кагыйдәле камил тел ул”, - дигән телебезне үстерүгә гаять зур өлеш керткән Каюм Насыйри.

Сүзләрнең кыскалыгына, җыйнаклыгына, камиллегенә караганда татар теле нык шомарган бик борынгы тел.

Телдәге сүзләр һәм терминнар ни хәтле кыскарак һәм җыйнаграк булса, төгәл фәннәрне укыту дә шул хәтле җиңел бара. Бу факт киләчәктә тел галимнәрен генә түгел, бәлки башка фән укытучыларын да кызыксындырыр дип уйларга кирәк.

Татар теленең мондый үзенчәлеген белмәгән һәм ике телдә дә төгәл фәннәрне укытып карамаган кайбер галимнәр телебезне төгәл фәннәрне укытырга яраксыз дип исәплиләр. Шуңа күрә татар мәктәпләрендә төгәл фәннәрне русча гына укыту ягында торалар. Бу уңай белән мин шуны әйтер идем : мондый позициянең дөресме – түгелме икәнлеген ачыклау өчен, беренчедән, кимендә ике телне дә тигез дәрәҗәдә бик яхшы белергә кирәк ; икенчедән, бу ике телдә дә физика һәм математика фәннәрен мәктәптә һәм югары уку йортларында укытып карарга кирәк.

15-20 ел элек югары уку йортларында төгәл фәннәрне татар телендә укытып булмый дигән ялгыш фикер халык мәгарифе җитәкчеләренә дә барып җитте. Ә алар исә шул карашны фән кушуыдыр дип кабул иттеләр һәм нәтиҗәдә югары уку йортларында татар төркемнәренең бетерелүенә китерде, аннары мәктәпләр, балалар бакчалары шул хәлгә дучар булды. Тора-бара бу ялгыш караш ата-аналарга да көчләп тагылды. Шулай итеп, байтак ата-ана һәм әби-бабайлар, бала-оныкларын ике телне өйрәтеп җәфаланмыйк дип, ватып-җимереп булса да, алар белән русча гына сөйләшүгә күчтеләр.

Ә хәзерге көндә югары уку йортларында татар телендә укыту ни хәлдә? Татарлар татарча укыймы?

11нче сыйныфны тәмамлаучы кызым белән Казан шәһәренә ачык ишекләр көненә баргач, берничә югары уку йортында булырга туры килде.

Бүген Татарстанда югары уку йортларында татарча укыту КФУ, Россия Ислам институтында алып барыла.

КДАТУ (Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты) каршындагы Төзелеш институты ел саен бер татар төркеме кабул итә икән. Татар төркемнәрендә белем алучы студентлар 23 фәнне татар телендә үзләштерә. Лекция, имтиханнар – барысы да татарча. III курсның икенче яртысыннан, төгәлрәге, 6 нчы семестрдан, белем бирү тулысынча русчага күчә. Чыгарылыш имтиханнары һәм диплом эшләре рус телендә тапшырыла. Татар төркемнәрендә 13-15 кеше белем ала.

Университетта татарча укытуны оештыручыларның берсе – педагогика фәннәре докторы, физика-математика фәннәре кандидаты, профессор Наил Туктамышев. Ул уку йортында әле дә математика укыта. “Ике телне дә яхшы белгән белгечләр әзерләү мөһим. Татар халкын цивилизацияле халыклар арасына чыгарырга тиешбез. Шундый максат бар. Ул бүген фантастик булып яңгырыйдыр, бәлки. Ләкин зур максат юк икән, кечкенә эшне дә башкарып булмый. Бүгенге көндә русча, татарча, инглизчә дә белем алу мөмкинлеге булу – ул бөтен Татарстан, ә бәлки бөтен Россия өчен үрнәк дип саныйм. Бу – безнең киләчәк өчен кирәк “, - ди галим журналист Зилә Сафинага биргән интервьюсында

Наил Туктамышев чит илләрдә конференцияләрдә еш катнаша. Бразилиянең Сан-Паулу шәһәрендә узган халыкара конференция аның хәтерендә уелып калган. Анда 40-50 илдән вәкилләр җыелган. Галимнең чагышыннан соң, Татарстан белән кызыксынучылар күп булган икән. “Бездә математиканың югары уку йортында татарча укытылуына шаккаттылар. Папуа-Яңа Гвинеядән галимнәр бар иде. Алар математиканы үз телләрендә өйрәнә башлаган. Папуа телендә терминнар булдыралар. Бүген дүртенче сыйныфка кадәр үз телләрендә математиканы өйрәнәләр”, - дип яза математик.

Наил Туктамышев үз телләрендә фәнни дәреслекләр булмаган халыкның шушы юнәлештә эшләвен искәртеп, татарларның булган югары белемнән баш тартуына гаҗәпләнүен белдерә.

Әй кадерле ата-аналар һәм дәү эти-дәү әниләр! Баланың башында ике тел өчен генә түгел, ә өч-дүрт һәм аннан да күбрәк телләр өчен дә урын җитәрлек.

Балаларыгызны шулай ук милли телдән мәхрүм итмәгез. Күп телләр белү балага авырлык китерми, бары тик аның белемгә омтылышын гына арттыра. Бүгенге фән-техника үсеше заманында һәркемгә ике генә түгел, күбрәк тел белү дә бик кирәк.

Дөнья тәҗрибәсе шуны күрсәтә: милләт милләт буларак сакланып калсын өчен, мәгариф системасы түгәрәк цикл булып эшләргә тиеш. Балалар бакчасы – мәктәп – югары уку йорты. Бакча, мәктәптән соң, югары уку йортында да татарча белем алу мөмкинлеге тудырылган икән, бу – телнең тулы канлы кулланылышын күрсәтә торган бер дәлил.

Кешенең хисләре, кичерешләре әти-әни, әби-бабай,туган телгә мәхәббәттән, туган-үскән җирләрне сагынудан, үз урманнарың белән кырларыңны яратудан башлана. Бу исә алар турында кайгыртып яшәргә, һәр адымда шулар өчен җаваплы булырга дигән сүз.

Кулланылган әдәбият


1. Атна вакыйгалары. №4, 2017
2. Н. Дәүли. Мин җирдә калам. - Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1980
3. Ф.С. Сафиуллина, М.З.Зәкиев. Хәзерге татар әдәби теле.- Казан : Мәгариф нәшрияты, 2002
4. Ф.С. Сафиуллина, Г.Б.Ибраһимов. Хикмәтле дә, бизәкле дә туган тел. – Казан : Мәгариф нәшрияты, 1998
5. Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр. – Казан : Татарстан китап нәшрияты, 1987


## Татар әдәбияты дәресләрендә экологик һәм әхлакый тәрбиянең чагылышы.


***Валиева Роза Назиф кызы***
***Татар теле һәм әдәбияты укытучысы***
***Матвеевка төп мәктәбе***


Табигать... Безне әйләндереп алган бер сихри могъҗизадыр. Табигать элек- электән зур әһәмияткә, илаһи көчкә ия.  Борынгыдан табигать кешене киендергән, ашаткан, эчерткән, дәвалаган. Кешеләр дә табигатькә игътибарлы булганнар,  кадерен белгәннәр, аны тагын да ямьләндергәннәр. Табигатькә рәхмәт йөзеннән, төрле бәйрәмнәр уздырганнар. Еллар уза...

Без үзгәрәбез, табигать үзгәрә. Кеше белән табигатьнең бәйләнеше кими. Хәзер бездә техника заманы, күп вакытыбыз телевизор карап, компьтер артында үтә. Без табигатьтән ераклаштык. Авырсак, даруханәгә йөгерәбез, саф һавада йөрү, үләннәр белән дәвалану да арткы планга күчте.

Ә татар әдәбияты дәресләрендә экологик һәм әхлакый тәрбия, табигать темасы нинди урын алган соң? Мин күп еллар рус балаларына татар теле һәм әдәбиятын укытам. Хәйдарова дәреслекләре белән белем бирәбез. Бу дәреслекләрдә экологик һәм әхлакый тәрбия киң чагылыш тапкан. Һәр сыйныфта ел фасылларына бүленеш бар, анда туган ягыбыз табигатенең гүзәллеге сүрәтләнә. Һәр әсәр укучыларының яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып бирелгән. Кечкенә сыйныфларда табигать матурлыгы, тирә- ягыбыз гүзәллеге сүрәтләнсә, өлкән сыйныфларда әхлакый тәрбиягә йогынты ясала. Балалар күңелендә зур урын алган берничә әсәргә якынрак тукталасым килә.

Башлангыч сыйныфларда дару үләннәре турында хикәяләр бар. Халиковның “Витаминлы аш” хикәясе бик кызыклы. Тәнзилә укудан өйгә кайта. Өйдә тәмле аш исе таралган. Әбисе кычытканнан аш пешергән. Бу хикәяне укыганда, укучылар төрлефайдалы үләннәрне, ашларны искә төшерәләр.

Гасыйм Лотфиның ”Эш үткәч үкенүдән файда юк” әсәре 3 нче сыйныфта өйрәнелә.Әсәрдә төп герой- тискәре образ. Марат урамда йөри, агачта кошлар сайрый. Марат кошларга вак таш ата. Бер кош Марат янына төшә. Марат аңа таш ата. Таш кошның башына тия, һәм шунда ук үлә. Марат кош янына килә, аңа бик күңелсез була, ләкин, эш үткәч, үкенүдән файда юк. Кошларның табигатебезгә файдасы шушы хикәя аша күрсәтелгән. Маратның шаярып кына аткан ташы фаҗигагә китерә. Шаяртырга яратучы башлангыч сыйныф укучыларына бу хикәя зур тәрбияви чара булып тора.

8 нче сыйныфта бирелгән Нәбирә Гыйматдинованың “Болын патшасы” исемендәге әсәре бик кызыклы, үзенчәлекле. Әсәрнең төп геройлары икәү. Рәсим белән Айсылу. Айсылуның әниләре шәһәрдә яши, әбисе белән генә үскән бер кыргый кыз. Ул көнозын урманнарда, болыннарда йөри, төрле үләннәр җыя. Ә Рәсимнең кечкенәдән аяклары авырта, әниләре төрле табибларга йөртсәләр дә, соңыннан бөтенләй йөрми башлый. Дуслары башта хәлен белсәләр дә, Рәсим алар белән уйный алмаганга, бөтенләй керми башлыйлар. Хикәядәге Рәсимнең: “Мин бөтенләй ялгыз калдым” сүзләре укучыларның күңелләренә тыңгылык бирми. Айсылу тәрәзә аша кереп, Рәсимне урманга дәшә, Сай елга буендагы чишмәянына чакыра. Урын өстендә яткан малайга бу сүзләр авыр ишетелә, ләкин Айсылу, Рәсимне кул арбасына утыртып, елга янына алып килә.Рәсимне комга утырта. -Сай елга комы синең аякларыңны дәвалаячак!” – дип, Айсылу, әрекмән яфрагы өзеп, Рәсимнең башына каплый. Үзе чишмә суы белән Рәсимне дәвалый. Рәсим белән Айсылу үзләренең

хыялларын әйтәләр. Рәсимнең аяклы буласы килсә, ә Айсылу болын патшасы булып, үләннәр серен, бөҗәкләр телен аңларга хыяллана. Көн саен Айсылу Рәсимне комлыкка алып бара. Рәсимнең буыннарының авыртуы кими, атна-ун көннән соң аякларының көче арта, әзрәк йөри башлый. Барлык укучылар да Рәсимнең теләге тормышка ашыр, дип уйлый. Укучыларны әсәр бик кызыксындыра, тизрәк әсәрне укып бетерәселәре килә, татарча яхшы белгәннәре өйдә укып, тәрҗемәсен сөйлиләр. Әсәрне тулысынча өйрәнгәннән соң, файдалы дару үләннәре турында сөйләшү уза. Айсылу образы- уңай тәрбияви образ. Табигать күренеше, чишмә суының, әремнәрнең, кайнар комның дәвасы- экологик тәрбия. Нәбирә Гыйматдинованың "Болын патшасы" әсәре- бик кирәкле һәм әһәмиятле әсәр.

Шушы ук сыйныфта Кадый Даянның "Өзелгән чәчәкләр" әсәрен өйрәнәбез. Хәл шәһәр бакчасында башланып китә. Әсәрнең төп герое- Әхмәт. Ул шәһәр бакчасында йөргәндә, үсеп утырган матур розаларны күрә, аларга соклана. Әнисен шатландырырга теләп, чәчәкләрне өзә дә, әнисенә бүләк итә. Әнисе, чәчәкләрне күргәч. бик шатлана, улына рәхмәт әйтә , ләкин, чәчәкләрнең каян алынганын белгәч, чәчәкләрне улына кире бирә, күңелсезләнә. Әхмәт, чәчәкләрне газатага төреп, кабат бакчага әйләнеп кайта. Чәчәк түтәлләре янында бакчачы карт утыра. Бакчачы үзенең хәсрәтен Әхмәткә сөйли. Әхмәт елап җибәрә. Бакчачы карт барысын да аңлый. Инде өзелгән чәчәчкләр кире терелмәсәләр дә, Әхмәтнең терелүендә өмет бар. Малай үз хатасын аңлады, бүтән ул ялгышын кабатламас, кеше хезмәтен кадерләр, үзе дә чәчәкләр үстерә башлар. 8 че сыйныфта өйрәнелгән ике әсәрдә дә экологик тәрбия белән әхлакый тәрбия зур бәйләнештә.

Татар әдәбияты дәресләрендә экологик һәм әхлакый тәрбия зур чагылыш тапкан. Һәр сыйныфта да игътибарга лаек хикәяләр күп. Балаларыбыз табигатьнең файдасын белеп, аны кадерләп, чистартып торсыннар иде. Табигатебез зур дәвалау сәләтенә ия. Табигатебезне пычратмыйк, саклыйк. Шәһәр җирендә дә матурлыкны үз кулларыбыз белән үстерик. Дәреслекләрдә тәрбияви әсәрләрнең күп булуы бик шатландыра.

Мин үземнең чыгышымны шигырь юллары белән тәмамлыйсым килә:

Яралы кошлар кебек
Сызлана үләннәр дә,
Табигать мәрхәмәтле,
Кадерен белгәннәргә.
Матурлыклар кипмәсен,
Урманнарда, болыннарда,
Барча тереклек калсын.
Киләчәк буыннарга.

З.Минһаҗова

Кулланылган әдәбият:

Хәйдәрова Р.З., Р.Л.Малафеева. Татар теле: Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәкт. 3 нче сыйныфы өчен дәреслек – Казан: Мәгариф, 2006

Хәйдәрова Р.З., Р.Л.Малафеева Татар теле: Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәкт. 8 нче сыйныфы өчен дәреслек (рус телендә сөйләшүче балалар өчен) / – Казан: Мәгариф, 2007.

## «Экологическая проблема лесов в произведениях А.П. Чехова»

***Валиуллина Э.Т.,***
***преподаватель русского языка и литературы***
***ГБПОУ «Лубянский лесотехнический колледж»***

Цели работы: изучить произведения писателя, в которых затрагивается экологическая проблема, и выяснить, какую роль в них играет лес.

Задачи работы:

• выявить особенности употребления образа леса в произведениях А.П. Чехова;

• рассмотреть основные проблемы, связанные с защитой лесов, выдвигаемые А.П. Чеховым в своих произведениях.

Актуальность работы: 2017 год объявлен Годом Экологии, поэтому изучение произведений, в которых эта проблема имеет место, актуально на сегодняшний день.

Природа нередко занимает особое место в произведениях Чехова. Природа у него - символ прекрасной жизни. В его пейзажах мы видим стремление писателя к единству добра и красоты через воссоединение с окружающим миром.

О своем отношении к лесу, о его великолепии и значимости писатель не раз говорил устами своих героев различных произведений.

А.П. Чехов посадил собственноручно не одно дерево. Он развел целый сад обычных для нас, а также экзотических деревьев. Сажая с заботой каждое дерево, он как ребенок радовался успеху и плодам своего труда. Кусты приживались, росли и приносили истинное наслаждение писателю и радовали глаз многим.

Чехов относился к лесу с уважением. Он был не просто «посетителем» леса, а при каждом своем визите делал определенные наблюдения, сопоставлял с увиденным ранее, делал выводы и вел свои записи. По ним можно было изучать как географию, так и ботанику.

Экологическая проблема была актуальна в двадцатом веке, сегодня она волнует нас все больше и больше. Но, оказывается, еще в девятнадцатом веке эта проблема волновала людей и имела место быть. Люди задумывались о пагубном влиянии человека на природу, об

уничтожении лесов. Антон Павлович Чехов – один из первых, кто заговорил об этой проблеме устами своих великолепных героев

Любя природу, говоря о бездумном уничтожении лесов, сам своими руками сажал и сажал деревья.

В 1887 году Чехов пишет рассказ «Свирель», где показаны важнейшие экологические проблемы России того времени. О них говорит не барин, не интеллигент, не ученый, а малограмотный и нищий пастух. Но этот «человек из народа» искренне любит свою страну и переживает за ее судьбу. Именно из его уст исходят слова о защите русской природы.

«– Все к одному клонится. Летошний год мало дичи было, в этом году еще меньше, а лет через пять, почитай, ее вовсе не будет. Я так примечаю, что скоро не то что дичи, а никакой птицы не останется.

– И леса тоже, – повторил пастух. – И рубят их, и горят они, и сохнут, а новое не растет. Что и вырастет, то сейчас его рубят; сегодня взошло, а завтра, гляди, и срубили люди – так без конца и краю, покеда ничего не останется, Пригляделся я за свой век и так теперь понимаю, что всякая растения на убыль пошла».

«Вишневый сад» - пьеса, в которой мы слышим символичный стук топора. Этот звук означает уходящую Россию с ее девственными лесами, на месте которых возникают города, дачные домики. А леса исчезают, гибнут. Они вырубаются с легкостью, но тяжело восстанавливаются. «Вишневый сад» становится символом погубленной красоты, показывает пошлость и никчемность жизни тех людей, которые говорят и действуют в пьесе.

Чехов неоднократно возвращался в своих произведениях к экологическим проблемам России. В пьесе «Дядя Ваня» тема экологии звучит также остро. В уста доктора Астрова Чехов вложил своё отношение к природе. Здесь под маской сельского врача, конечно, выступает сам Чехов.

«...Раньше половина площади была занята лесом. Где по зелени положена сетка, там водились лоси, козы... Я показываю тут и флору, и фауну. На этом озере жили лебеди, гуси, утки и, как говорят старики, птицы всякой была сила, видимо-невидимо: носилась она тучей.... Разрушено уже почти все, но взамен не создано еще ничего». В общем, картина постепенного и несомненного вырождения.

Доктор Астров с горечью говорит: «Русские леса трещат под топором, гибнут миллиарды деревьев, опустошаются жилища зверей и птиц, мелеют и сохнут реки, исчезают безвозвратно чудные пейзажи <…>. Человек одарен разумом и творческой силой, чтобы преумножать то, что ему дано, но до сих пор он не творил, а разрушал. Лесов все меньше и меньше, реки сохнут, дичь перевелась, климат испорчен, и с каждым днем земля становится все беднее и безобразнее».

Проблемы экологического оскудения земли российской, проблема вырубания лесов, возможно впервые в литературе, изложены в диалоге доктора Астрова.

Таким образом, любовь Чехова к природе неразрывно связана с любовью к самому человеку. Он утверждает, что если нет любви к одному, то нет её и к другому.

Источники:


1. Евгений Бузни. Наболевший вопрос (А.П. Чехов защищает лес)
2. Громов М. П. Сады и степи Антона Чехова // Громов М. П. Книга о Чехове. - М., 1989.
3. http://sochineniye.ru/rol-prirody-v-proizvedeniyah-chehova/


## Әмирхан Еники. “Матурлык” хикәясенең тәрбияви роле


***Вафина Альмира Мөхәмәтнәҗип кызы***
***Казан шәһәре Авиатөзелеш районы***
***“62 нче мәктәп”нең***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы***


Миңа калса, язучы һәрвакыт матурлыкка сусап, матурлыкны сагынып яшәргә тиеш... Гыйбрәт алыр,күңелне баетыр, теләкләрне үстерер өчен генә түгел, һәртөрле түбәнлек-ваклыклар, ямьсезлек-әшәкелекләр белән килешмәс өчен, шуларга нәфрәт саклар өчен дә кирәк бу...

Әмирхан Еники

Автор ни өчен бу хикәясен “Матурлык” дип атый? Нәрсә соң ул матурлык? Дөньяда яшәр өчен табигый матурлык кына җитәме? Нинди матурлык турында сөйләнә? Бу матурлыкның көче нәрсәдә?

Әйтергә кирәк, Әмирхан Еники бу әсәрендә матурлыкны түбәндәге образлар һәм мөнәсәбәтләр аша ача:

1. Шәкертләрнең бер-берсенә булган хөрмәтләре.
2. Бәдретдин.
3. Табигать матурлыгы.
4. Гаиләдәге җылы мөнәсәбәтләр.
5. Ана белән баланың самими мөнәсәбәте.

Хикәя өч шәкертнең өяз мәдрәсәсеннән авылларына кайтып барулары белән башланып китә. Дус, тату, бер-берсен ихтирам итү, юлдашларын аңлау, бер атта кайту шәкертләр арасында булган җылы мөнәсәбәтне күрсәтә. Хикәядә очраклы юлдаш – шәкерт Бәдретдин образына зур урын бирелә. Рәхимсез мохтаҗлык тарафыннан күпме генә эзәрлекләнсә дә,

Бәдретдин бик сәләтле, тырыш, ярдәмчел һәм сабыр. Нинди генә авырлыклар кичермәсен, Бәдретдин укуын дәвам итә. Ул үз көнен үзе күрергә тырыша. Хәтта каникулга кайтканда ата-анасына күчтәнәч тә алып кайта: “Бәдретдин үзенең сандыгыннан бер-ике уч шикәр алып, шуны ашъяулык уртасына салды”,- дип языла бу хакта хикәядә [1: 222].

Әмирхан Еники хикәясендәге язгы табигать күренешләренә зур урын бирелә. Яз һәркемгә бәхет, шатлык, күңел күтәренкелеге, сафлык, чисталык алып килә. Хикәя геройлары да табигать матурлыгын күрә беләләр һәм аның белән хозурланалар. Әдип шулай ук әсәрдә тургай сайравын да очраклы рәвештә кертми. “Юл буе безне тургайлар сайравы озатып барды. Гүя менә төпсез нурлы күктән өстебезгә сихри бер моң тибрәнеп-чыңлап, өзлексез явып торды. Ә беләсезме, тургай сайравының сихере нәрсәдә?.. Иң элек, сынаганыгыз бардыр, тургай сайраганда җир өстенә җиңелчә генә уйчан-моңсу бер тынлык җәелә. Әйтерсең, барлык табигать, барлык җан иясе, әдипләр әйткәнчә, сөкүт калып, тәмам мөкиббән китеп, бары аны гына тыңлый, аны тыңлап, сөенечле, сагышлы, ләззәтле бер рәхәткә чума... Икенче сихере шунда ки, тургай сайраганда дөнья ничектер искиткеч җәелеп, киңәеп, яктырып киткәндәй була. Әнә шул югарыда кечкенә кошчык талпынган күкнең үзе шикелле үк, җир йөзе дә иксез-чиксез булып, гаҗәеп тын, нурлы булып тоела башлый” [1: 221]. Бу гаҗәеп кечкенә генә кошчык шулкадәр сихри сайрый, дөнья яктырып, киңәеп киткәндәй була. Бөтен дөнья нурга күмелгән, искиткеч, гаҗәеп матурлык! Менә мондый матурлыкны күрә белгән бала гына тәрбияле бала була ала, безнеңчә.

Алга таба әсәрне уку барышында без матурлыкка каршы куелган ямьсез урыннар табабыз. Ләкин беренче күргәндә ямьсез, чирканчык булып тоелган әлеге ямьсезлек тора-бара матурлыкка әйләнә. Шәкерт башта аптырый, аннан соң гаҗәпләнә, соңрак бу матурлыкка соклана башлый. Шәкерт матурлыкны нәрсәдә күрә соң? “Матурлык барысында да: Бәдретдиннең әнисендә дә, әтисендә дә, үзендә дә, хәтта сукыр бабайда да. Ләкин бу матурлык аерым-аерым матурлык түгел. Ул бу иске өйдәге ямьсез, имгәнгән кешеләрнең үзара мөнәсәбәтендә. Өй эчендәге хәерчелек, тузганлык, ятимлек эченнән, чәчәк кебек, бу кешеләрнең үзара яратышуы, татулыгы, мәхәббәтләренең риясызлыгы һәм табигыйлеге үсеп чыга [4: 64]. Аның күңеленең матурлыгын без, ярлы булса да, аннан оялмыйча, кимсенмичә егетләрне кунакка алып керүендә, әти-әнисенә булган мөгамәләсендә күрәбез. Әсәрдә халкыбызның гореф-гадәтләре, әхлак кагыйдәләре ак сызык булып күренеп бара. Әтисе белән тыйнак кына күрешәләр. “Улым” дип күрешү аша гына алар бөтен сагынуларын, бер-берсенә булган ихтирамнарын белдерәләр.

Әсәрнең төп көче, матурлыгы – аның бала белән ана арасындагы булган мөнәсәбәттә. Чәй өстәле әзерләнгәч, Бәдретдин, йомшак кына дәшеп әнисен чакыра. Әнисенең рәхимсез чәчәк авыруыннан бер күзе кысылып, икенчесе зураеп калган, кашсыз-керфексез. Бәдретдин

әнисенең ямьсезлегеннән һич тә уңайсызланмый, оялмый. Димәк, ул ямьсез хатын гына түгел, ә Ана кеше икән. Алай гына да түгел, ул гыйлем иясе булачак кешенең анасы, шуңа да Бәдретдин белән бик горурлана. Ана кеше ямьсез була алмый.

Шулай итеп, Бәдретдиннәр өендә моңа кадәр башларына китермәгән матурлыкны күреп, шәкертләр шакката. Бу хәерче гаилә эчендә биләп алган мәхәббәт хисе аларның матурлыкка карата булган фикерләрен үзгәртә. Матур нәрсәдә генә матурлык күрергә өйрәнгән шәкертләр дөньяның үзләре белмәгән ягын ачалар. Алар дөньяның матурлыгы нәрсәдә икәнлеген аңлап китәләр: "... Кемгәдер йодрык селкеп, кычкырасым килә: ямьсез түгел бит ул, матур бит ул, матур, матур Бәдретдиннең әнисе!" [1: 232].

Әмирхан ага Еники үзенең әсәрләрендә кешеләрнең эчке кичерешләрен, хис-тойгыларын, күңелнең кадерле серләрен, матурлыгын, үзәк өзәрдәй сагышны, сөенеч һәм көенечләрне үзенә генә хас булган язу алымы ярдәмендә күрсәтә. Чыннан да, төп әһәмият тышкы матурлыкта түгел, ә күңелдә, йөрәктә, уйларда.

Библиография.

1. Еники Ә. Матурлык // Әмирхан Еники. Әсәрләр. 1 том. Хикәяләр.- Казан: Тат.кит.нәшр., 2002. – 411 б.

2. Еники Ә. Әсәрләр, өч томда. 3 том: Хикәяләр.- Казан: Тат.кит.нәшр., 1991.- 416 б.

3. Хатипов Ф., Сверигин Р. Яшәү мәгънәсе // Мәгариф.- 2009.- №3.- 6 б.

4. Яхин А.Г. 5 нче сыйныфта әдәбият дәресләре.- Казан: Мәгариф, 2006.- Б.64

## Әхлакый-экологик белем һәм тәрбия бирүдә әдәби әсәрләрнең әһәмияте.

***Ваһапова Зөлфия Мансур кызы,***
***Нурлат аграр техникумы ;***
***Хәйбуллова Халисә Минзакир кызы,***
***Нурлат аграр техникумы***

Әхлакый-экологик белем һәм тәрбия бирүдә әдәби әсәрләрнең әһәмияте зур. Язучыларыбыз, беренчеләдән булып, табигатьне саклау турында чаң сукты. Әйләнә-тирә дөньяны, кеше сәламәтлеген, аның рухын, телен саклау аларны иң борчыган һәм дулкынландырган проблемага әйләнде. Нәфис сүз, сәнгать чаралары ярдәмендә кешедә югалып бара торган иң изге әхлакый-рухи кыйммәтләрне торгызу, Җир-анага игелек, хөрмәт

хисләрен ояту, кешелекнең экологик һәлакәт каршында торуында искәртергә кирәк иде. Якташ шагыйрәбез Роза Мәсләхова шигырендәгечә:

Саклагыз Җир тереклеген,
Табигатен саклагыз,
Җирдә яшисегез килсә,
Кануннарын ятлагыз!
Саклагыз елганың моңын,
Тынычлыгын, сафлыгын,
Зәңгәр күлне сихри иткән
Аккошларның аклыгын. – дип әйтәсе килә. [4, б. 18]

Бүгенге көндә табигатьнең кеше белән бәйләнеше проблемасы кискен тора, чөнки кеше җирдә җимергеч эш-гамәлләр кыла. Аларны ничек булдырмый калырга? Гомумән, кеше табигать белән ярашып яши аламы, кеше табигать белән бербөтенме, әллә кеше табигатьнең патшасымы? Элек-электән үк кеше белән табигать аерылгысыз булган. Кеше үзен беркайчан да табигатьтән өстен куймаган. Кеше белән табигать бербөтен булганда гына, тормыш елдан-ел матурлана ала. Бүген кеше табигатькә бәйле дип әйтү генә дөрес булмас иде, чөнки табигатьнең язмышын кеше дә хәл итә, ул экологик тотрыклыкны саклап калырга бурычлы. Татар әдәбиятында кеше белән табигать мөнәсәбәтләрен күрсәткән әсәрләр байтак.

Хәзерге әдәбиятта иң талантлы язучыларыбызның берсе - Н. Гыйматдинова иҗатында табигать һәм кеше мөнәсәбәте темасы төрле яклары белән ачыла. Күп санлы укучылар тарафыннан яратып кабул ителгән «Сихерче» повестендә ул әлеге теманы повесть жанрында ачып бирергә омтыла һәм табигать белән гармоник яшәү өчен көрәш башлаган геройны әсәрнең үзәгенә куя. Әсәрдә язучы укучының игътибарын геройның табигатькә, тормышка, андагы үсеш-үзгәрешкә, тирә-юньдәгеләргә мөнәсәбәтенә юнәлтә. Төп героиня Сәвиләнең максаты - табигатьне саклау, башкаларны да шуңа өндәү, кешелек өчен «әнисе кебек кадерле булырга тиешле хәзинәне» югалтмау. Шушы максатына ул гомере буе тугрылыклы кала. Н. Гыйматдинова кешеләрнең табигатькә карата үзләрен ерткычларча тотуларын тормыш фаҗигасенә китерә дип саный. Язучы табигатькә җавапсыз карау һәм аның бөтенлеген җимерүнең бик зур югалтуларга китерүен ышандырырлык итеп тасвирлый. Беренче карашка болынга терлек кертү, басу-кырларга ашлама сибү гадәти күренеш кебек. Повестьның табигатькә битараф геройларына да шулай тоела. Әдибә моңа башка күз белән карарга мәҗбүр итә: «ашлама сиптерелгән, тапталган болында күп кенә үсемлекләр харап булган, бөҗәкләр юкка чыккан». Сәвилә тарафыннан әйтелгән түбәндәге сүзләр дә бу фикерне раслый: «Ә бит кешеләр, һаман саен табигать белән бәйләнешен өзә

бара, аның нәтиҗәсендә коточкыч фаҗигагәләргә юлыга: авырый. Дөньяга гарип-гораба туа, әшәке чир аза, им табылмый торганы...» [2, б. 108]

Геройның әле балачагын, уку дәверен тасвирлаганда ук, язучы аның табигатькә, кош-кортларга, бөҗәкләргә, үләннәргә карата бик игътибарлы булуын, биология фәненә карата артык кызыксынуын билгеләп үтә, мәктәпне гел бишкә тәмамлавына басым ясый. Нәкъ менә шушы сыйфатлары кызны җәмгыятьтән, кешеләрдән читләшкән, ялгыз образ — Убыр белән аралашуга, аның белемнәрен үзләштерүенә, соңрак санитарка, табибә булып эшләвенә этәргеч була. Героиняның авыл тормышын күрсәтүен тәмамлаганнан соң, әдибә сюжет үстерелешен кискен үзгәртә. Сәвиләнең кылган изгелекләрен, яхшылыкларын халык күрми, сүзләрен ишетми. Өзелеп сөйгән яры — Тәминдары да аны аңламый. Бердәнбер аны якын күрүче кеше — Убыр. Ул гомере буе кешеләргә изгелек кенә кылган, әмма авылдашлары аңа «убыр» дигән ямьсез исем ябыштырып, үлгәч йортына ут салу белән җавап бирәләр. Ул мәңгегә кешеләр арасыннан сөрелгән, читләтелгән, ялгыз образ. Сәвиләдә дә шул ук язмыш. Сөйгән яры, авылдашлары аңа «сихерче», «күз буячы» дигән исем бирәләр. Әлеге каршылыкның ни дәрәҗәдә җитди икәнлеген күрсәтү өчен, әдибә әсәрнең исеменә үк «Сихерче» дип куя.

Героиня шәһәр тормышына кул селтәп, күп михнәтле юл үтеп, ул туган җиренә, туган якларына кайтып ямь таба. Шунысын билгеләп үтәргә кирәк, әсәрдә Сәвилә авызы аша язучының бүгенге гаҗәеп катлаулы, каршылыклы, аңлаешсыз чорга бәясе бирелә: «Әйе, чоры шундый, яхшылык белән изгелек тартыша... Табигатьтән аерылганга күрә адәмнең иманы юк, күңелемдә шуңа кара уй, кара фикер... Җирне тимер басты... Кая карама тимер атлар үкерә, тимер гәүдәләр йөгерешә, күктә тимер ат оча... тимер кешене сыта, изә, таптый...» [2; 89], «табигать —халык байлыгы» дип, бугаз киереп кычкырган чорда, син чын кайгыртучыны, чын хуҗаны табалмассың...» [2; 120]. Шул рәвешле, Н. Гыйматдинова «Сихерче» әсәре белән беренчеләрдән булып үз заманының реаль тормышына мөрәҗәгать итеп, аның актуаль мәсьәләләрен күтәреп чыга. Шул ук вакытта ул табигатькә карата күңелләрдә мәхәббәт уята, моңа кадәр битараф булганнарны уйландыра, шул гүзәллекне сакларга кирәклеген аңларга ярдәм итә.

Кулланылган әдәбият

1. Гыйлаҗева-Хәмидуллина, Р. Сихерчеләр кирәк дөньяда / Р. Гыйлаҗева-Хәмидуллина // Казан утлары. — 1994. — № 4.

2. Гыйматдинова, Н. Сәвилә: повестьлар, хикәяләр. / Н. Гыйматдинова. — Казан: Тат. кит. нәшр., 2001.

3. Заһидуллина, Д.Ф. Әдәби әсәргә анализ ясау: Урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма. / Заһидуллина Д.Ф. — Казан: «Мәгариф» нәшр., 2005.

4.Мәсләхова Р. Киекле-киек иле/ Казан: ООО “ОФСЕТ”, - 2003.

## Нәбирә Гыйматдинова иҗатында табигать образлары

***Вәлиева Гүзәл Данис кызы***
***Казан шәһәре Авиатөзелеш районы***
***«62нче мәктәп» нең***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

Әдәбият күгендә сиксәненче- туксанынчы еллар ахырында калкып чыккан язучылар арасында, инде бүгенге көндә популярлашып киткән Нәбирә Гыйматдинова исемен дә күрергә була.

Нәбирә Гыйматдинова күбесенчә табигать турында язарга ярата. Аның иҗатында еш очрый торган образларның берсе- кош образы. Кошлар элек- электән изге җаннар булып саналганнар. Тасвирларга алынган темаларның яңалыгы, геройларның эчке кичерешләрен табигатьтәге үзгәрешләр белән үреп бирүе Нәбирә Гыйматдинованы аерып тора.

"Ак торна каргышы"- авторның иң матур һәм фаҗигале әсәрләреннән берсе.Торналарның табигатьтәге ирекле, соклангыч кошларның игътибар үзәгенә куелуы, язучының бөтен әсәр буйлап үтә торган фикерен- табигать белән кешенең берлеген, кешенең җәмгыять законнарына буйсынып түгел, табигый кануннарны саклап яшәргә тиешлеге хакындагы субъектив идеясын калку итә.

"Каракош" повесте- авторның иң фаҗигале һәм мифологик күренешләр белән язылган әсәре. Әсәрдә табигатькә каршы бармаска чакыру идеясы сурәтләнә. Рәхимҗанның кара каргаларга мылтык белән атып, табигатькә каршы чыгуы, аларның ояларын туздырып, балаларын үтерүе үзе өчен дә аяныч тәмамлана. Кара кош аны үлек базына ыргыта.

Повесть проблемалар ягыннан "Ак торна каргышы" әсәренә охшаш. Тигезсез мәхәббәт, җавапсызлык, азгынлык, куркаклык, табигатькә сак караш мәсьәләләре,кеше белән кеше, кеше белән табигать, кеше белән җәмгыять арасындагы конфликтларда ачыла, шулай ук заман кешеләренә һәм җәмгыятькә бәя бирүгә хезмәт итә.

Йомгаклап шуны әйтергә кирәк, Нәбирә Гыйматдинова үз әсәрләрендә укучы игътибарын төрле мөһим проблемаларга юнәлтә. Шушы әсәрләре аша язучы бүгенге көндә табигатьтәге образларның ничаклы актуаль булуын сурәтләргә тели.

## Ыкта сал агызып буламы?

***Вәлиева Зөлфия Насих кызы***
***беренче квалификация категорияле***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы***
***ТР Мөслим муниципаль районы***
***“Түбән Табын сәламәтлекләре чикләнгән***
***балалар өчен мәктәп-интернаты”***

Уралып-уралып ага
Мөслимнең Ык сулары,
Шул суларны эчеп үсә
Эшчән, матур кызлары.

Безнең Мөслимебез табигатьнең кыш көне иң салкын, җәй көне иң эссе урынына урнашкан. Башкортстаннан юл алган Баулы, Азнакай районнарын үтеп, Мөслимне икегә аерып торучы тал-тирәкле, зифа камышлы Ык елгасы тирә-якка яшәү көче бирә.

Минем туып-үскән Тугаш авылы яныннан, алай гына да түгел, безнең бәрәңге бакчасы артыннан гына борылып-борылып ага ул Зифа Басыйрова җырындагы Ык елгасы. Эх, андагы су керүләрнең рәхәтлеге! Балаларның чыр-чуыннан бөтен югары оч шаулап торыр иде.Суда нинди генә уеннар уйналмады! “Кем беренче?”-дип өс киемнәрен сала-сала килә һәм беренче булырга тырышып суга чума идек. Артта калганнар суның салкынлыгыннан куркышып торсалар, аларга су чәчрәтәбез.Чәчрәткән су бигрәк тә салкын тоела.

Ык елгасы элекке вакытларда бик киң һәм тирән булган. Анда шулай ук сал да агызганнар. Шагыйрә үзенең “Әй, кешеләр” шигырендә әйткәнчә:

Газиз җирем – Салавыз-Мухан.
Бабам Ыкта сал агызган.
Шул салларың утырып агар идем,
Алларыма син чыгар булсаң.

18гасыр азагында 19 гасыр башында Ык елгасы су юлы булып файдаланылган, су баржалары Ык буйлап Минзәләгә кадәр икмәк, бодай төяр өчен менә торган булганнар. Сал агызу өчен дә файдаланылган.

Авылның яшьләре шул вакытта җырлаганнар, думбра чирткәннәр, сазын уйнаганнар. Ләкин киткәннәрнең барысы да кайта алмаганнар шул. Ыкта давыл да күп булган, сал әйләнгән вакытлар да гел булгалап торган.

Авыл халкын гына түгел, якын-тирә авылларны да тәэмин итеп торучы су тегермәне эшләп торган Ыгыбызда. Тегермәнне әйләндерерлек көчле агымы, тирәнлеге дә булган бит аның! Аръякка чыгу өчен ел да авыл халкы көче белән күпер салынды. Күпер төзелгәнче савымчыларны көймәләр белән йөртәләр иде.

Бозлар кайный, бозлар борыла,

Бозлар актарыла.

Боз киткән вакытларда авыл халкы шунда җыела иде. Ык буе тальян моңыннан чыңлап торган. Зурлар гармунга кушылып җырласа, балалар төрле уеннар уйныйлар иде. Кичен исә яшьләрнең, егет-кызларның очрашу урыны була иде ул. Яр буендагы биек-биек таллар күпләрнең яшерен серләрен сакладылар.

Шау чәчәкле шомырт,баланнарың

Гашыйкларның серен сыйдырган.

Язгы ташу вакытларында әрәмә су астында калган. Ык суы йортлар урнашкан биек тауның уртасына кадәр күтәрелгән. Авылның түбәнге өлешендәге йортларга су кергән. Җәй уртасына кадәр җыелып торган су колхозның яшелчә бакчасында төрле яшелчәләр үстерү өчен бик яхшы була иде.

Булган монда борын карурман,

Күпме качкын шунда сыенган.

Вакытлар үтү белән, Ык елгасының суы бик кимегән, чөнки сугыш чорында, ягарга булмагач, авылым кешеләре агачларны кискәннәр, соңрак колхозның терлекләр көтүе җәен шунда тукланды. Сыерлар утарын да елга буенда төзеделәр. Әрәмәлекләр беткәч, язгы ташу суы белән килеп, авыл

янында утырып калган агач төпләрен уфалла арбасына талдан үрелгән чуман утыртып җыя идек. Бу авыл кешесенә мичкә ягу өчен кулланылса, печәнле болынны чүптән чистарту да булган икән. Хәзер исә, җәй буена болында, күллектә эшмәкәрләрнең каз көтүе йөри. Кош тизәгенең бик нык тәэсир итү көчен бар кеше дә белә, димәк киләчәктә әле болыннарыбыз бөтенләй чирәмсез калмас дип тә әйтеп булмый.

Болын уртасында ялгыз имән,

Бирешмәгән, йөз ел яшәгән.

Беркөн килеп гомерен өзгәннәр,

Төбе-тамыры белән кискәннәр.

Елга буендагы йөз еллык, икешәр кешенең колачы да җитмәслек дәү-дәү таллар да яр ишелүдән юкка чыктылар. Ык аръягындагы авылга чыгу юлы да юк: күпер яки басма салу гадәте бетте. Йортларга газ ялгангач халыкның утынга ихтыяҗы да кимеде. Экологларның саллы-саллы штрафлары ярдәмендә елга буен пычрату, чүп түгү дә бетте. Ләкин кышын түгел, җәй көннәрендә дә анда беркем дә кер чайкарга бармый, чөнки Ык суы бик нык пычрак, андагы микробларның иге-чиге, хисабы-саны юктыр. Ык кибә. Ык тарая. Киләчәктә ул бөтенләй кибеп тә бетәр инде.

Энҗе бөртек Ыгым кара кучкыл,

Көне-төне агып торса да.

Шикләнәләр: хәзер инде беркем

Кер чайкамый анда-басмада.

Елга буенда түгел, урамда да хәзер бала-чага тавышы ишетелми. Балалар бакчалары, мәктәпләр ябылды, терлек асрау да бетте, яшьләр дә эшсезлектән читкә киттеләр. Ара-тирә элеккеге матурлыкны, ямьлелекне, яшьлекләрен сагынып, моңланып, йөрәк түрендәге күңелле мизгелләрне искә төшереп салмак атлап баручы өлкән яшьтәге әби-бабайларны гына күрәсең.

Әй, Кешеләр! Уйланыгыз әле:

Нишләттек соң без бу дөньяны?!

Нәрсә көтә туар баланы,

Ыкта сал агызып буламы?!

Җирсез-сусыз яшәп буламы?!

Кулланылган әдәбият.

1. Хәйдәрова В. Елар чакта көл икән. – Казан: “Школа” редакция-нәшрият үзәге, 2015. Б.26,27.

2. Хәйдәрова В. Мизгел. – Мөслим: Матбугат үзәге, 2004. Б.92-93.

## «Татар әдәбияты дәресләрендә Муса Җәлилнең шигырьләре аша балаларны әхлаки һәм экологик яктан тәрбияләү»

***Вәлиева Лира Марсил кызы***
***Алабуга муниципаль районы***
***“11 нче төп белем бирү мәктәбе” нең***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

**I.Кереш өлеш.**

Муса Җәлил-бөек шәхес.Ул бик күп матур әсәрләр язган шагыйрь.Бу фәнни эштә без М.Җәлилнең балалар өчен язган шигырьләренә тукталып үтәрбез.Татар әдәбияты дәресләрендә балаларны әхлакый һәм экологик яктан тәрбияләү проблемаларына тукталырбыз.

Бу эшнең **актуальлеге** шунда, М.Җәлилнең бай әдәби эшләре хәзер дә балаларны тәрбияләүдә чиксез байлык булып тора.

Үземнең бу эшнең **бурычы** итеп,М.Җәлилнең әсәрләрен тирәнтен өйрәнү һәм балаларны әхлакый йәм экологик тәрбияләүне өйрәнү итеп билгеләдем.

Эшемнең **объекты**:М.Җәлилнең иҗаты.

Эшемнең **максатлары:**

1.М.Җәлилнең балалар өчен язган әсәрләрен өйрәнү;

2.Балаларны әхлакый һәм экологик яктан тәрбияләүне өйрәнү.

**Әзерләнү базасы**:мәктәп китапханәсе,авыл китапханәсе.

**Эшнең структурасы һәм күләме**:кереш өлеш,төп өлеше (2 бүлек),йомгаклау,кулланылган әдәбият.

**II.Төп өлеш.**

**I бүлек.Татар әдәбияты дәресләре барышында балаларга тәрбия бирү.**

Дәресләрне мәктәптәге тәрбия эшенең үзәге дип әйтергә була. Дәресләр, гомумән, тәрбия эшенең барлык өлкәләренә дә кагыла. Алар аңлы дисциплина тәрбияләүдә аеруча мөһим роль уйный. Дәресне башлап җибәрү алдыннан укытучы сыйныф бүлмәсендә чисталык-пөхтәлек торышына игътибар итәргә тиеш. Дәреснең башы, аның барышы – тәрбия чарасы. Сыйныфта тулы тынлык, ныклы тәртип урнаштырмыйча, укучыларның игътибарын тупламыйча торып, дәресне башлап җибәрү һич тә ярамый. Әгәр дә инде укучылар тәнәфестән соң тиз генә тынычланып бетә алмыйлар, һаман шаулашалар икән, махсус педагогик алымнар белән аларның игътибарын яуларга, тынычландырырга, дәресне шуннан соң гына башларга кирәк.

**II бүлек. Муса Җәлилнең балалар өчен язган шигырьләре.**

Муса Җәлилнең шигырьләрен хәзер дөньяның төрле почмакларында укыйлар,ул төрле телләрдә яңгырый.Шуның белән бергә аның тормышы,иҗаты,көрәш юлы белән кызыксыну да көннән-көн үсә бара. Язучы үзенең фикерен образлы итеп күрсәтү өчен табигатьне җанландыра.Мәсәлән,”Вәхшәт” шигырендә

“Үзем күрдем,үз күзләрем белән.

Үкереп акты ничек елгалар;

Балалар күк ничек үкси-үкси

Яшен түкте ярсып җир-ана.”

Кешеләр генә түгел,хәтта барлык яхшы һәм яманны,матур һәм хәшәрәтне үз күкрәгендә асрарга мәҗбүр булган җир-ана да үкси-үкси елый.Табигать белән кеше арасындагы бәйләнешне күрсәтә.

Дүрт строфалы “Субуенда” шигырен алып карыйк.Кыска гына шигырьавтор кызылармеецбелән кызның су буенда очрашулары һәм аларның эш белән килүләре турында матур картина биргән.Егет кеше яр буенда атын юа.Басмада кыз “җитеннәргә су эчерә” һәм тыйнак кына яр читен күзәтә.

Елга ага бөдрәләнеп,

Кызның алтын чәче кебек

Кыз керфеген түбән сузып,

Битен каплап сорау бирә:

-Матур егет,әйтче миңа,

Кызылармееһ кемне сөя?

Кыз оялчан һәм тыйнак кына сорау бирә.Шушындый бай картиналы кыска шигырь тәмамлана.Аның дәвамы кирәкми.

“Кышкы шигырь» шигырендә Кояш-шагыйрьролендә.Ул кышның пейзажын нурландыра,кар шул нурларга төренеп оча.Шагыйрь табигатьнең ис китәрлек матурлыгын сурәтли.

Кыска булуына карамастан,тирән эчтәлек салынган “Сәгать» җырында шагыйрь баланы тәртипле булырга,вакытында уйнап,вакытында ял итәргә ,вакытында укырга барырга өнди.

Без карап үткән бу шигырьләрдә М.Җәлил укучының рухына үтеп керә,туган илнең табигать байлыклары,матур пейзажлары белән сокландыра,аның хисләре аша тормышны тагын да ныграк сөяргә өйрәтә.

**III. Йомгаклау өлеше. Нәрсә ул әхлак тәрбиясе һәм экологик тәрбия?**

Әхлак ул – кешенең эш-хәрәкәтләрендә , көндәлек тормышында билгеле бер калыпка салынган, билгеле бер кыйммәтләрдән торган сыйфат. Әхлаклылык сыйфатлары мәңгелек калып түгел, алар җәмгыятьтәге үзгәрешләр бәрабәренә үзгәреп торалар һәм шул рәвешле үзләре дә җәмгыятьне үзгәртәләр.

Әхлак һәм хокук үзара тыгыз бәйләнештә, алар бер – беренә тәэсир итәләр. Гадәтә, әхлак нормаларының иң катгыйлары хокук нормалары булып урнаша. Шуңа күрә дә, җәмгыять тормышында хокук һәм закон әлеге җәмгыятьнең нинди әхлак сыйфатларына табынып яшәвенә бәйле.

Экология тәрбиясе. Кеше – табигатьнең аерылгысыз бер өлеше.

Ул табигатьтән башка бер генә көн дә, бер генә сәгать  тә, бер генә минут та яши алмый; аңа су, һава, азык-төлек, торак, җылылык һәм яктылык кирәк. Шуңа күрә дә табигатька мөнәсәбәт, кешеләргә мөнәсәбәт кебек үк, гуманлы, шәфкатьле булырга тиеш.

Балаларда табигатькә әнә шундый мәрхәмәтле караш кечкенәдән үк тәрбияләнеп, аларның күңелендә чын гуманлылык рәвешендә урын алырлык булсын. Махсус бүлмәләрдә оештырылган тере почмаклар, төрле экскурсияләр, җәнлекләр һәм кош-кортлар турында, үсемлекләр турында лекцияләр һәм әңгәмәләр – болар барысы да балаларның табигать белән аралашуы, табигать белән мөнәсәбәткә керүе.

Укучы бала әлеге мәктәпнең эчке тәртипләрен белергә, аларны хөрмәт итәргә, үтәргә, укуга һәм хезмәткә, җәмәгать эшләренә җаваплылык белән карарга тиеш. Укучының үз бурычларын ни дәрәҗәдә үтәве аның тәртип мәдәниятендә чагылыш таба.

Кеше шәхесенә хөрмәт белән карау, аның ireген ихтирам итү һәм шул ук вакытта таләпчән була белү кебек диалетик берлектә генә балалар коллективында чын мәгънәсендә аңлы дисциплина, тәртип культурасы тудырып була, шул рәвешле генә югары культуралы, әхлаклы, гуманлы шәхес тәрбияләп була.

**IV.Кулланылган әдәбият:**

1.Рафаэль Мустафин.По следам поэта-героя.-К.: Татарское книжное издательство,1973.

2.Муса Җәлил.Моабит дәфтәрләре.-К.: Татарское книжное издательство,2000.

3.Гази Кашшаф.Муса Җәлил.-К.:Татарстан китап нәшрияты,1961.

4.Әнвәр Хуҗиәхмәтов.Тәрбия-мәңгелек фәлсәфә.-К.: “Мәгариф” нәшрияты, 2001.

## Туган телен кадерләгән халык кадерле булыр”

***Габтунурова Наилә Наил кызы,***
***Хадиуллина Әнисә Рашит кызы-***
***татар теле һәм әдбияты укытучылары,***
***Алабуга муниципаль районы***
***“2 нче урта гомуми белем мәктәбе”***
***гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе***

Әй син, телем, айлы төнем, якты көнем.
Әремнәрдән әче, балдан татлы телем.
Сине саклап калыр өчен, күпме белем
Кирәклеген аңладым мин, белдем бүген...
/Л.Шагыйрьҗан/

Телләрне саклау һәм үстерү - дәүләт күләмендәге, бөтен дөнья масштабындагы мөһим сәяси эш. Чөнки һәрбер тел ул - аз санлы кешеләрнеке булса да, күп санлы милләтнеке булса да - халык иҗат иткән чиксез кыйммәтле хәзинә. Тел яшәсә, халык та яши, тел бетсә, халык та бетә. Белгәнебезчә, дөньяда бик күп телләргә юкка чыгу, яшәештән туктау куркынычы яный. Тел юкка чыктымы, шул телдә сөйләшкән халык та юкка чыга дигән сүз, чөнки ул инде башка телдә сөйли, шул тел хуҗасы булган халыкча яши, уйлый башлый, алар телендәге мәгълүматны үзләштерә, ә аның үз бабаларының йөзләрчә ел үсеп-формалашып килгән мәдәнияте тел белән бергә юкка чыга.

Татар теленең хәзерге торышына караган ике җитди проблема бар. Беренчесе аның кулланылыш дәрәҗәсе, икенчесе - сыйфаты, сафлыгы һәм дөреслеге белән бәйләнгән.

Кулланылыш дәрәҗәсе дигәннән без татарларның туган телләрен күпмесе белүен һәм аннан ни дәрәҗәдә файдалануын күздә тотабыз. Олы яшьтәге һәм урта буын татар кешеләре гаиләдә күбрәк үз телләрендә сөйләшсә дә, шәһәр яшьләре һәм балаларының күбесе өйләрендә дә русча сөйләшә. Шәһәрдә туып үскән татар яшьләре һәм балалары уку йортларында да, нигездә, русча аралашалар. Беренчедән, яшь буынга һәм олыларга да татар халкыньң бай тарихын яхшы итеп, үтемле итеп өйрәтергә кирәк. Безнең тарихыбыз узләрен бөек дип санаган халыкларныкыннан бер дә ким түгел, анда күркәм сәхифәләр, фидакарьлек, батырлык үрнәкләре, горурлык хисләре уятырлык вакыйгалар бик күп.

Мондый максатларда беренче чиратта Мәгариф министрлыгына тарих дәреслекләрен, тәнкыйть күзлегеннән карап, тулы объективлык зарурлыгы таләпләрен куеп, ашыгыч рәвештә тикшереп чыгарга һәм, кирәк булса, төзәтеп, яңадан бастырып чыгарырга кирәк. Шулай ук татар халкы тормышының әһәмиятле чорларын яктырткан популяр китаплар да булырга тиеш.

Икенчедән, халыкта милли горурлык тәрбияләү өчен бик әһәмиятле һәм нәтиҗәле чара - татарларның бөек улларын һәм кызларын, күренекле шәхесләрен пропагандалау. Татар халкының яшьләрдә - аларда гына түгел, олыларда да - хаклы горурлык хисләре уятырлык күпме генә шәхесләре юк!

Милләт ул - теле булган халык. Милли тел язмышы ул - милләт язмышы, аның яшәеш, үсеш формасы, милләтнең сакчысы да, аның киләчәгенең гарантиясе дә. Кешелек әле милләтнең төп таянычы булган, йөрәк парәседәй нечкә, кадерле башка төр могҗизаны уйлап

тапмаган, таба да алмас, бу бөек көчне бернәрсә дә алыштыра алмый. Чыгышы белән татар булса да, үз телен белмәгән, шул ук вакытта үз халкын яраткан, аны сөйгән кеше дә милләтнең сакчысы, аның үсешенә өлеш кертә алган зат була алмый...[3, 16 бит]

И туган телем, мөкатдәс моңым, яшәешемнең бөек мәгънәсе булган могҗизам!

Безне тагын сөйләмебезнең саф булмавы борчый. Сөйләм саф булсын өчен, гасырлар буена тупланып килгән сүз байлыгын дөрес куллана белү таләп ителә. Туган телдә сөйләшкәндә, башка тел сүзләрен катнаштырып җөмлә төзү бу таләпне бозуга китерә. Тел уйнатуның наданлыкка ишарә булуын шагыйрь Дәрдемәнд узган гасырда ук әйтеп калдырган:

Кил,өйрән, и туган, бер башка телне,

Бүтән телләр белү – яхшы һөнәрдер.

Катыштырма вәләкин телгә телне,

Тел уйнатмак наданлыктан әсәрдер. Атаклы шагыйребез Дәрдмәнд күп телләр белүенә карамастан, Ана телебездә язганда, сөйләмендә дә чит-ят сүзләрне аралаштырмаган.

Мәҗит Гафури әсәреннән алынган менә мондый әңгәмәне саф сөйләмгә корылган дип кем генә әйтер икән?!”Ну,товарищ, ярминкәгә барасыңмы?

-Юк, нигә? Дахуты расхутка җитми торган нәрсә артыннан вримә тирәйт итеп йөрүе не стоит.“

Соңгы вакытта телнең рус сүзләре белән чуарлануында, саф булмавында, әлбәттә, катнаш никахларның да роле бик зур.“Бабай белән дедушка, бергә йөриләр эшкә”, – дип язган катнаш никахлар турында бер шигырендә Бари Рәхмәт.

Ә Хәсән Сәрьян телебез турында түбәндәге матур фикерләрне әйтеп калдырган: “Тел ул буыннан буынга ана сөте белән күчә килгән һәм күчәчәк иң мөкатдәс бер мирас булып, телен җуймаган милләтләрнең өстә ярылып яткан бердәнбер сыйфаты, билгеседер. Тел, ниһаять, – туган ил, туган җир ул!” Һәр кеше, бигрәк тә гаилә, татар шәхесләре булып, татар телен саклауда үзенең индивидуальлеген, йөзен сакласа, телне саклап калу, үстерү өлкәсендә үзеннән өлеш кертсә, милләтемнең һәм телемнең киләчәге ышанычлы булыр иде.

Әлбәттә, телне, милләтне саклау — безнең уртак бурычыбыз. Зыялылар, милләлпәрвәрләр, муллалар – без барыбыз да бер көймәдә, чөнки безнең милләтебез бер, без – татарлар! Әгәр телебез юкка чыга икән, барыбызга да кыен булачак .

Әдәбият

1. Ватаным Татарстан  газетасы, №236, ноябрь, 2010.

2."Мәдәни җомга" газеталары (№29, №30, №33; 2010).

3. Юсупов Р.А. Икетеллелек һәм сөйләм культурасы. – Казан: Татарстан китап нәшрияте, – 1987.-126б.

**Матур әдәбият битләрендә табигатьне саклауга өндәүче авылдашым.**

***Гадршина Алия Минефәрит  кызы,***
***“Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 69нчы Яр Чаллы мәктәбе” дәүләт бюджет гомуми белем учреждениесе***
***башлангыч сыйныфлар укытучысы***

Җир-Ана- ул бер могҗиза,
Иксез-чиксез хәзинә.
Бетмәслек сихри көчләрне
Туплаган ул үзенә.

Бүген җир-анабыз елый, сыкрый, җан авазы белән кешеләргә эндәшә. Шагыйрьләр, язучылар бу темадан читтә кала алмыйлар. Авылдашыбыз Садыйков Шиһабетдин абый 70 яшенә җиткәч, кулына каләм ала. Табигатьнең гүзәллеген дә, аның аянычлы хәлләрен дә үз йөрәге аша үткәреп әсәрләр иҗат итә. Быелгы экология елында аның шигырьләрен дәресләрдә, бәйрәмнәрдә куллану бик урынлы булыр, дип уйлыйм.

Кеше - табигать баласы. Авыл баласының тормышы урман, кошлар, су белән тыгыз бәйләнештә. Бу темага язу аңа кыен түгел.Автор шулар арасында , шулар белән яши.

Авторның китапларында аерым бер бүлек табигатькә, аны саклауга багышлана. Кайбер шигырьләренә тукталып китик.

“Күке” шигыренең башында күкенең аянычлы язмышы сурәтләнә һәм азагы әдәплелеккә килеп тоташа. Тиккә генә автор табигать белән кешелекне бергә бәйләми. Бу аның җан авазы кебек ишетелә.

“Чәчкәләр” шигырендә дә сүз табигать күрке булган чәчәкләрне саклауга багышлана.

Чәчәкләр дә кешеләрдән
“...мәрхәмәтлек көтәләр,
Өзмәгез, таптамагыз,диеп,
Ялварып үтенәләр”

Кошлар да яз җитүен зарыгып көтәләр. Укучы бу шигырләрьне укыгач, аның күңелендә кошларга карата миһербанлык хисләре уяначак. Авылда туып-үскән кеше буларак, язын кошлар кайтуны автор зур түземсезлек белән көтә.

Кош чире чыгуга да автор кайгыра .Бу турыда "Кош чире" шигырен язып, моңарчы ишетмәгән бетмәс афәт, хәвеф-хәтәр җир өсләренә иңгән булуына сызлана. Кош чирләрен туктатырга чара табылмауга, "ошбу чирне тыярга" кешелекнең көче җитмәвенә сыкрана.

Газета битләрендә, телевидение тапшырулары буенча без шундый мәрхәмәтле кешеләр барлыгын беләбез. Өлкән кешеләр балалары, оныклары белән бергә кошларны ашаталар.Авылда гына түгел, хәзер шәһәрдә дә кошларга җимлекләр куялар. Кече яшьтән үк табигатькә сак караш, мәхәббәт тәрбияләү үзенең җимешләрен озак көттермәс. Бу балалар начарлык кыла алмаслар.

Мин шагыйрьнең ике китабына күзәтү үткәрдем, бу җыентыкларда табигать, аны саклау һәм яклау темасына 45 шигыре кергән. Бу шигырьләрне укыган кешеләрнең барысында булмаса да яртысы ,бәлки, табигать турында кайгыртыр, дип уйлыйм. Табигать турында экология елында гына түгел, һәрдаим кайгыртып торырга кирәк. Башкарыла торган һәр эшкә дә кече яшьтән үк балаларны тартсак, тормыш матур, киләчәк ышанычлы булачак.

## Творческий проект как одно из средств воспитания духовно-нравственных качеств личности школьника (Из опыта работы)

***Гайфуллина Р. А.. учитель русского языка и литературы***
***МБОУ «Гимназия№1» г. Менделеевск***

Духовно – нравственное воспитание - это основа государственности, условие силы нашего народа, единства и величия России. В современном мире, где доброта, милосердие, патриотизм стали дефицитом, становится актуальным личностное, гражданское, духовное развитие подрастающего поколения. Особая роль при этом отводится урокам литературы. Одной из

главных задач учителя литературы является формирование духовно-нравственной личности на основе духовных и культурных традиций народа. Необходимое звено в процессе нравственного развития – моральное просвещение, цель которого – сообщить школьнику совокупность знаний о моральных принципах и нормах общества, которыми он должен овладеть. Осознание и переживание моральных принципов и норм прямо связано с осознанием образцов нравственного поведения. Басни И.А. Крылова – целый мир жизненных явлений и образов. Поступки и нравы героев басен – поступки и нравы человеческого общества. Благодаря изучению басен И.А. Крылова, дети глубже познают мир, получают представление о нормах поведения в обществе. Для заключительного урока по изучению басен мы с пятиклассниками задумали творческий проект «Театрализация басен Крылова». Проект позволил значительно увеличить количество изучаемых басен (для постановки выбрали 20 басен), способствовал расширению представления о творчестве великого баснописца,развитию творческого потенциала учащихся, формированию умения работать в команде.

Как поставить такой спектакль в рамках урока (гостями стали педагоги гимназии, родители), какие басни инсценировать, в каком порядке их расставить, как сделать декорации, чтобы они были многофункциональными, - над такими и другими организационными вопросами приходилось думать в процессе работы совместно с ребятами. Для пятиклассника очень важен успех в глазах товарищей, поэтому все 23 ученика класса были задействованы в постановке. На этапе распределения ролей, обсуждения плана работы и анализа текстов басен ребята проявили высокую степень заинтересованности и творчества.

Программу составили таким образом, чтобы спектакль смотрелся единым целым. В программе нет ничего случайного. Например, басни, в которых участвует Волк, идут подряд, одна за другой. Это как бы ряд эпизодов одной пьесы из жизни волка, каждый из которых раскрывает всё новые качества волка - его жадность, коварство, свирепость, неблагодарность, лицемерие. Так же

группировали вместе басни про обезьян. Такие группы басен, с одними и теми же персонажами, помогают спектаклю быть цельным, пусть даже этих групп не так много и они перемежаются баснями-одиночками.

Единство спектакля во многом зависит от оформления, от тех декораций, в которых протекает действие. Чтобы не заниматься перестановкой декораций, не мешать общему впечатлению, мы решили сделать одни декорации, общие для всех басен. В них можно было играть весь спектакль. Вместо деревьев использовали школьные комнатные растения. Одно большое дерево сделали из лестницы-стремянки, которую обернули коричневой тканью, листья сделали из бумаги. Сзади по ступенькам стремянок исполнители соответствующих ролей влезают на дерево и видны, когда нужно, сверху или по пояс. Около деревьев расставили четыре пня, ровно столько нужно для «Квартета». Таким образом, у нас получилось много игровых площадок.

Важную роль в постановке спектакля играют костюмы.  Не всегда удаётся одеть исполнителей в роскошные костюмы, поэтому мы постарались найти для каждого персонажа отдельные, самые характерные для него детали. Для Волка, например, самое характерное - лапы с длинными когтями, Ослу достаточно сделать длинные уши, Журавлю - длинный клюв.

Самое главное в постановке – исполнение ролей. Сначала мы подробно разобрали басни. В баснях Крылова нужно понимать буквально каждое слово, каждое выражение. В его произведениях встречаются имена из греческой и римской мифологии, из древней истории. Басню «Гуси», например, невозможно играть, не узнав о том, как «гуси Рим спасли». Или, например, кот Васька «слушает да ест» курчонка, в то время как Повар многословно уговаривает его:

А я бы повару иному/Велел  на стенке зарубить: /Чтоб там речей не тратить по – пустому,/Где нужно власть употребить. [1, с.84]

Смысл этих слов хорошо был понятен тогда всем. Подходил 1812 год. Наполеон шёл со своей армией на восток. О войне уже говорили все, но Александр I медлил, не принимал никаких решений и пытался договориться с Наполеоном. Положение было тревожное – это видели все истинные патриоты

России. Крылов не мог молчать: он понимал, что нельзя терять время, надо готовиться к бою и об этом смело, решительно сказал в своей басне «Кот и Повар».

«Волк на псарне», «Обоз», «Кот и Повар» - под пером Крылова эти басни превратились в живую историю, с которой ребята соприкоснулись в процессе подготовки спектакля.

Длительная совместная работа заметно сплотила коллектив класса. Ребята научились работать в команде, где успех складывается из старания, отдачи каждого участника. В процессе подготовки спектакля ребята по - новому взглянули на творчество великого баснописца. Как много правды о жизни, о людях сказано в этом маленьком стихотворном рассказе, как басня! Горькая правда звучит в его произведениях о злых, завистливых и чванливых людях, о лицемерах, взяточниках и ворах. Но в то же время им воспет талантливый, остроумный, трудолюбивый народ, его простая, образная и меткая речь. Басни Крылова призывают к честному труду на благо родине, учат мудрости.

В заключение хочется сказать, что творческие проекты дают большой простор для планомерной работы по духовно- нравственному воспитанию школьников.

Литература:

1.Крылов И. А. Басни /Примеч. Н. Л. Степанова. - М.: Худож. лит., 1983. – 303 с.

## Рус телле студентларга татар телен укытуда әхлак тәрбиясе

***Люция Рәхимҗановна Галәветдинова,***
***Түбән Кама педагогика көллиятенең***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

Татарстан Республикасы Конституциясенең 8 маддәсе нигезендә җөмһүриятебездә ике тел – татар һәм рус телләре – тигез хокуклы дәүләт телләре булып санала: «... Татарстан Республикасының дәүләт телләре

бертигез нигезләрдә кулланыла». Бу исә барлык белем һәм тәрбия бирү оешмаларында да, нинди милләт вәкиле булуына карамастан, һәр укучы ике телне дә тигез дәрәҗәдә өйрәнергә тиешлекне аңлата. Башка милләт халыкларына карата ихтирам хисе тәрбияләү максатыннан, белем бирү оешмаларында поликультуралы белем бирү турындагы карар кабул ителде. Поликультуралы уку-укытуның нигезе – уку процессында укучыларны төрле милләтләрнең культураларына якынайту, аралаша белү һәм төрле милләтле дәүләттә яшәргә өйрәтү. XXI гасыр укыту системасының төп бурычы – укучыларда булган сәләтне, балаларның потенциаль мөмкинлекләрен яшьтән үк ачыклап, аларны максатчан рәвештә үстерү аша милли-интеллектуаль элита формалаштыру. Милләтләр берлеге проблемасы һәр белем бирү оешмасында да яшәп килә. Төрле милләттән булган укучыларның бер гаилә булып яши алуын укытучылар укыту-тәрбия процессын нәтиҗәле оештыру аша тәэмин итәргә тиеш.

Яшь буынны мәгърифәтле итү процессында тәрбиягә өстенлек бирү – Россия педагогик традициясенең үзенчәлеге. Тәрбия эше кешелек җәмгыяте барлыкка килгәннән бирле яши. Тәрбия – иҗтимагый күренеш. Тәрбия эшенең стратегик максаты, асылда, бала шәхесенең барлык эчке табигый көчләрен хәрәкәткә китерүдән, аны физик һәм рухи яктан әзерләп, яңа җәмгыять шартларында интеллектуаль-әхлакый шәхес буларак эш итә алучы ирекле бер зат итеп тәрбияләү. Уку-укыту процессында әхлакый тәрбиягә игътибар бирү бик мөһим.

Шәхеснең камилләшү һәм үсүендә әхлак тәрбиясенең ролен педагогика элек-электән исбатлап, раслап килгән. Әле борынгы грек философы Сенека ук: «Гыйлемлелектә алга китеп тә, әхлак ягыннан артта калган кеше алга китүдән дә бигрәк артка калып яши», – дигән гыйбарә әйткән. Әхлак ул – кешенең эш-хәрәкәтләрендә, көндәлек тормышында билгеле бер калыпка салынган, билгеле бер кыйммәтләрдән торган сыйфат. Кеше җәмгыятьтә яши һәм тәрбияләнә. «Россия Федерациясенең мәгариф турында» 273 нче федераль законының 2 нче маддәсендә: «Белем бирү – бердәм максатка юнәлтелгән укыту һәм тәрбия бирү

процессы…» диелгән. Табигый ки, белем бирү укучыда универсаль уку гамәлләре формалаштыру һәм шул ук вакытта гомумкультура сыйфатлары тәрбияләү процессы буларак та аңлашыла. Шунлыктан барлык уку йортларында да укыту һәм тәрбия бирү һәркайсы аерым-аерым түгел, бердәм белем бирү процессы буларак оештырылырга тиеш. Федераль дәүләт белем бирү стандартлары да шуны таләп итә.

Рус телле укучыларга татар телен укытуның төп максаты – балаларны татар телендә аңлашырга, аралашырга өйрәтү булса, шул ук вакытта үзләре яшәгән җиргә, төбәккә мәхәббәт уяту, туган җирнең тарихын өйрәнү, анда яшәгән шәхесләрнең иҗаты белән кызыксыну, аларга карата ихтирам тәрбияләү бурычы да куела. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә рус балаларының тел аша татар мәдәниятен үзләштерүенә ирешергә кирәк. Бу процесста ул үзенең туган халкының мәдәниятен дә тирәнрәк өйрәнә. Нинди дә булса яңалыкны ачу укучыга үз-үзен ачарга ярдәм итә. Татар телен контекстта өйрәнү безнең җәмгыятьтә һәм мәдәнияттә яшәп килгән төрле фикерләү формаларын аңлауга китерә.

Рус балаларына татар телен өйрәтү күптәннән бергә яшәгән ике халыкның мәдәни диалогын оештыру өчен бик уңайлы. Татар һәм рус халыкларының тарихларында, гореф-гадәтләрендә, шөгыльләрендә күп уртаклык бар. Татар теле дәресләрендә ике дәүләт теленең грамматикасын чагыштырып өйрәтү белән беррәттән, укучыларда милли горурлык, туган һәм татар телләренә мәхәббәт тәрбияләү, халкыбызның мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, иң күркәм йолаларын, тарихын, җәмгыятьтә тирән эз калдырган шәхесләрен хөрмәт итәргә өйрәтү эше дә алып барыла. Татар теле дәресләре өчен материал туплаганда, укучыларга төрле яклы тәрбия бирерлек текстлар сайлау укучыларда әхлакый сыйфатлар тәрбияли. Педагогия көллиятендә булачак тәрбиячеләрдә һәм укытучыларда милләтара дуслык, хөрмәт, түземлелек тәрбияләүгә ирешүдә рус телле төркемнәрдә «Татар халкы тарихыннан» «Татар халкының язу тарихы», «Татар китабы тарихы», «Атаклы татар шәхесләре», «Чит илләрдәге татарлар», «Татар матбугаты», «Татар телен

кайларда өйрәнәләр?»,  «Татар сәнгате» һ.б. кебек текстлар белән эш итү уңай нәтиҗәләргә китерә. Шулай ук «Гаилә», «Туганлык мөнәсәбәтләре» темаларын өйрәнгәндә, үз нәселенең шәҗәрәсен төзү укучыларда искиткеч кызыксыну уята.  Шәҗәрә – нәсел агачы, нинди дә булса нәселнең санап864 кителгән рәте, килеп чыгышын билгеләүче һәм туганлык җепләрен тоташтыручы генеалогик чылбыр. Әлеге эшне, әлбәттә, укучы үзе генә башкарып чыга алмый, аңа әти-әнисе, туган-тумачасы ярдәм итә. Эзләнә торгач, озак вакытлар хәбәрләшми торган туганнар табыла, элемтәләр ныгый, кайберәүләр үз нәселләрендә бөек шәхесләр барлыгын ачыклыйлар.  Мондый эшләр укучыларда горурлык хисләрен арттыра, рухын баета, бала күңеленә әхлаклылык орлыклары чәчә.

Татар әдәбияты дәресләре – рухи һәм әхлакый тәрбия бирүнең нигезен тәшкил итә. Күренекле әдипләребезнең гүзәл әсәрләре, дәреслекләргә кертелгән халык авыз иҗаты үрнәкләреннән мәкаль, табышмак, әкият, мәзәк, әйтем, җырлар укучыларга татар халкының бай рухи дөньясын тирәнрәк һәм тулырак аңларга, күп гасырлар буена тулыландырып, туплап килгән югары әхлак-әдәп нормаларын, күркәм гореф-гадәтләрен яратырга һәм үзләштерергә ярдәм итәләр.

Әхлаклы кеше тәрбияләү  – катлаулы бурыч, ләкин аңа ирешергә мөмкин. Бу гаҗәеп җаваплы, әһәмиятле эшне үтәү өчен, педагог көчен кызганмаска, армый-талмый эшләргә, профессиональ осталыгын даими күтәрергә тиеш.

Кулланылган әдәбият:

1. Ә.Н.,Хуҗиәхмәтов. Тәрбия – мәңгелек фәлсәфә. – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2001.

2. Р., Исламшин. Поликультурное образование в условиях реализации нового стандарта. -  Мәгариф №4, 2011.

3. С.В., Селеменев А.А., Ткаченко Школа “диалога культур”. Что это? // Школьные технологии. – 1996. – №3.

## Алар һаман күңелдә
## (Җәлилчеләргә багышланган кичә)

***Ганиева А.С., татар теле укытучысы***
***Менделеевск шәһәре 1 нче урта мәктәбе***

Без батырлык эзләп яшәмибез, батырлыкка ләкин без әзер –

Кирәк булса, үлемебез белән ныгытырбыз илне, бизәрбез!

Җәлилчеләр кебек! Еллар аша үрнәкләре тора яктырып.

Ватан өчен үлү – безнең бурыч!

Батырлыктан туа матурлык!

25 нче август – татар халкы зур югалтулар кичергән көн: 1944 нче елның 25 нче августында, көн уртасында, Плетцензее төрмәсендә Империя судының карары белән Муса Җәлил һәм аның ун көрәштәшен гильотинада җәзалап үтерәләр.

Муса Җәлил – дөньяның горурлыгы, бөтен прогрессив кешелек культурасының мактанычы. Аның “Моабит дәфтәре” циклы шигырьләрендә батырлык рухы һәм ихтыяр көче ташып тора. Алар Ватанга, халыкка тирән мәхәббәт, хак эшнең тантана итәчәгенә ышаныч белән сугарылганнар.

Үлем карары чыгарылгач та, шагыйрь күңелен төшерми, рухын сындырмый. Төрмәнең кысан, караңгы камерасында да аның өчен иҗат йолдызы балкый. Тоткынлыкта тимер чыбыклар белән уратып алынган төрмә камерасында да ул, җырчы сабан тургаедай, һаман биеккә талпына.

(“Төрмәдә төш” шигыре, “Кошчык”, “Авыру сызмалар” шигырьләре)

Татар легионында аның башка лагерьларга чыгып йөрергә, кешеләр белән аралашырга мөмкинлеге бар, ләкин аның тынгысыз җаны богаулы. Ул үз фикерен ачыктан-ачык әйтә алмый, һәр адымын үлчәп атларга мәҗбүр. Йөрәгеннән ургып чыккан кичерешләре, фашистларга карата нәфрәт, ачу шигырьләренә күчә. Фашистларга каршы көрәшкә ул штык белән түгел, көчле каләме белән чыга. (“Кичер, илем” шигыре)

Аудиоязма. “Мин үлемнән курыкмыйм. Куркыныч хәлләргә очраган чакларда, мин үлем турында котым очып уйлап утыруымны белмим... Дөньяда шундый итеп яшәргә кирәк, үлгәннән соң да үлмәслек булсын – яшәүнең бөтен максаты шунда түгелмени?” (“Дуска” шигыре)

Мин ант иттем җанны кызганмаска,

Саклар өчен халкым, илемне,

Йөзәү булса гомрең, син барсын да

Шушы юлга бирмәс идеңме?

Дөнья һәм дөнья әдәбияты – исемнәре иҗатларының мәңгелек данына әйләнгән күп кенә шагыйрьләрне белә. Ләкин шагыйрь һәм герой Муса Җәлил кебек, әсәрләре белән генә түгел, бәлки үлеме белән дә исемен мәңгеләштергән шагыйрьләр бик аз. Менә алар: бөек Байрон, Венгриянең халык шагыйре Петефи, герой Юлиус Фучик һәм, ниһаять, Муса Җәлил. Сәмәд Вургун

Муса Җәлил килеп эләккән фашистлар концлагеренда хәлләр коточкыч була. Фашистлар әсирләрне куркытып тору өчен җәзалыйлар, кыйныйлар. Аларда җиңүгә ышанычны, туган илләренә мәхәббәтне бетерергә телиләр.

(“Төрмә сакчысы”шигыре”)

Муса Җәлил, җай чыккан саен, яшеренеп, татар әсирләре алдында үзенең җиңүгә ышаныч, туган илгә мәхәббәт тулы шигырьләрен укый, көрәшкә чакыра. (“Яшәүгә өмет”шигыре)

Әкренләп Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре тирәсенә фашистларга каршы көрәшү өчен яшерен оешма туплана. Аңа бик сыналган, ышанычлы кешеләрне генә алганнар. Яшерен оешма кешеләре газета редакциясенә, радиостудиясенә һәм башка күп кенә оешмаларга кереп урнашалар. Бу юнәлештә бигрәк тә балалар язучысы Абдулла Алиш зур эш алып бара. Яшерен оешманың төп бурычы – Кораллы восстание әзерләү, күрше поляк һәм әрмән легионнары белән элемтә урнаштыру, корал табу, әсирләр арасында пропаганда алып бару. (Абдулла Алиш шигыре)

Аңлату эшләрен үзләре оештырган музыка хор копелласы аша да алып баралар. Аның җитәкчесе – яшерен оешманы оештыручыларның берсе Гайнан

Кормаш була. Концертка әсирләр күңелендә илне ярату, үз халкыбыз, мәдәниятебез белән горурлану хисләре, фашистларга карата нәфрәт уятырлык җырлар, шигырьләр сайлап алына. (“Җырларым” җыр)

1943 ел уртасында легионның беренче батальоны Белоруссиягә патризаннарга каршы җибәрелә. Алар баш күтәрә, немец офицерларын үтереп, партизаннар ягына чыга һәм фашистларның зур көчләре тар-мар ителә. Шушы уңыштан канатланган җәлилчеләр әсирләр арасында восстание күтәреп, легиончыларның аерым группаларын качарга әзерләргә телиләр.

Ләкин восстание булмый кала. Оешма җитәкчеләрен кулга алалар. 1944 елның 12 нче февралендә Дрезденда хәрби трибунал аларны үлем җәзасына хөкем итә. (“Хөкем алдыннан”шигыре) (“Ышанма” шигыре)

Дрезденнан тоткыннарны Моабит төрмәсенә алып киләләр. Монда алар коточкыч җәзалауларга дучар ителәләр. Җәлилчеләр ахыргача нык торалар. Бар эшләгән эшне үз өсләренә алып, башка беркемнең дә исемен атамыйлар. Шулай итеп, яшерен оешманың бик күп кешеләрен үлемнән коткарып калалар.

Данлы Казанның чал Кремле янында Муса Җәлил һәйкәле тора. Ул югарыга очар өчен канатларын җайлап куйган бөркетне хәтерләтә. Ике кулы артка каерылып бәйләнгән... Менә-менә җилкәләрен киереп, чылбырларын өзәр дә, һавага күтәрелеп китәр кебек. Муса Җәлил һәйкәле янына җәлилчеләрнең портретлары урнаштырылган .

Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә
Һәм үләргә кыю ир булып,
Гомерем минем моңлы бер җыр иде,
Үлемем дә яңгырар җыр булып.

Әйе, алар фашистларны җиңеп, халкыбызның намусын саклап калып, безнең бүгенге көнебез хакына, батырларча һәлак булдылар. (“Үлемгә”шигыре)

Туфрак күмәр тәнне, күмә алмас
Ялкынлы җыр тулы күңелне.
“Үлем” диеп әйтеп буламы соң
Җиңеп үлгән мондый үлемне.

# Варваризмы. Нужно ли с ними бороться?

***Гарипова Резеда Габделфатовна,***
***учитель русского языка и литературы***
***МБОУ «Средняя общеобразовательная школа №1»***

В современном обществе особенно актуальной становится проблема экологии. Термин “экология" возник в рамках биологии. Его автором был профессор Йенского университета Э. Геккель (1866 год). Экология первоначально рассматривалась как часть биологии, изучавшая взаимодействие живых организмов, в зависимости от состояния окружающей среды.

Стремительное развитие инновационных технологий, большой интерес к ним в современном обществе, сложившаяся непростая ситуация в мире привели к проникновению экологии во многие отрасли науки, в том числе и в лингвистику. Появилась так называемая наука – лингвоэкология, которая изучает экологические проблемы языка в современной лингвистике.

В последние годы во всем мире доминирующую роль среди современной молодежи играют интернет, социальные сети, через которые и проникают в наш язык варваризмы.

Для нас интерес представляет использование варваризмов среди современных школьников. Именно поэтому был проведен опрос учащихся школ города Мензелинска.

Актуальность настоящей работы обусловлена рядом факторов.

Во-первых, в последние десятилетия снизился интерес к книге и возрос к интернету и социальным сетям.

Во-вторых, отметим, что в современном обществе стало модным использование в речи варваризмов, приводящих к «засорению» родного языка.

Эти факторы оказывают существенное влияние на развитие человека, его грамотность, образованность, интеллигентность, духовную зрелость.

Предмет исследования – лингвоэкология.

Объектом исследования являются варваризмы в речи современного школьника.

Цель настоящей работы – определить роль варваризмов в современном обществе.

Достижению поставленной цели служит решение следующих задач:

– дать определение варваризмов с помощью словарей;

– выявить отношение к варваризмам в современном обществе;

– рассмотреть, какое влияние оказывает использование варваризмов на состояние экологии языка;

– сделать выводы по данной проблеме.

В решении названных цели и задач в работе применялись следующие методы исследования:

– опрос;

– обобщение;

– наблюдение и анализ.

Материалом для исследования послужили результаты опроса школьников города Мензелинска.

## “Уйларым кәгазьгә түгелә...”

(С.Шәмсинең “Соңгы юаныч” хикәясендә рухи – экологик тәрбия)

***Гарифуллина Дилбәр Рафак кызы,***
***Татарстан Республикасы***
***Мөслим муниципаль районы***
***Күбәк урта гомуми белем бирү мәктәбенең***
***югары категорияле татар теле һәм***
***әдәбияты укытучысы***

... бар нәрсәгә битарафлы

Сай күңел кирәк түгел.

Ф.Дәүләтгәрәева

Табигать, әхлак, кеше... Бу төшенчәләрне бер-берсеннән аерып карап булмый. Алар үзара нык бәйләнгән. Татар әдәбияты укытучылары дәресләрдә, класстан тыш чараларда шушы бәйләнешне әдәби әсәрләрне өйрәнү аша ачыкларга бурычлы. Нәфис сүз, сәнгать чаралары ярдәмендә укучыларга Җир-анага игелек, хөрмәт хисләрен уяту, кешелекнең экологик һәлакәт каршында торуын да искәртергә кирәк. Кеше табигатьнең яклаучысы, яңадан тууда, күтәрелүдә булышчысы да булырга тиешлеген аңлату зарур.

Бүген кеше табигатькә бәйле дип әйтү генә дөрес булмас иде, чөнки табигатьнең язмышын кеше дә хәл итә, ул экологик тотрыклыкны саклап калырга бурычлы. Хәзерге чорда халыкның экологик культурасы түбәнәйде. Бүген табигатьнең экологик халәте борчу уята, табигатькә янаган куркыныч проблемалар бездән яңача уйлану, яңа эш-гамәлләр сорый.

Табигатьне саклау турындагы экологик проблемалар әдипләребез тарафыннан күп әсәрләрдә күтәрелгән. Мондыйлар рәтенә Ә. Сәлахның "Соңгы вальс" повестен, Ф. Яруллинның "Иске өй истәлеге", Н. Гыйматдинованың "Ачкыч", Ф. Бәйрәмова "Болын" хикәяләре һәм башка бик күп әсәрләрне кертергә мөмкин. Бу әсәрләр программада юк. Ләкин мин укучыларыма өйдә аларны әти –әниләре белән бергә укырга кушам. Соңыннан әсәр буенча диспут – дәрес үткәрелә. Китап укучылар конференциясен әти –әниләр катнашында үткәрү дә тиешле нәтиҗә бирә. Куелган проблемалар төрле чишелеш ала. Шулай эшләгәндә, рухи фаҗиганең экологик фаҗигагә китерүче көч икәнлегенә балалар да, өлкәннәр дә ныграк төшенә.

Кулымда Солтан Шәмсинең "Җәяүле буран" җыентыгы. Күзем төшкән беренче хикәя – "Соңгы юаныч". Соңгы юаныч... Ни өчен соңгы? Әсәрнең исеме үк күңелгә берникадәр шом өстәп куя. Хикәя без бик күп тапкырлар сөйләгән ата-аналар белән балалар арасындагы мөнәсәбәтләр һәм экология турында. Алар тормышчан кырыс хакыйкать рәвешендә тасвирлана. Ләкин, бакчасына гади үлән чәчеп, соңгы тапкыр хуш исле печән чабып карыйсы килгән гади авыл абзые бу хикәягә серле бизәкләр өсти. Кемгәдер бу хикәя артык гади кебек тә тоелыр, кемдер кайбер вакыйгаларга ышанмас. Ләкин бер

генә әйберне әйтә алам: хәтерендә җиләкле печән исен саклаган һәм туган җирен сагына белү сыйфатын җуймаган моңлы кешеләргә бу әсәрдә барысы да аңлашыла.

Печән исе... Шәһәргә килеп төпләнгән авыл малайлары һәм кызлары берни белән дә чагыштырып булмый торган печән исен хәтерлиләрме икән? С. Шәмси печән өстен болай тасвирлый: “каерып чабарлык булып” җитешкән печән “җилдә дулкынланып уйный”, “чыклы үлән тагын да куерып, калынаеп күренә, парланган пыяладай аксылланып утыра”, иртәнге кояшта “өстенә асылташлар сибелгәндәй, җемелдәп-җемелдәп куя...” Көнкүреш ыгы-зыгысыннан башланган хикәядә печән чабуның тыйнак бөеклеген күрәбез. Бөек, чөнки кулына чалгы алып, печән чапканда, картның күңелен чалгы тавышы иркәли. Бу тавыш аның йөрәгенә сихәт өсти. Бәреп чыккан тирләре картны еллар авырлыгыннан арындыра. Еллар томаныннан яшьлеген күргәндәй була. Чабылган печән исе... Менә кайда икән ул юаныч! Соңгы юаныч!

Печән үскән бакчада күрше картлары бергә гәп корырга яраталар. Автор үзенең укучысына әйтергә теләгән фикерен Рафаэль авызыннан әйттерә: “Үзегез уйлап карагыз: кеше гасырлар буе тырыша –тырыша прогресска омтылды, яңадан – яңа җирләр ачты, зур шәһәрләр корды, заводлар төзеде, табигатьнең бихисап серләрен ачты. Аның хыялы – җир йөзен гөлбакча итү, үзенә матур, рәхәт тормыш төзү иде. Ә нәтиҗәдә...? кеше үзе сулый торган һаваны бозды, елга – суларны пычратты, бик күбесен корытты, урманнарны кырды, тереклек ияләрен юк итте... кылган эшләренең нәрсәгә китерәсен аңламады. Һәм менә бүген кешегә үзе төзегән зур шәһәрләрдә һава җитми... Кыскасы, Анасы – табигатьтән бик тә ераклашты кеше”. Бу сүзләр авторның чаң сугуы! Укучыны ышандырырга теләгәндәй, бу эшләрнең бер чиге булырга тиешлеге, табигать кешене моңа мәҗбүр итәчәге турында да яза ул.

Бу хикәядә һәр җөмлә, һәр сүз, һәр ишарә, һәр сурәт белән, шулай ук үзенә хас  салмак хикәяләү алымы аша С.Шәмси ялкау вөҗданыбызны уятырга тели кебек. Ул моңа ирешә дә. Бу урында М.Горькийның “”Иң авыры - гади итеп язу...”- дигән сүзләре искә төшә. Ә бит чыннан да, кычкырмыйча гына,

шаккатырырга теләмичә генә үзенең авырткан җире турында сөйләгән кешегә ныграк ышанасың!

Шулай итеп, бакчадагы печән чабу күренеше аркылы ул укучысын күпләрне борчыган олы һәм тирән күренешләргә алып керә, шулар турында уйланырга куша. Бу хикәядә табигать тудырган матурлыкка соклану да, шул матурлыкның сүрелә баруына өзгәләнү дә бар. Автор табигатьне саклаучы, аны яратучы кеше тәрбияләргә омтыла. Рухи ярлылыкның табигатьне юкка чыгаручы көч икәнлеген С.Шәмси аерым эпизодлар аша кат – кат аңлата. Табигать белән гармониядә яшәсә генә, кеше чын мәгънәсендә бәхетле була, дигән фикерне алга сөрә. Әсәрне укып чыккач, әлбәттә, укучы уйланачак. Ә аның нинди нәтиҗәгә килүе үзеннән тора.

Тәкъдим ителгән тема гаять катлаулы, киң колачлы. Шуңа күрә бу теманы тулысынча ачу кыска гына чыгыш кысаларына сыеп бетмәгәндер дә. Ләкин мин бер нәрсәгә ышанам: кеше күңеле төбендә, кеше җанында, явызлыкка караганда, изгелек күпкә артык! Тирә-ягыбыз, туган җир – яшел бишегебез, сулар һавабыз, эчәр суларыбыз кешеләр битарафлыгыннан сыкрап утырмасын иде!

Кулланылган әдәбият.

1. Шәмси Солтан. Җәяүле буран: Повесть һәм хикәяләр. - Казан: Татар. кит. нәшр., 1988

2. “Мәйдан” журналының 2008 нче елгы 5 нче саны.

## Татар теле һәм әдәби уку дәресләрендә экологик һәм әхлак тәрбиясе

***Гафурова Д.М.-башлангыч сыйныф укытучысы,***
***Әгерҗе районы Салагыш урта мәктәбе***

Экология , фән буларак , мәктәпнең укыту программасына кертелмәгән . Шуңа күрә экологик проблемаларны табигать фәне дәресләрендә һәм түгәрәкләрдә генә түгел , ә башка фәннәрдә дә , аерым алганда татар теле һәм

әдәбият дәресләрендә дә өйрәнергә кирәк . Башлангыч сыйныф укучыларына әхлакый - экологик белем һәм тәрбия бирү ”Әйләнә-тирә дөнья “ курсы материалларына нигезләнеп алып барыла. Әхлакый- экологик  белем һәм тәрбия бирүдә  әдәби әсәрләрнең дә әһәмияте бик зур . Башлангыч сыйныфлар өчен уку китапларына табигатьне саклауга багышланган бай материал тупланган . Әлифба  дәресләрендә авазлар һәм хәрефләрне өйрәнү  белән беррәттән ,  табигатьнең матурлыгын тоя белергә өйрәтү , кошларга сак караш һәм кайгыртучанлык тәрбияләү максаты да  куела. “Табигать - тиңсез хәзинә” баш астында үткән класстан тыш уку дәресе укучыларны дару үләннәрен таный , куллана белергә өйрәтә , аларның файдасы турындагы белемнәр белән баета , табигатькә мәхәббәт һәм сак караш тәрбияли. Бу үз чиратында әхлак тәрбиясе юнәлешен дә күздә тота . “Нәүрүз”  , “Сөмбелә” , “Карга боткасы” кебек бәйрәмнәр дә кеше сәламәтлеге һәм әйләнә-тирә мохитның чисталыгы арасындагы бәйләнешне ачык күрсәтә торган мөһим чаралар. Балаларда зирәклек , күзәтүчәнлек кебек сыйфатлар тәрбияләүче табигать күренешләренә багышланган табышмаклар шәфкатьлелек , миһербанлык , игътибарлылык кебек хисләр тәрбияләүче әкиятләр , мәзәкләр , мәсәлләр дә шактый .. Халык мәкалендәгечә , ”үзе утырган ботакка балта чапмый торган” , табигатьнең гүзәллеген тоя белгән, кирәклеген аңлаган , миһербанлы , кешелекле балалар тәрбияли алсак иде. Һәм үзебез дә аларга бар нәрсәдә дә үрнәк булсак иде .

Кулланылган әдәбият:

Заһидуллина Д.Ф. Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2000.

Низамов А.М. Милли мәктәп тәрбия нигезләре.- Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2005.

Сәхипова Р.Ә. Халык педагогикасы нигезендә укыту һәм тәрбия бирү. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2005.

# Тукай әсәрләрендә экологик тәрбия.

***Гомәрова Ләйсинә Марс кызы***
***ТР Алабуга районы МБУБ учреждениесе***
***«Урта белем бирү мәктәбе №10»***

Табигатьне саклау темасына язылган әсәрләр бик күп. Г. Тукай күп кенә шигырьләрендә җәнлекләрне, кошларны, бөҗәкләрне яратырга, аларга мәрхәмәтле, шәфкатьле булырга өнди, үзенең шигъри бизәкләре белән табигатьнең гүзәллеген ача. Табигатьне саклау – милләтебезне, туган телебезне, гореф-гадәтләрне, рухи һәм тарихи байлыкларны саклау белән тыгыз бәйләнгән. Табигатьнең матурлыгын, серлелеген Тукаебыз - үзенең җаны, саф күңеле, йөрәк җылысы салынган шигъри юллары белән укучы җанына, аның күңеленә салучы, ныгытучы, мәңгеләштерүче. Бигрәк тә ул- Туган ил,Туган җир җырчысы, аның табигатенә мөкиббән китүче.“ Валлаһи” шигыренең түбәндәге юлларын укыганда, моңа тагын бер кат инанасың:

Валлаһи, и валлаһи, и валлаһи,
Бәхте барлар кырда җәйли, валлаһи!
Ак күмәч берлән ашарлык саф һава;
Җир яшел; кошлар да сайрый, валлаһи! [3:215]

“Сагыныр вакытлар” шигырендәге кебек табигать күренешләрен кешеләр, аларның холкы белән матур итеп чагыштырып бирүне бары тик Тукай шигырьләрендә генә таба аласың:

Һәр чәчәк – сеңлең, апаң; абзаң – үсеп торган агач;
Син сабыйдай нечкә аваз берлә сайрый сандугач.
Чәчмәгән җир кук – күңлеңнең һәр гүзәлгә бушлыгы,
Тик кояшны һәм табигатьне сөюдән хушлыгы. [2:106]

"Су анасы", "Шүрәле" әсәрләрендә баланы гаҗәеп табигать дөньясына алып керә. Матурлык дөньясын тою балаларда гүзәллеккә омтылу хисе уята. Ә хисләр, хыяллар дөньяны танып белүнең башлангычы ул. Тирә-юньнең бик үк ачык булмаган “серләре” турында мәгълүмат бирә, аларның карашларын

киңәйтүгә ярдәм итә. Без моны “Җәй көнендә”, “Җәйге таң хатирәсе”, “Яңгыр”, “Яңгыр илә кояш”, “Җир йокысы”,”Кышка бер сүз” һ.б. шигырьләре ярдәмендә дәлиллибез. Ә үзе болай ди ” “ Чыршы”, “ Җил белән Кояш” мәкалә вә шигырьләре белән баланы дөнья вә табигать хакында уйлату һәм аны сөйдерүне күзгә алу.”[1:8]

”Җәй көнендә” шигырен алыйк.Әлеге шигырендә Тукай, шулай ук бик үткен, матур итеп, һәр табигать күренешеннән: искән җилдән, ялтыраган яшеннән, яуган яңгырдан, хәтта бик нык кыздырган кояштан нинди дер ямь, матурлык, канәгатьләнү табарга өйрәтә.

Үз сүзләре белән әйтсәк ”...мотлак рәвештә , берничә мәсәлләр язып үткәч, балаларга табигатьнең һәртөрле хәл вә эшләрен күрсәтер өчен (балаларга бераз күңелсезрәк булса да) “ Кояш”,”Җир”, ”Су”, ”Һава”, ”Елның дүрт фасылы” кеби фәнни вә гыйльми мәкальчекләр язылды”. [1:8] Гомумән, Тукай үз әсәрләре аша һәр ел фасылыннан, табигать күренешеннән, безне чолгап алган әйләнә- тирәлектән матурлык, җан рәхәте, күңел тынычлыгы табарга һәм табигатьтән үзеңә генә нидер алу түгел, ә бирергә дә кирәклеген искәртә.Табигатьтне сакласаң, аңа игьтибарыңны арттырсаң, ул да сиңа шулай ук җавап бирәчәген күрсәтә.

Нәтиҗә ясап шуны әйтәсебез килә: Габдулла Тукайның нинди әсәрен генә алма, барысы да тәрбия бирә торган. Ләкин бу шигырьләрдә тәрбия турыдан-туры эчпошыргыч өйрәтү, мораль уку формасында, өстеңә куела торган бер максат кебек бирелмәгән, ә бәлки бик оста, үтемле, матур сүзләр кулланып, чын психологлар кебек җанга, йөрәккә үтеп керерлек итеп язылган. Г.Тукайның табигать күренешләрен тасвирлаган шигырь-поэмалары уку өчен кызыклы, кечкенә балаларга да аңлаешлы. Иң мөһим әйбер шул: алар тулысынча балада яхшы сыйфатлар тәрбияләүгә корылган. Шагыйрь үзенә генә хас осталык белән баланы табигать дөньясына алып керә, матурлыкны күрә белергә өйрәтә, гүя аның белән бергә кошлар сайраганны тыңлап, аллы-гөлле чәчәкләр, кып-кызыл җиләк үскән урманда йөрисең, алар белән сөйләшәсең һәм әлеге табигать балалары сиңа туганың кебек якынга әйләнәләр.

Кулланылган әдәбият

1.Габдулла Тукаев. Мәктәптә милли әдәбият дәресләре.-Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2000.-8 б.

2. Габдулла Тукай. Сагыныр вакытлар. -Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2006 ел.-106 б.

3. Габдулла Тукай.Сайланма әсәрләр.-Казан: Татарстан китап нәшрияты,2006 ел.-3б.

## Ел фасылы буенча шагыйрь бәйрәмен истә калдыру

***Яр Чаллы шәһәре***
***53 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы***
***Гыйззатуллина Айгөл Илфак кызы***

Бөек шагыйребез Габдулла Тукайны зурлау, аның бөеклеген буыннардан – буыннарга җиткереп бару – безнең изге бурычыбыз. Әлбәттә, Тукаебыз турында күп яздылар, күп сөйләделәр...Ләкин минем ***максатым Тукайны “яз илчесе” итеп укучыларга таныштыру һәм шушы ел фасылына бәйләп күңелләрендә истә калдыру.***

**Бурычларым:**

-***Яз ел фасылына багышланган шигырьләрен барлау.***

**Теманың актуальлеге.**

Татар халкының ел фасылларының иң үзенчәлекле көннәренә багышланган бәйрәм-йолалары күп. Мәсәлән, кышкы һәм җәйге Нардуган бәйрәмнәре, Сөмбелә, Карга боткасы һ.б. Без бу бәйрәмнәрне табигатьтә, урманда уздырырга тырышабыз. Мондый бәйрәмнәр белән танышу ерак бабаларыбызның табигать белән бер бөтен булып яшәгәннәрен күзалларга ярдәм итә. Балаларны татар халкының рухи тамырлары, ерак бабаларыбызның яшәү рәвеше, һөнәрләре белән таныштыру, аларда милли горурлык тәрбияләү мөһим. Табигатьнең матурлыгын, серлелеген Тукаебыз үзенең җаны, саф күңеле, йөрәк җылысы салынган шигъри юллары белән укучы җанына, аның

күңеленә салучы, ныгытучы, мәңгеләштерүче. Ул яңгыр, чык, кырау, буран, җил, кояш, ай, яз, көз, җәй, кышның — һәрберсенең үзенчәлекле билгеләре турында шигъри ачышлар ясап, укучы күңеленә җиткерә. Ел фасылларын Тукай кайта – кайта, яңадан – яңа үзенчәлекләрен ача – ача тасвирлый.

Чыганакка күз салсак, Габдулла Тукай "елның дүрт фасылын" билгеле бер тәртипкә салган. Беренче чиратта "яз" ел фасылын куйган.Яз март аеннан башлана. "Кояш инде күктә, кыштагы кеби күренеп кенә китмичә, озак тора башлый. Шунлыктан көннәр озая, төннәр кыскара." ди. Иҗатына күз салыйк: *"Яз хәбәре"*

*Яуса да карлар, табигать эшли инде үз эшен;*
*Тиздән иснәрбез кызыл, ал. ак чәчәкләрнең исен.(1910)[1, 204 б.]*

Шигырьне укыганда ук, борынга "яз исе" килеп бәрелә. Нindидер өмет чаткылары барлыкка килә. Нинди генә салкын кышлар, усал бураннар булса да, күңел түрендә яшеренгән җылы өмет чаткысын сүндермәскә чакыра автор. Кыскасы, яз ул – өмет чаткысы. *"Яз галәмәтләре"*

*"Яз якын"ның шатлыгыннан йөзгә чыккан елмаю*
*Инде яшьләрдә түгел, хәстә вә хәлсез картта бар. (1912) [1, 180 б.]*

Яз үзе үк безне мәхәббәткә, матур хисләргә өнди. Күңелләребез әлеге ел фасылы килү белән каядыр ашкына, ниндидер тылсымлы танышулар, очрашулар көтә. Ә нигә әле шигырьдәге картка "елмаймаска"? Ул да бит җан иясе, аның да йөрәге яз житү белән ешрак тибә башлый...Ә бәлки ул яшьләргә карап, үзенең беренче мәхәббәтен искә төшерәдер. Димәк, яз ул – күңелләрдәге матур хисләрне уятучы һәм искә төшерүче.

«Яз» шигыре исә, фәлсәфи юнәлеше белән аерылып тора: лирик герой каләмен язарга, иҗат итәргә өнди нурлы. Якты яз килгән бит. Шул ук вакытта каләм туктап калган, герой нәрсәнедер аңлап бетерми кебек. Әйе, тормышка нур иңә, яз килә, әмма анда мәхшәр: бозлар, ахыр заман җиткән кебек, берберсен кага-кага агалар, чабалар, бетүгә баралар. Кайсының җәннәткә, ә кайсының утка барганлыгын белеп да булмый.

“Елның дүрт фасылы” (1910) шигырендә дә Тукай беренче итеп яз фасылын куйган. Лирик герой хисләрнең чагылышы аша шагыйрьнеңязгы табигатькә уңай мөнәсәбәтен, андагы үзгәрешләргә сизгерлеген, уңай бәясен төсмерлисең.

Габдулла Тукай әйтергә теләгән фикерләре укучыга барып җитсен өчен, әдәби телебезнең төрледән-төрле сурәт-бизәкләрен куллана, төрледән-төрле чагыштырулар куллана. Мәсәлән: «Тәгәридер ул матур кыз —язның алтын фәйтуны» «Барыбер, күрсәң, качарсың, язны — гөлләр патшасын».

**ЙОМГАКЛАУ.**

Һәр кеше үзенең табигате белән төрле. Аңа салкынлык та, җылылык та, моңсулык та хас. Характерлар күп булган кебек ел фасылларының да сыйфатлары биниһая. Адәм баласы бер генә ел фасылын көтеп алырга мөмкин, шул ук вакытта төрле айларның нинди дер җир үзенчәлеген генә ярата ала. Һәр кешенең сайлау хокукы бар. Әйтик, минем күңелемә кышның салкын саф һавасы, көзнең алтын төсләре, язның алмагач исләре, җәйнең җиләкләре якын. Бу минем сайлау хокукым.

Нәтиҗә. Габдулла Тукай язның сафлыгын, җәйнең күңелле айларын яраткандыр. Тукаебызның бәйрәме яз ел фасылы белән бәйле булганга күрә дә, аны ***яз илчесе, яңалык алып килүче*** дип атарга була. Әлеге материаллар укучылар күңелендә яз белән Тукай бәйрәмен истә калдырырга ярдәм итәр дип ышанып калам.

**Кулланылган әдәбият:**

1. Г.Тукай Әсәрләр: 5 томда: 5 том. Истәлекләр. Юльязмалар. Хатлар. Мәсәлләрһәмбалаларөченхикәяләр (1902–1913). – Казан: Татар.кит. нәшр., 1986. – 368 б.)

**Тикшерү эшенең темасы: Ф.Садриев иҗатында күтәрелгән әдәп-әхлак мәсьәләләре.**

***Гыйлфанова Лилия Мирзәриф кызы,***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы,***
***Мөслим муниципаль районы муниципаль***
***бюджет гомуми белем бирү учреждениесе***
***”Мари Буләр төп гомуми белем бирү мәктәбе”***

Эшнең максаты: язучы иҗат иткән әсәрләр аша әдәп - әхлак мәсьәләләренең чагылышын күзәтү, аларны өйрәнү, анализлау һәм нәтиҗә чыгару.

Тикшерү объекты: Ф.Садриевның “Көлми торган кеше”,”Адәм әүлиясе”,”Рәхмәт,этием” повестьлары.

Кереш. Фоат Садриев - талантлы язучы.

Татарстанның халык язучысы, Габдулла Тукай премиясе лауреаты Фоат Садриев “Бәхетсезләр бәхете”, ”Таң җиле”, ”Зөбәйдәнең күңел дәфтәреннән”, ”Рәхмәт,этием”,”Адәм әүлиясе” кебек роман-повестьлары, драма әсәрләре белән укучылар күңелен күптән яулады. Халыкчанлыгы, үзенчәлекле образлары, җылы лиризмы, тирән психологиясе, юморга бай теле аша Ф.Садриевны шундук танып аласың. Авылны, аның гади кешеләрен аеруча яратып тасвирлый ул.

Нәтиҗә. Үзенең туган ягын, үзе белән бергә яшәгән якташларын әдәби биеклеккә күтәргән, ихлас зурлаган, кадерләп тасвирлаган кеше ул - Ф.Садриев.

2. Төп өлеш. Ф.Садриев иҗатында әдәп - әхлак мәсьәләләренең чагылышы.

I бүлек. “Көлми торган кеше” әсәрендә бәхет төшенчәсе.

Һәркем бу дөньяда бәхет өчен туа. Кемнәргәдер бәхет тиз генә, җиңел генә бирелгән кебек, кемнәрдер өчен бәхет кояшы урау юллар аша, күп тормыш сынаулары үткәннән соң гына елмая. Булган бәхетеңне күз карасыдай саклый белү, аны югалтмау һәркемнең дә кулыннан килә торган эш түгел.

Ф.Садриевның “Көлми торган кеше” әсәрендә Газизҗан образы үзәктә тора. Тормыш, авыл мәшәкатьләренең кайнап торуы, гаиләдәге каршылыклы

хәлләр – һәммәсе Газизҗанның йөрәген ташка әвереллергән, көләч йөзен салкын, төссез карашка әйләндергән төсле.

Язмыш кешене төрле вакыйгалар алдына куя, төрлечә сынап карый. Газизҗан да, соң булса да, үзен аңлаучы, тыңлаучы, аның күңел серләренә үтеп керүче, йөрәгендәге ташны эретергә сәләтле кешене очрата. Автор шушы урында аңа тормыш йомгагын сүтеп карарга, истәлекләрне яңартырга, серләрен чишәргә мөмкинлек бирә.

Ләкин бу өметләр куе томан артындагы рәшә кебек кенә тоела. Ул яшь чагында эләктергән "бәхет кошы" аның ышанычын аклый аламы соң?

Аның йөрәген әрнетә торган уйлар тынгылык бирми: гаиләләрендә бер генә бала туу, хатынының читләргә күз ташлавы – Газизҗанның ирлек намусына тап төшерә түгелме?

Газизҗан белән Фирдәүсәне бәйләгән икенче төрле тормыш аны тагын бер кат уйланырга, тормышын күздән кичерергә ярдәм итә. Хәзерге вакытта егерме яшькә җиткән улында өмет-ышаныч бармы? Газизҗан үзенең җанына тынычлык тапкан яңа җирдә яши алырмы?

Нәтиҗә.Соңгы хәлиткеч минутта бөтен тамырлары белән җиргә береккән Газизҗан шушы җиреннән аерыла алмаячагын аңлый, чөнки шушы газиз җире аны нинди халәтендә дә аңлый, үлеп барганда да ,аңа хыянәт итми, кичерә белә.

II бүлек. "Адәм әүлиясе"повесте: яшәешнең матур булуы яки тәртипсез төс алуы кемнән тора?

"Адәм әүлиясе"- бәхәс кузгатырлык, тормыш-яшәеш күренешләренең төрле якларын ачып салган әдәби әсәрләрнең берсе.

Кәеф-сафа корып, җиңел тормышта яшәргә омтылучы Альфред - әсәрнең төп герое. Югары уку йортына керергә имтиханнар бирергә дип, Казанга киткән авыл егете төрле маҗаралы хәлләрдә кала һәм аңа үзенең күп ялгыш гамәлләре аша кыенлыклар кичерергә туры килә. Безнең күз алдына тормышта үзенә максат куймаган, җиңел уй-фикерле егет образы килеп баса. Моның сәбәпләре нидә соң? Әти-әнисенең дөрес тәрбия бирә алмавындамы, әллә

бүгенге җәмгыять шартларында башка факторларның тәэсире көчлерәкме? Укучы әсәр белән танышу барышында шушы күп сорауларга җавап эзли

Нәтиҗә. Ә шул геройларда үзен таныган һәр укучы тормышта чын кеше булу өчен нинди сыйфатларга ия булу кирәк дип уйланырга тиеш.

III бүлек. “Рәхмәт, этием”- әхлакый мәсьәләләрнең фәлфәси проблемаларга әйләнүен күрсәткән әсәр.

“Рәхмәт, этием”әсәре Ф.Садриевның зур осталыкка ирешкән язучы булуын тагын бер кат раслый.

Повестьның эчтәлеге фаҗигале: Камил хатынына хыянәт итә, шул төенләнештән вакыйгалар малаена сугып җибәрү, Сәгадәтнең авырый башлавы, яман шешнең сәбәбе бәрелүдә булып чыгу, малайның үлеме кебек үсеп бара. Автор ата-бала мөнәсәбәтләрен үзәккә куя, чишелешне дә балага хыянәт яссылыгында кора. Әсәрдәге хата ясау – үкенү – гафу итү чылбыры әхлакый проблемадан фәлсәфи проблемага әверелдерелә. Сәгадәт этисен гафу итә, аны бәхилләп үлә, ләкин Камил үз-үзен гафу итми. Акылдан язуның да сәбәбе шунда.

Нәтиҗә. Үз-үзеңә хыянәт итү иң якын, иң кыйммәтле нәрсәләрне җуюга китерә. Гомумән, кешенең тормышта эшләгән һәр гамәле язмыш китабына языла барыла. Әдәп-әхлак кануннары таянып яшәсәң, үткәннәрең дә үкенерлек булмас һәм үзеңә киләчәк буыннан да яхшылыклар өмет итә алырсың.

4. Йомгаклау. Тургай җырына тиң иҗат.

Эзләнүләрдән күренгәнчә, авторның һәрбер әсәре аның эзләнүе, яңадан-яңа алымнарны сынап каравы, шулай әдәбиятыбызга да яңалык алып килүе турында сөйлиләр. Аның һәр яңа әсәре татар әдәбиятында саллы күренеш төсен ала, фикер уята, бәхәс кузгата, уйлата һәм елата. Саф татарча матур, бай әдәби тел мөмкинлекләрен тулысынча файдалана белүче, милли традицияләрне яңа алымнар хисабына баетып килүче Фоат Садриевның иҗаты әдәбиятыбызда тургай җыры булып яңгырый.

Файдаланылган әдәбият


1. Баһаутдинов Ф.Н. “Без -Мөслим балалары”. Казан: “Идел-Пресс” нәшрияты, 2006 нчы ел.

2. Садриев Фоат “Таң җиле”.Татарстан китап нәшрияты, 1994 нче ел.

3. Садриев Фоат “Көлми торган кеше”.Түбән Кама: “Ихлас” нәшрияты, 2004 нче ел.

4. Садриев Фоат ”Гөлчәчәк” хикәясе. “Сөембикә” журналы, июнь, 2015 нче ел.

5. Заһидуллина Дания “Әдәбиятыбызның тургае”. “Авыл утлары” газетасы, 11 нче март, 2016 нчы ел.

6. Галимуллин Ф. Гыйбрәтләр алсак иде. Казан утлары. – 1993 нче ел.

7. Мостафин Р. “Бәхетлеләр һәм бәхетсезләр”. Казан утлары.– 2002 нче ел.


## Г.Тукай шигырьләрендә табигать темасы.


***Башкарды : I квалификацион категорияле***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы***
***Гыйльметдинова Илгизә Миркасыйм***
***кызы***


Кереш.

Кеше тормышы һәрвакыт табигать белән бәйле. Ул - кешенең сәламәтлек, туклану,гомумән, яшәеш чыганагы. Табигать дигәч, иң беренче чиратта, калын яшел урманнар, саф сулы чишмәләр, бай тарихлы елгалар, күлләр, иксез-чиксез җәелеп яткан далалар күз алдына килә. Табигать безгә азык, кием, торыр урын бирә. Кеше тормыш өчен кирәкле бар нәрсәне табигатьтән ала. Шуңа күрә табигатьне сакларга кирәк. Табигатьне саклау- һәр

кешенең изге бурычы. Быелгы , 2017 ел - табигатьне саклау елы , дип игълан ителде.

Экологик белем һәм тәрбия бирүдә әдәби әсәрләрнең әһәмияте зур. Язучыларыбыз, беренчеләдән булып, табигатьне саклау турында чаң сукты. Әйләнә-тирә дөньяны, кеше сәламәтлеген, аның рухын, телен саклау аларны иң борчыган һәм дулкынландырган проблемага әйләнде. Нәфис сүз, сәнгать чаралары ярдәмендә кешедә югалып бара торган иң изге әхлакый-рухи кыйммәтләрне торгызу, Җир-анага игелек, хөрмәт хисләрен уяту, кешелекнең экологик һәлакәт каршында торуында искәртергә кирәк иде.

Теманың актуальлелеге: халкыбызның улы, бөек шагыйре Г. Тукайның иҗаты турында күп язылды, күп укылды. Әдәбият белгечләребез һаман да аның биографиясенең, иҗатының ачыкланып бетмәгән кайбер фактларын тикшерәләр, барлыйлар.

Эш барышында мин дә үземә шундый максатлар һәм бурычлар куйдым:

Бөек шагыйребезнең экология һәм аның проблемаларына багышлап язылган шигырьләренә күзәтү ясау.

Габдулла Тукай - табигать сакчысы.

Табигатьне саклау темасына язылган әсәрләр исемлеге бай һәм төрле. Г. Тукай күп кенә шигырьләрендә җәнлекләрне, кошларны, бөҗәкләрне яратырга, аларга мәрхәмәтле, шәфкатьле булырга өнди, үзенең шигъри бизәкләре белән табигатьнең гүзәллеген ача. Табигатьне саклау – милләтебезне, туган телебезне, гореф-гадәтләрне, рухи һәм тарихи байлыкларны саклау белән тыгыз бәйләнгән. Чөнки туган тел, әдәби һәм тарихи мирас газиз җиребездә барлыкка килгән. Шуңа күрә балаларны татар халкының рухи тамырлары, ерак бабаларыбызның яшәү рәвеше, һөнәрләре белән таныштыру, аларда милли горурлык тәрбияләү мөһим.

Г. Тукай үзенең шигырьләрендә туган җиребез матурлыгына, гүзәл табигатенә дан җырлаган шагыйрь. Табигать темасын һәр язучы үзенчә күрә, тасвирлый, укучыга төрле тел бизәкләре, сурәтләү чаралары, әдәби алымнар аша ачып бирә. Шагыйрьнең пейзажы туган туфрактан, балачагы үткән Кырлай

якларыннан аерылгысыз. Пейзаж күп очракта сабыйлык хатирәләре аша үтеп тасвирлана. Тукайның туган як табигатенә балаларча мәхәббәте сизелеп тора. Шигырьләренең исемен дә күңелгә якын, үз итеп «Туган җиремә», «Туган авыл», «Җәйге таң хатирәсе» һ. б. дип атый.

Тау башында салынгандыр безнең авыл,

Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;

Аулыбызның ямен, су тәмен беләм,

Шуңа күрә сөям җаным-тәнем белән. (Г.Тукай "Туган авыл")

-дип яза шагыйрь туган авылының матурлыгына сокланып. Г.Тукайның табигатькә багышланган шигърияте укучыны дөньяга гаҗәпләнеп карарга, матурлыкны күрә белергә өйрәтә. Яшь укучылары өчен шагыйрь танып-белү материалы бирә, табигать табышмаклары иҗат итеп, баланы уйлануга этәрә,

сораулар куя. Мәсәлән, «Елның дүрт фасылы», «Җәй көнендә», «Көз», «Чыршы» һ. б. күп шигырьләрендә татар авылының табигатенә мәдхия җырлый. Яңгыр, чык, кырау, буран, җил, кояш, ай, яз, көз, җәй, кышның — һәрберсенең үзенчәлекле билгеләре турында шигъри ачышлар ясап, укучы күңеленә җиткерә.

Г. Тукай үзенең авылының гаҗәеп табигатен, үз вакытын белеп алышынган ел фасылларын, аларның һәрберсенең үзенә хас матурлыгын соклану катыш гаҗәпләнү хисләре белән яза. Кырлай авылы тирәсендәге калын урманнарны, сайрар кошлары, җәнлек-җанварлары, хуш ис бөркегән чәчкәле, кызыл җиләкле аланнары турындагы шигъри юллар кайсы укучыны гына хыял дөньясына алып китми икән

Йомгаклау. Бөек шагыйребез "Экология" фәнен өйрәнмәсә дә, Җир һәм анда яшәүчеләрнең тормышлары өчен борчылган. Ул табигатьнең кешегә яшәү өчен матди мөмкинлекләр дә, иҗат өчен илһам да бирүен дөрес аңлаган. Экологиянең чикләре бик киң. Тукай бу мәсьәләгә дә төрле яктан якын килә . Кыскасы, Г.Тукай фикеренчә, кеше табигатьне яратырга, сакларга, аның белән хозурланырга, аның кочагына омтылырга тиеш. Шулай булганда гына "тәнгә

дә, җанга да мунча” (“Тәлләһеф”) табылыр. Шул чакта гына шагыйрьгә илһам килер.

Каршыларга иң сәза чак, иң матур чак, җәйге таң;

Шул вакытта уйла, шагыйрь: килде илһам уйласаң.

(“Җәйге таң хатирәсе”)

Гомумиләштереп әйткәндә, Г. Тукай иҗатында туган як образы зур урын алып тора. Туган ягына булган мәхәббәтен иҗат җимешләре аша укучыларына җиткерә шагыйрь.

Һәм шушы әсәрләре белән ул кешеләргә: “Табигатьне саклагыз!” – дип әйтә кебек.

Кулланылган әдәбият.


1. Габдулла Тукай. Әсәрләр. Биш томда. 4 том. Проза. Публицистика (1907-1913), - Казан, Тат.кит. нәшр., 1985.
2. Тукай Г. Сайланма әсәрләр: 2 томда. - Казан: Татар.кит. нәшр., 2006.
3. Нуруллин И. Тукай.-Казан, Тат.кит.нәшр., 1979.
4. Рәсүлова З. Тукай эзләреннән.-Казан,Тат.кит.нәшр., 1985
5. Сайланма әсәрләр. Шагыйрь турында истәлекләр.- Казан: Татарстан Республикасы ”Хәтер нәшрияты” (ТаРИХ), 2002.


## Минзәлә төбәге әдәби киңлегендә экологик проблемалар һәм аларны чишү юллары.


***“Муса Җәлил исемендәге***
***Минзәлә педагогия колледжы” укытучысы***
***Гимадиева А. Ф.***


Экологик проблема - кешелек дөньясы язмышын билгели торган җитди мәсьәлә. Россия Федерациясе Президенты Указы белән 2017 ел - Россиядә Экологик культура һәм әйләнә- тирә мохитне саклау елы дип игълан ителде. Табигать – безнең яшәү урыныбыз. Без табигатьне яратабыз, аннан җаныбызга ямь, күңелебезгә тынычлык алабыз. Табигатьне саклау – ул үзебезне, киләчәгебезне, өебезне саклау дигән сүз. Кеше гомере буе табигать белән тыгыз

элемтәдә яши. Бүген кеше табигатькә бәйле дип әйтү генә дөрес булмас иде, чөнки табигатьнең язмышын кеше дә хәл итә, ул экологик тотрыклылыкны саклап калырга бурычлы.

Дәреслекләрдә язучыларыбызның да экологик темага багышланган әсәрләре зур урын били. Бу темага багышланган әсәрләрдә кеше, аның рухи дөньясы үзәктә тора: Л.Зөлкарнәй “Бичуралар һәм бичаралар”, И.Туктар “Урман букеты”, Ш.Маннапов “Су тәме”. Өлкән сыйныфларга тәкъдим ителгән зур күләмле әсәрләр арасында да әйләнә-тирә дөньяны, кеше сәламәтлеген, аның рухын, телен саклау проблемаларын күтәргән повесть-романнар шактый. Боларга мисал итеп, Г.Бәшировның “Туган ягым – яшел бишек”, “Җидегән чишмә”, М.Мәһдиевнең “Торналар төшкән җирдә”, Р.Мөхәммәдиевнең “Ак кыялар турында хыял”, М.Әмирнең “Агыйдел” һәм башка шундый әсәрләрен китерергә була. Әдипләр бу әсәрләре белән борынгыдан килгән гореф-гадәтләргә ихтирам тәрбияләргә, табигый байлыкларга сакчыл караштa булырга, кадерен белергә, өлкәннәргә хөрмәт белән карарга чакыралар, шатлык-куанычларны, кешенең матурлыгын, кайгы-хәсрәтне, олы фаҗигаләрнең тирәнлеген табигать аша ачып салалар.

Табигать ана яшел хәтфәдән чигелгән мендәренә башыбызны салдырып изрәтеп йоклата, йомшак җилләре белән биттән иркәли, тәмле сулы чишмәләре белән туендыра, телең йотарлык җиләк-җимешләре белән сыйлый.

Минзәлә төбәге әдәби киңлегендә урын алган күп кенә шагыйрьләребез, әдипләребез әсәрләре дә экологик проблемаларны читләтеп үтми, бик актив күтәреп чыга. Шигърияттә бу темага урын бирмәгән шагыйрьне табуы кыендыр. Табигать темасына язган шагырьләр, китап авторлары исемлеге бай һәм төрле: Рәшит Гәрәй, Салисә Гәрәева, Марс Шабаев, Гөлшат Зәйнашева, Азат Мәрданов, Фәрит Миргалимов, Мөслимә Гайниева, Фәнилә Ибраһимова. Әлеге әсәрләр балаларны табигатьне аңларга, яратырга, аның байлыкларына сакчыл караш формалаштырырга, туган җирнең кадерен белергә өйрәтә. Күренекле прозаиклар: Габделхәй Сабитовның “Бизәкле чиләк”, “Өч җан”, “Таңсылу – урман кызы”; Газиз Мөхәммәтшинның “Торналар киткәндә”,

“Саумысез, аккошлар”, “Яз башы”, “Кояш кызы” , Гөлшат Зәйнашеваның “Бәхет кошым”, “Рамай”, “Язмышлар һәм ялгышлар” әсәрләрендә җәнлекләрне, кошларны, бөҗәкләрне яратырга, аларга мәрхәмәтле, шәфкатьле булырга өндиләр, нәфис сүз, сәнгать чаралары ярдәмендә Җир-анага игелек, хөрмәт хисләрен уяталар, тел-сурәтләү чаралары белән табигатьнең гүзәллеген ачып, кешелекнең экологик һәлакәт каршында торуын да искәртәләр. Бүгенге көндә планетабызда табигатьтәге экологик проблемалар катастрофа дәрәҗәсенә җитте: суларыбыз пычранды, урманнарыбыз киселде, янды, сулар һавабыз агулы матдәләр белән зарарланды. Экологик белем һәм культураның түбән булуы, планетадагы катастрофаларның нәтиҗәләрен аңламау һәм күз алдына китерә белмәү – табигатьне саклау проблемаларына җавапсыз карашның иң беренче сәбәбе. Шуңа күрә бу өлкәдә эзлекле укыту системасын булдыру, экологик белем һәм тәрбия бирү мөһим мәсьәләгә әйләнде. Авторлар туган туфракка сабый чакта җибәргән тамырлар гына кешене ватанлы итә, хәерле итә, бәхетле итә дигән фикерне дәлиллиләр. Табигать баласы икәнлегеңне тою нәкъ шул чорда башлана һәм куе урманнардан, киң кырлардан, яшел болыннардан, тирән сулардан килүче кадерле кунак икәнлегең күңелгә мәңгегә берегеп кала. Язучыларыбызның, шагыйрьләребезнең тирән эчтәлекле әсәрләре аша шушы хис-тойгыларны балаларның күңеленә җиткерү, сеңдерү – укытучының изге бурычы.

Зыялылар алдында укучыга экологик белем бирү: дөньяга караш даирәләрен киңәйтү, аларны табигатьне сакларга, аңа мәрхәмәтле, игътибарлы булырга өйрәтү, туган җиребезне ярату, аның белән горурлана белү хисе тәрбияләү - иң төп максатларның берсе. Аларны тормышка ашыру өчен, нәтиҗәле алымнар һәм ышандырырлык фактлар кулланып, эзлекле эш алып барырга кирәк.

Кулланылган әдәбият:

1. Заһидуллина Д.Ф. Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2000.

2. Низамов А.М. Милли мәктәп тәрбия нигезләре.- Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2005.

3. Сәхипова Р.Ә. Халык педагогикасы нигезендә укыту һәм тәрбия бирү. –Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2005.

4. Җәләлиев Ш.Ш. Татар халык педагогикасы. –Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2000.

## Әдәбият дәресләрендә экологик һәм әхлак тәрбиясе.

***ТР НМР “Кизләү төп гомуми белем мәктәбе”***
***МБГБУ татар теле һәм әдәбияты укытучысы***
***Гыймалетдинова Нурзия Минәхмәт кызы***

Татарстанның иң матур почмагында, Кизләүдә яшәвебез белән бәхетле без. Кизләү - “чишмә” дигән сүз. Зур сулы Чирмешәне, изге чишмәләре, мәдрәсәләре белән, шушы матурлыкка дан җырлаучы, саклап, кадерләп яшь буынга тапшыручы халкы белән данлыклы безнең яклар. 27 ел авыл мәктәбендә укытучы булып эшләү дәверендә, мин авылда укучыларга әхлак тәрбиясе бирү, табигатькә сакчыл караш тәрбияләү күпкә үтемлерәк, уңайлырак, дип саныйм. Табигать ана яшел хәтфәдән чигелгән мендәренә башыбызны салдырып изрәтеп йоклата, йомшак җилләре белән биттән иркәли, тәмле сулы чишмәләре белән туендыра, телең йотарлык җиләк-җимешләре белән сыйлый. Бала авылның назлы кояшын тоеп, сулыкларында коенып, җимешләрен ашап үсә. Ата-аналарның мәктәпкә якынрак торуын, үз баласы турында ныграк кайгырта алуын да авылда уңайрак икәнлегенә иманым камил.. Авыл мәктәбенең дә берни белән дә бәяләп булмый торган өстенлекләре бар. Авылда һәркемнең тормышы күз алдында. Күрше күршесенә ярдәм итеп, хәл белешеп яши. Гаиләдә баланы әти-әнисе, әби-бабасы тәрбияли. Әти-әни эштә вакытта

баланы әбисе яки бабасы бакчага, су буйларына, яки урамга, тыкырыкка алып чыга. Анда чәчәкләрне иркәләп, күбәләкләр оча, кошлар сайрый. Бала бакчаның, су буйларының матурлыгын күреп үсә, кошлар сайравын тыңлый. Авылның саф һавасын сулап, хезмәт тәрбиясе алган авыл баласы сулыкларны пычыратмаска, кош ояларын туздырмаска, урамга пычырак атмаска кирәген дә аңлап үсә, чөнки ул бу эшләрне олкәннәрдән күреп, үзе дә башкара. Нәкъ Гомәр ага Бәшировның “Туган ягым яшел бишек” әсәрендә Гомәрнең әтисе Бәшир ага кебек. Ул да бит үз үрнәге белән балаларына тәрбия биргән. Балаларын эшкә дә өйрәткән, туган җирнең матурлыгын да күрә белергә ярдәм иткән. Зур, көчле куллары белән нәни сандугачны күмеп куюы гына да олы әхлак дәресе!.

Кеше гомере буе табигать белән тыгыз элемтәдә яши. Бүген кеше табигатькә бәйле дип әйтү генә дөрес булмас иде,чөнки табигатьнең язмышын кеше дә хәл итә, ул экологик тотрыклылыкны саклап калырга бурычлы. Әмма бүгенге көндә планетабызда табигатьтәге экологик проблемалар катастрофа дәрәҗәсенә җитте: суларыбыз пычранды, урманнарыбыз киселде, янды, сулар һавабыз агулы матдәләр белән зарарланды. Экологик белем һәм культураның түбән булуы, планетадагы катастрофаларның нәтиҗәләрен аңламау һәм күз алдына китерә белмәү – табигатьне саклау проблемаларына җавапсыз карашның иң беренче сәбәбе. Шуңа күрә бу өлкәдә эзлекле укыту системасын булдыру, экологик белем һәм тәрбия бирү мөһим мәсьәләгә әйләнде.

Без – табигать балалары,
Гел аның кочагында.
Уйнаганда ялгышлар да
Була шул кайчагында.
Учак яксак урманнарда,
Сүндерегез кисәвен.
Тик җыярга онытмагыз
Чүп-чар, кәгазь кисәген.

Әби – бабаларыбыз фольклорның бала тәрбияләүдәге әһәмиятен белеп эш иткәннәр, аның ярдәмендә балага тирә - юньне танырга һәм аңларга да өйрәткәннәр. Табигать, матурлык, әдәп - әхлак кагыйдәләре белән бала беренче тапкыр нәкъ менә милли гореф – гадәтләр аша таныша башлый. Шулай булгач, фольклор бала психологиясен тирәнтен ачарга, омтылыш һәм иҗат мөмкинлекләрен дә билгеләргә ярдәм итә.

Язучыларыбыз, беренчеләрдән булып, табигатьне саклау турында чаң какты. Әйләнә-тирәне, кеше сәламәтлеген, аның рухын, туган телен саклау аларны иң борчыган проблемага әйләнде. Кешедә югалып бара торган иң изге әхлакый-рухи кыйммәтләрне торгызу, Җир-анага игелек-хөрмәт хисләрен уяту, кешелекнең экологик һәлакәт каршында торуын нәфис сүз, сәнгать чаралары ярдәмендә искәртү кирәк булды.

Мәктәп һәм экологик культура –бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә булган төшенчәләр. Педогоглар алдында укучыларга экологик белем бирү: укучыларның дөньяга караш даирәләрен киңәйтү, аларны табигатьне сакларга, аңа мәрхәмәтле, игътибарлы булырга өйрәтү, туган җиребезне ярату, аның белән горурлана белү хисе тәрбияләү - иң төп максатларның берсе. Аларны тормышка ашыру өчен, нәтиҗәле алымнар һәм ышандырырлык фактлар кулланып, эзлекле эш алып барырга кирәк. Балаларда табигатькә сакчыл караш тәрбияләү катлаулы һәм дәвамлы педагогик процесс. Экология, фән буларак, мәктәпнең укыту программасына кертелмәгән. Шуңа күрә экологик проблемаларны табигать фәне дәресләрендә һәм түгәрәкләрдә генә түгел, ә башка фәннәрдә дә, аерым алганда татар теле һәм әдәбият дәресләрендә дә өйрәнергә кирәк. Татар теле һәм әдәбияты дәреслекләре экологик темага язылган бөтен әдәбиятны колачлый алмый, әлбәттә. Ләкин ул шактый күләмдәге әсәрләр белән таныштыра, экологик темаларга мөрәҗәгать итү алшартларын, аларның үзенчәлекләрен билгели. Моннан тыш, китаплар укырга мәҗбүр итә. Укучыларга милли, әхлаки тәрбия белән бергә, экологик белем һәм тәрбия бирүнең үрелеп баруы мөһим шарт булып кала. Сабый баланың әйләнә-тирәдәге үзгәрешләргә карап соклануы, кошлар сайравын

тыңлап тәэсирләнүе аның табигать белән кызыксынуын күрсәтә. Менә шул матурлыкны күрә, соклана белү сәләтен, нечкә хис-тойгыларны кечкенәдән үк үстерергә, ныгытырга кирәк.Халыкның тормыш тәҗрибәсе һәм табигатьне өйрәнү нәтиҗәсендә туган кыска, ләкин тирән мәгънәле өйрәтүләре, тәрбия алымнары бик гыйбрәтле. Әлеге өйрәтүләр татар халкының мәкаль һәм әйтемнәрендә аеруча күп тупланган һәм тирән мәгънәгә ия булган өйрәтү-киңәшләр формасын алган: “Хайваннарны җәберләгән рәхәт күрмәс”, “Яралы кошка таш атмыйлар”, “Кош йомыркаларын ватма, күз яшең түгәрсең”, “Яшь агачны сындырма, яшь гомерең өзелер”. Экологик белем һәм тәрбия бирүгә кагылган мәкаль-әйтемнәрне еш очратырга мөмкин. "Кул пычранса, су белән юарсың,

Су пычранса, ни белән юарсың". “Бер агачтан мең шырпы ясап була, бер шырпы белән мең агачны яндырып була”. Әлеге әйтем урманнарны саклау, янгын булдырмау максатыннан чыгарылган. Балаларда зирәклек, күзәтүчәнлек кебек сыйфатлар тәрбияләүче табигать күренешләренә багышланган табышмаклар: “Төнлә баксам – күк тулган, иртән баксам – юк булган”, “Язын ямь бирә, җәй салкын бирә, көзен тәм бирә, кышын тун бирә”; сынамышлар: “Кар барында күк күкрәсә, ашлык булмас”, “Җилгә каршы яуган яңгыр каты давыллы булыр”; шәфкатьлелек, миһербанлык, игътибарлылык кебек хисләр тәрбияләүче экиятләр, мәзәкләр, мәсәлләр дә шактый: “Умарта корты һәм чебеннәр”, “Кем көчле?”. Әдәбият дәреслекләрендә урын алган күп кенә шагыйрьләребез әсәрләре дә экологик теманы күтәреп чыга. Сөекле шагыйребез Габдулла Тукай күп шигырьләрендә җәнлекләрне, кошларны, бөҗәкләрне яратырга, аларга мәрхәмәтле, шәфкатьле булырга өнди, үзенең шигъри бизәкләре белән табигатьнең гүзәллеген ача. «Җир йокысы», «Яз галәмәтләре», «Карлыгач», «Бичара куян», «Бала белән күбәләк» кебек шигырьләрендә бу ачык чагыла. Ә «Кояш», «Һава», «Су», «Җир», «Елның дүрт фасылы» исемле кечкенә хикәләрендә табигать турында шактый мәгълүмат тупланган.

Шигърияттә бу темага урын бирмәгән шагыйрьне табуы кыендыр. Табигать темасына язылган шигырьләр исемлеге бай һәм төрле. Әлеге әсәрләр балаларны табигатьне аңларга, яратырга, аның байлыкларына сакчыл караш формалаштырырга, туган җирнең кадерен белергә өйрәтә. Шулай да мәктәп дәреслекләрендә зур урын бирелгән кайбер шәхесләребезне аерым әйтеп китү кирәктер: Г.Тукай, А.Алиш, Х.Туфан, Ш.Галиев, Р.Вәлиева шигырьләрендә җәнлекләрне, кошларны, бөҗәкләрне яратырга, аларга мәрхәмәтле, шәфкатьле булырга өнди, нәфис сүз, сәнгать чаралары ярдәмендә Җир-анага игелек, хөрмәт хисләрен уяталар, шигъри бизәкләре белән табигатьнең гүзәллеген ачып, кешелекнең экологик һәлакәт каршында торуын да искәртәләр.

Якташ шагыйрьләребез: Гакыйль Сәгыйров, Фәүзия Мөхәммәтова, Мөнәвәрә Усманова, Гөлүсә Нугаева, Роза Мәсләховаларның шигырьләре, җырлары аша укучыларда экологик тәрбия, әхлак тәрбиясе бирү максатыннан күп кичәләр, тәрбия дәресләре уздырабыз.

Дәреслекләрдә язучыларыбызның да экологик темага багышланган әсәрләре күп. Бу темага багышланган әсәрләрдә кеше, аның рухи дөньясы үзәктә тора: Л.Зөлкарнәй “Бичуралар һәм бичаралар”, И.Туктар “Урман букеты”, Ш.Маннапов “Су тәме”. Өлкән сыйныфларга тәкъдим ителгән зур күләмле әсәрләр арасында да әйләнә-тирә дөньяны, кеше сәламәтлеген, аның рухын, телен саклау проблемаларын күтәргән повесть-романнар шактый. Боларга мисал итеп, Г.Бәшировның “Туган ягым – яшел бишек”, “Җидегән чишмә”, М.Мәһдиевнең “Торналар төшкән җирдә”, Р.Мөхәммәдиевнең “Ак кыялар турында хыял”, М.Әмирнең “Агыйдел” һәм башка шундый әсәрләрен китерергә була. Әдипләр бу әсәрләре белән борынгыдан килгән гореф-гадәтләргә ихтирам тәрбияләргә, табигый байлыкларга сакчыл булырга, кадерен белергә, өлкәннәргә хөрмәт белән карарга чакыралар, шатлык-куанычларны, кешенең матурлыгын, кайгы-хәсрәтне, олы фаҗигаләрнең тирәнлеген табигать аша ачып салалар.

Туган туфракка сабый чакта җибәргән тамырлар гына кешене ватанлы итә, хәерле итә, бәхетле итә. Табигать баласы икәнлегеңне тою нәкъ шул чорда

башлана һәм куе урманнардан, киң кырлардан, яшел болыннардан, тирән сулардан килүче кадерле кунак икәнлегең күңелгә мәңгегә берегеп кала. Язучыларыбызның, шагыйрьләребезнең тирән эчтәлекле әсәрләре аша шушы хис-тойгыларны балаларның күңеленә җиткерү, сеңдерү – укытучының изге бурычы.

Җир елый ишетәсезме?
Мин ишетәм!
Челтерәп аккан чишмәләрем
Нигә кипкән?
Җир елый ишетәсезме?
Мин ишетәм!
Сандугачлы талкайларны
Кемнәр кискән?
Табигатьне кемнәр шулай
Әрәм иткән?
Кешеләрдә миһербанлылык
Кая киткән?
Җир елый ишетәсезме?
Мин ишетәм!
Бу гүзәллек, бу Җир шары
Яшәр микән?

Кулланылган әдәбият:

1. Заһидуллина Д.Ф. Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2000.

2. Низамов А.М. Милли мәктәп тәрбия нигезләре.- Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2005.

3. Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр. – Казан. – Татарстан китап нәшрияты, - 1987

4. Тукай Г. Шигырьләр һәм поэмалар. – Казан – Татарстан китап нәшрияты, - 1990

5. Бәширов Г. - “Туган ягым - яшел бишек”

6. Билалова Ә.Г., Гыймадиева Н.С. Әдәбият дәреслекләре буйлап. – “Яңалиф” нәшрияты. – 2006

7. Татар әдәбияты тарихы. 6 том. – Казан. “Раннур” нәшрияты. – 2001

10 .Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов Ә.М., Гыйләҗев Т.Ш. – Татар әдәбияты. Теория. Тарих . – “Мәгариф” нәшрияты. - 2004

## Экологик һәм әхлаклылык сыйфатлары тәрбияләүдә Нәҗип Мадьяров поэзиясен файдалану үзенчәлекләре.

*Данилова Зөлфирә Сәләхетдиновна*
*Алабуга шәһәре 10 нчы урта мәктәбенең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Балада югары әхлакый сыйфатлар тәрбияләү проблемасы кешеләрне гасырлар буе борчып килгән, чөнки кешелекнең киләчәге баланың бүген нинди тәрбия һәм белем алуына бәйле. Киләчәктә нинди кеше булыр? Ул үзеннән алда килгән өлкән буынның лаеклы дәвамчысы була алырмы? Менә шул уйланулар нәтиҗәсендә, милләтебез элек - электән туган җиргә, аның байлыкларына хөрмәт тәрбияләгән, сакчыл эш итәргә кушкан.

Табигать – бала тәрбияләүнең бай чыганагы.Шуңа күрә дә табигатькә мөнәсәбәт, кешеләргә мөнәсәбәт кебек үк, гуманлы, шәфкатьле булырга тиеш.[2;164 б] Әлбәттә,татар халкының күренекле шәхесләренең әсәрләре бу эштә укытучыга әйтеп бетергесез зур ярдәм күрсәтә. Шундый шәхесләрнең игътибарга лаегы, бөтен иҗатын шул максатка юнәлткән шагыйрьләрнең берсе — Нәҗип Мадьяров.Балаларга атап язылган һәр әсәре аша туган илгә, табигатькә, бер-беребезгә карата миһербанлы, кешелекле, изге күңелле, шәфкатьле булып яшәргә өнди. Аларда туган як, хезмәт; бәйрәмнәр;халык иҗаты;табигать: ел фасыллары,табигать күренешләре, табигать байлыклары,

кошлар, хайваннар, үсемлекләр, экология темалары берләшә. Мондый тематик төрлелек укучыга тәэсир итеп кенә калмый, аларга туры юлдан барырга ярдәм итә. Әдипнең әсәрләрен дәреслекләр, мәктәпкәчә яшьтәге балалар хрестоматияләрен төзүдә дә киң кулланалар.

Нәҗип Мадъяров**н**ың поэзиясе татар мәктәпләрендә укучы башлангыч татар класслары дәреслекләрендә урын алган. Мәктәпнең 1нче сыйныфына килеп, кулына тәүге тапкыр «Әлифба» тотып укырга өйрәнгән бала Нәҗип Мадъяровның «Балкый фонтан», «Тәнкыйтьлиләр», «Чаңгы шуам» шигырьләре белән таныша. Түбәндәге санап кителгән шигырьләре балаларга мактану кебек тискәре сыйфатларның нәрсә икәнен аңлату, дуслык һәм татулыкка өндәү, сәламәт яшәү рәвешен күрсәтү өчен алынган.

Аерым бер төркем шигырьләрендә туган як табигатенең серләрен ачу, аны танып-белү, өйрәнү игътибар үзәгендә тора. Шуның белән ул балаларда табигатькә сак һәм сизгер мөнәсәбәт тәрбияли. Мәсәлән,аның «Шуабыз», «Кар астыннан чыкты яз», «Томан», «Алмалар ничек кызарган?», «Балан» шигырьләре балаларда экологик культура тәрбияләү бурычын ашыруга ярдәм итүче әсәрләре.Нәҗип Мадъяров «Көзге урман» шигырендә көзге табигатьтәге үзгәрешләрне тасвирлап, төп уйны чагылдырган сүзләр табып, сабый күңеленә үтеп керергә тырыша. Рус балаларына тәкъдим ителгән әлеге шигыре укучыларда шулай ук туган яктагы үзгәрешләрне сизә белергә,тирә-юньдәге җәнлекләргә, кошларга сакчыл караш тәрбияләү бурычы куела.

Нәҗип Мадъяров «агач сындырмагыз!», «тирә–юньне чүпләмәгез!» кебек кисәтүләр тезми. Ул бала күңеленә якын вакыйгалар аша үгет–нәсихәт бирә.

– Күр әле, – ди – менә хикмәт,

Ник кран юк соң монда?

Ни карый икән сантехник?

Күпме су әрәм була. («Сәми авылга кайтты»)

Альтернатив дәреслекләр авторы Альберт Яхин урта яшьтәге мәктәп укучыларына «Кышкы әкият» шигырен туган илгә мәхәббәт хисе тәрбияләүдә үзенең дәреслекләренә керткән. Игелек сыйфатлары тәрбияләүдә «Әби күзлеген эзли» шигыре алына. Малай эшләгән игелек бик кечкенә. Ә игелеге зур. Автор бәясе мондый: игелекнең кечкенәсе, зурысы булмый, игелек, нинди генә булса да, зур итеп кабул ителә. VI сыйныфта өйдә уку өчен Нәҗип Мадъяровның «Имән» шигыре бирелә. Укучылар әлеге шигырьне өйдә укып тагын бер кат туган як турында уйланалар. Туган җирдә генә кеше шәбрәк яши дигән фикергә киләләр.

Нәҗип Мадъяров мәсәлләре, мәзәкләре балаларда әхлак тәрбиясе бирүдә иң үтемле чара булып санала ала. Бу мәсәлләрдә мактанчыклык, тәккәберлек, алдакчылык кебек сыйфатлар фаш ителә. Мәсәлән, «Мыексыз, имеш» мәзәген кешедән көлү, тәккәберлек сыйфатларын бетерү юнәлешендә балаларга тәкъдим итәргә була. Балалар әлеге мәзәк аша үзеңдә булган нәрсәнең һәрбер кешедә дә булуы мөмкин эш түгел, барлык җанварлар, шул ук вакытта кешеләр үзенчәлекле була дигән фикер салынган. Балалар шуңа төшенәләр.

Мәсәлләрдә персонажлар вазыйфасын башкарган кош-кортлар, хайваннар, халык аңында урнашкан төп бер сыйфатны гәүдәләндерә. Әтәч – көнчелекне, бүре – ерткычлыкны, ишәк – аңгыралыкны, мәче – мактанчыклыкны, куян – куркаклыкны, кырмыска эшлеклелекне чагылдыра. Шуның белән балаларда әхлакый сыфатлар тәрбияләүгә юл ачыла.

Нәҗип Мадъяровның тагын бер яратып иҗат итә торган жанрларының берсе – әкият. Аларның һәркайсына да олы фикер, саф әхлак һәм батырлыкка омтылу ята.Нәҗип Мадъяровның бай рухлы, кешеләрне гүзәл киләчәккә рухландыручы әкият-поэмалары киләчәк буынны милләт тормышын дәвам итәрлек, аны үстерүгә өлеш кертерлек итеп тәрбияләүдә зур чыганак

ролен үти.Әдипнең кайсы гына әсәрен алсак та, туган иленә, туган ягына гашыйклыгын тоясың. Гашыйк икәнсең, димәк, барысын да изге итеп саклый беләсең.

Гомумиләштереп әйткәндә, Нәҗип Мадъяров иҗатын тәрбияви максатларда өйрәнү, педагогик эшчәнлектә куллану балаларны тәрбияле шәхес итеп үстерүдә нәтиҗәле чара.

**Кулланылган әдәбият.**

1.Закирова К.В. Балачак аланы: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти-әниләр өчен хрестоматия – Казан: РИЦ, 2011. – 560 б

2. Мадъяров Н. Күбәләк: Шигырьләр [Кече яшьтәге мәктәп балаларына]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. – 30 б.

3.Хуҗихмәтов Ә.Н.Тәрбия – мәңгелек фәлсәфә: Югары һәм махсус урта уку йортлары өчен педагогикадан уку ярдәмлеге. – Казан:Мәгариф,2001.-223б.

## Башлангыч сыйныфта әдәби уку дәресләрендә әхлакый һәм экологик тәрбия.

*Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе “Тойгелде төп гомуми белем бирү мәктәбе”нең башлангыч сыйныф укытучысы Дәүләтова Гөлназ Мөбәрәкҗан.*

Бүгенге көндә югары әхлакый һәм экологик тәрбия –кешеләр һәм җәмгыять өчен иң кирәкле сыйфатлар булуга карамастан, кызганычка каршы, күпчелек яшьләребез өчен “популяр булмаган” һәм “модадан артта калган” сыйфатлар булып калдылар.Күпчелек галим-социологларыбызның фикере буенча ,без яшь буыныбызны югалттык: яшьләр әхлаклылыкны иң кирәксез сыйфатлар рәтенә кертәләр. Моның шулай булуында телевидение һәм интернетның өлеше бик зур.

Кеше, үз исеменә лаеклы шәхес буласы килсә, әхлаксыз яши алмый. Әхлакый һәм экологик тәрбия балага тумыштан бирелми, яки генетик код ярдәмендә буыннан буынга күчми.Тормышта төрле хәлләр булырга мөмкин.

Югары белемле,интеллигентлы, акыллы һәм тәртипле ата-аналарның балалары җәмгыять өчен бер файдасыз кешеләр,я булмаса җинаятьчеләр булып үсү очраклары бик күп. Шулай ук, киресенчә, авыр тормышлы, начар гаиләләрдә чиста күңелле, һәрвакыт яхшылыкка омтылучы, тыйнак һәм үзләренә карата таләпчән шәхесләр чыгу очраклары да җитәрлек. Олы буын кече буынның җитешмәгән якларын арттырыбрак та күрә. Дөрес, кызганычка каршы, безнең яшьләр хезмәткә өйрәтелмәгән, табигать байлыкларын сакламыйлар, башкаларга ихтирам белән карамыйлар, бөтенесен әти-әнисе эшләп биргәнне көтәләр дип уфтануларыбыз бик үк урынсыз түгел. Кем гаепле соң яшьләрнең шундый тәрбиясез булуларында: гаиләме, мәктәпме әллә ураммы? Дөрес монда өчесе дә гаепле, чөнки аларның һәрберсенең тәрбиясе бер-берсенә бәйле. Гаилә, мәктәп һәм урам бер үк дәрәҗәдә тәрбияләгән очракта гына югары нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин.

Балаларның аңына нәрсә генә булса да яхшылык җиңә дип сеңдерергә кирәк. Аларны шушы җиңү өчен көрәшергә өйрәтергә , бу җиңүгә бару юлында күп авырлыклар кичәргә, көлүләрдән югары булырга кирәклеген аңлатырга кирәк. Ләкин беренче чиратта без үзебез бу принципларга таянып яшәргә тиеш. Безгә, укытучыларга, үзебезнең һәм башка балалар карыйлар, алар киләчәк тормыш турында безнең гамәлләребездән чыгып фикер йөртәләр. Киләчәктә алар безне шул ук сыйныф бүлмәләрендә,идарә итү пультлары артында һәм башка урыннарда алмаштырачаклар, ләкин аларның фикерләре һәм гадәтләре бүгенге көндә формалаша. Табигатькә карата сак караш һәм әхлакый тәрбияне алар бүген гаиләдә һәм мәктәптә үзләштерәләр. Башлангыч сыйныфларда бу белемнәрне бала күңеленә ирештерү буенча эш барлык фәннәрдә дә алып барыла, ләкин әдәби уку фәннәренә аерым тукталып үтәсе килә.

Әдәби уку дәресләрен укытуның методлары һәм формалары турында бик күп бәхәсләр алып барылса да, бүгенге көндә бу дәресләрнең төп бурычы балаларга әхлакый тәрбия бирү икәнлеге көн кебек ачык. Шулай ук әхлакый тәрбиягә үрелеп экологик тәрбия дә алып барыла. Күпчелек әсәрләрдә кешенең тормышы һәм төрле шартларда үз-үзен тотышы чагыла. Күренекле

язучыларыбыз Габдулла Тукай, Абдулла Алиш, Муса Җәлил һ.б. әсәрләрендә чагылыш тапкан элекке вакыйгалар ничек кенә бездән ерак булмасын, аларда күтәрелгән проблемалар бүгенге көндә дә актуаль булып кала бирәләр. Бәхет һәм бәхетсезлек,тугрылык һәм хыянәт,ялган һәм дөреслек, батырлык һәм куркаклык, мәхәббәт һәм дуслык – бу һәм башка проблемалар гомерлек булып кала бирәләр һәм бер кемне дә битараф калдырмыйлар.

2нче сыйныфта үзләштерелүче әдәби әсәрләрнең балаларны экологик һәм әхлакый тәрбияләүдәге роленә аерым тукталып үтәсем килә. Мәсәлән, бөҗәкләр турында шигъри әсәрләр өйрәнү дәресендә балаларга Җ. Дәрзаманның “Бөҗәкләр белән сөйләшү” шигыре укыла. Бу шигырьдә бөҗәкләр тормышындагы проблемалар турында язылган: малайларның кырмыска ояларын туздыруы, чикерткәләрне тотулары, күбәләкләргә очарга һаваның начар булуы, кешеләрнең төрле дарулар һәм агулар сибүләре турында тасвирлап язылган. Бу шигырьне укыганнан соң балалар белән фикер алышу була. Балаларга:

- Бөҗәкләр дөрес зарланамы? Бөҗәкләрнең табигатьтә әһәмияте бармы? Аларның безгә булган әһәмиятләре нәрсәдә?- кебек сораулар бирелә.

Бөҗәкләрнең матур төсләре, күңелле җырлары белән безне сөендерүләре, тормышыбызны матурлаулары,табигатьтә бернәрсәнең дә артык түгеллеге турында фикер алышу була. Табигатьтә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре искә төшерелә.

Яшь язучылардан Гөлназ Вәлиеваның “Борынгы әкият”, “Су әкияте” әсәрләрен укыганда, чишмәләрнең ничек барлыкка килүе, аларның нәрсәдән куркулары ачыклана. Экологик һәм әхлакый тәрбия буларак, чишмәләрне ничек карарга һәм сакларга кирәклеге турында фикер алышу була, суның яшәү чыганагы икәнлеге,чишмәләрнең табигатьнең зур байлыгы, могҗизасы икәнлеге аңлатыла. Авылдагы чишмәләр турында әңгәмә корыла. Бу темага өй эше буларак чишмәләр турында иҗади эш әзерләп килергә мөмкин, мәсәлән, балаларга үзләренең чишмәләргә карата сак карашы, яки чишмәләрнең файдасы турында кечкенә генә инша язарга, я рәсем ясарга кушарга була.

Әдәби уку дәресләрендә бик күп әсәрләр аша балаларга экологик , әхлакый һәм эстетик тәрбия бирергә мөмкин. Роза Хафизованың “Күңел күзе” әсәрен генә алыйк. Бу әсәрдә Камил белән әтисенең урманда йөрүләре тасвирлана. Алар язгы урманның матурлыгына сокланып йөриләр.Бу әсәр балаларга үсемлекләрне, агачларны, чәчәкләрне, кошларны, җәнлекләрне сакларга кирәклеген, шәфкатьсез, начар кеше булырга ярамаганлыгын төшендерә. Әсәрдә табигатьнең дә җанлы икәне, каеннарның авыртудан елавы, кошларның, җәнлекләрнең сөйләшүе сурәтләнә.Әсәрне укыганнан сон балаларның кичерешләре белән уртаклашырга, аларның урманда үзләрен ничек тотулары белән кызыксынырга, табигатьне саклау өчен нәрсәләр эшләүләре турында сорарга мөмкин.

Резеда Вәлиеваның “Ак песи” әсәрендә ике песи турында язылган. Алар да кешеләр кебек үк төрле холыклы.Песиләрнең берсе башкаларның кайгысына битараф, аның үзенә яхшы булса шул җитә, ә икенчесе йомшак холыклы, юмарт,дуслыкның кадерен белә торган итеп сурәтләнә. Бу әсәр балаларда йорт хайваннарына карата яхшы караш тәрбияли, аларны тәрбияләргә, ач тотмаска өйрәтә, шулай ук, үзара мөнәсәбәтләренә дә игътибарлы булырга,дуслыкның кадерен белергә, комсыз булмаска кирәклеген аңлата.

Әдәби уку программасына кертелгән бик күп әсәрләр табигать, тормыш турында уйланырга, балаларның характерларын формалаштырырга, түбәндәге сорауларга җавап бирергә ярдәм итәләр:

- Син табигатьне саклауга үзеңнән нинди өлеш кертәсең? Табигать синдә нинди яхшы сыйфатлар тәрбияләргә ярдәм итә? Синдә нинди яхшы яклар,нинди начар яклар бар? Кеше бөтенләй яхшы сыйфатлардан гына торырга мөмкинме?

Һәр кеше иртәме соңмы үз юлын үзе сайлый. Ләкин без, укытучылар, үзебезнең дәресләребез, тәрбия сәгатьләребез белән балаларга үз юлларын сайларга ярдәм итәбез.Балаларга әхлакый, экологик тәрбия бирү - безнең зур бурычыбыз!

Кулланылган әдәбият:

1. Г. М. Сафиуллина, Ф. Ф. Хәсәнова, Ә. Г. Мөхәммәтҗанова. Әдәби уку: 2 нче сыйныф: Дәреслек. 3 кисәктә. 2 кисәк. — Казан: «Мәгариф — Вакыт» нәшрияты, 2013.

2. Г. М. Сафиуллина, Ф. Ф. Хәсәнова, Ә. Г. Мөхәммәтҗанова. Әдәби уку: 2 нче сыйныф: Дәреслек. 3 кисәктә. 3 кисәк. — Казан: «Мәгариф — Вакыт» нәшрияты, 2015.

3. Р.Вәлиева “Ак песи”-әкиятләр. Казан: Татарстан китап нәшрияты,2006

## Әдәбият дәресләрендә әхлакый-экологик тәрбия бирү.

*“Тойгелде төп гомуми белем бирү мәктәбе”нең*
*беренче категорияле татар теле һәм әдәбияты*
*укытучысы Дәүләтова Рушания Фатих кызы*

Заман алга бара дип чын күңелдән сөенәбез. Ләкин тирә-як мохит моңардан зыян гына күрүен онытып җибәрмәскә тиешбез. Кешелекнең табигать белән бәйләнеше – хәзерге заманның актуаль мәсьәләләреннән санала. Промышленностьнең үсүе табигатьнең тигезлеген югалтуга китерде: сулыкларның, һава, җир өслегенең пычрануы кеше сәламәтлегенә куркыныч яный, бигрәк тә балаларга. Күп кешеләрдә экологик белемнәр һәм экологик культура җитеп бетми. Һичшиксез, бу укыту-тәрбия эшенең җитешле дәрәҗәдә булмавы ─ илебез халкына, табигатькә карата дөрес караш формалаштыра белмәү нәтиҗәсе.

Әхлакый-экологик белем һәм тәрбия бирүдә әдәби әсәрләрнең әһәмияте зур. Язучыларыбыз, беренчеләрдән булып, табигатьне саклау турында чаң сукты. Әйләнә-тирә дөньяны, кеше сәламәтлеген, аның рухын, телен саклау аларны иң борчыган һәм дулкынландырган проблемага әйләнде. Нәфис сүз, сәнгать чаралары ярдәмендә кешедә югалып бара торган иң изге әхлакый-рухи

кыйммәтләрне торгызу, Җир-анага игелек, хөрмәт хисләрен уяту, кешелекнең экологик һәлакәт каршында торуын да искәртергә кирәк иде.

Дәреслекләрнең эчтәлегенә игътибар итсәк, экологик тәрбия бирү аеруча яктыртыла. Мәсәлән, Әхмәт Халидовның “Урман сакчылары”, Фирдәвес Гарипованың “Су кадере”, Клара Булатованың “Ана сүзләре”, Сибгат Хәкимнең “Яшь юкә”, Габдулла Тукайның “Бала белән күбәләк”, “Яшь агач” укучыларда экология проблемасы турында белү генә түгел, аны чишү юлларын эзләү теләге уята.  М.Кәрим "Озын ─ озак балачак", Г.Сабитов "Ярсулы яз", Г.Бәширов "Туган ягым – яшел бишек", Әхсән Баянов "Сәяхәтнамә" әсәрләрендә кеше һәм табигать мөнәсәбәтләре, табигатьне саклау мәсьәләләре үткен итеп куела.

Г.Тукай күп кенә шигырьләрендә җәнлекләрне, кошларны, бөҗәкләрне яратырга, аларга мәрхәмәтле, шәфкатьле булырга өнди, үзенең шигъри бизәкләре белән табигатьнең гүзәллеген ача. Табигатьне саклау– милләтебезне, туган телебезне, гореф-гадәтләрне, рухи һәм тарихи байлыкларны саклау белән тыгыз бәйләнгән. Чөнки туган тел, әдәби һәм тарихи мирас газиз җиребездә барлыкка килгән. Шуңа күрә балаларны татар халкының рухи тамырлары, ерак бабаларыбызның яшәү рәвеше, һөнәрләре белән таныштыру, аларда милли горурлык тәрбияләү мөһим. Табигатьнең матурлыгын, серлелеген Тукаебыз үзенең җаны, саф күңеле, йөрәк җылысы салынган шигъри юллары белән укучы җанына, аның күңеленә салучы, ныгытучы, мәңгеләштерүче.

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;
Аулыбызның ямен, су тәмен беләм,
Шуңа күрә сөям җаным-тәнем белән.  (Г.Тукай. "Туган авыл") [4.64]

"Су анасы", "Шүрәле" әсәрләрендә баланы гаҗәеп табигать дөньясына алып керә. Матурлык дөньясын тою балаларда гүзәллеккә омтылу хисе уята. Бу әсәрләр аша балаларда кешегә, аның акылына, зирәклегенә, хәйлә катнаш тапкырлыгына, кыюлыгына, батырлыгына соклану хисе уяна. Ә хисләр, хыяллар дөньяны танып белүнең башлангычы ул.

Урман татар халкының тормышында да зур урын алып тора. Тукай урманнарның гүзәллегенә соклана. Ул яхшы белә: урман саф һава чыганагы да, бетмәс-төкәнмәс байлык та. Кырлай урманнарының матурлыгы, сихри тылсымы аның күңелендә мәңгелекккә уелып калган. Шагыйрь үзенең “Исемдә калганнар” әсәрендә “Бу Кырлай авылы минем дөньяга иң элек күзем ачылган урыным”,─ дип юкка гына язмагандыр. Шагыйрь фикеренчә, урман ─ саулык, байлык сандыгы.

Табигать турындагы белемнәр халык авыз иҗатында да киң чагылыш тапкан, экият, мәкаль, әйтем, сынамыш һәм табышмакларда күп кенә экологик мәгълүмат бирелгән. Бу чыганакның төп өстенлеге шунда: белемнәр балаларга мавыктыргыч рәвештә җиткерелә.

Дәресләрдә халык авыз иҗатының бар төре булган табышмакларны еш кулланабыз. Аларның күбесе еш очрый торган табигать күренешләренә багышланган “Ак яулыгым төшеп калды...”, яки табигый җисемнәргә хас үзенчәлекләр турында “Җәен соры, кышын ак, аңа шулай яхшырак”. Табышмаклар балаларда зирәклек, күзәтүчәнлек кебек сыйфатлар тәрбияли, дәресне җанландыра, укучыларның активлыгын күтәрергә ярдәм итә. Табышмакларны теләсә кайсы дәреснең уңайлы моментын табып файдаланырга мөмкин. Аларны кулланып кроссвордлар, төзергә була.

Халык авыз иҗатының икенче бер төре ─ мәкаль. Кыска, ләкин хикмәтле сүзләр белән халык бик тирән мәгънәле фикерләрне бер буыннан икенче буынга җиткергән; шуңа күрә күпчелек аны “ата-баба сүзе” дип йөрткән. Мәкальләр арасында табигатькә багышланган һәм экологик тәрбияне күз алдында тотканнарын сайлап, дәресләрдә куллану, аларның асылын укучыларга җиткерү дәреснең нәтиҗәлелеген күтәрә, аларга игелекле эшләр башкарырга омтылыш уята. Мәсәлән, “Суга сусаган ─ чишмә әрчегән”, “Агач утырткан ─ ага булган”, “Кул пычраса, су белән юарсың?” һәм башка шундый мәкальләрдән файдаланабыз.

"Кешенең борынгыдан килгән гуманлы карашларына, гореф-гадәтләренә, еллар буена сыналып килгән тормыш тәжрибәсенә хилаф килердәй, аны рухи,

әхлакый яктан рәнжетердәй башабаштаклык ахыр чиктә табигатькә дә зарар булып төшә", — дип язган халык язучысы Г.Бәширов. [2.45] Димәк, яшь буында табигатькә сакчыл караш тәрбияләүне кешедә гасырлар буе тупланган, аңа хезмәт аша сеңгән гомумкешелек әхлак сыйфатларын, тирә-юньгә кешенең элеккеге мөнәсәбәтен эзләү белән тыгыз бәйләргә кирәк.

Кулланылган әдәбият исемлеге


1. Гафаров И.Ә. Туган як мирасы. – Казан, 2004.

2. Галимуллин Фоат. Эзләнү вакыты. ─ Казан: Мәгариф нәшрияты, 2005

3. Заһидуллина. Д.Ф. Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы: метод.кулланма. – Казан: Мәгариф, 2000.

4. Тукай Г. Сайланма әсәрләр. Шагыйрь турында истәлекләр.─ Казан: Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты (ТаРИХ), 2002. ─ 511 бит

5. Хаков В.Х. Татар әдәби теле тарихы. – Казан, КДУ нәшрияты, 1993.

6.http://www.docme.ru/doc/1062018/gimnaziya-N-155.-sbornik---2015.poslednij


## Габдулла Тукай ижатында экология темасы


***Ермолаева Эльвира Сабирҗан кызы,***
***башлангыч класс укытучысы,***
***Мөслим муниципаль районы***
***муниципаль бюджет гомум***
***белембирү учреждениясе***
***“Мөслим гимназиясе”***


Кеше тормышы һәрвакыт табигать белән бәйле. Ул — кешенең сәламәтлек, туклану,гомумән, яшәеш чыганагы. Табигать дигәч, иң беренче чиратта, калын яшел урманнар, саф сулы чишмәләр, бай тарихлы елгалар, күлләр, иксез-чиксез җәелеп яткан далалар күз алдына килә. Табигать безгә азык, кием, торыр урын

бирә. Кеше тормыш өчен кирәкле бар нәрсәне табигатьтән ала. Шуңа күрә табигатьне сакларга кирәк. Табигатьне саклау- һәр кешенең изге бурычы.

Экологик белем һәм тәрбия бирүдә әдәби әсәрләрнең әһәмияте зур. Язучыларыбыз, беренчеләрдән булып, табигатьне саклау турында чаң сукты. Әйләнә-тирә дөньяны, кеше сәламәтлеген, аның рухын, телен саклау аларны иң борчыган һәм дулкынландырган проблемага әйләнде. Нәфис сүз, сәнгать чаралары ярдәмендә кешедә югалып бара торган иң изге әхлакый-рухи кыйммәтләрне торгызу, Җир-анага игелек, хөрмәт хисләрен уяту, кешелекнең экологик һәлакәт каршында торуында искәртергә кирәк иде.

Мин эшемне “Тукай иҗатында экология темасы” дип атадым.

Теманың актуальлелеге: халкыбызның улы, бөек шагыйре Г. Тукайның иҗаты турында күп язылды, күп укылды. Әдәбият белгечләребез һаман да аның биографиясенең, иҗатының ачыкланып бетмәгән кайбер фактларын тикшерәләр, барлыйлар.

Экология һәм табигать.

Экология (грек сүзе) эйкое – йорт, тереклек ияләре һәм үсемлекләрнең яшәү урыны; логос – закон, канун дигәнне аңлата. Кояш, су, ком, таш, хайван һәм үсемлекләр – барысы бергә табигать дип атала. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә менә ничек язылган: «Табигать – билгеле бер урынның җир сулары, үсемлек, хайваннар дөньясы кеше эшчәнлегеннән башка барлыкка килә торган һәммә нәрсә». «Кеше табигатьтән башка яши алмый. Табигатькә чыгып, без ял итәбез, кошлар җырын тыңлыйбыз, хуш исле үләннәр, чәчәкләр иснибез, күңелләребезне сафландырабыз. Мәрхәмәтлелек тамыры табигатьтән башлана. Ә мәрхәмәтлелек ул – мәхәббәт, ярату. Мәхәббәт – җәнлекләрне, кошларны, бар табигатьне ярату, саклау.Табигатьнең матурлыгына хозурлану гына аз, аны саклый, аңлый белергә дә кирәк.

Габдулла Тукай — табигать сакчысы.

Табигатьне саклау темасына язылган әсәрләр исемлеге бай һәм төрле. Г. Тукай күп кенә шигырьләрендә җәнлекләрне, кошларны, бөҗәкләрне яратырга, аларга мәрхәмәтле, шәфкатьле булырга өнди, үзенең шигъри бизәкләре белән

табигатьнең гүзәллеген ача. Табигатьне саклау – милләтебезне, туган телебезне, гореф-гадәтләрне, рухи һәм тарихи байлыкларны саклау белән тыгыз бәйләнгән. Чөнки туган тел, әдәби һәм тарихи мирас газиз җиребездә барлыкка килгән. Шуңа күрә балаларны татар халкының рухи тамырлары, ерак бабаларыбызның яшәү рәвеше, һөнәрләре белән таныштыру, аларда милли горурлык тәрбияләү мөһим. Табигатьнең матурлыгын, серлелеген Тукаебыз үзенең җаны, саф күңеле, йөрәк җылысы салынган шигъри юллары белән укучы җанына, аның күңеленә салучы, ныгытучы, мәңгеләштерүче.

Г. Тукай үзенең шигырьләрендә туган җиребез матурлыгына, гүзәл табигатенә дан җырлаган шагыйрь. Шагыйрьнең пейзажы туган туфрактан, балачагы үткән Кырлай якларыннан аерылгысыз. Пейзаж күп очракта сабыйлык хатирәләре аша үтеп тасвирлана. Тукайның туган як табигатенә балаларча мәхәббәте сизелеп тора. Шигырьләренең исемен дә күңелгә якын, үз итеп «Туган җиремә», «Туган авыл», «Җәйге таң хатирәсе» һ. б. дип атый.

Тау башында салынгандыр безнең авыл, Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул; Аулыбызның ямен, су тәмен беләм, Шуңа күрә сөям җаным-тәнем белән.(Г.Тукай “Туган авыл”) - дип яза шагыйрь туган авылының матурлыгына сокланып.

Г.Тукайның табигатькә багышланган шигърияте укучыны дөньяга гаҗәпләнеп карарга, матурлыкны күрә белергә өйрәтә. Яшь укучылары өчен шагыйрь танып-белү материалы бирә, табигать табышмаклары иҗат итеп, баланы уйлануга этәрә,сораулар куя. Мәсәлән, «Елның дүрт фасылы», «Җәй көнендә», «Көз», «Чыршы» һ. б. күп шигырьләрендә татар авылының табигатенә мәдхия җырлый. Яңгыр, чык, кырау, буран, җил, кояш, ай, яз, көз, җәй, кышның — һәрберсенең үзенчәлекле билгеләре турында шигъри ачышлар ясап, укучы күңеленә җиткерә. “Чыршы” шигырендә автор көзнең бер билгесен- агач һәм үләннәрнең саргаюын, чыршының исә “үз төсен үзгәртми” калуын контраст кую рәвешендә ача:

Саргаядыр көз көнендә һәр агач яфраклары;

Юк яшеллекләр хәзер, урман вә сахра сап-сары.

…Үз төсен үзгәртми саклаучы арада берсе бар:

Көз көне һәм кыш буе саргаймый торган чыршы бар.

“Көз”, “Мәктәптә” шигырьләрендә исә әлеге тема инде киңрәк планда һәм тулырак бирелә, фикер катлаулана төшә: “саргаю” билгесенә кошлар китүе, игеннәр җыелу, кояшның җылысы киму һ.б. сыйфатлар өстәлә.

Мифологик сурәтләргә бай “Шүрәле”, “Су анасы” әсәрләре халык әкиятләре стилендә язылган, тирән халыкчанлык белән сугарылган. Биредә табигатьнең бөтен матурлыгы һәм серлелеге сыйдырылган. Шагыйрь үзенә генә хас алым һәм зур осталык белән укучыларны табигать дөньясына алып керә, матурлыкны тоя һәм күрә белергә өйрәтә. Тукай борынгылыкны саклаган, халкының гореф-гадәтләренә нигезләнгән мифларны яхшы белә.

Шүрәле — әсәрдә төп образ. Ул табигать иркәсе, урман хуҗасы, шагыйрь аны әкияттәгечә куркыныч кыяфәтле, адәмнәрне кытыкларга яратылган озын бармаклы «урман пәрие» итеп сурәтли. Былтыр белән Шүрәле очрашуы укучыны сагайтса, Былтырның акыл зирәклеге, тапкыр хәйләсе ярдәмендә җиңүе сөендерә.

Г. Тукай үзенең авылының гаҗәеп табигатен, үз вакытын белеп алышынган ел фасылларын, аларның һәрберсенең үзенә хас матурлыгын соклану катыш гаҗәпләнү хисләре белән яза.

Йомгаклау.

Габдулла Тукай әйтергә теләгән фикерләре укучыга барып җитсен өчен, әдәби телебезнең төрледән-төрле сурәт-бизәкләрен куллана, төрледән-төрле чагыштырулар куллана. Мәсәлән: «Тәгәридер ул матур кыз —язның алтын фәйтуны»; «Барыбер, күрсәң, качарсың, язны — гөлләр патшасын».Әйе, кеше табигатьнең аерылгысыз өлеше. Шагыйребезнең шушындый кешелекле, шәфкатьле әсәрләре безне асылыбызга кайтара, табигать дөньясы белән тагын да якынайта. Киләчәк буын вәкилләре дә әлеге әсәрләр аша гүзәллек дөньясын күреп, тоеп, киләчәктә аны кайгыртып яшәсә иде.

Табигать сурәте Г. Тукайның поэзиясендә гаҗәеп күп төрле функцияләрдә кулланыла, шагыйрьнең иҗатынан гуманистик рух, җылы лиризм бөрки.

Табигать күренешләре аша дөньяга карашын, тормыш фәлсәфәсен чагылдыра. Табигатьнең биниһая чиксез рухын, мәңгелеген, бетмәс-төкәнмәс матурлыгын, төсләр, исләр байлыгын укучысына җиткерергә омтыла шагыйрь. Табигатьтәге нәфислектә, иллелектә, хәзерге җәмгыятьнең матурлыгын, кешеләр арасындагы камил мөнәсәбәтләрнең чагылышын күрә, алар арасында рухи якынлык таба.

Язучының, туган табигатькә, табигый матурлыкка мөнәсәбәте бала чактан тәрбияләнә. Яшьлек хатирәләре аның өчен илһам чыганагы, алдагы тормышында маяк булып тора. Мәгълүм булганча, шагыйрьнең балачагы мәһабәт урман-тугайлар, хәтфә болыннар, чылтырап аккан чишмә-елгалар кочагында үтә. Авыл малайлар белән су буенда, балыкта. Печән җитсә — ул печәндә. Аунасаң- чәчәге ияреп кайта. Урагы җитсә — ул да урак өстендә җир сөреп, сука сукалап үсә ул. Нәкъ менә Туган якның яме булачак шагыйрьнең дөньяга карашын, зәвыгын тәрбияләүгә үзеннән зур өлеш кертә.

Бөек шагыйребез “Экология” фәнен өйрәнмәсә дә, Җир һәм анда яшәүчеләрнең тормышлары өчен борчылган. Ул табигатьнең кешегә яшәү өчен матди мөмкинлекләр дә, иҗат өчен илһам да бирүен дөрес аңлаган. Экологиянең чикләре бик киң. Тукай бу мәсьәләгә дә төрле яктан якын килә.

Бүгенге көндә кешеләр табигатьне сакламыйлар. Елгалар пычратыла, хайваннар үлә, күп кенә үләннәр, чәчәкләр, агачлар юкка чыга. Габдулла Тукай табигатьне сакларга тырышкан. Безне дә шуңа чакыра!

Кулланылган әдәбият.

Габдулла Тукай. Әсәрләр. Биш томда. 4 том. Проза. Публицистика, — Казан, Тат.кит. нәшр., 1985.

Тукай Г. Сайланма әсәрләр: 2 томда. — Казан: Татар.кит. нәшр., 2006.

Лаисов Н. Габдулла Тукай. Тат.кит.нәшр.,

Нуруллин И. Тукай.-Казан, Тат.кит.нәшр., 1979.

Рәсүлова З. Тукай эзләреннән.-Казан,Тат.кит.нәшр., 1985

## Экологик тәрбиядә төбәк үзенчәлекләре

***Җиһангәрәева Тәнзилә Рәхимҗан кызы,***
***Шәйхетдинова Әлфия Билал кызы***
***Әгерҗе районы Көчек урта гомуми белем бирү мәктәбе***

*Табигать сөючеләр арасында мин*
*явыз холыклы,*
*кара эчле әшәке кешеләр*
*очратмадым.*

***Гомәр Бәширов***

“Экологик тәрбия” сүзтезмәсе – педагогик термин буларак кулланылышы белән генә яңа юнәлеш. Халкыбызның милли педагогикасында буыннан-буынга экологик тәрбия бирелгән. Татар кешесе үзен табигатьнең бер кисәге дип хис иткән, табигать белән гармониядә яшәгән. Моны халык авыз иҗатының мәкаль-әйтемнәре дә раслый: “Яшь агачка кагылган – гомерен кыскарткан”, “Урман үстер – ачлык килмәс”, “Кош оясы туздырма – каргышы төшәр”, “Баканы кыерсытма, кайгыдан башың чыкмас”, “Түкермә коега, суын үзең эчәрсең” һ.б.. Ата-баба үрнәгендә, яңа буын яшьләр дә, табигать баласы булып яшәү рәвешенә буйсынганнар.

Заман цивилизациясе уңай якка гына түгел, тискәре якка да үзгәрешләр ясады, тормышны гына түгел, яшәү рәвешен, гореф-гадәтләрне дә тамырдан үзгәртергә сәләтле булып чыкты. Гомумкешелек дөньясына янаган экологик фаҗигаләр шундый тискәре үзгәрешләргә нигезләнә. 21нче гасыр баласына экологик тәрбия бирү мәсьәләсен ничек чишәргә? Без, татар теле укытучылары, бу эшне ике факторга таянып алып барабыз: яхшы һәм начар үрнәк.

Яхшы үрнәк тормыш, яшәү рәвеше белән бәйле. Тормыш позициясе – рухи тәрбиянең асылы. Ә экологик тәрбия рух белән, җаваплылык белән тыгыз бәйләнештә. Баланың рухы, күңеле – үзендә, кешелек, табигать, тирә-юнь каршында олы җаваплылык сизәрлек итеп формалашырга тиеш. Татар теле һәм

әдәбият дәресләре рухи тәрбия аша йогынты ясау өчен менә дигән җирлек. Татар теле дәресләрендә җөмлә кисәкләренең тиңдәшләшеп һәм үзара бәйләнеп килү чараларын өйрәнгәндә мисал итеп, әдәби әсәрләрдәге табигать күренеше тасвирларыннан файдаландык. Укучыларга да татар әдәбияты әсәрләреннән тиңдәш кисәкләр кулланып сурәтләнгән пейзажлы өзекләр эзләргә куштык. Укучылар Г.Ибраһимов, Ә.Еники, М.Мәһдиев кебек классикларның һәм башка күп кенә татар әдипләренең әсәрләреннән табигать күренешләре белән бәйле өлешләрдән тиңдәш кисәкле җөмләләр кергән өзекләр туплаганнар. Гамәли биремгә нәтиҗә ясау эшендә һәркем актив булды. Бу эшне фәнни эш кысаларында да дәвам итергә булдык. Моңа кадәр дә укучылар белән бергә, фәнни эштә тел өйрәнү теориясе һәм экологик фикерне берләштереп эшләү тәҗрибәсе булды. “Татар һәм рус телләрендә чит сөйләм төрләре” дигән темага әзерләнгән фәнни эш 2017 елның Татарстанда Экология һәм иҗтимагый киңлекләр елы булу уңаеннан эшләнелде. Сөйләм үрнәкләре балалар өчен русча-татарча тәрҗемәләр белән басылган Аяз Хәсәновның “Где живут лесные тайны. Урман серләре” китабыннан алынды. Шул мисалларга нигезләнеп, татар һәм рус әдәби телендәге мисалларда чит сөйләм структурасы чагыштырылды.

Халкыбыз классиклары безгә олы мирас калдырган. Г.Ибраһимовның “Табигать балалары”, Г. Бәшировның “Туган ягым – яшел бишек “ кебек уникаль әсәрләре әдәбият дәресләрендә җентекләп өйрәнелә. Быел 8нче сыйныфлар белән бу әсәрне өйрәнгәч, әсәр өзегендәге фикерне дәвам итеп язу шарты куелган иҗади эшләр конкурсы үткәрелде. Моннан тыш, сыйныфтан тыш иҗади эшләрдә дә экологик фикер көче зур булды. 6нчы сыйныф укучылары белән сәхнәләштергән “Авыл эте Акбай” спектаклендә Т.Миңнуллин тарафыннан ассызыклап бирелгән экологик проблемалар авылыбыз сәхнәсеннән аеруча көчле яңгыраш тапты.

Без – Әгерҗе төбәгендә яшибез. Безнең төбәк тарихы, халкы, әби-бабайларыбыз экологик афәтне үзләре дә кичергәннәр. Алда аталган “начар үрнәк” мисалы менә шул вакыйгалар белән бәйле. Түбән Кама сусаклагычы

төзелеше диңгез өсте тигезлегеннән 68 метр биеклеккә күтәрелеп, районыбыз авылларын су баскан. Кешеләр туган авыл, туган нигез, нәселләре күмелгән зиратларын югалтканнар. Бу вакыйгалар телдән-телгә сөйләнә, балалар да ишетеп үсәләр. Йорт-җирләрен туздырып, туган илен калдырып, иң мөһиме – берничә буын ата-бабалары күмелгән каберләрне казып күчерүне якташыбыз шагыйрь Ринат Батталовка да кичерергә туры килгән. Аның шигырьләрендә, иҗатында да бу вакыйгалар чагылыш тапкан. Туган авылы Рыс нигезләре инде дистә еллар су астында. “Бу якларга барып, яр буена утырып, елашып кына кайтабыз”, – дип яза бу хакта Ринат Батталов.

Якташыбыз Мансур Вәли-Барҗылы үз иҗатында Чулман буенда урнашкан күп кенә җирләрнең су астында калуы һәм бу җирләрдән авылларны күчерү вакыйгаларының кеше язмышлары белән ничек бәйле булуын ачык тасвирлаган. Якташыбызның ГЭС төзү нәтиҗәсендә юкка чыккан туган авылына багышлап язылган “Идел яры” әсәрен югары сыйныф укучылары белән сыйныфтан тыш уку сәгатьләрендә өйрәнәбез.

Урман-кырда, табигать кочагында үскән балалар тирәнрәк хисле, сәләтле һәм кешелеклерәк була. Балаларыбыз, вакыт юклыкны сылтау итеп урамда, табигатьтә аз була, күбрәк компьютер артында утыра. Яз-көз айларында, 5-6нчы сыйныф укучылары белән тел-әдәбият дәресләрен, яисә, дәресләрнең бер өлешен ачык һавада, табигатьтә үткәрүне сынап карадык. “Табигатьтә кунакта”, “Экскурсия-дәрес”ләр белем бирү белән бергә, матурлыкка сокланып карый белү, күзәтеп, үз фикерләреңне әйтә белү күнекмәләрен булдыру максаты белән оештырылды. Бу төр дәресләр аеруча ныклы әзерлекне, балалар игътибарын эшкә юнәлтеп оештыруны таләп итә, әмма, нәтиҗәләре һәм рухи кыйммәте арта.

Халык телендә “ашлаган җир аш китерер, ашламаган – таш китерер”, дигән тирән мәгънәле мәкаль бар. Экологик тәрбия эшендә әлеге мәкальнең эчтәлеге тагын да актуальләшә. Табигатькә сакчыл караш, туган туфракны изгеләштергән хисләр һәр баланың күңел түрендә кечкенәдән уянсын, мәктәп чорында ныгып, гомерлеккә җанга сеңсен иде!

**Туган телне ничек саклап калырга?**

***Закирова Ләйсирә Муллаян кызы.***
***Әгерҗе районы МБББУ Салагыш***
***урта мәктәбе башлангыч класслар укытучысы***

Мин чыгышымны “Ватаным Татарстан”газетасында тарихчы, этнолог Дамир Исхаков белән булган әңгәмәдән башлап җибәрәсем килә.

...-Бүген татар милләте алдында торган иң зур,иң актуаль проблемалар, Сезнеңчә,нидән гыйбәрәт?

-Икенче төп проблема-татар телен ничек саклау проблемасы .Бу хәзер шундый катлаулы нәрсәгә әйләнде .( ВТ” №12-27.01.2017.”Колачлырак фикерләү күренми”Әңгәмәдәш Рәшит Минһаж)

Район үзәкләрендә генә түгел, күп кенә авылларда да укыту рус телендә алып барыла. Телне саклауда дәреслек материаллары гына түгел, дәрестән тыш уздырыла торган чаралар да ярдәм итә.Үз телен белгән кеше туган җиренең патриоты була. Татарны милләт буларак саклап калуның бердәнбер юлы – телне саклап калу. Татарны ничәмә гасырлар иманлы, көчле рухлы итеп яшәткән нәрсә – ислам дине, шәригать кануннары. Бала иң беренче чиратта үзенең чыгышын белергә тиеш. Моны истә тотып, мин укучылар белән шәҗәрә бәйрәме,”Башваткыч”уеннары уздырдым. Кайчандыр Габдулла Тукай татар теле турында “әткәм-әнкәмнең теле” дип язган булса, бүгенге балаларның күбесе бу гыйбарәне ишеткәндә, күз алдына рус телен генә китерәләр. “Тел ул-мөселманның үзенчәлеген күрсәтүче төп билгеләрнең берсе, чөнки мөселман башка милләтләр арасында эреп югалырга тиеш түгел. Милләтебез горурлыгы булган Мәрҗани хәзрәт, зур галим буларак ...үрнәк булып тора. Ул ...”русча сүз катыштырудан сакланырга, мөмкин кадәр үз телеңне сакларга тырышырга кирәк”, ди .[2-№3(26) март,2015 ел] Безнең район күпмилләтле. Анда татар, рус, мари , удмурт халкы дус-тату гомер кичерә. Татар янына бер генә башка милләт кешесе килеп басса да татарлар русча сөйләшүгә күчә. Марилар үз телләреннән

оялмый, үз милли киемнәрен киеп район үзәгенә җыелышларга да баралар. Үз милләтен әллә кайдан танып, шунда ук үз телендә аралаша башлыйлар. Менә телебезне, милләтебезне саклауга кемнән үрнәк алырга кирәк татар халкына?!“Ак калфак” Бөтендөнья татар хатын-кызлары оешмасы җитәкчесе Кадрия Идрисова сүзләре белән килешәм мин . “Ватаным Татарстан” газетасында ул түбәндәгеләрне яза: “-Телебезне, гореф-гадәтләребезне кайтарырга кирәк, дибез. Һәрвакыт “тел” дип сөйлибез. Ә бит иң элек “кием” дип сөйләргә кирәк. Үзебезнең милли киемнәрне кигән кешенең башка телдә сөйләшәсе килмәс. Без шул рәвешле башка милләт вәкилләрендә үзебезгә карата хөрмәт уята алачакбыз. Әгәр дә үзебез белән горурланып яшибез икән, безгә һәркем сокланачак”.[№3, Атна вакыйгалары,3-9.02.2017/№4]

Туган телебезне саклау өчен күбрәк татарча китап укырга, концерт-спектакльләр карарга, үз телебездә белем бирергә һәм аралашырга кирәк, дип уйлыйм. Без үзебезнең татарлык белән горурланырга тиешбез, татар исемен горур йөрткәндә генә ТЕЛ яшәячәк.

## Нәбирә Гыйматдинованың “«Ак торна каргышы» әсәрендә күтәрелгән әхлак мәсьәләләре.

***Закирова Роза Ахмедовна,***
***Муллагалиева Халидә Миннесаяфовна,***
***Татарстан Республикасы Менделеев муниципаль районының***
***муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе***
***“Гимназия №1”, Менделеев шәһәре.***

Кешелеклелек сыйфатларын тәрбияләү, югары әхлак идеалын тудыру татар әдәбиятында әле борынгы чордан ук төп темаларның берсе саналган. Бу мәсьәлә бүгенге җәмгыять өчен бигрәк тә әһәмиятле. Чөнки бөек тарихы булган мәдәниятле, затлы милләтебез бу сыйфатларын югалта бара. Җәмгыятьнең эчкечелек, наркомания, талау, кеше алдау, фахишәлек кебек чирләре тамырыбызга кадәр үтеп керә башлады. Санап үтелгән проблемаларны безнең буын язучылары да әсәрләрендә яктыртырга, үзләре аңлаганча сәбәпләрен күрсәтергә тырышалар.

Шундый язучыларның берсе – Нәбирә Гыйматдинова. Аның фикеренчә, адәм баласы абынса, бәхетсезлеккә тарыса, сәбәбен беркайчан да үзеннән эзләми. Ул аны заманга яисә үзе дә аңлап җиткермәгән күренешләргә сылтый. Ә дөреслек бик якында, һәм ул без барысына да үзебез гаепле дигән фикердән гыйбарәт...

«Ак торна каргышы»- авторның иң матур һәм фаҗигале әсәрләреннән берсе. Әсәрдә күтәрелгән беренче мәсьәлә - кешеләрнең бер-берсенә битараф мөнәсәбәте. Моны әсәрдә бигрәк тә Сара язмышы аша күрәбез. Сара − гап-гади хатын, андыйлар тормышта җитәрлек. Яшь, көче ташып торган чагында, ул да башкалар кебек үк эшләгән, шатланган-көлгән, хезмәттәшләре белән аралашкан. Ә инде сырхаулап, урын өстенә яткач, аның беркемгә дә кирәге калмаган. Ә бүгенге көндә башкалар ярдәменә мохтаҗ кешеләр азмы?! Сәламәт чагында кеше һаман каядыр чаба, нидер эшли, булганына гына канәгать булмыйча, яңадан-яңа планнар кора. Башкаларда аның гаме юк, бары үзенеке генә җитеш булсын. Һәм бу хыялларның бер мизгелдә чәлпәрәмә килергә мөмкин икәнен бары соңлап аңлый... Нишләп соң бүген һәр кеше үзе өчен генә яши, кая киткән халкыбызга хас ярдәмләшү, бер-берсенә булышу кебек күркәм сыйфатлар? Бүген, кызганычка каршы, әсәрдәге Фәрдәнә һәм Сәрия кебек, эшләгән эшләре өчен зур бәя сорап, авыру кешеләрне җәфалаучы бәндәләр белән дөнья тулган. Аларга, ярдәмгә мохтаҗ кешедән күбрәк акча алып, баш төзәтү юлын чамалау артыграк. Шулай итеп, Н. Гыйматдинова күтәргән тагын бер проблема – эчүчелек.

Эчүчелек - аерым бер кешенең генә түгел, ә тулаем җәмгыятьнең әхлагын бетерүче корал. Моны язучы әсәрдә кат-кат ассызыклый.

Нәкъ менә хатын-кызларның ныклап аракыга үрелә башлавы безне чаң сугар дәрәҗәгә җиткерә. Кайбер хатыннарның ирләреннән дә уздырып аракы чөмерүләренә исең-акылың китәр. Ләкин бу шулкадәр гадәти хәлгә әверелеп бетте ки, хәзер моңа игътибар итүчеләр күренми дә диярлек. Мондый исерек аналар үз халкына нинди балалар табып, тәрбияләп бирәләр соң? Аннан җинаятьчелекнең очы-кырые булмаганга аптырыйбыз...Әлбәттә, һәр нәрсәне

аклардай сәбәпләр табарга мөмкин. Әсәрдә Арысланның әнисе дә, ачынып: “Менә яшәп кара әле, аракысыз сыңар салам да селкетмәгәннәрен үзең дә күрерсең. Бездә ялгыз карчык-корчык пинсә акчасына икенче көнне үк аракы юнәлтә. Аракы – баш, аракы – муен хәзер авылда”[1 с.257],- ди. Арысланның гына тынмас җаны авыл кешеләренең шул дәрәҗәдә үзгәрүен аңлый алмый. Аның моңа күңеле ышанмый. “Юк, юк, егерме ел эчендә авылның бу тикле бәгыре катмас. Болай ук үзгәрмәс Каратай” [1 с.265], - дип ачыргалана ул. Һәм, Габдулла мулла белән берлектә, авылдашларын иманга китерергә тырыша. Ләкин күзләре томаланган кешеләр аны аңлар дәрәҗәдә түгел шул. Аларга яңа мәчет тә, мулланың вәгазе дә кирәкми. Габдулла хәзрәт үзе үк: “Мәчетебезне түгел, иманыбызны савыктырырга иде әүвәлгесе” [1 с.261], - ди. Бу сүзләрне хәзерге заман яшүсмерләренә карата да кулланырга мөмкин.

Автор авылдагы әби - бабаларыбызның гореф-гадәтләрен кире кайтару кирәклеген искәртә, күрше хәлен белмәү хәзерге заманның фаҗигасе икәнен аңлата.

Табигатьнең язылмаган шундый законы бар: кеше тарафыннан кылынган изгелекләр яки усал нияттән башкарылган эшләрнең әҗере шул кешенең үзенә кайта. Үзенә кайтмаса – балаларына, балаларына булмаса – оныкларына. Олылар әйтмешли, каргыш - рәнҗеш адәм баласын җиде буынга чаклы озата бара. Монда сүз кешене рәнҗетү турында гына бармый, болар тереклек, җан ияләре, табигатькә дә карый. Н. Гыйматдинова моны да бик оста сурәтли. Ул табигать белән тыгыз бәйләнештә булмаганда адәм баласының шәфкатьлелек, бер-береңне аңлау, ягымлылык, хөрмәт итү һәм башка шундый сыйфатларны югалта баруын күрсәтмәкче була. “Ак торна каргышы” повестендә пар торнаның берсен аткан өчен җәза бөтен авыл халкына төшә: кинәт чыккан җил-давылдан электр чыбыклары өзелә, калай түбәләр, шиферлар оча, “әйтерсең дөньяны кемдер зур кәйлә белән бәрә-кыйный, изә – вата иде” [1 с.286]. Автор фикеренчә, кылган эш-гамәлләрнең берсе дә эзсез генә узмый, шуңа күрә, нидер эшләгәнче, алдын – артын уйларга кирәк.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтәсе килә: Н.Гыйматдинова күтәргән мәсьәләләр бүгенге көндә дә актуаль. Җәмгыятебезгә көннән-көн ныграк үтеп кергән җинаятьчелек, эчүчелек, битарафлылык, әхлаксызлык һәркемне борчый. Тирә – юнебездә Арыслан һәм Сара кебек, башкалар агымына иярмичә, үз кыйбласын, үз юнәлешен табып, кешеләргә риясыз яхшылык кылырга атлыгып торучы, әйләнә-тирәгә карата игътибарлы, эчкерсез, саф җанлы кешеләр булганда, әле киләчәккә өмет бар. Һәм халкыбызның һәрвакыт көчле, югары әхлаклы, зыялы булып калуына чын күңелдән ышанып каласы килә!

Әдәбият.

1. Гыйматдинова Н. М. Ак торна каргышы.- Казан: Татар китабы нәшрияты, 1997. -246-286 б.

## **“…Без тумыштан Туган телгә гашыйк, Туган җиргә гашыйк күптәннән”**

***Зәйнәгова Солтания Газизҗан кызы***
***Түбән Кама шәһәренең”Нефть химиясе һәм нефть эшкәртү техникумының татар теле һәм әдәбияты укытучысы.***

Туган ил, Ана ,икмәк –
Бөекләрнең бөеге,
Әнә шуларга сыенып,
Без яшибез сөенеп .

Табигать – кеше тәрбияләүнең бай чыганагы. Кеше иген игә, яшелчә,җиләк-җимешүстерә,терлек,кош-корт үрчетә.Үзенә яшәү өчен уңайлы шартлар тудыра.Тулысынча табигатьтән файдалана.Табигать-ул безне яшәтүче дә,терелтүче дә,дөньяны танырга өйрәтүче дә.Табигать матурлыгы-ул безнең матурлык.Табигатькә булган мәхәббәт тә,телгә,илгә , эти-әнисенә, әби-бабаларына булган мәхәббәт кебек , кадерле булырга тиеш.

Табигать ул үзен яклый алмый,
Үчтә ала алмый кешедән.

Ул бары тик рәнҗи генә ала,

Куркыйк шушы рәнҗеш төшүдән.

ФәнисЯруллин.

Кешенең шәхес буларак формалашуында әхлак тәрбиясе төп һәм иң әһәмиятле урынны били.

Гомумән алганда тәрбияләү эшендә халык авыз иҗатын куллану иң кулай дип табам.Әкиятләрдә халыкның педагогик культурасы,милли үзаң,әдәп-әхлагы,тәвәкәллеге,эчкерсезлеге тупланган.Һәрберсенең тәрбияви максаты бар,ул билгеле бер әхлакый чынбарлыкны алга сөрә.Анда гаделлек һәм зирәклек җиңә,ялкаулар,рәхимсезләр,әдәпсезләр җиңелә.Тәрбия эше буыннан буынга,дөньяга кеше барлыкка килгәннән алып,бүгенге көнгә кадәр актуаль проблема булып тора.

Ә менә яшьүсмерләргә килгәндә нишләргә?Аларның заманча яшиселәре килә.Аларга әкият кирәкми.Китап укый торганнары да бик аз.Уку йортларында укытучы үзе белгәнен өйрәтә,күрсәтә.

Тәрбия белән дәрес саен шөгыльләнәбез.Телебезне саклау,китапларны пропагандалау беләнберрәттән мәгърифәтчеләребезнең нәсыйхәтләрен җиткерү,җырларны өйрәтү,шигырь сөйләтү,биюләр өйрәтү.Бигрәктә студентлар сәхнә яраталар.Аларга җитди хәрәкәтле,нәтиҗәле,бигрәктә төрле уен рәвешендәге алымнар ошый.Җыр,бию алар өчен уңайлы.Парта арасында утырасы гына,язасы гына булмасын.Безгә бит уку алдынгылары түгел,ә дәрестә утыра алмый,тыңламый,хәрәкәтчән ләкинхезмәткә сәләтле балалар килә.Шуңа аларны эш,яки берәр мисал китереп тәрбияви минутлар үткәреп укытасың.Монда инде үзеңнең барлык сәләтләреңне кушып берәр әсәрдән өзек сөйләп,җырдан өзек җырлап та күрсәтәсең.Кайсы-берсе әсәрнең исемен язып ала,җырга кушылучылар да була,анысы авыл балалары инде.

Авыл балалары.Безнең кадерлеләребез!Безнең таянычыбыз!Безнең милләтебезнең әлегә яктыртып торган нурларыбыз!Алар булмаса татар теле укытучылары нишләр иде микән?Без барыбызда беләбез,телне аралашмыйча гына өйрәнеп булмаганын.Менә шуңа безгә кирәк инде ул татар балалары-авыл

балалары.Ә моның өчен безгә татар авыллары,андагы китапханәләрне,мәдәният йортларын саклау зарур.Ничә генә бала булсада-мәктәп булырга тиеш Һәм шулай ук китапханәсе,клубы.

Әдәбият укытучысының олы бурычы – гүзәл холыклы кеше тәрбияләү. Чөнки аның фәне шундый. Әдәбият укучының аңына гына тәэсир итеп калмый, ул аның хисләренә дә йогынты ясый. Әдәбият дәресләрендә бала

һәр күренешне җаны – тәне белән тоя, сиземли белергә өйрәтелә.

Әдәбият курсы катлаулы. Андагы тәрбияви мөмкинлекләр күп планлы, ләкин бик тә эчкә яшеренгән. Анда бу герой яхшы, шундый булырга кирәк, ә бу герой начар эшләгән, андый булырга ярамый дип укытуның файдасы юк. Бу акыл сатуга кайтып кала.

Әдәбият дәресләрен укытуда түбәндәге бурыч һәм максатларны алга куярга кирәк:

Татар халкының милләт буларак яшәешен, рухи сафлыгын саклау һәм үстерү;

- Татар халкының теле, тарихы, йолалары, ислам дине аша милли горурлык хисе тәрбияләү;

- Укучыларда гомумкешелек һәм татар милләтенең уңай сыйфатларын тәрбияләү;

Халык тудырган йөзәрләгән акыл уяләренең акыллы, тапкыр, зирәк фикерләрен өйрәнгәннән һәм анализлаганнан соң, шундый нәтиҗәгә киләсең: илдәге аяныч хәлдә яшь буында кешелек сыйфатларын саклап калуда бердәнбер юл, таяну ноктасы - ул да булса әхлак тәрбиясе бирү. Аны бала туганнан алып, аның гомере дәвамында алып барганда гына халык нинди генә афәткә юлыкса да, яшәвеннән туктамаячак.

Дөрес, җәмгыятьнең бөтен чирен дә әхлак тәрбиясе аша гына дәвалап бетереп булмый. Ләкин югары әхлаклы шәхесләр генә аны дәвалау юлларын табуга сәләтле икәнлегенә чын күңелемнән ышанам.

Хәзерге вакытта китап укулар укытучы тәкъдиме белән генә укыла дип әйтсәм, ялгыш булмас.Матур әдәбият укучылар нык кимеде.Халык

кыйбатсына.Ләкин укымый тормый.Күчермәләр ясап укыйлар.Телне саклап калу өчен нинди эшләр башкарырга кирәк дигәндә,мин Искәндәр Гыйләҗев һәм Рүзәл Юсупов фикерләренә кушыламдип әйтәсем килә.Шуларгакушылып кыскача :

-татар авылларын сакларга;

-һәр уку йортында татар телендәге газета-журналларга язылу;

-бердәм программалар, дәреслекләр булдыру;

-тәрбия эшләренә ике телдә алып баручыларны әзерләү;

- уку йортларына даими эшкә сәнгать җитәкчеләрен булдыру;

- ике телдә сөйләшүчеләргә өстенлек бирүне булдырырга;

- уку йортын тәмамлаган яшьләргә (татар теле укытучыларына) максатлы юлламалар бирүне булдырырга;

Кулланылган әдәбият


1.Богуславская И.Шәхес тәрбияләү- заман таләбе.”Мәгариф” журналы, № 7,2003, 8 нче бит.

2.Җәләлиев Ш.Татар халык педагогикасы.-Казан:Мәгариф, 2007.

3.Юсупов Рүзәл –Татар телен саклау ,өйрәнү һәм үстерү турында.

4.Гыйләҗев Искәндәр – “ Безнең мирас” № 7.


## Галимҗан Гыйльманов иҗаты аша укучыларга әхлакый һәм экологик тәрбия бирү


***Зәйнуллина Э.Т., татар теле һәм әдәбияты укытучысы,***
***Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының***
***«10нчы урта гомуми белем бирү муниципаль бюджет гомуми***
***белем бирү учреждениесе.***


“Балаларыгызны үзегезнең заманыгыздан башка заман өчен укытыгыз, чөнки алар сезнең заманыгыздан башка бер заманда яшәү өчен дөньяга килгәннәр”. Мәшһүр галимебез Р.Фәхреддиннең әлеге сүзләре мөгаллимнәр алдына зур таләпләр куя. Киләчәк укучысын нинди әсәрләр аша, нинди

юнәлештә  тәрбияләргә, Кол Галиләрдән килүче әдәп-әхлак, кешелеклелек, иманлылык төшенчәләренең туган җиргә, туган телебезгә сак караш белән үрелеп китүен күңелләренә ничек сеңдерергә? Бүгенге көндә үзенең үзенчәлекле, хыял һәм чынбарлык чигендәге кискен интригага, серле вакыйгаларга корылган әсәрләре белән шактый киң катлам укучыга танылып өлгергән Галимҗан Гыйльманов иҗаты бу яктан кызыклы. Авторның "Оча торган кешеләр" әсәрендә күтәрелгән әхлакый проблемалар туган җир, табигатебезне саклау өчен көрәш проблемалары белән кисешеп, шактый үтемле тәрбия чарасы була ала.

Галимҗан Гыйльмановның тормыш юлы һәм иҗат эшчәнлеге шактый бай һәм киңкырлы. Ул фән һәм тәнкыйть, мөгаллимлек һәм мөһәррирлек эшен дә, балалар һәм зурлар әдәбиятын да, халык арасында татар әдәбиятын, тарихи мирасын пропагандалау, тарату, хөкүмәт һәм җәмәгатьчелек эшен дә колачлый.

Гомумтөрки әдәбият вәкиле булган И. Баласагунлыдан башлап бүгенге көн язучы-әдипләренә кадәр кеше бәхете мәсьләсен күтәрәләр,  әхлаклы, кешелекле мөнәсәбәтләр генә бәхетле тормышка нигез салалар дигән фикергә киләләр. Г.Гыйльмановның фикере исә алгарак китә: кешегә бәхетле булу өчен үз-үзе һәм табигать белән гармониядә яшәү дә кирәк. Авторның "Оча торган кешеләр" әсәрендә Сәүбәннең уйланулары аша әйтелгән "Туган җирен яраткан кеше генә бөтен дөньяны ярата ала. Туган җир бер генә, чөнки гомер дә бер генә. Иң ярлы кеше — туган җирсез кеше. Читтә йөргән кеше — бер җирдә дә яшәми. Туган җирен яраткан кеше генә хатын-кызны чын-чынлап сөя, ярата ала. Ватан — мәхәббәт кенә түгел, Ватан ул — язмыш! Ә язмыш — җаваплылык дигән сүз!"[1:6] дигән сүзләре моны раслый. Шушы уйланулар аша әсәрнең төп проблемасы күтәрелә: кеше һәм туган җир бердәм, туган җиренә, идеалларына хыянәт иткән кеше бәхетле була алмый.

Әсәрдә бүгенге көн проблемалары да күтәрелә: кешенең әхлагы бозылу: "Иң элек ул урам башындагы иясез ватык арбага игътибар итте. Аның бер тәгәрмәчен кемдер салдырып алып киткән. Алдагы тәртәләре дә юкка чыккан. Гарипләнеп бер якка янтайган бу арбада Сәүбән үзен таныгандай итте". Изге

төшенчәләрнең, иманлылыкның бетә баруы: “Аерым хуҗалык йортлары матурайган, әмма авыл үзе бетәшкән — урамнары чүп-чар белән тулган, елга-инеш буйларына тирес өйгәннәр...Аның каравы авылда ике мәчет манарасы калыккан. “Мәчетләр салып кую гына иманлылык билгесе булса, эшләр бер дә әйбәт түгел”,— дип уйлап алды ул”. Табигатебезнең пычрануы: “Чишмә тирә-ягындагы сазлык киңәйгән, инеш, киресенчә, тарайган, янындагы таллык сирәкләнгән, аның тирәсендәге чирәмлек пычранган. Агышы шул ук, ярсып-ярсып, тулгак тоткан кебек ага. Улагы да шул, әмма шактый тузган, кителеп, яньчелеп беткән”. Шулай итеп әхлакый пычрану экологик һәлакәткә якынаю белән үрелеп бара, автор аларның аерылгысыз булуына басым ясый. Менә шушыны укучы күңеленә җиткерү, яшәешебез хакына аңга килергә, иманга кайтырга кирәклеген аңлату эше без татар теле һәм әдәбияты укытучыларының кешелек алдында торган югары миссияседер, минемчә.

Әсәргә аерым үзенчәлек биреп торучы алым ул – авторның фәлсәфи уйланулары, турыдан-туры укучыга мөрәҗәгать итеп яки геройлары аша әйтелгән фикерләре. Мәгърифәтчелек әдәбиятына хас шушы юл белән автор яшәү мәгънәсе, мәхәббәт һәм үз-үзең алдындагы җаваплылык, туган җиргә, кешеләргә мөнәсәбәт, кеше бәхете, һөнәр сайлау турында шактый уйландырырлык, яшь укучыга киләчәккә юллама кебек булган фикерләрен әсәр буенча сибеп бара. Һәр фикер сине тормышың, рухи яшәешкә, табигатькә мөнәсәбәтең турында уйланырга мәҗбүр итә. Мәсәлән, бәхет турында авторның фикерләре болайрак: “кеше үзе теләгән кадәр генә бәхетле була”, “Бәхет эзләүче бәхетледән дә бәхетлерәк”...[1:12] Туган җиргә мөнәсәбәт хакындагы фикерләре белән дә бәхәсләшә-бәхәсләшә килешәсең: “...кеше үзенең туган җирен, туган нигезен, бала чагын сагынмый башлый икән, дөресрәге, аны туган җире, туган нигезе, бала чагы сагындырмый башлый икән, димәк, аңа нидер булган, ул үзенең рухи орбитасыннан ычкынган, бала чагыннан ук килгән гомер юлыннан читкә тайпылган, кыйбласын югалткан, Иблис коткысына бирелгән”. Яисә менә бу фикерләр кемне генә уятып җибәрмәс икән: “Эчтән ирекле булмаган кеше тыштан ирекле була алмый”, “Тормышта иң хәтәре —

тереләй үлү”. Әйләнә-тирәбездәге битарафлык шуның билгесе түгелме? Эчтә утырган куркуыбыз аркасында милләт буларак югалу куркынычы алдына килеп басмадыкмы инде?

“Гомернең озынлыгы еллар белән түгел, кылган изгелекләр белән үлчәнә”, “Кеше — шаккатыргыч дәрәҗәдә сәер зат. Байлыгы, малы китсә, җаны сызып борчыла, ә мәгънәсез үткән көннәре хакында уйларга вакыт тапмый”, “Кеше үзенең кемлеген белмәсә, каян килүен, кая баруын белмәсә, аңа яшәү кыен, бик кыен” [1:123]. “Башкаларга ияргән кешеләр күңел тоемнарын бик тиз югалталар” [1:90] Азмы арабызда үзенең телен, милләтен, нәселен белмәгән маңкортлар?

Г.Гыйлмановның тагын бер фикерен мин укучыларыма еш кабатлыйм: “Кеше үзгәрмәскә мөмкин, әмма ул яхшырак була ала. Кеше үзен күпмегә бәяли, ул шулкадәр тора. Кеше үзен яратырга мәҗбүр итә алмый, әмма хөрмәтләргә мәҗбүр итә ала” [1:146]

Әдәбият.


1. Гыйльманов Г. Оча торган кешеләр: роман, повестьлар, бәяннар / Г.Гыйльманов. - Казан: Татар.кит.нәшр., 2007. - 463б.

2. Заһидуллина Д.Ф. Татар әдәбияты: Теория. Тарих. / Д.Ф.Заһидуллина, Ә.М.Закирҗанов, Т.Ш.Гыйләҗев. – Казан: Мәгариф, 2004. – 247 б


## Әдәбият дәресләрендә укучыларга экологик һәм әхлак тәрбиясе бирү


***Зиннәтова ЛилияМаксутовна***
***Алабуга шәһәре 10 нчы урта мәктәбенең***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы***


К.Насыйри: “Тәрбия – һәр нәрсәнең ачкычы,аның белән һәр нәрсәне хәл итеп була, ул – кешене кеше итүдә иң дөрес юл”, - дип язган. Яшь буында гуманлылык,патриотизм, табигатьне ярату кебек мәңгелек рухи-әхлакый кыйммәтләр тәрбияләү зур әһәмияткә ия.

Кеше гомере бue табигать белән тыгыз элемтәдә яши, шуңа да ул экологик тотрыклылыкны саклап калырга бурычлы. XXI гасыр балаларына табигать байлыкларының чиксез түгел икәнен аңлату, аларның дөньяга караш даирәләрен киңәйтү, табигатьне сакларга, мәрхәмәтле, игътибарлы булырга өйрәтү, туган җиребезне ярату, аның белән горурлану хисе тәрбияләү - бүгенге көн укытучылары алдына килеп баскан мөһим бурычларның берсе. Аны тормышка ашыру өчен, нәтиҗәле алымнар һәм ышандырырлык фактлар кулланып, эзлекле эш алып бару таләп ителә.

Мәсәлән, экологик проблемаларны татар әдәбияты дәресләрендә күтәрү уңай нәтиҗәләргә китерә, чөнки әдәби әсәрләр аша табигатьне танып белү укучы күңеленә тирән үтеп керү мөмкинлеге бирә. Ләкин монда укучыларга экологик белем һәм тәрбия белән бергә милли, әхлакый тәрбия бирүнең дә үрелеп баруы мөһим шарт булып тора. Бу эшне укучыларның яшь үзенчәлекләрен искә алып, экологик проблемаларның көн саен очрый торганыннан башлау кирәк. Мәсәлән, башлангыч сыйныф балалары белән уку дәресләрендә интернет картиналар ярдәмендә көзге, кышкы, язгы, җәйге урманга сәяхәт итү, андагы хайваннар, кошларның тормышы, үзгәреше турында сөйләшү укучыларда табигать белән кызыксыну уята. Без укучылар белән “Син дә үрнәк ал, әле” һәм “Бу ялгышны кабатлама” дигән папкалар тутырабыз, ягъни дүрт ел буе әлеге папкаларга табигатьтә үзеңне ничек тотарга кирәклеге турындагы рәсемнәр, шигырьләр, мәкальләр, сынамышлар кечкенә күләмле хикәя, мәкаләләр җыябыз. Табигать турында хикәя, яки шигырь укыгач, ситуатив күнегүләр эшлибез. Бу очракта, халык авыз иҗатындагы үгет-нәсыйхәтләргә мөрәҗәгать итәргә тырышам. Алар шушы үгет-нәсыйхәтләрдән чыгып, ситуатив күнегүләр төзиләр, проблеманы табып, аны чишү юлларын эзлиләр. Әлеге биремнәр укучыларда мәрхәмәтлелек тәрбияли, аларны табигатьнең матурлыгын тоя һәм аны саклый белергә өйрәтә, экологияне сакларга кирәклегенә төшендерә.

“Табигать, мин синең дустың” папкасы өлкән сыйныф укучыларының үсемлек, хайваннар дөньясы, табигать һәм кеше мөнәсәбәтләре турында үзләре

язган табышмаклар, шигырьләр, халкыбызның еллар буе табигатьне өйрәнү нәтиҗәсендә туган үгет-нәсыйхәтләре белән дә (“Хайваннарны җәберләгән рәхәт күрмәс”, “Яралы кошка таш атмыйлар”, “Кош йомыркаларын ватма, күз яшең түгәрсең”, “Яшь агачны сындырма, яшь гомерең өзелер” “Кошларны рәнҗетмә, каргарлар”, “Кошларга таш атма, күзең сукыраер”, “Хайваннарны кыерсытма, үзеңә килер”  ) тулыландырыла. Шулай ук, укучылар агач исемнәренә салынган башка мәгънәне табу биремен дә кызыксынып үти. Мәсәлән: каен агачы матур әдәбиятта сагынуны белдерә, кызларның сылулыгы, сагыш, аерылу һ.б., наратлар - төз гәүдә, имәннәр – ныклык. Алар арасындагы уртаклыкны эзләгәндә, укучыларның тел байлыгы да, әдәби әсәрләрне һәм табигать байлыкларын белүләре дә таләп ителә.  Тел чарлау чарасы буларак, һәр дәрестә диярлек табигать турында укучылар үзләре әзерләп килгән мәгълүматлар белән таныштыра (ел буена ... урманнар юкка чыга,  кошларның .....төре югалган, үсемлекләр ... кызыл китапка кертелгән, Татарстан урманнарында элек ... дигән үсемлекләр бик күп булган һ.б.) Бу төр мәгълүмат туплау балаларны табигатьнең бүгенге хәле турында уйланырга мәҗбүр итә, проблемаларны ничек хәл итү чараларын эзләргә этәрә.

Өлкән сыйныфларга тәкъдим ителгән Г.Бәшировның “Туган ягым – яшел бишек”, “Җидегән чишмә”, М.Мәһдиевнең “Торналар төшкән җирдә”, Р.Мөхәммәдиевнең “Ак кыялар турында хыял”, М.Әмирнең “Агыйдел” һәм башка шундый әсәрләрне китерергә була. М. Кәрим "Озын, озак балачак", Г. Сабитов "Ярсулы яз", Г. Бәширов "Туган ягым – яшел бишек", Әхсән Баянов "Сәяхәтнамә" һ. б. әсәрләрендә кеше һәм табигать мөнәсәбәтләре, табигатьне саклау мәсьәләләре аеруча кискен куелган. Әдипләр бу әсәрләре белән борынгыдан килгән гореф-гадәтләргә ихтирам тәрбияләргә, табигый байлыкларга сакчыл булырга, аларның кадерен белергә, өлкәннәргә хөрмәт белән карарга чакыралар, шатлык-куанычларны, кешенең матурлыгын, кайгы-хәсрәтне, олы фаҗигаләрнең тирәнлеген табигать аша ачып салалар. "Кешенең борынгыдан килгән гуманлы карашларына, гореф-гадәтләренә, еллар буена сыналып килгән тормыш тәҗрибәсенә хилаф килердәй, аны рухи, әхлакый

яктан рәнжетердәй башабаштаклык ахыр чиктә табигатькә дә зарар булып төшә" дип язган халык язучысы Г. Бәширов. Димәк, яшь буында табигатькә сакчыл караш тәрбияләүне кешедә гасырлар буе тупланган, аңа хезмәт аша сеңгән гомумкешелек әхлак сыйфатларын, тирә-юньгә кешенең элеккеге мөнәсәбәтен эзләү белән тыгыз бәйләргә кирәк.

Язучыларыбызның, шагыйрьләребезнең тирән эчтәлекле әсәрләре аша Туган туфракка, табигатькә мәхәббәт хисләрен уяту, аны кадерләп саклау кирәклегенә төшендерү балаларның күңеленә җиткерү, сеңдерү – укытучының изге бурычы. Шуңа да, табигатьнең матурлыгын күрергә өйрәтү, аңа сакчыл карашлы гуманлы шәхес тәрбияләү һәр дәрестә диярлек тәрбияви максат итеп билгеләнә.

Кулланылган әдәбият исемлеге


1.Заһидуллина Д.Ф. Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. - Казан: Мәгариф,2000.

2. Халикова Т. Сәләтле бала – ил байлыгы. “Мәгариф” журналы, № 1, 2012, 19 нчы бит.


## Татар теле дәресләрендә экологик белем һәм тәрбия бирү.


***Зиязиева Рәйлә Шәрипҗан кызы***
***Минзәлә шәһәре “1 нче санлы***
***гомуми белем бирү мәктәбе”***


Кешелекнең табигать белән бәйләнеше – хәзерге заманның актуаль мәсьәләләреннән санала. Промышленностьнең үсүе табигатьнең тигезлеген югалтуга китерде: сулыкларның, һава, җир өслегенең пычрануы кеше сәламәтлегенә куркыныч яный, бигрәк тә балаларга. Күп кешеләрдә экологик белемнәр һәм экологик культура җитеп бетми. Һичшиксез бу укыту-тәрбия эшенең җитешле дәрәҗәдә булмавы илебез халкына табигатькә карата дөрес караш формалаштыра белмәү нәтиҗәсе.

Экологик тәрбия бирүнең күп төрле формалары бар: факультатив, түгәрәк, экологик лагерьлар, әлбәттә, традицион форма буларак, татар теле һәм

әдәбият дәресләре. Табигать белән аралашу хәзерге заман кешесенең иң зур мохтаҗлыгы булып санала.. Шуңа күрә, дәресләрдә экологик материал куллану укытучының мөһим мәсьәләсе булып тора.

Мәсәлән, 5 нче сыйныф татар әдәбияты дәреслегендәге (автор Ә.Р.Мотыйгуллина, Р.Г.Ханнанова) эчтәлеккә игътибар итсәк, экологик тәрбия бирү аеруча яктыртыла,аерым бер бүлек булып бара . Мәсәлән,Гадел Кутуйның“Яз җиткәч”, Фәтих Кәримнең “Кыр казы”, Равил Фәйзуллин “Табигать кочагында”,Габделхәй Сабитовның “Чәчәк нигә боекты?” һ.б. әсәрләр. Укучыларда экология проблемасы турында белү генә түгел, аны чишү юлларын эзләү теләге уята.

Татар теле дәресләрендә экология сүзенең мәгънәсен ачыклыйбыз, фән буларак экология турында сүз алып барабыз. Бүгенге көндә кешенең сәламәтлеге начараюын да, психикасы какшавын да – һәммәсен экологиягә бәйләп карыйбыз.. Укучылар белән “Кеше һәм табигать” темасы буенча мәкаль-әйтемнәр җыябыз, мәгънәләрен аңлатабыз,рәсем кокурслары уздырабыз. Иҗади характердагы язма эшләр эшлибез. Ул үсемлек, хайваннар дөньясы турында табышмаклар уйлап табу, “Табигать”, “Минем туган җирем”, “Ел фасыллары”, “Туган ягым”, “Сулыклар”,”Чишмәләр” темасына караган кроссвордлар төзү, табигать күренешен телдән сурәтләү, “Истәлекле урыннар”, “Кышкы сихри урманда”, “Табигатьнең һәр мизгеле ямьле”, “Урман яме” исемле сочинениеләр язу. Төрле фотоконкурслар оештырабыз.Мондый иҗади эшләр балаларны бик кызыксындыра, биремнәрне зур теләк белән башкаралар.

Туган телне укытуда җирле материалларның бетергесез тәрбияви әһәмиятен ия.

Экологик тәрбия бирүдә “Лексика” темасы бик отышлы. 5нче сыйныфта шундый биремнәр тәкъдим ителә: рәсемнәргә карап, нинди тематик төркемнәргә бүлеп була (каен, акчәчәк, канәфер, имән, чаган, дәлия, умырзая), “Күпмәгънәле сүзләр” темасын үткәндә “тоту”, “салу”, “каты” сүзләренең күптөрле мәгънәдә кулланыуын тикшерү, кеше тормышы һәм табигать белән бәйләп карау (кар тоту, кулдан тоту, балык тоту, юл тоту; йорт салу, су салу,

күз салу, хәтергә салу, суга салу; каты агач, каты су, каты кул, каты суык, каты буран, каты күз, һ.б.). Сүз төзелешен аңлатканда: төркемләп бирелгән сүзләр бер үк тамырдан ясалганмы, тамырдаш сүзләрне күрсәтегез кебек биремнәр үтиләр. “ Агачның чәчәген өзәргә ярамый”, “Учак – урманның дошманы” дигән темага диалог-аңлатмалар төзү, “Кошларны рәнҗетмә, каргарлар”, “Кошларга таш атма, күзең сукыраер”, “Хайваннарны кыерсытма, үзеңә килер” үгет-нәсыйхәтләрен ничек аңлыйсыз; тыңлагыз һәм бәйләнешле текстка әйләндерегез, мәсәлән:

- Кара, нинди матур күбәләк тоттым!

- Матур икән шул. Тик беләсеңме нәрсә, Алсу, җибәр син аны. Рәхәтләнеп очып йөрсен.

- Дөрес әйтәсең: очсын. Аның болай да гомере кыска.

Тыңлагыз, төп мәгънәсен аңлатыгыз:

- Марат, нигә син кошларны тотасың?

- Мин аларның сайраганнарын яратам.

- Ә нигә алар сайрамыйлар соң?

- Белмим. Урманда алар сайрыйлар, ә миннән нигәдер оялалар. Мондый биремнәр укучыларда мәрхәмәтле караш, табигатьнең матурлыгын тоя һәм аны саклый белү, тирә -якның ямен югалтмаска, тагын да матурайта, үстерә төшәргә, моннан чыгып экологияне сакларга кирәклеген төшендерә.

Әдәбият дәресләрендә “Салават күпере”журналында басылып чыга торган мәкаләләрне укып фикер алышабыз.Шулай ук, балалар үзләренең мәкальләрен язып,журнал битләрендә бастыралар.

Экологик тәрбия бирүдә сыйныфтан тыш эшләрнең роле дә бик зур. Мәктәптә оештырылган чараларда да укучыларыбыз актив катнаша. Мәсәлән, экопатруль акциясендә катнашып, мәктәп укучылары Республика конкурсында җиңү яулап, проектор һәм электрон тактаэкга лаеклы булдылар.

Яз җитүгә,укучыларыбыз тирә-як табигатебезне: паркларда, су буйларында санитар рейдлар оештыралар.

Балалар җәйге аяз көндә нурланып кояш чыгуын, хуш исле аллы-гөлле чәчәкләр үсүен, матур-матур кошлар сайравын, язын гөрләвекләр агуын күреп олы шатлык хисе кичерәләр. Без, укытучылар, табигатьнең шундый гүзәллеген кечкенә чактан ук күрергә, сөенеп яшәргә өйрәтергә тиешбез.

Табигать-анабыз безне туендыручы, яшәргә көч-дәрт бирүче дә. Кеше нинди генә катлаулы машиналар уйлап чыгармасын, барыбер, туу, тереклек итү өчен җир, су, һава, кояш кирәк.

## Татар әдәбияты дәресләрендә экологик тәрбия.

***Ибрагимова Венера Әгъраф кызы***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы***
***Әгерҗе шәһәре 2 нче урта мәктәбе.***

Кеше гомере буе табигать белән тыгыз элемтәдә яши. Бүген кеше табигатькә бәйле дип әйтү генә дөрес булмас иде,чөнки табигатьнең язмышын кеше дә хәл итә, ул экологик тотрыклылыкны саклап калырга бурычлы .

Экологик белем һәм культураның түбән булуы, планетадагы катастрофаларның нәтиҗәләрен аңламау һәм күз алдына китерә белмәү – табигатьне саклау проблемаларына җавапсыз карашның иң беренче сәбәбе. Шуңа күрә бу өлкәдә эзлекле укыту системасын булдыру, экологик белем һәм тәрбия бирү мөһим мәсьәләгә әйләнде.

Мәктәп һәм экологик культура – бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә булган төшенчәләр. Укытучылар алдында укучыларга экологик белем бирү: укучыларның дөньяга караш даирәләрен киңәйтү, аларны табигатьне сакларга, аңа мәрхәмәтле, игътибарлы булырга өйрәтү, туган җиребезне ярату, аның белән горурлана белү хисе тәрбияләү - иң төп максатларның берсе.

Татар теле һәм әдәбияты дәреслекләре экологик темага язылган бөтен әдәбиятны колачлый алмый, әлбәттә. Ләкин ул шактый күләмдәге әсәрләр белән таныштыра, экологик темаларга мөрәҗәгать итү алшартларын, аларның үзенчәлекләрен билгели.

Һәр сыйныфның әдәбият дәреслегендә халык авыз иҗатының нинди дә булса бер жанрына урын бирелә. Халыкның тормыш тәҗрибәсе һәм табигатьне өйрәнү нәтиҗәсендә туган кыска, ләкин тирән мәгънәле өйрәтүләре, тәрбия алымнары бик гыйбрәтле. Әлеге өйрәтүләр татар халкының мәкаль һәм әйтемнәрендә аеруча күп тупланган һәм тирән мәгънәгә ия.

Дәресләремдә табигатьнең матурлыгын сурәтләгән, байлыгын саклап калу фикере яктыртылган төрле өстәмә материаллар сайлап алам. Дәресләрдә төрле мәкаль-әйтемнәр, табышмаклар, төрле язма эшләр файдаланам. Мондый иҗади эшләр балаларны бик кызыксындыра, биремнәрне зур теләк белән башкаралар.

Табигать куренешләрен тасвирлаган картиналар өстендә эш, газета-журнал материаллары- барысы да экологик тәрбия бирүгә ярдәм итә.

Кулланылган әдәбият:

1.Заһидуллина Д.Ф. Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2000.

2.Низамов А.М. Милли мәктәп тәрбия нигезләре.- Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2005.

3.Сәхипова Р.Ә. Халык педагогикасы нигезендә укыту һәм тәрбия бирү. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2005

4.Җәләлиев Ш.Ш. Татар халык педагогикасы. –Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2000.

5. В.Х. Хаков. Татар әдәби теле тарихы. – Казан, КДУ нәшрияты, 1993.

## Экологические проблемы языка в татарской медицинской терминологии

*Ильдарханова Флюса Мухаматхазиевна,*
*преподаватель татарского языка*
*ГАПОУ «Мензелинское медицинское училище»*

Сегодня проблема экологии волнует всех и каждого. Речь идет о катастрофическом состоянии природной среды обитания человека, о загрязнении воды и воздуха, рек и морей, лесов и полей. Академик Д.С.Лихачев расширил понятие экологии, поставив проблему экологии духовной культуры.

Невероятно, но язык, как животные, растения, человек, – это тоже элемент экосистемы. Бесспорно, существует и проблема экологии языка.

Экология языка (лингвоэкология, эколингвистика) — это наука, занимающаяся изучением факторов, негативно влияющих на развитие и использование языка, и изысканием путей и способов обогащения языка и совершенствования практики речевого общения. Экология языка, по идее, должна лежать в основе так называемой языковой политики государства, прежде всего в сферах образования, юриспруденции, переговорных процессов, делопроизводства и, конечно, в деятельности средних медицинских работников и врачей.

Ценность и востребованность средних медицинских работников, врачей на современном рынке труда в Республике Татарстан во многом зависит и от наличия у них грамотной устной и письменной татарской речи, умения общаться, воздействовать на других людей посредством слова. Ведь ещё Вересаев говорил: «Врач может обладать огромным распознавательным талантом, уметь улавливать самые тонкие детали своих назначений, но все это останется бесплодным, если у него нет способности покорять и подчинять себе душу больного».

Нарушение языковых норм татарского языка, речевые ошибки даже очень авторитетного в своей области специалиста субъективно снижают в сознании пациентов или родственников уровень достоверности излагаемой им информации. Интерес к медицинской терминологии современного татарского литературного языка вызван в первую очередь потребностями практики. Учитывая, что слово в профессиональной медицинской деятельности играет не последнюю роль, нужны специалисты, владеющие двумя государственными языками.

Татарская медицинская терминология - часть лексики татарского литературного языка. Она непосредственно связана с историей татарского народа, с развитием его материальной культуры. Лексика, относящаяся к данной области, переходя из века в век, пополнялась и обогащалась. Не

случайно, лексика, выражающая понятия народной медицины отличается самыми распространенными, исконными моделями словообразования татарского языка. Поэтому эти модели могут послужить как образованию современных научных медицинских терминов татарского языка, так и образованию терминологии других отраслей. Выявление наиболее древних, исконных образцов словообразования является одной из проблем национальной терминологии, которая требует особого внимания. Ее специфической чертой следует признать особую выраженность в ней общей интернациональной медицинской терминологии, что диктуется потребностями самой науки.

Татарскую медицинскую терминологию к настоящему времени можно считать сформировавшейся, но складывалась она в значительной мере стихийно. Ей присущи с точки зрения идеальной терминологии такие недостатки, как наличие многозначных терминов и терминоэлементов, наличие параллельных конструкций, синонимия, вариативность, наличие громоздких терминов-описаний, наличие неточных и даже ложноориентирующих терминов, неразработанность терминологий новых разделов медицины приводит к новым искажениям, вследствии чего появляются разные переводы одного и того же термина.

Достаточное количество материалов, источников, позволяющих выявить максимальное число татарских медицинских терминов, дает возможность провести на этой основе интересный, детальный анализ данной терминосистемы.

Большинство медицинских терминов представляет собой производные слова, образованные от других производящих основ посредством различных способов словообразования: использование приставок и суффиксов, осново- и словосложение. Значение таких производных слов обычно определяется семантикой их составных частей, которые принято называть терминоэлементами.

Экологические проблемы языка в татарской медицинской терминологии и на сегодняшний день остается актуальной, так как, во-первых, сама татарская

медицинская терминология очень сложна и многогранна, во-вторых, на дисциплину «Татарский язык» в медицинском училище отводится всего лишь 40 часов, где параллельно изучаются ещё и другие темы. А для русскоязычных студентов это катастрофически мало. Знание татарской медицинской терминологии требует от студентов сознательных усилий и труда.

В современный период, когда повышается статус татарского языка как государственного, настало время создания научной медицинской терминологии, серьезных исследований по разработке терминов новых направлений медицины, фармацевтики, инструментариев, основываясь на богатых традициях терминообразования татарского языка. Растет спрос на специалистов, профессиональная культура которых предполагает не только наличие глубоких специальных знаний, но и высокую языковую и общекультурную подготовку.


Интернет-ресурсы:

1 http://nsportal.ru/ap/library/ "Лингвоэкология: как спасти родной язык"

2 http://www.dissercat.com/ Медицинская терминология в татарском языке

3 http://cheloveknauka.com/ Медицинская терминология в татарском языке


## Әйләнә-тирәлекне өйрәнү дәресләрендә матур әдәбият аркылы экологик тәрбия бирү


***Имаметдинова Рәсимә Галиәскәр кызы,***
***ДАҺБУ "Муса Җәлил исемендәге***
***Минзәлә педагогия колледжы" укытучысы***


"Алтын-көмеш яуган җирдән туган-үскән ил артык" ди татар халык мәкале. Моның шулай икәнен шагыйрьләребез, язучыларыбыз, сәнгатьчеләребез иҗат иткән әсәрләр дә раслый.

Идел ярларына нурлар сибеп

Матур булып ата бездә таң.

Таң шикелле матур туган җирем,

Бәхет биргән җирем Татарстан,- дип язды Г.Зәйнашева үзенең Туган җирем – Татарстан шигырендә.

Әйе, Туган як, Туган ил, Туган җир һәркем өчен якын һәм кадерле. Юкка гына Туган җирне газиз ана белән тиңләмиләр. Һәркем үзенең Туган иле, аның байлыклары һәм уңышлары белән горурлана. Ләкин туган җиреңне ярату, аның байлыклары белән мактану гына җитми әле. Аның турында кайгыртырга, табигый байлыкларын сакларга, алардан дөрес файдалана белергә кирәк. “Җире байның иле бай” диелгән бит халык мәкалендә.

Кешелек җәмгыятенең көчле үсеше чорында кешенең табигатькә тәэсире иксез-чиксез. Табигатькә күпьяклы тәэсирнең нәтиҗәләре бер дә куандырмый. Шуңа күрә дә экологик тәрбия көнүзәк мәсьәлә булып тора. Үсеп килүче буынны табигатьтәге үзгәрешләрне аңлый алырлык итеп тәрбияләү – укыту-тәрбия процессының бурычы. Балаларда табигатькә җитди һәм игътибарлы караш тәрбияләү бик катлаулы һәм дәвамлы процесс. Укучыларның белемнәре һәм осталыклары гына укыту–тәрбия процессының соңгы нәтиҗәсе булып тормый, ә аларда табигатьне ярату, аңлау, яхшырту һәм табигатькә сакчыл караш тәрбияләү мәҗбүри.

Табигатькә экологик яктан аңлы, дөрес, сакчыл караш әкренләп тәрбияләнә. Балаларда табигатьне ярату хисен, аның матурлыгына соклануны, тере дөньяның телен аңлауны, табигатьнең байлыгын саклауны кечкенәдән үк тәрбияләү шарт, чөнки бу вакытта балаларда табигать белән, тирә - юнь белән кызыксынучанлык бик югары була. Педагогикада да бу чор иң кулай вакыт санала.

Безне әйләндереп алган тирә-юньнең әһәмияте турында уйлаганда, шундый нәтиҗәгә киләсең: “ Безнең яхшы көнкүреш, югары техник үсеш ул зур байлык түгел, ә менә чиста һава, саф су, иксез – чиксез үсемлекләр һәм күп сандагы хайваннар дөньясы нинди зур байлык икән!”

Мин башлангыч сыйныф укытучылары хәзерләү булегендә әйләнә-тирәлекне өйрәнү методикасы фәне укытучысы буларак, дәресләрдә татар

халык иҗатын киң кулланам. Җир йөзенең кабатланмас ямен – табигатьтәге төсләр, исләр, авазлар хәзинәсен үзең дә “яшел яфрак” чагында күреп, тоеп-ишетеп калырга кирәк икән.Туган туфракка сабый чакта җибәргән тамырлар гына кешене ватанлы итә, хәерле итә, бәхетле итә. Табигать баласы икәнлегеңне тою нәкъ шул чорда  ярала. Абдулла Алиш әйткәнчә, куе урманнардан, киң кырлардан, яшел болыннардан, тирән сулардан килүче кадерле кунак икәнлегең күңелгә мәңгегә берегеп кала. Алиш үз әсәрләрендә табигатьнең матурлыгын балаларга түбәндәгечә җиткерә: “Бик яхшы сабак алды ябалак” әкияте түбәндәгечә башланып китә: “Зәп-зәңгәр күк йөзенә барып тоташкан, очы кырые күренмәгән бер кара урман бар. Ул урманда яшел киемле агачлар гөрләп үсәләр, тәмле-тәмле җиләкләр кызарып пешәләр. Анда ерткыч бүреләр, хәйләкәр төлкеләр, куркак куяннар, агулы еланнар яшиләр”. “Күз күреме җитмәслек, очы-кырыена чыгып бетмәслек бик зур бер болында күкрәшеп үләннәр үскәннәр. Чалгы белән чабарлык булып өлгергәннәр. Төрле төстәге матур чәчәкләр анда хуш ис тараткannар. Кош-кортлар үзләренең матур сайраулары белән болынны яңгыратканнар...” Бу “Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар әкиятеннән”.

Әсәрләрдә матурлык белән бер рәттән язучылар табигатьнең зар елавын да яктырталар. Моңа Хәкимҗан Халиковның “Ятим тургай” шигыре  мисал.

-Тургай, нигә моңлы син?
Нигә болай елыйсың?
-Инде елап ардым мин:
Япа ялгыз калдым мин.
-Абау, шулай укмыни?
Балаларың юкмыни?
Аждаһадай коточкыч
Мәрхәмәтсез бер очкыч
Агу сипте басуга.
Балаларым барсы да
Шундук үлеп беттеләр...

Мине ятим иттеләр.

Әле безнең кадерне

Тора-тора белерсез.

Тургайларны бервакыт

Төштә генә күрерсез...

Белмим, нинди кеше сез?

Нишлисез?!

Туфан ага Миңнуллин “Кәрлә – мәктәп баласы” пьесасында нинди акыллы сүзләр әйтеп калдырган.

Дию: ...Аннан ни өйрәттеләр?

Кәрлә: Табигатьне сакларга өйрәттеләр.

Дию: Ничек итеп?

Кәрлә: Чишмәләр корымасын өчен аларны чистартып торырга кирәк, агачларны күп утыртырга кирәк, кошларга оя ясарга кирәк.

Дию: Һе...Үзләре өйрәтәләр, үзләре киресен эшлиләр. Авыл башындагы чишмәне карап кайттым, буралары ишелеп беткән, күлләренә пычрак су агызалар, әрәмәлекләрендә көтү йөри. Кош оя ясарлык урын да юк. Урманны теләсә ничек кисәләр. Агач утыртмыйлар. Өйрәткәч аны, өйрәткәнчә эшләргә дә кирәк. Коры өйрәтү кемгә хаҗәт?

Туфан ага кебек Татарстаның иминлеге, матурлыгы, сафлыгы өчен янып көючеләр бик кирәк. Туфан ага кыю фикерен курыкмыйча әйтә ала һәм аны тормышка ашырганчы тырыша иде. Татарстанда кешелекне куркыныч астына куючы проектлар алга сөрү һаман дәвам итә. Кама аланында атом станциясе төзү-төземәү ачыкланмаган. Минзәлә районы Коноваловка авылында дугызчылык комплексы төзергә жыеналар. Ә бит анда тыюлык зонасы: анда кыргый дуңгызларны чир таратмасын өчен юкка чыгарырга мөмкиннәр.

Әсәрләрдә күтәрелгән мәсьәләләр барысы да чынбарлыктан алынган. Шуна күрә дәресләрдә әсәрләрдән өзекләр китерү урынлы һәм нәтиҗәле булыр дип саныйм.

## Әдәби укуда экологик проблема чагылышы

***Исмәгыйлова Голчәчәк Фирдәвис кыз***
***МБОУ "Мослим гимназиясе",***
***башлангыч сыйныф укытучысы***

Хәзерге вакытта табигатьне, аның байлыкларын саклау һәм алардан дөрес файдалану проблемасы бик актуальләшә бара. Табигать белән турыдан – туры аралашу сәбәпле, үсә барган саен баланың табигать белән кызыксынуы да, әйләнә - тирәдәге предметлар һәм күренешләр турында белемнәре дә арта бара. Балалар табигатьтәге күренешләрнең эзлеклелеген күреп алалар, тәрбияче ярдәме белән табигать күренешләре арасындагы бәйләнешләрне аңлы рәвештә билгели башлыйлар. Шуңа да без балаларның сорауларын канәгатьләндереп, күзаллауларын киңәйтеп, табигать белән сак эш итүне тәрбияләү, күзәтүчәнлекләрен, белергә омтылышларын, яратучанлыкларын үстерү һәм үзенең туган табигатенә мәхәббәт тәрбияләргә тиешбез. Балага үзлектән эзләнергә, табарга, нәтиҗә ясарга мөмкинлекләр тудырырга кирәк. Шуңа да мин экологик тәрбияне балаларга кече яшьтән үк өйрәтергә кирәклеген аңладым.

Теманың актуальлеге шунда – берәү дә табигатьтән башка: һава, су, урман-күлләр һ.б. башка яши алмый. Алар безгә һәр мизгел кирәк. Әмма, без табигый байлыклардан фадаланырга гына түгел, аңа ярдәм итәргә дә тиешбез. Әлеге фәнни эшемдә мин экологик мәсьәләләрне хәл итү өчен башлангыч сыйныф әдәби уку дәреслегенә кертелгән әсәрләргә мөрәҗәгать итәргә булдым. Максатым – балалар иҗатында экология темасының бирелешен тикшерү һәм экологик проблемаларны чишү юлларын эзләү.

Максаттан чыгып түбәндәге бурычларны куйдым:

1) башлангыч сыйныфта әдәби уку дәреслекләрендә табигатьне саклауга, экологиягә багышланган шигырьләрне, хикәя, әкиятләрне туплау;

2) аларда күтәрелгән төп мәсьәләләрне ачыклау;

3) экологиябезне саклап калу өчен мин укыткан балалар хезмәте нидән гыйбарәт

Бу юнәлештә балалар белән байтак эш башкарабыз: әдәби уку дәресендә әсәрләр укыйбыз, кош-кортларны, үсемлекләрне саклау; елга-чишмәләргә рейдлар ясау, аларны чистарту, яңарту, агачлар утырту, экологик сукмаклар оештыру кебек эшләр эшлибез. Экология темасына әкият, шигырьләр язабыз.

Безнең бурыч – табигатьне өйрәнү, саклау, үсемлек һәм хайваннар популяциясен арттыруга ирешү.

## М.Җәлилнең "Моабит дәфтәрләре" циклын өйрәнүнең кайбер үзенчәлекләре

***Ишмөхәммәтов Илһам Шакирҗан улы,***
***Түбән Кама шәһәре, 20нче урта мәктәп укытучысы***

Олы, бай, чал тарихлы, Тукай, Дәрдмәнд, Такташ һәм Туфанлы XX йөз татар әдәбиятын үлемсез шигырьләре белән халык йөрәгендә мәңгеләшкән Муса Җәлил исеме дә бизи.

Герой-шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты мәктәптә укытуның һәр этабында өйрәтелә. Башлангыч һәм урта сыйныфларда әдип шәхесе һәм көрәше турында кыскача белешмәләр бирү белән бергә аерым шигырьләре ("Кызыл ромашка", "Җырларым", "Ана бәйрәме", "Соңгы җыр" һ.б.) өйрәнелсә, өлкән сыйныфларда иҗаты монографик планда карала.

Монографик өйрәнү, билгеле булганча, шагыйрьнең биографиясе һәм әсәрләрен тарихи-әдәби процесс һәм халыкның мәдәни тормышы белән бәйләнештә карау булып аңлашыла.

Татар әдәбияты буенча мәктәп программасы укучыларның М.Җәлил шәхесе формалашуның тарихи һәм мәдәни алшартларын, иҗади мирасы үзенчәлекләрен эзлекле, система буларак үзләштерүне максат итеп куя. Әлеге максатны шул рәвешле тормышка ашыруга шагыйрьнең тоткынлыктагы иҗаты нәтиҗәсе булган "Моабит дәфтәрләре" циклын өйрәнү үзенә бер урын алып тора.

Бу теманы ничек өйрәтү укытучы карамаганда, ягъни аның теләгенә, кайсы әсәрләренә өстенлек бирүенә, кулында нинди материаллар булуына, укучыларның әзерлек дәрәҗәсен исәпкә алуына калдырыла. Шулай итеп, һәр очракта да герой-шагыйрь иҗатына гомуми күзәтү ясала, һәм бу эшне укытучы төрлечә оештыра ала: бер-бер артлы шигырьләр укып, һәрберсе буенча да әңгәмә, аннары гомумиләштерүче бер-ике сорау биреп, шигырьләрне билгеле бер темаларга берләштерү. Мәсәлән, мондыйрак сораулар тәкъдим итәргә мөмкин: Лирик герой нинди сыйфатлар белән күз алдыгыздан узды? Ниндирәк лирик геройны автор аерата үз күрә?

Ләкин дәресне икенче төрлерәк уздырырга да була: укытучы укучыларга иң элек өйдә өйрәнергә тиешле шигырьләрне сәнгатьле итеп укырга әзерләнергә куша, ә дәрестә иң яхшы шигырь укучыга конкурс уздыра һәм дәресен шагыйрь һәм аның әлеге циклга кергән шигырьләре турында фикер алышу белән тәмамлый. Шулай ук дәрес укучыларга мөрәҗәгать итә-итә уздырылган лекция тибында да уза ала.

“Моабит дәфтәрләре”нә кергән шигырьләрне бер үк шагыйрь Муса Җәлил иҗат иткән һәм әлеге шигырьләрне аның язмышыннан, аның катнашыннан башка күз алдына китерергә дә мөмкин түгел.

Ә ни өчен шигырьләр циклы “Моабит дәфтәрләре” дип йөртелә? Шагыйрь Германиядә әсирлектә бер Моабит төрмәсендә генә булганмы? (сорауга җавап йөзеннән укытучы “Муса Җәлил” альбомыннан шагыйрь әсирлектә булган шәһәр һәм камераларның исемнәрен әйтә, ә укучылар дәфтәргә яза баралар: Шарлоттенбург, Шпандау, Вустрау, Лертерштрасе, Моабит, Тегель, Дрезден, Варшава, Демблин крепосте, Плетцензее).

Димәк, шигырьләр бер Моабит төрмәсенәдә генә язылмаганнар. “Моабит дәфтәрләре” – шартлы исем, шагыйрь үзе биргән исем түгел.

Сез М.Җәлилнең нинди шигырьләрен беләсез? Бу шигырьләр нинди темаларны чагылдыра? (сорауга җавап дәфтәрләрдә бирем үтәү формасында дәвам итә. Бирем: араларына икешәр юл калдырып, һәр теманы

дәфтәрләрегезгә язып куегыз, үзегез белгән шигырьләрне дә шунда, темасы янына урнаштырыгыз).

Бирем үтәү буенча түбәндәге нәтиҗә чыгарыла: шагыйрь иҗатына тема киңлеге хас; кайбер шигырьләрдә тема кабатлануы да сизелә (“Дуска”, “Соңгы үпкә”, “Бакчачы” һ.б.), әмма һәр очракта тема яңача ачыла [3, 47 б.].

Алга таба әдипнең “Моабит дәфтәрләре” циклына кергән әсәрләренә, аларның сәнгатьчә эшләнешенә күзәтү ясала (проблемалы сорау куела, ул чишелә).

Көрәш, бигрәк тә яшерен оешма ачылгач, әсирлек шартлары турында сез нәрсә әйтә аласыз? (укучыларның җаваплары тыңлана). Әйе, авыр шартлар. Өзлексез, төн урталарында да сорау алулар. Допрослардан канга батып кайту һ.б. М.Җәлил авыр шартларда да талантлы, сәнгатьчә камил шигырьләр иҗат итә.

Мисалга “Таш капчык” шигыре. Шигырь кыска җырлар үлчәменә салынган, шуның белән тиз, тигез бара торган процесс – тегермән ташы әйләнеп тору күз алдына килә. “Тыр”, “кыр” (таш шыгырдый), “с”, “з” (кеше гәүдәсе сытыла, кан сыгыла) авазларның алмашынып тору төсмере өстәлә: менә бер кеше үтте, икенчесе...

Шуннан “Моабит дәфтәрләре”нең сәнгатьчә эшләнешенә күзәтү ясала. Алда шигырьләрнең аермалы якларына игътибар ителсә, бу урында М.Җәлил шигырьләре өчен уртак сәнгатьчә билгеләрнең дә күп булуы исәпкә алына.

Аннары әдипнең беренче дәфтәрнең соңгы битенә [2, 78 б.] язылгын васыяте укылып, аның эчтәлегеннән һәм укучыларның шагыйрьнең әсирлектәге көрәшен һәм иҗатын белгәннәре буенча җавапларын язмача өйдә әзерләү өчен сораулар тәкъдим ителә.(М.Җәлил нинди шартларда әсирлеккә төшә? Шагыйрь үз васыятендә “Кырык үлемнән калып” ди. Бу “үлемнәр” турында белгәннәрегезне языгыз [1, 23 б.]. Ни өчен шагыйрь, васыятеннән күренгәнчә, үз шигырьләре өчен шулай борчыла? Шагыйрь ышанычының тормышка ашуына сез нинди дәлил китерә аласыз? “Моабит дәфтәрләре”нең безнең илгә кайту юлы хакында сез ниләр беләсез?

1. Әминев А.Г., Галиева Һ.Н. Муса Җәлил мәктәптә. Шагыйрьнең иҗат һәм тормыш юлын өйрәнү мәсьәләләренә карата. Укытучылар өчен ярдәилек.- Казан: Тат.кит.нәшр., 1967. - Б.80-93.

2. Җәлил Муса. Моабит дәфтәрләре. Факсимиль басма. - Казан: Тат.кит.нәшр., 2000, Б.78.

3. Кашшаф Г. Муса Җәлил. Тормышы һәм иҗаты турында очерк. Казан: Татгосиздат., 1957. Б.318-330.

4. Мостафин Р. Ат караучы шагыйрь/ Ачык дәрес, 2004, №1.- Б.12-14.

5. Фәйрушина З. Муса Җәлил – шагыйрь һәм көрәшче/ Совет мәктәбе, 1976, №3. - Б.23-25.

## Яшә син, туган телем!

***Камалиева Дания Вәсил кызы, Түбән Кама шәһәре***
***13 нче гимназия-интернатның***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

1999 елның ноябрь аенда ЮНЕСКО үткәргән конференциядә туган телләр проблемасы карала һәм ул 2000 елның февраленнән билгеләнә башый. Берләшкән Милләтләр Оешмасы мәгълүматларына караганда, җир шарындагы 6700 телнең яртысына югалу куркынычы яный. Шуңа күрә һәр халыкның гореф-гадәтен, йолаларын, җыр-моңнарын, авыз иҗатын, гомумән, телен саклап калу максатында 21 февраль – Халык-ара туган-тел көне дип игълан ителә. Бу – үзебезнең телнең дә язмышы турында уйланырга бер сәбәп.

Татарстан галимнәре, җәмә¬гать эшлеклеләре татар теле һәм рус теле канун нигезендә рәсми рәвештә ике дәүләт теле булып исәпләнсә дә, татар теле чын мәгънәсендә дәүләт теле булмады, диләр. Әйе, Татарстанда “Дәүләт телләре турында”гы Закон, “Татарстандагы дәүләт һәм башка телләр үсеше турында” дәүләт программасы эшли, төрле институтлар бар, әмма татар теленең дәрәҗәсе артмый. Моның да сәбәпләре уч төбендә күренеп ята. Дәүләт тарафыннан татар телен өйрәнүгә этәргеч, ике телне дә су кебек эчкән белгечләргә киләчәк перспективалар булдырылмады. Андый белгечләргә өстенлек

бирел¬мәде. Бүген татар телен өйрәнүгә кызыктыру эше мәктәп укытучылары җилкәсенә генә төшә.

Татар теле  дәресләрендә әхлак тәрбиясенең бер өлеше булып, туган телгә мәхәббәт һәм ихтирам тудыру тора. Татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак бу максатка ирешү өчен күп ысуллар кулланам. Туган тел  хакында фикер йөрткәндә, беренче чиратта шагыйрьләр иҗатына мөрәҗәгать  итәм. Чынлап  та,  шагыйрьләр  – алар  чын  поэтик сүз осталары, сүзнең кадерен белүчеләр, халыкның телен һәм рухын саклаучылар. Икенчедән, халык авыз иҗатыннан туган тел турындагы мәкальләрне табып, мәгънәләрен аңлату биремнәрен башкару уңышлы. Өченчедән, туган телгә ихтирам тәрбияләүдә әдипләребезнең әсәрләреннән китерелгән өзекләр дә зур роль уйныйлар.

Мине тагын сөйләмебезнең саф булмавы борчый. Сөйләм саф булсын өчен, гасырлар буена тупланып килгән сүз байлыгын дөрес куллана белү таләп ителә.Туган телдә сөйләшкәндә, башка тел сүзләрен катнаштырып җөмлә төзү бу таләпне бозуга китерә. Тел уйнатуның наданлыкка ишарә булуын шагыйрь Дәрдемәнд узган гасырда ук әйтеп калдырган:

Кил, өйрән, и туган, бер башка телне,
Бүтән телләр белү – яхшы һөнәрдер.
Катыштырма вәләкин телгә телне,
Тел уйнатмак наданлыктан әсәрдер.

Йомгаклап шуны әйтәсем килә, күп кенә милләттәшләребез, язучылар, шагыйрьләребез туган телебезнең язмышы өчен борчылалар, аны яратырга, сакларга чакырып, матур фикерләрен язып калдыралар. Мәсәлән, үз чорында язучы Гомәр ага Бәширов телне бик югары бәяләгән. “Тел… халыкның өзлексез байый һәм, иҗтимагый тормышның үзгәрүе белән бергә, һаман үзгәрә, яңара торган чиксез бай һәм кыйммәтле күңел хәзинәсе. Бу хәзинәгә халык үзенең ничә мең еллар буенча тупланган тормыш тәҗрибәсен,яшәеш турындагы фәлсәфәсен, үзенең иҗатын, гореф-гадәтен, уйларын-хыялларын, моңнарын-сагышларын, хәтта иң яшерен күңел кичерешләрен, интим хисләрен ышанып тапшырган. Шунлыктан һәр сүз борын-борыннан ук, халыкның әманәте

рәвешендә, үзе белән билгеле бер мәгънә –йөкләмә алып килә, моңарчы билгеле булмаган бик күп серләрне ачарга ярдәм итә, аларны аңлатып бирә. Телсез халык үзе дә була алмый, халыксыз – тел дә юк. Шунлыктан телгә мәхәббәт бер үк вакытта халыкка да, туган илгә дә мәхәббәт дигән сүз… “- дип язган ул.

Кулланылган әдәбият


1. Вәлиева З. Теле барның – иле бар // Мәгариф, №2, 2003. Мирас
2. Нургалиева Х. Туган телне саклыйк!//Ялкын, №3, 2016.
3. Юсупов Р.А. Әдәп башы – тел: икетеллелек шартларында дөрес сөйләм мәсьәләре. – Казан, 2000.


## Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә кече яшьтәге укучыларга экологик белем һәм тәрбия бирү


***Камбеева Гюзель Галимзяновна,***
***учитель татарского языка и литературы***
***МБОУ НМР «Средняя общеобразовательная школа №33***
***с углубленным изучением английского языка»***
***г.Нижнекамск***


“Экология” атамасын немец галиме Эрнест Геккель 1886 нчы елда керткән. “Эко” - йорт, “логос” - өйрәнү дигән сүз.

Кешенең яшәеше өчен фән һәм техниканың алга китүе, тормыш-көнкүреш шартларының уңайлы булуы гына җитми, тирә-юньнең чисталыгы, су һәм һаваның сафлыгы, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясының төрлелеге дә зур әһәмияткә ия. Җирдәге тереклекне саклап калу проблемасы көннән-көн кискенләшә бара.

Башлангыч сыйныф укучыларына әхлакый–экологик белем һәм тәрбия бирү “Әйләнә-тирә дөнья һәм ТИН” курсы материалларына нигезләнеп алып барыла. Уку, рус теле, математика, ана теле, технология, музыка, сынлы сәнгать дәресләрендә дә моның өчен мөмкинлекләр зур.

Экологик бәйләнешләрне өйрәнү балаларның логик фикерләү сәләтен, хәтерен, күзаллауларын, табигатькә сакчыл караш һәм шулай ук сөйләмнәрен

үстерүгә дә ярдәм итә. Моны гамәлгә ашыру өчен, иң элек, түбәндәге өч мәсьәләне хәл итәргә кирәк:

- табигатьтәге бар нәрсә дә үзара бәйле икәнлеген дәлилләү;

- укучыларга ни өчен табигать бәйләнешләрен белергә кирәклеген (бу бәйләнешләрне бозуның табигать өчен дә, кеше өчен дә начар нәтиҗәләргә китерүен) төшендерү;

- балаларда шушы бәйләнешләрне белү нигезендә табигатьтә үз-үзләрен дөрес тоту күнекмәләрен үстерү.

Җир йөзендә яшәүче организмнар белән терек булмаган табигать арасында кызыклы бәйләнеш бар.

Терек табигатьнең үз эчендә дә экологик бәйләнеш күп төрле.

“Акыллырак булыйк!” дип исемләнгән мәкаләдә болай дип язылган: “Планетабыз үзе теп-тере җан. Әмма безнең аны тәмам азынып-тузынып хурлауларыбызны, мыскыллап басымчак итүебезне ул күтәрә алмый... тәмам азган балалары бераз акылга утырмас释мы дип, тайфуннар, цунамиләр,җир тетрәүләр, көтмәгән су басулар, тау-кыя ишелүләр чыгарып, безне кисәтеп карый.

Бүген без шулкадәр шапшак яшибез, торган-яшәгән җиребез елдан-ел, иң кыйммәтле порошоклар белән җиң сызганып юсаң да чистарта алмаслык дәрәҗәдә пычран бара. Планетабыз бу хәлгә озак түзә алмас.”

Планетада соңгы 20 ел эчендә генә 200 млн. га мәйданда урман массивлары юкка чыгарыла. Планетаның “үпкәләре” булып торган тропик урманнар аеруча аяныч хәлдә. Монда ел саен 200 мең кв. км. мәйданда агачлар киселә, яндырыла. Бу исә, 100 мең төрдәге үсемлекләр һәм тереклек ияләре юкка чыга дигән сүз. Күпчелек галимнәр глобаль экологик кризис бик тирәнгә үтеп кергән һәм аның катастрофага китерәчәге бәхәссез, хәзер бары тик аның нәтиҗәләрен бераз йомшарту турында гына сүз алып барырга мөмкин, дип исәплиләр. Шул ук вакытта үз пычрагы өстендә үзе “утыручы” кешенең сәламәтлеге аның нинди һава сулавына, ничек туклануына һәм нинди су эчүенә, хәтта әйләнә-тирәдә нәрсә күрүенә бәйле.

Шуңа күрә, укучыларда табигатькә сакчыл караш тәрбияләү, уртак йортыбыз булган Җир планетасы язмышына җаваплылык хисе булдыру - экологик проблемалар кискенләшкән чорда аеруча әһәмиятле һәм ул максатчан алып барылырга тиеш. Укучыларга түбән сыйныфларда ук әби-бабаларыбызның табигать байлыкларыннан бик саф файдаланулары турында аңлатырга кирәк.

“Әгәр дә кешеләр табигатькә, мөхиткә зыян китермичә генә матди байлыклар тудырырга өйрәнмәсә, җир йөзеннән кеше үзе дә юкка чыгарга мөмкин” дигән хакыйкәтьне күптән аңлаган әби-бабайлар, беркайчан да үз ихтыяҗларыннан артык җәнлек ауламаганнар, балык тотмаганнар. Ау вакыты башланганнан соң, беренче тотылган җәнлекне яисә балыкны “Урман иясенә”, “Су иясенә” атап, кире җибәргәннәр, яшь агачларны кисмәгәннәр. Үз балаларын да табигатьне саклаучы, хөрмәт итүче итеп тәрбияләү һәрбер әти-әнинең изге бурычы дип саналган. Мондый тәрбия төрле йола, җыр, бәет аша бирелгән. Бүген исә без балаларга әхлакый-экологик белем һәм тәрбия бирүдә халык педагогикасына һәм әдәби әсәрләргә таянып эш итәбез.

Чыгышымны Антуан де Сент Экзюпериның түбәндәге фикере белән тәмамлыйсым килә: “Без – Җир дигән бер корабльнең балалары, димәк, аннан беркая да күчеп утырып булмый. Әгәр кешедә табигать белән килешеп яшәү өчен көч, чара һәм акыл булмаса, тузан белән капланган, тереклек юкка чыккан Җир өстенә” һәркем үзе өчен генә иң яхшыны теләде” дип язылган кабер ташы куярга туры килер иде, ахрысы. Димәк, экология тәрбия бирү ул иң беренче чиратта, әхлак тәрбиясе бирү. Табигатьне яраткан, аның матурлыгын күрә белгән кеше беркайчан да каты бәгырьле була алмый.

Чыгышымны тәмамлап шуны әйтәсем килә: халык мәкалендәгечә, “үзе утырган ботакка балта чапмыйлар”, табигатьнең гүзәллеген тоя белгән, кирәклеген тоя белгән, табигатьнең ккирәкэлеген аңлаган, миһербанлы, кешелекле балалар тәрбияли алсак иде. Һәм, үзебез дә аларага бар нәрсәдә дә үрнәк булсак иде. Чөнки, “үрнәк – иң яхшы тәрбия”!

Кулланылган әдәбият.

1. Г. Гыйльманов. Тозлы яңгыр: Повестьлар, хикәяләр, нәсерләр, парчалар.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1994

2. Г. Гыйльманов. Китек ай: Повестьлар, хикәяләр, парчалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 383 бит.

3. “Мәйдан” журналының 2008 нче елгы 5 нче саны.

4. И.С.Нәбиуллина. Җанкаем: повестьлар, хикәяләр. – Казан: Сүз, 2006

5. http://maratkabirov.com/izat/mehebbetten-jyrlar-kala.html

**“Мин тумыштан гашыйкмын телемә, туган җиремә”**

(Марсель Гыймазетдинов)

***Эшне башкарды: Менделеевск шәһәренең***
***4 нче гомуми урта белем бирү мәктәбенең***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы***
***Кашапова Гөлфирә Хәмәт кызы***

Менделеев җире алты Советлар Союзы Герое гына тәрбияләп үстермәде, бу төбәк әле күп кенә җырчы һәм шагыйрьләр дә бирде. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә, класстан тыш чараларда без районыбызның күренекле шәхесләрен, шагыйрьләрен искә төшерәбез, өйрәнәбез, аларның иҗат һәм тормыш юллары белән танышабыз. Менә аларның кайберләре: Вафирә Гыйззәтуллина, Егор Уткин, Илгиз Абдуллин, Марсель Гыймазетдинов,Фәния Шакирова, Дифгат Сирай һәм башкалар. Шулар арасыннан мин туган якның моңлы җырчысы, күпкырлы сәләт иясе, авыл рухы белән сугарылган шигырьләре белән бөтен республикага танылуга ирешкән Марсель Гыймазетдиновның тормыш һәм иҗат эшчәнлеген тирәнрәк өйрәнү һәм эзләнүе үз алдыма максат итеп куйдым.

Эшем аның бертуган апасы Римма апа Гыймазетдинова, яшьтәше Тәскирә апа Галиева һәм Бәзәкә урта мәктәбенең ветеран укытучысы Рәмзия апа Мөхетдинова сөйләгән материалларга нигезләнеп эшләнде.

...Радиодан бүлмә эченә талгын гына моң ишетелә.

...Туган як кырларын сагынып,

Әйләнеп авылга кайт әле.

Җыр агыла да агыла. Моңы күңелгә якын, сүзләре җанга ятышлы, сагышлы –якты көе йөрәкне назлый, иркәли. Кем соң шулай туган якларыннан кайчандыр чыгып киткәннәрне кире авылга кайтырга чакыра? Кем үзенең җырга әверелгән шигъри юллары аша авылны терелтергә, яңартырга, аның язмышына йөз белән борылырга дәшә, чакыра, өнди, үтенә? Бу сорауларны

мин болай гына бирдем. Чөнки бу җырны белмәгән авыл кешесе юктыр Татарстанда. Әйе, җыр сүзләренең авторы – Марсель Гыймазетдинов(1 нче рәсем). Кемдер үз гомерен тыныч кына, ә кемдер метеоритка тиң булып, кыска гомерен дә башкалар өчен янып үткәрә. Марсель Гыймазетдинов та шундыйлардан. Кешеләргә булган хөрмәтен, туган җиргә булган мәхәббәтен шигырьләрендә тирән итеп чагылдыра ул. Үзе дә авыл баласы, җир кешесе, колхоз рәисе, шулар өстенә, шигъри җанлы кеше дә булганга, туган як, туган авыл, туган тел, кешеләр язмышына һич кенә дә битараф булмый. Кайчандыр туган төбәкләреннән чыгып киткән якташ – милләттәшләргә авылларны бетермәү, киресенчә, күтәрү, үстерү өчен аларны авылга кире кайтару максатыннан Казан телевидениесеннән мөрәҗәгать итүче дә. Марсель Гыймазетдинов үзенең чыгышы белән халыкны туган авылларын, җирләрен ташламаска, җир хезмәтеннән курыкмаска өнди. Бу – бүгенге тормыш, киләчәк яшәеш өчен көрәшнең бер ысулы, юлы була. Ул шушы юлдан соңгы минутына кадәр туры һәм нык бара.

1. Балачагы, мәктәп еллары, инсититут, хезмәт эшчәнлеге .

Марсель Гыймазетдиновның тормыш юлын һәм иҗатын мин бер кечерәк кенә китапчык итеп күз алдына китерәм. Шагыйрьнең шигырьләрен укыганда, мин китапчыкны да күңелемнән актарам.

Китапчыкның беренче битләрендә – гади генә биография. Марсель Гыймазетдинов Менделеев районы (элеккеге Бондюг районы) Бәзәкә авылында 1943 нче елда туган. Әтисе Гыйлфан абый – авыл советы рәисе, әнисе – Газдә апа – йорт хуҗабикәсе. Җылы мөнәсәбәтле гаиләдә ике бала тәрбияләнә. Балалар бакчасыннан соң Марсель 1951нче елда Бәзәкә урта мәктәбенә укырга керә. Мәктәп елларында ул үзен тырыш, зиһенле, фәннәрне җиңел үзләштерүе, физик яктан нык, көчле(чөнки спортны бик яраткан), шул ук вакытта шук, бик хәрәкәтчән, туры һәм үткен сүзле булуы белән аерылып торган. Шушы сыйфатлары аның укытучылары хәтерендә истә калган. Мәктәпне уңышлы гына тәмамлагач, Алабуга дәүләт педагогия институтының филология факультетына укырга керә. Ул укытучы булырга хыяллана. Аның

теләге – татар халкының тарихын, телен, мәдәниятен, культурасын өйрәнү тормышка аша. Белгечлеге буенча Марсель Гыйлфан улы армиядә хезмәт итеп кайтканнан соң гына - 1962 нче елда башлый. Башта Тойгуҗа (Тойгузино) мәктәбендә гади укытучы, аннан Ык Тамагы (Икское Устье- рус авылы) мәктәп директоры булып эшли. Бераздан Тихоново (рус авылы)мәктәбендә, Менделеевск махсус мәктәп- интернатында җитәкче була. Укыту-тәрбия эшләре аңа бик ошаса да, аны тагын да җаваплырак эшкә тарталар. Менә шулай итеп, ул “Тойма” совхозы партия оешмасын җитәкләргә алына. Бераз 1976 - 1981 нче елларда 543 нче төзү- монтаж поезды начальнигы урынбасары булып эшли. Менделеевск районы кабат төзелгәч, 1985 нче елда Марсель Гыйлфан улы «Батыр кул» колхозына партия оешмасы секретаре булып эшләргә килә. Тиздән аны  Тукай исемендәге колхоз рәисе, ә 1990 -1991 нче елларда Менделеев районы халык депутатлары советының председателе урынбасары итеп билгелиләр. Әмма ул җылы креслога ябышып ятмый, үз теләге белән артта калган “Бондюг” совхозына директор булып китә. Аның рекомендациясе буенча бу хуҗалык икегә бүленә һәм ул “Татарстан” дип аталган колхозга җитәкчелек итә. Яшьлек елларындагы теләген – заманга лаек , кешелек сыйфатларына ия  булган буын тәрбияләү – җитәкче булып эшләгәндә дә  дәвам итә.  Ул һәр кешегә: механизатормы, игенчеме, интеллигенцияме, гади бер кешеме – кем булуына карамастан, һәркайсына шәхсән якын килә, тыңлый, алар белән аралаша, киңәшләшә. Үзен беркайчан да зурга куймый. Марсель Гыймазетдинов шәһәр һәм районның иҗтимагый-сәяси тормышында актив катнаша. Халык депутаты итеп сайлана. Гадилеге, игътибарлы, кешелекле булу сыйфатлары белән бик  күпләрдән аерылып тора.

2. Иҗат – ләззәтле газап.

Китапчыкның  иң зур өлеше – аның иҗат җимешләре. “ Шигырь язу минем һөнәрем түгел” дисә дә, аның кулыннан  каләм төшми. Көнозын иген кырлырында хезмәт куеп, кичкә җеп өзәрлек хәле калмаса да, ул иҗат эшенә керешә.Татарстан радиосыннан ясаган  бер чыгышында ул үзенең иҗаты турында болай дигән: ”...Минем ярты гомерем басу – кырларда үтә. Мин бит

гашыйк туган җиремә. Яз уянып килгән бер мәлдәме, яисә иртә – кичләрдәме, йә булмаса көзгә кергәчме – кырлар түренә карап уйланып торасың да ирексездән күңелгә шатлык хисләре тула һәм үзең дә сизмәстән: “ Матур бу дөнья!”- дип куясың. Мондый чакларда тормышның, вак мәшәкатьләре бердән онытылып китә, иркен сулыш белән яшисе килә башлый. Һәм мин шул уй – хисләремне, үземчә, кәгазьгә төшереп барырга тырышам.”

Марсель Гыймазетдинов республикабызда колхоз рәисе дип кенә түгел, ә танылган шагыйрь, берничә китап авторы буларак та билгеле. Беренче шигырьләрен ул 5 нче сыйныфта укыганда яза һәм район газетасында бастыра. Беренче китабы “ Аккош канат кагына “ исеме астында”Беренче карлыгачлар” циклына кергән “Туган як җыры“ исемле төрле авторларның шигырьләр җыентыгында 1987 нче елда басылып чыга. 1990 нчы елның гыйнвар аенда Татарстан китап нәшрияте шагыйребезнең “Яшәү мәгънәсе” дип исемләнгән икенче китабын бүләк итте. Өченче китабы 1992 нче елда дөнья күрә. Ул “Язлардан алалмыйм күземне “дип атала. Шагыйрьнең тематикасы күп төрле күп төрле. Ул туган як, анның гүзәллеге, кешеләре, Ана, мәхәббәт,туган тел, тынычлык турында яза.

Шигырьләр, шигырьләр...Шагыйрьнең бөртекләп җыйган иҗат җимешләре. Һәрберсе кадерле, изге, үзенчәлекле, ачык хисле. (2,3,6 нче рәсем)

Яз Кояшы җирдә
Гөрләвекләр
Язгы ташкын булып йөгерә.
Якты көннең якты бизәкләрен
Алып була хәтта өлгегә...

“Якты шигырь”

Марсель Гыймазетдинов шигырьләрендә туган як табигатенә, җиргә, авыл кешеләренә – икмәк үстерүчеләрнең күңел матурлыгына дан җырлый.

Чыгам да кырларга , сокланам,
Башаклар тирбәлә саф җилдә.
Игенче , горурлан, хезмәтең,-

Чыгам да кырларга, уйланам:
Игенче, син изге, хикмәтле.
Туган ил сүзенә тиң сүзләр:

Иң бөек, иң даһи бу җирдә. Тынычлык, игенче, икмәктер.

” Игенчегә”

Табигать белән бер сулышта яши автор, андагы матурлыкны, сафлыкны кеше күңеленә күчерергә омтыла. Халыктагы күркәм гореф – гадәтләрнең башлангычын – туган җирендә, кеше җаны белән бердәмлегендә тоя ул.

3. Җырчы шагыйрь

Марсель абый шигърият дөньясына аяк басучы һәр яшь талант өчен сөенә. Каләм тибрәтүче авылдашы Фәния апа Шакированың, районымдашыбыз Илгиз Абдуллинның иҗатларын даими күзәтеп бара һәм үзенең киңәшләрен әйтеп тора. Яшь шагыйрьләр белән генә түгел, ул композиторлар белән тыгыз элемтәдә яши, чөнки күп кенә шигырьләренә җырлар язылган: ”Язлардан алалмыйм күземне”, “Юксынам дисең син”, “Аккош канат кагына”, “Туган җирнең китмәс кошлары без”, “Сагышларым туган якта” һәм башкалар. Аларны дулкынланмый уку һәм хисләнмичә тыңлау мөмкин түгел. Һәвәскәр композиторлар Луиза – Батыр Болгари, Илгиз Закиров, Зөфәр Хәйретдинов, Сафьян Ибраһимов, Фирзәр Мортазин, үзешчән композитор Владимир Мироваев Марсель абыйның иҗади дуслары булалар. Бу инде аның әсәрләренең бик музыкаль булуын, аларның үз – үзләрен көйгә салуны сорап торуын, ә үзен - җырчы-шагыйрь икәнен күрсәтә! (4 нче рәсем)

4. Җәмәгать эшлеклесе

Марсель Гыймазетдинов күпкырлы талант кешесе. Ул педагог та, җир кешесе – икмәк үстерүче дә, шагыйрь дә һәм тагын җәмәгать эшләрен башкаручы да. Менделеевск районында ул “Ядкарь” исемле әдәби – музыкаль берләшмәгә нигез сала, аны җитәкли. Бу берләшмә район күләмендә Вафирә Гыйззатуллина катнашында “Ана һәм бала”, “Җырлыйк әле”, “ И туган тел”, керәшен татарларының фольклорына багышланган “Ялгыз яшәп кара” дигән әдәби кичәләр, татар халкының бәйрәмнәрен, кичке уеннарын, төрле очрашулар оештыра. Үзе дә, һәр кич репетицияләргә йөреп, спектакльләрдә катнаша. Һәрчак ачык күңелле кеше була. Берләшмә яшь талантларга иҗади ярдәм күрсәтә. (Кызганыч, бу берләшмә, җитәкчесез калгач, тарала.) 1991 нче елның

декабрендә яңа оештырылган крайны өйрәнү җәмгыяте Менделеевскида дәүләт музеен төзү кирәклеге турында белдергәч, Марсель Гыймазетдинов моны берсүзсез яклап чыга. Ул вакытта Марсель абый район Советы башкарма комитеты рәисе урынбасары булып эшләгән була. Бүгенге көндә туган якны өйрәнү музее Татарстан Дәүләт музее филиалына әверелә. Аның турыдан-туры катнашы белән районда һәм шәһәрдә күп истәлекләр ачыклана. Марсель Гыйлфан улы туган якны өйрәнү буенча зур белемле кешеләрне, вакыйгаларны, фактларны яхшы белә, тикшерү-эзләнү процессына ярдәм итә. ”Кайда гына эшләсә дә, җаны-тәне белән бирелеп хезмәт куя. Җитәкче кеше булгач, төрле кешеләр белән очрашырга туры килә. Ләкин ул нечкә күңелле шагыйрь булгандыр, күрәсең, кешеләр белән уртак фикер, аларның йөрәгенә үтеп керерлек сүзләр табучы, кешелекле, олы җанлы, тормышны нык яратучан кеше иде”- дип искә ала элеккеге хакимият аппараты җитәкчесе Тәскирә Галиева.(5 нче рәсем)

5. Көрәшче шагыйрь

Кызганычка каршы Марсель Гыймазетдиновның тормышында һәм хезмәтендә бар да ал да гөл булмый. Ул күп төрле каршылык-киртәләргә, тормышыбыздагы ямьсез һәм күңелсез, тискәре күренешләргә каршы ашкынып һәм туктаусыз көрәшә. Мәсәлән, туган телебезне саклау һәм торгызу буенча күп эшли. Мәктәпләрдә татарча укытуны беренче планга куя. Район үзәгендә үткәрелә торган чараларның, Сабантуйның татарча алып барылуына ирешә. Районда татар иҗтимагый үзәге оештыру, алты авылда мәчет салу өчен рөхсәт алу, Менделеевск шәһәрендә төзеләчәк дүрт манаралы мәчетнең проектын булдыру, урамнар,зиратлар чистарту буенча өмәләр оештыру һәм аларда үзе дә катнашу – болар барысы да бер кешенең тырышлыгы нәтиҗәсе, көрәше. Боларның барысы да килеп чыксын өчен ул эзләнә, сөйләшә, киңәшләшә, шалтырата, хәтта ачуланыша да... . Марсель абыйның шундый тынгысыз булуы .уңыш-табышлары, халык арсында хөрмәтле һәм популяр булуы, иҗат күгендә якты йолдыз булып кабынуы күпләргә охшамый, билгеле. Аңа аяк чалырга, аның дәрәҗәсен төшерергә, исемен каралтырга тырышалар, хәтта аңа матди

зыян салудан да курыкмыйлар. Бервакыт, Марсель Гыймазетдинов колхоз рәисе булган чакта, аның өстеннән шикаять хаты (жалоба) язалар, Комиссия килә, тикшерүләр китә. Менә шул чакта, рәис кулына каләм алып, газетага мәкалә яза. “Анонимчыга хат” дип атала ул. “Куркак җан , сиңа хат язарга булдым. Бәлки бу хатым синең намусыңны, вөҗданыңны уятыр. Синең шикаятьләр минем һәм белгечләрнең омтылышына аяк чала, колхозның үсешен тоткарлый. Әгәр синең чыннан да колхоз үсешенә файда китерәсең килә икән, син күргән, белгән эшләр дөрес икән, нигә дип чын исемеңне атамыйсың? Яисә безнең янга килеп турыдан-туры әйтмисең? Уйлан әле, вөҗданың газапламас микән? “- дип эндәшә ул кара йөрәкле кешеләргә. Ә икенче түбән җанлы һәм куркак теш кайраучылар бөтенләй этлек эшлиләр: шагыйрьнең дача өен ут төртеп яндыралар. Менә шундый көнче һәм кара эчле бәндәләр тынгысыз, эзләнүчән, туры сүзле кешегә аяк чалырга, аны бөтенләй туктатырга тырышалар. Ләкин бу артык мәшәкать кенә була. Марсель Гыйлфан улы эшлисен - эшли , әйтәсен - әйтә. Тел, сүз белән әйтеп бетермәгәнен шигырьләре аша җиткерә.

Дөреслекнең гел күзенә карап, Куркыттылар,
Күпме гомер яшим дөньяда. Майлап карадылар,
Бюрократны кистем, Янадылар карап күземә.
Ялагайны ярдым, Бирешмәдем. Түздем. Көрәшәмен.
Ришватьчегә көн юк мин барда. Шул пычракны түгәм бу җирдән.
Күпме түздем яла ягуларга, Тавышымны минем ишетерләр
Ябырылды алар үземә. Үлгәчтен дә тирән кабердән, - дип яза ул үзенең “Тынгы бирмәм” шигырендә. Чыннан да, Марсель Гыймазетдинов менә шулай, күп киртәләрне җимереп, колхоз йөген тарта – тарта иҗади хезмәткә дә вакыт таба. Татар халкындагы булган күркәм сыйфатларны: тыйнаклылыкны, чисталыкны, аклыкны эшчәнлекне, дөреслекне, тырышлыкны һәм башкаларны алгы планга куя, ә кайбер кешеләрдәге битарафлык, табыш - байлык артыннан куу кебек тискәре сыйфатларга ия булганнар белән аусыз көрәшә. Моңа мисал итеп ”Шәфкатьлерәк кирәк булырга”, “Әй, кешеләр”, “Йа,

ходаем, берүк арала” һәм башка шигырьләрен әйтеп китәргә була. Аның тынгы белмәс йөрәге начар хәлләргә борчыла, үртәлә, сызлана... Кызганычка каршы, аның йөрәге түзми – язның бер матур көнендә кинәт туктап кала...

Авылыбызның бер улын югалттык
Бик вакытсыз китте арадан.
Шигърияттә йөзек кашы идең,
Кайталмассың инде яңадан.

Иҗатыңда саф йөрәгең белән
Саф мәхәббәт, яшәү, дәрт бирдең.
Хезмәтеңдә бар көчеңне куеп
Халкың өчен икмәк үстердең.

Киттең, ләкин исемең, даның калды,
Син бу җирдә мәңге балкырсың.
Хезмәт иттең сөйгән халкың өчен –
Балкыр өчен җирдә хаклысың,-

дип яза “Хаклысың” шигырендә аның авылдашы, дусты шагыйрә Фәния апа Шакирова.

Бу тынгысыз йөрәкле Кеше озак яшәргә, берсеннән -берсе матур, гүзәл эшләр башкарырга тиеш иде... Ләкин язмыш барысын да үзенчә хәл итә... Марсель Гыймазетдиновның җирдән, туган туфрактан шыткан шигырьләре безнең телләрдә, аның китаплары - өстәлләрдә, җанга якын җырлары сәхнә, радио һәм зәңгәр экраннардан көнаралаш яңгырый, безнең күңелләребезне иркәли, тынычландыра. Ә “Әйләнеп кайт әле авылга” җыры татар иленең авыл кешеләре өчен гимнга әверелде дип уйлыйм:

"...Кайгырма, моңайма, юксынма,
Әйләнеп кайт кына авылга...”

Марсель Гыйлфан улы Гыймазетдинов тормышта көчле язгы ташкын кебек. Яз турында ул күп яза, яратып яза. “Язлардан алалмыйм күземне”, “Язларны көтә күңел”, “Язлар белән китәрмен” һәм башкалар. Язлар белән туган якларга аккошлар кайта. Аккошлар –мәхәббәттә иң тугры кошлар, парларын гомерлеккә берне генә сайлыйлар... Әйе, бүгенге авыр, болгавыр заманда, бик күпләр акча, затлы әйбер, югары постлар белән саташканда, аккошларга хас сыйфатларны үзеңдә булдыру ай –һай авыр шул. Аклык, чисталык, тугрылык кебек югары сыйфатларга ия булган аккошларны Марсель

Гыймазетдинов  үз иҗатына тиккә кенә кертмәгән, күрәсең. Ул үзенең шигырьләрендә, хисләрендә чиста, якты, ак, саф була һәм туган ягына гомерлеккә бирелгән, туган җиренә мәңге тугры булып яшәгән Кеше булып кала.

“Туган җирем, синдә гомер буе

Яшәдем мин тугры ул булып” -  дип яза ул үзенең “Язмышларым –иген кырлары”шигырендә.

Эшемне йомгаклап шуны әйтәсем килә. Әгәр ул исән булып,  аның белән очрашырга туры килсә, мин мондый сүзләр җиткерер идем: “Марсель абый! Сезнең тормыш юлыгыз, шигырьләрегез сокланырга, уйланырга мәҗбүр итәләр. Тәрбияле, фикерләүгә сәләтле, үз хокукларын, телен, милләтен яклый белгән чын Кеше булырга өндиләр. Рәхмәт Сезгә!”
Мин кемнәрдән генә Марсель Гыймазетдинов турында сорасам да, кайдан гына аның турында укысам да, аның чын ир, хезмәт кешесе, кешелекле, намуслы, туган ягын, халкын, телен яратучы булуын ишетәм, укыйм, күрәм. Бүгенге көндә мондый кешеләргә сокланмыйча, алар белән  горурланмыйча мөмкин түгел! Аның күркәм эшләре, сокландыргыч шигырьләре безнең күңелләрдә сакланыр, безнең өчен һәрчак үрнәк булыр!

Кулланылган әдәбият исемлеге

1. М. Гыймазетдинов. Яшәү мәгънәсе

2. М. Гыймазетдинов. Язлардан алалмыйм күземне

3. М. Гыймазетдинов . Син мине белмисең

4. Наис Гамбәр “Туган якның китмәс кошы”. “Казан утлары” журналы

5. “Менделеев яңалыклары” газетасы. 1993, 1995, 1998 еллар

## Әдәбият дәресендә әхлак тәрбиясе

*Кәримова Рәсимә Габделхәй кызы*
*1 квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
*ДАҺБУ «Түбән Кама индустриаль техникумы»*

Элек-электән ата-ана бала-чаганың иге¬лекле, итәгатьле, тәртипле, кешелекле булып үсүенә нык игътибар иткән. Гаиләдә ата-анага, әби-бабага, мөгаллимнәргә хөрмәт, олы¬лау хисләре тәр¬бияләү үзәккә куелган. Гаилә балаларда ту¬ган теленә, туган төбәгенә, үз халкына, җир-суына, хезмәткә мәхәббәт тәрбияләгән. Бу - халыктагы әхлак сый¬фатларының иң бөеге.

Борынгы әдәби әсәрләр аша укытучылар балаларга ата-анага кадер-хөрмәт, гыйлемгә омтылу, күркәм эшләр башкару, кешелекле, шәфкатьле булу сыйфатларын иңдергәннәр. Бу сыйфатлар әхлак тәрбиясе алган кешеләргә генә хас.

Балаларга әх¬лак тәрбиясе бирү бүгенге көндә дә бик актуаль мәсьәлә. Хәзерге тормышта күп кенә гаиләләрдә ата-ананың баласына вакыты җитми. Ата-ана баланы үстерер өчен акча эшли. Бала игътибар, җылылыкны урамнан, телевидение, интернеттан эзли. Менә шул шартларда, бернигә дә карамастан, зур сабырлык белән укытучы укучыларга әхлак тәрбиясе бирергә тиеш була. Укытучы балаларны укы¬та, үз предметын, татар теле һәм әдәбият дәресләрен әхлак тәр¬биясе коралы итеп ала. Чынбарлыкта тел дәресләре тәрбияви ма¬териалларга бик бай.

Мин үземнең чыгышымда Муса Җә¬лил иҗатына мөрәҗәгать итәсем килә.

Муса Җәлил әсәрләрендә әхлаклылык мисаллары искиткеч күп. Аның тормышы, илебезне сөюе - югары әхлак үрнәге. Муса Җәлилне - герой-шагыйрьне,Советлар Союзы Героен белмәгән укучы юктыр. Әсирлектә, образлы итеп әй¬ткәндә, "палач балтасы астын¬да" шигырь язучылар аз бул¬маган. Җәлилчеләр төркемендә дә һәркем — шагыйрь. Абдулла Алиш, Абдулла Баттал - инде та¬нылган әдипләр буларак су¬гышка китә. Әхмәт Симаев - сугышка кадәр газета хезмәт¬кәре, Гайнан Курмаш – барысы да иҗат кешеләре. Алар бергәләп лагерь¬да гәзит чыгаралар, концерт¬лар куялар.

Муса Җәлил шундый катлаулы шартларда түземле ши-гырьләрен туган илгә, дусларына багышлап, тирән мәгънәле итеп иҗат иткән.

Һәрбер¬сенең кешелек сыйфатларын, эчке рухи дөньясын ачуга буй¬сындырылган сурәтләү чара¬лары: халык иҗатыннан алынган традицион образлар, табигать күренешләре, иҗа¬ди эшкәртелеп алынган мәкаль һәм әй¬темнәрне шагыйрь үз әсәрләрендә кулланган. Муса Җәлилнең кайбер шигырьләре фашизмга, коллыкка, сатлык¬лыкка нәфрәт, протест булып яңгыраса, башкалары үзенә генә билгеле эчке кичереш белән сагы¬ну, сөюне тәсвирлый, кайберләре— горур¬лану, өмет яки ышаныч, көтү булып ишетелә һәм һәр шигырь¬нең күңелдә уелып калуына сәбәп була. "Җырларым", "Ышанма", "Кошчык", "Ба¬тырлык турында", "Вәхшәт" һ.б. шигырьләре безнең күңелләрдә җырлап, чыңлап торалар. Бу шигырьләр тоткынлык шар¬тларында да гәзит битләрен¬дә язылып, яшерен укылып, әсирләргә Кеше булып калырга, кеше¬лек горурлыгын, илгә тугры-лыклы булу хисләрен саклап калырга, оешып, хәзерләнеп, ирек өчен көрәшкә күтәрелер¬гә ярдәм иткәннәр. Муса Җәлилгә көрәшергә, талантлы шигырьләр иҗат итәргә, нык ир-ат булыр¬га да мөмкинлек биргән ба¬тырлык әсирлек шартларын¬да гына тумый. Батырлык — Җәлилнең кечкенә вакытыннан ук формалашкан ха¬рактерының төп сыйфаты. Үзе бала вакытында ук “Кечкенә Җәлил” кушаматы астында шигырь язулары, Мәскәүдә укыганда балалар өчен жур-нал чыгаруын, анда эшче та¬тарлар өчен клубта кичәләр оештыруын, Казанда төрле-төр¬ле нәтиҗәле эшчәнлекләр алып баруын укучыларга да җиткерү кирәк. Шагыйрьнең җаваплылык хис¬ләре Бөек Ватан сугышының гаять кырыс, чы¬дый алмаслык сынауларында бөтен тулылыгы белән ачы¬ла. Муса Җәлил шигырьләре - поэтик үрнәкләр генә түгел, Кешенең сынмас рухы, бет¬мәс-төкәнмәс көче, аңлап һәм аңлатып бетерүе кыен булган талантлылык, киеренке иҗа¬ди хезмәт үрнәкләре дә.

Дәһшәтле сугыш кырында алып барылган хәрби бурыч һәм канлы сугыш ситуациясе кар¬шылыгында калган солдат, бәлага тарыган бала, солдат күкрәгендә сабый сулкылда¬вы... Герой хисләре бер-берсен кискен алыштырып торалар. Шул хисләрнең әхлакый асы¬лын укучыларга ачу, аларда ки¬черешү хисләре булдыру - укы¬тучының җитди бурычы.

Кыска гына итеп әйткәндә, әдәбият дәресләрендә укылган һәр әсәр, билгеле бер эзлеклелек һәм система белән файдаланылган методик алымнар укучыларны герой образында реаль әхлаклы кеше итеп күрергә күнектерә¬ләр һәм эстетик зәвыклы әдә¬бият сөючеләр тәрбиялиләр, әхлакый сафлык хисләрен ка¬милләштерүгә ярдәм итәләр.

## Балаларда табигатькә сакчыл караш тәрбияләү

***Латыйпова Наилә Нәбиулла кызы, татар теле һәм әдә-биятыукытучысы, Нурлат районы Бикүле төп мәктәбе.***

“Без барыбыз да Җир дип исемләнгән корабль пассажирлары, димәк каядыр күчеп утырырга урын юк. Әгәр дә кешелек табигать белән килешә алмаса, тузан белән капланган Җир өстенә: “Һәркем үзе өчен бары яхшысын гына теләде,”- дип кабер ташы кую хаклы булачак”,- дип язган Антуан де Сент – Экзюпери.

Без тормышыбыз белән планетабызга, диңгез – океаннарга, серле урман-нарга, саф сулы чишмәләргә, сайрар кошларга, иксез-чиксез далаларга бай булган, әмма авыртудан ыңгырашучы, ярдәмгә чакыручы һәм, ни кызганыч, Кеше алдында баладай яклаучысыз булган матур һәм бердәнбер Җир – ана-бызга бурычлы . Шуңа күрә дә табигатьне саклау,балаларга экологик тәрбия бирү иң зур проблемаларнын берсе булып тора. Чөнки сулаган һавабыз, эчкән суыбыз пычрана, урманнар киселә. Тирән сулы елгалар саега-кибә, яшел болыннар юкка чыга. Бу хәл һәркемне уйландыра, шуңа күрә без бөтен көчебезне табигатьне саклауга, экологик хәлне яхшыртуга юнәлтергә тиеш . Табигатьнең бөтенлеге, киләчәге кеше кулында. Серле табигатьне, зур дөньяны ничек сакларга? Тәрбия эшен бала кечкенә чагында ук башуларга кирәк. Менә шушы проблемалар мине үз дәресләремдә, сыйныф сәгатьләрендә укучыларымда табигатькә карата сакчыл караш тәрбияләүгә этәрде.

Милләтебез элек-электән табигатькә сакчыл булырга кушкан. Бу аның мәкаль-әйтемнәрендә, әкиятләрендә, йолаларында, мифларында чагылыш

тапкан. 5 сыйныфта бу жанрларны өйрәнгәндә, экология проблемасы күтәрелгән бу әсәрләргә дә басым ясала, аларның мәгънәләре буенча әңгәмәләр үткәрелә. Мәсәлән, “Урманга шырпы белән бармыйлар”, “Хайваннарны кыерсытма, үзеңә килер”, “Сыерчыкларга оя яса – эшең уңар”, “Бер агач кисәрдән элек, ике агач утырт” кебек мәкальләр укучыларга экологик тәрбия бирә.

Татар халкының йолаларында да җир-анага сакчыл караш чагылыш тапкан.

Һәр ир-егет өй төзү, бала үстерү белән бергә агач утыртырга тиеш булган. Йорт тирәсендәге җимеш агачларын кисүдән курыкканнар, йорт тирәсенә тирәк агачы утырту макталган, ишек төпләренә миләш, балан агачлары утырту бәла-казалардан саклый дип ышанганннар. Коеларны күмү, чишмәләрне томалау бэхетсезлек китерә дип ышанганннар, шуңа сулыкларны саклаганннар, коеларның өсләре һәрвакыт ябулы булган, кое казучылар, чишмә юлын ачучылар хөрмәтләнгән.

Табигать, аның матурлыгына дан җырламаган бер генә язучыны да, бер генә шагыйрьне дә очратып булмас иде.Ләкин алар матурлыкка дан җырлап кына калмыйлар, әсәрләрендә кешеләрнең җиргә, туган туфрагына мөнәсәбәтен дә тасвирлыйлар. Мондый әсәрләрне өйрәнү дә укучыларда табигатькә сакчыл караш тәрбияли.

Табигатьнең без күреп җиткермәгән серләре күп, ә матур әдәбият безгә шуларны ачык күрергә, тоярга, эчке мәгънәсен табарга ярдәм итә, җир-су, урман –кырларның байлыгын акыл белән файдаланырга кирәклеген кисәтә, кошларга, үсемлекләр һәм хайваннарга карата миһербанлы булырга чакыра.

Мирсәй Әмирнең “Озын-озак балачак” әсәрендә сандугач баласы түгел әле дип очарга өйрәнүче саесканга таш бәргән малайга дусты Әсгать : “*Саесканга да үз баласы газиз. Аның да эчендә җаны бар. Бөтен нәрсәләрнең дә җаннары бар – агачларның да, ташларның да, үләннәрнең дә... Җаннары булмаса, яшәрләр идемени алар? Безнең бармак киселсә, кызыл кан ага, агач ботагын кырыксалар, ак кан ага,*” – ди.

Г. Ахуновның 1958 нче елда язылган “Артышлы тау буенда” повестенда Татарстанда нефть чыгару эшенең башлангыч чоры сурәтләнә. Әсәрдә Артышлы тау буендагы бик матур табигатьле, мул сулы, балыклы күлләре, чәчәкле болыннары булган Кәлимәт авылы сурәтләнә. Нефтьчеләр килгәч, матур кына яшәп яткан авылның тынычлыгы югала. Су пычрана, балыклар бетә, урамнарда чирәм актарыла, ә факел кабызгач, авыл өстеннән “төн кача”. Язучыны бу хәл борчый, ул табигатькә саксыз карауның зарары турында кисәтә.

Мөхәммәт Мәһдиевнең “Без – 41 нче ел балалары” әсәрендә хикәяләүче-нең зур сулы, чишмәле авыллар турында уйланулары бирелә. “*Авылда су кибү – зур эш. Моны бөтен тереклек авыр кичерә. Дөрес, эчәргә су бар. Авылның өч-дүрт җиреннән менә дигән чишмәләр чыга. Әмма инештә зур су кипкәч – Гыйззәтуллинның сынаганы бар – халыкның табигате бозыла, кеше үзеннән - үзе холыксызлана.”* Бу әсәре белән автор күлләрнең, инеш – елгаларның кеше өчен кирәклеге турында сөйләп, суның тереклек өчен әһәмиятен аңлата, чишмәләрнең , елгаларның кадерен белергә дә чакыра.

“Туган ягым – яшел бишек” әсәрендә Г. Бәширов татар халкының кошларга, җиргә мөнәсәбәтен тасвирлау аша экологик тәрбия бирә. Бу әсәрләр барысы да табигатькә карата сакчыл караш тәрбияли, аның какшамас кануннарын аңлата. Аларны өйрәнү аша балалар күңеленә матурлык һәм мәрхәмәтлелек орлыклары чәчү, битарафлыкны җиңү, нәниләрне табигатьне саклаучылар итеп тәрбияләү – безнең изге бурыч.

Кулланылган әдәбият

1. “Татар әдәбияты тарихы” 6 нчы том Казан. “Раннур” 2001
2. “Татар балалар шигърияте” ТаРИХ. 2004
3. “Татар балалар әдәбияты” ТаРИХ. 2003
4. Татар балалар әдәбиятыннан хрестоматия 2 нче том Казан 2011
5. Р. Шәймарданов “Татар милли педагогикасы” “Мәгариф” 2007

**Татар әдәбияты дәресләрендә экологик проблема**

*Мельникова Ләйсән Сәхибетдин кызы,*
*“Яңа Мажын төп гомуми белем мәктәбе”*

Туган илебез зур һәм гаять матур. Бездә челтерәп аккан чишмәләр дә, калын-калын урманнар да, тирән сулы елгалар да күп. Безнең табигатебез шундый матур, чәчәкле, гүзәл,бай. Шушындый табигатьтә яшәвебезгә без бик шат һәм аны шушы хәлдә саклаган өчен эти-әниләребезгә,әби- бабаларыбызга рәхмәтле.

Без дә үзебездән соң киләчәк буынга аны зарарламый, тагын да ямьлерәк итеп калдырсак иде. Әйләнә -тирәбездәге табигатьнең матурлыгы һәм муллыгы югалмасын, челтерәп аккан чишмәләре кипмәсен, җир өсте чәчәккә күмелсен, кошлар сайрасын, елгаларында аккошлар йөзеп йөрсен дисәк, үзебезгә күп көч куярга, шуңа омтылып яшәргә кирәк. Кылган гамәлләребез өчен киләчәк буын алдында йөзебез кызарырлык булмасын.

Табигатьне саклау - һәр кешенең изге бурычы ул. Безнең тормышыбыз табигать белән тыгыз бәйләнгән. Әгәр без һаваны, суны агулап, урманны корытып бетерәбез икән, димәк без үзебезнең киләчәкне юк итәбез дигән сүз. Табигатьне күз карасы кебек сакларга кирәк. Шуңа күрә,без – укытучылар, балаларны табигатьнең матурлыгын күрә белергә өйрәтергә, тырнак очы кадәр генә бөҗәкнең дә бу җирдә яшәргә хаклы булуына төшендерергә тиеш.Моңа өйрәтү өчен тәрбия сәгатьләре генә җитми. Бу очракта безгә әдәби әсәрләр, шигырьләр ярдәмгә килә. Һәр сыйныфта татар әдәбиятыннан Татарстан табигате турында бүлекләр бар. Балалар алардагы әсәрләрне өйрәнеп,елдан ел үзләренең күзаллауларын киңәйтәләр.Башлангыч сыйныфларда Җ.Тәрҗемановның “Табигать китабы” шигыре,”Чирик” хикәясе, Г.Лотфиның “Үкенүдән файда юк” хикәясе, Р.Фәйзуллинның “Табигать кочагында” шигырьләре безгә балаларда туган ил табигатенә сакчыл караш, кошларга һәм җәнлекләргә карата мәрхәмәтлелек тәрбияләргә ярдәм итсә, зуррак сыйныфларда Г.Тукайның “Су анасы”, “Шүрәле”се, М.Җәлилнең

“Чәчәкләр” шигыре,Ф.Яруллинның “Хәтерсез күке” әсәре, Н.Гыйматдинованың “Болын патшасы” әсәре, Г.Ибраһимовның “Алмачуар”ы, Ә.Еникинең “Туган туфрак” хикәясе, Г.Бәшировның “Язгы сабан туйлары”әсәре, Г.Кутуйның “Сагыну” нәсере, Г.Бәшәрнең “Авыру урман” шигыре һәм башка бик күп әсәрләр, балалардан туган иленең табигатен яратучы, аның белән горурланучы, аның турында кайгыртучы кешеләр тәрбияләүдә, безгә ярдәмгә килә.

Без дәресләрдә туган ягыбыз табигате, экологик проблемалар турында да сөйләшәбез, төрле әсәрләрдән һәм шигырьләрдән мисаллар китерәбез.Миңа үзебезнең якташ шагыйрәбез Энҗе Авзалованың “Бу гүзәллек яшәрме?” шигыре бик ошый. Анда менә нинди юллар бар:

“Җир елый, ишетәсезме?
Мин ишетәм!
Челтерәп аккан чишмәләрем
Нигә кипкән?
Табигатьне кемнәр шулай
Әрәм иткән?
Кешеләрдә миһербанлык
Кая киткән?”

Чыннан да, ташландык чишмәләрне, тегендә-монда түгелгән тирес һәм чүп өемнәрен күреп, күңел әрни. Шул ук Энҗе Авзалованың тагын бер шигыренә тукталасым килә,ул “Белмим, нәрсә белән бетәр”дип атала.

“Чикләвеге,шомырты да, баланы да-
Санап бетерерлек түгел...
Кешеләрнең табигатькә ерткычлыгын
Гафу итә алмый күңел.
Агачларны таптый, кисә,
Җәнлекләрне атып китә.
Бу кадәре начарлыклар
Белмим, нәрсә белән бетәр?”

Әйе,бик дөрес.Бу проблемалар чыннан да бар. Безнең табигатебезгә куркыныч яный. Туган илебезнең чиста сулы елга һәм күлләрен пычрату,очсыз-кырыйсыз урманнарын бер мәгънәсезгә кисү, химия заводларының агулы газлары белән чиста һавабызны бозуы – болар хәзерге цивилизациянең туган ягыбыз табигатенә салган зыянның бер өлеше генә.Табигатьне пычратучылар белән көрәшне без бүгеннән үк башламасак, берничә дистә елдан соң әйләнә-тирәбезнең шыр-ялангач калуы мөмкин. Шуңа күрә, бүген табигатьне саклау дөньякүләм проблемага әйләнә.Бу проблеманы чишүдә һәр кеше үзеннән өлеш кертсә генә, без табигатебезне саклап кала алачакбыз. Әнә бит, Резеда Вәлиева да үзенең “Ана сүзе” шигырендәге сүзләр белән кешеләрне кисәтә.

“Онытма, туган җир бер генә,

Кадерләрен аның бел генә..

Дәвала аның һәр ярасын,

Син бит соң,табигать баласы!”

Табигатьне саклау эше бездә ничек башкарыла соң? Хәзер табигатькә куркыныч янавын бөтен халык аңлады. Шуңа күрә илебездә табигатьне саклау чараларын күрә башладылар. Мәсәлән, күп кенә завод - фабрикалар яңача җиһазландырылды. Һәм алар әйләнә - тирәне азрак пычрата башлады. Киселгән урманнар урынына яңалары утыртыла. Сирәк очрый торган үсемлекләрне җыю, хайваннарны аулау тыела. Тыюлыклар булдырыла һәм аның табигате сак астына алына. Без дә, укучыларыбыз белән, кулдан килгәнчә булышырга тырышабыз: юл буйларында утыртылган посадкаларны чистартабыз, өйләребез янына миләш, балан, алмагачлар утыртабыз. Яз-көз авылыбыз тирәләрен чүп-чардан чистартабыз. Дәресләрдә Кызыл китапка кертелгән үсемлекләр,җәнлекләр турында өйрәнәбез. Чыннан да, табигатебезне саклау безнең үзебездән тора. Сүземне Фәнис Яруллинның “Рәнҗемәсен” шигырендәге сүзләре белән тәмамлыйсым килә.

“Табигать ул үзен яклый алмый

Үч тә ала алмый кешедән.

Ул бары тик рәнҗи генә ала

Куркыйк шушы рәнҗеш төшүдән.”

## Габдулла Тукай иҗатында әхлак тәрбиясе.

*Алабуга муниципаль районы*
*“10 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе”*
*ГБМБУ татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
*Минһаҗева Рәмзия Марс кызы*

Ишеттем мин кичә : берәү җырлый.

Чын безнеңчә матур, милли көй;

Башка киләэ уйлар төрле-төрле-

Әллә нинди зарлы, моңлы көй,-дип язды татар халкының бөек шагыйре Г.Тукай

Бөек халыкның бер улы буларак , Тукайны милләт мәсьәләсе борчыган.Ул телебезне саклап калу өчен көрәшкән.Тукай үзенең гомерен, тормышын, яшәешен милләт язмышы белән бәйләгән.Билгеле, милләт мәсьәләсе, тел язмышы бүгенге көндә дә иң зур проблемаларның берсе. Без укучыларыбызда туган телебезгә хөрмәт, мәхәббәт тәрбияләргә тиешбез.Сөекле Тукаебыз да заманында телебезне хөрмәтләп, яратып: “И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле! Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы”,-дип язган.Газиз туган телебез турында моннан да матуррак итеп әйтеп буламы соң инде. Шагыйрьнең милләтне артка сөйрәүчеләрне , наданнарны шәпләп тәнкыйтьли торган үткен каләме була.Г.Тукай милләтнең белемле, алдынгы карашлы, әхлаклы булуын тели. Дәресләрдә “Эшкә өндәү”,”Туган авыл”, “Бәхетле бала”, “Кошларга”, “Карлыгач”, “Бала белән күбәләк”, “Кызыклы шәкерт”, “Сабыйга” шигырьләрен яратып укыйбыз. Шагыйрь балаларны эш сөяргә, белем алырга, яхшы укырга, хайваннарны, кошларны сакларга,табигать матурлыгын күрә белергә чакыра.Әдәбиятыбызның чишмә башы булган Тукай иҗаты тулысы белән милләт язмышына багышланган дисәк тә хата булмас, чөнки ул – халык улы, аны халык үстергән.Г.Тукай әдәби тәнкыйтьче,

публицист, әдип буларак, туган халкының язмышын уртаклашкан, куанычына сөенгән, фаҗигасенә тетрәнеп җырлаган.

Тукай Казанга зур өметләр белән килә, Казанда мәгърифәт нуры күрергә өметләнә, милли моңнар ишетергә тели.Ул татар милләтенең мәгърифәт юлыннан китүенә, ирек алачагына ышана иде. Өметләре акланмый, һәм шагыйрь бу турыда ачыктан-ачык әйтә:

Кайчан соң , и факыйрь милләт, бәһарең!

Кайчан китәр кичең , килер кәһарең?- дип , халкы өчен якты көннәр килүен тели.Г.Тукай күрсәткәнчә, халык үзенең бәхетен тату, дус булып, бер максатка бердәм барганда гына таба ала.20 яшьлек шагыйрь татарның таркаулыгын зур кимчелек итеп күрсәтә.Г.Тукай татар халкына ирек даулый.Без бу фикерне "Китмибез!" шигырендә күрәбез.Наданлыкта яшәгән халыкны иреккә чыгару мәсьәләсен күтәрү- шагыйрьнең төп темасы.Татарлар иреккә чыксын өчен, Россия үзе ирекле булырга тиеш, дип исәпли шагыйрь."Хөр мәмләкәт-хөр Русия"- аның идеалы.

"Шүрәле" поэмасы да бик үзенчәлекле.Шүрәле- халкыбыз әкиятләрендә сөйләнә торган мифик образ.Әсәрнең мәгънәсе тирән, туган илгә, туган якка мәхәббәт хисләре белән тулы.Шагыйрь туган җирнең газизлеге, Кырлай авылы, урманының матурлыгы турында сөйли.Ул туган якны борынгы бабайларыбыз яшәгән урын буларак та якын иткән."Шүрәле" әсәрендә Кырлай урманында Былтыр исемле егет Шүрәле белән очраша, көч сынаша.Язучы "былтыр" сүзен каршылыкка китерә һәм ике мәгънәдә яктырта, кеше исеме һәм үткән ел.Бу алым Шүрәленең аңгыралыгын, көлке хәлендә калуын күрсәтү өчен уңышлы кулланылган.Шүрәле –дошман, ләкин әллә ни куркыныч түгел.Ул егеткә үчле түгел, янамый да, куркытмый да.Ул, көлә-көлә генә башкаларга зыян китерүче кешеләрнең берише, хәйләкәр.Шулай итеп,шагыйрь , авыл, урман матурлыгы белән янәшә дошманны куя. Матурлыкка явыз көч, ямьсезлек каршы куела.

Ачыла алдында тарихтан театр пәрдәсе,

Аһ,-дисең, без ник болай соң?

Без дә Хакның бәндәсе.

Бу сүзләр белән шагыйрь безне йокыдан уятып җибәрә.Әйе безнең дә башка милләтләр кебек яхшы яшәргә хакыбыз бар.”Без ник болай соң? дигән сорау борынгы тарихыбызга кагыла, бабайларыбыз көчле дәүләт булып яшәгәннәр, даннарга ия булганнар.Урманның чиксезлеге шагыйрьнең хәтеренә борынгы бабаларыбызны искә төшерә.Аларның куәте белән үзе яшәгән чордагы татарлар белән чагыштырып карый да, Тукайның йөрәге әрни.Шагыйрь күңелендә туган илен ярату хисе тормыш гаделсезлеге тудырган хәсрәт хисе белән берләшә.”Шүрәле” поэмасына шул күзлектән чыгып анализ ясарга мөмкин.Былтыр, Шүрәле-халык, милләт.2 катлам вәкиле сурәтләнгән.1 нче катлам вәкилләре- Шүрәлеләр, мескен, изелгән, буйсынган, беркатлы, ышанучан гади халык, урман сарыгы. 2 нче катлам вәкилләре - Былтыр образында-батыр, хәйләкәр. Башы эшли.Аның төп кимчелеге- үз мәнфәгатьләрен генә кайгырту.Тукай татар халкының бетеп баруын аңлата.Татарның кыю йөрәкле батыр уллары үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртып яшиләр, шуңа күрә татар милләте алга бара алмый.

20 нче гасыр башында халык бик кечкенә булып яши.1908 нче елда талантлы шагыйрьнең каләменнән чыккан “Су анасы” әсәрендә әхлак тәрбиясе күтәрелә.”Татар милләтенең алга китә алмавының төп сәбәбе – милләт аналарының балага дөрес тәрбия бирмәвендә,малайның урлавына күз йомуында” дигән фикер үткәрелә , шагыйрь балаларга әхлакый тәрбия бирергә чакыра.Г.Тукай үзенең язмышын, бәхетен һәм бәхетсезлеген татар милләте язмышы белән бәйли.Милләтебезне алга киткән башка халыклар рәтендә күрү-Тукайның бар теләге.

Бар уем кичен-көндезен сезнең хакта, милләтем;

Саулыгың- минем саулык, авыруым- минем авыруым,- ди ул.Г.Тукай-халкыбызның таянычы, горурлыгы, йөз аклыгы, якты һәм мәңге балкып торачак кояшы ул. Җидееллык иҗат гомерендә татар халык шагыйре дәрәҗәсенә күтәрелгән Тукай әнә шулай милләт җанына мәңгелеккә береккән затлы шәхес булды.Тукай рухы яшәгәндә,Тукай моңнары чыңлаганда, Тукай

сүзе җанда кайтаваз алганда, татар милләтенең ерак киләчәккә ниятләгән сәфәре ышанычлы да, якты да , күркәм дә булыр.

Кулланылган әдәбият:

1. Заһидуллина Д.Ф.Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы.-Казан:Мәгариф,2004.-367 б.

2. Нуруллин И. Моңлы саз чыңнары: Документаль роман. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2000.-272 б.

3. Тукай Г. Сайланма әсәрләр. Шагыйрь турында истәлекләр.– Казан: Татарстан Республикасы «Хәтер» нәшрияты, 2002.-511 б.

## Якташыбыз Амур Фәләх иҗатында XXI гасыр проблемалары

***Минһаҗева Р.Ә, Кәрамова А.Җ.***
***татар теле һәм әдәбияты укытучылары***
***ДАҺБУ «Яр Чаллы педагогия көллияте»***

XXI гасыр башында үткен фикерләре белән сискәндерә, гаҗәпләндерә, әдәби осталыклары белән сокландыра торган язучылар Яр Чаллы төбәгендә шактый. Алар арасында Вахит Имамов, Факил Сафин-Әмәк, Айдар Хәлим, Фәүзия Бәйрәмова, Айгөл Әхмәтгалиева, Зифа Кадыйрова, Амур Фәләх һәм башкалар.

Амур Фәләх үзенең күпсанлы мәкаләләрендә, әдәби әсәрләрендә көндәлек тормышта тирән тамыр җәйгән эчкечелек, наркомания кебек тискәре күренешләргә карата чаң кагучы, милли менталитетыбызны, күркәм әхлакый сыйфатларыбызны саклап калу өчен зур көч куючы әдипләр сафыннан. Бу тенденция аның «Таш бәгырь» (2004) дип аталган беренче проза әсәрләре җыентыгыннан ук башлангыч ала.

«Таш бәгырь» повестенда язучы һәр герой-персонажның эчке дөньясын, күңел кичерешләрен көндәлек вакыйгалар чылбырына оста ялгап, тәэсирле сурәтләр белән XXI гасыр башы яшьләре язмышы белән тыгыз мөнәсәбәттә яктырткан.

Әсәр, замана егетләребезнең башына җиткән Чечен сугышы вакыйгаларын сурәтләүдән башланып китә. Кайнар ноктага эләккән өч егет комендант сәгате вакытында Шамил урамын күзәтәләр.  Кануннар бик кырыс.  «Бу – сугыш! Син үтермәсәң, сине үтерәчәкләр. Икенчедән, боерыкны үтәмәсәң – трибунал!» [2, 8 б.].

Повестьның исеменә килгәндә, әсәрдә таш образы символик мәгънәгә ия һәм ул сюжет төзүдә мөһим деталь булып, әсәргә үзенчәлекле тон бирүче дә, һәм җәмгыятебезгә «таш» рәвешендә кереп урнашкан замана проблемаларына ишарә дә булып тора.

Физкультура институтының дүртенче курсыннан Россия армиясенә алынып, Чечняга юлланган Әмир бу сугышта үзенең тәмам хокуксызлыгын, вәхши боерыклар алдында көчсез булуын, кеше гомеренең берни тормавын күрә. Аның бу каһәрле дөньяга: «Таш бәгырьле без, кешеләр! Каткан җанлылар!» дип кычкырасы килә

Әсәрнең төп каһарманы Әмирне өенә, вакытлы ялга кайткач та гаделсезлек ләр сагалый гына тора. Туган нигезендәге хәлләрне күргәч, егетнең йөрәге өзгәләнә: сеңелесе Ләйлә Газинур исемле егет аркасында көчләү-мәсхәрәләүгә дучар булып, аздан гына дөнья белән хушлашмый калган, нәтиҗәдә, акылга зәгыйфьләр хастаханәсенә эләккән. Иң зур кайгы – унынчыда укучы энесе Хәмитнең наркоманга әверелүе. «Упкын! Бар кешелек упкынга таба тәгәри. Менә газета-журналлар, телевидение аша үгетлә син ул яшьләрне! Файдасы бармы сон?» [2, 20 б.]. Әмир үзе ишеткәннәренә үзе ышанмады, ләкин дөресе шул иде.

Наркомания – замана чире! Әйе, җитте ул заман. Тирә-ягыбызны тәртипсезлек, әдәпсезлек, бозыклык, шәфкатьсезлек, битарафлык чолгап алган. Эчүчелек, тәмәке тарту көннән-көн киңрәк колач җәя. Наркомания, СПИД корбаннары көнләп түгел сәгатьләп арта. Иң куркынычы: бу начар гадәтләр күп очракта яшьләрне, әле мәктәпне дә тәмамламаган үсмерләрне йота.

Хезмәт итә торган җирендә дә упкын, өендә дә мәшхәр Әмирнең. «...Пычрак дөнья! Вәхшиләр, таш бәгырьлеләр дөньясы... » [2, 46 б.]. Ләкин, бар

нәрсәнең асылына төшенергә күнеккән Әмир, энесе Хәмитнең үлеменә Газинур (Газон) гаепле булганын ачыклый. Ул Газинур Чечняда «махсус төркем» составында булып, Әмирләрне газаплаган, якын дусты Азатны да үтергән булып чыга. Ә бит таш бәгырьлегә әйләнгән башкисәр Газинур әүвәл яхшы яктан гына характерлана: үрнәк гаиләдә үскән, спорт белән шөгыльләнгән, наркоманиягә бөтен җаны-тәне белән каршы булган, әфьюнчы очратса, аны канга батырып бетергәнче кыйный торган булган. «Әйе, Борис абыйсы аңа нәкъ менә наркотик сату, клиентлар табу эшен тәкъдим итте... Нәкъ менә күршесе Юра кебек наркотик колына әверелгән мескеннәр, гөнаһсыз яшүсмерләр сәламәтлеге, ата-аналарның кайгы-хәсрәтләре бәрабәренә мул тормыш... Газинур бераздан наркотик сатучы булып китте» [2, 41 б.]. Бу кеше упкынга әнә шулай килеп эләгә.

Әмирләр гаиләсен күп газапларга салган, дусты Азатны җәзалап үтергән Газинурның үз-үзен тотышында гаебен тану дигән нәрсәнең эзе дә булмавы егетнең тәмам ачуын чыгара. Нәфрәте чиктән ашкан Әмирне инде бернәрсә дә туктата алмый ... Ул аны үтерә...

Әйе, якты дөньядагы гаделсезлекне, вәхшилекләрне, пычраклыкларны үз күзләре белән күргән һәм үз башыннан кичергән егетне киләчәк куркытмый иде... Хезмәттәш дусларына вәхши Газинур турында хәрби дөреслекне ачкан Әмир рота командиры тарафыннан атып үтерелә һәм әсәр башында сурәтләнгән мәйдандагы ташка сөялеп, җан бирә.

Г.Тукай премиясе лауреаты Вахит Имамов Амур Фәләхнең бу әсәре хакында болай дип язган: «Бүгенге Рәсәй хакимиятенең, армиясенең, гомумән, системасының чын йөзен күрәсең килә икән, ач та укы» [1, 43 б.]. Тарихның серле битләре, бездән яшерергә теләгән ачы хакыйкать шушы түгелме?! Ә бит бу сугыш күпме егетләребезнең яшь канын эчте, күңелләрен җәрәхәтләп, таш бәгырьлеләр санын арттырды.

Повестьны укып чыккан һәр кеше, мөгаен, шаккату тулы тетрәнү кичергәндер. Амур Фәләх бүгенге яшьләр өчен актуаль темаларны бар киеренкелеге белән күтәреп чыккан: эзмәвердәй егетләребезнең гомерләрен

кисүче, илнең иминлеген какшатучы ике афәт − гади халык өчен бөтенләй кирәге булмаган сугышлар һәм яшь буын кереп баткан төпсез сазлык – наркомания.

Повестьтан күренгәнчә, тормышта үз урынын эзләүче яшьләрне күптөрле авырлыклар, киртәләр еш сагалап тора. Без, мөгаллимнәр, укучыларга тәрбия сабаклары биргәндә, якташ әдипләребезнең тәрбияви әһәмияткә ия әсәрләрен укучылар күңеленә җиткерә алсак иде.

Әдәбият

1. Имамов Вахит. Амур Фәләх // Мәйдан. – 2003. − № 3. – 43-48 б.

2. Фәләх Амур Таш бәгырь: Повесть. новелла, хикәяләр. – Казан: Татар кит.нәшр., 2004. – 127 б.

## Г. Ибраһимовның «Диңгездә» хикәясен өйрәнү тәҗрибәсеннән

***Минһаҗева Р.Ә, татар теле һәм әдәбияты укытучысы***
***ДАҺБУ «Яр Чаллы педагогия көллияте»***

Нәкъ бер айдан күренекле шәхес, XX гасыр башы татар Яңарыш әдәбиятының нигез ташларын салучы, Ауропа һәм рус әдәбиятларының модерн күренешләрен Шәрекъ әдәбияты традицияләре белән синтезлап, татар әдәбиятына кертеп җибәрүче язучы Г.Ибраһимовның тууына − 130 ел.

Билгели ки, Г.Ибраһимовның да «табигать һәм кеше» мөнәсәбәтенә үзенчәлекле карашы, төпле позициясе булган. Татар мәктәпләренең X сыйныфында Г. Ибраһимовның башлангыч чор иҗатында романтизм концепциясен һәрьяклап чагылдырган «Диңгездә», «Яз башы», «Сөю-сәгадәт» хикәяләре аша әлеге мәсьәләсенең куелышын өйрәнү максаты куела.

Дөрестән дә, XX йөз башы татар әдәбиятында кешенең рухи дөньясын, күңелендәге эчке каршылыклар көрәшен ачып бирүдә иң отышлы юнәлеш романтизм булган. Г. Ибраһимов иҗатында без шәрекъ, аурупа, шул исәптән рус романтизмының йогынтысын күзәтә алабыз.

Мәсәлән, Г. Ибраһимовның башлангыч чор иҗатына караган «Диңгездә» хикәясендә без XVIII йөз әдибе Ж.-Ж. Руссодан башлангыч алган романтик традицияләр белән очрашабыз.

Тормыш гармониясен табигатьтән эзләү – хикәя героен табигать кочагына – диңгезгә чыгарган төп сәбәп. Ул, шәһәрдән ерагайган саен, табигать белән соклanудан туган халәтен Ж.-Ж. Руссо каһарманы Сен-Пре кебек аңлата: «Диңгезгә кереп югалу белән, үзеңдә акрын, ләкин тирән бер рәхәтлек сизенә башлыйсың... Тән басыла, рух җиңеләя, күңел киңәя, йөрәкне әрнеткән авыр кайгылар үзеннән үзе эриләр, таралып, каядыр югалалар» [ 68 б.]. Әйе, романтик каһарманыбыз нәкъ менә табигатьтә генә үзенең уй-хыяллар дөньясына чума, кеше яшәешенең табигый хасиятен ача, сыкранган җанына ямь-дәва табарга сәләтле. Әсәрдә табигать күренешләре хыялдагы гүзәл илаһи дөнья, күңел көзгесенә, җан пейзажына әверелә.

Язучы табигать сурәтләрен тәэсирле шигърият көче белән, музыкага тартым итеп кенә биреп калмый, ә үзенә бер символ рәвешенә китерә. Мәсәлән, романтиклар яратып тасвирлый торган символик образ диңгез төрле төсләргә һәм халәтләргә керә. Ул аның тыныч ягын да, җил давыллы, яшенле, ярсыган чагын да күрсәтә. Диңгез – романтик әдәбиятта мәңгелек хәрәкәт, гомер агышы, үзгәреш символы. Кеше белән чагыштырганда, диңгез ирекле, ул җир әсире түгел. Диңгез кеше җанының идеалга булган мәңгелек омтылышын тасвирлый.

Татар әдәбиятында маринистик жанрны нигезләүче буларак, Г. Ибраһимов диңгез образының бар киңлеген һәм бөеклеген күрсәтә: күгелҗем шома диңгез; бөек диңгез; куркынулы диңгез; көмеш төсле; нурлы айлар белән зиннәтләнгән олы күзге кебек диңгез; иге-чиге булмаган диңгез; тын, авыр, куе диңгез. Хикәядә романтик идеаль дөнья үзенең ассоциатив чагылышын шулай ук күк, йолдызлар, ай кебек шәрекъ романтизмыннан килгән символик образларда да таба. Аларны сурәтләгәндә Г. Ибраһимов «якты, җылы» буяулар палитрасын кызганмый. Мәсәлән: Күк йөзе – ачык; нурлы, киң; сөеп, иркәләп елмая торган. Йолдызлар – нурлы; миллионнарча; алар арталар, күбәяләр, шул хәлгә җитәләр ки, бөтен күк йөзе якты алмаз белән зиннәтләнә.

Диңгез җанлы булган кебек, күк тә хикәядә – җанлы, алар бер-берсенә тартылалар. Күк – югары (возвышенное), бөек, югары камиллек символы. Аның капма-каршысы саналган җир исә хакыйкәтьсез, гамьсез дөнья символы.

Г. Ибраһимов, романтик-руссочыл рухта, контраст буларак, табигать күренешләренә бозык шәһәр тормышын, меңнәрчә җәфа чиккән адәмнәре белән реаль җир тормышын каршы куя. Шәһәр пейзажын тасвирлаганда, язучыбыз тулы бер «караңгы, салкын» төсләрдәге семантик рәткә кергән лексик берәмлекләр куллана: аклы-кызыллы байраклы (!); шау-шулы; биек таш коймалы; катлаулы тәрәзәләре; тирә-ягы олы йортлар; гөрелтеле урамнар; андагы поездның вәхши кычкырулары; корымнар, төтеннәр белән буялып беткән завод морҗалары. Мондый тискәре эстетик сыйфатларга ия шәһәр куенындагы кешелек яшәеше дә куе караңгы төсләргә манылган.

Әйе, беренче тапкыр нәкъ менә романтиклар иҗатында капиталистик шәһәр кешегә коточкыч хәшәрәт, инсаннарның канын суыручы ерткыч (чудовище) рәвешендә килеп басты. Кешеләр монда шул зур, капиталистик шәһәрнең бер кечкенә генә көпчәгенә әйләнеп калалар. Алар табигать-ана белән тәмам элемтәләрен өзгән, ниндидер билгеле бер төркемгә куып кертелгән, кешелек сыйфатларын җуйган җансыз механизмны хәтерләтәләр. Монда кысанлык, пычраклык, хәерчелек хөкем сөрә. Бүген, XXI гасырда, «мәдәни» шәһәр тормышының зыянын медицина өлкәсендәге фәнни-тикшеренү нәтиҗәләре дә раслады: «В настоящее время до 80% больных находящихся в психиатрических лечебницах, – больные с так называемым синдромом большого города» [1].

Аурупа романтизмында Ж.-Ж. Руссодан башлангыч алган табигать культы – диңгез хәяте аша, төп каһарман «мин»нең бозык әхлаклы шәһәр тормышына каршы бунты рәвешендә гәүдәләнгән. Дөнья һәм рус әдәби-эстетик фикере белән яхшы таныш Г. Ибраһимов та татар прозасында беренчеләрдән булып руссочыл-толстойчыл рухта антиурбанизм темасын күтәреп чыга һәм цивилизациянең, фәнни-техник алгарышның кешегә әхлакый зыянын,

табигатьнең исә дәвалау, рухларны чистарту өслүбен тану кебек руссочыл карашларын «Диңгездә» хикәясендә калку төстә гәүдәләндерүгә дә ирешә.

Йомгаклап шуны әйтергә кирәк: мәктәптә, урта һөнәри уку йортларында Г. Ибраһимовның романтик чор хикәяләрен өйрәнгәндә, аларның Аурупа, рус, шәрекъ романтизмы традицияләре синтезында иҗат ителүенә һәм авторының дөнья әдәбиятында «кеше һәм табигать» темасын сурәтләүдә новатор саналган Ж.-Ж. Руссо, Л.Толстойлар традицияләренең дәвамчысы, шәрекъ традицияләре белән баетып, татар җирлегендә үстереп җибәрүче булуын күрсәтү дә мөһим.

Әдәбият

1. Ибраһимов Г. Әсәрләр: тугыз томда. Т. 1: Хикәяләр (1907–1929) / Г. Ибраһимов; беренче томны төзүче Г. К. Камалиев, текстларны, искәрмәләр һәм аңлатмаларны Р. Р. Гайнанов әзерләде. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. – 510 б.

2. Соколова Е. Красота и польза / Е. Соколова // Мой ребенок. – 2004. – № 9. – 144 б.

## Әхлакый –экологик  тәрбия – күңел хәзинәсе

***Мифтахова  Эльмира Флуровна,***
***МБББУ “14 нче лицей”, татар***
***теле һәм әдәбияты укытучысы***

Мәктәп алдында торган иң мөһим проблемаларның берсе – бу укучыларга әхлакый һәм экологик тәрбия бирү. Мәгълүм ки, кешене яман эшләрдән белемлелек түгел, бәлки әхлак тәрбиясе, әдәплелеге, намуслылыгы саклый. Әхлак белән әдәбият бергә булганда гына укытучы көтелгән нәтиҗәләргә ирешә ала. Ә әхлакый тәрбия белән янәшә экологик тәрбия дә урын ала, чөнки татар әдәбияты дәресләрендә кеше һәм табигать арасындагы мөнәсәбәтләрне өйрәнүгә зур игътибар бирелә. Шунысын да онытмыйк, әдәбият дәресләре милли үзаң, экологик мәдәният булдыруда үзәк булып тора. Башлангыч һәм урта сыйныфларда бу мәсьәлә кеше һәм җанлы табигать арасындагы мөнәсәбәтләрнең әхлакый-экологик проблемасы яктылыгында чишелеш таба.

Әхлакый-экологик белем һәм тәрбия бирүдә әдәби әсәрләрнең әһәмияте зур. Язучыларыбыз, беренчеләрдән булып, табигатьне саклау турында чаң сукты, әйләнә-тирә дөньяны, кеше сәламәтлеген, аның рухын, телен саклау аларны иң борчыган һәм дулкынландырган проблемага әйләнде. Шунысы аянычлы, бүгенге көндә укучылар әдәби әсәрләрне укымыйлар диярлек, чөнки алар күбрәк интернетта төрле челтәрләр аша мәгълүмат алалар. Ә бит әдәби әсәрләрне укып, асылын аңлап кабул итсәң генә әхлакый һәм экологик тәрбия бирүдә уңышларга ирешеп була. Менә шушы проблеманы күз алдында тотып мин әхлакый-экологик тәрбия бирүне ике юнәлештә алып барам: дәрестә һәм дәрестән тыш.

Беренче юнәлеш - ул дәрестә һәм дәрестән тыш эшчәнлектә матур әдәбият әсәрләре һәм өстәмә әдәбият белән эшләргә өйрәтүне, укучыларда мөстәкыйль эшләү күнекмәләре булдыруны күздә тота. Әдәбият дәресләренең төп максаты - әдәби әсәрләрнең матурлыгын күрә белергә, шул ук вакытта әдәби әсәрләр аша укучыларның дөньяви күзаллауларын, аңлау-фикерләү сәләтен үстерү, әхлакый-экологик тәрбия бирү максатын да онытырга ярамый.

Программага әсәрләр киләчәк яшь буынга әхлакый-экологик тәрбия бирү бурычларын күз алдында тотып сайланган. Бу бурычларга ирешүдә әдәбият дәресләрендә проектлар методы әһәмиятле урын алып тора. Мин бу методны үз дәресләремдә бик еш кулланам. Бу метод белән эшләгәндә, укучылар актив рәвештә уйлау, фикерләү эшчәнлегенә тартылалар һәм әхлакый шәхес буларак җитлегәләр. Мәсәлән, Галимҗан Ибраһимов иҗатын йомгаклау дәресе итеп, “Алмачуар” әсәрендә тел сүрәтләү чараларыннан чагыштыруның кулланылышын тикшерү”, Г.Бәшировның “Туган ягым-яшел бишек” әсәрендә гореф гадәтләр, йолалар”, “М.Мәһдиев әсәрләрендә исемнәр бакчасы” “М.Мәһдиев әсәрләрендә татар җырларының кулланылышы” һ.б. бик күп темалар буенча проект эшләре оештырам. Әсәрләрнең асылына төшенгән бала гына әхлаклы, туган җирен яратучы, туган туфрак табигатен саклаучы, халкын хөрмәт итүче шәхес буларак формалаша. Бу эшләрнең нәтиҗәсе булып фәнни-тикшеренү эшләре тора. Бүгенге көндә берникадәр уңышларыбыз да бар,

укучыларым һәрдаим конференцияләрдә катнашып призлы урыннар яулыйлар. Бу эшчәнлек аша укучы әдәби әсәрләрне аңларга өйрәнә, мәрхәмәтле, шәфкатьле, туган як табигатен саклаучы һәм яратучы, гомумкешелекнең уңай сыйфатларына ия булган, милләт мәнфәгатен яклардай кеше тәрбияләүдә ярдәм итә. Фәнни эшчәнлек, проект методы аша укучыларның күңеле, хисләре байый, ә инде күңеле бай икән, әйләнә - тирәне яратучы, аңа сакчыл караучы социаль-актив, гуманлы иҗади шәхес тәрбияләүдә уңышка ирештек дигән сүз.

Икенче юнәлеш - укучыларга әхлакый-экологик тәрбия бирүнең тагын бер нәтиҗәле формасы – ул әдәби түгәрәк. Мин "Сәләтле балалар "Эрудит" түгәрәге"н җитәклим. Бу түгәрәктә 6, 8 нче сыйныф укучылар катнаша. Түгәрәк шулай ук ике юнәлештә эшли:

Беренче эшчәнлек - туган шәһәребез, туган ягыбыз турында мәгълүматлар туплау, чөнки милләтебез борын-борыннан туган җиргә, туган туфрак төшенчәсенә, аның байлыкларына хөрмәт тәрбияләгән, сакчыл эш итәргә кушкан. Үз туган ягының тарихын, мәдәниятен, истәлекле урыннарын белгән укучы гына табигатьне яратучан, аның байлыкларына, матурлыкларына сокланучан һәм бу байлыкларга сакчыл шәхес буларак формалашачак. Шушы максаттан чыгып туган җиребез турында җыелган материалларны туплау һәм эшкәртү, өстәл календаре, шәһәребезнең истәлекле урыннары турында китап чыгару, фәнни эшләр язу оештырылды. Эшебезнең нәтиҗәсе булып, "Театрсыз шәһәр, шәһәр түгел", "Шәһәремдә иҗат әһелләре", "Туган шәһәремдә Г.Тукай исемен мәңгеләштерү" дигән эшләр белән укучыларның фәнни-гамәли конференцияләрендә катнашуы, "Шәһәребездәге истәлекле урыннар" дип исемләнгән, татар һәм рус телендә мәгълүмат туплаган өстәл календаре чыгару булды.

Икенче эшчәнлек - шәһәребез театры артистлары, иҗат әһелләре белән очрашулар, укучылар белән әдәби әсәрләрне сәхнәләштерү тора, чөнки үз ягының танылган шәхесләрен белгән укучыда шәһәре, туган җире өчен горурлык хисе арта, сакчыл караш туа. Бу эшчәнлек тә үз нәтиҗәләрен бирә - һәр ел саен республика күләмендә оештырыла торган театр фестивалендә

катнашып, призлы урыннар яуладык. Минем түгәрәккә йөрүчеләрне тату, бер-берсенә ярдәмчел коллектив дип әйтер идем мин.

Менә шундый юллар, чаралар, формалар аша укучыларымда намуслылык, тугрылыклы булу, кешеләрне ярату, җаваплылык, шәфкатьлелек, инсафлылык, тирә-юньгә, табигатькә, тереклек ияләренә сакчыл караш, кешелеклелек, киң күңеллелек сыйфатлары тәрбияләргә тырышам.

Без, әдәбият укытучылары, балаларны маңгай күзе белән генә түгел – күңел күзе белән дә "укырга" өйрәтергә тиешбез. Укучы әйләнә-тирәдәгеләрнең шатлыкларына һәм хәсрәтләренә игътибарлы булырга, ямьсезлектән йөз чөерергә өйрәнергә тиеш.

Кешелек җәмгыятен һәрвакыт борчып килгән әхлакый-экологик мәсьәләләре – намус, гаделлелек, җирдә дөрес итеп яшәү, эти-әни һәм Ватан алдындагы изге бурычны үтәү кебек төшенчәләр мәңгелек, һәркем өчен уртак. Аларны үзеңдә булдыру өчен Кеше булу кирәк. Ә укучыларны Кеше итеп тәрбияләү – безнең һәрберебезнең бурычы.

Кулланылган әдәбият

1. Җәләлиев. Ш. Татар халык педагогикасы. – Казан: Мәгариф, 2007.

2. Богуславская И. Шәхес тәрбияләү – заман таләбе. “Мәгариф” журналы, № 7, 2003, 8 нче бит.

## Туган телне ничек саклап калырга.

***Мортазина Ләйсән Габбас кызы,***
***башлангыч сыйныф укытучысы***
***Мөслим районы “Мөслим гимназиясе”***

Теманың актуальлеге: дөрес сөйләшү, татар сүзләрен башка тел сүзләре белән алыштырмыйча аралашу, сөйләүнең әһәмиятын ассызлыклау, теманың актуальлеген тәшкил итә.

Фәнни эшнең максаты: мәктәптә белем алучы укучыларны, ата-аналарны матур әдәбият, дөрес аралашу аша, татарча дөрес сөйләшергә өйрәтерү.

Өйрәнү материалы: теманы яктыртуда миңа күпъеллык тәҗрибәм; интернет порталдан кулланган “2014-2020 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы” ярдәмгә килде.

Бурычым: сөйләмне бозучы башка тел сүзләрен кулланган очракларны ачыклау.

Эзләнү процессы: татар телен бозмыйча сөйләшү һәм саклап калу өстендә эшне өйрәнү, калыпка салу һәм туплау.

Кереш өлеш

Татарстан Республикасында яшәүче һәр милләт кешесенә, үз халкы тарихыннан тыш, шушы төбәктә төп халык булып саналган татар халкы мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, тарихи үткәнен, бүгенгесен, киләчәген белү зарур. Татар халкы белән кулга-кул тотынып яшәргә әзерләнүче һәр кеше бу халыкның бәйрәмнәрен, традицияләрен аңларга, хөрмәт итәргә, әдәбият-сәнгать вәкилләренең иҗади казанышлары белән үзенең рухи үсешен баета алу мөмкинлегеннән файдаланырга тиеш.

Укучыларның татар теле буенча лексик, грамматик күнекмәләре филологик белемнәр суммасы дәрәҗәсендә генә калмыйча, ә сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрендә дә аралашуда кулланырлык дәрәҗәгә җитүе зарур. Ягъни, укучылар, нинди дә булса сүзне, я грамматик категорияне тану, аеру, аңлау, тәрҗемә итү дәрәҗәсендә генә түгел, аларны аралашу максатыннан мөстәкыйль кулланырлык дәрәҗәдә өйрәнергә тиешләр. Укучының белеме дигәндә, без аның аерым сүзләрне яки грамматик категорияне тану, аера белүен генә күзалламыйбыз, ә аларны кулланып сөйләшә алуын күзаллыйбыз.

Сайлап алынган лингвистик материал филологик формада таныштыргач, аны төрле аралашу сфераларындагы социаль контактларда, аралашу ситуацияләрендә, текстлар эчтәлеген сөйләүдә куллану камилләштерелә. Өйрәнелгән грамматик материал максатчан рәвештә төрле

жанрдагы текстлар эчтәлегендә кулланылып, укучыларның сөйләшә алулары камилләштерелә.

Укучылар эмоциональ, хәрәкәтчән, тиз арыйлар. Бала материалны үзе өчен кызык булса гына, үзенең шәхси ихтыяҗларына туры килсә генә, кабул итә һәм фикерли башлый. Күрсәтелгән психологик үзенчәлекләрнең, һичшиксез, эчтәлек сайлаганда исәпкә алынуы зарур.

Укыту процессында әкияти, фантастик сюжетлар, кызыклы геройлар белән очрашу, уен элементларын куллану – лингвистик материалны өйрәнүнең мотивлашкан булуын тәэмин итә. Ассызыклап шуны әйтергә кирәктер, өйрәнелгән лексик-грамматик материал балаларның социаль контактларына туры килеп, аларның татарча аралашуын тәэмин итәрлек булырга тиеш. Әлбәттә, укучыларның психофизиологик мөмкинлекләрен исәпкә алу зарур.

Төп өлеш

Үземнең эшем буенча, интернетта утырганда, кызыклы мәкаләләр укырга туры килә. Шундый мәкаләләрнең берсе, мине бик гаҗәпләндерде һәм уйланырга мәҗбүр итте. Дөньяда бик күп телләр “үлү” дәрәҗәсендә икән.Һәр ике атна саен бер тел үлә. Галимнәр фикеренчә, алтмыш елдан соң, барлык булган телләрнең яртысы юкка чыгачак. Ирексездән телләрне хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы белән чагыштыру барлыкка килде, ягъни “Кызыл китап” белән. Безнең татар телебез дә, чит телләр йогынтысында, юкка чыкмас дип кем әйтә ала.Чөнки, телләр юкка чыгу, хайваннар һәм үсемлекләр үлүенә караганда тизрәк бара. Хәзер кырыктан артык телне “Кызыл китап”ка кертеп булыр иде.

Тәҗрибәм күрсәткәнчә, укучылар мәктәптә чиста татарча сөйләшә белмиләр. Димәк, алар татарча матур итеп, чиста итеп сөйләшә белмәүче дуслары, әти-әниләре, туганнары белән аралашканда телне боза торган сүзләр кулланалар. Мисал өчен, 2 нче сыйныфта татар теле дәресендә “Предметларны белдергән сүзләр” темасын үтәбез. Укучылар, “Тауда” рәсеме буенча җөмләләр төзиләр. Шул вакытта алар рус сүзләре кулланалар: “салазка”, “ледянка”, “таблетка” һ.б. Шул очракта бергәләп бу предметларга исемнәр уйлыйбыз: шугыч, чана, кабартылган тәгәрмәч, дип өйрәнәбез.

Әдәби уку дәресләрендә татар язучыларының әсәрләре белән танышабыз, укыйбыз, ә соңыннан әнгәмә үткәрәбез. Әминә Бикчәнтәеваның “Сөйкемсез песи” әсәрен укыгач, песи кушаматлары әйтергә куштым. Укучылар: “Кэсси”, “Рыжик”, “Мурка”, “Пушок”, “Васька”, дип тезеп китәләр. Шунда бик тәрбияви, мәгънәле әңгәмә үткәрү урынлы була. Без татарча сөйләшәбез, песи һәм этләрнең төсенә, холкына карап: Акбикә, Сарбай, Акбай, Актүш, Акыллы, Бердәнбер кебек исемнәр уйлап табарга мөмкин.

Роза Хафизованың “Күңел күзе” әсәре буенча фикер алышканда, укучылар чәчәк исемнәрен: ландыш, астра, колокольчик дип рус телендә саныйлар. Татар телендә бик күп матур чәчәк исемнәре бар: энҗе, кашкарый, ак чәчәк, миләүшә, кыңгырау чәчәк. Шушы вакытта чәчәкләрнең рәсемен күрсәтеп бару, бик урынлы булыр иде.

Габдулла Тукайның “Баланың ата-анасын сөюе” хикәясен укыгач, укучылар гаилә темасына кагылышлы җөмләләр төзеп әйтәләр. Әти, әни сүзләре кулланганч, укытучы, тагын да ягымлы, итагатьле итеп әйтер өчен татар телендә: әнием, әтием, әнкәй, әткәй, дәү әни, дәү әти сүзләрен кулланырга киңәш итә.

Хәзерге буын китап укырга яратмый, дип әйтәбез. Китап уку ирекле эш. Кешене китап укырга мәҗбүр итеп булмый. Мәсәлән, без туган көннәргә барганда ни өчен татарча язылган китап сатып алмыйбыз? Бәлки күбрәк китап бүләк итәргә кирәктер. Бер мисал, оныклары туган көненә әбисе белән бабасы кибеттән бүләк эзлиләр, алар фикеренчә, бер яшь тулган оныкка зур машина бүләк итү иң отышлысы. Бәлки баланы бер яшеннән үк китап тотарга өйрәтергә, битләрен дөрес ачып күрсәтергә, рәсемнәренә карап татарча сүзләрне кабатларга күнектерергә кирәктер.

Ирексездән, татар мәкальләрен искә төшерәм: “Теле барның иле бар”, “Теле татлының дусы күп”, “Сөйли белсәң, тыңлый да бел”. Бала гаиләдә беренче сүзләрен ана телендә әйтсә, кечкенәдән туган теленә карата хөрмәт итү хисләре тәрбияләнсә, ул гомере буена татар телен онытмас, аралашыр, дөрес сөйләшер, дигән фикер кала.

Йомгаклау өлеше

Тормыш дәвам итә. Без көндәлек тормышта төрле кешеләр белән аралашабыз, сөйләшәбез, әңгәмә корабыз. Ләкин кеше сүзләрне дөрес әйтми, дип көлү, төзәтү, тәрбияле кеше эше түгел.

Дәрес сөйләшүне үзебездән башлыйк. “Магазин”га барам әле, дигәнче “кибеткә барам” дип әйтик. Кибеткә кергәч, “песок”ны шикәр комына алыштырсак нинди әйбәт булыр иде. Санап китсәк, көндәлек тормышта алар бик күп икән: “подружкалар”, “лечить итте”, “давай”, “минем внук”, “потом” , “нәрсә белән занимается» һ.б.

Туган телне саклау безнең үзебездән тора. Без аны югалтмаска, ничек булса да саклап калырга тиешбез. Киләчәк буыннарга туган телебез-татар телен саклап, тапшыра алсак иде.

Файдаланылган әдәбият

1.“2014-2020 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы” (2013 ел, 25 октябрь);

2. http://beznen.ru/basma/2016-34/monda-boten-keshe-tatarcha-soyleshe/

3. Уку китабы. Авторлар Р.Х.Ягъфәрова, Р.И.Раскулова.2012 нче ел.

4. Флёра Харрасова "Мин сөйләргә өйрәнәм" Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның авазларын төзәтү буенча кулланма. Казан: "Паритет" нәшрияты, 2008. - 48 бит.

## Духовно-нравственное воспитание на уроках литературы

*Мусина Лейсания Закиевна,*
*учитель русского языка и литературы*
*МБОУ Терсинская СОШ Агрызского муниципального района РТ*

Мы живём в удивительное время. 21 век - это век высоких технологий, век комфорта, век новых открытий. Казалось бы, 21 век - самое лучшее время для проживания на планете Земля. Но, гоняясь за комфортными условиями

физического существования, общество не всегда заботится о духовном развитии подрастающего поколения. К сожалению, изменение общественных отношений в нашей стране повлекло за собой сложные духовные проблемы, которые выразились в обесценивании многих жизненных идеалов и образовании идеологической пустоты. Очень отрадно, что в настоящее время большое внимание уделяется не только процессу обучения, но и воспитанию учащихся. Моя цель как учителя заключается в том, чтобы защитить детей от насилия, сделать их невосприимчивыми к злу и способными творить добро на благо людей. Это задача решается, прежде всего, с помощью духовно-нравственного воспитания и на уроках литературы.

Несомненно, русская литература – основа воспитания, она всегда была гордостью, совестью народа. Говоря о духовном воспитании молодого поколения, мы имеем в виду и воспитание внутреннего мира, и отношение к окружающему миру. Любая тема в литературе может рассматриваться с точки зрения духовно-нравственного понимания. Рассмотрим в этом аспекте некоторые ключевые произведения, включенные в школьную программу (за основу взята программа В.Я. Коровиной).

Устное творчество любого народа содержит богатейший материал для воспитания в духе дружбы, взаимопонимания, трудолюбия, патриотизма. Этой цели служат пословицы, поговорки, загадки, песни, былины. Отражение народных идеалов - патриотизма, богатырской силы, ума, находчивости - мы видим в древнерусской литературе, в летописи “Повести временных лет”, изучающейся на протяжении трех лет. В 8 классе, изучая “Житие Александра Невского”, ученики говорят о бранных подвигах Александра Невского и его духовном подвиге самопожертвования, о защите русских земель от нашествий и набегов врагов. Горячий призыв к единству Руси перед лицом внешней опасности, призыв к защите мирного созидательного труда русского населения – вот основной вывод, к которому приходят девятиклассники при изучении “Слова о полку Игореве”.

И, конечно, при воспитании настоящего человека с большой буквы нельзя не обойтись без русской классики. И сколько бы времени не прошло, русская классическая литература останется бесценным достоянием русского народа. Например, в романе А.С.Пушкина «Евгений Онегин» перед нами предстает настоящая русская девушка Татьяна Ларина – хранительница русских традиций. «Но я другому отдана и буду век ему верна» - это пример того как высоко Татьяна ценит такие понятия как честь, совесть, верность. Точно также поступает и Маша Троекурова из повести А. С. Пушкина «Дубровский», она отказывается нарушить клятву пожизненной верности, данной в церкви.У М. Ю. Лермонтова в произведении «Песня про купца Калашникова» главный герой защищает честь своей семьи, жены. Ради этого Калашников готов пожертвовать своей жизнью. На примере этих произведений ученики знакомятся с такими понятиями как: верность слову, честь семьи, достоинство и моральный облик русского человека.

Литература – это учебный предмет, где ученики могут, не стесняясь, высказывать свою точку зрения, спорить, вместе решать проблемы, находить выход из трудных ситуаций. Поэтому на уроках выигрышны следующие формы работы, как уроки-исследования, беседы, семинары, дискуссии, которые позволяют в непринужденной беседе рассуждать о настоящих человеческих ценностях: о долге, о чести, об ответственности за свои поступки, о величайшей силе любви, о семье.

Например, при изучении рассказа Л. Андреева «Кусака» в 7 классе учащиеся бурно обсуждают проблему отношения людей к животным, они искренне сочувствуют этой бедной несчастной собачке. А какое потрясение испытывают пятиклассники, узнав о поступке Герасима. Многие со слезами на глазах доказывают, что Герасим мог бы с собой увести и свою любимицу. Как он смог так со своей питомицей, ведь Герасим спас щенка от смерти, ухаживал за ней лучше всякой матери. Это доказывает то, что наши дети способны сочувствовать не только людям, но и животным.

«После бала» Л. Н. Толстого, «Кавказ» И. А. Бунина, «Куст сирени» А.И. Куприна, «О любви» А. П. Чехова, «Капитанская дочка» А. С. Пушкина - все эти произведения напрямую связаны с духовно-нравственным воспитанием, так как они затрагивают такие проблемы, как честь, совесть, чувство собственного достоинства, самопожертвование, семейные ценности. В процессе изучения этих произведений учащиеся не остаются равнодушными поступкам главных героев, и во многом дети выражают несогласие с тем, как герои ведут себя по отношению к другим людям. Они четко представляют себе, что значит быть благородным, честным человеком. Значит ещё не все потеряно, и мы сможем возродить в детях добрые чувства.

Процесс формирования духовных ценностей – длительный, быстрого результата быть не может, но та работа, которая проводится учителями на уроках литературы, поможет «заронить» драгоценное зерно в души наших учеников. Конечно, необходимо воспитание и в семье, и в школе. Но для многих детей именно школа становится местом, где закладываются духовные ценности.

Могу с уверенностью сказать, что словесник в школе – главная фигура. Ведь за ним стоят Пушкин, Гоголь, Толстой, Достоевский, Тютчев и весь сонм великих нашей отечественной словесности. За учителем каждого предмета стоят великие, но духовность, к которой литература имеет самое прямое отношение, – это особое и наиболее значительное дарование России, наклон ее фигуры, смысл ее цивилизации. Литература, родной язык, затем история, прежде всего, творят сына Отечества.

Список литературы

1. Караковский В. А. Стать человеком. – М.: «Творческая педагогика», 1993.

2. Сухомлинский В. А. Сердце отдаю детям. – К.: «Школа», 1973.

3. Локтионова Н. П. Нравственные уроки детства по произведениям современной литературы (5-6 классы). – Литература в школе, 2009.

**Әдәбият дәресләрендә әхлак тәрбиясе**

*Муханова Мария Гавриловна Зәй политехника көллиятенең 1 нче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Халыкта борын-борыннан туган ил, туган җир, туган телгә мәхәббәт; якыннарга, кардәш – ыруга хөрмәт һәм кайгыртучан мөнәсәбәтләр яшәп килгән. Алар борынгы бабаларыбыз тарафыннан югары бәяләнгән. Без бу гүзәл сыйфатларны, гомумиләштереп, “әхлак” дибез.

“Илен белмәгән – игелексез,

Халкын белмәгән – холыксыз,

Нәселен белмәгән – нәселсез”, -дигән тәкъбирләр әхлаклы булырга өнди.

Соңгы елларда әхлаксызлык күренеше тормышыбызның күп ягына үтеп керде. Электән үк әхлак кагыйдәләре белән яшәгән татар авылына да чор үзенең “әхлаксызлык чирен” йоктырды.

Мондый шартларда әдәби әсәрләрнең, әдәбият дәресләренең әхлак тәрбиясе бирүдә әһәмияте гаять зур. Шуңа күрә дәресләрне планлаштырганда, әдәби әсәргә анализ ясаганда группаның һәм группадагы аерым укучыларның үзенчәлекләрен исәпкә алып, теге яки бу әхлак сыйфатларын формалаштырырга тырышам. Татар әдәбияты дәресләрендә укучыларны бу гүзәл сыйфатларга бәя бирергә, үз-үзләренә тәнкыйть белән карарга өйрәтү мөмкинлеге бар. Күпчелек әдәби әсәрләрнең төп максаты – олы кешегә яхшы мөнәсәбәт, игътибарлылык, ихтирам һәм хөрмәт хисе тәрбияләү, һәркемне әхлаклы итү.

10,11 сыйныфларда укучыларга әхлак тәрбиясе бирүдә Г.Исхакый әсәрләренең әһәмияте бик зур. Бу сыйныфларда укучылар олы тормыш юлына басарга, һөнәр алырга, алга таба гаилә корырга әзерләнүче егетләр һәм кызлар. Язучының “Ул әле өйләнмәгән иде” әсәрен анализлау гаилә төзүгә бәйләнешле әхлак сыйфатлары формалаштыру мәсьәләсенә дә кагыла.

9,10,11 сыйныф укучылары һәрнәрсә белән кызыксыналар. Бигрәк тә кызларны мәхәббәт мәсьәләсе дулкынландыра. Аларны егетләр алдында үз-

үзеңне тоту мәсьәләсе борчый. Шуңа күрә Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф”, Сәиф Сараиның “Сөһәил вә Гөлдерсен”, Г.Кандалыйның “Сәхибҗамал” поэмаларын, Ф.Әмирханның “Хәят” повестен өйрәнгәндә, татар кызларына хас әдәплелек, тыйнаклык кебек сыйфатлар тәрбияләүне максат итеп куям.

10 сыйныфта Ф.Әмирханның “Хәят” повестен өйрәнгәндә группадагы аерым кызларның үз-үзләрен тотышына игътибар итеп, аларга тәрбия бирү максаты белән, Хәяттагы күркәм сыйфатларны укучыларның үзләреннән әйттерергә тырышам. Аның тәрбияле кыз булуына, үзен иптәшләре арасында гади һәм әдәпле тотуына, эчке һәм тышкы матурлыгына игътибар иттерәм. Группага “Хәятнең әдәпле кыз икәнлеген каян күрәбез?” дигән сорау куям. Укучылар төрле мисаллар китерә. Мәсәлән, иптәш кызы Лиза аны алырга килгәч, ул әти-әнисеннән рөхсәт сорый, ул рөхсәтсез кая да булса китәргә гадәтләнмәгән, әти-әнисен ихтирам итә. Зурларны хөрмәт, ихтирам итү – кешенең иң күркәм сыйфатларыннан берсе икәнлегенә басым ясала. Хәят бары тик дини тәрбия генә алса да, егет белән кыз арасындагы мөнәсәбәтнең зур нәрсә икәнлеген аңлый һәм аңа җаваплы карый. Хәяткә “Яшьләр уенында” шактый гына тупас сүзләр ишетергә туры килә, ә ул шулай да күтәрелеп бәрелми, тупаслыкка тупаслык белән җавап кайтармый. Бу да – матур гадәт. Димәк, Хәяттә үчләнү, үч кебек ямьсез сыйфат юк. Ул кичерә белә.

11 сыйныфта Ә.Еникиның “Әйтелмәгән васыять” хикәясе өйрәнелә. Әсәрнең үзәгендә – Акъәби образы. Аның тойгы-кичерешләре, кешелекле һәм җитди уй-фикерләре тасвирланган. Бу образда халык рухы, борын-борыннан килгән гореф-гадәтләр сурәтләнгән. Акъәби гомере буена хәләл көче белән көн күргән. Берсеннән – берсе уңган, илгә файдалы, кирәкле балалар үстергән. Ул – киң күңелле, эшчән, зур хөрмәткә лаек ана. Акъәби балаларының олы дәрәҗәгә ирешүләренә ихлас күңелдән куана, ләкин аларның туган туфрактан читләшүләренә, туган халкыннан, туган телләреннән аерыла баруларына җаны рәнҗи. Олы улы Суфиянның балалары үз туган телләрендә “бабушкаларына”дәшәрлек бер авыз сүз дә белмичә үсәләр бит. Суфиян гаиләсендә туган тел, гореф-гадәтләр онытыла. Акъәби балаларына “газиз туган

телне күз карасыдай кадерләп сакларга кирәк” дип васыять әйтеп калдырырга тели. Һәр милләттә халыкның тарихын, үзенчәлекләрен, яшәү рәвешен чагылдырган, ата-бабалардан буыннан – буынга күчеп, сакланып килгән ядькәрләр була.  Акъәби үзе өчен бик кадерле кайбер нәрсәләрне балаларына төсе итеп калдырырга тели. Мәсәлән, ак ука тоткан, якут каптырмалы сары бәрхет камзулын – Гөлбикәсенә, ак мәрҗәннән җыеп эшләнгән әдрәс астарлы кашмау белән чәчкабын – Пермьдәге олы кызы Сылубикәсенә, картыннан калган камчат бүрекне улы Суфиянга билгеләп тора. Аннары бик борынгы тәңкәләре һәм төрле төстәге ташлар белән бизәлгән бәяте (хәситәсе) бар, шуны, кабул итсә, килененә бүләк итәр иде. Ләкин балалары Акъәбинең соңгы теләген тыңларга вакыт таба алмыйлар, кирәксенмиләр дә. Хәтта ананың соңгы васыятен – аны үзебезчә җирләүне дә – тиешенчә үти алмыйлар. Акъәби вафат булгач, аның әйберләренә урын табылмый, күбесен театр гардеробына илтеп бирәләр. Ата-бабаларының истәлеге эзсез югала.

Рухи байлык, әлбәттә, үлгәннәр өчен түгел, ә исәннәр һәм киләчәк буын өчен кирәк. Әсәрдәге йөзьяшәр картның “учагында ут сүнмәсен” дигән сүзләре халыкның рухи байлыгы бервакытта да саекмасын, кимемәсен, киләчәк буыннарга да тапшырылсын дигәнне аңлата. Гади генә авыл карчыгы яшь буынның мәгънәле, матур, рухи яктан бай булып яшәвен тели.

Әдәбият дәресе – әхлак дәресе. Әдәби әсәрләр уку бу дәресләрне кызыклы, үгет-нәсихәтле, гыйбрәтле итәргә булыша.

Әсәрне анализлаганда, мин баланың логик фикерләвен, хәтерен, дөрес нәтиҗә ясый белү сәләтен үстерергә, үз-үзенә бәя бирергә өйрәтергә омтылам. Нәтиҗә ясап әйткәндә, балаларны олы хисләргә ия булырга: фарыз гамәлләрне үтәп, хәрам эшләрдән тыелып яши белергә өйрәтүне әдәбият дәресләренең мөһим тәрбияви максаты булырга тиеш дип саныйм.

Кешелек җәмгыятен һәрвакыт борчып килгән әхлак мәсьәләләре: намус, гаделлек, җирдә дөрес итеп яшәү, әти-әни һәм Ватан алдындагы изге бурычны үтәү кебек төшенчәләр – мәңгелек, һәркем өчен уртак. Аларны үзеңдә булдыру өчен кеше булу кирәк.

Ә укучыларны кеше итеп тәрбияләү – безнең һәрберебезнең бурычы.

Кулланылган әдәбият:

1. Богуславская И. Шәхес тәрбияләү – заман таләбе. “Мәгариф” журналы, № 7, 2003,

2. Җәләлиев .Ш. Татар халык педагогикасы. – Казан: Мәгариф, 2007..

3.Заһидуллина Д.Ф. Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. - Казан: Мәгариф, 2000.

4. Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов Ә.М., Гыйләҗев Т.Ш.Татар әдәбияты.Теория,тарих.Казан: Мәгариф,2004.

5. Маликов В. Яңа информацион технологияләрдән файдаланып. “Мәгариф” журналы, № 9, 2003.

## Габдулла Тукай иҗатында экологик тәрбия

***Набиуллина Луиза Зөфәр кызы, татар теле һәм әдәбият укытучысы,***
***Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль***
***бюджетлы гомуми белем биру учреждениесе Тирсә урта гомум белем бирү мәктәбе***

Кешелекнең табигать белән бәйләнеше – хәзерге заманның актуаль мәсьәләләреннән санала. Балаларга экологик тәрбия бирү һәм белем бирүдә, аларда табигатькә, тереклек ияләренә аңлы, сакчыл караш, кешелеклелек, киң күңеллелек сыйфатлары тәрбияләүдә, туган якка, аның табигатенә мәхәббәт уятуда әдәби әсәрләр зур әһәмияткә ия.

Табигать һәм аның әдәби тасвирлары кешене әхлакый яктан югары күтәрә , нәфислек һәм гүзәллекне танырга , аларга дөрес бәя бирергә һәм аларның кадерен белергә өйрәтә.

Шәхесне формалаштыруда табигатьнең роленә зур бәя бирүчеләрнең берсе бөек рус педагогы К.Д.Ушинский булды . Табигатьтәге искиткеч гүзәл күренешләр , К.Д.Ушинский фикеренчә, яшь акылның үсүенә зур йогынты ясый. [ 2, 6-7 ]

К.Д.Ушинскийның алдынгы карашларын татар халкы арасында таратуга талантлы шагыйрь , җәмәгать эшлеклесе һәм педагог Габдулла Тукай күп көч

куйды. Татар әдәбияты үсешендә Габдулла Тукай кебек зур өлеш керткән башка каләм иясен табу кыен. Тукай дигәндә − татар халкы күздә тотылса, татарлар дип әйтүгә − Г.Тукай исеме аңга килә. Шагыйрьнең иҗаты барлык сыйныфларда да диярлек өйрәнелә. Аның иҗатында кеше һәм табигать мөһим урыннарның берсен алып тора. Туган табигать, аңа мәхәббәт , аның матурлыгын аңлау югары кешелек һәм туган илне чиксез ярату хисләреннән аерылгысыз. Габдулла Тукайның балалар өчен язган шигырьләре укучыларда тормышка актив мөнәсәбәт тәрбияләү , белемгә омтылыш , Ватанга, туган телгә туган табигатьнең матурлыгына тирән мәхәббәт тәрбияләү идеяләре белән сугарылган. Тукай дөньяны да, табигатьне дә, табигать күренешләрен дә сабыйлар карашы, сабыйлар акылы белән күзәтә белгән. Аның шигъри юллары укучыны гаҗәпләндерә, шатландыра, сөендерә, куандыра, дулкынландыра. Тукайның мөгаллимлек осталыгы тагын шунда: ул укучысына уйларга, ишеткәннәргә һәм күргәннәренә карата үз мөнәсәбәтен булдырырга урын калдыра.

Шигырьләрендә шагыйрь балаларга очсыз-кырыйсыз киңлекләр һәм туган илнең гүзәл матурлыгы , аның кара урманнары, язгы болыннарының саф яшеллекләре , елгалары, һәм күгенең зәңгәрлеге турында сөйли. Туган якның сихри матурлыгын Г. Тукай "Туган авыл " , "Туган җиргә", "Җәйге таң" , "Шүрәле" , "Иртә", "Көз" "Пар ат" , "Кышкы кич" , "Елның дүрт ел фасылы" , "Җил", "Буран", "Яңгыр" һәм башка күп кенә әсәрләрендә сурәтли. Шигырьләрдә туган якның табигате, ел фасыллары, күк җисемнәре, җир-сулары, урман-болыннары , үсемлекләре, кош-кортлары , киек-җанварлары кызыклы һәм һәм күп мәгълүматлар китерелеп, бик матур итеп тасвирлап бирелә. [2, ] Тукайның хикәяләрендә, шигырьләрендә, мәсәлләрендә төп геройлар – урман хуҗалары: маймыл ("Көзге һәм маймыл") , күке ("Әтәч илә күке") , сандугач ("Мәче илә сандугач")."Чыршы" , "Җил вә кояш" , "Яңгыр илә Кояш" әсәрләре баланы дөнья вә табигать хакында уйлану һәм аны сөйдерүне күздә тота.[1,40]

Г. Тукай балалар өчен иҗат иткән шигырьләрнең, әкиятләрнең күпчелегендә табигать тасвирланган. Бу юкка гына түгел, чөнки табигать – балаларга иң якын булган тормыш.Бу – язучының табигатькә булган мәхәббәте,

аны яхшы белүе, матурлыкны башкаларга да җиткерү омтылышы.[3, 7] Г. Тукай шигырьләренең күбесендә хайваннар һәм кошлар, бөҗәкләр дөньясы сурәтләнә: “Фатыйма белән сандугач”, “Бала белән күбәләк”, “Кошчык”, “Бичара куян”, h.б. Андагы хайваннар, кошлар, бөҗәкләр үзләренә хас табигый сыйфатлары белән бирелгәннәр, шулай ук аларда кеше характерында була торган үзенчәлекләрне дә күреп була. Бу алымнар шигырьләрнең тәрбияви көчен үстерә, бала вакыйгалардан чыгып, фикер йөртеп, үзе тиешле нәтиҗәне ясый ала.

Табигатьтә һәрвакыт төрле үзгәрешләр булып тора. Балаларга багышланган шигырьләрендәге, табигатьнең сихри серләрен күрсәткән “Ел фасыллары” исемле табышмак-шигырь балалар өчен бик кызык һәм мавыктыргыч. Әлеге шигырьләрдә ел фасылларының үзенчәлекләре турында сөйләнелә. Әйе, кыш аенда ап-ак юрганга ябынып, сулар, елгалар бозланып, кошлар җылы якка китсәләр, ә яз көне, кояш үзенең җылы нурлары белән дөньяны җанландырыр, ә инде җәй аенда табигатьтә һәр җирдә тереклек, хәят, күңеллелек башланыр, көз дә үзенең эстафетасын алыр, көннәр кыскарыр, бертоташ яңгырлар явар, җанлылык, тереклек бетәр.

Габдулла Тукайның туган як табигатенә карата булган кайнар мәхәббәт хисләре , әлбәттә, аның “Шүрәле” поэмасында бөтен тулылыгы , бөтен матурлыгы белән сурәтләп , гәүдәләндереп, җанландырып күрсәтелә. Әсәрдә Кырлай табигате күңелләрне тибрәтерлек итеп тасвирлана. Табигать кошлары һәм аларның өздереп сайравы аеруча тәэсирле. Туган табигатьнең урманнарын , гаскәр кеби чыршы-наратларын ,хәтфәдәй  яшел болыннарның ягатуның чиге юк. Бу поэма туган як табигатенә карата мәхәббәт хисләре тәрбияләүдә бай чыганак, хәзинә булып тора.

Габдулла Тукайның “Бала белән күбәләк”, “Яшь агач” әсәрләрендә экологик тәрбия бирү аеруча яктыртыла. Укучыларда экология проблемасы турында белү генә түгел, аны чишү юлларын эзләү теләге уята.

Габдулла Тукай шигырьләре аша балаларда туган телебезгә, табигатькә кызыксыну уяту мөһим.

Кулланылган әдәбият.

1. Д.Ф.Заһидуллина “Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы”, Казан “Мәгариф” нәшрияты, 2000 нче ел

2. С.Исмагилова “ Табигат тасвирлары – тәрбия чарасы” , Казан , Татарстан китап нәшрияты, 1974 нче ел.

3. “Мәгариф” журналы ,№ 11, 2013. Хәнәфи Бәдигый “Ул таныш кырлар , болыннар...”, 6-8 бит.

## Татар теле һәм әдәбият дәресләрендә әхлакый һәм экологик тәрбиянең актуальлеге

***Насыйрова Зөлфидә Шәйдулла кызы, укытучы,***
***Габдулла Тукай исемендәге Әтнә авыл хуҗалыгы техникумы***

Тәкъдим ителгән тема гаять катлаулы, киң колачлы. Шуңа күрә бу теманы тулысынча ачу өчен күп вакытлар кирәк булыр иде. Чөнки әдәбият ул үзе – әхлакый һәм экологик тәрбия чыганагы. Әдәбият, әхлакый һәм экологик тәрбия сүзләрен аерып карап булмый. “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә “әдәбият” сүзенә “әдәби образларны нәфис сүз, тел ярдәмендә барлыкка китерү белән аерылып торган сәнгать төре” дигән аңлатма бирелә. Ә сәнгать “иҗтимагый аңның чынбарлыкны нәфис образлар аша чагылдыра торган формасы”.

Темада тагын әхлакый һәм экологик тәрбия дигән сүзтезмәләр бар. “Әхлак” сүзенә сүзлектә “кешеләрнең бер – берсенә һәм җәмгыятькә карата мөнәсәбәтләр нормасы һәм принциплар җыелмасы”, ә “әхлаклы” сүзенә “тотнаклы, тәрбияле, әдәпле” дигән аңлатмалар бирелә.

Әдәпле – әхлаклы камил шәхес тәрбияләү – татар халык педагогикасында төп мәсьәлә.

Кешегә яхшылык кылу, изгелек эшләү, кешелеклелек – яшьтән үк тәрбияләнә торган иң күркәм әдәп – әхлак сыйфатларының берсе.

“Кыз баланы ялгыз мунчага җибәрмә – җен кагыла”, “Утка төкермә, авызың кутырлар”, “Ут булса, тереклек бар, аны игътибарсыз калдыру да куркыныч” дигәнне аңлата. “Җиргә ятып йоклама, җен кагыла”, “Тозны чәчмә, өйдә тавыш чыга” – пөхтәлеккә, саклыкка өнди. “Җиргә ятып су эчмә, елан керер” – савыттан эчү – әдәплелек, чисталык билгесе. [5, с 34]

Шундый тапкыр, зирәк фәлсәфәле кисәтү, катгый тыюларга нигезләнеп тәрбияләгән ата – бабаларыбыз балаларны. Уйлап карасаң, алар беркемне дә рәнҗетми, бары тик әдәпле, иманлы булырга чакыра. Шуңа күрәдер, безнең халык әүвәл – әүвәленнән әдәпле, эшчән, кешелекле булган. Хәзерге яшьләребезне дә, әнә шул тыю – кисәтүләргә, халкыбызның әдәп – әхлак турындагы тәгъбир  - нәсыйхәтләренә, алар белән исәпләшерлек итеп тәрбиялисе иде. Ә тәрбия эше – гаять катлаулы, җаваплы бурыч, бу бурычны үтәү өчен иң беренче үзебезгә таләпләрне арттырырга, аларны үз үрнәгебездә акыл һәм сабырлык, олыларга ихтирам, нәниләргә шәфкатьле булып, бәхетле гомер кичерергә хәзерләргә кирәк.

Мөлаемлылык, тәрбиялелек, тәмле теллелек, дуслар сайлый белү – халкыбызның күркәм гадәтләре. Без бу сыйфатларны Фатих Кәриминең “Салих бабайның өйләнүе” хикәясендә күрәбез. Анда “әхлак”, “әхлак тәрбиясе” дигән сүзләр бар. Салих бабай образы аша без укучыларда кешеләргә карата йомшак табигатьлелек, мәрхәмәтлелек, тугрылык тәрбиялибез. Салих бабай табигатьнең гүзәллегенә соклана. Тормышны ярата, яшәүдән тәм таба. Нинди авыр тормыш кичерсә дә, кешелеклелеген югалтмаган.

Бүгенге көндә әхлаксызлык һәммәбезне борчый. Чыннан да, урамнарда, җәмәгать урыннарында кайвакыт балаларның, үсмерләрнең, яшьләрнең үзара мөнәсәбәтендә дорфалык, тупаслык, шәфкатьсезлек күреп гаҗәпкә каласың. Юкка гына шагыйрь Нажар Нәҗми “Ачыну” дигән шигырендә мондый юллар язмагандыр:

Бер – беребезгә нинди бәгырьсез без,
Хәтта кансыз – кемнән өйрәндек?
Усаллыкка, әдәпсезлекләргә

Нинди иләк аша иләдек?

Усаллык, бәгырьсезлек, әхлаксызлык, эшсезлек кебек сыйфатлардан, ничек арынырга? Тәрбиянең кайсы урыннарында нинди ялгышлыклар җибәрелгән? Бүген шундый сорауларга җаваплар эзлибез. Тәрбия бирү юлларын, чараларын яхшыртырга тырышабыз. Әхлак тәрбиясе – тәрбия эше системасының үзәге, иң мөһим юнәлеше. Әхлак тәрбиясе белән беррәттән, экология дигән зур төшенчәне дә онытмаска кирәк.

“Экология – тирә - як мохит белән организмның үзара мөнәсәбәтен өйрәнүче фән” диелә сүзлектә. Ә ни өчен хәзер экология актуаль мәсьәләгә әйләнде? Кешеләр гомер – гомергә  тирә - як мохит белән тыгыз элемтәдә торган. Табигать аны тукландырган, җылыткан, киендергән, савыктырган. Табигатькә моннан артык зыян да салмаган.

Әмма вакытлар узу белән фән һәм техника үсә. Хәзер инде табигатьне төрле химикатлардан, зарарлы газлардан да сакларга кирәк. Диңгезләргә нефть агып төшә, балыклар үлә, сазлыклар кибә, дару үләннәрен кочак – кочак җыеп, төбе – тамыры белән юк итәбез. Менә шундый шартларда экология фәнен өйрәнү, экологик культура тәрбияләү мәсьәләсе бөтен кискенлеге белән алдыбызга килеп баса.

Безгә, әдәбият укытучыларына үтә дә җаваплы эш йөкләнгән. Без әдәбият ярдәмендә укучыны тормышка хәзерләргә тиешбез. Педагог К.Д.Ушинский “Үле булмаган, максатсыз булмаган һәртөрле укыту баланы тормышка әзерләүне күздә тота”, дип язган. Әдәбият фәне – иң тормышчан фән. Ул үлә алмый. Аны тормышның бернинди фаҗигасе дә яшәүдән туктата алмый. Шулай булгач, әдәбият мәңгелек. Бары тик әдәбият кына әйләнә – тирәдәге кешеләрнең үз җаннарында ничек итеп матурлык һәм яхшылык йөртүләрен аңлата. Әдәби әсәрләр ничек яшәргә һәм нинди булырга юл күрсәтә. Кайбер әсәрләр елмаю тудырса, кайберләре күз яшьләре дә чыгара.Укытучы һәр әсәрнең үзенчәлеген тоеп, укучы күңеленә үтеп керерлек алымны сайларга тиеш. Өйрәнелә торган әсәр укучыга йогынты ясамый калмый, аның күңелен баета, игътибар үзәгенә тормышның нинди дә булса бер проблемасын калкыта.

Дәрестә иҗади эшләр башкару, биремнәр үтәү - һәр укучының уй – фикерләрен белергә ярдәм итә. Дәреслекләргә кертелгән мәкаль, табышмак, әкият, легенда, риваятьләр укучыга халкыбызның әдәп – әхлак нормаларын, күркәм гореф – гадәтләрен яратырга һәм үзләштерергә ярдәм итәләр.

Мәгълүм булганча, 2013ел - Рәсәйдә экология елы. Кешенең табигать белән тыгыз элемтәдә яшәве тормыш өчен кирәк. Табигатьне саклау - аны хөрмәт итү, кыерсытмау, киләчәк буынга әрәм - шәрәм итмичә тапшыру дигән сүз. Ирексездән, бу урында Э.Авзалованың “Бу гүзәллек яшәрме?” дигән шигыре күз алдына килә:

Табигатьне кемнәр шулай
Әрәм иткән?
Кешеләрдә миһербанлык
Кая киткән?
Җир елый,ишетәсезме?
Мин ишетәм!
Бу гүзәллек, бу җир шары
Яшәр микән?

Табигатьне саклау - һәркемнең изге бурычы ул. Планетабыз бик нык пычранган, без зур бер чүплектә яшәгән кебек, ләкин кешелек дөньясы әле моны аңлап бетерә алмый. Без бүген җирдә яшибез, ләкин киләчәк буыннар яши алырмы?

Табигатьнең чын бүләген
Җәберләгән җансыз адәм.
Мәгънәсезлек, вөҗдансызлык
Арта бармыймы һаман?

Бу урында Нурислам Хәсәновның “Эт каргышы” хикәясендәге кансыз җанлы герой Фазылның эт баласын вәхшиләрчә каен агачына асып, юк итүе укучыларны уйланырга мәҗбүр итә. [4, с 223]

Шулай ук Нурислам Хәсәновның “Ак балык” әсәрендәге ташландык хәлдә булган табигать укучыны битараф калдырмый.

[3, с 49]...Җиһангирның, юл кырыйлап барганда, ягулык агып сеңүдән шактый гына җирнең үлән үсмәслек хәлгә килеп пеләшләнеп калуын күргәч, йөрәге әрни. Шул ук вакытта ашламадан бушаган бер полиэтилен капчыкның яртылаш җиргә күмелеп, туфракка кысылып калганын күреп:

- Тәртипсезлек инде, - болай барса, бөтен дөньясын чүп басар, адәм чирдән арына алмас, - ди ул. Кая барабыз, белгән юк. Үләт базын да оныттык, тиресе бүреккә дип атылган этнең үләксәсе инеш буенда ауный.

Г.Ибраһимовның “Алмачуар” хикәясен өйрәнү барышында без гадәттә укучыларда хайваннарга, табигатькә мәхәббәт тәрбияләүне максат итеп куябыз.

Беркемгә дә сер түгел, соңгы елларда кешенең табигатькә йогынтысы көчәю белән тирә - юньнең пычрануы артты, ашамлыкларның сыйфаты начарайды. Югыйсә, кеше гасырлар дәвамында табигатьне үз иткән, аның күренешләрен өйрәнгән, шуның нигезендә табигатьне саклау күнекмәләренә ия булган һәм аны көндәлек тормышта файдаланган. Боларның барысы да халык тәҗрибәсендә, традицияләрендә, гореф - гадәтләрендә чагылыш тапкан. Без аларны мәкаль - әйтемнәрдә, табышмак - сынамышларда, риваятьләрдә, җыр - бәетләрдә очратабыз. Шулай итеп, халыкның педагогика һәм экология белемнәре халык авыз иҗатында киң чагылыш тапкан. Әкият, мәкаль, әйтем, сынамыш һәм табышмакларда бик күп экологик белемнәр тупланган. Аларны дәрестә һәм дәрестән тыш чараларда кулланганда укучылар күз алдына халыкның экология эшчәнлеге һәм табигатьне саклау чараларыннан торган образлар туа. Әйтик, “Иске коега төкермә, әле яңасын казыйсы бар”, “Агач утырттыңмы, инде син хөрмәтле кеше булдың”, “Өй янында бакчаң булса, сандугач теләп килә”. Экологик белем һәм тәрбия бирү ул - укучыларга экологиянең эчтәлеген, закончалыкларын, төшенчәләрен аларга сөйләп аңлату гына түгел, ә бәлки халыкның бай – әхлакый - психологик мирасын яшь буынга җиткерү чарасы да. Ул укучыга шәхес буларак җитлегергә булыша. Шулай итеп, бүгенге көн алдында торган төп бурычларның берсе – әхлакый яктан җитлеккән экологик культуралы шәхес тәрбияләү.

Табигатьне олыларга, яратырга өйрәтү - укучыларга экологик белем бирүдә мөһим бурычларның берсе. Табигатьнең матурлыгына хозурлану гына аз, аны саклый белергә дә кирәк. Укучыларга экологик белем һәм тәрбия бирү дәрестә, класстан тыш эшләрдә тормышка ашырыла. Татар теле дәресләрендә сүзләрнең мәгънәләрен аңлату барышында экологик белемне тирәнәйтергә була. Сөйләм үстерү күнегүләре эшләгәндә табигать турында мәкальләр куллану, аларның мәгънәләрен ачыклау урынлы. “Урманда кунакта”, “Табигать - безнең байлыгыбыз”, “Табигатьне саклау - безнең бурыч” кебек темаларга иншаларны укучылар теләп яза. Укучыларга үзең яшәгән тирәлекнең бер почмагын тасвирларга тәкъдим итәргә мөмкин. Экологик белемне үстерүдә әдәбият дәресләрендә табигать турында бирелгән әсәрләргә анализ ясау, укучыларга табигатьтәге үзгәрешләрне күрергә, чагыштырырга мөмкинлек бирә.

Яңа белемнәрне үзләштерү максатыннан “Болай буламы, әллә юкмы?”, “Хайваннарның моң - зары”, “Сурәтләү ярдәмендә бел” дигән дидактик материаллар кулланыла. Яз җитте исә бакчаларга сәяхәт, экскурсияләр оештырыла. “Туган як чишмәләре” дигән темаларга әзерләнү, тикшеренү эшләре алып барыла. “Экология” темасына төрле кичә, викторина, КВНнар, түгәрәкләр оештыру - максатка ирешергә ярдәм итә.

Без әдәбият дәресләрендә М. Әмирнең “Агыйдел” әсәрен укып, табигать матурлыгына соклandык. Гаяз белән Ильясның табигатьне яратучы, аның ямен аңлаучы егетләр булуына инандык. Шушы әсәр аша әйләнә – тирәгә сакчыл караш тәрбиялибез.

Соңгы вакытта без “экология” дигән сүзне көннән - көн ешрак кабатлый башладык. Нәрсә соң ул экология? Анын мәгънәсен без тулысынча аңлап бетерәбезме?

Безнең максат - әдәби әсәрләр аша укучыларда экологик чисталык кануннарын яшәешебезгә торган саен ныграк кертү. Бурычларына килгәндә: сәламәт яшәү рәвеше тәрбияләү, әйләнә – тирә мохитнең экологик халәтенә анализ ясау алымнарын һәм методларын өйрәнү; чын мәгънәсендә туган

җиреңә, халкыңа мәхәббәт тәрбияләү. Моңа бары тик табигатьнең матурлыгын, гүзәллеген аңлау, ярату аша гына ирешеп була.

Шулай булгач, безгә бар көчебез белән табигатьне сакларга кирәк түгелмени? Әйе, бик кирәк. Бу сорауны һәркем үзенә биреп караса,туган җиребез гөлбакчага әвереләчәк. Ә нигә соң елгаларыбыз һаман пычрана, кырларда чәчәкләр, сайрар кошлар кими? Бу – җавапсызлыктан килә. Һәркем эшләгән эше өчен җаваплылык тоярга тиеш.

Безнең бурычыбыз – экологиядән билгеле бер күләмдә белем бирүдән тыш, әдәби әсәрләр аша укучыларга фәнни анализ күнекмәләрен үзләштерүнең, җәмгыять белән табигатьнең үзара бәйләнешен аңлауның, мохиткә гамәли ярдәм күрсәтүнең мөһимлегенә төшендерүдән гыйбарәт. Әлеге эш барышында укучы үзе проблеманы формалаштырырга, аның килеп чыгу сәбәпләрен ачыкларга һәм дәлилләргә, нәтиҗәләр ясарга, тәкъдимнәр ясарга өйрәнә.

Әлбәттә без табигатьтәге  глобаль үзгәрешләрне төзәтә алмыйбыз, ә елга, инеш, урамнарның халәтен яхшыртуга юнәлдерелгән дәресләр, чаралар оештыру – безнең көчтән килә торган эш.

Әйтик, безнең дәрес – экскурсияләребез бар. Бу дәресләр аша табигатькә күзәтү ясыйбыз, табигатькә һәм тирә – юнебездәге кешеләргә карата дустанә мөнәсәбәт һәм җаваплы караш тәрбиялибез. Экскурсияләрдә укучыларның күбесе төрле яктан ачылып китә. Аннан кайткач укучылар ирекле хикәя, иншаларны бик теләп язалар.

Табигать - кешенең яшәү урыны. Без табигатьне  яратабыз, аннан җаныбызга ямь, күнелебезгә тынычлык алабыз. Табигатьне саклау - ул үзебезне, киләчәгебезне, өебезне саклау дигән сүз. Үз - үзеңә, туган җиргә тугры булып калу, аның кадерен белү, элек - электән яшәү мәгънәсенең асылын аңлаткан. Безгә аны югалтмыйча, тагын да баетып, килер буыннарга мирас итү бурычы йөкләнгән.

Кулланылган әдәбият

1. Мәгариф журналы, 2007 ел №2
2. Мәгариф журналы, 2013 ел №6

3. Н. Гыймадиева. Дәрестә һәм дәрестән соң. “Яңалиф”. Казан – 2004 ел

4. Н.Хәсәнов. Хакыйкать хакы. Татарстан китап нәшрияты. Казан – 2005 ел

5. С.М. Трофимова. Татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен методик ярдәмлек. “Яңалиф” нәшрият йорты. Казан – 2005 ел.

## Кабатланмас шәхесләр тәрбиялик

***Насыйрова Миләүшә Сәлмән кызы,***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы***
***МББУ “Лицей №14” Түбән Кама шәһәре***

Мәшһүр татар мәгърифәтчесе К.Насыйри үз вакытында: «Тәрбия – һәр нәрсәнең ачкычы, аның белән һәр нәрсәне хәл итеп була, ул – кешене кеше итүдә иң дөрес юл», – дип, бик дөрес язган. Яшь буында гуманлылык, патриотизм кебек мәңгелек рухи-әхлакый кыйммәтләр тәрбияләүдә тупланган байлыкны югалтмау, киресенчә, аны үстерү, баету, тәрбия эшендә куллану зур әһәмияткә ия. Балаларга белем һәм тәрбия бирү юлы – туган нигезгә, төбәккә, халыкка, аның гореф-гадәтләренә, йолаларына ихтирам тәрбияләү, моның өчен төрле чаралардан киң һәм нәтиҗәле файдалану, шулар ярдәмендә укучыларда югары әхлак сыйфатлары булдыру, белем алуга, сәламәт яшәешкә омтылыш уяту, үзара һәм башка кешеләр белән иркен аралаша белү күнекмәләре үстерү дә ул…

Билгеле булганча, кешенең шәхес булып формалашуында әхлак тәрбиясе төп һәм иң әһәмиятле урын алып тора.

Яңа стандартлар без укытучыларга, фән-техника зур тизлек белән үскән, радио-телевидениедә, интернетта чуар мәгълүмат ташкыны агылган һәм алардан күбесенчә тормышның тискәре яклары күрсәтелгән заманда югалып калмаслык, үз урынын табарлык нык ихтыяр көченә ия булган, белемле, әхлаклы һәм шуның өстенә бүгенге хезмәт базары шартларында көндәшлек сыйфатларына ия булырдай буынны тәрбияләү бурычын куя.

Әхлакый тәрбия ул:

- халкыбызның милли үзенчәлекләрен, күркәм сыйфатларын, йола-гадәтләрен, гаилә этикасын кече яшьтән үк төшендереп, укучыларны өлкәннәр үрнәгендә тәрбияләү;

- җәмгыятьтә яшь буынны рухи әхлаксызлыктан коткару;

- балаларда гомумкешелек кыйммәтенә аңлы караш тәрбияләү;

- кешеләр белән аралашу кагыйдәләренә өйрәтү;

- югары әдәп, әхлак сыйфатлары булдыру;

- иҗади сәләт һәм милли үзаң формалаштыру;

- тәрбия бирү процессына әти-әниләрне катнаштыру;

- йолалар нигезендә сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау.

Әхлакый тәрбия бирүнең эш формалары:

- татар теле һәм әдәбияты дәресләре;

- фәнни-тикшеренү эшләре;

- әдәби-музыкаль кичәләр;

- тәрбия сәгатьләре;

- экскурсияләр (музейлар, китапханәләр);

- конкурслар, ярышлар;

- түгәрәкләр;

- әхлак һәм иман дәресләре.

Мәктәпкә укучыларга белем бирү генә түгел, дәресләрдән соң аларны хезмәткә өйрәтү, балаларның сәләтен ачарга ярдәм итү , аларга әхлак тәрбиясе бирү мөһим. Татар теле һәм әдәбияты дәресләре – рухи һәм әхлакый тәрбия бирүнең нигезен тәшкил итә. Татар теле дәресләре өчен материал туплаганда укучыларга төрле яклы тәрбия бирерлек текстлар сайлау укучыларда әхлакый сыйфатлар тәрбияли. Әдәбият дәресләре әхлак тәрбиясе булдыру өчен иң туры юл булып санала.Укытучы әдәбият ярдәмендә укучыны олы тормышка әзерли. Дәреслеккә кертелгән текстлар, әдәби әсәрләр мавыктыргыч эчтәлекле, аларда тормышчан ситуацияләр тасвирлана. Алар укучыга үз-үзен тоту, үзендә нинди шәхси сыйфатлар булдыру кирәклеге турында мәгълүмат бирә.

Фәнни-тикшеренү эшләре дә укучыларны тормышка әзерләү уңаеннан бик әһәмиятле. Галимнәр сәләтсез балалар юк, һәркемнең нәрсәгә дә булса сәләте, омтылышы була диләр, ә безнең – укытучыларның бурычы – баланың сәләтен ачыклау, ихтыяҗын төрле яктан канәгатьләндерү, сәләтен үстерү.

Бу уңайдан татар теле һәм әдәбияты дәресләре – укучылар эшчәнлеген активлаштыру, иҗади фикерләү өчен бик тә уңайлы җирлек.

Татар теле укытучысы буларак, мөһим бурычларымның берсе – укучыларны мөстәкыйль рәвештә иҗади фикер йөртергә һәм нәтиҗә ясарга өйрәтү, укучыларның эзләнү, тикшеренү һәм иҗади фикерләү эшчәнлеген активлаштыру, сәләтле балалар белән эшләү.

Сәләтле балалар барлыгын ачыклау гына татар теле укытуның нәтиҗәлелеген күтәрми. Һәр баланың үзенә генә хас сыйфаты бар. Мин исә, сөйләү күәсе көчле булган, татар әдәби телендә дөрес, ачык сөйләшүче, фикер йөртүче, зиһенле балаларны фәнни-гамәли конференцияләргә, ә татар теле грамматикасы буенча тырыш, ныклы белеме булганны, ләкин тыныч холыклы, күзгә артык ташланмый торган укучыларны фән олимпиадаларына тартырга тырышам. Төрле эш юнәлешләрне кулланып, фәнни-тикшеренү эшләрен башкарганда, әлбәттә, көтеләчәк нәтиҗәләр дә бик югары була. Бу эшләр сәләтле балаларның шәхесен, әхлакый-эстетик сыйфатларын, дөньяга карашын, холкын формалаштыра.

Үз чорының, милләтенең барлык күркәм сыйфатларына ия булган, халкын хөрмәт итә, ярата торган һәм аның мәнфәгатьләрен кайгыртып яшәргә сәләтле булган иҗат кешесе, башка милләт вәкилләренә әдәплелек тойгысы һәм ихтирам белән карый белә торган зыялы укучылар тәрбияләүгә ирешү. Әхлаклы кеше тәрбияләү – катлаулы бурыч, ләкин аңа ирешергә мөмкин дип саныйм. Бу гаҗәеп җаваплы, әһәмиятле эшне үтәү өчен, педагог көчен кызганмаска, армый-талмый эшләргә, профессиональ осталыгын даими күтәрергә тиеш.

Кулланылган әдәбият

1. В. С. Казыйханов. Әхлак дәресләре. Дәрес эшкәртмәләре. Яр Чаллы. Өзлексез педагогик белем бирү институты, 2001.

2. Заһидуллина Д.Ф. Мәктәптә татар әдәбияты укыту методикасы. Казан: Мәгариф, 2004.

3. Җәләлев Ш.И. Татар халык педагогикасы. – Казан, “Мәгариф”, 1997.

## Дәрья суы сыман минем уйлар...

(Якташ әдипләребез иҗатында экологик һәм әхлакый тәрбия чагылышы)

***Нәҗмиева Гөлнар Ленар кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы, МБГББУ “Күбәк урта гомуми белем бирү мәктәбе”***

XXI гасыр – инновацион технологияләр һәм мәгариф өлкәсендә зур мөмкинлекләр тудырган заман. Бүгенге мәктәпнең төп бурычлары – укучыларның иҗади сәләтләрен, потенциалын ачу һәм үстерү; көндәшлеккә сәләтле шәхес тәрбияләү. Әлеге бурычлар янәшәсендә, укучыларга әхлакый тәрбия бирү белән беррәттән, XXI гасырның иң мөһим тәрбияви юнәлешләреннән экологик тәрбия бирү зарурлыгы килеп туды. Дөрес, тәрбиядә бу юнәлешләр элек-электән яшәгән, халык педагогикасы шуны раслый. Ләкин бүгенге зур тизлек һәм үзгәрешләр, яңа технологияләр белән эшләүче завод-фабрикалар үрчегән заманда Табигать-анабызны саклау, чистарту зарурлыгы мөһим проблемаларның берсенә әверелде. Ә бу өлкәдә тәрбия бирү укытучыларның һәм тәрбиячеләрнең төп бурычлары дияр идем мин. Бигрәк тә татар теле һәм әдәбияты мөгаллимнәре бу юнәлештә максатчан һәм нәтиҗәле эш алып баралар. Мин үзем сыйныф җитәкчесе һәм тел-әдәбият укытучысы буларак, укучыларыма әхлакый һәм экологик тәрбия бирү эшчәнлегендә якташ әдипләр иҗатына бик теләп мөрәҗәгать итәм. Чөнки барысы да үзебезнеке, кичәге, бүгенге, үзебезнең тормыш... Геройлары, персонажлары, вакыйга барган урыннары да көн саен аралашкан, очрашкан, ачуланышкан, дуслашкан үз кешеләребез, урамнарын таптаган авылларыбыз, күнегеп беткән үз мохитебез. Ә бу хезмәтемдә Мөслим районының Г.Тукай исемендәге премия лауреаты, халык язучысы, прозаик, драматург Ф.Садриев һәм Татарстанның

атказанган сәнгать эшлеклесе, мәшһүр татар шагыйре, СССР Язучылар берлеге әгъзасы, Түреш авылы егете Харрас Әюп иҗатларында әхлакый һәм экологик тәрбия чагылышына күзәтү ясармын.

Харрас абый – табигать, авыл җырчысы. Туган як табигате аңа бөтен барлыгы белән ярдәм итә: “җил яшьләрен сөртә”, “җәйләр елаган җанын җылыта”. Шагыйрь үзенең кылган һәм кылачак эшләрен дә табигать бизмәнендә үлчи.

Шагыйрь образы безнең алга табигатьнең, туган як туфрагының телен белүче тылсым иясе булып килеп баса. Әдипнең үз сүзләре белән әйткәндә, “ул пәрәвез тирбәлүен ишетә”, “гөлләрдәге күбәләкне укый, җилләр җырын тыңлый”, “камыш белән серләшә”. Харрас абый шигъриятенең үзенчәлеге табигатьне, авылны халык яшәеше белән, җиһан белән бербөтен итеп, бер җан, бер тән итеп гәүдәләндерүендә. Барлык яшәеш – рухи һәм матди дөнья - бердәм, алар туктаусыз бер-берсенә йогынты ясыйлар. Шагыйрь бу бөтенлекне бозарга ярамый дип әйтә шикелле, укучыны үзеннән-үзе уйланырга этәрә.

Хыянәткә барсам, тау ишелер,

Нәкъ урталай ярылыр бу болын.

Имәннәрне давыл йолкып ташлар,

Барысы бергә дәшәр: “И-и-х, улым!”

Харрас абый өчен авыл образы белән үрелгән иң җылы, иң якты Кояш, әлбәттә, Ана образы. Газиз аналар - безнең барыбыз өчен дә изге җаннар. Шул бөек затны шагыйрь тере һәйкәл итеп пьедесталга менгерә, күңелендәге җылы хисләргә төреп, аңа Дан һәм мәдхия җырлый. Фоат Садриев билгеләп үткәнчә, “ана образы Х. Әюп иҗатында туган йорт, Ватан, милләт төшенчәсе белән кушылып китә һәм зур символик мәгънәләр ала”. Димәк, әнкәйләргә тугрылык – ул милләтеңә, Ватаныңа, кешелеккә тугрылык дигән сүз.

“Харрас” дигән гарәп сүзенең безнеңчә мәгънәсе – саклаучы, яклаучы. Харрас Әюп, чыннан да, исеме җисеменә туры килә торган шәхес. Аның иҗаты белән күбрәк танышкан саен, аның әсәрләре аша Табигатебезне һәм Милләтебезне яклау белән шөгыльләнгәнен ачык күрәбез.

Ф.Садриев иҗатына күз салсак, монда да саллы гына тәрбияви хәзинә туплануын күрербез. Әдип фикеренчә, авыл - кешене тәрбияли торган урын. Аның күпчелек әсәрләрендә авыл кешеләренең эшкә намуслы карашы, бер-берсенә карата матур мөнәсәбәтләре, тормышта максатчан яшәү, ата-бабаларыбыздан калган гореф-гадәтләрне саклау, аларны баету кебек тәрбияви өлешләр бар. Ә табигать күренешләре геройларының уй-хисләре, тормышы белән үрелеп бара. Язучы “Адәм әүлиясе” повестенда хәзерге авылның аяныч сурәтен тудыра. Монда без әле күктән, әле җирдән агу сиптерү сәбәпле, яртылаш саргаеп беткән каенлыкны да, бер генә төнбоегы калмаган, өстеннән кара нефть өреләре һәм җәйләүләрдән төшкән сыер тизәкләре агучы үлмәс Чалмыя елгасын да, сөт планын үтәргә мәҗбүр булган сыерларның әрәмәдәге соңгы карлыган, шомырт, балан куакларын юк итүен дә, алабута баскан хуҗасыз өй урыннарын да, кызыл миләш тәлгәшедәй колорадо коңгызы каплаган бәрәңге бакчаларын да күрәбез. Ә инде Кояш, шушыларның барысыннан да качып баргандай, кып-кызыл булып офыкка якынлаша. Бу картина авылның бүгенге хәлен тулаем сурәтли. Ә инде чынбарлыкта әлеге күренеш белән очрашкан укучыны тагын бер кат авылга янаган куркыныч турында уйланырга мәҗбүр итә, табигатькә дустанә мөнәсәбәттә булырга өнди, ата-бабаларыбыз ясаган хаталарны төзәтү өстендә эшләргә чакыра.

Якташ әдипләребез иҗаты - бетмәс-төкәнмәс рухи, мәдәни, тәрбияви хәзинә. Аларны өйрәнү аша фән-техника, яңа технологияләр белән җенләнгән яшь буынга аз булса да иман, әдәп-әхлак, игелек орлыклары чәчеп булыр дип өметләнәм.

Кулланылган әдәбият

1. Мәйдан № 2 – Яр Чаллы, 2004.
2. Мәйдан № 8 – Яр Чаллы, 2006.
3. Садриев Ф.М. Көлми торган кеше. – Түбән Кама: Ихлас, 2004.

## М. Җәлил иҗатында әхлак һәм экологик тәрбиянең чагылышы

***Низамбиева Раушания Ринат кызы,***
***Әгерҗе районы Тирсә урта гомуми белем бирү***
***мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы,***
***Дәүләтбаева Рузилә Нуршаех кызы***
***Әгерҗе районы Тирсә урта гомуми белем бирү***
***мәктәбенең башлангыч сыйныфлар укытучысы.***

Укучыларда туган илебезгә мәхәббәт һәм туган як табигатенә сакчыл караш тәрбияләү аларның рухи-әхлакый сыйфатларын үстерүдән башлана. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә күренекле әдипләребезнең иҗаты ашы укучыларда әхлак сыйфатлары камилләштерелә. Һәр язучының әсәрендә әхлак проблемалары үзәккә куела. Без эшебездә М. Җәлил иҗатында әхлак һәм экологик тәрбия бирелешен өйрәнүне максат итеп билгеләдек. Шул максаттан чыгып, мәктәп программасында өйрәнелгән “Кызыл ромашка”, “Ана бәйрәме” шигырьләренә тукталдык. Ике шигырьдә дә шагыйрьнең туган илгә, аның табигатенә мәхәббәте чагыла. Шигырьләрдә Ватан өчен көрәшкән батырларга дан җырлана. “Кызыл ромашка” шигырендә сугыштагы батырлыклар һәм батырларның үлемсезлеге турында гына сүз бармый, ә сугышлар табигать матурлыгы белән капма-каршы куела. Шигырьдә автор сурәтләгән болыт, зәңгәр күк , ромашкалар, таң ату кебек табигать матурлыгы аша шатлык хисе бирелә. Автор кулланган сынландырулар (ромашка уены, елмая, хәл сораша, моңлана) табигатьнең җанланып егет өчен борчылуын, теләктәшлеген белдерә. Димәк, кеше һәм табигать аерылгысыз. Егет тә бит, Ватаны, туган җире өчен көрәшеп, туган туфрагында үскән ромашкаларны саклый. Әлеге шигырь Җир-Анага игелек, хөрмәт хисләрен уята, шигъри бизәкләре белән табигатьнең гүзәллеген ачып бирә. Табигатькә мәрхәмәтле караш автор тарафыннан кулланылган сынландырулар ярдәмендә формалаштырыла, укучыларның күңелендә кешелеклелек сыйфатлары тәрбияләүгә ярдәм итә. Шигъри сурәтләүләр, табигать матурлыгын тою аша укучыларда туган җирне, аның табигатен яклый, саклый белү хисе уяна.

Ватан-Ана төшенчәсе белән Җир-Ана төшенчәсе аерылгысыз. Ватан-Ана дигәндә, туган җир ана кебек кадерле, изге дигәнне күзаллыйбыз. Туган җиргә мәхәббәт анага мәхәббәттән башлана . Анасын сөйгән бала туган илен, туган җиренең гүзәл табигатен сөя, аның табигатенә сак караштa була дигән нәтиҗә ясарга мөмкин. Муса Җәлилнең “Ана бәйрәме” шигырендә дә ана образының туган ил, Җир-Ана белән бәйле булуын күрәбез. Ана Ватанны саклап көрәшкән ике улы өчен сагышлана, ә илгә Җиңү алып кайткан улы өчен шатлык кичерә. Өч батыр анасының һәрвакыт балалары һәм ил язмышы өчен борчылып яшәве табигать аша укучылар күңеленә салына. Бу әсәрдә дә автор ананың язмышын сурәтләгәндә җил, күгәрчен, очар кош кебек табигать образларын куллана. Алар да анага теләктәшлек итә: ана белән кайгыра, ана белән сөенә. Ә “Вәхшәт” шигырендә дошманга каршы ана үзенең сөекле баласы белән бергә көрәшә. Аларның икесен дә фашист ерткычлыгы куркытмый. Әлеге вәхшәтне ана һәм бала белән бергә табигать тә кабул итә алмый. Автор сынландыру алымы аша укучы күңелендә табигатьне җанландыра. Табигать кеше кебек уйлана, борчыла башлый. Мәсәлән: үкереп акты елгалар, яшен түкте ярсып Җир-Ана, моңлы кояш үксеп үпте, урман шашып шаулады, җир елады кысып тешләрен һәм башкалар. Автор тарафыннан кеше һәм табигать берлегенең аерылгысыз рәвештә сурәтләнүе укучыларга экологик һәм әхлак тәрбиясе бирүдә мөһим чара буып тора. Фикерне йомгаклап, түбәндәге нәтиҗәгә киләбез:

1. Кеше һәм табигать арасындагы теләктәшлек нәтиҗәсендә, укучыларда Ватанга, туган җиргә мәхәббәт, Җир-Анага сакчыл караш тәрбияләнә;
2. М. Җәлил шигърияте аша укучы табигать матурлыгын тоя;
3. М. Җәлил шигъриятен өйрәнү, милләтебез тарихын белүгә кызыксыну уята.

М. Җәлил шигъриятенең үлемсезлеге шунда: шагыйрь туган ил, Ватан-Ана, табигать төшенчәләрен үзара тыгыз бәйләнештә куеп, яшь буынга шигырьләре аша әхлак сыйфатларын тапшыра алган. Татар халкының герой-

шагыйре Муса Җәлил иҗаты милләтнең әхлагын үстерүдә, яшь буында әхлак сыйфатлары тәрбияләүдә һәм экологик тәрбия бирүдә мөһим урын алып тора.

Кулланылган әдәбият:

1. . Ә. Җәлил “М.Җәлил турында”, 1989.

2. Заһидуллина Д.Ф. Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2000.

3. Низамов А.М. Милли мәктәп тәрбия нигезләре.- Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2005.

## Туган телебезне, аның сафлыгын саклыйк!

***Нургалиева Халидә Әбүзәр кызы,***
***Татарстан Республикасы Азнакай***
***муниципаль районы муниципаль***
***бюджет гомуми белем учреждениесе***
***«Тымытык авылы гомуми урта белем мәктәбе”нең***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы.***

Тел, тел, дибез, тел нәрсә!-
Әгәр телә белмәсә:
Бәгырьләрне телә-телә,
Усал көлә белмәсә,
Йомшарып, тасма телләнеп,
Җанга керә белмәсә?!
Телнең ачысы була,
Телнең төчесе була;
Ачысын да, төчесен дә
Татыр кешесе була;
Ачы тел хак агайда,
Төче тел ялагайда:
Төче тел бик кирәк була
Тәлинкә ялаганда.
Телнең тияге булмый,

Өнди ул әдәпкә дә,
Күндәм ул әләккә дә.
Ләчтит саткан да шул тел,
Дан тараткан да шул тел,
Тәнкыйтьченең авызында
Эшсез яткан да шул тел.
Тел елата, юата,
Матур уйлар уйлата,
Я үрти, я көлдерә
Уңдыра, я бөлдерә.
Сөйдергән дә тел генә,
Көйдергән дә тел генә...
Тел шикелле универсал
Бу дөньяда бер генә.
Телең барында, бер дә

Телнең сөяге булмый.
Никадәрле сөйләсә дә,
Телнең сөяге булмый.
Эшләгәннең – кулында,
Сөйләгәннең – телендә.
Телнең серен белим дисәң-
Хикмәт-телнең төбендә.
Тел шигырьләр дә укый,
Тел вәгазьләр дә тукый,
Сүз әйталмый тилмермә:
“Тел – дошманым!” – дип әйтеп,
Телгә телең тидермә.
Уе юкның - теле юк,
Теле юкның – иле юк.
Илен санга санамаган
Телсездән дә тиле юк.

Нури Арслановның “Тел” шигырендә телнең иҗтимагый тормыштагы әһәмияте бик тулы чагылган. Кешеләр арасында телдән башка тулы канлы аралашу мөмкин түгеллеге әйтелгән. Чыннан да, тел – кешеләр аралашуында иң әһәмиятле чара. Тел җәмгыятькә бәйле, һәм җәмгыять үсеше өчен гаять әһәмиятле.

СССР таркалгач, милли союздаш республикалар мөстәкыйльлек алды, элекке автономияле республикалардан Татарстан да мөстәкыйль дәүләт дип игълан ителде.

“Татарстан Республикасы халыклары телләре турында”гы Татарстан Республикасы Законында татар теле рус теле белән бертигез дәрәҗәдә дәүләт теле дип игълан ителүе турында әйтелгән. Ә дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрелгәнче, телебез нинди язмышларга дучар ителгән соң?

Сыйнфый һәм милли изүгә корылган патша Россиясендә рус булмаган милләтләргә карата бөек державачылык сәясәте алып барылды. Ягъни патша хөкүмәте рус булмаган халыкларны, көчләп, христиан диненә күчерү һәм шуның аркылы аларны руслаштыруны, ягъни ассимиляцияләүне алга сөрде. Учреждениеләрдә эш алып бару өчен, бары рус теле генә файдаланылды. Мәктәпләрдә бары рус телендә генә укыттылар. Рус дәүләте , милли телләрне үстермәү өчен, барлык чараларны күрде.

Үз чорында шагыйрь Һади Такташ та, тел язмышына борчылып, “Авызлары, борыннары җимерелгән сүзләрне яклап” дигән шигырен иҗат итте:

Кабыргасыз, йомшак урыс теле ,
Ничек борсаң шулай борыла
(Башка чарасы юк)
Безнең агай-эне
Эләккән һәр урыс сүзенең
Кабыргасын тотып сындыра!
Сүз юк –
Урыс телен белү кирәк нәрсә,
Ләкин
Кирәклеген аның бутыйлар,
Татарларга татар була торып,
Урысчалап доклад укыйлар.
Ответработниклар!
Бәлки,
Урыс теле шәп тел икәнлекне

Урыс теле инде урыс белән
Сөйләшергә, әйтик, яраса,
Татар теле ул бит татар белән
Аңлашырга ярый лабаса...

Күрсәтүдер сезнең уегыз,
Тик шулай да зинһар куегыз!
Ответ дигән сүзнең “в” сын ашап,
“Әтбит” дигән булып йөрисез,
“Моя” белән “мой”ның муенын борып,
Үтерергә, ахры, телисез.
“Совсем” сүзен “Чәпчим” чәпчеттегез,
Урыс аңламаслык иттегез,
Бу ни хәл бу, “әтбит работниклар”,
Бу нинди юл белән киттегез!?
Татар газетына урысчалап
Мәкаләләр язып бирәсез
(Секретарьга кушып яздыруны
Сизмиләр дип, ахры, беләсез...)

Шагыйрь, үз чиратында, татар телен кимсетмәскә чакырып , чаң суга.

Ләкин җәмгыять хосусый милеккә корылган булганлыктан, татарлар арасында да хәлле, бай кешеләр күренә башлый, һәм алар татарлар өчен хосусый мәктәпләр, мәдрәсәләр ачалар. Нәтиҗәдә патша Россиясенең бөек державачыл сәясәтенә карамастан, татар милли әдәби теле формалаша һәм каршылыкларны җиңә-җиңә үсеп килә.

“СССР таркалып, Татарстан мөстәкыйль дәүләт дип игълан ителгәннән соң, телебезнең кулланышын тагын да киңәйтү өчен көрәш

башланды. Мәктәпләрдә, югары уку йортларында, дәүләт учреждениеләрендә татар теленең кулланышын арттыру эше бара”, - дип язылган Мирфатыйх Зәкиев һәм Сәгадәт Ибраһимов авторлыгындагы 2008 нче елда нәшер ителгән 9 нчы сыйныф татар теле дәреслегенең “Татар әдәби телен ассимиляцияләүгә, ягъни руслаштыруга, рәсми чик кую” дигән 39 нчы параграфында.

Әмма бу дәреслек чыкканга да инде 9 ел вакыт узып киткән. Соңгы вакытта татар авылы мәктәпләрендә дә аерым фәннәр русча укытыла башлады. Сәбәбе – 9, 11 нче сыйныфлардан соң биреләсе имтихан биремнәренең нигездә рус телендә булуы. Нишлисең? Заман таләбе шундыйдыр инде.

Бу җәһәттән, мин укыта торган мәктәп бу мәсьәләдә берничә еллар алда бара инде. Татар авылының татар мәктәбендә бүген бары тик 5 кенә татар сыйныфы калды. Хәзерге вакытта мәрхүм булган элеккеге авыл Җирле үзидарә башлыгы Рушан Шәйхетдинов Министрлыкка авылыбызда рус сыйныфы ачтыруны үтенеп мөрәҗәгать итә. Аның үтенече канәгатьләндерелә. Шул үрнәктә хәзер һәр елны диярлек беренче сыйныфка балаларын укырга кертергә теләүче ата-аналар рус сыйныфы ачтырып баралар. Аларны рус сыйныфы ачтырган өчен гаепләр идең – киләчәктә БДИ бар, гаепләмәс идең, бу тагын кыйбланы большевиклар чорына юнәлтүгә охшап кала. Бу хәлләр, имтихан бирергә рус теле кирәк булган өчен генә, татар теленең дәрәҗәсен тагын төшерә башламадык микән дигән уй тудыра миндә.

Үз чорында Садри Максуди мондый фикерләр әйткән: “Ят телдә иң мөкатдәс нәрсәләрне өйрәнү мөмкин түгел. Һәрвакытта ислам динебезне вә телебезне өйрәнергә теләячәкбез һәм телебезне өйрәнми башлаган көннән башлап без бетә башлаячакбыз. Безнең бер милләт булып тора алуыбыз телебезне саклый алуыбызга баглыдыр. Телебезне саклый алсак, бер милләт булып тора алырбыз, әгәр телебезне саклый алмасак, милләтебездән мәхрүм булырбыз. Укуханәләрдә (югары уку йортлары) телебезнең укылу-укылмавы безнең милләтебезнең исән калу-калмавы мәсьәләсе белән бер дип уйлыйм...”

Ә бит башка милләт кешеләре бу мәсьәләгә бик сак килә. Күптән түгел Казанда яшәүче Әлфия Гайнуллинаның “Себерке” газетасындагы

“Уйланырга җирлек бар...” дигән рубрика астында бирелгән “Рус телендә генә сөйләшергә тиешсез!..” Яки кемнән үрнәк алырга? дигән мәкаләсен укыдым. Мәкаләне үзгәртмичә бирәм: “Күршебездә чечен егетенә кияүгә чыккан татар хатыны яши. Бу тыйнак, мөлаем хатын белән еш күрешәбез. Әлбәттә инде, рәхәтләнеп үз телебездә гапләшәбез. Ул минем белән күрешүләрне көтеп ала, чөнки, уйлавымча, туган телендә сөйләшү теләге көчле. Ә гаиләсендә ире белән дә, балалары белән дә (гәрчә алар татар мәктәбендә белем алсалар да) русча сөйләшергә туры килә. Берникадәр вакыт чечен җирендә яшәсәләр дә, ханым чечен телен тулысынча үзләштерә алмаган, ә калганнары, ни өчендер, татар телен өйрәнергә атлыгып тормыйлар.

Мине чеченнарның ана теленә булган мөнәсәбәте бигрәк тә таң калдырды. Ике чечен халкы бергә туры килсә, алар яннарында тагын башка милләт вәкиле булса да, бары тик үз телләрендә генә сөйләшәләр икән.

Күршем сөйли: иренең сеңлесе  Казанда (ягъни чит мәмләкәттә) яшәгәндә, үз баласын балалар бакчасына йөртә һәм баласы белән бары тик ана телендә генә сөйләшә. Тәрбияче моңа кисәтү ясый. “Өегездә теләсә нишләгез, тик биредә, ягъни бакчада, бары тик рус телендә генә сөйләшергә тиешсез!” – дип күрсәтмә бирә. Кайда язылды икән бу канун? Шулай да монысына әллә ни шаккатмыйбыз, кайсы татар әнисе генә заманында мондый күрсәтмә алмаган?! Иң кызыгы яшь ананың тәрбиячегә биргән җавабында. “Мин, - дигән ул, - кайда гына, хәтта Америкада булсам да, үз балам белән бары тик ана телендә генә сөйләшәчәкмен!” Тәрбияче ни дип җавап биргәндер горур халыкның бу горур баласына, билгесез. Тик бу сүзләрдә гади генә хатын-кызның үз Ватаны, халкы һәм туган теле өчен горурлыгы ярылып ята. Менә кайда ул туган телен яклаучы һәм саклаучы! Менә кемнән үрнәк аласы иде! Мондый сакчылары булган халыкның киләчәге өчен дә, теленең язмышы өчен дә куркасы юк”.

Башка милләт кешеләренең үз телләренә мәхәббәтенең көчле булуы турында тагын бер  мисал китерәсем килә. Мөслим районында туганнарыбыз Гассан һәм Айгөл Нассерлар яши. Икесе дә врачлар,  дүрт бала тәрбиялиләр. Гассан Нассер – Ливан гарәбе. Гаиләдәге балалар әниләренең татар телен дә,

этиләренең гарәп телен дә, өстәмә рус, инглиз телләрен дә үзләштергәннәр. Югыйсә, Мөслимдә, аралашыр өчен, бүтән бер генә гарәп тә юк. Ә эти кеше, үз балаларын үз телендә рәхәтләнеп сөйләшә аларлык итеп, телләрен ачтырган. Хәтта 3-4 яшьлек малайлары узган ел Ливаннан кунакка килгән ерак әбиләре белән татар Илсөяр әбиләре арасында тылмач та булып йөргән әле.

Мине тагын сөйләмебезнең саф булмавы борчый. Сөйләм саф булсын өчен, гасырлар буена тупланып килгән сүз байлыгын дөрес куллана белү таләп ителә. Туган телдә сөйләшкәндә, башка тел сүзләрен катнаштырып җөмлә төзү бу таләпне бозуга китерә. Тел уйнатуның наданлыкка ишарә булуын шагыйрь Дәрдемәнд узган гасырда ук әйтеп калдырган:

Кил,өйрән, и туган, бер башка телне,
Бүтән телләр белү – яхшы һөнәрдер.
Катыштырма вәләкин телгә телне,
Тел уйнатмак наданлыктан әсәрдер.

Мәҗит Гафури әсәреннән алынган менә мондый әңгәмәне саф сөйләмгә корылган дип кем генә әйтер икән?!

-Ну,товарищ, ярминкәгә барасыңмы?

-Юк, нигә? Дахуты расхутка җитми торган нәрсә артыннан вримә тирәйт итеп йөрүе не стоит. Үткән ел ул ярминкәгә барып, тәк сибә бушка йөреп, расхутланып кайттым. Бармасаң, двадсат раз лутчы икән.

Соңгы вакытта телнең рус сүзләре белән чуарлануында, саф булмавында, әлбәттә, катнаш никахларның да роле бик зур.

“Бабай белән дедушка Әби карчык Мәрфуга,
Бергә йөриләр эшкә Ә бабушка Матрёна.
Бабайның исеме Рәхим, Кече улы Рәхимнең
Дедушканың Трофим. Яшь кияве Трофимның,” - дип язган катнаш никахлар турында бер шигырендә Бари Рәхмәт. Гәрчә Коръән китабы катнаш никахларны бик хупламаса да, мәхәббәт тудыра шул аларны.

Үзебезнең Азнакай районы кызы, яшь автор-башкаручы Гөлгенә Кәлимуллинаның “Дочка” дигән җырында кайнананың марҗа килененә мөнәсәбәте көчле юмор белән иҗат ителгән.

Улым өйләнде бит әле,
Алып кайтты марҗаны.
Малай сөйгәч сүз әйтмәдем,
Марҗаның да бар җаны.

Здравствуй, дочка дорогая,
Миленькая ты моя.
Свадьба будет, гулять будем
Киленушка ты моя.

Татарның да була инде,
Була инде төрлесе.
Эш эшләми кабарынган
Бакадай гөберлесе.

Здравствуй, дочка дорогая,
Миленькая ты моя.
Андый татар кызларына
Җитәргә сиңа кая?

Туйлар узды, туннар тузды,
Инде дөнья куабыз.
Идәнне дә чиратлашып
Малай белән юабыз.

Здравствуй, дочка дорогая,
Усталая ты моя
Бераз гына булыш инде,
Я уж больно старая.

Малайны бик яраткандыр,
Ел саен бәби таба.
Ә кичләрен “мамага” дип,
Каядыр гулять чаба.

Здравствуй, дочка дорогая,
Весёлая ты моя.
Балаларга кирәк мама,
Төн йөрисең син кайда?

Китсен, китсен туктатмагыз,
Әнисе бар марҗаның.
Үпкәләмим, рәнҗемим дә.
“Бар өеңә, бар, җаным”

Здравствуй, дочка дорогая,
Марҗакаем, бичара.
Балаларны как-нибудь
Үстерербез ничава.

. Ә Ильвина җырлый торган “Яшьләрский мәхәббәт” җырында тел чуарлау иң югары ноктага җиткән. Бу - шулай ук бүгенге яшьләрнең сөйләменә бик нык охшатып иҗат ителгән шаян җыр.

Мин бит сөйдем сине генә,
Пора понимать инде.
Күпме ждала мин сине,

Ә мин, җүләр, һаман сине,
Ждать итәм кичләрен.
Сине мин уйлап йөрим,

Йөрәк замерзать итте. Сердцем яна кичләрен.

Ә син, милый, килмәдең, Әй, син, милый, ишет мине

Даже звонить итмәдең. Очрашыйк соң вечером.

Всё, значить, ташладың, Мин бит сине очень люблю,

Бүтән любовьлар таптың. Очень люблю, матурым.

Миңа тагын, симпотягам,

Письмо язмасаң бүтән.

Синңа любовь аңлатмамын

Луна астында кичтән.

Йомгаклап шуны әйтәсем килә, күп кенә милләттәшләребез, язучылар, шагыйрьләребез туган телебезнең язмышы өчен борчылалар, аны яратырга, сакларга чакырып, матур фикерләрен язып калдыралар. Мәсәлән, үз чорында язучы Гомәр ага Бәширов телне бик югары бәяләгән. “Тел... халыкның өзлексез байый һәм, иҗтимагый тормышның үзгәрүе белән бергә, һаман үзгәрә, яңара торган чиксез бай һәм кыйммәтле күңел хәзинәсе. Бу хәзинәгә халык үзенең ничә мең еллар буенча тупланган тормыш тәҗрибәсен,яшәеш турындагы фәлсәфәсен, үзенең иҗатын, гореф-гадәтен, уйларын-хыялларын, моңнарын-сагышларын, хәтта иң яшерен күңел кичерешләрен, интим хисләрен ышанып тапшырган. Шунлыктан һәр сүз борын-борыннан ук, халыкның әманәте рәвешендә, үзе белән билгеле бер мәгънә –йөкләмә алып килә, моңарчы билгеле булмаган бик күп серләрне ачарга ярдәм итә, аларны аңлатып бирә. Телсез халык үзе дә була алмый, халыксыз – тел дә юк. Шунлыктан телгә мәхәббәт бер үк вакытта халыкка да, туган илгә дә мәхәббәт дигән сүз... “- дип язган ул.

Ә Хәсән Сәрьян телебез турында түбәндәге матур фикерләрне әйтеп калдырган: “Телне без иң камил бер аралашу коралы, кешелек дөньясын алга әйдәп баручы бер прогресс чарасы дибез. Тел ул буыннан буынга ана сөте белән күчә килгән һәм күчәчәк иң мөкатдәс бер мирас булып, телен җуймаган милләтләрнең өстә ярылып яткан бердәнбер сыйфаты, билгеседер. Тел, ниһаять, - туган ил, туган җир ул!”

Кулланылган әдәбият:

1. М. З. Зәкиев: 8нче сыйныф өчен татар теле дәреслеге. – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2002.

2. М. З. Зәкиев, С.М. Ибраһимов: 9нче сыйныф өчен татар теле дәреслеге. – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2008.

3. Ф. С. Сафиуллина, Г. Б. Ибраһимов: ”Хикмәтле дә, бизәкле дә Туган тел”. - Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 1998.

4. “Себерке” газетасы: “Рус телендә генә сөйләшергә тиешсез!..” мәкаләсе.

## Татар әдәбияты дәресләрендә әхлакый тәрбия бирү

***Нуриева Лилия Фаиловна,***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы,***
***“Казан педагогия көллияте”ДАҺБУ***

Белем бирү стандартының яңа концепциясендә тәрбияләүнең төп максаты булып, күпмилләтле дәүләттә халыкның әхлакый һәм мәдәни байлыгы нигезендә әдәпле шәхес тәрбияләү тора. Бүгенге көндә белем бирү системасында әхлакый яктан тәрбияле буын үстерү, аеруча, актуаль мәсьәлә булып санала һәм, башлыча, әдәбият дәресләрендә башкарыла. Әлеге максатка ирешү юллары түбәндәге бурычларга таянып башкарыла:

- татар әдәбиятына хас рухи-әхлакый кыйммәтләрне, әдәби-эстетик үзенчәлекләрне аңларга өйрәтү;
- баланың үзаңын үстерү, ватанны яратырга өйрәтү, горурлык һәм гражданлык хисләре тәрбияләү;
- укучының мөстәкыйль, иҗади фикерләвен активлаштыру;
- әдәби әсәрнең эстетик кыйммәтен һәм милли үзенчәлекләрен тою хисе формалаштыру һ.б.

Әлбәттә, балага әхлакый тәрбия бирүне кече яшьтән үк башлау мөһим. Чөнки нәкъ менә кечкенә вакытта баланың үзаңы формалаша, яхшыны яманнан

аерырга өйрәнә. Үсә төшкәч, әдәби әсәрләр белән танышу барышында шәхес буларак тагын да камилләшә төшә, дөньяга, тирә-юньгә карашы ныгый.

Татар әдәбияты дәресләрендә нинди дә булса язучының иҗаты белән танышканда, иң беренче чиратта, әхлакый проблемаларга игътибар ителә. Нәкъ менә әдәби әсәрдә яктыртылган мәсьәләләр аша киләчәк буынны тәрбияләү бурычы килеп баса. Әлбәттә, укучының әдәби әсәрне кабул итү үзенчәлеге төрлечә. Әдәби әсәрне кабул итү төрле факторларга барып тоташа: дөньяга караш, хис-кичерешләрне кабул итү дәрәҗәсе, тәрбия. Тәрбиягә мөнәсәбәттә дөньяга булган караш та, хис-кичерешләрне кабул итү дәрәҗәсе дә үзгәрергә мөмкин. Шушы нисбәттән, матур әдәбиятның роле һичшиксез ачык чагыла. Әдәбият дәресләре әхлакый яктан тәрбияле шәхес формалашуга ярдәм итә.

Программа нигезендә, “Казан педагогия көллияте”ндә татар әдәбияты дәресләрендә Г.Исхакый, Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г. Кутуй, М. Җәлил, Ф.Кәрим, Ә.Еники, М.Мәһдиев, А. Гыйләҗев, Т. Миңнуллин кебек бөек шәхесләрнең әсәрләре җентекле анализлана. Шулар нигезендә яшь буынны рухи һәм әхлакый яктан тәрбияләү башкарыла.

Г.Исхакыйның “Ул әле өйләнмәгән иде” (катнаш никахлар темасы) повесте укучыны уйланырга, тормыш коруга җитди карарга чакыра. Төрле милләт вәкилләре бергә гаилә корган очракта халыкның гореф-гадәтләрен, дини ышануларын да истә тотарга кирәклеген ассызыклый. А. Гыйләҗевның «Әтәч менгән читәнгә” повесты да (күршеләр арасында мөнәсәбәт, хәзерге көн проблемалары) бүгенге көн укучысында кешелек мөнәсәбәтләрен тәрбияләүдә әһәмиятле роль уйный. Ни өчен дигәндә, әлеге әсәрләрдә күтәрелгән проблемалар бүгенге көндә дә актуаль яңгырый.

Г.Тукай шигырьләрендә халыкчанлык темасына тукталганда, шагыйрь иҗатының үзәгендә халыкның авыр тормышы өчен әрнү, аны яхшыртырга тырышу торганлыгы күренә. Аның шигъриятенең бүгенге көн укучысын тәрбияләүдә әһәмияте әйтеп бетергесез. С. Рәмиев, Дәрдемәнд иҗатларында милли темаларның чагылышы укучыларда татар халкына карата горурлык хисләре тәрбияләргә булыша.

Ф.Әмирханның “Хәят” повестенда хатын-кыз темасының яктыртылышы аша милли-әхлакый тәрбияне үзгәртергә кирәк дигән караш үткәрелә.

Һ. Такташ иҗаты аша (“Мәхәббәт тәүбәсе”) мәхәббәт, гаилә ныклыгы, бала тәрбияләүнең җаваплылыгы, ата-ана һәм балалар мөнәсәбәтенең иң изге, бөек хисләр булуына төшендерәбез. Г.Кутуйның “Тапшырылмаган хатлар” әсәрендә күтәрелгән гаилә темасын анализлаганда исә, Галия һәм Искәндәр образларының уй-фикерләре, хәрәкә-гамәлләре аркылы кеше психологиясенең никадәр катлаулы, каршылыклы булуын күрәбез. Укучыларда гаилә төзүнең кеше гомерендә олы һәм хәлиткеч адым икәненә ышаныч булдырыла.

М.Җәлил иҗатын өйрәнгәндә патриотизм, туган илгә мәхәббәтнең никадәр көчле хис булуын күрәбез (“Моабит дәфтәрләре” циклы). Ватан темасының чагылышы Ф.Кәрим иҗатында да ачык чагыла. С.Хәким исә, “Туган як җырчысы” буларак билгеле. Әлеге шагыйрьләрнең иҗатлары укучыларда туган илгә мәхәббәт, патриотизм хисләре тәрбияләргә ярдәм итә.

Әмирхан Еникинең “Матурлык”, “Туган туфрак” хикәяләре авторның кешенең эчке дөньясын сурәтләп бирүе аша укучыларда соклану уята, психологик алымнар ярдәмендә матурлыкны тоя белү хисен арттыра.

Т. Миңнуллин “Үзебез сайлаган язмыш”, “Әлдермештән Әлмәндәр”, “Әниләр һәм бәбиләр”, “Нигез ташлары” кебек әсәрләре аша җәмгыятебездәге каршылыклар, әхлаксызлык күренешләре, тормышыбызда торган саен күбрәк урын ала барган кешелексезлек, миһербансызлык, ата-ананы хөрмәт итмәү, балаларны ятим калдыру күренешләре турында язып, укучыларны тәрбияли, уйланырга мәҗбүр итә.

Тулаем алганда, әдәбият дәресләрендә укытучы күренекле язучыларыбызның әсәрләре аша укучыларны рухи һәм әхлакый яктан тәрбияли. Матур әдәбият әсәрләре нигезендә укучы яхшы белән яманны аерырга, рухи кыйммәтләрне танырга өйрәнә, шәхес буларак формалаша.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, киләчәк буынны тәрбияләүдә әдәбият дәресләренең роле бик зур. Матур әдәбият әсәрләре укучыларда кешелеклелек сыйфатлары

тәрбияләүдә ярдәм итә. Нинди дә булса әдәби геройның язмышына битараф булмаган бала начарлык эшләргә сәләтле түгел, дигән фикер яши. Бу фикер дөреслеккә туры килә. Чөнки әдәби әсәрләр, кешене яхшылыкка гына өйрәтеп калмыйча, әхлаклы, әдәпле шәхесләр тәрбияләүгә дә зур өлеш кертә.

## Әдәби уку дәресләрендә экологик һәм әхлак тәрбиясе

***Нуриева Флюра Бәдри кызы,***
***башлангыч сыйныф укытучысы,***
***Салагыш мәктәбе***

Яңа гасыр алдыбызга көннән-көн катлаулырак бурычлар куя. Бүген белемгә һәм мәгълүматка ия булу гына җитми, аларны тормышта төгәл куллана да белергә кирәк. Әхлаклы, белемле, проблемаларны мөстәкыйль хәл итәрлек, илнең социаль–икътисадый үсеше өчен җавап бирерлек буын үстерә алуыбыз мәгариф системасының камиллегенә бәйле. Шуны ассызыклап үтәргә кирәк: әхлак тәрбиясе башка барлык тәрбия юнәлешләренең нигезен тәшкил итә. Минем максат - укучыларга хәзерге җәмгыятьтә яшәү өчен кирәк булган сыйфатларны үзләштерергә, тормышта үз урынын табарга ярдәм итү.

Борынгы грек фәлсәфәчесе Сенека: “Гыйлемлелектә алга китеп тә, әхлаклылыкта артта калган кеше алга китүдә иң артта калган кеше” [1,б.53] – дигән. Шуннан чыгып минем төп бурычым булып – балада әхлак тәҗрибәсе тәрбияләү, яхшыны яманнан аера белергә өйрәтү тора.

Әдәби уку дәресләрендә яшь буында нинди юллар белән әхлаклы булу омтылышы тәрбиялибез? Бүген сөйләшүебез шул хакта булыр. Ә мин бу максатыма ирешү өчен нәниләрне 1 нче сыйныфка алу белән әзерлек чорында аларның иң яраткан йорт хайваннары турындагы сөйләшүдән башлыйм. Яраткан дусларына яшәү өчен нинди шартлар кирәк? һ.б. шундый сорауларга җавап эзләүдән башлана безнең эшебез. Бала табигать белән бәйләнешен күзаллый башлый. Шушы кызыксынулар экологик тәрбия алуга беренче адымнар булып тора да инде.

XXVII гасырның беренче яртысында Я.А.Каменский туган төбәкне өйрәнү идеясен алга куйган[2,б.3]. Бүгенге көндә бу эшне дәвам итүчеләр–без, укытучылар дип уйлыйм мин. Һәм ялгышмыйм да. Халык туган якны, аның табигатен ямьле булганга, рухи һәм табигый байлыкларга юмарт булганга ярата, мәхәббәт хисен җырларына салып җырлый. Ә дәрестә бала барлык өйрәнгәннәрен, алган кичерешләрен йөрәге аша үткәреп хикәяләре аша тапшыра. "Әбием сөйләгәннәрдән" темасын үткәннән соң язылган язмадан өзек белән танышыйк: "Авылыбыздагы "Бакырлы кое" чишмәсе изгеләрдән саналган. Өлкәннәр анда барып намаз укыган, суын эчкән, ятып ял иткән. Рәхмәт хисен белдерү өчен кое урынына бакыр акчалар салганнар..." Әдәби уку дәресләрендә язылган язмаларыбыз "Көмеш кыңгырау", "Яңарыш" гәҗитләрендә бастырылды.

Дәресләрдә авылыбыз тирәсендә урнашкан "Кичке-Тан" тыюлыгы буенча эзләнү-тикшерену эшләре дә алып бардык. Тыюлык хезмәткәрләрен чакырып конференция үткәрдек. "Марш Парков" конкурсларында бу эшләребез урыннарга, дипломнарга лаек булдылар. Үземне, балаларны актив катнаштыру, экологик тәрбия өлкәсендәге хезмәтләрем өчен, Экология Министрлыгы тарафыннан диплом белән билгеләп үттеләр.

Балаларның югарыда укылган эшләре белән танышканнан соң, уку дәресләрендә яшь буынга әхлак һәм экологик тәрбия тиешле дәрәҗәдә бирелә. Балалар моны кабул итә, үз фикерләрендә бик якты чагылдыралар.Үз алдыма куйган бурычларым үтәлә, максатыма ирешәм дигән нәтиҗә ясыйм. Югары сыйныфларда да эш давамлы барса, әхлаклы, экологик яктан алдынгы карашлы алмаш тәрбияли алырбыз дигән фикердә калам.

Әдәбият

1. Гирфанова Р,З., Исхакова З,М,, Сәйфуллина Ф,Ә. Башлангыч мәктәптә дәресләрдә һәм тәрбия эшендә милли-региональ компонент./ Гирфанова Р,З., Исхакова З,М,, Сәйфуллина Ф,Ә.-Яр Чаллы,2005.-55 б.

**Әдәбия дәресләрендә әхлакый-экологик тәрбия**

*Нуруллина Айгөл Әхсән кызы*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының*
*«Инглиз телен тирәнтен өйрәнүле 33 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе»*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Яшь буынга трбия бирү мәсьәләсе теләсә кайсы чорда әһәмиятле һәм актуаль. Ул борынгы акыл ияләрен дә гел борчып торга һәм бүгенге көн галимнәрен дә уйланырга мәҗбүри итә. Әйтергә кирәк: хәзерге заманда укучыга белем һәм тәрбия бирү зур кыенлыклар аша алып барыла. Әхлаксызлык, бозыклык белән тулган шушы заманда укучыны тәрбияле, кешелекле, әхлаклы итү укытучыдан, тәрбиячедән, ата – анадан зур тырышлык, максатчанлык сорый.

Бөек галимебез Р. Фәхретдиннең «Бала чакта алынмаган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы да биреп бетерә алмас» дигән сүзләрен яшь буынга тәрбия бирүдә девиз итеп алырга да мөмкин.

Әйе, әхлаксыз баланың рухы да сәламәт булмый. Кешенең күңел сафлыгы, күңел матурлыгы, гүзәл холкы барлык байлыктан да өстенрәк, дибез. [1,17бит]

Бүгенге көн мәктәбе алдында торган төп бурычларның берсе – әхлакый яктан җитлеккән экологик культуралы шәхес тәрбияләү. Әйтеп үтәргә кирәк: тәрбиянең бу ике юнәлеше бер-берсе белән нык бәйләнештә тора. Бу - баланың табигатькә карашы формалашуда экологик, әхлакый, рухи компонентларның берләшүе.

Әхлакый-экологик белем һәм тәрбия бирүдә әдәби әсәрләрнең дә әһәмияте зур. Язучыларыбыз, беренчеләдән булып, табигатьне саклау турында чаң сукты. Әйләнә-тирә дөньяны, кеше сәламәтлеген, аның рухын, телен саклау аларны иң борчыган проблемага әйләнде.

Табигатьне саклау темасына язылган әсәрләр исемлеге бай һәм төрле.

Җирнең матурлыгын, һаваның сафлыгын саклау мәсьәләләре Г.Тукайны да борчыган. Бөек шагыйребез яшәгән чор экологик катастрофа алдында тормаса да, ул бу турыда уйланган, шул хакта күп кенә әсәрләр иҗат иткән

Шагыйрь фикеренчә, дөнья матур, шушы матурлыкны күп вакыт кеше үзе бетерә. Шагыйрь иҗатында "Җир күпмегә түзәр икән" дигән хафалану да чагыла. Шулай да Г.Тукайның табигатькә, туган ягына багышланган шигырьләре саф табигатькә дан җырлаудан гыйбарәт.[2,6бит]

Г. Тукай үз ягының урманнарына чын күңеленнән гашыйк. Ул яхшы белә: урман - саф һава чыганагы да, бетмәс-төкәнмәс байлык та. Кырлай урманнарының матурлыгы, сихри тылсымы аның күңелендә мәңгелеккә уелып калган. Шагыйрь үзенең «Исемдә калганнар» әсәрендә «Бу Кырлай авылы минем дөньяга иң элек күзем ачылган урыным...» дип юкка гына язмагандыр. Чынлап та, табигатьнең бөтен гүзәллеген ул шушында тойган: урманында җиләк җыйган, болынында аунаган, суында коенган, печән җыешкан, туйганчы уйнаган-чапкан. Шулар турында бик күп әкият-хикәят ишетеп, язарына илһам алган. Шагыйрь фикеренчә, урман - саулык, байлык сандыгы. Аны урмандагы һәр кош, чәчәк, агач илһамландыра. «Чыршы» шигырен генә алыйк. Авторда ул табигатьнең мәңге яшь булуын дәлилләүче образ буларак бирелә.

Үз төсен үзгәртми саклаучы арада берсе бар:

Көз көне һәм кыш буе саргаймый торган чыршы бар...[2,7бит]

Әйләнә - тирәне саклауда, аңа сакчыл караш тәрбияләүдә әби-бабайларның тәҗрибәсен, үгет - нәсихәтен, тәрбия алымнарын, буыннан-буынга күчеп килгән мирасны файдалану, аларның дөреслеген фәнни нигезләү кебек алымнар куллану укыту һәм тәрбиядә уңай нәтиҗә бирә, өлкән буын кешеләренә хөрмәт, ихтирам хисе уята.

Милләтебез борын-борыннан туган җиргә, туган туфрак төшенчәсенә, аның байлыкларына хөрмәт тәрбияләгән, сакчыл эш итәргә кушкан. Халык тарафыннан иҗат ителгән гади һәм образлы әсәрләр балалар күңеленә тиз үтеп керә. Бу халык әйтемнәрендә, мәкальләрендә чагыла. Дәресләрдә бу әйтемнәрне куллану, аларның асылына төшендерү укчыларны уйланырга мәҗбүр итә.

Мәсәлән, халкыбыз урманнарның әһәмияте, аларның табигатьтә һәм кеше тормышындагы роле турында: «Урман үстер —ачлык күрмәссең», — ди. Инде урманны саклау һәм үстерү турында кисәтә һәм борчылып: «Урманга шырпы белән бармыйлар», «Агач үлеме —балтадан». Урман кисәргә туры килгәндә дә, иң кирәклесен генә, юкка сарыф итмичә генә эш итәргә куша. «Бер агач кисәрдән элек, ике агач утырт!»— дип кисәтә.

«Яшь агачны сындырма —яшь гомерең өзелер», «Агачның тамырына балта чабып, киләчәгеңне караңгылама», «Җимеш ашыйсың килсә, чәчәген өзмә», — дип һәрдаим кисәтеп тора. Мондый кисәтүләр баланы уйланырга мәҗбүр итә.

Сулыкларны саклау, аларның адәм баласы тормышында әһәмиятен ассызыклап: «Төкермә коега, суын эчәрсең», «Су кулны юа, ә суны ни юа?», савыттагы су өсләрен һәрвакыт ябулы тотарга, чишмә яннары чиста, пөхтә җыештырылган, агач утыртылган булуын искәргән һәм шулай эшләгән. Коеларның өсләре ябулы, кое бурасының җир өслеге өлеше балчык белән шактый биек итеп күтәртелгән булуын теләгән. [3,201бит]

Әхлакый-экологик тәрбия бирүнең иң мөһим бурычларының берсе - табигатьне аңларга, яратырга өйрәтү. Яшь буында табигатькә кызыксыну тәрбияләү, туган якка мәхәббәт уяту аеруча зур әһәмияткә ия. Ул үзен табигатьнең бер кисәге итеп сизеп, табигатьне саклауда үзенең җаваплылыгын тоеп яшәргә тиеш.

**Кулланылган әдәбият**

1. Шәйхетдинова Л. Әхлаклылык – рухи саулык. /Л.Шәйхетдинова// Мәгариф./ -2005. -№3.-17б.

2. Гыймадиева Н. Г.Тукай иҗатында экология темасы. /Гыймадиева Н. //Мәгариф ./ -2009. №4.- 6б.

3. ШәймәрдановаР.Х. Татар милли педагогикасы. /Р.Х.Шәймәрданова, Р.Г.Сибгатуллина. -К.,-2004.-201б.

## «Памяти никакой не стало, вся износилась…Господи, как легко расстается человек с близкими своими, как быстро он забывает всех»

(по повести В.Г. Распутина «Прощание с Матерой»)

***Переина Миляуша Талгатовна,***
***учитель русского языка и литературы***
***МБОУ «Гимназия №1» г. Менделеевска РТ***

Есть произведения в русской литературе, которые не только не теряют своей актуальности, но и становятся актуальными в последние годы. «Прощание с Матерой», В.Г. Распутина по широте и охвату проблем - это поистине грандиозная история о жизни, которая может тронуть каждого человека.

В основе сюжета повести В.Г. Распутина «Прощание с Матерой» лежит реальная история. В ходе строительства ГЭС на Ангаре были затоплены окрестные деревни. Об одной из таких деревень расскажет В.Г. Распутин в своей повести. Переселение стало трагедией для жителей затопляемой деревни. Жители перестали чинить дома и прибирать в избах. Лишь оставшиеся в ней старики сохраняли до конца существования деревни «жилой дух».

В.Г. Распутин эмоционально и детально описывает уклад деревенской жизни. Главная героиня повести-Дарья Пинигина, все остальные дополняют образ. Но все они чем-то похожи: в них нет беззаботного счастья, потому что все заняты тяжелым трудом по хозяйству, всех беспокоят неустроенность быта да редкие обыденные радости.

Единственная настоящая отдушина в жизни для этих людей - ощущение благодати родной земли. Этой радости и лишают людей, которые привыкли жить на родной земле, где похоронены их близкие. Распутин показывает, как жителей Матеры поставили перед выбором и какие нравственные качества проявляются в людях, поставленных в такие сложные ситуации. Переезд для Дарьи и еще нескольких старух деревни сравнивается со смертью. В.Г. Распутин подробно и убедительно показывает, как тяжело человеку, всю жизнь прожившему на одном месте, отрываться от корней, от истоков, покидать родимый дом, оставлять под затопление могилы близких.

Невозможно читать сцену разорения кладбища…Это одна из самых трагических страниц повести. Старая слабеющая Дарья, защищая надгробия, преображается и с палкой бесстрашно бросается на здоровенного, как медведь, мужика в брезентовой куртке, обещая ему все кары на свете. В.Г. Распутин в своей повести показывает взаимосвязь нравственности народа с его прошлым и окружающими местами, малой родиной. В понимании писателя без малой родины человек не может жить по-настоящему, ведь родная земля дает человеку гораздо больше, чем он в состоянии осознать. И поэтому отрыв человека

от родной земли, корней, традиций для В. Распутина равносилен утрате совести. Это осознают пожилые герои повести, в первую очередь, главная героиня - старуха Дарья: «Памяти никакой не стало, вся износилась. А-а, про совесть. Раньше ее видать было: то ли есть она, то ли нету. Кто с ей — совестливый, кто без ее — бессовестный. Тепери холера разберет, все сошлось в одну кучу — что то, что другое. Поминают ее без пути на кашном слове, до того христовенькую истрепали, места живого не осталось» Эта носительница многовековых традиций не в силах навсегда расстаться с обжитым местом, ведь в избе, которой она прожила всю свою долгую жизнь, жили еще ее дед и бабка. В этих старых стенах прошло ее детство, радостные годы материнства и замужества, тяжелое время войны. Неслучайно образ дома в повести изображен, словно одухотворенный и живой. Другие старики также остаются верными родной Матере. В. Распутин приводит красочное сравнение стариков со старыми деревьями, которые взялись пересаживать. Так происходит распад семьи, через которую символически показано крушение народа и всей страны.

В. Распутин хочет показать, что неверно достигать новых целей ценой предательства своего прошлого, мотивируя это словами Дарьи: «У кого памяти нет, у того нет и жизни». Таким образом, повесть можно назвать криком души о заглублении деревень и людей, которых насильно выселили с родных мест.

## Обучение нравственности на уроках литературы

***Постовая Виолетта Витальевна,***
***преподаватель русского языка и литературы,***
***ГАПОУ «НИТ»***

Что такое нравственность? На сегодняшний день не каждый взрослый образованный человек сможет сразу понятно и доходчиво объяснить значение этого слова, что уж говорить о детях и подростках. Отчасти поэтому в настоящее время нас окружает огромное количество безнравственных людей. В связи с этим начиная со школьных лет детей нужно не только знакомить с этим понятием, но и воспитывать в школьниках основные принципы морали и этики.

Сама по себе нравственность считается духовной величиной, особым взглядом человека на жизнь, подразумевающим соблюдение неких моральных принципов, установленных в обществе. Раньше воспитанием нравственности занималась церковь, но сейчас церковь уже не имеет того авторитета, особенно среди молодежи. Поэтому этот тяжелый труд ложится на плечи педагогов.

Наиболее удобными для осуществления данной цели становятся уроки литературы. Это связано не только с тем, что литература – единственный предмет эстетического цикла, изучаемый с первого по одиннадцатый класс; но и с тем, что влияние литературы в целом, и чтения, в частности, на формирование личности школьника является неоспоримым фактом. Важность чтения подчёркивал еще В.А. Сухомлинский: «Чтение как источник духовного обогащения, не сводится к умению читать; этим умением оно только начинается. Чтение – это окошко, через которое дети видят и познают мир и самих себя». Читательская культура является существенным показателем духовного потенциала общества.

Практически любое произведение русской классической литературы, так или иначе, поднимает проблему нравственности (начиная с понимания понятий «добро» и «зло» и заканчивая пропагандой каких-либо моральных принципов).

Специфика нравственного воздействия урока литературы заключается в том, что читатель-подросток, читая произведение, имеет возможность не просто познакомиться с оценкой окружающего мира автором, но и сравнить свои взгляды на мир с авторитетными взглядами писателя. Таким образом, у подростка через познание других совершается процесс самопознания.

Увеличивая степень самостоятельности учащихся, осуществляя индивидуальный подход, учитель развивает творческие способности каждого ученика. Активность не возникает сама собой при обращении к той или иной форме, а создается совместным творческим трудом.

Остановимся на наиболее эффективных формах и методах обучения, применяемых на уроках литературы.

Метод творческого чтения является первой ступенью в логике познания литературы. Его цель – активизация художественного восприятия, как в начале изучения произведения, так и при его анализе. Чтение художественного произведения требует особого внимания к слову, фразе, ритму; поэтому данный метод вызывает у учащихся работу воображения, чувственной сферы.

Метод творческого чтения реализуется через приемы выразительного чтения учителя, чтение мастеров художественного слова, комментированное чтение, выполнение творческих заданий по личным впечатлениям.

Следующий этап в познании литературы – эвристический метод. Основным изучаемым материалом также остается художественное произведение, его более расширенный анализ. На этой ступени эмоциональное восприятие школьников углубляется, стимулируются интеллектуальные усилия учащихся. Чаще всего этот метод осуществляется в эвристической беседе. В данном случае преподавателем продумывается логически четкая система вопросов. При этом учитель не просто выясняет личные впечатления о произведении, но и направляет внимание учащихся на идейные и художественные особенности произведения, помогает в постановке художественной, нравственной и философской проблем, вытекающих непосредственно из прочитанного произведения.

Эвристический метод обучения развивает в учащемся способности к продуцированию идей, формируют умения вести продуктивный диалог, развивают способности действовать в ситуации неопределенности, поставить учебную цель, составить план ее достижения, находить разные ракурсы решения проблем. Кроме того, в учащемся развиваются способности к самоанализу и рефлексии.

Для активизации мыслительной деятельности учащихся используются следующие формы обучения: диспут, исследовательские задания, ролевые игры, творческие задания.

Одной из главных задач, связанных с обучением нравственности, является формирование умения анализировать художественные произведения. Для формирования этого умения используются следующие виды деятельности: создание характеристик героев, составление таблиц, сопоставление разных точек зрения на одно произведение.

Формирование умения работать с книгой, дополнительными источниками; умение создавать письменные и устные сочинения помогают в организации

уроков-семинаров, которые интересны учащимся ( «Проблема нравственного выбора в драме Островского «Гроза»»; «Проблема вечных человеческих ценностей в романе «Отцы и дети»», «Идеал человека в поэзии Некрасова»; «Образ Родины в поэзии А.Блока и С.Есенина» и др..).

Организуя и реализуя свою деятельность в системе, продумывая каждый урок и используя эффективные методы обучения, каждый преподаватель обязательно «достучится» до сердец школьников, научит их ставить и достигать цели, действовать в сложных ситуациях, которые потом поставит перед ними жизнь. Современный урок литературы заставляет постоянно находиться в поиске, самосовершенствоваться не только ученика, но и учителя.

Таким образом, духовно-нравственное развитие и воспитание обучающихся является первостепенной задачей современной образовательной системы, с которой, бесспорно, справится урок литературы.

Список литературы

1. Бекова, Л.С. Необходимость обучения нравственности на уроках гуманитарного цикла [Электронный ресурс] – Режим доступа: https://kopilkaurokov.ru/literatura/prochee/nieobkhodimost-obuchieniia-nravstviennosti-na-urokakh-ghumanitarnogho-tsikla, свободный. (Дата обращения: 8.02.17г.)

2. Д. Радчук. Безнравственность – это отсутствие духовности и морали. Почему в мире так много безнравственных людей? [Электронный ресурс] – Режим доступа: http://fb.ru/article/197949/beznravstvennost---eto-otsutstvie-duhovnosti-i-morali-pochemu-v-mire-tak-mnogo-beznravstvennyih-lyudey, свободный. (Дата обращения: 8.02.17г.)

3. Дубовцева, Ю.В. Воспитание нравственности на уроках литературы [Электронный ресурс] – Режим доступа: https://videouroki.net/razrabotki/vospitaniie-nravstviennosti-na-urokakh-litieratury.html, свободный. (Дата обращения: 8.02.17г.)

## Күңелдә былбыллар сайрармы?

(Факил Сафинның “Былбыл оясы” повесте буенча)

***Рамазанова Диләрә Фәнәвис кызы***
***1 нче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы***
***Алабуга шәһәре, 10 нчы урта мәктәп***

Кеше-табигать проблемаларын яктырткан әсәрләр татар әдәбиятында шактый. Экологик проблемалар кискенләшкән бүгенге катлаулы заманда бу – аеруча актуаль мәсьәлә. Факил Сафин да үзенең “Былбыл оясы” повестенда бу мәсьәләне читләтеп үтмәгән. Әсәрнең үзәгендә Хәсән образы. Егет тышкы кыяфәте буенча күз явын алырлык чибәрләр рәтенә эләгә алмаса да, аның күңел байлыгына сокланмый мөмкин түгел.Бу байлык аңа табигать тарафыннан бирелгән. Хәсән табигать турында сәгатьләр буена сөйли алырлык белемнәргә ия. Аның балачагы авылда, табигать кочагында узган. Ул күрше Фәсхи абзый сөйләгәннәрне тыңлап үскән. Ә Фәсхи абзый, бер яктан, аучы, икенче яктан, туган авылының табигатен яклаучы. Болыннарны сөрдертмәс, урманнарны кистермәс өчен, ул нинди генә ишекләрне какмаган, кем белән генә сүзгә килмәгән. Колхоз рәисе абзыйга: “Көн-таң атса, әле әрәмә дип, әле Калгын елгасы, әле Зиреклек урманы дип җан корытасың. Язмаган җирең калмады безнең өстән. Имеш, без бернәрсә аңламыйбыз, табигатьне кырып бетереп барабыз, авылда син генә иң һушлы, зирәк кеше, син генә барысын беләсең, күрәсең, имеш”, [2,57] – дип ачулана. Әлбәттә, ул үз мәнфәгатьләрен дә кайгыртып эш итә. Аның турында Хәсәннең әтисе менә нәрсә ди: “Фәсхи урман-болыннан, су буеннан кайтып керми... Урманнар корый, чишмәләр кибә. Болыннарны эштән чыгарып бетердек. Кош-корт бетте, урманнан киекләр кача.Ауның көе китте. Шуңа кешеләргә ачулы Фәсхи...” [2,54] Шулай булуга карамастан, ул кешеләргә табигатькә карата мондый мөнәсәбәтнең дөрес түгеллеген күрсәтә. Әби-бабайларыбызның эш-гамәлләренә күз, киңәшләренә колак салырга чакыра. Әгәр икмәк уңа торган булса, алар болыннарны сөргән, чәчкән, урган булырлар иде. Хәсәннең әтисен бөтен авыл җиләккә, мәтрүшкәгә, дару үләннәренә йөргән болыннлыкны эштән чыгарган өчен ачулана Фәсхи. Чыннан да, аның белемнәре зур. Сандугачлар, бүреләр, үләннәр, аларның ни

өчен кирәклеге, файдалы үзенчәлекләре турында мавыктыргыч та, гади дә итеп сөйли белә ул. “Табигать ялгышмый! Юк, кешеләр ялгышы харап итә табигатьне Һәм дә боларның барысы өчен дә кеше җавап тотарга тиеш”, – ди Фәсхи.[2,65] Аның фикеренчә: “Табигатьтә бөтен нәрсә акыллы булып туа, зирәк булып яши. Кеше генә сыната.” [2,64] Табигатьтән башка яши алмасын белә торып, адәм баласы гына, бүгенгесен кайгыртып, балаларының киләчәгенә балта чаба. Өстән кушалар дип, болыннарны сөрә, сазларны,  күлләрне киптерә, урманнарны кисә, “зур кунаклар” килүгә әзерләнеп, былбыл оясын аямыйча, үләнне чабып ташлый, табигатьне ботарлап, биек таш йортлар төзеп куя... Нәкъ шуңа эче поша да инде Фәсхинең. “Бу кояш ни өчен яктырта? Ни өчен шаулап урман үсә? Бу сандугач ни өчен оя ясап балалар очыра? Без ни өчен килдек бу дөньяга? Ни өчен яшибез? Үзебездән соң ни калдырып китәбез?” [2,66] Менә шундый сораулар борчый Фәсхине. Абзый табигатьне көчле тәрбия коралы итеп тә файдалана белә. “Син пышылдама, әнә сандугачтан үрнәк ал! Ачык итеп, һәр авазы тыңлаучыга килеп җитәрлек итеп сайрый бит.” – ди ул Хәсәнгә.Трактор радиаторына оя корган сандугачка карап: “Әти кеше бурычын төгәл үти: бала тәрбияләү, үстерүдә катнаша... Гаилә кորгансың икән, сиңа ышанып килгән бичәне дә, дөньяга аваз салган балаларны да ач, ялангач итмә.” [2,65], “Кешегә ни сан: бу кошчыктан күпме үрнәк алырга кирәк аңа дөньясы бөтен, түгәрәк булсынга” [2,60] – ди. Бүген табигатьне саклап, кешеләр үз-үзләрен саклап калалар икәнен аңлатырга тели Фәсхи: “...бер сандугач оясын саклап калу турында түгел, үзебезне саклап калу турында сөйләшәбез, Мирхәт кордаш, менә бу балаларны җаннарын имгәтмичә саклап калырга иде.”[2,66]

Фәсхине экология өлкәсендә Хәсәннең остазы дип танырга мөмкин. Балачакта үзе саклап калган былбыл оясы егетнең югары әхлакка ия кеше булып формалашуына зур йогынты ясаган. Хәсән табигать белән гармониядә яши. Аның бетмәс-төкәнмәс серләренә төшенергә тырыша, бик күп укый. Аның һөнәре дә экологияне саклау белән бәйле. “Техника заманы дип, табигатьне онытырга, аңа зыян салырга ярамый. Минем хезмәтем дә бүгенге машина төзелешендә һаваны пычратуга каршы чаралар белән бәйле”, - ди егет. [2,73]

Төзелеш дип кырылган урманнар, америкалылар алтынга сатып алырга әзер булган, актарып ташланган туфракка карап, Хәсәннең йөрәге сыкрый. Кешедә булган сәләтнең, моңның, җырның, гомумән, бөтен асыл сыйфатларның табигатьтән килүенә  чын күңелдән инанган кебек, кеше күңеленең җитешсез якларын төзәтү көченә ия булуына да ышана ул: “Без табигать баласы, безнең күңелләрне табигать кенә төзәтә ала.” [2,76] Нечкә күңелле егет тузгытылган былбыл оясын бәхет оясы итеп өендә саклый, бакчасында сандугачлар почмагы оештыра, аларның сайрауларын сәгатьләр буе тыңларга әзер. Шулардан алган илһам аңа яшәргә, эшләргә, яратырга, авырлыкларны җиңәргә, хөсет бәндәләргә каршы торырга, һәм... кеше булып калырга, үзе булып гомер итәргә, хәтта хыянәтне кичерергә  көч бирә. Намуслы, авылча нык холыклы, ярдәмчел, милләт җанлы Хәсәнгә тормышында, авыр мизгелләрдә аны аңлардай, ярдәм итәрдәй рәхимле кешеләр очрап тора. Хәсәннең кызы да үзе кебек табигать җанлы, димәк, киләчәккә өметебез бар дигән сүз.

Бүген Хәсән кебек кешеләр түрәләр арасында күбрәк булсыннар иде. Киләчәк буыннар турында кайгыртып, Фәсхи биргән сораулар хакында уйланып эш оештыручылар кирәк бүген безгә. Табигатькә кеше кирәк түгел. Кеше пырдымсыз тыкшынуларын туктатса, ул үз-үзен яңартачак, яшәртәчәк. Ә менә кеше...

Әдәбият

1. Мотыйгуллина Ә.Р. Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек. – Казан:”Мәгариф - Вакыт” нәшр., 2014. – 135 б.

2. Сафин Ф.М. Былбыл оясы: повестьлар. – Казан : Сүз, 2014. – 352 б.

**Татар әдәбияты дәресләрендә рус балаларына экологик һәм рухи-әхлакый тәрбия бирү**

*Романова Валентина Григорий кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының*
*"5 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе"*

Яшь буынга тәрбия бирү мәсьәләсе теләсә кайсы чорда әһәмиятле һәм актуаль булып кала. Ул борынгы акыл ияләрен дә гел борчып торган һәм бүгенге көн галимнәрен дә уйланырга мәҗбүр итә. Әйтергә кирәк, хәзерге заманда укучыга белем һәм тәрбия бирү зур кыенлыклар аша алып барыла. Әхлаксызлык, бозыклык белән тулган шушы заманда укучыны тәрбияле, кешелекле, әхлаклы итү укытучыдан зур тырышлык, максатчанлык сорый. Мәшһүр татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйри үз вакытында: «Тәрбия – һәр нәрсәнең ачкычы, аның белән һәр нәрсәне хәл итеп була, ул – кешене кеше итүдә иң дөрес юл», – дип, бик дөрес язган. Билгеле булганча, кешенең шәхес булып формалашуында экологик һәм рухи-әхлакый тәрбиясе төп һәм иң әһәмиятле урын алып тора. Әдәбият – тәрбия фәне ул. Күренекле галим, педагог, олпат дин әһеле, мәгърифәтче Ризаэддин Фәхреддин бу хакта: "Әхлак берлә әдәбият бергә булырлар. Бер кавемнең әдәбияты нинди рәвештә булса, әхлагы да шул рәвештә булыр," - дигән. Әдәбият кешенең йөрәген сафландыруда, аның аңына тәэсир итүдә әйтеп бетергесез зур көч. Ул укучының рухын, фантазиясен баета, дөньяны күзаллауга ачыклык кертә, үзаңын үстерә, үзенең эстетик зәвыкларын тормыш белән бәйләргә өйрәтә. Әдәбият дәресләре балада әхлак тәҗрибәсе булдыру өчен иң туры юл, дип саныйм мин. Татар әдәбияты дәресләрендә рус балаларын экологик һәм рухи-әхлакый кагыйдәләре белән ничек, нинди алымнар кулланып таныштырырга? Яшь буында нинди юллар белән әхлаклы булу омтылышы тәрбияләргә?

5 нче, 6 нчы, 8 нче сыйныфларда әдәбият дәресләрен мин гомуми белем бирү федераль дәүләт стандартларына нигезләнеп эшләнгән Ә.Р.Мотыйгуллина, Р.Г.Ханнанов, Л.Х. Хисмәтова тарафыннан язылган

дәреслекләре белән укытам. Һәр сыйныф дәреслегендә  халык авыз иҗатының нинди дә булса бер жанрына урын бирелә. Мәсәлән, 5 нче сыйныф дәреслегендә әкият жанры (“Ак бүре”, “Өч кыз”, “Куркак юлдаш”),  6 нчы сыйныф дәреслегендә - мифлар жанры (“Шүрәле”, “Шүрәлене ничек алдарга?”, “Су иясе”, “Өй иясе” татар халык мифлары, 8 нче сыйныф дәреслегендә риваятьләр (“Сихерче кыз”), легендалар (“Зөһрә кыз”) тәкъдим ителә. Халык авыз иҗатында табигать һәм аны саклау – иң борынгы һәм киң урын алган темаларның берсе. Ул фольклорның барлык төр жанрларында диярлек бар. Халыкның тормыш тәҗрибәсе һәм табигатьне өйрәнү нәтиҗәсендә туган кыска, ләкин тирән мәгънәле өйрәтүләре, тәрбия алымнары бик гыйбрәтле. Әлеге өйрәтүләр татар халкының мәкаль һәм әйтемнәрендә аеруча күп тупланган һәм тирән мәгънәгә ия булган өйрәтү-киңәшләр формасын алган: “Хайваннарны җәберләгән рәхәт күрмәс”, “Яралы кошка таш атмыйлар”, “Кош йомыркаларын ватма, күз яшең түгәрсең”, “Яшь агачны сындырма, яшь гомерең өзелер”. Балаларда зирәклек, күзәтүчәнлек кебек сыйфатлар тәрбияләүче табигать күренешләренә багышланган табышмаклар: “Төнлә баксам – күк тулган, иртән баксам – юк булган”,  “Язын ямь бирә, җәй салкын бирә, көзен тәм бирә, кышын тун бирә” һ.б.; сынамышлар: “Кар барында күк күкрәсә, ашлык булмас”,  “Җилгә каршы яуган яңгыр каты давыллы булыр” һ.б.; шәфкатьлелек, миһербанлык, игътибарлылык  кебек хисләр тәрбияләүче әкиятләр, мәзәкләр, мәсәлләр  дә шактый: “Умарта корты һәм чебеннәр”, “Кем көчле?” һ.б.

Әдәбият дәреслекләрендә урын алган күп кенә шагыйрьләребез әсәрләре дә экологик теманы күтәреп чыга.  Шигърияттә бу темага урын бирмәгән шагыйрьне табуы кыендыр. Табигать темасына язылган шигырьләр исемлеге бай һәм төрле.  Әлеге әсәрләр балаларны табигатьне аңларга, яратырга, аның  байлыкларына сакчыл караш формалаштырырга, туган җирнең кадерен белергә өйрәтә.  Шулай да мәктәп дәреслекләрендә зур урын бирелгән кайбер шәхесләребезне аерым әйтеп китү кирәктер: Габдулла Тукай, Абдулла Алиш, Хәсән Туфан, Шәүкәт Галиев, Резедә Вәлиева һәм башкалар

шигырьләрендә җәнлекләрне, кошларны, бөҗәкләрне яратырга, аларга мәрхәмәтле, шәфкатьле булырга өнди, нәфис сүз, сәнгать чаралары ярдәмендә Җир-анага игелек, хөрмәт хисләрен уяталар, шигъри бизәкләре белән табигатьнең гүзәллеген ачып, кешелекнең экологик һәлакәт каршында торуын да искәртәләр.

Дәреслекләрдә язучыларыбызның да экологик темага багышланган әсәрләре зур урын били. Бу темага багышланган әсәрләрдә кеше, аның рухи дөньясы үзәктә тора: Галимҗан Ибраһимов "Кар ява", Кави Нәҗми "Кызыклы хәл", Айдар Хәлим "Өч аяклы ат". Әдипләр бу әсәрләре белән борынгыдан килгән гореф-гадәтләргә ихтирам тәрбияләргә, табигый байлыкларга сакчыл булырга, кадерен белергә, өлкәннәргә хөрмәт белән карарга чакыралар, шатлык-куанычларны, кешенең матурлыгын, кайгы-хәсрәтне, олы фаҗигаләрнең тирәнлеген табигать аша ачып салалар.

Минем уйлавымча, әдәбият укытучысы – кешенең хис дөньясын уңай якка үстерүче шәхес. Баланың рухи дөньясы тиешенчә үсмәгәндә, аның үсеш мөмкинлекләре чикләнә. Әдәби сүзнең көче бик зур. Бала күңелендә үз геройлары кичергәнне тою, алар өчен борчылу, теләктәшлек күрсәтү тойгылары уяна. Мәрхәмәтсез, аяусыз тормыш мисалларын, чит илләрдә барган сугыш афәтен күреп үскән баланың аңына бүген шәфкать орлыгы салу зарур. Моны, беренче чиратта, мәктәп укытучысы эшли. Бала күңелендә мәрхәмәт тойгысы, матурлыкны күрә белү, кешеләргә мәхәббәт хисе тәрбияли алабыз икән, димәк, аларның әхлагы да дөрес формалашачак. Бу безнең кыйблабыз дөрес булуын күрсәтә.

Йомгаклап, шуны әйтәсем килә: туган туфракка сабый чакта җибәргән тамырлар гына кешене ватанлы итә, хәерле итә, бәхетле итә. Табигать баласы икәнлегеңне тою нәкъ шул чорда башлана һәм куе урманнардан, киң кырлардан, яшел болыннардан, тирән сулардан килүче кадерле кунак икәнлегең күңелгә мәңгегә берегеп кала. Язучыларыбызның, шагыйрьләребезнең тирән эчтәлекле әсәрләре аша шушы хис-тойгыларны балаларның күңеленә җиткерү, сеңдерү – укытучының изге бурычы.

Кулланылган әдәбият:


1. Заһидуллина Д.Ф. Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. / Д. Ф. Заһидуллина. - Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2000.

2. Низамов А.М. Милли мәктәп тәрбия нигезләре./ А.М. Низамов. - Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2005.

3. Сәхипова Р.Ә. Халык педагогикасы нигезендә укыту һәм тәрбия бирү. / Р.Ә. Сәхипова. – Казан: “Татарстан” китап нәшрияты, 2005.

4. Җәләлиев Ш.Ш. Татар халык педагогикасы. / Ш.Ш. Җәләлиев.– Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2000.

5. Данилюк А.Я. Концепция духовно-нравственного развития и воспитания личности гражданина России. / А.Я. Данилюк – Москва: Просвещение, 2009.

6. Риза Фәхреддин. Нәсыйхәт. – Казан, “Мәгариф”, 2005.- гыйнвар


## Гарәфи Хәсәнов иҗатында экологик тәрбия


***Солтанова Гөлшат Марс кызы,***
***педагог-китапханәче,***
***Мөслим муниципаль районы “Мөслим гимназиясе” муниципаль бюджет гомуми белем бирү оешмасы.***


XXI нче гасырга без глобаль экологик проблемалар белән бергә кердек. Кеше үзен табигатьнең хуҗасыдай тоеп табигатькә каршы чыкса да, бүген ул үзен табигатьнең бер кисәкчеге икәнен ниһаять таныды.

Әдәбият мәйданында менә шулар турында ачынып язучы әдипләребез бар. Табигатьне саклау темасына язылган әсәрләр исемлеге бай һәм төрле.

Сер түгел, кайбер балалар әдәби әсәрләр укыганда табигать матурлыгын, аның белән кешеләр арасында барган үзара сөйләшүләрне тасвирлаган өзекләрне укымыйча калдыралар яки игътибар белән укымыйлар. Мин укучыларга шундый тасвирлауларны ашыкмыйча, берничә тапкыр укып

чыгарга һәм бөтен тулылыгы белән күз алдына китереп, эчтән кабатлап чыгарга киңәш итәм.

Табигатьне саклау темасына язылган әсәрләр исемлеге бай һәм төрле. Татар балалар язучылары арасында табигать темасына мөрәҗәгать иткәннәре байтак. Шундыйлардан язучы Гарәфи Хәсәновның әсәрләренә тукталып китәсем килә.

Гарәфи Хәсәнов иҗаты бу өлкәдә аерым урын алып тора. Әйләнә-тирә мохитне саклау темасын аның балалар өчен язылган һәр китабында очратырга була. Ул тема язучының хикәяләрендәме, повестьларындамы – күренмичә калмый. Язучы табигатьне тасвирлап, аның матурлыгына соклану белән беррәттән, шул халәтне сакларга да кирәклеген искәртеп куя. Укучы аны үзеннән-үзе аңлый, уйланырга мәҗбүр ителә.

Язучы үзенең хикәяләрендә туган як табигатен, аңа хас булган күренешләрне, үзгәрешләрне сурәтли. Кайсы ел фасылы турында гына язмасын, авторның туган як табигатен чын күңелдән сөюен, күзгә күренмәс үзлекләрен җаны белән сиземләвен тоясың. Г.Хәсәнов күп кенә хикәяләрендә җәнлекләрне, кошларны, бөҗәкләрне яратырга, аларга мәрхәмәтле, шәфкатьле булырга өнди, үзенең шигъри бизәкләре белән табигатьнең гүзәллеген ача. Туган як табигатенең ел тәүлегендәге һәр фасылына хас үзенчәлекләрен, анда яшәүче тереклек ияләренең – кош-корт, җанвар-җәнлекләрнең табигать үзгәрешләренә җайлаша-җайлаша ничек гомер кичерүләрен укучы күңеленә тәэсир итәрлек җиңел һәм образлы тел белән сөйләгән әсәрләр татар балалар әдәбиятында бер яңалык буларак кабул ителә. Шуннан соң язылган күләмле «Җирем-суым» повестенда да автор, үз темасына турылыклы калып, табигать турында әңгәмәсен дәвам итә, укучыларны җәнлек, кош-корт, үсемлекләр дөньясының кызыклы һәм гыйбрәтле хәлләре, могҗизалары, серләре белән таныштыра.

Табигатьне саклау – милләтебезне, туган телебезне, гореф-гадәтләрне, рухи һәм тарихи байлыкларны саклау белән тыгыз бәйләнгән. Чөнки туган тел, әдәби һәм тарихи мирас газиз җиребездә барлыкка килгән. Шуңа күрә балаларны татар халкының рухи тамырлары, ерак бабаларыбызның яшәү

рәвеше, һөнәрләре белән таныштыру, аларда милли горурлык тәрбияләү мөһим. Табигатьнең матурлыгын, серлелеген Гарәфи ага үзенең җаны, саф күңеле, йөрәк җылысы салынган әдәби юллары белән укучы җанына, аның күңеленә салучы, ныгытучы, мәңгеләштерүче.

Г.Хәсәновның табигатькә багышланган әсәрләре укучыны дөньяга гаҗәпләнеп карарга, матурлыкны күрә белергә өйрәтә. Балалар өчен әдип танып-белү материалы бирә, табигать табышмаклары иҗат итеп, баланы уйлануга этәрә, сораулар куя. Мәсәлән, «Кара елан», «Гөлҗимеш », «Йорт ябалагы», «Артыш» һ. б. күп хикәяләрендә туган ягымның табигатенә мәдхия җырлый, аны сакларга, якларга кирәклеген ассызыклый. Яңгыр, чык, кырау, буран, җил, кояш, ай, яз, көз, җәй, кышның — һәрберсенең үзенчәлекле билгеләре турында ачышлар ясый, укучы күңеленә җиткерә.

Үтәли сюжет сызыгы, вакыйга үстерелеше нигезенә корылган булмасалар да, Г.Хәсәновның табигать турындагы хикәя һәм повестьлары күп фәнни мәгълүмат бирүдән тыш чын әдәби әсәрләр булып кабул ителә. Моңа автор үзенчәлекле хикәяләү стиле, образлы сөйләү манерасы белән ирешә. Ул табигать күренешләрен, кошларны, җәнлекләрне, хәтта үсемлекләрне дә, кешеләр турында язган кебек, җанландырып-сынландырып сурәтли һәм аларга карата үзенең сокланулы мөнәсәбәтен, карашын белдерә.

Г. Хәсәнов үз әсәрләре аша балаларны кечкенәдән үк кошларны яратырга, аларга мәрхәмәтле булырга өнди, аларны гөнаһсыз фәрештәләр белән тиңли. Кошларның табигатькә бик күп файда китерүенә басым ясый, аларның иркендә генә матур итеп сайрый алуын әйтә. “Кыр үрдәге”, “Карлыгач” хикәяләре әнә шундыйлардан.

Гарәфи Хәсәнов әйтергә теләгән фикерләре укучыга барып җитсен өчен, әдәби телебезнең төрледән-төрле сурәт-бизәкләрен куллана, төрледән-төрле чагыштырулар куллана. Мәсәлән: “Яңгыр теләнчеләре курай уйнады. Уткойрыклар сызгырган тавыш чыгарды. Ябалаклар, йөрәкне өшетеп, уһылдашып алды. Йөрәккә шом салып, бүреләр улады”.

Әйе, кеше табигатьнең аерылгысыз өлеше. Шагыйребезнең шушындый кешелекле, шәфкатьле әсәрләре безне асылыбызга кайтара, табигать дөньясы белән тагын да якынайта. Киләчәк буын вәкилләре дә әлеге әсәрләр аша гүзәллек дөньясын күреп, тоеп, киләчәктә аны кайгыртып яшәсә иде.

Һәм шушы әсәрләре белән ул кешеләргә: “Табигатьне саклагыз!” – дип әйтә кебек. Бүгенге көндә кешеләр табигатьне сакламыйлар. Елгалар пычратыла, хайваннар үлә, күп кенә үләннәр, чәчәкләр, агачлар юкка чыга. Гарәфи Хәсәнов табигатьне сакларга тырышкан. Безне дә шуңа чакыра!

Кулланылган әдәбият


1. Хәсәнов Г. Чү! Сайрар кошым оя тибә...: туган як табигате турында кечкенә хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1976.
2. Хәсәнов Г. Җир ул уртак йортыбыз: хикәяләр, повестьлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981.
3. Хәсәнов Г. Елның дүрт фасылы: повестьлар, хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1991.
4. Бәширов Г. Игелекле иҗат // Казан утлары. – 1981. – № 6. – 186–188 б.
5. Сәхапов Ә. Табигать исеменнән // Казан утлары. – 1982. – № 8. – 156–157 б.


## Нравственное воспитание личности средствами татарской и русской литературы


***Сабитова З.А, преподаватель татарского языка и литературы***
***ГАПОУ «Бугульминский строительно-технический колледж»***


ГАПОУ «Бугульминский строительно-технический колледж», где я работаю преподавателем татарского языка и литературы, работает в условиях татаро-русского двуязычия. Языком обучения является русский, а татарский язык и литература преподаются как иностранный язык. Языковая национальная среда имеет принципиальное значение для воспитания наших обучающихся в коренной культурной традиции своего народа, формировании

этнической самоидентификации. Процесс восприятия художественного произведения - сложное и индивидуально неповторимое явление. Художественная литература воздействует на очень широкую сферу психики, на мировоззрение, речь, этические и эстетические чувства, то есть, по существу, на формирование всей личности.

На уроках татарской литературы мы ведем взаимосвязанное изучение татарской и русской литературы. Основой уроков литературы является чтение, изучение и сравнение произведений татарской и русских литератур, наблюдение нитей схождения литератур. Художественные тексты, привлекаемые на уроках татарского языка, не только способствуют усвоению различных языковых категорий и форм, не только содействуют пониманию их функций в связной речи, но и служат средством эмоционального воздействия, а также активизируют познавательную и речемыслительную деятельность обучающихся.

«Солнце русской поэзии» – А. С. Пушкин освещал путь очень многим великим поэтам, жившим в одну эпоху с ним и после него. Путеводной звездой был он и для татарского поэта Г. Тукая.

При изучении творчества Тука, его стихотворение “Махбус” уместно сопоставить с “Узником” А. С. Пушкина. Преподаватель знакомит обучающихся с произведениями:

Сижу в железной клетке
Весь охваченный горем, горьким чувством,
В темноте, на жесткой земле, в сырости,
Все время в одном состоянии. ( у Г.Тукая)
Сижу за решеткой в темнице сырой,
Вскормленный в неволе орел молодой,
Мой верный товарищ, махая крылом,
Кровавую пищу клюет под окном. (А.С. Пушкин)

А затем обучающиеся разбирают стихи, сопоставляя и делая выводы, что и для Тукая, и для Пушкина главное – свобода, ведь, как восклицает татарский поэт:

Мой порыв, мои стремленья
С детских лет сродни твоим.

Г. Тукай был лучшим переводчиком стихов А. С. Пушкина на татарский язык; лучшим, потому что разделял его взгляды на литературу и искусство.

Поэта, негаснущей романтики Х.Такташа, называют “татарским Есениным”. Оба поэта прожили короткую, но бурную жизнь и умерли совсем молодыми — в 30 лет. Оба воспевали уходящую деревню накануне её разгрома согласно сталинскому плану “великого перелома”. Один — рязанские поля, хаты “в ризах образа” и “скирды солнца в водах лонных”, другой — тамбовские дубравы и хлебородные нивы Поволжья:

Деревня, твой я!
Твой я, как и прежде!
Пою я песни на твоей груди...

Тему взаимовлияния, взаимопроникновения культур татарского и русского народов можно продолжать бесконечно. Это было и в мирные дни, и продолжалось в годы Великой Отечественной войны.

Кому из нас неизвестно имя Мусы Джалиля? Его смело можно поставить рядом с именами А. Твардовского, М. Исаковского, О. Берггольц, К. Симонова и др.

Взаимосвязанное изучение военной тематики, позволяет понять, что война не имеет национальности, и горе, и боль - общенародные категории, нравственные и патриотические вопросы одинаково остро воспринимаются и воспроизводятся поэтами. Во время таких занятий предлагается выставка книг поэтов; фотовыставки, рассказывающие о жизни и деятельности героев, демонстрация рисунков. На занятиях звучат стихи поэтов на татарском и русском языках; рассказы о жизни и творчестве поэтов, проводится викторина “Чьи это строки?”

М.Джалиль

Они с детьми погнали матерей

И яму рыть заставили, - а сами:

Они стояли; кучка дикарей

И хриплыми смеялись голосами.

У края бездны выстроили в ряд

Бессильных женщин, худеньких ребят

Пришел хмельной майор

И медными глазами окинул обреченных…

М. Исаковский.

Враги сожгли родную хату,

Сгубили всю его семью.

Куда ж теперь идти солдату?

Кому нести печаль свою?                                 и т.д.

Никогда не покидало вдохновение Джалиля, даже когда топор палача уже был занесен над его головой. 25 августа 1944 он был казнен, но стихи дошли до его Родины.

За цикл "Моабитская тетрадь" Мусе Джалилю присвоено звание Героя Советского Союза. Завершить такой урок можно четверостишьем:

Пускай во всем, что совершаешь ты,

Проступит след душевной чистоты:

Ведь сила не во внешности твоей,

А только в человечности твоей.

Роль уроков литературы в современном колледже многогранна. Это и роль общественной трибуны, и роль интеллектуального центра, и роль аккумулятора эстетической энергии. Но из всего этого множества главное – нравственное воспитание. Чувство доброты, человечности приходит к нам через осознание лучших произведений художественной литературы, и не важно, на каком языке они написаны, важно, что они понятны.

Таким образом, татарская литература, обладающая богатейшими художественными традициями, играет очень важную роль в условиях татаро-русского двуязычия.

## Теле юкның – иле юк.

***Сабитова Саимә Әкрәм кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы***
***Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының***
***“21 нче гомуми урта белем бирүче мәктәп” муниципаль***
***белем бирү бюджет учреждениесе.***

**Кереш өлеше.** 2017 нче ел Рәсәй Федерациясе һәм Татарстан Респуб - ликасында Экология елы дип игълан ителде. Димәк, әдәбият дәресләрендә без туган җиребезгә, туган телебезгә мәхәббәт тәрбияләүне әйләнә-тирәбезгә сакчыл караш тәрбияләү белән тыгыз бәйләнештә алып барырга тиеш булабыз. Башкача мөмкин дә түгел, чөнки “туган җир” төшенчәсен безне әйләндереп алган табигатьтән башка күз алдына китерә алмыйбыз. Бала якты дөньяда күргән һәр нәрсәнең исемен туган телендә ишетә, кабатлый, күңеленә сеңдерә.Тик хәзер телебезне саклап калу мәсьәләсе бик җитди проблемага әйләнеп бара...

**Төп өлеш.** Теле юкның – иле юк.

Сүземне дәвам итеп, түбәндәге юлларны укып китәсем килә.

“Тел ничек сакланыр? Төгәл һәм тәңгәл җавап булырмы-булмасмы – монысы мәгълүм түгел, әмма әлеге сорауның дөрес җавабы исә: “Башлангыч мәктәпләр һәм әдәбият белән сакланыр”, - диюдән гыйбарәт. Әдипләр һәм галимнәр тел өчен кагыйдәләр булдырсалар, сүзләрне җыеп, сүзлек китаплары язсалар, һәркем аңларлык һәм мәхәббәт белән укырлык рәвешләрдә китаплар һәм хезмәтләр, газета һәм журналлар нәшер итсәләр, мөгаллимнәребез башлангыч мәктәпләрдә нигезле итеп укытырга ирешсәләр, хосусан киләчәк көннәрнең аналарын бүгенге бала вакытларында укырга һәм язарга өйрәтсәләр – тел сакланыр һәм һичкайчан югалмас”, - дип язып калдырган “Тел саклауның

юлы” исемендәге бер мәкаләсендә татар халкының олуг педагогы Риза хәзрәт Фәхретдин. [1, с. 20]

Үз вакытында шагыйрь Нури Арсланов та:

Уе юкның – теле юк,

Теле юкның – иле юк.

Илен санга санамаган

Телсездән дә тиле юк”, -

дип язып калдырган.[3, с. 2]

Нәтиҗә ясап, бер фикергә килсәк, телсез без беркем дә түгел, чөнки тел бетсә, милләт бетә; милләт бетсә, ил дә бетә. Яшь буында телгә, илгә мәхәб - бәт; табигатькә сакчыл караш тәрбияләүдә, олуг педагог Риза хәзрәт Фәхретдин әйткәнчә, әдәбият дәресләре зур роль уйнарга тиеш.

Җир-анага хөрмәт хисләре уяту, кешелекнең экологик һәлакәт алдында торуын искәртү, кеше сәламәтлеген, аның рухын, телен саклап калу проблемаларын язучыларыбыз элек-электән үз әсәрләрендә яктыртып килгәннәр. Бу әсәрләрнең күбесе, мәктәп программасы буенча, уку һәм әдәбият китапларына кертелгәннәр. Шундый әсәрләрнең берничәсенә тукталыйк. Мәсәлән, рус мәктәпләрендәге 2 нче татар сыйныфлары өчен Рәдинә Хәким кызы Ягъфәрова тарафыннан төзелгән “Уку китабы”нда Резеда Вәлиеваның “Кыңгырау чәчәк” әкияте бар. Әкият ахырында балаларны уйланырга мәҗбүр итүче сорау куелган: “Бу әкияттә синең өчен кирәкле 2 кагыйдә бар. Шуларны әйт”.[4, с. 73] Әйтә алмаслар дип борчылган идем, ләкин укучылар җавапларны тиз таптылар. Беренче кагыйдә - кыңгырау чәчәкне өзәргә ярамый; икенчесе - дуслык ул – мәңгелек. Балалар Кыңгырау чәчәкне өзәргә теләгән малайга карата да үз фикерләрен җиткерделәр. Урманда, урамда, паркларда үскән чәчәкләрне өзәргә, агачларны сындырырга ярамаганлыгын аңлаттылар. Кыңгырау чәчәк, ромашка, төнбоек кебек кайбер чәчәкләрнең Татарстанның Кызыл китабына кертелгәнлеге турында да сүз алып барылды. Бу чәчәкләрнең рәсемнәрен ноутбук аша гына күрсәтү дә дәресебезне тагы да бизәде, балаларда

соклану хисе тудырды. Шушыннан соң инде бу балаларның берәрсе табигатькә зыян китерер дип уйлау һич дөрес булмас иде.

3 нче сыйныфта “Бичаралар һәм бичуралар” хикәясен укыганнан соң, туган җиребездә сулыкларга, урманнарга кеше тарафыннан китерелгән зыянны ничек төзәтеп булуы турында озак сөйләштек, бәхәсләштек. [5, с. 42] Сөйлә - шүдә, өй эше аша, әти-әниләр дә катнашты. Алар табигатьне саклау өчен:

- урманнарны рөхсәтсез кисмәскә;

- үсемлекләрне таптамаска;

- урманнарда, паркларда сукмаклардан гына йөрергә;

- чишмәләрне , урманнарны пычратмаска;

- мөмкин булган җирләргә агачлар, чәчәкләр утыртырга;

- теләсә кайда чүп ташлап калдырмаска;

- ял иткән урыннарда учакларны яхшылап сүндереп китәргә;

- басуларга нефть, суларга агулы матдәләр агызмаска;

- балык тотар өчен шартлаткычлар кулланмаска;

- тыелган вакытта кошларны һәм җәнлекләрне ауламаска;

- кош ояларын туздырмаска кирәклеге турында үз фикерләрен җит-керделәр.

Бу фикерләрнең күбесе укучылар өчен табигатькә чыккач үзеңне дөрес тоту кагыйдәләре итеп дәфтәрләргә дә язып куелды. Шамил Маннаповның “Су тәме” хикәясе буенча диафильм өчен кадрлар да эшләнелде.

Башлангыч сыйныфларда табигатькә сакчыл караш тәрбияләүдә халык экиятләре, табышмаклар, төрле мәкальләр дә ярдәм итә. Мәсәлән, 3 нче сыйныф дәреслегенә кертелгән ”Кем көчле?” дип исемләнгән татар халык экияте кеше табигатьне аек акыл белән, табигатьнең үзенә зыян китермичә генә буйсындырырга өйрәнергә тиешлегенә ишарә итә. [5, с. 106]

Мәкальләргә килгәндә, мин үземне таң калдырганына тукталырга булдым.

“Кул пычранса, су белән юарсың,

Су пычранса, ни белән юарсың?” [5, с. 45]

Бу мәкаль халкыбызның зирәклеген генә түгел, аның суга булган мөнәсәбәтен дә күрсәтә. Сусыз яшәү мөмкин түгел, су - барлык тереклекнең нигезе. Шуңа күрә элек-электән су чыга торган урыннарны койма яки бура белән әйләндереп алганнар, юлаучылар су эчә алсын өчен савыт куеп калдырганнар, аларны һәрдаим чистартып торганнар. Менә ничек чагылган ул суга булган хөрмәт!..

Гомумән алганда, туган җиребезнең матурлыгын күңелендә йөртмәгән, шигырь юлларына салмаган язучы сирәктер. Ул шигырьләрнең күпмесенә инде көйләр язылган. Муса Җәлилнең "Чишмә", Сибгат Хәкимнең "Башка берни дә кирәкми", Гөлшат Зәйнашеваның "Үз илемдә", Нәкый Исәнбәтнең "Туган ил" шигырьләре җырга әйләнгәннәр. Бу җырларның моңлы көйләре 5-6 нчы сыйныф укучыларын гына түгел, хәтта 2-4 нче сыйныф укучыларын да битараф калдырмый. Җырларны балалар тын да алмый тыңлыйлар, җыр беткәч, кул чаба башлыйлар. Шул минутларда аларның күзләрендә балкыган шатлык нурларын күрү - үзе бер бәхет ул. Беренчедән, җырның сүзләрен аңлап тыңлаулары куандыра; икенчедән, моңга бирелеп, аны җаны-тәне белән кабул итә белүләре сөендерә.

**Йомгак өлеше.**

Балалар безнең милләтебезнең, илебезнең киләчәге. Шуңа күрә аларны кечкенәдән милли рухта, Туган иленә тугрылыклы, туган теленә хөрмәтле итеп тәрбияләү һәр укытучының бурычы дип уйлыйм.

2 нче сыйныф дәреслегендә Зәкия Туфайлованың "Туган ил" шигыре бар.

Туган ил ул була бер генә,

Туган илнең кадерен бел генә, -

дип тәмамланган бу шигырь. [4, с. 85] Әйтерсең лә, баланың тормыш юлы башында ук Туган илең булу - зур бәхет, тик син аны яратып яшә, гомерең буена аңа тугрылыклы булып кал, аның лаеклы гражданины булып үс,- ди шагыйрә. 5 нче сыйныфка җиткәч, Нәкый ага Исәнбәт бу җөмләләргә мөһер сугып куя шикелле:

Китми күңлемнән минем һич

Шул сөекле илкәем;

Анда – сөйгән моңлы халкым,

Анда – сөйгән әнкәем, - ди ул.[2, с. 105]

Бу юллар, чын мәгънәсендә, нинди тормыш кыйммәтләрен саклап яшәргә кирәклеген укучыга аңлатып, йомгак ясап куйганнар. Минемчә, татар әдәбияты дәреслекләренә кертелгән әсәрләр барысы да укучыларыбызны халкыбызның яшәү рәвеше белән таныштыра; табигатькә карата мәрхәмәтле, сакчыл була белергә өйрәтә; туган телебезгә, туган җиребезгә мәхәббәт тәрбияли.

Кулланылган әдәбият


1. Мәрданов Р. Мөфти Ризаэтдин Фәхретдин хәзрәтләре (“Яңа милли юл” журналы, 1936, № 7-8) / Казан: Рухият, 2007. – 88 б.

2. Хәсәнова Ф. Ф., Г. М. Сафиуллина, М. Я. Гарифуллина / Татар әдәбияты: рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек ( татар балалары өчен ), 5 нче сыйныф. Ике кисәктә. – Казан: “Мәгариф – Вакыт” нәшрияты, 2014.

3. Юсупов Р. Чыктым аркылы күпер. / “Мәдәни җомга” гәзите, 2013, 9 нчы август саны, 2 нче бит.

4. Ягъфәрова Р. Х. Уку китабы: дүртьеллык башлангыч рус мәктәбенең 2 нче сыйныфында укучы татар балалары өчен дәреслек. – 3 нче басма.- Казан: Мәгариф, 2003. – 143 б.

5. Ягъфәрова Р. Х. Уку китабы: рус телендә белем бирүче дүртьеллык башлангыч мәктәпнең 3 нче сыйныфы өчен дәреслек (татар балалары өчен) – 4 нче басма.- Казан: Мәгариф, 2009. – 143 б.


## Телебезне, тәрбиябезне, милләтебезне югары дәрәҗәгә күтәрергә омтылыйк.


***Алабуга муниципаль районы***
***муниципаль гомуми бюджет***
***белем учреждениесе”4нче гиназия”***
***Салихова Рузилә Вәсыйгать кызы***
***беренче квалификацион категорияле***

Бөек педагог А.С Макаренко гаиләдә мәктәптә балаларны әхлакый тәрбияләүгә багышланган лекцияләренлә бодай дип яза: “Балаларга әхлакый тәрбия бирү – тормышыбызның иң мөһим өлкәсе. Безнең балалар менә дигән гражданнар, яхшы аталар-аналар булып үсәргә тиеш. Тагын бер хакыйкәтне онытмыйк: балаларыбыз-алар безнең картлыгыбыз. Дөрес тәрбия бирү – ул безнең бәхетле картлыгыбыз, начар тәрбия бирү-ул безнең булачак кайгыларыбыз, күз яшьләребез, безнең башка кешеләр, ил алдында калган гаебебез”. Тәрбия бала тормышының беренче көннәреннән үк башлана. Тормыш раслаганча, кеше гамәлләренең әхлакый сыйфатларына бик яшьли нигез салына. Гаделлек, оешканлык, хезмәт сөючәнлек, кыюлык кебек уңай сыйфатлар яшьтән үк әхлакый гадәтләр буларак тәрбияләнгәндә генә кешенең гомерлек юлдашына әйләнәчәк.

Безнең гимназиябездә дәресләрдә һәм кластан тыш чараларда балаларга әхлакый-патриотик тәрбия белән бергә телебезне, милләтебезне югары дәрәҗәгә күтәрү өсндә эшләр алынып барыла. Аларның һәрберсендә укучы шәхесе белән якыннан торып аралашырга, аның уй-хисләрен омтылышларын белергә була. Укучының ни дәрәҗәдә әхлаклы булуы укучы һәм укытучының үзара мөнәсәбәтенә бәйле.

Минем уйлавымча, әхлакый эшчәнлеккә этәрүче әхлакый хәл-вакыйгаларны,тел һәм милләт мәсьәләләрен күз уңында тотып аларны һәрдаими кабатлап тору уңай нәтиҗәләргә ирешергә ярдәм итә.

Безгә укучы белән укуытучы бәхәсләшүе бик ошый. Бәхәсләшәбез икән, димәк без телебез һәм милләтебез өчен битараф кешеләр түгел, безне ниндидер вакыйга дулкынландыра, димәк без уйлыйбыз.

Тәрбияви момент та монда бик киеренке роль уйный. “Башкаларның характерын өйрәнгәндә үзеңнең дә тискәре сыйфаларыңны күрә бел, аларны

төзәт” дигән темага әңгәмә үткәргәндә укучылар бер – берсенең характерын өйрәнәләр, иптәшләрендәге тискәре һәм уңай сыйфатларны билгелиләр.

Әлбәттә, бәхәстә төрле милләт балалары кушылган төркем булса, һәр бала татармы, башкортмы, русмы үз милләтен, телен зур дәрәҗәгә күтәрергә тели. Искиткеч, сөенечле күренеш һәм бәхәс. Күпмилләтле Татрстаанызбызның гаиләләрендә үз телләрендә сөйләшеп, милләтенә җылы караш тәрбияләгән гаиләләр, минем карамакка, иң көчле рухлы, милли үзаң белән яшәгән балаларыбызның җылы учагы. Киләчәктә бу гаиләдәге балалар илебезнең кайсы почмакларында гына яшәмәсен үзенең милләтен, телен гореф-гәдәтен биеклеккә күтәрәергә омтылачак. Укучыларыма һәрдаими бу турыда гел сөйләп, дәресләрдә төркемнәрдә эшләгән вакытта бу темага кагылабыз. Кызганыч күренешкәдә еш кына тап булабыз, төркемдә утырган татар баласы “я не знаю по- татарски разговаривать”-дип әйткән укучыларыбыз шактый. Ни кызганыч, минем уйлавымча бу гаиләдә әхлак тәрбиясе, теленә иленә, милләтенә урыннар иң сонгы урында тора.

Минем уйлавымча, бу гаиләдәге ата-ананың уйланырга, борчылырга сәбәбе бар. Милләтен, телен иң төп ноктага күтәрергә теләмәгән, теләргә уйламаганда ата-ананың тәрбиясе, тормыш мәгънәсенең дәрәҗәсен “юк” билгесе белән билгеәр идем. Гимназиябезне алтын медальгә бетереп чыккан чыгарылыш укучыларыбыз илебезнең төрле почмакларында яшиләр. Аларның күбесенең инде телләре инглиз теленә тартымрак булса да, алар скайп аша аралашканда укытучысы белән матур итеп татарча сөйләшергә тырыша һәм өстәп куя ,“5 телдә җиңел итеп сөйләшә алам, ләкин шуны әйтәсем килә, иң матуры, безнең милләт телебез, татар телебез”-ди алар. Америкада яшәгән күп кенә чыгарылыш укучыларыбыз, татар милләтле кешеләрне эзләп табып, алар белән җыелышып еш кына татар җырларын өйрәнеп һәм җырлап утыралар икән.

Бу турыда, күптән түгел үткән чыгарылыш кичәсенә кайткан, гимназиябезне алтын медальгә тәмамлаган укучым, кызык һәм сокландыргыч итеп-Әнвәр Гөбәйдуллин сөйләде. Безгә, аларның укытучыларына, бу мизгел

тормышыбызның иң бәхетле мизгелләренең берсе бит. Синең телгә, милләткә ихтирам тәрбияләгән укучың, океанның икенче ярларында татарлыгын онытмыйча, аны башка милләт халкы алдында бөеккә күтәрә икән, димәк телебезнең , милләтебезнең киләчәге биек омтылышлар алыр Ин-шәә Аллах...Укыткан укучыларыбыз арасында тырышып тырмашып татар телен өйрәнергә теләгән рус милләтеннән дә балалар очрый. Әлбәттә, бу бик шатлыклы күренеш. Еш кына өлкәнрәк сыйныф укучыларыма мисал итеп Әткәемнең Бөек ватан сугышының камау вакытында татар дусты Мусаның соңгы сулышын алганын мисал китереп сөйлим. Мин кечкенэ булсамда әткәем аны очраклы рәвешә сугыш кырында татарча сөйләшкәнен ишетеп артыннан барып кочаклашканнарын, җиңү турында җыр җырлаганнарын, сугыштан соң да аралашып яшәргә вәгъдәләшкәннәрен искә төшереп сөйли иде. Ләкин аяусыз сугыш үзенекен итә шул. Кулында соңгы сулыш алган дусты аңа, басу капкасы янында озвтып калагн әнисен табып, аны яратканын, аларга тыныч тормыш теләгәнен тапшырырга куша. Телнең, милләтнең кадерен искиткеч әһәмияте зур икәнлеген балачагымда ук, әткәем сөйләве буенча каныма сеңгән иде.

Әткәемнең Муса дусты, балта остасы була. Сугышның эссе бер көнендә,суга сусаган бер зур төркем солдатлар коега су эчәргә йөгерәләр. Шулвакытта боерык була “Коелар агуланган суларны эчәргә ярамый”-диләр.

Авылыбыз яшьләре җыела торган Салкын чишмә янында сугышка китәр алдыннан хушлашу сүзләрен искә төшереп сөйли шулчак әткәем Муса дустына.

“Салкын чишмә, син корыма мине көт. Мин сугышта җиңү яулап, суга сусап үҗәтләнгән җанымны синең салкын суларыңны эчеп, сусавымны басар өчен килермен. Салкын чишмә, насыйбыма язган булса, авылыбызның иң чибәр кызы Миннесәхибәгә өйләнермен. Җирән кашкамны җигеп мәхәббәт җимешләребез, сабыйларыбызны утыртып яныңа килермен. Тирә ягыңа, суер ташлар җыеп, энҗе кебек ялтыратып төшәр сукмаклар ясарбыз. Уратып алып сырлап агачтан капкалар эшләрбез.Капкаларыңа язын кайтып, яныңдагы каеннарга кунып сайрый торган -сандугач, сыерчыкларның рәсемен төшерермен. Ә хәзергә хуш. Йөрәкле яшь егет юл тота сугышка» Әткәемә

кунакка килгән Муса дусты чишмәне уратып заманча коймалар куярга вәгъдә иткән булган икән. Ни кызганыч, бу аларның киләчәккә татар рухлары белән сулыкларыбызны саклап яшәргә корган планнары гына була. Әткәем Башкортстанның Борай районы Яңатазлар авылының биек тауларның астында агып яткан Салкын чишмәне матурлап, татар дустын искә алып гөл итеп куйды. Бу безнең һәммәбезгә табигый бүләк. Алтыннан да, көмештән дә кадерлерәк. Сугыш җирләрендә бер йотым суга тилмергән атагыз, дөньяда суга сусап эчәсе килүнең нинди кирәкле хәләт, әмма эчәргә булмаганлыктан тилмерүнең нәрсә икәнеә әул вакытта аңладым.Тәбигый байлык, сулык, чишмәләрне без ахирәткә күчкәч сез сакларга тиеш, дип әйтеп калдырды әткәбез.

Укучыларымны шул исәптән, экологик тәрбия бирү белән беррәттән дөньядагы төрле кискен ситуацияләрдә көчле рухлы булырга, Рәсәйне саклардай, халкын, телен, милләтен саклаучы ныклы, курку белмәс егетләр итеп тәрбияләсе килүем иде - дәресемдәге бу күренешләр.

Чыгышымның соңында, Роберт абый Миңнуллинның әнисе белән 2011 нче елны Шәммәт авылына махсус очрашуга кайтканнан соң, аның әйткән сүзләре белән тәмамлыйсым килә. Гөлҗәүһәр апа, искиткеч тыйнак, акыллы, элеккечә, үз заманындагы кешеләргә генә хас тыйнак тәрбияле, телен, милләтен олы ихтирамлаган Роберт абыйны ”Горурлыгым-улым, Башкортстаннан Татарстанның башкаласына урнашып, кан кардәшләребез- татарларны бөеккә күтәрергә, танытырга тырышты”,- дип искә алды аны.

Әткәй-әнкәй тәрбиясендә дөрес тәрбия алган уллар, кызлар милли рухны югары ноктага күтәрергә тырышкан, шул вакытта әхлакый, патриотик тәрбия бирергә тырышкан гаиләләргә ихтирамым бик зур. Тормыш тәҗрибәмнән чыгып язган бу чыгышымны, дәресләремдә еш кына балаларым белән уртаклашам. Бәхетемә каршы, минем укучыларым, мине йотлыгып, чынбарлык мисаллар китергәнемне кызыксынып, киләчәктә, бездә милләбез өчен, телебез өчен тормышта үзебезнең өлешбезне кертербез дип, алга карап дәрт белән яшиләр. Әлбәттә, бу балалар тәүфыйклы гаиләдә тәрбияләнгән балалар. Аларның фикер йөртү дәрәҗәләре уртача гына булсада, киләчәктә татар

халкының телен, милләтебезне күтәрүдә күпмедер булса өлешләрен кертерләр, дип уйлыйм.

Кулланылган әдәбият

1.Макаренко А.С.”Педагогик поэма”-Мәскәү,1981

2.Миңнуллин Р.М. “Тал бишек”- Казан, 1985

**Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә экологик тәрбия бирү.**

***Сәгйтова Эльвира Рәхимҗан кызы***
***Татар теле һәм әдәбияты укытучысы***
***“21 нче урта гомуми белем бирүче мәктәп”***
***муниципаль белем бирү бюджет учреждениясе,Түбән Кама шәһәре***

Экология ул – киләчәк фене. Кешенең җир йөзендә яшәү-яшәмәве дә, бәлки, киләчәктә шушы фәннең үсешеннән торыр. Шуңа күрә экологик яктан белемле кеше тәрбияләүне башлангыч мәктәптән үк башларга кирәк.

Экологик белем бирү укыту һәм тәрбия процессында укучыларга системага салынган фәнни һәм практик белемнәр бирүне, тормыш кыйммәтләрен аңларга өйрәтүне күз алдында тота, ләкин бу эш өзлексез алып барылырга тиеш.

Табигать белән аралашу кешедә кешелеклелек сыйфатын тәрбияли. Ә бу, үз чиратында, кызгана белү хисен үстерә һәм хайваннарны, үсемлекләрне яклау, саклау теләге барлыкка килүгә этәргеч була. Билгеле, киң күңеллелек табигать белән аралашудан алган рәхәтлек хисенең үсүе аркасында барлыкка килә.

Экологик тәрбия бирүнең формалары күп төрле: экологик лагерьлар; факультатив дәресләр яки түгәрәкләр; үзлегеннән шөгыльләнү һәм, билгеле, традицион форма буларак, дәрес.

Экологик тәрбия һәм белем бирүдә татар теле дәресләре шактый әһәмиятле роль уйныйлар. Балаларда табигатькә карата җаваплылык тәрбияләү катлаулы процесс. Ул еллар дәвамында алып барыла. Әмма ул бик мөһим, чөнки кешенең табигать файдасына көч куярга теләү-теләмәвеннән безнең планетабызның киләчәге хәл ителә. Шулай булгач, укытучы алдында торган төп бурыч – эколгиягә кагылышлы материалны бер дәрестә генә түгел, ә төрле дәресләрдә куллану.

Татар теле һәм әдәбияты дәреслекләре һәм программаларына анализ ясау күрсәткәнчә, бу фәннәр аша экологик – әхлак тәрбия бирү мөмкинлеге бик зур. Мәсәлән, экологик тәрбия бирүдә Р.З. Хәйдәрованың “Татар теле”

дәреслекләре отышлы. Экология өлкәсенә караган мәсьәләләр 2-9 нчы сыйныф укучылары өчен чыгарылган дәреслекләрендә киң яктыртылган. Бу теманы ачу өчен җитди текстлар сайланган. Алар төрле иллюстрацияләр белән баетылган. Иҗади эшләр балалар өчен кызыклы итеп уйланылган. Дәреслекне төзүдә катнашкан авторларның экологик проблемаларны хәл итүдә тудырган эмоциональ киеренкелеге укучыларда ул проблемаларны белеп калу гына түгел, аларны, хәленнән килгәнчә, чишәргә тырышу теләген дә тудыра. Һәр сыйныф дәреслегендә экологиягә кагылышлы бүлекләр бар. 1 нче сыйныфта “Урмандагы дуслар”, “Ел фасыллары”; 2-3 нче сыйныфларда “Ел фасыллары”; 4 нче сыйныфта “Без кошларга ярдәм итәбез”, “Хайваннар дөньясында”; 5 нче сыйныфта “Туган ягым – Татарстан”, 7 нче сыйныфта “Табигать һәм кеше”, 9 нчы сыйныфта “Кеше һәм әйләнә-тирә мохит” бүлекләрен күрсәтергә була.

Экологиягә кагылышы булган дәресләрдә эшне тиешле лексика белән танышудан башлыйбыз. Шул рәвешле сүзлек запасы елдан-ел баетыла бара. Монда ел фасылларының атамалары, хайваннарның исемнәре, табигать күренешләре күздә тотыла. Мәсәлән, ел фасыллары: кыш, яз, көз, җәй; табигать күренешләре: кар, яңгыр, болыт, буран, бозлавык, күлләвек, һ.б. Билгеле, бу сүзләрдән сүзтезмәләр, ә сүзтезмәләрдән җөмләләр төзергә өйрәнү үз урынында бик кирәк эшләр. Шулай ук бу сүзләрнең язылышын истә калдыруда сүзлек диктантлары яздыру да бик әһәмиятле дип уйлыйм.

Татар телен өйрәнүнең беренче елларыннан ук балаларда табигатькә мәхәббәт тәрбияләү бурычын куярга кирәк. Хайваннарга һәм кошларга карата шәфкатьлелек хисен тәрбияләү бурычы да шушы яссылыкта тора.

Лексик материалны үзләштергән укучылар үзләренең өйләрендә яшәүче хайваннар турында мөстәкыйль рәвештә сөйли башлыйлар, яки үз бакчаларында үстергән гөлләре, яшелчәләре турында, бер-берсен уздырырга тырышып, җөмләләр төзеп язалар.

Өлкән сыйныф укучылары язма һәм сөйләм телне файдаланып, аерым бер җитди мәсьәлә буенча фикер алыша башлыйлар. Үз фикерен дөрес һәм ачык итеп җиткерә өйрәнү укучыларга матур әдәбияты китапларын, фәнни-

популяр, публицистик материалларны укып аңлауда ярдәм итә. Тормышта килеп туган төрле реаль ситуацияләрдән чыгу юлларын өйрәтә.

“Әйт, бу нинди җәнлек?”, “Бу нинди агачның яфраклары?”,”Артык сүзне тап”, “Бу елның кайсы фасылы?”, “Җөмләне тәмамла” кебек дидактик уеннар уздыруда экологик тәрбия бирүдә миңа ярдәм итәләр. 1-4 нче сыйныфларда кыш турында җөмләләр төзегез; текст эчтәлегенә туры китереп, җөмләләрне дөрес урнаштырыгыз; рәсемдәге предметларны ел фасылларына туры китереп төркемләгез...кебек эш алымнарын куллану дәресләрдә яхшы нәтиҗә бирә.

Өстәмә эшләрдән сүзлек диктантлар уздыру; экология темасына шигырь язып карау; табышмаклар, башваткычлар чишү; төрле карточкалар белән эшләү дә дәресләрне нәтиҗәле итүдә бик отышлы. Диктантлар өчен һава, су, туфрак, үсемлек һәм хайваннар турындагы текстларны алам. Шулай ук кайбер дәресләрдә, “экология  сукмагы”ннан йөрү оештырам. Урамда йөргәндә тротуардан гына йөрергә, чәчәкләрне өзмәскә, агачларны сындырмаска, газоннарны таптамаска өйрәтү өчен бу төр дәресләр бик яхшы. Экскурсия вакытында укучылар үсемлекләр, кошлар һәм хайваннарны күзәтәләр, табигатьнең матур урыннарын ачалар. Ул урыннарны үз хәлендә саклау өчен олылар гына түгел, балалар да тырышырга тиеш икәнлеге турында аңлап китәләр.

Экскурсияләрне көз көне үткәрү бик рәхәт. Бу вакытта табигать төрле төскә кергән була; яфраклар оча, алар ал, кызыл, көрән, сары төсләрдә. Җил аларны бөтереп алып уйната-уйната да, салмак кына җиргә төшерә... Әйләнтирәдә кошлар чыкылдаша, балалар йөгерешеп уйныйлар. Укучылар агачларның, чәчәкләрнең исемнәрен әйтәләр, һава торышындагы үзгәрешләрне күзәтәләр.

Экскурсиядән соң “Алтын көз” темасына сочинение язабыз. Сочинение язганда балаларның сөйләм теле, фикерләү дәрәҗәсе үсә; алар, язганнарыннан чыгып, көзге табигатьнең үзенчәлекләре турында нәтиҗә ясарга да өйрәнә башлыйлар.

Шул рәвешле, татар теле дәресләрендә укыту-тәрбия бирү комплексы мәсьәләсе чишелә.

Кулланылган әдәбият:

1. Харисова В. Г. «Экологическое образование и воспитание на уроках татарского языка и литературы».

2. «Экология и жизнь». Научно – популярный журнал №5/34 2003, №1/30 2003.

3. Журнал «Магариф» №5 1995, №7 1999.

## Табигать һәм без.

***Сәлимова Гөлшат Инсаф кызы,***
***Минзәлә шәһәре 1нче урта мәктәбенең***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

Максат:урман, бакча, су-елгагар, чишмәләрне карау, саклау тәртипләре белән таныштыру. Бакчаларда гөлләр, агачлар үстерү. Табигатьне саклауга өндәү. Табигатькә гуманлы мөнәсәбәт, тереклек өчен җаваплылык хисе тәрбияләү.

Җиһазлау: плакатлар, картиналар, проэктор.

Дәрес барышы:

Бүген без сезнең белән урман буйлап сәяхәткә чыгабыз. Юлда тукталышлар ясарбыз, яңалыкларны күрербез. Урман җирне матурлый, һаваны чистарта. Менә без урманга килеп тә кердек.

*I нче тукталыш – "Агачлар".*

Табышмак: Яз килсә, киенә,
Көз килсә, чишенә.
Ул нәрсә? **(Агач)**

Чәчәкләрем аллы – гөлле,
Меңләгән энәм сакта.
40 төрле дәва булам
Кеше авырган чакта. ***(Гөлҗимеш)***

Камырлы да түгел үзе,

Ә исеме ябышкан.

Чәнчергә дә күп сорамый,

Әгәр бераз ялгышсаң. ***(Камырлык)***

Кыш көне дә яшел кием

Килешеп тора безгә.

Күркәләр бүләк итәрбез,

Килерсез әле көзгә. **(Нарат)**

Кайрым яшел,яфракларым

Сөйләшәләр җилсез дә.

Йорт салырга теләсәгез,

Бүрәнә булам сезгә. **(Усак)**

- Агачлар нигә кирәк?

- Нинди агачлар беләсез?

*II нче тукталыш – "Чәчәкләр".*

Мылтык түгел - үзе ата,

Куркытмый ул шартлап та.

Күбәләк тә, бал корты да

Аны өзелеп ярата.

Күрсә, кеше дә шакката,

Я, нәрсә ул? Әйт, Гата? ***(Чәчәк)***

Ак энҗеләр төсле мин,

Исле гөлдән исле мин.

Анкып торам урманда,

Дару да, агу да –

Сак була күр җыйганда. (**Энҗе чәчәк)**

Сары эшләпә кигәннәр,

Җем-җем итә күзләре,

Гел кояшка карганга,

Кояш төсле йөзләре. **(Көнбагыш)**

Нечкә, яшел сабакта

Юл буенда шар үскән.

Кай арада җил искән,

Ак шар очкан да киткән. **(Тузганак)**

*III нче тукталыш “Яшел аптека”.*

Үсемлекләрдән башка бу дөньяны күз алдына да китереп булмый.Алар бөтен тереклек ияләренә суларга гына түгел, дәваланырга да булышалар. Кешеләр борынгы заманнарда ук хайваннарның кайбер үсемлекләргә игътибар иткәннәрен күргәннәр . Шуннан бу үсемлекләрне өйрәнә башлаганнар,аларның файдалы якларын ачканнар, китап итеп теркәгәннәр. Андый кешеләрне “**үлән җыючылар”** дип йөрткәннәр. Яшел тылсымчылар борынгы заманнан бирле кешеләрне дәвалаганнар,аларга көч биргәннәр.Медицинага нигез салучы Гиппократ 236 үсемлекне кулланган. Ә безгә исеме әкиятләрдән билгеле булган күренекле таҗик табибы Әбугалисина 900 гә якын үсемлекнең файдасы турында яза.Ә инде Россиядә 1581 елда беренче даруханә- Даруханә палатасы ачыла,беренче “Табиб китабы” (“Травник”) басылып чыга. Петр1 заманында даруханәләр бакчасында дару үләннәре әзерләү һәм үстерү белән шөгыльләнгәннәр.

Хәзер дә яшел даруханә кешеләргә һәрчак ярдәм итә.Тик бу байлыктан дөрес файдалана белергә кирәк.

Нинди генә дару үләннәре юк! Безнең илдә 500дән артык дару үләне үсә.Барлык даруның 45% ын дару үләннәреннән ясыйлар.

Сары мәтрүшкә(зверобой) – хайваннарны үтерми.ә сызлану барлыкка китерә. Зарарлы микробларны бетерә.Элекке заманнарда бу үләнне 99 чиргә дәва дип йөрткәннәр.

Көтүче сумкасының җимеше көтүчеләр асып йөри торган сумкага охшаган. Исеме шуннан килеп чыккан.Канны туктата, яраны төзәтә.

Сукыр кычыткан тынычландыргыч чара буларак кулланыла.Йөрәк эшчәнлеген яхшырта.

*IV нче тукталыш “Чишмәләр”.*

Таудан туа, диңгезгә куа.

Тау куенында анасы,

Чыгып кача баласы.

Чишмәләргә кешеләр борынгы заманнардан ук табынып яшәгәннәр.Чишмә суларын эчеп дәваланганнар.

Һәр чишмәнең үз тарихы ,үз моңы ,үз юлы бар. Бер чишмәсе шаулап ага , тавышы еракларга ишетелә.Икенчеләре акрын гына тавыш белән ага,өченчеләре җир куеныннан кайнап , ургылып чыга.Ә җырлары , көйләре?! Элек-электән чишмә тапкан , аны чистарткан кешене халык зурлаган,чишмәгә аның исемен биргән ,мәңгеләштергән.

Ләкин чишмәләр югалмасын , күмелмәсен иде! Чишмәне саклау-табигатьне саклау дигән сүз.

Челтер- челтер чишмә ага

Һич тә тыймалы түгел.

Ә сулары шундый йомшак

Эчеп туймалы түгел.

Табигать турында кайгырту нәрсә соң ул? Елгаларда суларны чиста итеп саклау – бу табигать турында кайгырту. Әгәр сулар пычранса, балыклар, су хайваннары һәм бөҗәкләр үлә башлый, табигатьтәге баланс бозыла. Бу баланс-ны саклау – мәҗбүри шарт, чөнки табигатьтә барысы да тыгыз бәйләнгән. Чүп-ләрне тәртип белән җыю – табигать турында кайгырту. Урманга килгән кеше полиэтилен пакетны болай гына ыргытса, табигатькә зур зыян китерәчәк, ә чүп савытына ташласа, аның турында кайгырту булачак. Кыш көне кошларга җим-лекләр ясап кую – бу шулай ук табигать турында кайгырту. Табигать бай, ләкин аны сакларга кирәк. Кешеләр киләчәк турында, алдагы бу-ыннар турында кайгыртырга тиешләр. Әгәр дә һәр кеше табигатьне саклау өчен ни дә булса эшләсә, безнең тирә-ягыбыз тагын да чистарак, матуррак, күңелле-рәк булачак.

**Нәбирә Гыйматдинова әсәрләрендә табигать һәм кеше**

*Сәхабетдинова Роза Гомәр кызы*
*татар теле укытучысы*
*Аксубай универсаль*
*технологияләр техникумы*

XX гасыр ахырында кешелек дөньясы алдына Җирдәге бөтен тереклекнең юк ителү куркынычы килеп басты. Шуңа күрә кешелекнең табигать белән бәйләнеше, яшьтән үк экологик белем һәм тәрбия бирү – бүгенге көннең актуаль проблемаларыннан берсе булып тора.

Экология – нәрсә ул? Экология ул  фән - белемнәр системасы һәм бу фән кешелек дөньясын саклауга хезмәт итә. Экологияне өйрәнү биләмәсе искиткеч зур. Аның, мөгаен чиге дә юктыр. Экология чикләренең соңгы вакытта киңәюе сизелә. Бүгенге көндә кешенең сәламәтлеге начараюын да, психикасы какшавын да – һәммәсен экологиягә бәйләп карыйбыз.

Нибары 20 -25 ел эчендә генә экологиянең әһәмияте югары күтәрелде. “Үзен – табигать патшасы” дип исәпләгән адәм баласының эшчәнлеге һәрчак уңай нәтиҗәләр бирми. Киресенчә ул күп очракларда табигать анабызга фаҗигале үзгәрешләр алып килә, әйләнә - тирәбезгә күпме зыян салды һәм сала. Күп сулы елгаларыбыз саега, җирләр упкынсыман ярыклар белән яргалана. Елга үзәннәре баткаклыкка әйләнә, пычрана. Эчәр суларыбыз, сулар һавабыз көннән – көн шакшылана бара. Иген үстерелә торган уңдырышлы җирләр чикләнгән.

Яшел бишегебез – Җир анабыз үзенең табигый тотрыклыгын мәңге саклар дип ышану, хата фикер. Иксез-чиксез киңлектә Кояш белән бергә гизүче планетабызга Кояштан, йолдызлардан даими рәвештә энергия, нурланышлар агылып тора. Җир өслегендә, тирәсендәге атмосферада климатны һәм һава хәлен билгели торган күп үзгәрешләр бара. Әгәр кеше кирәксезгә “кыбырсынса” (казылма байлыкларны ала, сынаулар үткәрә һ.б.) ,чамадан тыш табигатькә үзгәрешләр кертүгә безнең табигатьнең чыдамлылыгы күпмегә җитәр? Җир күпмегә түзәр? Моны беркемнең дә уйлаганы юктыр, беркемнең дә

исәпләп чыгара алганы юк. “Вакытлыча җиңүләре өчен табигать кешедән мәрхәмәтсез үч ала, – дигән сүзләрне онытмыйсы иде безгә.

Без 60-70 елларда И. В. Мичуринның “ Без табигатьтән мәрхәмәт көтәргә тиеш түгел, безнең бурыч – аңардан тартып алу,” – дигән сүзләрен укыдык. Ә хәзер киресенчә “Без табигатькә мәрхәмәтле рәвештә үзебез бирергә тиешбез”.

Кеше табигать патшасы, ә патшасы мәрхәмәтле булганда гына озак яши, хезмәт итә ала.

Табигать – безнең бүгенге байлыгыбыз гына түгел, киләчәгебез дә. Аның байлыгын бездән соңгы килгән буыннарга да калдыру безнең уртак бурычыбыз.

Кеше – табигатьнең аерылгысыз бер өлеше. Ул табигатьтән башка бер генә көн дә, бер генә сәгать тә, бер генә минут та яши алмый, аңа су, һава, азык – төлек, җылылык һәм яктылык кирәк. Шуңа күрә табигатькә мөнәсәбәт, кешеләргә мөнәсәбәт кебек үк, гуманлы, шәфкатьле булырга тиеш.

Балаларда табигатькә әнә шундый мәрхәмәтле карашны, табигатьнең матурлыгын тоя белүне әкренләп аны яклый, саклый белүне кечкенәдән үк тәрбияләүдә зур эшләр алып барырга тиешбез.

Шуңа күрә укыту барышында экологик культура формалаштыру, табигатькә кызыксыну уяту, аны саклау проблемаларын дөрес аңлау, экосистемаларда барган үзгәрешләрне, тере организмнар арасындагы үзара бәйләнешләрне күзәтүгә зур игътибар бирәм. Әдәбият укытучысы, сыйныф җитәкчесе буларак мине бүгенге яшь буында әхлаклылык сыйфатларының түбәнәя баруы да зур борчылу тудыра.

Әдәбият дәресләре - бу максатларга ирешүдә бетмәс-төкәнмәс белем һәм тәрбия чыганагы булып тора. Шуңа күрә мин үз дәресләремдә укучыларымны, мөмкин кадәр иртәрәк шәхес итеп тоярга, аларда әхлакый нормаларны формалаштыруга зур урын бирәм. Бу юнәлештә иң көчле коралым-сүз. Сүз сәнгате - әдәби әсәрләрдәге кеше образлары, фәнни-гамәли проектларның эчтәлеге аша үсмерләрдә толерантлык, табигать дөньясы өчен җаваплылык тәрбияләүдә иң мөһим рольне башкара.

Әдәби әсәрләрдәге кеше образлары белән янәшә хайваннар, үсемлекләр, кошлар, табигать стихиясе үзәк урынны били, я аерым күренешләр булып калкып чыга. Ә моның өчен тирә-як дөньяны табигатьне, кешеләрне - барысын да тирән аңлый белү кирәк.

Табигать образларының билге булып килүе: карурман – тормыш билгесе, су – кеше гомере, көз – картлык килү, җир шары – тереклек фәлсәфи әсәрләрдә күзәтелә. Табигать белән кешенең табигый берлеге яшәеш фәлсәфәсен ачып җибәрә. Бу юнәлештә мин якташыбыз Нәбирә Гиматдинова әсәрләренә мөрәҗәгать итәм. Язучының төп геройлары үзләренә көчне табигатьтән алалар. Алар – табигать балалары. Әдип кешеләрне табигатькә кире әйләнергә чакыра, табигать белән тыгыз бәйләнештә булмаганда, шәфкатьлелек, игымлылык, бер – береңне аңлау, хөрмәт итү кебек сыйфатларның югала баруын күрсәтә. Башлангыч иҗатыннан ук кызыл җеп булып сузылып килгән, бүгенге көндә кешелек дөньясын иң борчый торган темаларның берсе – кеше шәхесе белән табигать арасындагы гармониянең бозылуы һәм шуның аркасында җәмгыятьтә явызлык артуы, битарафлык көчәю, әхлакый – рухи бөтенлекнең какшавы мәсьәләләре үзәктә тора. Исемнәреннән үк күренгәнчә - “Йолдызлы кичтә”,”Су хикәяте”, “Зәңгәр чәчәк”, “Ак торна каргышы”, “Бүре каны”, “Болан”, “Күке төкереге” һ.б. әсәрләренә Нәбирә Гыйматдинова татар халкының тотемы саналган – бүрене, киекләрне, әкияти ак еланны һ.б. кертә. Әмма бу мутантлана барган дөньяны алар гына коткара алыр микән дигән сорауга җавап табу җиңел түгел. Дөньяның үзе кебек борынгы куркаклык, эчүчелек, хыянәт, байлыкка табыну, наданлык, хөсетлек дигәннәре дә бар бит әле. Әсәрләрне анализлау барышында укучылар белән шуларның барысын бергә Җир йөзеннән себереп түгү өчен Табигать кодрәте дә, мең сихерченең әфсене дә кирәк икәнлеген ачыклыйбыз. Шуның белән бергә, геройларның язмышлары аша кешенең дөньяга иҗат итәргә, матурлык тудырырга, башкаларга ярдәм итәргә яшәү көче бирер өчен килүе дә ачыклана.

Шулай итеп, әдәбият дәресләре экологик белем һәм тәрбия бирүнең, дөньяга караш формалаштыруның нигезе булып тора. Кешелек җәмгыять белән

табигатьнең бербөтен тәшкил итүен, кешелек дөньясы тарихының табигать тарихының аерылгысыз бер өлеше икәнлеген, табигать белән кеше арасындагы бәйләнешне ачыклау әнә шул максатка хезмәт итә.

Табигатькә куркыныч яный, әйләнә-тирә мохит мәнфәгатьләрен саклап калу һәрберебезнең бурычы. Хәл кискенләшә бара, бу барыбызны да борчуга сала. Тереклекне саклап калу өчен безгә табигатькә сакчыл караш булдыру турындагы сөйләшүләрдән конкрет эшкә күчәргә кирәк. Моның өчен беренче шарт, һәр кеше дә экологик белемгә, экологик культурага ия булырга тиеш. Экологик белемгә ия булган, табигать законнарын белгән кеше генә экологик культурага ия була.

Файдаланылган әдәбият:


Акмал Н. Мәйдан. – 2002. - №2 – 43 бит.

Гайсин Г.Г. Преемственность экологического воспитания. – Казань. – Издательство КГПУ, 1999г.

Заһидуллина Д.Ф. – Образлар системасын анализлау. Казан. 2005, 5-7б.

Ягодин Г.Н. Проблемы экологического образования., Вестник высшей школы, 1991г.


## Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә экологик һәм рухи-әхлакый тәрбия бирү


***Сәхәбиева Гөлфия Хафиз кызы,***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы,***
***Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының “5 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе”***


"Табигатьне саклагыз!" Бу сүзләрне без бик еш ишетәбез. Әмма, аларның чын мәгънәсен без аңлап бетерәбезме икән? Һәрвакытта да аңлап бетермибез шул. Ә бит бу сүзләргә киләчәгебез турында зур мәгънә салынган. Туган як табигате - чиста һава һәм экологик яктан чиста ашамлыклар гына дигән сүз

түгел әле ул. Ул - Туган илебезнең матурлыгы да, җаны да. Туган илебезнең чиста сулы елга һәм күлләрен пычрату, очсыз-кырыйсыз урманнарны бер мәгънәсез кисеп бетерү, химия заводларының агулы газлары белән чиста һавабызны бозып бетерү, хәрби уеннар вакытында туфракны һәм һаваны агулау, авиация ягулыгының агулы калдыклары- болар әле хәзерге цивилизациянең туган ягыбыз табигатенә салган зыянының бер өлеше генә. Табигатьне пычратучылар белән көрәшне без бүгеннән үк башламасак, берничә дистә елдан соң, бөтен тереклек көеп беткән чүл уртасында калуыбыз бар бит. Ул вакытта инде противогаз кимичә сулап та булмас, радиациядән саклый торган скафандрлар киеп яшәвебездә бик ихтимал. Ә бит әле туган як табигате ул - калкулыктагы кипкән печән эскертләре арасындагы каен агачлары да, тынлык һәм хуш исләр белән тулган чыршы урманы да, иң кызу җәй көннәрендә дә салкын һәм көмештәй саф сулы күлләрдә, кечкенә генә инештән башлап, зур елгага таба ыргылучы елгачыклар да. Без 9 сыйныфта татар теле дәресендә шагыйрь Р. Фәйзуллинның "Алтын балык түгел, гади балык сөйләде .." шигырен өйрәнәбез. Бу шигырьдә елга-күлләрнең пычрануына кешеләр үзләре гаепле булуын әйтелә. Балык булып балык кешенең мондый шапшаклыгына гаҗәпләнә, су пычрак булса, балыкка да, су үсемнәргә дә яшәү мөмкин түгел, кеше үзе дә зыян күрә икәнен укучылар бу шигырьне укып аңладылар. Дәреслектә укучыларга кызыклы мәгълүмат бирелә, Шәвәли исеменнән табигатьне сакларга чакырып, киңәшләр бирелә. “Урманда әдәпле бул” темасын өйрәнгәндә ,табигатьне сакларга , җәнлек- кошларга мәрхәмәтле булырга өйрәтәбез. Табигать – безнең бүгенге байлыгыбыз гына түгел, киләчәгебез дә. Аның байлыгын бездән соңгы килгән буыннарга да калдыру безнең уртак бурычыбыз.

Кеше - табигатьнең аерылгысыз бер өлеше. Ул табигатьтән башка бер генә көн дә, бер генә сәгать тә, бер генә минут та яши алмый, аңа су, һава, азык - төлек, җылылык һәм яктылык кирәк. Шуңа күрә табигатькә мөнәсәбәт, кешеләргә мөнәсәбәт кебек үк, гуманлы, шәфкатьле булырга тиеш.

Балаларда табигатькә әнә шундый мәрхәмәтле карашны, табигатьнең матурлыгын тоя белүне әкеренләп аны яклый, саклый белүне кечкенәдән үк тәрбияләүдә зур эшләр алып барыла. Табигатьне саклау проблемалары белән дә балалар кечкенәдән үк танышалар, үткәрелгән чараларда (җир көне,

кошлар көне, игенчеләр көне һ.б) актив катнашалар, өлкән класс укучылары табигатьне яклау һәм саклау дигән изге эшкә теләп кушылалар (урман полосаларны, юл буйларын чистарталар, агач, куаклар утырталар һ.б.)

Кешенең сәламәтлеге аның нинди һава сулавына, ничек тукклануына һәм нинди су эчүенә, әйләнә-тирәдә нәрсә күрүенә бәйле булуын онытмыйк. Җәмгыятьнең аңсызлыгына, саксызлыгына һәм шакшылыгына чик куярга кирәк! Шуның белән бәйле рәвештә, балаларда табигаткә сакчыл караш тәрбияләү, уртак йортыбыз булган Җир планетасы язмышына җаваплылык хисе булдыру- экологик проблемалар кискенләшкән чорда аеруча әһәмиятле һәм ул максатчан алып барылырга тиеш. Мәктәптә укучыларга әхлакый-экологик тәрбия бирү өстендә күп эшләр эшләнә.

Мәктәптә "Табигать белеме көне " дигән темага шәһәр семинары узды. Анда мәгариф идарәсе вәкилләре, милли белем һәм тәрбия бирү буенча директор урынбасарлары, шәһәр һәм район мәктәпләренең татар теле һәм әдәбияты укытучылары катнашты.

"Татар теле һәм ядәбияты дәресләрендә укучыларга экологик тәрбия бирү" дип атаган темага чыгыш ясадым. Экологик проблемаларның елдан-ел кискенләшә баруы, мәктәптә экологик тәрбиянең ни рәвешле алып барылуы турында сөйләдем, тәҗрибәләре белән уртаклаштым.Рус телле укучыларга татар телен дә өйрәтү, шул ук вакытта әхлакый- экологик тәрбия бирүне тиешле дәрәҗәдә алып бара белү бик күп көч, белем һәм ихтыяр таләп итә.

Мин 7нче класста "Туган ягым" исемле уен-кичә үткәрдем. Дәрес ике команда арасында ярыш формасында узды. Укучылар татар телендә яхшы гына аралашуларын, татарча матур итеп җырлый , шигырь сөйли һәм бии белүләрен күрсәттеләр. Тирән мәгънәгә ия булган моңлы татар җырын хисләнеп, чын күңелдән башкарган малай һәм кызлар сокландырды. Укучылар Алабуга

урманнарында үскән үсемлекләр, агачларның исемнәрен дөрес атадылар, татарча табышмакларның җавапларын таптылар. Татар теле дәресе экология, география белән бәйләнештә барды.

Мәктәбебезнең тәҗрибә участогын алыйк. Чын мәгънәсендә ачык һавадагы иҗат лабораториясе ул. Анда фенологик күзәтүләр , дәресләр өчен күргәзмә материаллар, гербарийлар әзерләргә дә, дәресләрдә караган аерым темалар буенча практикалар үтәргә дә, агрономик белемнәрне үзләштерергә мөмкин.Мин үзем татар теле укытучысы булсам да, быел мәктәптә тәҗрибә участогын җитәклим.

Укучыларны, үз куллары белән башкарган хезмәт нәтиҗәләрен күреп шатлыкларын тоярга да ярдәм итә. Тәҗрибә участогында коллективның һәр әгъзасы үз өлешен кертә. Башлангыч класс укучыларының үз участоклары һәм үз планнары, ә өлкән класс укучыларының һәр тәҗрибәсе гомуми эшкә файда китерерлек итеп оештырыла. Мәктәп ашханәсен ел дәвамында витаминнарга бай яшелчә, җиләк - җимешләр белән тулысынча тәэмин итү өчен тырышып эш башкарыла. Бу эшләр дә укучыларны тирә ягыбызны чиста тотарга, табигый байлыклардан файдаланырга өйрәтә.

Димәк , табигатебез-безнең уртак йортыбыз гүзәл һәм чиста булсын өчен, урманнарны сакларга, кош ояларын туздырмаска, елга буйларын пычратмаска кирәк.Һәм инде кеше үз гомерендә бер генә төп булса да агач утыртырга тиеш. Табигатьне кечкенәдән үк ярата, аның матурлыгын тоя, күрә белгән кеше беркайчан да каты бәгырьле була алмый. Бары тик әхлаклы, намуслы, чын кеше була ала.

Кулланылган әдәбият :

1.Ахтямова А. Я., Ившина И. Г., Миронова Е. А.Экологическое образование и воспитание в Елабужском районе : методическое пособие\А. Я. Ахтямова, И. Г. Ившина, Е. А. Миронова. Издание второе.- Елабуга: Из.-воООО “Елтик” 2013.-256с.

2.Безрукова В.С. Проективная педагогика. – Екатеринбург.: Деловая книга, 1996. – 344 с.

3.Загвязинский В.И., Поташник М.М. Как учителю подготовить и провести эксперимент. – М.: Педагогическое сообщество России, 2004.

4.Дахин А.Н. Эффективность педагогического моделирования.

5.Джонс Дж. К. Методы проектирования. / Изд. Второе, дополнительное. Пер. с англ. Бурмистровой Т.П., Фриденберга И.В. Под редакцией д-ра психол. наук Венды В.Ф., канд. психол. наук Мунипова В.М. / – М.: Мир, 1986. – 326 с.

## Әхлак – милли тәрбиянең нигезе

***Сорокина Резидә Фәрит кызы,***
***Сарман гимназиясенең 1 нче категорияле***
***башлангыч сыйныф укытучысы;***
***Фатыйхова Гөлия Фоат кызы,***
***Сарман гимназиясенең югары категорияле***
***башлангыч сыйныф укытучысы.***

Татар милләте кешелек җәмгыяте тарихында тирән эз калдырган халык буларак билгеле. Аның искиткеч матур аһәңле теле, күркәм гореф-гадәтләре, рухи мәдәнияте, милли холкы, әхлакый сыйфатлары бар. Халкыбызга хас әхлакый сыйфатлар ата-ана аша балага гаиләдә сеңдерелә. Шунлыктан татар халкы борынгыдан ук әхлак нормаларын камилләштерә килгән. Халкыбызның иң изге хыялы камил кеше тәрбияләү булган. Бу бүгенге көндә дә иң актуаль мәсьәләләрнең берсе булып тора. Әхлаклылык һәр дәүләтнең яшәве, үсүе, алгарышы өчен иң кирәкле шарт, безнеңчә. Гаиләдән тыш әхлак тәрбиясе бирү балалар бакчасы, мәктәп учреждениеләренә дә йөкләнә. Әхлак тәрбиясе өчен шартлар гаиләдә тудырыла, алга таба камилләштерелә генә.

Башлангыч сыйныф укытучылары буларак әдәби уку дәресләрендә әхлаклылык тәрбиясе бирү өчен мөмкинлекләр бар, әмма тәрбиядә бала үзе һәм ата-анасы да катнашырга тиеш. В. Казыйхановның «Әхлак дәресләре» җыентыгы бу максатны тормышка ашыруда бик кирәкле әсбап, укытучының өстәл китабы булып тора. Әдәби уку дәресләренең төп максаты булып, баллада дөрес һәм йөгерек уку күнекмәләре булдыру, халык авыз иҗаты һәм

әдипләрнең әсәрләре белән таныштыру, аларны уку ихтыяҗы тудыру, уку барышында әхлакый сыйфатлар тәрбияләү, эстетик ләззәт алырга өйрәтү тора.

Әдәби уку дәресләрендә әхлак тәрбиясен ничек бирергә соң? Әлбәттә, халык авыз иҗаты, әдипләрнең әсәрләре аша. 4 нче сыйныфта якташ шарыйрәбез Вәсимә Хәйруллинаның «Хәерле көн» шигыре бирелгән. Исәнләшү, аның төрле формалары, изге теләк теләү һәр дәрестә психологик уңай халәт булдыру өчен хезмәт итә. М. Җәлилнең «Дару» шигыре якын кешеләреңнең иң көчле шифа бирүләре, аларның кадерен белергә кирәклеге турында әйтеп була. Марсель Галиевнең «Туган як» шигыре аша ярату хисенең бирелешен турында сөйләшергә мөмкин. 3 нче сыйныфта Әзһәр Габидинең « Тере антенналар» шигыре буенча образлы фикерләү юнәлешенә нигез салырга була. Вәсимә Хәйруллинаның «Хозурлык һәм горурлык» шигыре туган як матурлыгының бирелешен күзәтү өчен кулай. Әдәби уку дәресләрендә салынган әхлакый орлыклар урта һәм югары сыйныфларда камилләштерелә.

Халык авыз иҗаты әсәрләре белән танышу кече яшьтән үк башлана. 5 нче сыйныфка килгәндә инде бала әдәбият дәресләрен үзләштерү дәрәҗәсенә җитәргә тиеш. Мифлар, әкиятләр,риваять һәм легендалар, хикәя һәм шигырьләр, аерым язучылар иҗаты белән танышкан бала тормыш өчен кирәкле булган әдәби әсәрләрне укырга күнегә. Күнекмә ныклы булганда, әдәби әсәрләр аша күп әйберләргә өйрәнергә, өйрәтергә мөмкинлек бар. Бу башлангыч сыйныф укытучыларына йөкләнә. Ул эстафетаны татар теле һәм әдәбияты укытучыларына тапшыра.

Татар халкына хас булган олыны олы итү, киңкүңеллелек, хезмәт ярату, кешелеклелек, туган якны ярату, саклау, матурлыкка соклану, табигатькә сакчыл караш, пөхтәлек кебек сыйфатларны формалаштыру, баланы дөрес һәм сәламәт яшәү рәвеше алып барырга, йорт-җир тотарга күнектерү – иң җаваплы бурычыбыз.

Ризаэтдин Фәхретдин юкка гына: “Әхлак белән әдәбият бергә булырлар. Бер кавемнең әдәбияты нинди рәвештә булса, әхлагы да шул рәвештә булыр,”- дип язмаган.

Швейцар педагогы Песталоцциның киңәшләре бик урынлы, ул: “Әхлак тәрбиясе балалар учреждениеләренең төп бурычы булырга тиеш. Бары әхлакый тәрбия генә яхшы холык, яшәү авыр чагында кешеләрдән ныклылык һәм шәфкатьле мөнәсәбәт формалаштыра”, - дигән. Чынлыкта тәрбия гаиләдән башлана, ә укытучы тәрбия бирүдә зур роль уйный.

Әхлак тәрбиясе бирү бик җаваплы, әмма аның нәтиҗәсен күрү өчен вакыт кирәк. Шуңа күрә кешенең әхлагын камилләштерергә омтылуы табигый күренеш. Әгәр дә шул омтылыш булмаса, кешелек алга китә алмый. Бу заруририлык мәктәп елларында, аннан сон да камилләшергә тиеш. Профессор

Ә. З. Рәхимов фикеренчә, әхлак кызларда 8 яшькә, малайларда 12 яшькә формалаша. Димәк, әхлак тәрбиясен иртәрәк башларга кирәк. Бала тәрбиясе ана карынында ук башланырга тиеш дигән фикер белән дә килешми мөмкин түгел. Ярый ла әхлак формалашса, ә киресенчә булса нәрсә эшләргә? Әлбәттә, баланың үзен үзе тәрбияләве өчен шартлар тудырырга кирәк. Әдәби уку, әдәбият дәресләре, сыйныф сәгатьләре – иң отышлы чаралар. Үзеңне тәрбияләргә өйрәнү иң зур батырлык була ала. Моның өчен бала аның кирәклеген аңларга тиеш. Максат куеп эшләгәндә генә нәтиҗәгә ирешергә мөмкин.

Милләтебезнең киләчәге булган яшь буынга әхлак тәрбиясе бирү аерым бер профессия кешеләренең генә вазифасы була алмый. Милли, әхлакый сыйфатлары сакланып калса гына милләт яши, алга бара ала. Моның өчен битарафлыкка юл куймаска кирәк. Халкыбызга хас булган күркәм сыйфатлар алмашка килгән буында да сакланып калуына без һәммәбез дә җаваплы.

Әдәбият

1. В. Казыйханов. Әхлак дәресләре. Дәрес эшкәртмәләре

2. Интернет ресурслар

3. Ш. Ш. Җәләлиева. Татар халык педагогикасы. _ Казан: Мәгариф, 1997

## Татар әдәбияты дәресендә экологик һәм әхлакый тәрбия.

***Сөләйманова Нурзия Нуртдин кызы,татар теле һәм әдәбияты укытучысы, “Алексеевский аграр көллиятенең Яңа Чишмәдәге 2 нче номерлы филиалы.”***

Туган телдә җырлый чишмә. Туган телдә дәшсәм генә, Туган телдә шаулый таллар. Туган җирем мине аңлар.

Туган җирен чын күңелдән яраткан, халкының тарихына, гореф – гадәтләренә, әдәбиятына, диненә ихтирам белән караган кеше генә туган телен чиксез кадерли. Аны бөтен күңеле белән яратып өйрәнә, татар икәнен күңеле белән сизеп яши

Безнең туган телебез – татар теле. Күп гасырлык тарихы булган, дөньядагы иң дәрәҗәле 14 тел исәбенә кергән, чит илләрдә дә өйрәнелә торган, камилләшкән, Моабитның таш диварлары эчендә дә тынмыйча, аның калын стеналарын “тишеп чыгып”, бөтен дөньяга яңгыраган, утларга – суларга “салсалар” да, “ассалар – киссәләр” дә исән калган, сынмаган – сыгылмаган, баш имәгән горур тел!

Һәр милләттә исеме телгә алынуга ихтирам уята торган шәхесләр була. Муса Җәлил әнә шундый исемнәрнең берсе. Муса Җәлил диюгә, татар халкын, ә татар халкы диюгә М.Җәлил күз алдына килә. Аның шәхесен һәм батырлыгын бөтен дөнья белә. Димәк, ул халкыбызның горурлыгы.Үзе үлсә дә, аның исеме, шигырьләре мәңгелек, ул һәрвакыт халык күңелендә яши. Барлык халыкларның сөекле улы Муса Җәлилнең исеме тарих битләренә алтын хәрефләр белән язылган. Шагыйрь Муса Җәлил үзенең бөтен гомерен туган иленә, туган халкына багышлады. Муса Җәлилнең тормышына һәм иҗатына кагылып үтик, ә балачагында Муса нинди булды икән соң? Бу турыда сеңлесе Хәдичә истәлекләреннән алынган өзекне тыңлап китик.

***Муса Җәлилнең балачагы***

Безнең Мостафа авылы Нил елгасы буена урнашкан. Ул елга авылның яртысын диярлек урап алган. Елга кечкенә булса да, авыл тирәсендә ул шактый тирән һәм балыклы. Каникулга кайткан чакларда, Муса буш  вакытын шул елга буенда уздыра иде. Аңа ияреп мин дә балыкка бара идем: Муса кармаклар күтәрә, мин селәүчән салган банка һәм ашарга икмәк алып барам. Менә без тугайлыктагы тын, тирән җиргә килеп җитәбез һәм кармак сала башлыйбыз Балык эләгеп чыкса, Муса шунда ук ул балыкның тарихын, биографиясен сөйләп китә иде. Янәсе ул, шундый, шундый маҗараларга очрап, чуртан авызыннан ычкынган...

Муса табигатьне бик ярата иде. Еш кына без аның белән ерак тегермәнгә бара идек. Буаның суы тулган, ярдан ташырга тора, як – якта куе әрәмәлек, әйләнә - тирәгә карасаң, хисапсыз чәчәкләр белән бизәлгән болынлык, бер яктан еракларга киткән дала, урман, тау чылбырлары, дулкынланып үсә торган ашлык, астарак яшелчә басулары. Муса шундагы матурлыкка сокланып карап тора, шуннан тиз генә дәфтәрен ала да, минем аркага куеп, бай табигатьнең пейзажын төшерергә керешә. Ул шул кадәр төгәл һәм матур итеп ясый, мин гаҗәпләнеп карыйм. Шуннан ул кычкырып шигырь укырга керешә, ул аны шунда иҗат итә иде булса кирәк.

М. Җәлилнең туган як табигате, аны саклау, кош-кортка һәм хайваннарга мәхәббәт темалары да чор рухы һәм патриотизм белән үрелеп китә.Табигать үзенчәлекләрен тирән аңлап, үзен дә шул табигатьнең бер кисәге рәвешендә хис итеп язганлыктан, М.Жэлилнен табигать турында әйткэн сүзләре дә күп. Ул кошларны, җәнлекләрне, хәтта үсемлекләрне дә нәкъ кешеләр турында язган кебек, җанландырып, кызыксынып укырлык итеп яза белгэн. Аның әсәрләрен, башка кайбер китапларны укыгандагы кебек, нәрсә буласын алдан ук белеп түгел, бәлки үзең өчен яңа ачышлар көтеп укыйсың. Билгеле, укучыда табигатькә мәхәббәт уяту өчен аны белеп язу гына җитми. М.Жэлил табигатькә чын күңелдән сокланган, хәтта аның кайбер күренешләренә гаҗәплэнгэн, хэйран калган, яңадан кабатланмый торган матурлыкларын күрә һәм аларны эчкерсез беркатлылык белән ярата белгэн.

Экологик тәрбиянең төп максаты – әйләнә - тирәне яратучы ,аңа сакчыл караучы социаль- актив, гуманлы иҗади шәхес тәрбияләү. Ул түбәндәге мәсьәләләрне эченә ала:

1.Туган як табигатенә сакчыл караш тәрбияләү.

2.Табигать күренешләре һәм бәйләнешләре турында күзаллауларын киңәйтү һәм системалаштыру.

3.Экологик белемнәрне пропагандалау.

Экологик тәрбия укучыларда табигатьнең бер өлеше булган кеше турында, аның сәламәтлеге турында күзаллауларының аерым системасын булдыра. Шулай ук экологик тәрбия баланың эмоция үсешенә йогынты ясый, тере организмнарга теләктәшлек белдерү,гаҗәпләнү, кызгану тойгылары, аларны үзенең кече туганнары итеп тою, әйләнә- тирәлекнең матурлыгын күрү хисләрен үстерә.

Экологик тәрбия буенча төрле эш алымнары куллану- табигатькә икенче төрле күз белән карарга, табигать өчен безнең дә җаваплы икәнебезне аңларга ярдәм итә.

Туган телдә җырлый чишмә. Туган телдә дәшсәм генә,
Туган телдә шаулый таллар. Туган җирем мине аңлар.

Авылыбыз чишмәләре... Безгә таныш та, якын да, кадерле дә. Халкыбызның кыю йөрәкле улларына каһарманлыкны алар биргән инде!

Туган йортын, туган авылын, туган ягын чын күңелдән яраткан кеше генә Ватанын ярата һәм кирәк вакытта аны саклау өчен үз-үзен аямыйча көрәшкә күтәрелә. Аны исә чишмәләрдән, елга-күлләрдән башка күз алдына китереп тә булмый.

Юкка гына авыл кешеләре үз чишмәләре белән горурланып яшәмиләр, чишмәләренә яратып ягымлы исемнәр кушмыйлар. Авыруга дәва була торган чишмәләр бар бездә.

Челтер-челтер чишмә ага,

Көмеш төсле сулары.

Су өстендә җем-җем итә

Көннең алтын нурлары

Безне чишмә борыла-борыла,.

Зур инешкә коела.

Идел суы шундый бик күп

Чишмәләрдән җыела.

**Табигатьне саклау – кешелекнең иң мөһим бурычы.** Табигать яклауга, саклауга мохтаҗ, гүзәл чәчәкләребезне өзеп, туган җиребез юкка чыгачак, сулар һавабыз бозылачак.

Һәр кеше үзе яшәгән җирне, аның табигатен яратырга, байлыкларын сакларга, киләчәгебез турында уйланып яшәргә тиеш.

**Кулланылган әдәбият:**


1. Муса турында истәлекләр. Төз. һәм әдәби эшкәртүче Г. Кашшаф.- Казан: Таткитнәшр., 1964.- 310 б.
2. Үлемсезлек таңында: Муса Җәлил турында истәлекләр.- Казан: Таткит. нәшр., 1971.-102 б., ил.
3. Җәлилова Х. Абыем турында.- Казан: Таткитнәшр., 1973.- 77 б. Максуд М. Сагынган минутларда: (Муса Җәлил турында истәлекләр һәм уйланулар).- Казан: Таткитнәшр., 1977.- 190 б.
4. В.И. Кузнецов. Экология России. Москва. 1995 г.
5. Ә. Н. Хуҗиәхмәтов. Тәрбия - мәңгелек фәлсәфә. Казан. Мәгариф нәшрияты. 2001 ел.

**Татар телендә лингвоэкологик проблемалар (туган тел сагында).**

***Тимереева Әлфия Валерий кызы,***
***ДАҺББМУ "Казан төзелеш көллияте"нең***
***1категорияле татар теле укытучысы.***

Лингвоэкология – телнең үсешенә, кулланылышына тискәре йогынты ясаучы факторларны һәм телне баету, камилләштерү чараларын өйрәнүче фән. Тел экологиясе дәүләтнең телгә бәйле сәясәте нигезендә булырга тиеш. Телдәге экологик проблемаларны караганда, һичшиксез, аны илнең мәдәнияте, гореф-гадәтләре, тарихи-иҗтимагый торышы белән бәйләнышларыннан читләшергә ярамый.

Күп еллар дәвамында төрле билгеле процесслар телнең үзгәрешенә, ә безнең очракта тискәре үзгәрешенә китерә. Балалар – безнең киләчәгебез дип сөйләшәбез, яңа буын тәрбияләүне үз җилкәләребезгә алабыз икән, без бу бурычны горур күтәрә белергә дә тиеш. Олы тормышка аяк басарга торган яшьләр белән бу темаларга дәресләрдә күп сөйләшенә, икетеллелек мәсьәләсе турында бик күп фикерләр алышына. Еш кына "татар теле көндәлек аралашу дәрәҗәсеннән төшеп калып килә, шуңа күрә тел бетүгә бара" дип ишетергә туры килә. Көндәлек аралашуда кем катнаша соң? Шул ук без түгелме? Дөрес сөйләшмәүнең нигезе нәрсәдән гыйбарәт дип сорасак, моңа да җавап ачык. Дөрес, камил сөйләшү өчен бу телдә фикер йөртә белергә кирәк. Әгәр дә синең фикерләрең, уйларың башка телдә формалаша икән, син аны автомат рәвештә тәрҗемә итә белергә тиеш. Һәр сүзгә тәрҗемәсен вакытында, мизгел эчендә таба белү өчен, һәркемнең сүзлек байлыгы булырга тиеш. Ә сүзлек байлыгын кайдан һәм ничек тупларга? Әлбәттә инде, китаплар укырга, әдәби әсәрләр укырга. Укучының кулына без китап тоттыра алмыйбыз икән, интернет челтәре аша булса да кызыксыну уятырга кирәк. Бу авыр мәсьәлә, ләкин безнең мөгаллимнәребез чишә алмаслык мәсьәләләр юк бу җирдә.

Еш кына шәһәр балалары үзләренең тел белмәүләрен "Татар теле – авыл теле" дигән сүзләр белән акларга тырышалар. Минем максатым - аларның фикерләрендә ялгышлык барын аңлату. Әйе, татар халкының милли гореф-

гадәтләрен саклауда, булганын барлауда авылның роле бик зур. Ә татар теле шәһәр теле түгел дип кем ризалашыр? Үземнең укучыларыма мин татар мәдәниятенең үзәге булган театрларга, концерт залларына барырга тәкъдим итәм. Безнең театрларның заллары тулы, премьера булган көннәрдә исә, билет табуы аеруча кыен. Олы буын гына түгел, яшьләр дә яратып театрга йөриләр.

Телдәге экологик проблемалар сәнгати-тарихи темага да кагылып үтә. Бу юнәлештә башкалабызда зур эшләр башкарыла. Билгеле булганча, тарихи һәйкәлләр юкка чыгу белән милли хәтер югала. Бүгенге көндә телебезне бары тик милли җанлы шәхесләр генә саклап кала ала. Татар теле дәүләт теле булуга карамастан, бу телдә сөйләшә белүчеләр саны азая бара. Шул ук вакытта тел бетә икән, милләт милләт буларак яшәүдән туктый. “Шунлыктан югары һәм урта мәктәптә белем бирү оешмаларында татар телен туган тел һәм дәүләт теле буларак укыту методикаларын яңадан карау өлкәсендә билгеле бер системалы эшчәнлек алып барыла”[1,с.17] дип сөендерде КФУ укытучылары.

Татар телен өйрәтүнең 200 елдан артык зур тарихы булуга, йөзләгән китаплар, дәреслекләр басылып чыгуга карамастан, татар теленә өйрәтүнең торышын хәзерге көндә тиешле дәрәҗәдә дип әйтеп булмый. Җир йөзендә телләр бик күп. Бар миллиардлап кеше сөйләшкән кытай, инглиз телләре, бар берничә мең, хәтта берничә йөз сөйләшкәннәре... Ә үзебезнең – татар теле дип йөртелгән Туган телебез ни хәлдә соң бүген? Ананың балага биргән иң зур бүләге – тел. Шуңа да ул байлык, хәзинә дип санала. Ә бүләкне, хәзинәне кадерләп саклый алу, күбәйтә - арттыра алу үзе бер батырлык сорый. Файдасын күреп яши белмәсәң, тиз югалту бик җиңел аны. Һәр халык үз тарихын, үз рухын, җыр-моңын, гореф-гадәтләрен сакларга, үзеннән соңгы яңа буынга тапшырырга тели. “Теле барлар – халык булган, теле юклар – балык булган”, - дигән сүзләр юктан тумаган. Ә бит телнең нечкәлекләрен белү һәм саклау өчен, аны һәрвакыт куллану кирәк. Бөек шәхес Садри Максуди менә нәрсә дигән: “Телебезне өйрәнми башлаган көннән башлап без бетә башлаячакбыз. Безнең бер милләт булып тора алуыбыз телебезне саклый алуыбызга бәйледер.

Телебезне саклый алсак, бер милләт булып тора алырбыз, әгәр телебезне саклый алмасак, милләтебездән мәхрүм булырбыз”.

Тел - халыкның, милләтнең иң беренче, иң әһәмиятле күрсәткече. Тел бетсә, ул телнең иясе булган халык та, милләт тә югала. Шуның өчен дә туган телен кадерләп саклау, үстерү, аның сафлыгы, матурлыгы өчен көрәшү - һәр кешенең изге бурычы. Без – татарлар! Шушы телебезне киләчәк буыннарга да тапшыру, туачак балаларыбызга гореф-гадәтләребезне сеңдерү – милләтебезне саклауның мөһим шарты.

Кулланылган әдәбият:


1. Ландыш Фазуллина “Тел, әдәбият, мәдәният сагында”. “Идел” журналы. №01(328), 2017 ел.
2. “Мәгариф” журналы. №6(952), 2015 ел. “Түгәрәк өстәл” 6-9 битләр.
3. http://teachersalliance.ru/index.php/biblioteka/tatar-tele/859-tugan-telem-tatar-tele


## Фәүзия Бәйрәмованың "Болын" әсәрендә күңел экологиясе бирелеше


***Тимерова Ландыш Нәсим кызы***
***беренче квалификация категорияле***
***технология укытучысы***
***ТР Мөслим муниципаль районы***
***“Түбән Табын сәламәтлекләре чикләнгән***
***балалар өчен мәктәп-интернаты”***


Фәүзия Бәйрәмованы белмәгән, аның турында ишетмәгән кеше юктыр. Тапкыр телле, арыслан йөрәкле бу апа вакытында бөтен илне дер селкетеп тотты, үзенең әйткән сүзе белән генә түгел, хәтта күз карашы белән зур урыннарда утырган ир-атларны хәтта телсез калдыра иде. Фәүзия апаның юлы хак – ул милләт өчен, татар дәүләте өчен көрәште. Соңгы елларда иҗат эченә чумган, бер-бер артлы китаплары дөнья күрә.

80 нче еллар — Фәүзия Бәйрәмованың зур иҗатка килеп, татар әдәбиятына гаять көчле, үзенчәлекле әсәрләрен биргән еллары. Аның беренче күләмле әсәре— «Болын» повесте 1983 елда «Казан утлары» журналында басылып чыга һәм әдәби дөньяда зур резонанс тудыра, матбугат битләрендә бәхәсләр кузгата. 80 нче еллар башындагы рухи торгынлык, икейөзлелек, каты режим чорында Фәүзия Бәйрәмованың бу әсәре күпләргә үзенең ихласлыгы, сафлыгы, теленең моңы һәм байлыгы белән тәэсир итә. Әдәбият аксакаллары Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев, Гариф Ахунов, Фарваз Миңнуллин яшь язучыга үзләренең фатихаларын бирәләр, аны режим һөҗүменнән саклап калырга тырышалар, каләмен ташламаска өндиләр. 80 нче елларда Фәүзия Бәйрәмова күп иҗат итә, үзенчә иҗат итә, кеше җаны, аның эзләнүләре, табышлары һәм югалтулары турында нечкә, зәвыклы әсәрләр тудыра. «Болын »нан соң бер-бер артлы «Чакрым баганалары» (1983), «Битлек» (1983), «Кем?» (1984), «Күл балыгы» (1984), «Кыңгырау» (1987), «Канатсыз акчарлаклар» (1988) повестьлары языла һәм матбугатта басылып чыга. 1986 елда Фәүзия Бәйрәмованың «Болын» дип аталган беренче китабы (Әмирхан Еникинең сүз башы белән), 1991 елда «Моң» дигән икенче китабы дөнья күрә. Бу җыентыкларга авторның югарыда санап үтелгән повестьлары кертелә. Татар әдәбиятында, нигездә, колхоз-совхоз, авыл, нефть һәм КамАЗ темасы хакимлек иткән бер чорда, Бәйрәмованың кеше рухына, күңел дөньясына багышланган бу әсәрләре тансык бер яңалык, тынчу дөньяда саф

һава кебек кабул ителә. Фәүзия Бәйрәмованың бу чор әсәрләре татар әдәбиятына бик үк хас булмаган күңел экологиясе әдәбиятына нигез була, кешеләрне тән турында гына түгел, җан турында да кайгыртырга өнди, шуңа өйрәтә.

«Болын» повесте үзәгендә кеше рухы тора. Төп герой Алсу өчен болын – изге урын. Анда чәчәкләр үсә, рух сафлана. Үзенә авыр булган көннәрдә кыз үзе дә аның әрәмәлегендә югала…

Әдәби башлам укучыны шомлы болын, ак томаннар эчендә адаштыра. Алсуның хыял-фикерләре әле буталчык. Гомер болынында ул үзенең идеалын

эзли. Болындагы уйлары аның күңелендә шәһәргә, соңрак бөтен дөньяга карашын формалаштыра.

Кызның җанын беренче җәрәхәтләгән хәл печән чабу була. Табигатьтән бары тик файда гына эзләүче авыл кешеләренә нәфрәте әнә шуннан башлана. Тормыш тора-бара моның кирәклегенә, шулай тиешлелегенә ышандыра, шунлыктан Алсу инде күбрәк урман белән саташа башлый. Битарафлык дөньясыннан качу өчен, урман бердәнбер урынга әйләнә. «Безнең шәһәр янында да урманнар бар. Ләкин мондагы урманнар бөтенләй икенче. Мондагы урманнарда ул абагаларның куелыклары, ул җирдән килгән баш әйләндергеч әллә нинди исләр. Ә агачлар гел гөжләп торалар кебек.»[1, 11 б ] Үсмер кыз урманның да чикләре булуга төшенә. Ул адашкан көннәрнең берендә шунда үз мәхәббәтен очрата. Алсуның аерым сукмак салганы өчен әрләгән егет аның үзеннән дә сафрак, мәрхәмәтлерәк тоела. Кыз шул хистән очкын кебек кабынып китә. Алмазга бәйле болын вакыйгалары булмаса, егет бөтенләй ачылмас һәм идеал булып калыр иде. Алсудан да изгерәк кебек күренгән егет үзгәрә, болынны сукалап ташлый. Хәзер инде болынның кипкән печән исе кызны буа. « Минем кычкырасым, елыйсым, кешеләргә тупас сүзләр әйтәсем килә, мин кырт борылам да авылдан чыгып йөгерәм» [1, 11 б ]

Алсу үз гомерендә беренче тапкыр кыш уртасында авылны, болынны сагынып кайта. «Ә авыл! Ә болын! Ә урман?! Йа Хода! Мин шушы яшемә кадәр бу кышкы матурлыкны күрмичә ничек яши алдым икән?!» [1, 31 б ]

Хәзер инде Алсу күңелендә иң якын кеше булып фәрештәдәй чиста, сабыр, акыллы, шәфкатьле авыл карчыгы – әбисе кала. Аның да вафатыннан соң Алсуның тормышка өйрәтүче кешесе калмый. Үзен бөтенләй аңламый дип хисаплаган әнисенә кыз зур югалтулар аша якыная. Яратмаган иреннән, шәһәр тормышыннан качып, авылга китеп бара. Тормышта урталыкны сайлаган , табигатькә якынлыгын да бөтенләй үк югалтмаган кыз авылның гади кешеләре арасында үз урынын табар, дип ышанасы килә, чөнки ул монда беренче тапкыр кешеләрнең якынлыгын тоя, үз араларына сыендыра алган зур җанлы кешеләр каршында тезләнеп рәхмәт әйтәсе килә.

“Табигатьнең һәр фасылын күңелемдә саклыйм. Хәтта исләре белән. Карның исе юк диләр, ничек кенә бар әле. Без аны ипи белән ашый идек. Мичтән чыккан кара ипи белән. Көзге яфраклар исен бик яратам. Яфрак өзелеп төшә, әкрен генә чери башлый, аннан тәмле ис юк. Юкә исе тәмле. Бәрәңге алганнан соң, нинди ис кала?! Капчык өсләрендә тәгәрәп-тәгәрәп уйный идек. Җылы көз. Нинди матур. Җәй көне урманга җиләккә бара идек. Яланаяк барасың, баскан урын пыф-пыф итеп кала…» - дип хәтерендә саклаган,чын йөрәге белән яраткан, һәрчак исендә тоткан авылы табигатенә ничек итеп инде язучы үзенең герое - Алсуны кире кайтармасын!

Тәнкыйтьче Фәиз Зөлкарнәев менә нәрсәләр ди: «Фәүзия ханымның әсәрләрен укыганда минем күңелне һәрвакытта гаҗәеп бер хис били: ул мине әсәрләренең рухы, «һавасы» белән әсир итә. Мин аның гаять тә үткер сиземләвен, тормышның иң элек тетрәндергеч якларына дикъкатьле булуын, вакыйгаларны җан әрнешенә, хәтта күз яшенә манчып бирүен һәрчак тоеп торам...»

Фәүзия Бәйрәмова—каләме бик тә үткен язучы, җәмәгать эшлеклесе, тарих фәннәре кандидаты. Туры сүзле, һич кенә дә пыскып яши торганнардан түгел. Халкының нужасын үз йөрәге аша үткәреп, татарның якты, ирекле киләчәге өчен җан атып яши ул.Мескенлекне җене сөйми, ирләргә биргесез гайрәтле көрәшче. Шул ук вакытта гадилек һәм гаделлек тә хас аңа. Милләттәшләребезнең йөрәге кай тарафта авыртса, аның да йөрәге шунда сыкрый.

Кулланылган әдәбият

1. Бәйрәмова Ф.Күңел карлыгачларым. - Казан: Татар.кит.нәшр, 2000. — Б.11, 31.

2. Еники Ә. Кереш сүз // Фәүзия Бәйрәмова. Болын. — Казан: Татар.кит.нәшр, 1986. — Б.3.

3. Зөлкарнәй Ф. Фәүзия Бәйрәмованың иҗат биләмәләрендә // Фәүзия Бәйрәмова. Моң. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1991. — 188, 191 бб.

4. Шамсутова А. Фәүзия Бәйрәмова прозасы. — Казан, 2004. — Б.76-77.

5. Китап киштәсендәниләр бар?.. Л.Хөснетдинова. Казан утлары № 1, 2016.Б.132 .

## «Место, где ты родился, должно быть всегда»

*Автор: Титова Галина Александровна,*
*учитель русского языка и литературы*
*МБОУ «Средняя общеобразовательная школа №1»*
*г. Мензелинска*

Цель работы:

- формирование у учащихся уважительного отношения к Родине; гражданской позиции;

- распространение педагогического опыта по теме доклада;

- совершенствование языковой культуры учащихся.

Структура работы:

1часть «Значение экологического и нравственного воспитания на уроках литературы».

2 часть «Место, где ты родился, должно быть всегда» (читательская конференция как один из эффективных типов урока).

3 часть Формирование гражданской позиции на уроках литературы – залог успешного ЕГЭ учащегося.

**Значение экологического и нравственного воспитания на уроках литературы**

В школе, безусловно, каждый предмет воспитывает нравственность, но литература, по моему глубокому убеждению, является главным проводником нравственности. Почему я так считаю? Ответ на этот вопрос содержится на поверхности – в самом определении этого слова. В Толковом словаре «нравственность» – это 1.Внутренние - духовные и душевные - качества человека, основанные на идеалах добра, справедливости, долга, чести и т.п., которые проявляются в отношении к людям и к природе.

2.Нормы и правила поведения человека,основывающиеся на таких качеств ах. Думаю, что никто не будет отрицать, что именно литература занимается воспитанием этих качеств и норм поведения.

Нравственное воспитание - очень тяжелая работа для учителя, так как не всегда требования школы и семьи совпадают, в обществе сегодня происходит много негативного, а обвиняют в этом зачастую школу. Кроме того результат работы учителя нельзя увидеть сразу. Ведь стал ли ученик хорошим человеком с «правильными» нравственными ориентирами , можно узнать только много позже, когда он станет взрослым.

Литература ( каждое художественное произведение школьной программы) развивает творческое воображение, призывает к сопереживанию, будит чувства и мысли, задаёт жизненные ориентиры, формирует жизненные ценности, обогащает речь и воспитывает чувство языка. Таким образом, целью литературного образования является постижение сущности художественного произведения как вида искусства и формирование нравственной системы ценностей.

Какие же методы и приёмы, служащие повышению литературного образования, используются на уроках литературы? Большинство из них традиционны, но существенным отличием современного урока стало то, что используются они в сочетании с ИКТ, которые позволяют осуществить различные подходы к изучению текста.

Чтобы воспитать грамотного читателя, достойного гражданина нашей страны необходимо научить его технике комплексного анализа художественного произведения, а также стимулировать развитие образного мышления и воображения. В книге Леонова С. А. « Речевая деятельность на уроках литературы в старших классах: Методические приёмы творческого изучения литературы» приведены некоторые способы, которые обеспечивают достижение этой цели.

1. Эмоциональное восприятие текста. Это самый важный этап при работе с текстом. Необходимо зафиксировать первичное восприятие, чтобы

впоследствии соотнести его с новым пониманием произведения, которое появится после его анализа.

2. Структурно-содержательный анализ текста. Художественное произведение - многослойная система. Текст - только первый знаковый уровень, порождающий виртуально - предметный, мифологический и другие.

Таким образом, анализ текста возможен только при овладении теоретико-литературоведческими понятиями, которые работают на постижение замысла писателя:

Тема и идея, сюжет и композиция, характеры и система образов.

Художественная речь как способ выражения замысла писателя.

Жанровое и видовое своеобразие произведения (например, отличие романа от романа-эпопеи).

Категория автора-повествователя и рассказчика. Эстетическая позиция писателя.

Герой произведения и его отражения (например, герои – двойники в романе Ф. М. Достоевского «Преступление и наказание»).

Сопоставительный анализ мнений критиков об одном и том же произведении.

3. Проблемные вопросы.

Эта группа вопросов выходит за рамки анализа содержания и связана с личным опытом школьника, затрагивает его мировоззрение. При постановке таких вопросов нельзя ожидать однозначных ответов, а потому выработать единственно верную точку зрения часто бывает невозможно.

4. Вопросы культурологического характера.

Если ребёнок способен вступить в диалог с текстом и его творцом, как носителем идеи, то становится соавтором. Чтение - это труд и творчество. Знание нельзя давать в готовой форме. Только при соблюдении этого условия чтение развивает личность, работает на формирование читательской и нравственной культуры.

На формирование читательских компетенций работают такие формы уроков: урок - путешествие, пресс- конференция, дискуссия, литературная игра.

Все эти методы и формы направлены на активное сотворчество, а также на осознание литературного произведения как единой художественной системы, которая учит и развивает учащегося.

«А экологическое воспитание ? Как оно связано с уроками литературы?»- спросит человек, далёкий от школы. «Экологическое воспитание – это часть нравственной системы учащегося, поэтому литература и экология несомненно связаны»,- отвечу я. В одной статье я встретила удивительно ёмкую метафору: «На гробнице одного из фараонов было высечено: «Я никогда не перегораживал текущей воды». Этот многозначный поэтический афоризм заключает в себе как бы квинтэссенцию того, что мы понимаем под экологической культурой. Экологическую культуру, как и любую другую, необходимо воспитывать. Экологическое воспитание на уроках литературы – это составная часть нравственного, эстетического воспитания».Какая убедительная мысль!

Думаю, что экологическая культура начинается с воспитания любви, бережного отношения к природе, «братьям нашим меньшим», родному городу или селу, в конечном счете – к Родине. Всё это «даёт» нам литература! На основе курса школьной программы по литературе можно составить внушительный список произведений, в которых в той или иной степени освещаются вопросы экологии, бережного отношения к природе. Среди них романы Ч.Айтматова «Плаха», «Буранный полустанок», повесть В.П. Астафьева «Царь-рыба», рассказ Д.Лондона «Белый клык», рассказы о животных Э. Сетона-Томпсона, повести В.Распутина «Пожар», «Прощание с Матерой» и многие другие.[1] Эти произведения побуждают юных читателей задуматься о своем месте в этом мире и развивают экологическое мышление.

## Проблемы экологии современного русского языка

***Трифонова Евгения Ивановна, преподаватель русского языка и литературы ГАПОУ «Тетюшский государственный колледж гражданской защиты»***

О "лингвоэкологии" в отечественной науке заговорили в конце 80-х, появился целый ряд публикаций, поскольку состояние современного русского языка, его дальнейшая судьба не могли не волновать лингвистов, литературоведов, культурологов, философов. Появилось целое культурологическое течение, которое в последние годы постепенно разрастается и все более набирает силу благодаря работам академика В.В.Виноградова, Л.И.Скворцова, В.П.Григорьевой, С.И.Виноградовой, В.В.Колесовой, Ю.Н.Караулова и других; концепции Ю.М.Лотмана о "семиосфере" и "онтокоммуникации" Г.Сатищева.

Культура языка должна быть осмыслена в экологическом аспекте – как часть здоровой окружающей "речевой среды существования", освобожденной от ошибок и неточностей, негативно влияющих на жизнь языка, на общую духовность и нравственность.

Особое значение лингвоэкология уделяет культуре мышления и речевого поведения, воспитанию лингвистического вкуса, защите и "оздоровлению" литературного языка, определению путей и способов его обогащения и совершенствования, эстетике речи. Экология языка и экология культуры становятся одной из актуальных задач современности. Современная устная и письменная речь стилистически снижается и огрубляется. Язык художественной литературы испытывает тенденции к безликости и стандартности. Язык науки страдает от ненужной усложненности, обилия не всегда оправданных иноязычных заимствований в области терминологии. Публицистика подчас грешит многословием, невнятностью и невыразительностью. "В русском литературном языке сконцентрирована наша

национальная культура. И пока мы хорошо говорим и пишем по-русски, нам не грозит никакая денационализация", - пишет Л.И.Скворцов.

Лингвоэкологическое "культивирование" родного языка как языка нации помогает духовному возрождению народа. Развитие и состояние того или иного языка неразрывно связано с экономическим, культурным и политическим состоянием народа, который является его носителем. Все бурные языковые изменения в современной России вызваны социальными, экономическими и политическими переменами, стремительность которых обусловливает возникновение языковых катаклизмов. Это обстоятельство дает основание говорить о порче, распаде, разложении, кризисе, упадке современного русского языка и ставить вопрос о его сохранении и спасении.

Лингвоэкологический мониторинг позволяет судить о некоторых нездоровых явлениях и тенденциях массовой речи. В русском языке наблюдается огромное количество иностранных слов, жаргонизмов, в повседневном общении распространяется грубость, мат, растет малограмотность и безграмотность во всех сферах. Но, с другой стороны наоборот, русский язык сейчас переживает *период интенсивного развития*. Интенсивные изменения в языке всегда тесно связаны с изменениями социальными. Чем значительнее последние, тем более интенсивно происходят изменения в языке.

Наиболее очевидным источником новой лексики стали заимствования (преимущественно из американского варианта английского языка): *имидж, киллер, мейнстрим, он-лайн, папарацци, поп-корн, прайс, промоутер, ремикс, сайт, секьюрити, транш, холдинг, эксклюзивный* и множество других. При этом многие слова, преимущественно термины информатики, употребляются в текстах современных газет, журналов, деловой литературы в написании латиницей, что демонстрирует их недостаточную освоенность языком (*Unix, notebook, BMW, CD, CD-ROM, Coca-Cola, Hi-fi, IBM, mass-media, on-line, Pentium, PR, VIP, Windows*).

Встречается также еще одно новое языковое явление - комбинированное (латиницей и кириллицей) написание сложносоставных слов (*IBM-совместимый, PR-акция, VIP-клиент, VIp-номер,, Web-сервер*), а также некоторых слов, образованных от иноязычного слова по словообразовательной модели русского языка (*PRщик, VIPовский* и т. п.).

Можно отметить ряд явлений, к которым привело активное заимствование:

1. Не установлен единый орфографический облик многих слов (*таун-хаус, биг-мак, фаст-фуд, ноутбук, скейтборд*).

Обилие безграмотной документации вследствие контаминации русской и англо-американской орфографических моделей (употребление прописной / строчной букв: *Исполнитель, Учредитель, Директор и т.д.*)

Контаминация произносительных норм, в частности, в аббревиатурах (*НЛП* - *эн эл пи*).

Появление двухчленной антропонимики в официальной номинации вместо принятой в русском речевом этикете трёхчленной (*"Пётр Чайковский", "Александр Пушкин"* и т.д.). Обращение только по имени, практикуемое в деловой среде, имплицитно занижает социальный статус человека. Язык не может развиваться в самоизоляции, и в языке всегда появляются заимствования, однако нашествие иноязычной лексики на русский язык в последнее время приняло размеры национальной катастрофы. Взаимодействие языков - исторически закономерный процесс, однако он не должен приводить к самоуничтожению целых наций, к искусственному изменению норм. Это лишь одна из проблем, волнующих современную науку о языке.

## Список литературы

1 .«О заимствованиях в русском языке» В. Костомаров. Журнал «Филология в школе». №3.2006 год.

2. Свободная энциклопедия «Википедия»;

www.mirmaek.ru;

# Экологическое и нравственное воспитание на уроках литературы в 5 классе

***Фаррахова Резеда Геннадиевна,***
***учитель русского языка и литературы высшей квалификациионной категории МБОУ «Амикеевская ООШ» Муслюмовского муниципального района Республики Татарстан***

Наш великий поэт Александр Сергеевич Пушкин сказал: «Чтение – вот лучшее учение». И действительно, род человеческий бесконечно многим обязан тому университету, имя которому – Книга. В этом университете приобретаем мы необходимые знания и получаем уроки нравственности, духовности, без которых оскудели бы сердцем. Чтение – это неисчерпаемый источник обогащения знаниями, универсальный способ развития познавательных и речевых способностей ребёнка, его творческих сил, мощное средство воспитания нравственных качеств и развития эстетических чувств.[1,с.3]

Уроки литературы – это уроки нравственности, одним из направлений нравственного воспитания является экологическое воспитание, воспитание ценностного отношения к природе, окружающей среде. Основная задача нравственного воспитания: воспитание людей совестливых, порядочных, уважающих жизнь и мнение других людей, ценящих человеческое достоинство в себе и других, способных самостоятельно и творчески решать поставленные задачи и противостоять злу, неспособных к аморальным поступкам, живущих достойно и счастливо.

Исходя из своего опыта работы, я хотела бы рассмотреть произведения, которые изучаются в 5 классе. На первых уроках знакомимся с произведениями устного народного творчества: пословицами, поговорками, колыбельными песнями, сказками. Во всех этих произведениях заключается народная мудрость.

Колыбельные песни наполнены материнской любовью, пословицы учат быть добрыми, трудолюбивыми, отзывчивыми, образованными. Пленительную силу сказок отметили русские писатели, начиная от Пушкина до Горького. «То,

чему мы привыкли в детстве удивляться и сочувствовать, оставляет в нём глубокие следы, и не для одного человека любимый герой книг детства сделался потом невидимым и иногда неосознаваемым руководителем жизни», говорил К. Ушинский. Те поучения, которые получают дети из народных сказок, находят продолжение и в литературных сказках. А.Погорельский в своей сказке «Черная курица, или Подземные жители» знакомит учащихся с Алёшей, «добрым, миленьким, умненьким мальчиком, которого все любили и ласкали».[2,с.122] Но вскоре он становится самолюбивым и излишне самонадеянным мальчиком. Все беды, которые с ним происходят, из-за его самонадеянности и упрямства. Читая это произведение, каждый получает себе урок от слов учителя: «Чем более вы от природы имеете способностей и дарований, тем скромнее и послушнее вы должны быть. Не для того вам дан ум, чтоб вы во зло его употребляли».[3,с.145]

В рассказе «Кавказский пленник» Л.Н.Толстой показал находчивость русского солдата Жилина. Только благодаря своему трудолюбию, своей выносливости он смог завоевать уважение у читателей. Он думает не только о себе, но хочет помочь и Костылину. В этом поступке видно его отношение к дружбе, автор показывает его отзывчивость. Именно на эти качества обращают внимание дети при чтении рассказа. Цену дружбы, правдивости учащиеся увидели при чтении повести В.Г.Короленко «В дурном обществе».

Основная задача нравственного воспитания: воспитание людей совестливых, порядочных, уважающих жизнь и мнение других людей, ценящих человеческое достоинство в себе и других, способных самостоятельно и творчески решать поставленные задачи и противостоять злу, неспособных к аморальным поступкам, живущих достойно и счастливо.

Экологическая культура подрастающего поколения – это составная часть общей культуры общества. Экологическая культура начинается с воспитания любви, бережного отношения к природе, «братьям нашим меньшим», родному селу, в конечном счете – к Родине.

Стихотворения А.А.Фета, Ф.И.Тютчева, А.Н Майкова, И.С.Никитина развивают в детях не просто чуткое отношение к слову, а способность удивляться, восхищаться красотой родной природы, которую воспели они в своих стихах.

В рассказе В.П. Астафьева «Васюткино озеро», в котором Васютка, ровесник пятиклассников, оказался один на один с тайгой. Произведение В.П. Астафьева учит не только выносливости, стойкости духа, смекалке, терпению, но и тому, что лес, река, животные, рыбы часто становятся нашими помощниками, помогают выжить человеку в трудных условиях.

Обострение экологической проблемы в стране и в мире диктует необходимость интенсивной просветительской работы по формированию у детей экологического сознания, культуры, природопользования. Наши дети экологически не воспитаны, не у всех проявляется доброжелательное отношение к живым существам, объектам природы, не у всех достаточен запас знаний об окружающей нас природе, они потребительски относятся к ней. Литература была и будет важным инструментом нравственности, человеческого отношения ко всему живому. Наша цель – дать нравственное и экологическое воспитание на уроках литературы, и это надо начинать как можно раньше.

Литература:

1.Литература. 5 класс. Учебник для общеобразовательных учреждений. В 2 ч., под ред. В.Я.Коровиной.

2. Литература. 5 класс. Учебник для общеобразовательных учреждений. В 2 ч., под ред. В.Я.Коровиной.

3. Литература. 5 класс. Учебник для общеобразовательных учреждений. В 2 ч., под ред. В.Я.Коровиной.

**Әйдәгез, туган табигатебезне саклыйк, чаң сугыйк!**

***Фаррахова Резеда Рәҗәп кызы,***
***Минзәлә шәһәренең I нче кв.категорияле***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы.***

Әхлакый тәрбия бирү- кешелек дөньясы алдында торган иң мөһим проблемаларның берсе. Кешенең әхлагы булмаса, ул үзе дә, аның тирә-ягындагылары да бәхетсез була. Кызганычка каршы,бүгенге көндә бу проблема көн кадагына сугылган проблемаларның берсе .Гаиләдә ата-ана тәрбиясе тиешенчә бирелмәгән бала өчен бердәнбер тәрбия учагы - мәктәп, ә мәктәптә бала күңеленә әхлакый сыйфатларны сеңдерүчеләр – тел һәм әдәбият укытучыларыдыр.

“Әхлак берлә әдәбият бергә булырлар. Бер кавемнең әдәбияты нинди рәвештә булса, әхлагы да шул рәвешле булыр”,- дигән Риза Фәхретдин.

Әдәбият дәресләренең төп максаты- әдәби әсәрләрнең матурлыгын күрә белергә, эстетик һәм интеллектуаль ләззәт алырга өйрәтү. Моның белән генә чикләнмичә, шул ук вакытта әдәби әсәрләр аша укучыларның дөньяви күзаллауларын аңлау- фикерләү сәләтен үстерү, әхлакый тәрбия бирү максатын да онытырга ярамый. Әдәбият укучының аңына гына тәэсир итеп калмый, ул аның хисләренә дә йогынты ясый. Әдәбият дәресләрендә бала һәр күренешне җаны – тәне белән тоя, сиземли белергә өйрәтелә. Бүгенге көндә рус һәм татар төркемнәрендә белем алучы һәр укучы иҗади фикер эшчәнлеген үстерү өстендә күп көч сарыф итә. Укучылар мавыктыргыч дәресләрдә генә үзләрен тулы шәхес итеп хис итәләр. Шуны истә тотып, без һәр әдәбият дәресен бала өчен кызыклы, алар чишә алырдай проблемалар белән” бизәп” төзергә тырышабыз.

Балаларга әхлакый-экологик белем һәм тәрбия бирү зарур. Татар халкының табигать күренешләре, ел фасыллары, бөҗәк, кош, җәнлекләр турында әхлакый эчтәлекле күпме табышмак, әйтем, сынамыш, бәйрәм-йолалары бар. Мәсәлән:

"Җәен – соры, кышын ак,
Аңа шулай яхшырак".

Укучыларда экологик белем һәм тәрбия бирүдә мәкаль-әйтемнәрне еш файдаланырга мөмкин.

"Кул пычранса, су белән юарсың,

Су пычранса, ни белән юарсың".

Халкыбыз су турында нинди зирәк фикер әйткән.

Татар халкының ел фасылларының иң үзенчәлекле көннәренә багышланган бәйрәм-йолалары күп. Мәсәлән, кышкы һәм җәйге Нардуган бәйрәмнәре, Сөмбелә, Карга боткасы һ.б. Без бу бәйрәмнәрне табигатьтә, урманда уздырырга тырышабыз.

Әхлакый-экологик белем һәм тәрбия бирүдә әдәби әсәрләрнең әһәмияте зур. Язучыларыбыз, беренчеләдән булып, табигатьне саклау турында чаң сукты. Әйләнә-тирә дөньяны, кеше сәламәтлеген, аның рухын, телен саклау аларны иң борчыган һәм дулкынландырган проблемага әйләнде. Нәфис сүз, сәнгать чаралары ярдәмендә кешедә югалып бара торган иң изге әхлакый-рухи кыйммәтләрне торгызу, Җир-анага игелек, хөрмәт хисләрен уяту, кешелекнең экологик һәлакәт каршында торуында искәртергә кирәк иде.

Табигатьне саклау, экология темасына язылган М. Кәримнең "Озын, озак балачак", Г. Сабитовның "Ярсулы яз", Г. Бәшировның "Туган ягым – яшел бишек", Ә. Баяновның "Сәяхәтнәмә", И. Юзеевның “Карурман” әсәрләрендә кеше һәм табигать мөнәсәбәтләре үткен итеп куела. Г.Гыйльмановның “Агроном егет”, “Бөркет”, “Мәңгелек матурлык”, “Табигать күзе”, “Җир тетрәү алдыннан”, “Каеннан һәйкәл” кебек парча һәм нәсерләре эчке, рухи киеренкелеге һәм авылга, табигатькә тугрылыгы белән дә үзенә җәлеп итә! Аның «Ана сүзе», «Әрем исе», «Күңел күзең күрәме?», «Гомер эзләү» һ. б. хикәяләре дә һәр яктан күңелне кузгатырлык.

Татар теле дәресендә дә экологик, әхлакый белем һәм тәрбия бирү мөмкинлекләре бар. Язучыларыбызның, шагыйрьләребезнең хикәя – шигырьләреннән тәрбияви моментларны үз эченә алган өзекләр белән эшләтү дә бала күңеленә берникадәр тәрбия орлыклары салынуга хезмәт итә.

Татар теле дәресендә дә экологик белем һәм тәрбия бирү мөмкинлекләре бар. Мәсәлән, ел фасыллары, үсемлек, җәнлекләр, табигатьне саклауга багышланган диктант, изложение, иншалар яздыру балаларда табигатькә, кошларга сак караш һәм кайгыртучанлык тәрбияләү.

Укучыларның яшь үзенчәлекләрен искә алып, экологик проблемаларның иң зурысыннан түгел, ә көн саен очрый торган әйберләрдән башласаң дөресрәк булыр. Дәресләрдә изложение һәм диктантлар өчен текстлар сайлаганда табигать байлыклары, алардан кешенең ничек файдалануы турындагы текстлар бик үтемле.

Шулай ук татар теле дәресләрендә гади һәм кушма җөмләләрне өйрәнгәндә ничек итеп дөрес учак ягарга өйрәнергә, үзләренең дуслары этләр, песиләр, аквариум балыклары турында хикәя язу да уңай нәтиҗәгә китерә. Табигать куренешләрен тасвирлаган картиналар өстендә эш, газета- журнал материаллары- барысы да экологик тәрбия бирүгә ярдәм итә. Текстлар буенча эшне төрлечә оештырырга мөмкин: текстка исем куй, текст буенча план төзү, текстның ахырын яз, сораулар төзе һ.б..

Экологик тәрбия буенча төрле эш алымнары куллану- табигатькә икенче төрле күз белән карарга, табигать өчен безнең дә җаваплы икәнебезне аңларга ярдәм итә.

Әйдәгез, туган табигатебезне саклыйк, чаң сугыйк! Миңа бүген булса җиткән, иртәгесен башкалар кайгыртсын дигән принцип белән яшәмик. Һәрбер кеше аз гына булса да өлеш кертсә, табигать безгә йөз белән борылыр иде.

Кулланылган әдәбият.


1. 1. Г. Гыйльманов. Китек ай: Повестьлар, хикәяләр, парчалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 383 бит.

2. Шәмси Солтан. Җәяүле буран: Повесть һәм хикәяләр. - Казан: Татар. кит. нәшр., 1988

3. "Мәйдан" журналының 2008 нче елгы 5 нче саны.

**Абдулла Алиш иҗатында экология темасының яктыртылышы**

***И.М.Фархутдинов, Г.М.Габдуллина,***
***татар теле һәм әдәбияты укытучылары,***
***Казан информацион технологиләр***
***һәм элемтә техникумы.***

Әкиятләрдә тормыш тәҗрибәсе, халык акылы, зирәклеге чагыла. Милли телләрне камилләштерүдә, укучыларның рухын баетуда әкиятләрнең роле гаять зур.

Муса Җәлилнең көрәштәш дусты Абдулла Алишның чын таланты әкиятләр жанрында ачыла. Әдип әкиятләрнең балаларга тәэсирен, бу нигездә тәрбияләүнең халык педагогикасында иң отышлы алымнарның берсе булуын аңлаган. Аның балалар әдәбиятындагы эшчәнлеген бәяләп, Гази Кашшаф: «... Олы йөрәгенең җылысын балаларга өләшеп бирергә әзер торуы һәрбер адымыннан сизелә», - дип язды. А. Алишның күп әсәрләре хайваннар тормышыннан алып язылган. Бу төр әкиятләрдә язучының табигатькә булган мәхәббәте, аны яхшы белүе, матурлыкны башкаларга да җиткерү омтылышы, гадилеге күзгә ташланып тора. Ул вакыйгаларны катлауландырмый, әмма әкиятләр фикер һәм фантазиягә, хисләргә бай. Алар гадилек белән сюжет барышында тыгыз үрелә. Гомумән, табигатькә соклану, аңа мәхәббәт уяту табигатьне, мохитне саклау темасы белән бергә үрелеп бара. Туган табигатькә мәхәббәт хисе патриотизмның төгәл бер чагылышы булып тора.

Эшчәнлегебездәге экология темасынының яктыртылышын мисаллар белән күрсәтергә кирәктер дип саныйбыз. “Бик яхшы сабак алды ябалак”, “Нечкәбил”, “Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар” кебек әсәрләр нигезендә укучыларда иң гади экологик тәрбия башлангычларын салып калдырырга мөмкин. Иртәнге чык сафлыгы, йөгерек елгалар җыры, шаян җилләр җитезлеге бар ул әкиятләрдә. Әкиятләрнең күбесендә хайваннар һәм кошлар дөньясы сүрәтләнә. Андагы хайваннар, кошлар, бөҗәкләр үзләренә хас табигый сыйфатлары белән бирелгәннәр, шулай ук аларда кеше характерында була торган үзенчәлекләрне дә күреп була. Бу нәрсә әкиятнең тәрбияви көчен

үстерә. Вакыйгалар һәм персонажлар турында фикер йөртеп, укучы үзе тиешле нәтиҗәне ясый ала. Мәсәлән, "Сертотмас үрдәк" экиятендәге үрдәк йорттагы барлык серләрне сөйләп йөрүе аркасында һәлак була, башка хайван һәм кош-кортларны да куркыныч астына куя. Ярый әле, хуҗа ерткычлардан саклану чараларын алдан күрә, вакытында кайтып, йортны коткара. Әкияттә, нигездә, кошлар, җәнлекләр турында сөйләнсә дә вакыйга реаль чынбарлыкка – кешеләр тормышына якын. Уяулык, сизгерлек, ил-йорт серен саклый белү – җаваплы һәм изге бурыч, намус эше дигән нәтиҗә ясала.

Иҗаты аша язучы кешеләрне табигать дөньясы, җәнлекләр һәм кош-кортлар белән аралаштыра, тормыш-көнкүреш детальләре белән таныштыра; балаларны төрле матур гадәтләргә, хезмәткә өйрәтү, ата-аналарны һәм олыларны ихтирам итү, гаделлек, батырлык кебек күркәм сыйфатлар тәрбияләүне күздә тота. Шулай ук экиятләрендә табигатьнең могҗизалы дөньясын, аның матурлыгын ачып бирү өчен ул сюжетны үзенә генә хас булган осталык белән кора, образлы итеп әйтеп бирә. Шуңадыр, күрәсең, экиятләре татар әдәбиятының алтын фондына кертелгән.

А. Алиш әсәрләрендә табигать күренешләрен тасвирлау фикерне тулырак һәм төгәлрәк җиткерү максатыннан кертелә, укучыларның танып-белү сәләтен үстерә.

Кулланылган әдәбият:


1. А.Алиш сайты: alish.ru
2. Алиш А.Г. Әсәрләр: 2 томда
3. А.Алиш: shigriyat.ru

**Табигать һәм шәхес бердәмлеге.**

***Алабуга муниципаль районы***
***муниципаль гомуми бюджет***
***белем учреждениесе"4нче гиназия"***
***Фәттахова Раушания Миңнеәхәт кызы***
***беренче квалификацион категорияле***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

Борынгы фәлсәфәчеләр: "Кеше ике тапкыр туа. Беренче тапкыр физик яктан, икенче тапкыр рухи яктан",- дип әйткән. Икенче тапкыр туу иң катлаулы, дәвамлы процесс.

Кешенең әхлакы - күпкырлы күренеш. Безнең мәктәп педагогик коллективы экологик тәрбияне укучыларга әхлак тәрбиясе бирүдә төп юнәлешләрнең берсе дип саный. Яшь буында табигатькә кызыксыну тәрбияләү, туган якка мәхәббәт уяту аеруча зур әһәмияткә ия. Шуңа күрә экологик белем нигезләрен башлангыч сыйныфларда ук өйрәнә башларга кирәк. Ә экологик күзаллау табигать белән турыдан-туры аралашканда гына формалаша. Шушы максатны күздә тотып, без елның төрле вакытларында экскурсияләр, сәяхәтләр оештырабыз, гамәли эшләр башкарабыз, КВНнар үткәрәбез, һәм, әлбәттә экология-биология үзәге белән бәйләнештә торабыз. Шушы чаралар вакытында укучылар күңеленә сеңеп калган һәр мәгълүмат балаларның эчке дөньясын баета, аларда матур хисләр тәрбияли. Әлеге юнәлештә эш уку елы тәмамлангач та тукталып тормый. Җәйге чорга укучыларга бурычлар билгеләнә, ә аның нәтиҗәләре ата-аналар катнашында үткәрелгән көзге "Уңыш бәйрәм"ендә ясала. Әгәр һәр эшчәнлек тә кешелеклелек мөнәсәбәтләре белән сугарылмаса, бернинди түгәрәкләр, секцияләр, конкурслар да балага уңай тәэсир итмәячәк. Ә моның өчен ата-аналар белән күп эшләргә кирәк. Алар гаиләдә әхлак тәрбиясе бирүне дәвам итә. Өлкәннәр үз эш гамәлләре, үрнәкләре белән балаларда хезмәт сөючәнлек, гаделлек, игелеклелек сыйфатлары тәрбияли. Мәктәбебез Алабуга шәһәрендә эшләп килүче "Түбән Кама тыюлыгы паркы" белән тыгыз элемтәдә тора. Алар үз чиратында балалар белән әңгәмәләр, конкурслар,

бәйрәмнәр үткәрәләр, аларны үсемлекләр тәрбияләргә өйрәтәләр, бергәләшеп кошларга җимлекләр, сыерчык оялары әзерлиләр, агачлар утырталар.

Ә без татар теле һәм әдәбияты укытучылары балаларда табигатькә әнә шундый мәрхәмәтле, сакчыл карашны әдәбият дәресләрендә әдәби әсәрләрне анализлау барышында тормышка ашырабыз.

Башлангыч сыйныфларда Габдулла Тукай әсәрләре өйрәнелә ( “Бала белән Күбләк”, Су анасы”, Шүрәле”). Ул үзенең әсәрләрендә җәнлекләрне, кошларны, бөҗәкләрне яратырга, аларга мәрхәмәтле, шәфкатьле булырга өнди, үзенең шигъри бизәкләре белән табигатьнең гүзәллеген ача. Табигатьнең матурлыгын, серлелеген Тукаебыз үзенең җаны, саф күңеле, йөрәк җылысы салынган әсәрләре белән укучы җанына сала.

4 нче сыйныфта үтелгән “Дару үләннәре”, “Витаминлы аш” хикәяләре укучыларда табигать биргән байлыклардан сак кулланырга кирәклекне тәрбияли.

8 нче сыйныфта Н. Гыймадиеваның “Болын патшасы” хикәясе өйрәнелә. Бу хикәядә табигать матурлыгы, бала белән табигать мөнәсәбәте, дуслык, игелеклелек, мәрхәмәтлелек хисләре чагылыш таба. Укучылар әсәрдә кешеләр һәм табигать язмышының охшаш һәм аларның бергә үрелеп баруын күрәләр. Кечкенә генә кызчыкның табигать серләрен белүе, аңа ышануы шулкадәр көчле, хәтта авыру малайны терелтү көченә ия. Сай елга буендагы җылы ком, шифалы дару үләннәре, саф һава, чишмә суы.

Әдәбиятта чишмә образы берничә дистә еллар дәвамында актуальлеген югалтмый. Аеруча бүген, экологик мәсьәлә кискенләшкән чорда, каләм әһелләренең чишмә образына мөрәҗәгать итүләре укучыны туган як табигатенә, халкына, милли йолаларына, гомумән, мәдәниятенә карата ихтирамлы, сизгер, сакчыл караштa булырга чакыра, матурлыкны тоя белергә өйрәтә.

Үзләренең шигъриятләрендә чишмә образын гәүдәләндергән шагыйрьләребез шактый безнең. Чишмә белән бәйләп туган як табигате дә, әнкәйләр образы да, әкияти сюжетка корылган баллада-поэмалар да, мәхәббәт,

сөю-сөелүләр дә, туган җирне юксынып, чишмә буйларына ашкынып кайткан авылдашлар, замандашлар да, укучы балаларның шефлык итүләре дә — барысын да сыйдыра, образлый, күңелгә үтеп керерлек аңлатып бирә шигърият.

Соңгы елларда табигать белән кеше арасында мөнәсәбәтләрнең шактый кискенләшүе күзәтелә. Моның сәбәбе аңлашыла да: заман кешесе торган саен фән-техника алгарышына омтыла, әмма кеше һәм табигать бер-берсеннән аерылгысыз һәм алар бер-берсенә ярдәм итеп, бер-берсен кыерсытмыйча яшәргә тиеш.

Табигатькә, әйләнә–тирәгә төпле, миһербанлы мөнәсәбәт прозага да чишмә образын алып керде. Аның иң үзенчәлекле чагылышы Г. Бәшировның "Җидегән чишмә" романында һәм Р. Мөхәммәдиевнең "Беренче умырзая" повестенда булды.

Бу ике әсәрдә дә чишмә образлары аркылы кешеләрнең тормыш-көнкүрешләре күбрәк табигатькә, аның кануннарына бәйләнгән булуын күрәбез. Әсәрләрдән күренгәнчә, кеше табигатькә сыенса, аңа "яшәргә" ярдәм итсә генә, табигать тә кешегә булыша. Ә кемнәр табигать белән килешеп яшәргә теләми ул алардан үч ала. Бәйләнешле сөйләм теле үстерү дәресләрендә "Туган як моңнары", "Табигать һәм без", "Чәчәкләр турында", "Яшел даруханә" шундый туган ягыбыз табигате, аны саклау, яклау, туган якка мәхәббәт тәрбияләү, аның белән горурлану хисләре уята торган темалар өйрәнелә.

Әдәбият буенча сыйныфтан тыш үткәрелә торган чаралар да экологик тәрбия бирүне күздә тотып башкарыла. Мәсәлән: "Нәүрүз", "Сөмбелә", кошлар көне.

Табигать байлыкларына битараф булу - кеше язмышына да салкын карау дигән сүз. Ә әдәбият белеме кеше язмышы белән тыгыз бәйләнештә яши. Табигать язмышыбыз - безнең язмышыбыз. Табигатьне саклау- ул үзебезне, киләчәгебезне, өебезне саклау дигән сүз. Үз-үзеңә, туган җиргә тугры булып калу, аның кадерен белү элек-электән яшәү мәгънәсенең асылын аңлаткан. Безгә аны югалтмыйча, тагын да баетып, килер буыннарга мирас итү бурычы йөкләнгән.

Әйе, без табигать белән тәңгәллектә генә генә яши алабыз. Һәр гамәлне акыл белән башкарырга кирәк. Шул чакта гына без матурлыкны, табигатьне коткарып кала алырбыз. Әдәбият дәресләрендә укучыларга шушы фикерне җиткерә алсак, киләчәкне ышанычлы кулларга тапшырдык дип әйтергә нигез булыр иде.

*Хәбирова Ф.З. педагогика һәм психология фәннәре укытучысы*

## Шәхес үсешендә әхлакый-экологик тәрбиянең роле.

***Хәбирова Фирая Заһир кызы***
***ДАҺБУ "Муса Җәлил исемендәге Минзәлә педагогия колледжы"ның***
***педагогика һәм психология фәннәре укытучысы***

Халык элек-электән, җәмгыятьнең явыз көчләренә каршы торып, кешелекнең табигать көчләре белән авыр көрәшендә тупланган күпъеллык тәҗрибәсе аша яктылыкка, белемгә омтылган. Халык педагогикасы, белем-тәҗрибәсе, күп гасырлар буе буыннан-буынга күчеп, яшь буынга тапшырылып килгән.

Халык педагогикасы яшь буынга белем алу, җитештерү, фән һәм сәнгать өлкәсендә иҗади эшчәнлек белән шөгыльләнү, әхлакый камилләшү өчен җирлек тудыручы чараларның башлангыч нигезен тәшкил итә.

Кешелек җәмгыятен һәрвакыт борчып килгән әхлак мәсьәләләре – намус, гаделлек, җирдә дөрес итеп яшәү, әти-әни һәм Ватан алдындагы изге бурычны үтәү кебек төшенчәләр мәңгелек, һәркем өчен уртак. Аларны үзеңдә булдыру өчен Кеше булу кирәк. Бүген, бөтен кешелек дөньясы күләмендә глобальләшү хәрәкәте киң колач алган чорда, киләчәкне үз кулларында тотачак буыннарны рухи-әхлакый тәрбияләүгә игътибарны арттыру турында һәркем уйланырга тиеш.

Кешелек яратылганнан бирле тәрбия мәсьәләсе көн кадагында тора.

Безнең максатыбыз - һәрьяклап камил шәхес тәрбияләү. Тарихи үсеш дәвамында халыкның хәтер сандыгында шәхес тәрбияләү белән бәйле карашлары, фикерләре, ысуллары тупланып килгән, һәм ул рухи хәзинә өзлексез камилләшә барып, буыннан- буынга тапшырылган. Яңа буын, үз чиратында, халык меңәр ел туплаган гореф-гадәтләрне, йолаларны саклап, телен-динен хөрмәтләп яшәгән. Олыга-олы дип, кечегә-кече дип караган.

Картайган ата-анасын тәрбия кылуны, тудырган баласын багып үстерүне изге бурыч итеп санаган, бәндәнең рәнҗеш - каргышыннан, ананың бәддогасыннан уттан курыккандай курыккан. Хак хаклый белгән безнең халык: Аллаһ хакын, күрше хакын, тол-ятимнәр, ярлы-ябагайлар, милләт хакын.

Борынгы грек фәлсәфәчесе Сенека:” Гыйлемлелектә алга китеп тә, әхлаклылыкта артта калган кеше алга китүдә иң артка калган кеше,”- дигән.

Әхлак –нәрсә ул?

Әхлак-күркәм холык, үзеңне тота белү, тәрбиялелек,тотнаклылык, кешеләр белән аралаша белү, янәшәдәгеләргә хөрмәт белән карау төшенчәләрен тәшкил итә.Әхлак ул - кешенең эш-хәрәкәтләрендә, көндәлек тормышында билгеле бер калыпка салынган , билгеле бер кыйммәтләрдән торган сыйфат.

"Әхлак тәрбиясе" мәңгелек төшенчә үзе. Элек-электән ата-ана, өлкәннәр, мөгаллимнәр бала-чаганың игелекле, итагатьле, тәртипле, кешелекле булып үсүенә нык игътибар иткән, гаиләдә ата-анага, әби-бабага, мәктәп-мәдрәсәсендә мөгаллимнәргә һәм аларга ярдәмгә куелган башка берәүләргә хөрмәт, олылау, тугрылык хисләре тәрбияләү үзәккә куелган. Шәхеснең формалашуында һәм үсүендә әхлак тәрбиясенең роле элек -электән исбатланган, расланган.

Федераль дәүләт стандартларына күчү барышында да әхлак тәрбиясенең нигезе һәм бурычлары, тәрбия процессы — кешенең тулысынча шәхес буларак формалашуы. Әхлак тәрбиясе – тәрбия эше системасының үзәге, иң мөһим юнәлеше. Кеше үз эшчәнлеге дәвамында, аралашу вакытында дөньяга , кешеләргә мөнәсәбәттә әхлак нигезләрен туплый. Шәхеснең һәрьяклап усешен тәэмин иткән башка төр тәрбияви берәмлекләр барысы да әхлак мөнәсәбәтләре , әхлаклылык принциплары аша уза.

Дәүләт стандартларын тормышка ашыруда әхлак тәрбиясе процессында укытучы-тәрбиячеләрнең роле зур. Алар тиешле шартларны тудыра, оештыра да — алар балаларнын укуы, хезмәте, ялы, уены һәм һәртөрле эшчәнлеге дәвамында әхлак мөнәсәбәтләрен тиешле якка юнәлтә. Шул ук вакытта әлеге тәрбия процессы тәрбиячеләр биргән юнәлеш буенча гына түгел, ә бәлки көтелмәгән хәлләр, көтелмәгән очраклар тәэсирендә дә дәвам итә. Ә болары әхлак тәрбиясе процессына уңай да, кире дә тәэсир итәргә мөмкин. Менә шушы хәл тәрбия эшендә катлаулылык тудыра һәм тәрбиячеләрдән зур осталык, күңел сизгерлеге сорый. Федераль дәүләт стандартларына күчү барышында колледжда әхлак тәрбисенең төп бурычлары студентларда әхлак тәҗрибәсе булдырудан тора. Яхшыны яманнан, яманны яхшыдан аера белү тәҗрибәсе кешедә яшьтән үк тәрбияләнә. Ул аны көндәлек тормышы, эше, эшчәнлеге, башкаларга мөнәсәбәте белән ныгыта гына бара. Бала чакта барлыкка килгән әхлак нормалары кешене җитлеккән, олыгайган чорына кадәр озата бара.

Җәмгыятькә, табигатькә әхлаклы мөнәсәбәт тәрбияләү исә – укучыда гражданлык хисләре, патриотизм, иҗтимагый һәм рухи активлык, Җир-анага игелек, хөрмәт хисләре тәрбияләү булып тора. Кеше үзенең шәхси тормышында, гаиләдә үзен билгеле бер җәмгыятьнең тулы хокуклы һәм җәмгыять алдындагы бурычларын тоя белгән гражданы итеп хис итәргә тиеш. Ләкин бу гына аз әле, әхлаклы бала табигатьне аңлый белергә тиеш.

"Үзен – табигать патшасы" дип исәпләгән адәм баласының эшчәнлеге һәрчак уңай нәтиҗәләр бирми. Киресенчә ул күп очракларда табигать анабызга фаҗигале үзгәрешләр алып килә, әйләнә - тирәбезгә күпме зыян салды һәм сала. Күп сулы елгаларыбыз саега, җирләр упкынсыман ярыклар белән яргалана. Елга үзәннәре баткаклыкка әйләнә, пычрана. Эчәр суларыбыз, сулар һавабыз көннән – көн шакшылана бара. Иген үстерелә торган уңдырышлы җирләр чикләнгән. Һәрберебезгә якын булса да һәм күп сөйләнелсә дә, экология фәне шул ук вакытта шактый серле булып кала.

Табигать – безнең бүгенге байлыгыбыз гына түгел, киләчәгебез дә. Аның байлыгын бездән соңгы килгән буыннарга да калдыру безнең уртак бурычыбыз. Кеше – табигатьнең аерылгысыз бер өлеше. Ул табигатьтән башка бер генә көн дә, бер генә сәгать тә, бер генә минут та яши алмый, аңа су, һава, азык – төлек, җылылык һәм яктылык кирәк. Балаларда табигатькә әнә шундый мәрхәмәтле карашны, табигатьнең матурлыгын тоя белүне әкеренләп аны яклый, саклый белүне кечкенәдән үк тәрбияләүдә зур эшләр алып барылырга тиеш.Табигать – саекмас белем чишмәсе. Заманыбызның күренекле педагогы В.А. Сухомлинский табигатьне, әйләнә - тирә мохитне һичкайчан саекмас белем чишмәсе, матурлык, бәхет чыганагы дип атады. Бу чыннан да шулай. Балалар җәйге аяз көндә нурланып кояш чыгуын, бөтерелә - бөтерелә күбәләкләр очуын, ә яз җиткәч гөрләвекләр агыун күреп олы шатлык хисе кичерәләр. Табигатьнең шушы гүзәллеген кече яшьтән үк күрергә, тормышка сөенергә өйрәтергә без педагоглар бурычлы.

Әхлакый-экологик белем һәм тәрбия бирү өлкәсендә безнең колледжда куп төрле чаралар үткәрелә. Группа кураторы буларак мин иң беренче чиратта студентларга тәрбиянең тормышта ни дәрәҗәдә әһәмияткә ия икәнлеген аңлатырга һәм бары тик, тәрбияне дөрес аңлаган, тәрбияле  кеше генә яхшы гамәлләр кыла алганын аңлатырга тырышам. Группа белән өлкән буын укытучыларга ярдәм итү, әйләнә-тирә мохитне чистартуда, агачлар утыртуда актив катнашу, барлык  төр мероприятияләргә теләп катнашу, белем алуга омтылыш, шигырь уку бәйгеләрендә катнашу, бер-береңә  ярдәм итү , начар гадәтләр булмау – менә болар барысы да студентларның  әхлакый - экологик нормаларын ныгытуда бик нык ярдәм итә.

Җирдә тереклек дәвам итә. Изге куәткә ия булган әхлак орлыклары шытым биреп, алар һаман да үсеп җимешләрен бирсен иде. Бала чакта барлыкка килгән әхлакый - экологик нормалары кешенең җитлеккән, олыгайган чорына кадәр озата бара.

Нәфис сүз, сәнгать чаралары ярдәмендә кешедә югалып бара торган иң изге әхлакый-рухи кыйммәтләрне торгызу, Җир-анага игелек, хөрмәт хисләрен уяту, кешелекнең экологик һәлакәт каршында торуын да искәртергә кирәк .

Кешелек җәмгыятен һәрвакыт борчып килгән әхлак мәсьәләләре – намус, гаделлек, җирдә дөрес итеп яшәү, әти-әни һәм Ватан алдындагы изге бурычны үтәү кебек төшенчәләр мәңгелек, һәркем өчен уртак. Аларны үзеңдә булдыру өчен Кеше булу кирәк. Ә укучыларны Кеше итеп тәрбияләү – безнең һәрберебезнең бурычы.

## Татар әдәбияты дәресләрендә әхлакый һәм экологик тәрбия.

***Хәйруллина Рәдисә Ахун кызы,***
***ДАҺББМУ "Казан төзелеш көллияте"нең***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы.***

Татар әдәбиятында экологик тәрбия нигезендә әхлакый тәрбиягә ия булган әсәрләр зур урын били. Аларда кеше, аның рухи дөньясы үзәктә тора: «Бичуралар һәм бичаралар» (Л. Зөлкарнәй), «Урман букеты» (И. Туктар), «Су тәме» (Ш. Маннапов). Зур күләмле әсәрләр арасында да әйләнә-тирә дөньяны, кеше сәламәтлеген, аның рухын, телен саклау проблемаларын күтәргән повесть-романнар шактый. Боларга мисал итеп, Г. Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек», «Җидегән чишмә», М. Мәһдиевнең «Торналар төшкән җирдә», Р. Мөхәммәдиевнең «Ак кыялар турында хыял», М. Әмирнең «Агыйдел» һәм башка шундый әсәрләрен китерергә була. Әдипләр борынгыдан килгән гореф-гадәтләргә ихтирам тәрбияләргә, табигый байлыкларга сакчыл булырга, кадерен белергә, өлкәннәргә хөрмәт белән карарга чакыралар, шатлык-куанычларны, кешенең матурлыгын, кайгы-хәсрәтне, олы фаҗигаләрнең тирәнлеген табигать аша ачып салалар.

1994 нче елда «Казан» журналында шагыйрь Зөлфәтнең (Дөлфәт Маликов) «Тояк эзләрендә гөл үсә» дип исемләнгән нәсере дөнья күрде. Бу әсәрендә

Зөлфәт туган як табигатенең аянычлы язмышы белән беррәттән, Казаныбызның табигате турында да тирәнтен уйлана. Мисал өчен, Сазлык язмышын тасвирлаган өзеккә тукталыйк: «Хәер, Казанда яши торгач, Адәм балалары һәлак иткән гүзәл Сазлыкларның язмышы үзәгемә үтеп сызландырды мине. Көмештәй инешне сазлык итү дә, табигать үзе яшәп торган соклангыч сазлыкны ком чүле итү дә бер үк кыргыйлык икән».

Узган гасыр уртасында, Савиново бистәсе урынына, 39 нчы квартал төзи башлаганнар. Шагыйрь йортының тәрәзәләре нәкъ шул Сазлыкка карап торган. Ул көн саен яңа төзелешне күзәткән һәм чын күңеленнән борчылган. Хәтта шул чорда «Казан шәһәренең 39 нчы квартал янындагы сазлыкның төнге бәхилләшүе» дигән шигыре дә туган.  Ә инде «Тояк эзләрендә гөл үсә» дигән әсәрендә тетрәнеп, ул болай дип яза: «Кем өчендер, бәлки, сәер дә тоелыр, әмма мин Әҗәлнең ни икәнен Казанда белдем. Әйтик, шул ук Сазлык. Хуш исле, күкрәп чәчәк ата торган Сазлык. Төнге көмеш Ай нурыннан җемелдәп, балкып тора ул, яшел дөньясы белән тирән иттереп, саф иттереп сулыш ала... Әмма аның язмышы хәл ителгән инде – Сазлыкны төбенәчә көрәп алып, аның урынына җансыз, кансыз ком тутырачаклар. Табигатьнең иң нәфис иҗаты өстенә Гыйфрит үзе ябырылып килә. Тимер тешләрен ыржайтып, моторларын үкертеп, Заман ябырылган гүзәллеккә! Йә, сазлыкларның һәммәсе дә Адәм баласына зыянлы микәнни соң инде? Йә, шушы якты Кояш астында сыешыр урыннарыбыз калмадымы?»

Авылда туып-үскән шагыйрь буларак, ул табигатьне җаны-тәне белән тоя. Укучыга бу фаҗигане Сазлыкның үз исеменнән сөйләве белән тетрәндерә:

«Күзем күрде, күзем түзде – кулым түзә алмады, дигәндәй, төннәрнең бер төнендә Сазлыкның төннәр буена Тәңрегә табынганын ишеткәндәй булдым. Сазлык инәлеп ялварды:

– И Бөек Төн! Үзеңә иман китергән һәр җан иясен тыңларга әзер син! Гөнаһларыбызны Көн күрә дә, Төн ала. Бу төндә мин Сиңа ялварам. Бу мин – Сазлыгың синең. Талларыма, түмгәкләремә оя корган тәкәрлекләремә дәшәм бүген. Сусыл камышларыма, тымызык күлләремә эндәшәм. Бәхилләшәм. Адәм

баласына ташпулатлар җитми, аяк терәрдәй тыгыз туфрак җитми. Адәм баласы комсыз. Мин китәргә, кибәргә, юл бирергә тиешмен. Сазлыгың Синнән бәхиллек сорый, Төнем!

...Мең тавышлы, мең сагышлы очар саз кошларым, мин сезне бүтән ял иттерә алмам инде! Кайларга гына китеп ышык табарсыз да, кайларда гына төн кунарсыз?

Ояларыгызны кем җылытыр? Сезне улап торган автострадалар өркетер, ком бураннары канатларыгызны каерыр. Яшел зирәкләремә сыендырып асрадым мин сезне. Саз күбәләкләрем, серле Саз утларым! Миннән гайре кем генә яшәү куәте бирер сезгә? Таңда болыт булып күтәрелергә хыялланган Ак Томаным! Сине нинди язмыш көтә? Бәхил булыгыз!...»

Туган авыл, туган як турында уйланулар – язучылар һәм шагыйрьләр өчен мәңгелек тема. Зөлфәт тә бу әсәрендә туган як чишмәләрен читләтеп үтми. Шагыйрьнең уйлары Казан буйлап Мөслим районының Яңа Сәет авылына әйләнеп кайта: «Изгеләр Чишмәсе булмаган ил – ил түгел. Андый ил – үксез ил, котсыз ил... Изгеләр Чишмәсен тимер-бетон белән томалап куйдылар. Изге Чишмә тимер-бетон астында сыкранды. Бәргәләнде. Тармакларга таралып, бүтән төшләрдән саркып-бәреп чыкты. Саф чишмәләр булып бөркелде!

Әйе, беләм, тамырлары корыган илләр, исемсез калган кавемнәр бар. Кыямәт уты Яшәеш тирәген көйдерә тора. Адәм балаларының иң зур гөнаһы – җаннардагы Изгелек чишмәсе кипте, тәмам корыды».

Бу урында сүз экологик тәрбия турында гына бармый. Әлеге язмада шагыйрь Җир-Ананың фаҗигасенә битараф булмавын тирән хисләр аша сурәтли. Автор Сазлык, Чишмә, көмештәй Инеш образлары һәм аларның кичерешләре белән укучыны уйландыра, сискәндерә, табигатькә башка күзлектән карарга мәҗбүр итә икән, димәк, бу инде әхлакый тәрбия дә.

Әхлакый-экологик белем һәм тәрбия бирүдә әдәби әсәрләрнең әһәмияте зур. Язучыларыбыз, беренчеләрдән булып, табигатьне – чишмәләрне, елгаларны, урман-кырларны саклау турында чаң сукты. Әйләнә-тирә дөньяны, кеше сәламәтлеген, аның рухын, телен югалтмау кебек кадерле байлыкны

киләчәк буыннарга тапшыру – аларны иң борчыган һәм дулкынландырган проблемага әйләнде. Нәфис сүз, сәнгать чаралары ярдәмендә кешедә югалып бара торган иң изге әхлакый-рухи кыйммәтләрне торгызу, Җир-анага игелек, хөрмәт хисләрен уяту, кешелекнең экологик һәлакәт каршында торуын да искәртергә кирәк иде.

Кулланылган әдәбият:


1. https://infourok.ru/tatar-tele-m-dbiyati-dreslrend-ekolrgik-trbiya-1098795.html.

2. http://ilbyak-school.ucoz.ru/publ/1-1-0-21.

3. «Ике урман арасы». Казан. ТКН. 1990 ел. 224 бит.

4. «Казан» журналы. №5, 1994 ел.


## Балаларга әдәбият дәресләрендә әхлакый тәрбия бирү


***Хамматова Гүзәлия Габделәхәт кызы,Мөхәммәдева Альфрида Биктимир кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы, ДБГБУ "Советлар Союзы Герое генерал-полковник Василий Николай улы Гордов исемендәге Минзәлә кадет мәктәп-интернаты"***


Әхлак берлә әдәбият бергә булырлар.
Бер кавемнең әдәбияты нинди рәвештә булса,
әхлагы да шул рәвештә булыр."
*(Ризаэддин Фәхреддин)*

"Россия Федерациясендә мәгариф турында" 273 нче федераль законның 2 нче маддәсендә: **"Белем бирү – бердәм максатка юнәлтелгән укыту һәм тәрбия бирү процессы…"** диелгән. Шунлыктан мәктәптә укыту һәм тәрбия бирү һәркайсы аерым-аерым түгел, бердәм белем бирү процессы буларак оештырылырга тиеш. Федераль дәүләт гомуми белем бирү стандартлары шуны таләп итә.

Яшь буынга заманча тәрбия бирүдә иң мөһим юнәлешләрнең берсе – **рухи-әхлакый тәрбия бирү.** Ул белем бирү оешмаларына дәүләт заказы булып тора һәм, әйткәнебезчә, төп гомуми белем бирү программалары нигезендә гамәлгә

ашырыла. Ул гаиләнең, җәмгыятьнең, дәүләтнең таләп-ихтыяҗларын берләштерә, һәм рухи-әхлакый тәрбия бирүдә бердәм эшчәнлек алып барганда гына күтелгән нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин булачак.

Күпмилләтле җәмгыятьтә яшәп тә, үз телебезне, мәдәниятыбызны саклап калу һәрберебезнең изге бурычы. Ә тәрбия бирүнең нигезендә әхлак тәрбиясе ята. Әгәр кешенең әхлагы булмаса, ул үзе дә, аның тирә – ягындагылары да бәхетсез була. Атаклы швейцар педагогы Песталоцци: “Әхлак тәрбиясе балалар учреждениеләренең төп бурычы булырга тиеш,” – дигән. Ә татар теле тел һәм әдәбияты дәресләре балада әхлак тәҗрибәсе булдыру өчен иң туры юл, дип саныйм мин. Иң беренче чиратта балада үз милләтенә, аның гореф – гадәтләренә, тарихына, тел, сөйләм үзенчәлекләренә карата кызыксыну, хөрмәт уятырга кирәк. Бу эш, башлыча, әдәби әсәрләрне һәм халык авыз иҗаты әсәрләрен өйрәнү – анализлау барышында алып барыла. Татар халык авыз иҗаты әсәрләрен өйрәнү дәресләрендә төрле жанрдагы фольклор әсәрләре белән, аларның рус телендәге вариантлары белән танышабыз, уртак һәм аермалы якларын, аларда әйтелгән төп фикерне билгелибез. Төрле әсәрләрнең фольклор белән бәйләнешне ачыклыйбыз.

Үзенең “Тәрбияле бала” исемле китабының иң башында мәшһүр галимебез Р. Фәхреддин тәрбияле баланың нинди булырга тиешлеген, андый баланың җәмгыять өчен нинди зур байлык икәнлеген күрсәтеп, болай дип яза: “Алтыннан да кыйммәтле, оҗмах нигъмәтләреннән дә кадерле булган нәрсә – тәрбияле баладыр. Ата һәм ана өчен тәрбияле бала кебек олы байлык һич булмас. Тәрбияле бала дөньяда җанга шатлык һәм ахирәттә йөзгә аклык китерер”. Нәкь менә мәшһүр мәгърифәтчебез хезмәтләренә таянып Р.З. Хәйдарова дәреслеге буенча һәр дәресебезне корырга тырышабыз.

Бүгенге көндә без рус балалары белән эшлибез. Рус мәктәпләренең татар теле һәм әдәбияты программасында Р.Фәхреддин иҗатын өйрәнүгә сәгатьләр каралмаган. Шулай булуга карамастан, аның үгет –вәгазьләрен өйрәнүне әдәби уку дәресләрендә тәрбияви текстлар белән бергә алып барам. Сөйләм, киенү, өстәл янында, кунак , туганннарга, дусларга карата әдәплелек кагыйдәләрен

тыңлап кына калмыйлар, ә бәлки үзләре дә бер- берсенең кимчелекле якларын күрсәтеп, шул кимчелекләрне төзәтү өстендә эшләргә тырышалар.

8 сыйныфта “Өлгерәм әле...” өзеген, Р.Вәлиеваның “Барый телевизор карый” шигырен укыгач, белем алырга теләмәгән , ялкау балаларга үзебезнең киңәшләрне бирәбез. Шулай ук мәктәптә, дәрестә үз –үзеңне яхшы тоту өчен мәктәп әдәпләрен белү кирәк. “Мәктәп әдәпләре” хезмәтендә шундый нәсыйхәтләр бар: “мәктәпкә баргач әдәпле генә үз урыныгызга утырыгыз, дәрес вакытында сөйләшмәгез, гыйлем өйрәнү өчен ихлас тырышыгыз, әдәп өйрәнегез, күркәм холыклы булуны олы бәхет дип белегез. Китап, кәгазь һәм башка язу әсбапларыгызны чиста тотыгыз, каләмегезне киемегезгә сөртмәгез”. Әлеге нәсыйхәтләрне 8 сыйныфта “Пирамида” текстын, 5 сыйныфта “Дәрестә” шигырен өйрәнгәндә кулланабыз. Әлеге нәсыйхәтләргә нигезләнеп геройларга киңәшләр бирәбез.

Бүгенге көндә укучыларда күрергә теләгән мөһим сыйфатларның берсе –әдәп, гүзәл әһлак, һәм хая, ягъни оялу, начар эшләрдән саклану, тартыну дигән сүз.

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак безнең бурычыбыз, программада каралган әсәрләрне аңлап үзләштерүдән, аның идея- эчтәлеген аңлатудан, укучыда эчке матурлыкка омтылу кебек күркәм сыйфатлар тәрбияләүдән, әйләнә - тирә мөхиткә, төрле вакыйгаларга дөрес бәя бирү, мөстәкыйльлеккә өйрәтүдән гыйбарәт. Укытучы буларак, үз халкымның мәдәниятен, гореф- гадәтләрен, иң күркәм йолаларын, халкыбызның тарихын хөрмәт итәргә өйрәтү, балаларда тәрбиялелек, тугрылык, намуслылык һәм башка шундый әхлакый сыйфатлар тәрбияләү.

Эшебезнең нәтиҗәсен без шунда күрәбез: татар теле дәресләрендә әхлак тәрбиясенә аеруча зур игътибар бирелергә тиеш. Туган телне яхшы белү, аны ярату, аны хөрмәтләү – әхлаклылыкның бер өлеше.

Кулланылган әдәбият исемлеге:

1. Фәхреддин Р.Р. Балаларга үгет- нәсыйхәт/Р.Р. Фәхреддин - Казан: “Дом печати” нәшр., 2001.- 192 б.

2. Фәхреддин Р.Р. Җәвамигуль- кәлим шәрехе/ Р.Р. Фәхреддин .- Казан: “Рухият” нәшр., 2005.- 352 б.

3. Хәйдәрова Р.З. Татар теле: Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәкт. 5 нче сыйныф өчен д-лек(рус телендә сөйләшүче балалар өчен)/Р.З. Хәйдәрова, Л.Д.Белоусова, Э.Н. Хәбибуллина.- Тулылындырылган өченче басма.- Казан: Мәгариф, 2006.- 192 б.

4. Хәйдәрова Р.З. Татар теле: Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәкт. 8 нче сыйныф өчен д-лек(рус телендә сөйләшүче балалар өчен)/ Р.З. Хәйдәрова, Р.Л. Малафеева.- Казан: Мәгариф, 2008.- 207 б.

## Уку дәресләрендә табигать һәм аны саклау, әхлак темасы

***Ханова Айсылу Илгиз кызы - Минзәлә шәһәре***
***“2 нче урта гомуми белем мәктәбе” муниципаль***
***бюджет гомуми белем учреждениесенең***
***беренче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

Табигать яшел хәтфәдән чигелгән мендәренә башыбызны салдырып изрәтеп йоклата, йомшак җилләре белән биттән иркәли, тәмле сулы чишмәләре белән туендыра, телең йотарлык җиләк-җимешләре белән сыйлый. Әмма бүгенге көндә планетабызда табигатьтәге экологик проблемалар катастрофа дәрәҗәсенә җитте: суларыбыз пычранды, урманнарыбыз киселде, янды, сулар һавабыз агулы матдәләр белән зарарланды. Экологик белем һәм культураның түбән булуы, планетадагы катастрофаларның нәтиҗәләрен аңламау һәм күз алдына китерә белмәү – табигатьне саклау проблемаларына җавапсыз карашның иң беренче сәбәбе. Шуңа күрә бу өлкәдә эзлекле укыту системасын булдыру, экологик белем һәм тәрбия бирү мөһим мәсьәләгә әйләнде. Экологик проблемаларны табигать фәне дәресләрендә һәм түгәрәкләрдә генә түгел, ә башка фәннәрдә дә, аерым алганда, татар теле һәм уку дәресләрендә дә өйрәнергә кирәк. Татар теле һәм әдәбияты дәреслекләре экологик темага язылган бөтен әдәбиятны колачлый алмый, әлбәттә. Ләкин ул шактый күләмдәге әсәрләр белән таныштыра, экологик темаларга мөрәҗәгать итү

алшартларын, аларның үзенчәлекләрен билгели. Моннан тыш, китаплар укырга мәҗбүр итә. Укучыларга милли, әхлаки тәрбия белән бергә, экологик белем һәм тәрбия бирүнең үрелеп баруы мөһим шарт булып кала.

Һәр сыйныфның уку программасында табигать һәм аны саклау, әхлак темасына урын бирелә.

Күзәтүләрдән шул күренә:

**2 нче сыйныфта** Рабит Батулланың “Куян белән Нуяк”, Идрис Туктарның “Җем-җем!.. Чвик!.., Гөлшат Зәйнашеваның “Тукран белән сөйләшү”, Резеда Вәлиева “Кыңгырау чәчәк”, Кәрим Әмири “”Безнең авыл”, Гасыйм Лотфи “Сыерчык”, “Урманда әдәплелек дәресләре”, Гайсә Хөсәенов “Агач” хикәяләре һәм шигырьләре урын алган.

**3 нче сыйныфта** Габделхәй Сабитовның “...кара урман”, Ләис Зөлкарнәйнең “Бичуралар һәм бичаралар”, **4 нче сыйныфта** Мәхмүт Галәү “Кырмыскалар”, Роза Хафизова “Күгәрчен һәм малай” әсәрләре өйрәнелә. Бу әсәрләрдә экологик проблема белән бергә мәрхәмәтлелек, игелеклелек проблемалары күтәрелә.

Мәсәлән, Идрис Туктарның “Җем-җем!.. Чвик!.. хикәясендә кошларга сак караш тәрбияләү мәсьәләсе күтәрелә. Кыш көннәрендә аларны ашатырга, җимлекләр куярга кирәк. Ә балаларга түбәндәге сорау тәкъдим ителә: “Син кошларга ярдәм итәсеңме?” Сорауга җавап әзерләү алдыннан дәреслектә бирелгән рәсем өстендә эшләү отышлы булыр.

Бу сыйныфта кошлар, аларга ярдәм темасына бик күп шигырьләр, хикәяләр тәкъдим ителә. Димәк, уытучы һәр дәрестә мәрхәмәтле, игелекле булу, кошларны ярату кебек тәрбияви моментларга туктала.

“Урманда әдәплелек дәресләре” тексты ***“урманны тыңлый белергә, аңа карата мәрхәмәтле булырга кирәк”*** җөмләсе белән бетә.

Укытучы укучыларга түбәндәге сорауларны тәкъдим итә:

- Бу юлларны сез ничек аңлыйсыз?

- “Урманны тыңлый белергә” юллары нәрсәне аңлата?

- Без тагын кемне яки нәрсәне тыңлыйбыз? (Әнине, укытучыны, йөрәкне, күңелне һ.б.)

Бу текстны өйрәнү дәресен укытучы Клара Булатова шигыре белән тәмамлый ала.

Урманнарга, улым, мылтыксыз бар,
Үзең белән алма шырпы да.
Пычаксыз бар, балта, пычкысыз бар –
Урманнарны салма куркуга!

3 нче сыйныфта якташ язучыбыз Габделхәй Сабитовның “...кара урман” дип башланган хикәясе бирелә. Өзектә табигатьнең матурлыгы, байлыгы кеше кулында идеясе үткәрелә.

Ә хәзер өзекне өйрәнүнең кайбер алымнарына тукталыйк.

Кешелек яшәешен урманнан башка күз алдына китерү дә мөмкин түгел. Урман - ул барлык тереклекнең яшәү чыганагы. Урман - безнең байлыгыбыз. Без аны сакларга тиешбез.

Хәзер безнең республикабызның 16,8%ын урманнар алып тора. Ә безнең районыбызның 26600 га мәйданында урманнар өстенлек итә.

Аннан соң укучылар Ришат Төхфәтуллин башкаруында “Керим әле урманнарга” җырын тыңлап китәләр.

- Димәк, бүген нәрсә турында сөйләшәчәкбез?
- Табигать, урман турында.

Шул рәвешле, бергәләп, дәрес темасын чыгаралар.

- Димәк, без бүген урман, чишмәләрне саклау турында сөйләшербез, якташ язучыбыз Габделхәй Сабитовның хикәясеннән өзек укырбыз.

Сүзлек эшенә түбәндәге сүзләр бирелә: ***шыбырдык, былбыл, бөдрә, көмеш тамчылар, төнбоеклар, тургайлы таңнарны.***

Түбән сыйныфларда ук сүзлекләр белән эшләү күнекмәләрен үстерү йөзеннән аңлатмаларны аңлатмалы сүзлектә карый алалар, рәсемнәргә күзәтү ясыйлар.

Бу очракта кошлар тавышын, чишмә челтерәвен язмадан тыңлап китү дә үзен аклаячак.

Текстны укытучы укып чыга һәм укучыларга беренчел аңлауны тикшерүгә юнәлдерелгән сораулар бирелә:

- Табигатьнең матурлыгы, байлыгы кем кулында?
- Текстта нәрсәләр сөйләшә?
- Салкын чишмә нинди теләкләр тели?

Укучылар укытучы ярдәмендә өзекне кисәкләргә бүләләр.

1 нче өлешне “Табигать матурлыгы”, 2 нче өлешне “Саф чишмәләр” дип атыйлар.

- Ә бу ике өлешне нәрсә берләштерә? Шул юлларны табып укыгыз.
- Чишмәләрне саф килеш...

Ак каеннарны ак килеш...

Гөлләрне – чәчәкләрне пакь килеш...

Сандугачлы кичләрне, тургайлы таңнарны имин килеш сакла...

- Табигатьнең матурлыгы кем кулында?
- Кешенең сәламәтлеге, бәхетле, тыныч, мул яшәве нәрсәгә бәйле?
- Урманны нигә сакларга кирәк?
- “Агач утырткан ага булган” мәкален ничек аңлыйсыз?

Шул рәвешле, өзекне укып анализлагач, укучылар урман темасына “Синквейн” язалар:

**Исем (тема)**

**2 сыйфат (теманы тасвирлау)**

**3 фигыль (темадагы хәрәкәтләр)**

**Темага мөнәсәбәт (сүзтезмә)**

**Нәтиҗә, хисләр**

**Мәсәлән:**

**Урман**

**Бай, яшел**

**Җырлый, ашата, шатландыра**

**Урманда ял итәргә яратам**

**Урман - зур байлык**

-Укучылар, сөйләгәннәрдән чыгып, без урман турында нәрсә әйтә алабыз? Урман безнең байлыгыбыз микән?

-Урманны ничек сакларга соң?

- Яндырмаска, агачларны сындырмаска, хайваннарны, кошларны рәнҗетмәскә.

Халык: “ Бер агачтан унау үскән, ун агачтан урман үскән,” – дип юкка әйтми.

Әйе, кеше үз гомерендә бер генә төп булса да агач утыртырга тиеш. Кайберәүләр урманны урманчы сакларга тиеш дип уйлап ялгышалар. Без дә үзебездән өлеш кертергә, аларга булышырга тиеш. Киләчәктә, бәлки, сез үзегез дә урманчы булып китәрсез.

Түбән сыйныфларда шул рәвешле әсәрләрне өйрәнү укучыларга әхлак һәм экологик тәрбия бирүдә әһәмиятле чара булып тора. Ә җәмгыятебезнең киләчәге әхлаклы, тәрбияле булып үскән буын кулында.

Кулланылган әдәбият:


1. Заһидуллина Д.Ф. Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2000.
2. Низамов А.М. Милли мәктәп тәрбия нигезләре.- Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2005.
3. Сәхипова Р.Ә. Халык педагогикасы нигезендә укыту һәм тәрбия бирү. –Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2005.
4. Җәләлиев Ш.Ш. Татар халык педагогикасы. –Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2000.


## Г. Исхакыйның “Кәҗүл читек” хикәясендә тәрбия мәсьәләсенең бирелеше


*Ханова Нурания Вәзир кызы, Сарман гимназиясенең югары квалификацион*

***категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

Тәрбия – җәмгыятьтә кабул ителгән яшәү кагыйдәләре җыелмасы. Җәмгыять тарихында тәрбия эшенә битараф кеше булмаган һәм дә була алмый. Ул – кешелек җәмгыяте белән яшьтәш. Язу барлыкка килгәнче ук татар халкында тәрбия тәҗрибәсе туплана башлый, әхлак тәртипләре, рухи-мәдәни хәзинәләр барлыкка килә. “Әхлак тәрбиясе балада гуманлылык, намуслылык, гаделлек, хезмәт ярату, тәртиплелек, җаваплылык, тыйнаклык кебек сыйфатлар формалаштыра; ныклы характер, ихтыяр көче, бурычны аңлау кебек кыйммәтләрне үстерә”, - ди К. Д. Ушинский. Тәрбия өчен уңай шартлар тудыру – ата-ана бурычы, бала гаиләдә тәрбияләнә. “Оясында ни күрсә, очканында шул булыр” дигән халкыбыз. Әхлак тәрбиясе халык педагогикасында төп урынны алып тора, әдәбият фәне дә бу юнәлештә үтемле чараларның берсе. Әдәбият дәресләрендә укучының әхлагын формалаштыруга әһәмият бирелә. Яшь үзенчәлегеннән чыгып, әдәби әсәрләр укучыга йогынты ясый, үзтәрбиягә омтылыш бирә. Әдәбият программасына кертелгән һәр әсәр әхлак формалаштыру, тормышка әзерләү өчен хезмәт итә. Моның ачык мисалын без Г. Исхакыйның “ Кәҗүл читек” хикәясендә күрәбез.

Гаилә – әни-әти, балалар һәм якын туганнардан торган кешеләр төркеме. Милли хис нәкъ менә гаиләдә формалаша. Әхлак һәм милли хис тәрбияләү кечкенә яшьтән үк башлана. Балалар – безнең киләчәгебез, бәхетебез. Шуңа күрә бала тәрбиясе һәрчак актуаль мәсьәләләрнең берсе булып кала.

“Кәҗүл читек” хикәясенең төп герое – Әхмәдулла, ул кечкенә малай. Әхмәдулла – ир-ат исеме, Алланың мактаулы, данлы кешесе.

Хикәя аның әтисен көтү шатлыгы белән башланып китә. Малай әтисе Казаннан алып кайтырга тиешле саплы калач һәм кәҗүл читек, прәннек белән мактана. Кәҗүл читекне бик җентекләп тасвирлый. Бу читек искиткеч матур булырга тиеш. Матур читек турында хыялы – аның теләге, өмете.

Әхмәдулланың әле чапаны, кәвешләре, чалмасы да булачак. Бу киемнәрне киеп, ул мөселман дөньясында билгеле булган иң күркәм бәйрәмнәрнең берсе – Корбан гаетенә барырга әзерләнә.

Икенче көнне малай гаеткә барырга әзерләнә. Ул өлкәннәрдән күргән гамәлләрне башкара. Чапан киеп, чалма урап, кәҗүл читек өстеннән әбисенең яшел башмагын киеп, хушбуй сөртеп гаеткә бара. Мулла абыйсы артыннан түргә уза, авыл малайлары янында калмый, чөнки ул – мулла малае. Ул үзенең мулла нәселеннән булуы белән горурлана, һәм башка малайлардан өстенрәк дип уйлый. Әмма малайлар аннан көлә башлыйлар, чөнки читеге – әнисенеке, чапаны – әтисенеке, башмагы – әбисенеке. Көлкегә калган малай сер бирергә теләми. Үзеннән көнләшәләр дип тынычлана. Чапаны да корымга буялган була, ул инде тагын көлкегә кала. Үрти-үрти өенә кадәр озаталар. Чапаны буялган, чалмасы сүтелгән, кәвешенең берсе аягыннан төшкән, читегенең төсе беткән хәлдә ул өенә кайтып керә. Әбисенең “Бәйрәм мөбарәк булсын” дигән сүзенә ул елап та җибәрә. Шатлык хисе белән янган малай бәхетсезгә әверелә. Бәйрәм малай өчен уңышсыз тәмамлана. Автор үзенең героен бәхетсез итә. Ни өчен малай бәхетсез?

Кем гаепле? Әлбәттә, үзе гаепле. Ул хисенә буйсынып яши. Хикәянең ахырында да ул шундый булып кала. Малайларга усаллык белән җавап бирә. Берсенең кулын тешли, икенчесе үрти, өченчесен куып китә. Шулай да авыл малайларының гаебе зуррак. Үзләреннән өстен булганга, Әхмәдулланы яклаучы бер генә малай да булмый.

Әхмәдулланың иркә булып үсүендә туганнары да гаепле. Алар аның бөтен теләкләрен үтиләр, малайны ялганлыйлар. Үзенең хурлыкка калуында аларның өлеше дә булуын аңлый.

Хикәя нәрсә турында соң? Әхмәдулла турында, аның холкы, өмете һәм өзелгән өмете турында дип әйтә алабыз. Заманының зыялы гаиләсендә тәрбияләнгән малайның киләчәге өметле.

Автор безне кечкенә малайның кичерешләре белән таныштыра.

Үл үз хисләре турында сөйли. Хиснең сәбәпләре дә төрле. Шатлыкның сәбәбе – алып кайтыласы читек, өмет булса, кәефсезләнүенең сәбәбе – читекнең дәү булуында. Хис туктаусыз алмашынып тора. Аның төрлечә бирелеше малайның хыял көче белән билгеләнә. Шатлык – хыялдагы читеккә соклану – түземсезлек – мактану – үпкәләү – сөенеч – кызыксыну – мактану – кызгану – борчылу – үпкәләү – тынычлану – масаю – гаҗәпләнү – һавалану – хурлану – күңеле тулу.

Г. Исхакый дингә каршы кешеләрдән булмаган, киресенчә халыкның язмышы дин әһеләре белән бәйле булуны аңлаган. Шуңадыр, аның герое үзенең чыбыркысы белән мактана. Чыбыркы – идарә итү, властьны белдерә. Хикәядә бала тәрбияләүнең шактый катлаулы күренеш булуы сурәтләнә. Әхмәдулла үз ялгышлары, хис-кичерешләре аша дөреслекне аңлаячак.

Гаилә – тәрбия учагы.

“ Кәҗүл читек” хикәсе аша бала үзенә күпме тәҗрибә туплый ала. Төрле үтемле чаралар аша әдип укучысының күңел дөньясына тәэсир итеп кенә калмый, аны уйландыра, кисәтә. Бәхетсезлек аша бәхетле булу юлларын эзләргә этәргеч ясый.

Әдәбият


1. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007.
2. Татар исемнәре сүзлеге. Казан, Татарстан китап нәшрияты
3. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 т. Т.
4. Яхин. А. Г. Әдәбият. 9 нчы сыйныф өчен дәреслек.- Казан: Мәгариф, 2007.


## Газиз, туган телем!


***Хасаншин Ирек Фаям улы***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы***
***ДАҺБУ “Түбән Кама шәһәре***

Ватан-ана бер дәрәҗәдә торучы төшенчәләр. Татар халкы үз туган телен ана теле дип атый. Чөнки баланың теле «әни» дип ачыла, телнең байлыгын ул беренче мәртәбә әнисе, туганнары аша үзләштерә башлый. Халык балага тел өйрәтүнең әһәмиятен электән үк аңлаган. Моны без балалар фольклорында күрәбез. Бишек җырлары, иркәләү сүзләре, такмак-такмазалар, әкиятләр аша туган теленең аһәңе, образлы тәэсирлелеге кечкенәдән үк баланың канына сеңә, аның геннары аша килгән информацияне ныгыта, ата-бабаларыннан килгән рухи көчен, матурлыгын арттыра, сәләтен, аң дәрәҗәсен үстерә. Шулай итеп, кешенең туган теле халкының тарихи традицияләре, горенф-гадәтләре, дин-иманы белән тоташтырып торучы җеп ролен үти. Билгеле булганча, бүгенге көндә татар балаларының теле туган телдә, ана телендә ачылмаган очраклар бик күп. Ләкин шуны истән чыгарырга ярамый: туган телендә, ягъни гасырлар буе ата-баба геннары аша күчкән телдә, ачылган баланың аң дәрәҗәсе теле чит телдә, ягъни ата-бабалары сөйләшмәгән телдә, ачылган баланың аң дәрәҗәсенә караганда югарырак булуы галимнәр тарафыннан исбатланган.

Теле туган теле белән ачылмаса да, аны өйрәнү аша кеше үзенең борынгы бабалары рухы белән тоташа, интеллектуаль һәм рухи яктан үсә, байый. Чөнки "телдә халыкның милли психологиясе, характеры, фикерләү һәм иҗат үзенчәлекләре ачыла, тарихы һәм мәдәнияте чагылыш таба. Туган телне яхшы белү, саклау һәм үстерү-ул телдә иҗат ителгән әдәбиятны, сәнгатьне үзләштерү, үстерү, халыкның рухи хәзинәләрен, мәдәниятен, тарихын, авыз иҗатын киләчәк буыннар өчен саклап калу дигән сүз".

Тел яшәсен өчен, бу телдә сөйләшүче халык кирәк. Халык та үз теле белән генә тулы мәгънәсендә халык дип кабул ителә. Халыкның дәүләтчелеге була икән, телнең кулланылыш даирәсе дә киңәя, үсә, байый. Алар үзара тыгыз бәйләнештә. Шулай булганда гына аларның һәркайсы тулы кыйммәтле яшәешкә ия.

Дөньяда иң киң таралган алты тел (инглиз, француз, рус, испан, гарәп, кытай телләре) БМОның (ООН) рәсми телләре булып торалар. Кызганыч какаршы, төрле сәбәпләр аркасында кайбер телләрдә аралашучылар бетә, һәм бу телләр үле телгә әйләнә. Андыйлардан шумер, скиф, латин һәм башка телләрне атап була. Җир йөзендәге күп телләр арасында татар теленеңдә үз урыны бар. Бу телдә сөйләшүчеләр санына карап (җиде миллионнан артык), татар теле дөнья телләренең алгы төркеменә керә. Сөйләшүчеләр саны миллионнар белән исәпләнүче 2400 тел татар теленнән артта урнашкан. Белгәнебезчә, татар теле төрки телләр гаиләсенә керә. Күп кенә галимнәр "болгар-татар тамырларының шумер-скиф чорларында ук җәеле пүсүен" күрсәтә.

Төрки халыкларның элгәрләре туран һәм һуннарда инде безнең эрага кадәр үк язу булу-аларның борынгылыгын исбатлый торган дәлил. Төрки-татар теле күпгасырлар буе үсү, шомару, баю юлы үткән. XII гасырда Кол Гали тарафыннан язылган «Кыйссаи Йосыф» әсәре борынгы татар әдәби телендә язылган дип санала. Аның поэтик яктан югары дәрәҗәдә эшләнеше, теленең байлыгы, әлбәттә, авторының талантлы булуы турында сөйли. Шуның белән бергә, сәнгатьчә югары дәрәҗәдәге мондый әсәрне шундый ук югары үсешкә ирешкән тел ярдәмендә генә тудырып була. Татар теленең байлыгын раслаучы әсәрләрне мисалга татар әдәбияты тарихыннан күпләп китерергә мөмкин. Борынгы төрки китаплар арасында фәннең төрле өлкәләренә караган хезмәтләр табылу,төрки телнең кулланылыш даирәсе шактый киң булганын күрсәтә. Җирнең теләсә кайсы җиренә барып чыгып, андагы халыклар белән аралашу өчен, галимнәр 14 тел белү җитә дигән фикергә килгәннәр. Шул 14 тел арасында татар теле дә бар. Төрки телләр гаиләсеннән татар теленең сайлануы үзе үк күпнәрсә турында сөйли.

Без үзебезнең көндәлек тормышыбызны телдән башка күз алдына китерә алмыйбыз. Сөйләм вакатында без күп сүзләр арасыннаң теге яки бу фикерне әйтү өчен кирәклесен генә сайларга тырышабыз. Укымышлы, зыялы

кешенең сөйләме дөрес, ачык, төгәл һәм матур булырга тиеш. Бары шундый сөйләм генә тыңлаучыга аңлаешлы, үтемле, матур яңгырый.

Сөйләмне дөрес, төгәл анык итү өчен кешенең фикер йөртүе эзлекле, нигезле, ышандыргыч булырга, әдәби тел нормаларыннан читкә китмәскә, стиленә карап, сүзләр фразеологик әйтелмәләр, сүз формалары, сүзтезмәләр, җөмлә төрләре уңышлы сайланырга тиеш.

Телнең чисталыгы өчен көрәш үзе бер мөһим проблема «Телне бозмыйча дөрес итеп фикереңне җиткереп сөйләшү ул-кешенең әдәп, культура билгесе”-дип язган Хәсән Сарьян. Кызганычка каршы, соңгы елларда социаль-сәяси, икътисади, мәдәни процессларның тәэсире шулай ук сөйләм әдәбен “яңача” күзаллаучылар, рус теленнән, турыдан-туры калькалаштыру нәтиҗәсендә колакка ятышсыз сүзләр, сүзтезмәләр җөмләләр барлыкка килә.

Көндәлек тормышта очрый торган мондый калькалар сөйләмне бозалар, мәзәк яңгырыйлар: “Сез дөрес түгел тукталышта төшкәнсез. Рәхмәтлек түгел”

Татар һәм рус телләрендә җөмләдәге сүзләр бәйләнеше төрлечә, рус телендә ия, хәбәр янәшә урнаша. Татар телендә җөмлә җыйнак булмаса ия, хәбәр бер-берсеннәң ерак урнашалар, хәбәр җөмлә азагында килә.Мәсәлән: Я иду в колледж.Мин көллияткә барам.

Һөнәри уку йорталында программага кертелгән “Сөйләм культурасы” фәненә игътибар тиешле дәрәҗәдә куелса, мондый хаталар аз булыр иде. Функциональ грамоталы шәхес югары дәрәҗәдә кешеләр белән аралашу чаралары-әйтмә һәм язма сөйләмгә, компетенцияләр җыелмасына ия булырга тиеш.

Матур сүзләргә бик бай бит безнең телебез. Шуларны кирәкле урынында, төгәллек белән кулланасы иде.

Әдәбият:

1. Галимуллин Ф. “Дөрес ачык һәм төгәл”. Мәгариф 1998 №8 (бит 48-49)

2. Сафиуллина Ф. С. “Хәзерге татар әдәби теле”. Казан Мәгариф 2002.

**Рус гимназиясе шартларында әхлак тәрбиясе бирү тәҗрибәсеннән**

*Хафизова Илһамия Мулланур кызы, Түбән Кама шәһәре*
*32нче гимназиянең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Әхлак – борынгы заманнарда ук иң мөһим мәсьәләләрнең берсе булган. Җәмгыятебез төрле яктан череп таркалган бу көннәрдә, әхлак тәрбиясенең әһәмияте гаять зур.

Әхлак тәрбиясе – тәрбия эшләре системасының үзәге, шул ук вакытта, иң дөрес һәм иң мөһим юнәлеше дә. Моны беркем дә инкарь итә алмас. Ә бу тәрбияне бирү безнең изге бурычларыбызның берсе.

Мин Түбән Кама шәһәренең рус гимназиясендә эшлим. Рус мохитендә тәрбияләнүчеләр арасында татар әхлагын саклап калу, әлбәттә, җиңел түгел. Тик гимназиябез җитәкчелегенең безгә булган уңай карашы күңелне сөендерә, яңа эшләргә рухландыра.

Минем методик темам: “Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә укучыларга әхлак тәрбиясе бирү”. Әлбәттә, бу эш дәресләрдә генә чикләнеп калынмый, ә сыйныфтан тыш чараларда да дәвам иттерелә. Иң мөһиме: балалар күңеленә әхлак орлыкларын, соңармыйча, вакытында салып калдыру. Әнә бит, хөрмәтле мәгърифәтчебез, остазыбыз Ризаэддин Фәхреддин дә “Укытучының дәрес бирүдән тыш тагын бер бик мөһим вазифасы бар, ул да булса – вакытын һәм урынын туры китереп һәрвакытта динлелекнең һәм әхлакның күркәмлекләре хакында сүз сөйләү,” ди.

Белгәнебезчә, әдәбият – әдәп һәм тәрбия дәресе. Монда һәр әсәр тәрбияле булырга чакыра. Хәтта әхлаксыз геройлар да безне үзләре кебек булмаска өнди, гыйбрәт алырга куша. Безнең бурыч: һәр әсәрне тиешенчә анализлап, аның тәрбияви әһәмиятен табып, укучыларны иҗади фикер йөртергә өйрәтү һәм фикерләрен курыкмыйча, төгәл, ачык итеп әйтергә мөмкинлек тудыру; игелеклелек, миһербанлылык һәм кешелеклелек кебек күркәм сыйфатлар тәрбияләү. Шушы максатларга ирешү өчен, Ризаэддин Фәхреддиннең “Балаларга үгет-нәсыйхәт” һәм “Тәрбияле бала”, Әнвәр

Хуҗиәхмәтовның “Тәрбия – мәңгелек фәлсәфә” һәм “Тәрбия дәресләре”, Вил Казыйхановның “Әхлак дәресләре” дигән хезмәтләренә мөрәҗәгать итәм. Бу китаплар – минем карусыз якын дусларым. Мин аларда үземне борчыган бик күп сорауларга җавап табам, укучыларга җиткерәсе фикерләрем дә ышанычлы, дәлилле була.

Бәйләнешле сөйләм үстерү дәресләрендә укучыларга темага ярашлы берәр кызыклы һәм гыйбрәтле хикәя тәкъдим итәм. Күп очракта ул хикәяләрне үзем язам һәм бәхәсле сораулар тудырам. Күп очракта уртак фикергә киләбез, кайвакыт төрле каршылыклар да туа. Ул шулай булырга тиеш тә, чөнки укучы үз фикерен белдерә. Мондый дәресләр укучыларны иҗади фикерләргә генә өйрәтеп калмый, ә мөстәкыйль тормышка әзерли.

Мәсәлән, 6 нчы сыйныфта Ибраһим Газиның “Йолдызлы малай” хикәясен тәмамлаганнан соң, түбәндәге хикәямне тәкъдим иттем: “Гайҗан бабайның уң аягын дошман пулясы бик нык яралый. Менә ярты гасырдан артык инде ул таякка таянып йөререгә мәҗбүр.

Соңгы елларда диннең көчәеп китүе аның өчен бик зур куаныч булды. Намаз укырга өйрәнде, бөтен күңелен дингә багышлады. Йөрүе бик кыен булса да, җомга намазын мәчеткә барып укырга гадәтләнде.

Менә бүген дә җомга намазына дип ниятләп чыгып китте ул. Ләкин кинәт кенә суытып җибәрү, юлны көзгедәй ялтыратып куйган икән. Таякка таянган аксак карт өчен генә түгел, хәтта ике аягы сау булган кешеләр өчен дә юл искиткеч хәтәрләнгән.

Тукталышка җитеп, автобуска җитештем дип сөенгән бабайның борыны төбендә генә шапылдап ишекләр ябылды...

Икенче автобус шактый озаклады. Кеше дә хәйран җыйналды. Берсен-берсе этә-төртә халык эчкә ыргылды. Гайҗан бабай да агымга иярде. Бабайны күрүгә, утыргычтагыларның күбесе күзләрен тәрәзәгә төбәде, янәсе, бабайны күрмиләр.

– Акчаларыгызны әзерләгез, – дигән тавышы ишетелде кондукторның. Ни кызганыч, бабай акчасын онытып калдырган иде.

Бабай, белеп торасың бит автобусның түләүле икәнен. Акчаң булмагач, өйдә генә утырырга иде!

Кондукторның бу сүзләре җанын телеп үтте бабайның. Тик бер сүз дә дәшмәде. Мәчет тукталышында төшеп калды ул. Каршысына хәер сорашып килгән кап-кара чәчле баланың башыннан сыйпады һәм алдан ук әзерләп куйган хәер акчасын бирде. “И Раббым, бәндәләреңә шәфкать һәм миһербан бир,” – дип пышылдый иде аның иреннәре. Ә үзенең күңелендә мең төрле уй, меңәрләгән сорау...”

– Укучылар, ни турында уйланды икән Гайҗан бабай? Нинди сораулар битәрләде икән аның йөрәген?

(“сугышны искә төшерде”, “кондукторның дорфалыгын уйлап борчылды”, “кешеләргә  хәтере калды”кебек җаваплар ишетелә).

– Димәк, укучылар,  нәтиҗә чыгарып, без нәрсә әйтә алабыз? (Җаваплартыңлана).

–  Әйе, әхлаклы, әдәпле булырга кирәк икән. Ә шундый сыйфатларга безне динебез өйрәтә. Аллаһны бар дип белгән кеше бервакытта да начарлык эшләми, башкаларэшләгәндә дә битараф булып кала алмый.

Әнә шул рәвешле, үзеннән-үзе әхлак тәрбиясе дин тәрбиясе белән үреле пкитә. Бу аңлашыла да, чөнки  дин ул – әдәпнең, әхлакның нигезе.

Чыгышымны мәшһүр мәгъритфәтчебез Р. Фәхреддиннең сүзләре белән тәмамлыйсым килә: “Киләчәк буын яшьләребез өчен авыру килеш көн-төн сәгатьләр үткәреп язып утырдым, өметләнәм: хезмәтем сынык күңелләргә шифа һәм якты нур булыр”.

Ә безнең җавап сүзебез бер: тыныч йокла!.. Үз милләтен яратып, аның әхлагын сезнең үрнәктә дәвам  иттерүчеләр, шөкер, бар әле.

Әдәбият


1. Фәхреддин Р. Җәвамигуль-кәлим шәрхе.-Казан: “Иман” нәшрияты, 1995.-439 б.
2. Насыйри К. "Китаб-әт-тәрбия". –  Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1992. – 144 бит.

# Башлангыч сыйныфларда әдәби уку дәресләрендә экологик һәм әхлакый тәрбия

*Хафизова Рузилә Рәшитовна,*
*Башлангыч сыйныфлар укытучысы,*
*ТР Мөслим муниципаль районы*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*“Мари Бүләр төп гомуми белем бирү мәктәбе”*
*филиалы – Исәнсеф-Чишмә башлангыч мәктәбе*

Мәктәп һәм экологик культура – бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә булган төшенчәләр. Педогоглар алдында укучыларга экологик белем бирү: укучыларның дөньяга караш даирәләрен киңәйтү, аларны табигатьне сакларга, аңа мәрхәмәтле, игътибарлы булырга өйрәтү, туган җиребезне ярату, аның белән горурлана белү хисе тәрбияләү - иң төп максатларның берсе. Аларны тормышка ашыру өчен, нәтиҗәле алымнар һәм ышандырырлык фактлар кулланып, эзлекле эш алып барырга кирәк.

Балаларда табигатькә сакчыл караш тәрбияләү катлаулы һәм дәвамлы педагогик процесс. Экология, фән буларак, мәктәпнең укыту программасына кертелмәгән. Шуңа күрә экологик проблемаларны әйләнә-тирә дәресләрендә һәм түгәрәкләрдә генә түгел, ә башка фәннәрдә дә, аерым алганда әдәби уку дәресләрендә дә һәм башлангыч сыйныфлардан ук өйрәтә башларга кирәк. Чөнки әдәби уку дәреслекләрендәге шактый әсәрләрдә экологик темаларга мөрәҗәгать ителә. Әсәр белән танышкач, укучы үзен табигатьнең бер кисәге итеп тоя. Әлеге процесс укучыларга милли, әхлаки тәрбия белән бергә, экологик белем һәм тәрбия бирүнең үрелеп баруы мөһим шарт булып кала.

Һәр башлангыч сыйныф әдәби уку дәреслегендә халык авыз иҗатының нинди дә булса бер жанрына урын бирелә. Халык авыз иҗатында табигать һәм аны саклау – иң борынгы һәм киң урын алган темаларның берсе. Ул фольклорның барлык төр жанрларында диярлек бар. Халыкның тормыш тәҗрибәсе һәм табигатьне өйрәнү нәтиҗәсендә туган кыска, ләкин тирән мәгънәле өйрәтүләре, тәрбия алымнары бик гыйбрәтле. Әлеге өйрәтүләр татар халкының мәкаль һәм әйтемнәрендә аеруча күп тупланган һәм тирән мәгънәгә

ия булган өйрәтү-киңәшләр формасын алган: “Хайваннарны җәберләгән рәхәт күрмәс”, “Яралы кошка таш атмыйлар”, “Кош йомыркаларын ватма, күз яшең түгәрсең”, “Яшь агачны сындырма, яшь гомерең өзелер”. Балаларда зирәклек, күзәтүчәнлек кебек сыйфатлар тәрбияләүче табигать күренешләренә багышланган табышмаклар: “Төнлә баксам – күк тулган, иртән баксам – юк булган”, “Язын ямь бирә, җәй салкын бирә, көзен тәм бирә, кышын тун бирә” һ.б.; сынамышлар: “Кар барында күк күкрәсә, ашлык булмас”, “Җилгә каршы яуган яңгыр каты давыллы булыр” һ.б.; шәфкатьлелек, миһербанлык, игътибарлылык кебек хисләр һәм Туган ягыңа мәхәббәт тәрбияләүче әкиятләр, мәзәкләр, мәсәлләр дә шактый: “Умарта корты һәм чебеннәр”һ.б.

Әдәби уку дәреслекләрендә урын алган күп кенә шагыйрьләребез әсәрләре дә экологик тема читтә калмый. Шигърияттә бу темага урын бирмәгән шагыйрьне табуы кыендыр. Табигать темасына язылган шигырьләр исемлеге бай һәм төрле. Әлеге әсәрләр балаларны табигатьне аңларга, яратырга, аның байлыкларына сакчыл караш формалаштырырга, туган җирнең кадерен белергә өйрәтә. Шулай да мәктәп дәреслекләрендә зур урын бирелгән кайбер шәхесләребезне аерым әйтеп китү кирәктер: Ш.Галиев, Р.Вәлиева, Г.Рәхим һәм башкалар шигырьләрендә җәнлекләрне, кошларны, бөҗәкләрне яратырга, аларга мәрхәмәтле, шәфкатьле булырга өндиләр, кешелекнең экологик һәлакәтне җиңә алуын исбат итәләр.

Дәреслекләрдә язучыларыбызның да экологик темага багышланган әсәрләре зур урын били. Бу темага багышланган әсәрләрдә кеше, аның рухи дөньясы үзәктә тора: Нурия Сәйәрнең “Айсылу”, Г.Рәхимнең “Песнәк”, “Апрель”, Ш.Маннапов “Су тәме” әсәрләре укучылар тарафыннан аеруча яратып укыла. Язучылар бу әсәрләрендә табигый байлыкларга сакчыл булырга, аның кадерен белергә, өлкәннәрне хөрмәт итәргә чакыралар, кеше рухи азыкны табигать белән берлектә яшәгәндә генә ала дигән фикер әйтеләләр.

Туган туфракка сабый чакта җибәргән тамырлар гына кешене ватанлы итә, хәерле итә, бәхетле итә. Табигать баласы икәнлегеңне тою нәкъ шул чорда башлана һәм куе урманнардан, киң кырлардан, яшел болыннардан, тирән

сулардан килүче кадерле кунак икәнлегең күңелгә мәңгегә берегеп кала. Язучыларыбызның, шагыйрьләребезнең тирән эчтәлекле әсәрләре аша шушы хис-тойгыларны балаларның күңеленә җиткерү, сеңдерү – укытучының изге бурычы.

Кулланылган әдәбият:

1.Заһидуллина Д.Ф. Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2000.

2.Низамов А.М. Милли мәктәп тәрбия нигезләре.- Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2005.

3.Сәхипова Р.Ә. Халык педагогикасы нигезендә укыту һәм тәрбия бирү. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2005.

4.Җәләлиев Ш.Ш. Татар халык педагогикасы. –Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2000.

5.

## Татар әдәбияты дәресләрендә фазыл туйкин эшчәнлеген һәм иҗатын өйрәнү

***Хәйретдинова Г.М., Шәрипова Г.М. – Лениногорск***
***музыка – сәнгать педагогика көллиятенең татар теле***
***һәм әдәбияты укытучылары***

Укыту методикасында “милли - төбәк компоненты”, “регианальләштерү” кебек төшенчәләр бар. Җирле шартлардан чыгып, укыту эшчәнлегенең вариантлы өлешен тәкъдим итү мөмкинлеген тудыра ул.

Шул рәвешле, һәрбер укытучы үз фәненең уку программасына, урта һөнәри белем стандартларына туры килерлек темалар белән бергә җирле материаллар да кертә ала.

Милли-төбәк компоненты халык һәм милләт үзенчәлеген, аларның мәдәниятен һәм рухи дөньясын, телен һәм тарихын, табигый - географик мохитен, хезмәтчел традицияләрен чагылдырган укыту материалын үз эченә берләштерә.

Телне яхшы үзләштерүдән тыш, укучыларның туган әдәбиятны, сәнгатьне аңлавы өчен җитди шартларның берсе - укучыларны образлы күзалларга,

образлы фикерләргә өйрәтү. Ә моңа нигездә, туган әдәбият, милли мәдәният, милли традицияләр, гореф - гадәтләр йогынтысында ирешелә.

Шул сәбәпле, укучыларны XX гасыр татар әдәбиятында тирән эз калдырган әдипләрнең тормыш юлын, иҗатын өйрәнгәндә, әсәрләр анализлаганда, дәрестән тыш чаралар үткәргәндә, шул чорда яшәгән һәм иҗат иткән үзебезнең төбәк язучыларының эшчәнлеге белән таныштыру да зарури.

Татарстаныбызның көньяк-көнчыгышына урнашкан Лениногорск районы төбәгебезнең иҗтимагый һәм мәдәни үсешенә уңай йогынты ясаган шәхесләргә, иҗат кешеләренә гаять бай.

Бертуган Фазыл һәм Кәбир Туйкиннар, Җәмит Рәхимов, Шамил Бикчурин, Әсрар Галиев, Рәшит Шиһап, Альберт Хәсәнов, Таһир Шәмсуаров, Миңнур Ханнанова, Рәзим Вәлиуллин, Рәмзия Габделхакова - буыннан-буынга, чордан-чорга күчеп баручы, мәхәббәт һәм сөю-сәгадәт, шәхес һәм аның борчулары, гомумән, күп кенә шундый катлаулы мәсьәләләргә фәлсәфи җавап эзләүче язучылар. Алар, кешелекнең югары әхлакый идеалларын тормышка ашыру өчен көрәшүче, заманының борылышларын романтик төсмерләргә бизәп, туган як табигатен якты, нәфис моң белән сурәтли алган бөек шәхесләр.

Татар әдәбияты тарихында мәгълүм бер сәяси –иҗтимагый сәбәпләр аркасында игътибардан бераз читтә калган мәгърифәтче, педагог, публицист, тарихчы, фольклор белгече һәм язучы Әхмәткәрим улы Фазыл Туйкинның күпкырлы эшчәнлеге, кызыклы мирасы аеруча игътибарга лаек.

Тоталитар режим тарафыннан хаксызга рәнҗетелгән, ахырда, атып үтерелгән, зыялы шәхес - Фазыл Туйкин биографиясе, иҗат мирасы турындагы мәгълүматлар татар җәмәгатьчелегенә бары тик XX гасырның азагына гына билгеле була башлый [1, с. 3].

Фазыл Әхмәткәрим улы Туйкин 1887 елның 22 июнендә Татарстанның хәзерге Лениногорск районы Зәй-Каратай авылында мөәзин гаиләсендә дөньяга килә. 1904 елда "Мөхәммәдия" мәдрәсәсенең урта сыйныфын тәмамлагач, Ф. Туйкин туган авылына кайта һәм 1909 елга кадәр мөгаллимлек итә. 1909-1911

елларда Ф. Туйкин Бөгелмә өязенең Ташлы авылында, 1911-1912 елларда Уфада, аннан Бөгелмә өязенең Кара елга авылында балалар укыта. Февраль революциясеннән соң ул укытучылык эшен Бөгелмә шәһәрендә дәвам итә. Гомеренең соңгы елларына кадәр татар теле һәм әдәбиятыннан дәресләр бирә.

Ф.Туйкинның беренче шигырьләре 1906-1907 елларда Уральск шәһәрендә чыккан "Фикер " гәҗитендә басыла. 1912 елдан башлап яңа революцион күтәрелеш елларында аның иҗат эшчәнлеге аеруча актив төс ала. Шул бер ел эчендә ул Казанда "Сугышчы Сатыш әфәнде" дигән хикәя, "Ватан каһарманнары" дигән драма, "Җырлар әхтәрисе" дип аталган җыентыклар һәм Уфада "Тормыш корбаннары " исемле сәхнә әсәре бастырып чыгара.

Туйкинның совет чорында иҗат иткән драма әсәрләреннән бары тик берсе генә балалар сәхнәсендә кую өчен язылган «Салих бабай» пьесасы гына безнең көннәргә килеп җиткән. Бу әсәр тапкырлыкка, кыюлыкка өнди, хезмәт тәрбиясе бирүне күздә тота.

Ф. Туйкин — җаны-тәне белән җырга, шигърияткә, музыкага бирелгән кеше. Үзе дә моңлы тавышлы булып, скрипка, гармун һәм мандолинада уйнаган. Музыкаль яңгырашлары, аһәңле булулары ягыннан аның шигырьләре халык җырларына якын тора.

Заманында аның иҗади эшчәнлегенә классик язучыбыз Галимҗан Ибраһимов та игътибар итеп, болай дигән: “Аның кемлеген мин үзем дә белмим, ләкин әсәрләрен газета, журналларда укып яратканмыз, хәтеремдә калган” [1, с. 4].

Бүгенге көндә Ф. Туйкинның тормыш һәм иҗат юлын өйрәнү эшен башлап җибәрүчеләрдән  шагыйрә Эльмира Шарифуллина, Җәүдәт Миңнуллин һәм Эльмера Ханнанова – Галимҗановаларны атап китәргә була.

Соңгы елларда башкорт галимнәре дә Ф. Туйкиның иҗаты белән кызыксыналар, аны башкорт язучысы итеп тә саныйлар, чөнки 1911-1914 елларда татар мәдәнияте үзәге дип саналган Уфада яши. Башкортлар тормышы белән кызыксына, алар тормышын чагылдырган байтак кына әсәрләр яза.

Якташыбыз Фазыл Туйкин утыз биш ел гомерен балалар укытуга багышлаган һәм татар мәгариф системасын яхшыртуга зур өлеш керткән шәхес. Ул абыйсы Кәбир белән берлектә “Төрек тарихы” дәреслек китабы яза һәм беренчеләрдән булып, халык авыз иҗаты әсәрләрен җыя, аларны системага салып “Җырлар мәҗмугасы” җыентыгы чыгара.

Ф. Туйкин – әдәби мирасыбыз җәүһәрләрен җыйнау, барлау, аларны фәнни эшкәртү өлкәсендә дә күп көч куйган галим. Аның 17-18 нче гасырлардагы татар әдәби мирасы ядкярләрен – Мәүлә Колый хикмәтләрен, Габдерәхим Утыз Имәнинең “Мәрсияи Хәмидә зәүҗәте Габдерәхим әл-Болгари” (1797) шигырен фәнни әйләнешкә кертүе мәгълүм [2, 156].

Якташыбыз әдәбиятның барлык төрләрендә дә эшләгән. Заманында ул шагыйрь, талантлы прозаик булып танылган. Мәсәлән, “Ямьле җәй” шигыре Кытайдагы Голҗа шәһәрендә басылган, “Туган тел” китабына кертелгән.

Ф.Туйкин “Сугышчы Сатыш әфәнде” исемле хикәясе белән татар әдәбиятына беренчеләрдән булып кассицизм элементлары алып килә.

Фазыл Туйкинның әсәрләре октябрь инкыйлабына кадәр “Шура”, “Идел”, “Әл-ислах” вакытлы матбугат битләрендә урын алган, ә утызынчы еллар башлангач, иҗади эшчәнлеген яктырткан язмалар матбугат органнары тарафыннан кабул ителми, 1938 елда “халык дошманы” дип атып үтерелә. Бары 20 елдан соң гына, 1958 елда эше яңадан карала һәм гаепләнүче «1937елда гаепсезгә кулга алынып хөкем ителгән» дип карар чыгарыла [3, 17].

Бары тик җитмешенче елларда гына аның әсәрләре турында кайбер күзәтүләр матбугат битләрендә күренә башлый.

Ниһаять, туксанынычы еллар башында якташыбыз мирасы халкыбызга әйләнеп кайтты.

Татарстан Республикасының Лениногорск районы Зәй-Каратай авылында Фазыл Туйкин яшәгән нигезгә мемориаль такта куелды. Авылның урта мәктәбе һәм үзәк урамы да Ф. Туйкин исемен йөртә.

Лениногорск шәһәренең “Сугышчан дан” музеенда да Ф.Туйкинның тормыш юлы турынла шактый күп материал тупланган.

XX гасыр башы татар әдәбиятына шактый кызыклы һәм мөһим яңалыкларны гәүдәләндергән, романтик һәм реалистик эчтәлекле әсәрләр алып килгән, гомерен халыкка багышлаган һәм репрессияләнгән олы шәхес, әдип Фазыл Туйкин бенең якташыбыз булуы белән чын күңелдән горурланабыз. Аның әсәрләрен өйрәнүне, эшчәнлегенең һәм иҗатының асылын укучыларыбызга дөрес итеп җиткерүне бурычыбыз дип саныйбыз.

Файдаланылган чыганаклар һәм әдәбият

1. Ханнанова – Галимҗанова Э.М. Фазыл Туйкин: язучы, телче һәм фольклорчы. Казан, 2006.-156 б.

2. Шәрифуллина Э. Илебез-кадерле җиребез/ Э.Шәрифуллина// Казан утлары. -1977, - № 6,-Б.163-169.

3. Шәрифуллина Э., Миңнуллин Җ. Бүген дә хәрәкәттә / Э. Шәрифуллина, Җ. Миңнуллин // Казан утлары, - 1987. - № 6. –Б.166.

## Муса Җәлил иҗатында– табигать, кеше һәм тәрбия

***Хайрутдинова Зөлфия Рафик кызы***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы***
***ДАҺБУ “Түбән Кама эретеп***
***ябыштыру - монтажлау көллияте”***

Табигать һәм Кеше бер-берсе белән гармониядә яшәргә тиеш. Кеше табигатьсез, табигать кешесез яши алмый, чөнки Табигать Кешене дөньяга китергән һәм шулай яраткан. Табигатькә зыян килде икән, моңа, һичшиксез, Кеше җаваплы булырга тиеш. Безнең язучыларыбыз бу турыда үзләренең әсәрләрендә бик ачык итеп бирәләр. Язучының иҗатын җаның-тәнең белән тоеп, аңлап укысаң, аның уй-кичерешләрен бүлешә аласың. Гомумән, язучыларның әсәрләре кешене дулкынландыра да, шатландыра, куандыра да һәм зур киңлекләргә очыра. Язучы булган кеше хисчән, мәрхәмәтле, искиткеч

матур күңелле һәм уйчан буладыр. Безнең бурыч шул хисләрне үзебезнең укучыларыбызга җиткерү.

Табигый образларны әхлак темасы белән бәйләп укучыларны табигатьне сакларга, яратырга өндәүче әсәрләр Муса Җәлил иҗатында зур урын алып тора. Кечкенә Муса ерак тегермәнгә барырга ярата торган була. Андагы табигатьнең матурлыгы искиткеч!!!Буаның суы тулган, ярдан ташырга тора, як – якта куе әрәмәлек, әйләнә - тирәгә карасаң, хисапсыз чәчәкләр белән бизәлгән болынлык, бер яктан еракларга киткән дала, урман, тау чылбырлары, дулкынланып үсә торган ашлык, астарак яшелчә басулары. Муса шундагы матурлыкка сокланып карап, тиз генә дәфтәрен ала да, бай табигатьнең пейзажын төшерергә керешә. Ул шул кадәр төгәл һәм матур итеп ясый.

Җәлил туган илен бик тә яраткан, аңа багышлап "Җилләр" исемле шигырь иҗат иткән. Шушы шигыре белән безне дә туган илебезне яратырга өндәгән.

"Чәчәкләр" шигырендә автор табигать матурлыгы аша шатлык хисен бирә.
Шатлык һәм фаҗига янәшә яши, һәм алар кампа-каршы сыйфатка ия. Шагыйрь бу шигырьдә балаларны чәчәкләр белән чагыштыра. Ул: "Дөньяда балалардан да гүзәлрәк нәрсә юк, алар безнең өметебез, бәхетебез ", - ди торган булган.

"Имән" шигыренә күз салсак, анда имән образы ашаавтор кешенең хезмәтен күрсәтә.Җир казыган, тир тамызган, имәннең яшәү иртәсен кабызган кешене сүрәтли. Имән ялгыз, карт, меӊ еллык, җил-яңгырдан саклый, җылы бирә, ял иттерә, кавыштыра, юл күрсәтә. Муса Җәлил имәннең ничек яшәве турында сөйли, аны утырткан кешегә, аның хезмәтенә баш ия. Имән – кеше хезмәтенә һәйкәл булып тора.

Мусаның туган авылыда, яр астында, көмештәй саф суларын эчәргә дәшеп, чишмә челтерәп аккан. Ул үзенең дуслары белән еш кына чишмә буенда ял итәргә яраткан чишмәгә рәхмәтен, соклануын белдереп, "Чишмә" исемле шигырь язган.**Ә, инде"Көз житте**" әсәрендә табигатьне яратырга, сак мөнәсәбәттә булырга өнди.

“Изге җимеш”, “Чаңгы шуганда”, “Чаңгы эзе” шигырьләрендә дә туган як табигате, аны саклау, кош-кортка һәм хайваннарга мәхәббәт темалары да чор рухы һәм патриотизм белән үрелеп китә.
Газиз Кашшаф Муса Җәлилнең 1935 нче елдагы бер хатыннан алынган мондый юллар китерә:«Мин тормышта тирән һәм ялкынлы сөя беләм. Мин табигатьне дә, кояшны да, чәчкәне дә, музыканы да һәм намуслы хезмәтне дә, ялкынлы иҗатны да, тиңдәшсез илемне дә шулай ук янып, кайнарланып сөям. Бу минем эчке тирән бер сыйфатым инде».

Табигать символлары Җәлил балладыларында аеруча еш күренеш. Аерым әсәрләр тулысынча шундый күренешләргә багышланган. Мәсәлән, «Сандугач һәм чишмә». Җанлы табигать вәкиле Сандугачукучы аңында сөюне, мәхәббәткә тугрылыкны гәүдәләндерә. Таң җырчысы, матурлык, нәзакәтлелек билгесе буларак, ул халык шигъриятендә киң урын ала. Чишмә - җансыз табигать вәкиле,сафлык, чисталык билгесе,изге итеп бирелгән. Ул сусаганнарны су белән сыйлый, батырларның яраларын юа.Шулай итеп, Сандугач һәм Чишмә монда үзләренең символик образлары белән Ватан һәм туган табигать идеяләрен берләштерергә ярдәм итә. Чыннан да, бу символлар – туган илне, туган якны, туган табигатьне белдереп килә торган символлар.

Без карап үткән барлык әсәрләрендә дә табигатьне сакларга, туган илне яратырга, агачлар, чәчәкләр утыртырга, табигатьнең байлыгын сакларга, төгәл, пөхтә булырга, хезмәт сөяргә өйрәтә.

Укыган әсәрләребез табигать дөньясы, тормыш, кешеләр, без белмәгән кызыклы хәлләр, вакыйгалар белән таныштыра. Безне куандыра, шатландыра, тормышны яратырга өйрәтә, яки, киресенчә, безне борчый, уйланырга мәҗбүр итә.

Без мәдәниләшүнең югары биеклегенә күтәрелдек. Инде кеше табигатьтән файдаланып кына кала алмый, ул аның яклаучысы, яңадан тууда, күтәрелүдә булышчысы да булырга тиеш. Бүген кеше табигатькә бәйле дип әйтү генә дөрес булмас иде, чөнки табигатьнең язмышын кеше дә хәл итә, ул экологик тотрыклыкны саклап калырга бурычлы.

Кулланылган әдәбият

1. Җәлил М. Әсәрләр. – Казан: Мәгариф, 2004. – 271 б.

2. Җәлил М. Әсәрләр. Дүрт томда. 1 нче том. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1968. – 558 б.

3. Кашшаф Г. Муса Җәлил, тормыш һәм иҗаты турында очерклар. – Казан: Матур әдәбият редакциясе, 1957. – 380 б.

## Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә экологик һәм рухи- әхлакый тәрбия бирү

***Хәйруллина Саһира Иршат кызы,***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы,***
***Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының***
***“5 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе”***

“Туган җиргә мәхәббәт табигатьне яратудан башлана”, - дип язган рус язучысы Константин Паустовский. Әлбәттә, табигатьне ярату - аның матурлыгына, байлыгына һәм көченә соклану гына түгел. Без - хәзерге буын вәкилләре өчен табигатькә мәхәббәт беренче чиратта аны кайгыртудан гыйбарәт булырга тиеш.

2017 ел Татарстанда Экология һәм иҗтимагый киңлекләр елы буларак игълан ителде. Россия күләмендә дә бу ел экологиягә багышланган. Республикада шәһәр һәм авылларны яшелләндерү, сулыкларны төзекләндерү эшләре быел да дәвам итә. Табигый ки, мәктәптә татар теле һәм әдәбиятын укытуда экологик мәсьәләләрнең әһәмиятен ачуда әле файдаланмаган мөмкинлекләр бар. Укучыларга табигать һәм хайваннар дөньясы таныш. Алар белән табигатькә экскурсиягә чыгабыз. Сирәк очрый торган чәчәкләр, агачлар белән танышабыз. Бу чараларны Бөтендөнья тирә- юньне саклау, Кызыл

китап, Татарстан Республикасы Конституциясе көннәре уңаеннан үткәрәбез. Укучылар күңелендә табигатькә, туган якка мәхәббәт тәрбияләүдән һәркем ота. Чөнки табигатькә якынайган саен, кеше үзен тагын да яхшырак, тирәнрәк аңлый бара. Экология проблемаларын хәл итү һәркемгә бәйле. Моны укучылар белергә тиеш. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә язучы, шагыйрьләр иҗатын үткәндә, күнегүләр эшләгәндә, укучыларның игътибарын экология проблемаларына юнәлтеп була. Мәсәлән, 4 нче сыйныфта “ Дару үләннәре ” темасын үткәндә, табигатькә сак караш тәрбияләү мөһим булып тора. Укучыга , өй эше итеп , хәзерге ФДС шартларында , Татарстанда, Алабугада үскән чәчәк , агач яфракларыннан гербарий ясату, татарча һәм русча исемнәрен яздыру балалар эшләрлек эш. Бу татар телен саклап калырга да ярдәм итә, укучы җәй көне урманда, кырда , бакчада үскән үсемлекләргә игътибарлырак та булыр. 3 нче сыйныфта

“ Туган якка кыш килде”, “Кечкенә дусларыбыз”, “ Күңелле җәй, ямьле җәй” темаларын үткәндә , Алабуга районында үсә торган чәчәкләр, дару үләннәре белән танышабыз. Сыйныфтан тыш чараларда, татар теле атналыкларында “Кошлар безнең дусларыбыз” темасына стена газеталары чыгарабыз, ачык чаралар үткәрәбез.

Укытучы бу темага үзе иҗади яктан килеп эшләсә, укучылар да табигатьне ярату , саклау турында уйланачаклар, төрле чараларга теләп катнашачаклар, бу эшләрнең әһәмиятенә төшенәчәкләр. Мин мәктәптә татар теле укытучыларының берләшмә утырышында “Рус телле укучыларга татар теле дәресләрендә әхлакый- экологик тәрбия бирү “ дигән темага чыгыш ясадым, укучыларга экологик тәрбия бирү максатыннан, 2016 нчы елда “Туган як” темасына ачык чара күрсәттем. Укучылар Алабуга урманына сәяхәт ясадылар. Табигать турында татар халык мәкальләрен белүләрен күрсәттеләр, туган як турында җырлар җырладылар.Укучыларны кече яштән үк татар халык иҗатына , мәдәниятына игътибарлы итеп тәрбияләргә кирәк. Халык бәйрәмнәрен, гореф - гадәтләрен белү - тәрбия чыганагы ул. Мәсәлән, күренекле шагыйрь С. Хәким үзенең поэзиясендә туган якка дан җырлый,

чишмә, елга, тау, үзәннәре турында илһамланып яза. Минем “С. Хәким поэзиясендә - табигать “ темасына ачык дәрес планым “Ачык дәрес “ газетасында басылып чыкты (2011ел) . Экологик тәрбия тәрбия темасына караган шәһәркүләм , Бөтенроссия семинарында чыгышлар ясадым. “Г. Бәширов әсәрләрендә табигать” дигән мәкаләмне “Ачык дәрес” газетасында бастырдылар. Алабуга университетында “Татар әдәбиятын өйрәнү һәм укыту” дигән темага Бөтенроссия фәнни - гамәли конференциясендә “Гомәр Бәшировның “Туган ягым - яшел бишек әсәренең тел - стиль үзенчәлекләре” темасына чыгыш ясадым .«Туган як. Родной край» (2012 ел) Республика бәйгесендә катнашкан өчен грамота белән бүләкләделәр. 2013 елда “Туган телем - шагыйрьләр теле” дигән Республика конференциясендә “ Р. Миңнуллин поэзиясендә аккаен образы” дигән темага чыгыш ясап, 3 дәрәҗәдәге диплом алдым. “Җиребез- уртак йортыбыз” дигән муниципаль бәйгедә катнашып, грамота алдым. Укучыларым да экология темасына муниципаль конференияләрдә , бәйгеләрдә катнашалар. 2013 елда муниципаль конференциядә Арсланова Диләрә “Ягъсүф Шәфыйковның “Хуш, Агыйдел!” повестенда табигатьне саклау проблемасының бирелеше” дигән темага чыгыш ясады. 2016 елда Нишонова Элиана “Галимҗан Ибраһимовның “Яз башы” хикәясендә пейзаж” темасына фәнни эш язды. Г. Ибраһимовның тууына 129 ел тулуга багышлаган VII республика фәнни- гамәли конференциясенең икенче турына үтте.

Йомгаклап шуны әйтергә була : мәктәп укучыларын яшьтән үк туган як табигатенең матурлыгын күрергә, аның закончалыкларын аңларга, байлыкларыннан дөрес итеп файдаланырга һәм табигатьне сакларга өйрәтү бик тә мөһим.

Кулланылган әдәбият:

1. Ганиев В. Бер авторның алты китабы / В. Ганиев // Ватаным Татарстан.- 2003.-14 февр.

2. Зарипов Р. Гасырларны йомгаклап. / Р. Зарипов// Ватаным Татарстан. — 2000. — Май.

3.Зарипов Р. Иҗатында – җан авазы/ Р. Зарипов// Мәйдан .- 2009.- 90 б.

4. . Миңнуллина М. Якташлар турында. / М. Миңнуллина. Татар иле. — 1997. — 10 гыйнвар

5 . Мостафин Р. Бер очрашу- бер гомер // Татарстан. -2002.- дек.

## «Тукай иҗатында экология һәм әхлак мәсьәләләре”

***Хәлиуллина Ризидә Хәмит кызы, ДБГБУ “Минзәлә шәһәренең ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган, сәламәтлекләре чикләнгән балалар өчен интернат-мәктәбе” татар теле укытучысы-дефектолог***

Балаларга экологик тәрбия бирү - дөньякүләм әһәмиятле, мөһим мәсьәләләрнең берсе булып тора. Ул үзенең актуальлеге, үткенлеге белән бүген бөтен кешелек алдына килеп басты. Чөнки киләчәк буыннар язмышын фән-техника казанышлары түгел, ә җир-суларның экологик торышы хәл итәчәк, җитештеру эшчэнлегенең тизлеге арткан саен, экологик проблемалар кубәя бара. Экология проблемасынын глобаль проблема булып, анын узебез яши торган урында да чагылуы без, тэрбиячеләрдэ дә борчылу тудыра һэм төрле педагогик эшчэнлеккэ этәрә. Экологик аңлылык, фикерләу дәрәҗәсе, культурылылык – болар килеп туган хэлдэн чыгунын бердэнбер юлы булып тора. Ә моңа балаларга кече яшьтән экологик тәрбия биреп кенә ирешергә мөмкин . Табигатьне күзэту, аны өйрэну, сакларга омтылу – балаларның рухи доньясын баета, уйларга ойрәтә.

Экологик сукмак мәктәпнең капкасыннан керү белән үк башлана. Мәктәпне әйләндереп алган агач һәм куаклар, чәчәкләр,яшелчә һәм җиләк-җимеш бакчасы -болар һәммәсе дә балаларны табигать белән таныштыруда зур булышлык ясый. Елның теләсә кайсы вакытында терек һәм терек булмаган табигатьне күзәтүләрдән чыгып кызыклы тәҗрибәләр үткәрү, әңгәмә корулар,

фикерләр алышулар укучыылар күңелендә тереклек ияләренә, туган як табигатенә сак караш, кызыксыну һәм мәхәббәт тәрбияли.

Кеше тормышы һәрвакыт табигать белән бәйле. Ул - кешенең сәламәтлек, туклану,гомумән, яшәеш чыганагы. Табигать дигәч, иң беренче чиратта, калын яшел урманнар, саф сулы чишмәләр, бай тарихлы елгалар, күлләр, иксез-чиксез җәелеп яткан далалар күз алдына килә. Табигать безгә азык, кием, торыр урын бирә. Кеше тормыш өчен кирәкле бар нәрсәне табигатьтән ала. Шуңа күрә, табигатьне саклау- һәр кешенең изге бурычы.

Экологик белем һәм тәрбия бирүдә әдәби әсәрләрнең әһәмияте зур. Язучыларыбыз, беренчеләдән булып, табигатьне саклау турында чаң сукты. Әйләнә-тирә дөньяны, кеше сәламәтлеген, аның рухын, телен саклау аларны иң борчыган һәм дулкынландырган проблемага әйләнде. Нәфис сүз, сәнгать чаралары ярдәмендә кешедә югалып бара торган иң изге әхлакый-рухи кыйммәтләрне торгызу, Җир-анага игелек, хөрмәт хисләрен уяту, кешелекнең экологик һәлакәт каршында торуында искәртергә кирәк иде.

Кеше табигатьтән башка яши алмый. Табигатькә чыгып, без ял итәбез, кошлар җырын тыңлыйбыз, хуш исле үләннәр, чәчәкләр иснибез, күңелләребезне

сафландырабыз. Мәрхәмәтлелек тамыры табигатьтән башлана. Ә мәрхәмәтлелек ул – мәхәббәт, ярату. Мәхәббәт – җәнлекләрне, кошларны, бар табигатьне ярату, саклау.

Татар халкының ел фасылларының иң үзенчәлекле көннәренә багышланган бәйрәм-йолалары күп. Мәсәлән, кышкы һәм җәйге Нардуган бәйрәмнәре, Сөмбелә, Карга боткасы һ.б.  Без бу бәйрәмнәрне табигатьтә, урманда уздырырга тырышабыз. Мондый бәйрәмнәр белән танышу ерак бабаларыбызның табигать белән бер бөтен булып яшәгәннәрен күзалларга ярдәм итә. Табигатьнең матурлыгына хозурлану гына аз, аны саклый, аңлый белергә дә кирәк.

Табигатьне саклау темасына язылган әсәрләр исемлеге бай һәм төрле. Г. Тукай күп кенә шигырьләрендә җәнлекләрне, кошларны, бөҗәкләрне яратырга,

аларга мәрхәмәтле, шәфкатьле булырга өнди, үзенең шигъри бизәкләре белән табигатьнең гүзәллеген ача. Табигатьне саклау – милләтебезне, туган телебезне, гореф-гадәтләрне, рухи һәм тарихи байлыкларны саклау белән тыгыз бәйләнгән. Чөнки туган тел, әдәби һәм тарихи мирас газиз җиребездә барлыкка килгән. Шуңа күрә балаларны татар халкының рухи тамырлары, ерак бабаларыбызның яшәү рәвеше, һөнәрләре белән таныштыру, аларда милли горурлык тәрбияләү мөһим. Табигатьнең матурлыгын, серлелеген Тукаебыз үзенең җаны, саф күңеле, йөрәк җылысы салынган шигъри юллары белән укучы җанына, аның күңеленә салучы, ныгытучы, мәңгеләштерүче.

Г.Тукай үзенең шигырьләрендә туган җиребез матурлыгына, гүзәл табигатенә дан җырлаган шагыйрь. Табигать темасын һәр язучы үзенчә күрә, тасвирлый, укучыга төрле тел бизәкләре, сурәтләү чаралары, әдәби алымнар аша ачып бирә. Шагыйрьнең пейзажы туган туфрактан, балачагы үткән Кырлай якларыннан аерылгысыз. Пейзаж күп очракта сабыйлык хатирәләре аша үтеп тасвирлана. Тукайның туган як табигатенә балаларча мәхәббәте сизелеп тора. Шигырьләренең исемен дә күңелгә якын, үз итеп «Туган җиремә», «Туган авыл», «Җәйге таң хатирәсе» һ. б. дип атый.

Габдулла Тукай әйтергә теләгән фикерләре укучыга барып җитсен өчен, әдәби телебезнең төрледән-төрле сурәт-бизәкләрен куллана, төрледән-төрле чагыштырулар куллана. Мәсәлән: «Тәгәридер ул матур кыз —язның алтын фәйтуны»; «Барыбер, күрсәң, качарсың, язны — гөлләр патшасын». Әйе, кеше табигатьнең аерылгысыз өлеше. Шагыйребезнең шушындый кешелекле, шәфкатьле әсәрләре безне асылыбызга кайтара, табигать дөньясы белән тагын да якынайта. Киләчәк буын вәкилләре дә әлеге әсәрләр аша гүзәллек дөньясын күреп, тоеп, киләчәктә аны кайгыртып яшәсә иде.

Табигать сурәте Г. Тукайның поэзиясендә гаҗәеп күп төрле функцияләрдә кулланыла, шагыйрьнең иҗатынан гуманистик рух, җылы лиризм бөрки. Табигать күренешләре аша дөньяга карашын, тормыш фәлсәфәсен чагылдыра. Табигатьнең биниһая чиксез рухын, мәңгелеген, бетмәс-төкәнмәс матурлыгын, төсләр, исләр байлыгын укучысына җиткерергә

омтыла шагыйрь. Табигатьтәге нәфислектә, иллелектә, хәзерге җәмгыятьнең матурлыгын, кешеләр арасындагы камил мөнәсәбәтләрнең чагылышын күрә, алар арасында рухи якынлык таба.

Ни өчен соң Г. Тукай иҗатында табигать образы шундый әһәмиятле урын тота? Башка шагыйрьләр белән чагыштырганда аның үзенчәлеге, яңалыгы нәрсәдә соң?

Язучының, туган табигатькә, табигый матурлыкка мөнәсәбәте бала чактан тәрбияләнә. Яшьлек хатирәләре аның өчен илһам чыганагы, алдагы тормышында маяк булып тора. Мәгълүм булганча, шагыйрьнең балачагы мәһабәт урман-тугайлар, хәтфә болыннар, чылтырап аккан чишмә-елгалар кочагында үтә. Авыл малайлар белән су буенда, балыкта. Печән җитсә - ул печәндә. Аунасаң- чәчәге ияреп кайта. Урагы җитсә - ул да урак өстендә җир сөреп, сука сукалап үсә ул. Нәкъ менә Туган якның яме булачак шагыйрьнең дөньяга карашын, зәвыгын тәрбияләүгә үзеннән зур өлеш кертә.

XX гасыр башында промышленность үсә башлый, шәһәрләрдә күп кенә завод – фабрикалар ачыла. Аларда эшләү өчен авыл кешеләрен җыялар. Казан да читтә калмый. Завод-фабрикаларда эшләү өчен кешеләр кирәк. Саф табигать кочагыннан шәһәргә килгән кеше тынчу, пычрак мохиткә эләгә. Бу хәл шагыйрьне борчуга сала. Сәнәгать үсеше табигый матурлыкка зыян китерә.

Ут, төтен, фабрик-завод берлә һаман кайный Казан;
Имгәтеп ташла савын, сау эшчеләр сайлый Казан.

("Казан")

Шагыйрьне бөтен "өязгә нур чәчеп" торган Казанның пычрануы, төтен, корымга күмелүе сызландыра.

Бөек шагыйребез "Экология" фәнен өйрәнмәсә дә, Җир һәм анда яшәүчеләрнең тормышлары өчен борчылган. Ул табигатьнең кешегә яшәү өчен матди мөмкинлекләр дә, иҗат өчен илһам да бирүен дөрес аңлаган. Экологиянең чикләре бик киң. Тукай бу мәсьәләгә дә төрле яктан якын килә.

Әйтелгән фикерләр шагыйрьнең бик күп әсәрләрендә чагылыш тапканын күрдек.

Кыскасы, Г.Тукай фикеренчә, кеше табигатьне яратырга, сакларга, аның белән хозурланырга, аның кочагына омтылырга тиеш. Шулай булганда гына “тәнгә дә, җанга да мунча” (“Тәлләһеф”) табылыр. Шул чакта гына шагыйрьгә илһам килер.

Каршыларга иң сәза чак, иң матур чак, җәйге таң;

Шул вакытта уйла, шагыйрь: килде илһам уйласаң.

(“Җәйге таң хатирәсе”)

Гомумиләштереп әйткәндә, Г. Тукай иҗатында туган як образы зур урын алып тора. Туган ягына булган мәхәббәтен иҗат җимешләре аша укучыларына җиткерә шагыйрь.

Һәм шушы әсәрләре белән ул кешеләргә: “Табигатьне саклагыз!” – дип әйтә кебек.

Бүгенге көндә кешеләр табигатьне сакламыйлар. Елгалар пычратыла, хайваннар үлә, күп кенә үләннәр, чәчәкләр, агачлар юкка чыга. Габдулла Тукай табигатьне сакларга тырышкан. Безне дә шуңа чакыра!

Тау башында салынгандыр безнең авыл,

Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;

Аулыбызның ямен, су тәмен беләм,

Шуңа күрә сөям җаным-тәнем белән.

(Г.Тукай “Туган авыл”)

- дип яза шагыйрь туган авылының матурлыгына сокланып.

Г.Тукайның табигатькә багышланган шигърияте укучыны дөньяга гаҗәпләнеп карарга, матурлыкны күрә белергә өйрәтә. Яшь укучылары өчен шагыйрь танып-белү материалы бирә, табигать табышмаклары иҗат итеп, баланы уйлануга этәрә, сораулар куя. Мәсәлән, «Елның дүрт фасылы», «Җәй көнендә», «Көз», «Чыршы» һ. б. күп шигырьләрендә татар авылының табигатенә мәдхия җырлый. Яңгыр, чык, кырау, буран, җил, кояш, ай, яз, көз, җәй, кышның — һәрберсенең үзенчәлекле билгеләре турында шигъри ачышлар ясап, укучы күңеленә җиткерә. “Чыршы” шигырендә автор көзнең бер

билгесен- агач һәм үләннәрнең саргаюын, чыршының исә “үз төсен үзгәртми” калуын контраст кую рәвешендә ача:

Саргаядыр көз көнендә һәр агач яфраклары;

Юк яшеллекләр хәзер, урман вә сахра сап-сары.

Үз төсен үзгәртми саклаучы арада берсе бар:

Көз көне һәм кыш буе саргаймый торган чыршы бар.

“Көз”, “Мәктәптә” шигырьләрендә исә әлеге тема инде киңрәк планда һәм тулырак бирелә, фикер катлаулана төшә: “саргаю” билгесенә кошлар китүе, игеннәр җыелу, кояшның җылысы кимү һ.б. сыйфатлар өстәлә.

Кояш та яктысын киметте шактый;

Тәәссеф!Басты золмәт,китте якты.

Колакны шаулата инде инде суык җил,

Тулып эчкә, өрә, мисле куык, җил.

Ничәйтсәң дә, күңелсез көз, күңелсез;

Чәчәксез көз, үләнсез һәм дә гөлсез.

“Яратырга ярый” шигырендә исә табигатьнең күп вакытта кешегә дә бәйле булуы искәртелә. Кеше еш кына табигый матурлыкка тап төшерә.

Яратырга ярый дөнья: матур кырлар, матур таулар;

Яратмыйм мин вәләкин һич, сәбәп шул: ибне адәм бар! –

(“Яратырга ярый”)

Шагыйребез иҗатында әйберләрне җанландыру, сынландыру, хайваннарны кешеләргә хас аерым билгеләр белән сурәтләү алымы киң файдаланыла. Бу аеруча йорт хайваннарын һәм кош-кортларны бирүдә күзгә ташлана. Ул шигырьләрендә һәрбер җан иясенең индивидуаль портретларын таба, аларны билгеле бер характерда, җанлы тормыш эчендә ача: “Мияубикә”, “Бичара куян”, “Кызыклы шәкерт”, “Бала белән күбәләк”, “Фатыйма белән сандугач”, “Шаян песи”, “Күгәрчен”, “Карлыгач” ,”Карга”, “Кошларга”, “Кошчык”һ.б. шундыйлардан. Г. Тукай үз шигырьләре аша балаларны кечкенәдән үк кошларны яратырга, аларга мәрхәмәтле булырга өнди, аларны

гөнаһсыз фәрештәләр белән тиңли. Кошларның табигатькә бик күп файда китерүенә басым ясый, аларның иркендә генә матур итеп сайрый алуын әйтә. “Фатыйма белән Сандугач” шигырендә читлектәге кош ирек турында:

Белмисеңме син: читен мәхбүслек ул,

Булса да алтын, һаман да читлек ул, -дип әйтә.

“Кошларга” шигырендә исә: “Әллә иркендә торуның кадерен белмимме мин?!” – ди.

Г.Тукай күп кенә шигырьләрендә табигатьнең төрле җан ияләре образлары аша укучыда кешелеклелек, йомшак күңеллелек, мәрхәмәтлелек сыйфатлары тәрбияли. Читлектән чыгарылган сандугачның сайравы кызда шатлык хисе уята.

Тик гомрем бик кыска:

Бары бер көн генә, —

Бул яхшы, рәнҗетмә,

Һәм тимә син миңа!

Килде дә бер явыз аучы эт белән,

Атты үтерде аны мылтык белән

(«Фатыйма һәм Сандугач »)

- дигән юллар укучыда табигатьнең тере җан ияләренә кызганучан, мәрхәмәтле караш тәрбияли.

Шагыйрь хайваннарны дуслары, ярдәмчеләре дип саный, һәркемгә билгеле булган “Гали белән Кәҗә” шигыре үзе генә чын дуслыкның, мәхәббәтнең үрнәге булып тора. Табигатьтәге көчсез хайваннарны кызгана шагыйрь, кешеләрне бәгырьсезлектә гаепли. “Бичара куян” әсәрендә бүре куянның балаларын ашап китә, соңыннан әнкә куянны аучы ата. Ата куян ялгыз кала һәм аның өчен дөньяның яме, яшәүнең мәгънәсе бетә. Автор фикеренчә, явызлык,ерткычлык, бәхетсезлек китерә.

Шул вакыттан бирле аш булмый ашым,

Моңланам ялгыз башым, агъзам яшем.

Шигырьдә бүре белән кеше бер яссылыкта куела. Икесе дә – корткычлар.

"Мияубикә" шигырендә шагыйрьне яшь буынның киләчәге борчый. Аларда нинди хисләр өстенлек итәр: мәрхәмәтлелекме, кешелексезлекме? Автор шул мәсьәләләргә туктала. Кеше кайвакыт кылган эшләре турында эш узгач кына уйлана, ләкин инде соң була:

Фани дөнья! Нинди эшләр эшлисең син шак та кат!

Шундый шат уйнап йөргән песи инде вафат!

Кеше үзен корткычлардан, күсе-тычканнардан саклап торган песинең кадерен

белми, аны рәнҗетә, песи үлә. Чын дусты аңа хыянәт итә. "Бу җиһанның дусны дустан аеруы бигрәк яман!" – дип, акны-карадан, дусны дошманнан аера белергә кирәклеген әйтә шагыйрь.

Мифологик сурәтләргә бай "Шүрәле", "Су анасы" әсәрләре халык әкиятләре стилендә язылган, тирән халыкчанлык белән сугарылган. Биредә табигатьнең бөтен матурлыгы һәм серлелеге сыйдырылган. Шагыйрь үзенә генә хас алым һәм зур осталык белән укучыларны табигать дөньясына алып керә, матурлыкны тоя һәм күрә белергә өйрәтә. Тукай борынгылыкны саклаган, халкының гореф-гадәтләренә нигезләнгән мифларны яхшы белә.

Шүрәле — әсәрдә төп образ. Ул табигать иркәсе, урман хуҗасы, шагыйрь аны әкияттәгечә куркыныч кыяфәтле, адәмнәрне кытыкларга яратылган озын бармаклы «урман пәрие» итеп сурәтли. Былтыр белән Шүрәле очрашуы укучыны сагайтса, Былтырның акыл зирәклеге, тапкыр хәйләсе ярдәмендә җиңүе сөендерә.

Г. Тукай үзенең авылының гаҗәеп табигатен, үз вакытын белеп алышынган ел фасылларын, аларның һәрберсенең үзенә хас матурлыгын соклану катыш гаҗәпләнү хисләре белән яза. Кырлай авылы тирәсендәге калын урманнарны, сайрар кошлары, җәнлек-җанварлары, хуш ис бөркегән чәчкәле, кызыл җиләкле аланнары турындагы шигъри юллар кайсы укучыны гына хыял дөньясына алып китми икән?

Монда бульварлар, клуб һәм танцевальная, цирк та шул;

Монда оркестр, театрлар да шул, концерт та шул.

Зур бу урман: читләре күренмидер, диңгез кеби;

Биниһая, бихисаптыр, гаскәри Чыңгыз кеби.

- юлларын укыгач, шагыйрьнең үткәндәге тарихыбыз белән горурлануына, бай әдәби теленә, көтелмәгән чагыштыруларына, эпитетларына сокланасың. Әсәрдәге халык көйләренең дәртле яңгырашын, интонация байлыгын, шигъри төгәллекне укучы сизеп кенә калмый, матурлык дөньясын күреп, аның сәнгатьчә сурәтләнүеннән ләззәт ала.

Урман татар халкының тормышында да зур урын алып тора. Шул сәбәпле, әдәби әсәрләрдә урманны сурәтләү еш очрый. Тукай урманыбызның гүзәллегенә соклана. Борын-борын заманнардан бирле ул кешене туйдырган, һәртөрле куркыныч хәлләрдән саклаган. Урман — дәва ул, сәламәтлек чыганагы. Күкрәгеңне тутырып сула әле бер урман һавасын. Ипигә ягып ашарлык бит, билләһи. Бөек рус галиме Менделеев әйткән: «...урман утырту илеңне дошманнан саклау шикелле үк изге эш, кешеләрнең урманга карата булган мөнәсәбәте буенча илнең культура дәрәҗәсен билгелиләр, диләр!..»

Су анасы да — халык авыз иҗатында киң таралган образ. Авыл малаеның ялгыш адымы, аның эчке газабына әверелеп, тәүбәгә китерә. Шагыйрь, әкияти эчтәлектән чыгып, укучыны гыйбрәтле уйга сала.

Шагыйрьнең, миф дөньясына хас образлар ярдәмендә иҗат ителгән бай эчтәлекле, матур яңгырашлы, киң хыялый поэмалары укучыларында мифик образларга карата кызыксыну уята. Бу әсәрләрендә укучыны гаҗәеп табигать дөньясына алып керә. Матурлык дөньясын тою гүзәллеккә омтылу хисе уята. Бу әсәрләр аша кешегә, аның акылына, зирәклегенә, хәйлә катнаш тапкырлыгына, кыюлыгына, батырлыгына соклану хисе уяна. Ә хисләр, хыяллар дөньяны танып белүнең башлангычы ул.

**Кулланылган әдәбият.**

1. Габдулла Тукай. Әсәрләр. Биш томда. 4 том. Проза. Публицистика (1907-1913), - Казан, Тат.кит. нәшр., 1985.

2. Тукай Г. Сайланма әсәрләр: 2 томда. - Казан: Татар.кит. нәшр., 2006.

3. Лаисов Н. Габдулла Тукай. Тат.кит.нәшр.,

4. Нуруллин И. Тукай.-Казан, Тат.кит.нәшр., 1979.

Рәсүлова З. Тукай эзләреннән.-Казан,Тат.кит.нәшр., 1985

5. Сайланма әсәрләр. Шагыйрь турында истәлекләр.- Казан: Татарстан Республикасы ”Хәтер нәшрияты” (ТаРИХ), 2002.

6. Халит Г. Тукай иҗаты.-Казан,Тат.кит.нәшр.,1956

7. Яхин А.Г. Әдәбият: Татар урта гомуми белем бирү мәкт. 9 нчы сыйныф өчен дәреслек. - Казан: Мәгариф, 2007

8. Яхин А.Г. 9 нчы сыйныфта татар әдәбиятын укыту. Укытучылар өчен кулланма. - Казан,“Мәгариф”,1994.

## Шәхес үсешендә әхлакый-экологик тәрбиянең роле.

***Хәбирова Ф.З.***
***педагогика һәм психология фәннәре укытучысы***

Халык элек-электән, җәмгыятьнең явыз көчләренә каршы торып, кешелекнең табигать көчләре белән авыр көрәшендә тупланган күпъеллык тәҗрибәсе аша яктылыкка, белемгә омтылган. Халык педагогикасы, белем-тәҗрибәсе, күп гасырлар буе буыннан-буынга күчеп, яшь буынга тапшырылып килгән.

Халык педагогикасы яшь буынга белем алу, җитештерү, фән һәм сәнгать өлкәсендә иҗади эшчәнлек белән шөгыльләнү, әхлакый камилләшү өчен җирлек тудыручы чараларның башлангыч нигезен тәшкил итә.

Кешелек җәмгыятен һәрвакыт борчып килгән әхлак мәсьәләләре – намус, гаделлек, җирдә дөрес итеп яшәү, әти-әни һәм Ватан алдындагы изге бурычны

үтәү кебек төшенчәләр мәңгелек, һәркем өчен уртак. Аларны үзеңдә булдыру өчен Кеше булу кирәк. Бүген, бөтен кешелек дөньясы күләмендә глобальләшү хәрәкәте киң колач алган чорда, киләчәкне үз кулларында тотачак буыннарны рухи-әхлакый тәрбияләүгә игътибарны арттыру турында һәркем уйланырга тиеш.

Кешелек яратылганнан бирле тәрбия мәсьәләсе көн кадагында тора.

Безнең максатыбыз - һәрьяклап камил шәхес тәрбияләү. Тарихи үсеш дәвамында халыкның хәтер сандыгында шәхес тәрбияләү белән бәйле карашлары, фикерләре, ысуллары тупланып килгән, һәм ул рухи хәзинә өзлексез камилләшә барып, буыннан- буынга тапшырылган. Яңа буын, үз чиратында, халык меңәр ел туплаган гореф-гадәтләрне, йолаларны саклап, телен-динен хөрмәтләп яшәгән. Олыга-олы дип, кечегә-кече дип караган. Картайган ата-анасын тәрбия кылуны, тудырган баласын багып үстерүне изге бурыч итеп санаган, бәндәнең рәнҗеш - каргышыннан, ананың бәддогасыннан уттан курыккандай курыккан. Хак хаклый белгән безнең халык: Аллаһ хакын, күрше хакын, тол-ятимнәр, ярлы- ябагайлар, милләт хакын.

Борынгы грек фәлсәфәчесе Сенека:” Гыйлемлелектә алга китеп тә, әхлаклылыкта артта калган кеше алга китүдә иң артка калган кеше,”- дигән.

Әхлак –нәрсә ул?

Әхлак-күркәм холык, үзеңне тота белү, тәрбиялелек,тотнаклылык, кешеләр белән аралаша белү, янәшәдәгеләргә хөрмәт белән карау төшенчәләрен тәшкил итә.Әхлак ул - кешенең эш-хәрәкәтләрендә, көндәлек тормышында билгеле бер калыпка салынган , билгеле бер кыйммәтләрдән торган сыйфат.

"Әхлак тәрбиясе" мәңгелек төшенчә үзе. Элек-электән ата-ана, өлкәннәр, мөгаллимнәр бала-чаганың игелекле, итагатьле, тәртипле, кешелекле булып үсүенә нык игътибар иткән, гаиләдә ата-анага, әби-бабага, мәктәп-мәдрәсәсендә мөгаллимнәргә һәм аларга ярдәмгә куелган башка берәүләргә хөрмәт, олылау, тугрылык хисләре тәрбияләү үзәккә куелган. Шәхеснең формалашуында һәм үсүендә әхлак тәрбиясенең роле элек -электән исбатланган, расланган.

Федераль дәүләт стандартларына күчү барышында да әхлак тәрбиясенең нигезе һәм бурычлары, тәрбия процессы — кешенең тулысынча шәхес буларак формалашуы. Әхлак тәрбиясе – тәрбия эше системасының үзәге, иң мөһим юнәлеше. Кеше үз эшчәнлеге дәвамында, аралашу вакытында дөньяга , кешеләргә мөнәсәбәттә әхлак нигезләрен туплый. Шәхеснең һәрьяклап усешен тәэмин иткән башка төр тәрбияви берәмлекләр барысы да әхлак мөнәсәбәтләре , әхлаклылык принциплары аша уза.

Дәүләт стандартларын тормышка ашыруда әхлак тәрбиясе процессында укытучы-тәрбиячеләрнең роле зур. Алар тиешле шартларны тудыра, оештыра да — алар балаларнын укуы, хезмәте, ялы, уены һәм һәртөрле эшчәнлеге дәвамында әхлак мөнәсәбәтләрен тиешле якка юнәлтә. Шул ук вакытта әлеге тәрбия процессы тәрбиячеләр биргән юнәлеш буенча гына түгел, ә бәлки көтелмәгән хәлләр, көтелмәгән очраклар тәэсирендә дә дәвам итә. Ә болары әхлак тәрбиясе процессына уңай да, кире дә тәэсир итәргә мөмкин. Менә шушы хәл тәрбия эшендә катлаулылык тудыра һәм тәрбиячеләрдән зур осталык, күңел сизгерлеге сорый. Федераль дәүләт стандартларына күчү барышында колледжда әхлак тәрбисенең төп бурычлары студентларда әхлак тәҗрибәсе булдырудан тора. Яхшыны яманнан, яманны яхшыдан аера белү тәҗрибәсе кешедә яшьтән үк тәрбияләнә. Ул аны көндәлек тормышы, эше, эшчәнлеге, башкаларга мөнәсәбәте белән ныгыта гына бара. Бала чакта барлыкка килгән әхлак нормалары кешене җитлеккән, олыгайган чорына кадәр озата бара. Җәмгыятькә, табигатькә әхлаклы мөнәсәбәт тәрбияләү исә – укучыда гражданлык хисләре, патриотизм, иҗтимагый һәм рухи активлык, Җир-анага игелек, хөрмәт хисләре тәрбияләү булып тора. Кеше үзенең шәхси тормышында, гаиләдә үзен билгеле бер җәмгыятьнең тулы хокуклы һәм җәмгыять алдындагы бурычларын тоя белгән гражданы итеп хис итәргә тиеш. Ләкин бу гына аз әле, әхлаклы бала табигатьне аңлый белергә тиеш. “Үзен – табигать патшасы” дип исәпләгән адәм баласының эшчәнлеге һәрчак уңай нәтиҗәләр бирми. Киресенчә ул күп очракларда табигать анабызга фаҗигале үзгәрешләр алып килә, әйләнә - тирәбезгә күпме зыян салды һәм сала.

Күп сулы елгаларыбыз саега, җирләр упкынсыман ярыклар белән яргалана. Елга үзәннәре баткаклыкка әйләнә, пычрана. Эчәр суларыбыз, сулар һавабыз көннән – көн шакшылана бара. Иген үстерелә торган уңдырышлы җирләр чикләнгән. Һәрберебезгә якын булса да һәм күп сөйләнелсә дә, экология фәне шул ук вакытта шактый серле булып кала.

Табигать – безнең бүгенге байлыгыбыз гына түгел, киләчәгебез дә. Аның байлыгын бездән соңгы килгән буыннарга да калдыру безнең уртак бурычыбыз. Кеше – табигатьнең аерылгысыз бер өлеше. Ул табигатьтән башка бер генә көн дә, бер генә сәгать тә, бер генә минут та яши алмый, аңа су, һава, азык – төлек, җылылык һәм яктылык кирәк. Балаларда табигатькә әнә шундый мәрхәмәтле карашны, табигатьнең матурлыгын тоя белүне әкеренләп аны яклый, саклый белүне кечкенәдән үк тәрбияләүдә зур эшләр алып барылырга тиеш.Табигать – саекмас белем чишмәсе. Заманыбызның күренекле педагогы В.А. Сухомлинский табигатьне, әйләнә - тирә мохитне һичкайчан саекмас белем чишмәсе, матурлык, бәхет чыганагы дип атады. Бу чыннан да шулай. Балалар җәйге аяз көндә нурланып кояш чыгуын, бөтерелә - бөтерелә күбәләкләр очуын, ә яз җиткәч гөрләвекләр агыун күреп олы шатлык хисе кичерәләр. Табигатьнең шушы гүзәллеген кече яшьтән үк күрергә, тормышка сөенергә өйрәтергә без педагоглар бурычлы.

Әхлакый-экологик белем һәм тәрбия бирү өлкәсендә безнең колледжда куп төрле чаралар үткәрелә. Группа кураторы буларак мин иң беренче чиратта студентларга тәрбиянең тормышта ни дәрәҗәдә әһәмияткә ия икәнлеген аңлатырга һәм бары тик, тәрбияне дөрес аңлаган, тәрбияле кеше генә яхшы гамәлләр кыла алганын аңлатырга тырышам. Группа белән өлкән буын укытучыларга ярдәм итү, әйләнә-тирә мохитне чистартуда, агачлар утыртуда актив катнашу, барлык төр мероприятияләргә теләп катнашу, белем алуга омтылыш, шигырь уку бәйгеләрендә катнашу, бер-береңә ярдәм итү , начар гадәтләр булмау – менә болар барысы да студентларның әхлакый - экологик нормаларын ныгытуда бик нык ярдәм итә.

Җирдә тереклек дәвам итә. Изге куәткә ия булган әхлак орлыклары шытым биреп, алар һаман да үсеп җимешләрен бирсен иде. Бала чакта барлыкка килгән әхлакый - экологик нормалары кешенең җитлеккән, олыгайган чорына кадәр озата бара.

Нәфис сүз, сәнгать чаралары ярдәмендә кешедә югалып бара торган иң изге әхлакый-рухи кыйммәтләрне торгызу, Җир-анага игелек, хөрмәт хисләрен уяту, кешелекнең экологик һәлакәт каршында торуын да искәртергә кирәк .

Кешелек җәмгыятен һәрвакыт борчып килгән әхлак мәсьәләләре – намус, гаделлек, җирдә дөрес итеп яшәү, әти-әни һәм Ватан алдындагы изге бурычны үтәү кебек төшенчәләр мәңгелек, һәркем өчен уртак. Аларны үзеңдә булдыру өчен Кеше булу кирәк. Ә укучыларны Кеше итеп тәрбияләү – безнең һәрберебезнең бурычы.

## Татар әдәбияты дәресләрендә социаль-мәдәни компетенция формалаштыру

***Хәсәншина Зәйнәп Зәки кызы, Түбән Кама шәһәре***
***21нче урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

Әхлаклы кеше тәрбияләү – балалар бакчасы, мәктәп һәм башка уку йортлары алдында торган төп максат. Кызганычка каршы, инсафлылык, тыйнаклык, шәфкатьлелек, эш сөючәнлек урынына дорфалык, каршы әйтүчәнлек, ялкаулык күзгә күренеп арта.

Федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләре укытучы алдында шактый четерекле һәм җаваплы бурычлар куйды: урта гомуми белем бирү баскычын тәгәлләгәндә, укучының үзенә һәм үзенең әйләнә-тирәсендәге кешеләргә, тормыштагы яшәеш проблемаларына карата шәхси кыйммәтләр формалашкан булуы. Икенче төрле әйткәндә, бүгенге көн укучысы әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомүмкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирә; әхлакый кагыйдәләрдә ориентлаша, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңларга тиеш, дигән сүз.

Башка милләт вәкилләренең күңелен яулардай, аларда гомумкешелек әхлакый сыйфатлар тәрбияләрдәй татар әдәбияты өлгеләре белән таныштыру – татар теле һәм әдәбияты дәресләренең төп максаты. Тырыш, миһербанлы (гуманлы), кешелекле, сабыр (толерант), гүзәл холыклы, җәмгыятькә лаеклы һәм үрнәк шәхес тәрбияләүне бөек мәгърифәтчеләр, күренекле язучылар һәм шагыйрьләр хезмәтләренә таянып алып бару – бу максатка ирешүдә беренче адым дип саныйм.

Билгеле: рус телле балаларга белем һәм тәрбия бирүдә иң әһәмиятле компетенция – социаль-мәдәни компетенция. Татар халкының милли-мәдәни үзенчәлекләрен, этикет кагыйдәләрен өйрәтүне ничек алып барырга?

Татар халкының бөек әдипләре, галимнәре һәм мәгърифәтчеләре тормышы һәм иҗаты белән таныштыру – татар әдәбияты программасының төп таләбе. Минемчә, 5-7 нче сыйныфларда әхлак темасына караган тел материалы турыдан-туры мәгърифәтчеләр хезмәтләренә таянырга мөмкинлек бирә. Мин, бала кабул итәрлек итеп, билгеле бер калыпка салынган, гади стандарт библиографик белешмәләр булдырам. Ә "Мәгърифәтчелек хәрәкәте" темасы белән бәйле рәвештә К.Насыйриның, Р. Фәхреддиннең эшчәнлеге өйрәнелә. Шуңа күрә дәресләрдә "Яшик әдәп-әхлак белән, көнебез үтәр имин" дигән девиз астында эшләү турында кисәтәм.

"Гаиләмне яратам" темасын өйрәнгәндә, "Балаларга үгет-нәсыйхәт" китабыннан өзекләрне укыйм: "Сезгә иң якын кешеләр – ата-аналарыгыз. Шуның өчен аларга һәрвакыт итагатьле булыгыз» [1,15б.]. Туганлык мөнәсәбәтләренә багышланган дәресләр балаларга бик ошый. Алар, бик теләп, эти-әниләре ярдәме белән, гаилә агачы проектын башкаралар; дәрестә үз гаиләләре турында сөйлиләр. Бу эшнең максаты, беренчедән, рус телле укучыларның лексик-грамматик материалны үзләштереп, туганнар турында сөйләмгә чыгуы булса, икенчедән, язучы хезмәтләрендә күрсәтелгән "Туганнарыгыз белән һәрвакыт әдәпле һәм мәрхәмәтле булыгыз. Аларга ачык йөзле һәм киң күңелле булыгыз" [1,18б.] юллары мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек сыйфатларын тәрбияләүгә игътибарны юнәлтергә мөмкинлек бирә.

Программадагы 12 сәгатьлек “Бөтен эшне бергәләп эшлибез” темасының йомгагы да “...Кулыгыздан килгән эшләрдә ата-аналарга ярдәм итегез” [1,16б.] чакыруы белән тәмамлана.

Әхлак сыйфатлары тәрбияләүдә искиткеч зур роль уйнаган берничә темага күз салыйк. Мәсәлән, ”Әдәпле булу җиңелме?” бүлегенә караган “Кунакка йөри беләсеңме?”, “Табын янына рәхим итегез!”, “Кунак булсаң, тыйнак бул!” темаларына керешкәнче, русча текст тәкъдим итәм: “Воспитанный ребенок особенно ярко проявит себя за обеденным столом: займет место, указанное старшими и, не опираясь локтями на стол, терпеливо будет ждать, пока не подадут блюда, не торопясь будет есть. После трапезы он первым делом тщательно вымоет руки и прополощет рот и только после этого коснется чего-либо” [1,8б.]. Шуңа дәлил буларак берничә мисал:

| | |
|---|---|
| Ә.Гаффарның “Суалчан кунакка барган” әкияте. (Вакытында бармаганлыктан, Яңгырның Карга әйләнүе) | “Үзегез кунакка чакырылсагыз, билгеләнгән вакыттан соңга калмагыз” [1,46б.]. |
| Коля, кунакка килгәч, Алмазның әбисе белән елмаеп исәнләшә, өс һәм аяк киемнәрен тиешле урынга куя. Ә үз өенә кайткач, киресенчә эшли. | “...аяк киемнәрегезне, бүрек, тун кебек киемнәрегезне билгеле урынга куегыз” [1,23б]. |
| Мишаның Ленага туган көнгә килүе турында текст.(Миша ризыкны әнисенең башкача пешерүен әйтә, үзенең киңәшләрен бирә, бертуктаусыз сөйләп, кунакларны ялыктырып бетерә) | “Ашлар хакында бәхәсләшмәгез, теләгәнегезне ашагыз, теләмәгәнегездән гаеп тапмагыз” [1,44б.]. “Башкаларга сүз бирмичә, үзегез генә сөйләп утырмагыз” [1,51б.]. |

“Әдәп башы – матур гадәт” бүлегендә дә мондый мисаллар бихисап.

Күргәнебезчә, тәрбия өлкәсендә булган тәгълиматлар кешенең милләтенә дә, социаль хәленә дә карамый.

33 ел мәктәптә балаларга белем һәм тәрбия бирү тәҗрибәмнән чыгып, шуны ассызыклыйсым килә: мәктәптә укыту һәм тәрбия процессы аерылгысыз бер бөтен булганда, әти-әниләр, укытучылар һәм җәмгыять шәхесне тәрбияләүдә үзенең төп бурычын аңлап эш иткәндә генә, яхшы нәтиҗәләргә ирешеп була.

Әдәбият:


1. Ибраһимов Н. Балаларга үгет һәм нәсыйхәт.-Казан: "Матбугат йорты" нәшрияты, 2001.-192 б.
2. Нигъмәтуллина Р.Р. "Татарча да яхшы бел". Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең 5 нче классы өчен татар теле дәреслеге.- Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2014.
3. Фәхреддин Р. Җәвамигуль-кәлим шәрхе.-Казан: "Иман" нәшрияты, 1995.-439 б.
4. Хуҗиәхмәтов Ә. Мәгърифәт йолдызлары.-Казан: "Мәгариф" нәшрияты, 2002.-274б.
5. Хузиахметов А. Воспитание личности школьника.-Казан: "Матбугат йорты" нәшрияты, 2002.-224б.


## Г.Тукай иҗатында табигать темасы.


***Хөсәенова Гөлнара Халис кызы***
***ТР Алабуга районы МБУБ***
***учреждениесе «Урта белем бирү мәктәбе №10»***


Бормаланып аккан елга ярлары, дулкыннар ташкыны , шау урманнар, һәр үлән һәм чәчкәләрнең үзләренә генә хас үзенчәлекле тормышы,кар өстендә төрле төсмерләргә бизәлгән аксыллык,таң аткандагы җанлылык ,туган якның я ачы, я назлы җилләре-болар бар да табигый матурлык чыганагы, матурлыкның чынбарлыкта , ә чынбарлыкның матурлыкта чагылышы.Эзләнүләр,күзәтүләр, тикшеренүләр иң башлап әлеге чын матурлыктан башлана.Соклану,

нәфрәтләнү,сагыну һәм моңлану хисләре иң элек табигатьтә уяна.Тирә-юньдәге төрлелекләр,үзгәрешләр,төрледән-төрле авазлар,төсләр һәм формалар кешеләрнең игътибарын үзенә җәлеп итә, алардан ул үзенә үткен күзәтүчеләр хәзерли. Шәхесне формалаштыруда табигатьнең роленә зур бәя бирүчеләрнең берсе ,талантлы шагыйрь ,җәмәгать эшлеклесе һәм педагог Г.Тукай күп көч куйды.

Г.Тукай иҗатында кеше һәм табигать мөһим урыннарның берсен алып тора.Туган як табигате, аңа мәхәббәт, аның матурлыгын аңлау -югары кешелек һәм туган илне чиксез ярату хисләреннән аерылгысыз. Габдулла Тукай үз иҗатында табигатькә ямь өстәүче , аны җанландыручы кошларга зур урын бирә , аларны гөнаһсыз фәрештәләр белән тиңли . “Карлыгач” ,”Карга” , “Кошларга”, “Кошчык”, “Күгәрчен”, “Фатыйма белән Сандугач” шигырьләре аша шагыйрь балаларны кечкенәдән үк кошларны яратырга, аларга мәрхәмәтле булырга өнди. Кошларның табигатькә бик күп файда китерүенә басым ясый, аларның иркендә генә матур итеп сайрый алуын әйтә. “Фатыйма белән Сандугач” шигырендә читлектәге кош ирек турында:

Белмисеңме син: читен мәхбүслек ул,

Булса да алтын, һаман да читлек ул, - дип яза.[1:295]

“Кошларга” шигырендә исә: Әллә иркендә торуның кадерен белмимме мин?! – ди.[1:275]**.**

XX гасыр башында промышленность үсә башлый. Казан авыл кешеләрен җыя. Завод-фабрикаларда эшләү өчен кешеләр кирәк. Саф табигать кочагыннан шәһәргә килгән кеше тынчу, пычрак мохиткә эләгә. Бу хәл шагыйрьне борчуга сала. Сәнәгать үсеше табигый матурлыкка зыян китерә.Тукай моны ачы итеп “Казан” шигырендә яза:

Ут, төтен, фабрик-завод берлә һаман кайный Казан;

Имгәтеп ташласавын, сау эшчеләр сайлый Казан.[1:401]

Шагыйрьне бөтен “өязгә нур чәчеп” торган Казанның пычрануы, төтен, корымга күмелүе сызландыра.

Г.Тукай табигатьне ярата, аның һәр күренешенә, җан иясенә саклык белән, яратып карый. Кешеләрне дөрес яшәргә чакыра. Бүгенге көн белән генә яшәүнең табигатькә зур зыян салуын искәртә.

Бөек шагыйребез туган йортыбыз булган Җир һәм табигатьнең кешегә яшәү өчен матди мөмкинлекләр дә, иҗат өчен илһам да бирүен дөрес аңлаган. "Сагыныр вакытлар" шигыре үзе генә дә әдипнең җирдәге матурлыкның сагында торучы зур Кеше икәнлеге турында сөйли.

Шагыйрь күңеле табигатьтән илһам ала.

Бар күңел хәдсез, хисапсыз мәрхәмәт, шәфкать тулы.[1:357] Габдулла Тукай фикеренчә, кеше табигатьне яратырга, сакларга, аның белән хозурланырга, аның кочагына омтылырга тиеш. Шул чакта гына шагыйрьгә илһам килер.

Каршыларга иң сәза чак, иң матур чак, җәйге таң;

Шул вакытта уйла, шагыйрь: килде илһам уйласаң.-дип яза "Җәйге таң хатирәсе"шигырендә. [1:225] "Җир- һәр җанлыларның ризык бирүчесе һәм анасыдыр"-, дип язган автор "Җир"әсәрендә.Шуның өчен туган җирне, иң кадерле кешебез белән тиңләп, гаҗәеп итеп укучы күз алдына бастыра, төрле серле бизәкләр белән бизәп , җылы нурлар чәчеп торган әсәрләр иҗат итә . Эшемне йомгаклап, шуны әйтәсе килә: лирик әсәрләрдәге табигать күренешләре укучыларда матурлык тойгылары тәрбияләүдә, аларның фикерен үстерүдә һәм танып белү офыкларын киңәйтүдә гаять зур роль уйныйлар.

**Кулланылган әдәбият**

1.Тукай Г. "Туган авыл", Шигырьләр,әкиятләр, поэмалар.Татарстан китап нәшрияты, 1968,-511б.

2.http://nsportal.ru/shkola/rodnoy-yazyk-i-literatura/library/2013/01/28/tukay-izhatynyn-khzerge-vakytta-aktuallege

**“Әхлакый-экологик белем һәм тәрбия бирүдә әдәби әсәрләрнең әһәмияте”**

***Чукова Диләрә Раситовна***
***ТР Әгерҗе муниципаль районы муниципаль***
***бюджет гомуми белем бирү учреждениесе***
***Бертуган Бубыйлар исемендәге Иж-Бубый***
***гомуми урта белем бирү мәктәбенең***
***мәктәпкәчә яшьтәге балалар төркеме тәрбиячесе***

Кешелек җәмгыятен һәрвакыт борчып килгән әхлак мәсьәләләре – намус, гаделлек, җирдә дөрес итеп яшәү,табигатьне ярату, әти-әни һәм Ватан алдындагы изге бурычны үтәү кебек төшенчәләр мәңгелек, һәркем өчен уртак. Туган телгә, туган төбәккә, үз халкыңа, җир-суга мәхәббәт - халыктагы әхлак сыйфатларының иң бөеге. Бу сыйфатлар әдәби әсәрләр,әкиятләр, җырлар, уеннар аша, буыннан-буынга тапшырылган.

Әхлакый-экологик белем һәм тәрбия бирүдә әдәби әсәрләрнең әһәмияте зур. Язучыларыбыз, беренчеләрдән булып, табигатьне саклау турында чаң сукты. Әйләнә-тирә дөньяны, кеше сәламәтлеген, аның рухын, телен саклау аларны иң борчыган һәм дулкынландырган проблемага әйләнде. Нәфис сүз, сәнгать чаралары ярдәмендә кешедә югалып бара торган иң изге әхлакый-рухи кыйммәтләрне торгызу, Җир-анага игелек, хөрмәт хисләрен ууяту, кешелекнең экологик һәлакәт каршында торуында искәртергә кирәк иде.

Намуслылык, кешелеклелек, кайгыртучанлык, белемгә омтылыш, хезмәт сөючәнлек кебек сыйфатлар кечкенәдән үк тәрбияләнә. Балалар бакчасында безгә бу эштә әдәби әсәрләр ярдәмгә килә. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга экологик тәрбия бирү эшендә мин Г.Тукай әсәрләренә еш мөрәҗәгать итәм. Табигать ул – Ватан, туган як, туган туфрак.Тукай тасвирлаган табигать күренешләре яшь буында туган якка ихтирам хисе уята, күзәтүчәнлек тәрбияли, табигать күренешләре аша бай мәгълүмат бирә. Балаларга багышланган кайсы гына шигырен алма, алар һәммәсе дә укучыга үгет-нәсыйхәт, тәрбия бирүдән гыйбарәт. Балалар Тукай әсәрләрен яратып кабул итә. Аның әсәрләре ата – аналарга, тәрбиячеләргә, яшь буынга әхлак, хезмәт, физик һәм башка

юнәлешләрдә тәрбия бирү бурычларын гамәлгә ашырырга ярдәм итә. Тукай — балаларның үз шагыйре.Ул аларның телләрен,уй-фикерләрен,ниятләрен,эчке дөньяларын аңлый, аларча сөйләшә һәм иң әһәмиятлесе,алар дөньясында, тирәсендә яши алган. Тукай дөньяны да,табигатьне дә төрле күренешләрне дә сабыйлар карашы,сабыйлар акылы белән күзәтә белгән. Үзенең тәрбия өлкәсенә караган хезмәтләрендә кечкенә хикәятләр, шигырьләр, мәсәлләрнең тәрбия өлкәсендә файдалы булуына басым ясый. Шуңа күрә ул үзенең әсәрләрен тәрбияви максатны күздә тотып иҗат иткән. Тукайның осталыгы тагы шунда:ул уйларга ишеткәннәргә һәм күргәннәргә карата үз мөнәсәбәтен булдырырга урын калдыра.

Габдулла Тукай әсәрләре туган якка тирән мәхәббәт белән сугарылган,аның тәбигатенә,буынан буынга мәхәббәт һәм саклык.туган йортка,туган җиргә сабырлык, тырыш хезмәтнен кадерен белергә өйрәтә.дөньяга эстетик караш нигезләрен сала .

Тукай иҗаты белән танышкач, шундый фикергә киләсең: шагыйрь-табигать сакчысы. Ул аны ярата, аның һәр күренешенә, җан иясенә саклык белән, яратып карый. Кешене дөрес яшәргә чакыра.  Бөек шагыйребез “Экология” фәнен өйрәнмәсә дә яшәү йортыбыз булган Җир һәм анда яшәүчеләрнең тормышы өчен борчылган. Кечкенә дусларыбызны рәнҗетергә ярамаганны, аларның кешеләргә файда китерүен, табигый байлыкларны сакларга кирәклеген балаларга һәм яшь үсмерләргә аңлату өстендә эшләүнең кирәген белдергән.

Кыш көне кошларга җим кую, өйдә, бакчада җанлы почмак булдыру, андагы кошларны, җәнлекләрне ашату, эчертү, гөлләргә су сибү – болар барысы да билгеле, балаларда табигатьне саклау, тереклек ияләрен рәнҗетмәү, аларга рәхимле һәм шәфкатьле булу хисләре тәрбияли.

«Бичара Куян», «Гали белән Кәҗә», «Фатыйма белән Сандугач», «Кошчык», «Кошларга», «Карлыгач» – болар һәммәсе балалар, кошлар, җәнлекләр образлары аша бала күңеленә табигать һәм җәнлекләргә карата мәхәббәт хисе тәрбияли, сакчыл булырга өнди, кешелеклелек хисләре уята.

Г.Тукай үз иҗатында табигатькә ямь өстәүче аны җанландыручы кошларны гөнаһсыз фәрештәләр белән тиңли:  шигырьләре аша шагыйрь балаларны кечкенәдән кошларны яратырга, аларга мәрхәмәтле булырга өнди. Кошларның табигатькә зур файда китерүләрен аңлата, аларның иркендә генә матур сайрый алуларын әйтә.

Шулай итеп, Г.Тукай балаларга табигать күренешләренең асылын, хәтта кайбер очракларда аларның фәнни нигезен дә ачыклап килә. Кече яшьтәге балаларга табигатьтә һәр күренеш серле һәм кызыклы, һәрнәрсә – яңалык. Ел фасыллары, кошлар, җәнлекләр тормышы шушы чорда аеруча файдалы. Г.Тукай җирнең матурлыгын,һаваның сафлыгын саклау турыда уйланган, шул хакта күп кенә әсәр иҗат иткән. Шигырь фикеренчә дөнья матур, шул матурлыкны кеше үзе бетерә. Г.Тукай иҗатыннан табигатьнең бер мизгеле дә читтә калмый, ул аның һәр мизгелен, матурлыгын күрә, җаны-тәне белән тоя, табигатьнең бөтенлеген, анда кирәксез нәрсәнең булмавын балаларга аңлата..Матурлык дөньясын тою балаларда гүзәллеккә омтылыш хисе уята. “Бала белән Күбәләк” шигырендәге  Күбәләк сүзләренә бер генә баланың да битараф калганы юк. Бу юллар бала аңында шулкадәр тирән уелып кала, ул зур үскәч тә табигатьнең бу нәфислегенә кул күтәрә алмый.

Бала аңына яхшылык орлыгын ничек иртә салынса, шулкадәр отышлы була. Димәк, Тукайның иң гади шигыре дә бала күңелендә миһербанлылык тәрбияләргә сәләтле икән. Сабыйларда уңай геройларга охшау теләге искиткеч көчле.Шулай ук аның шигырьләрендә кешелеклелек, тере табигатьнең җан ияләренә мәрхәмәтлелек хисе белән сугарылганнар. Г.Тукай шигырьләренең тәрбияви асылы шунда.

Балалар өчен язылган кайбер әкиятләргә күз салыйк. Г.Тукай үзенең әсәрләрендә балаларны гаҗәеп серле табигать дөньясына алып керә.

“Шүрәле”, “Су анасы”, “Кәҗә белән Сарык хикәясе” кебек халыкчанлык белән сугарылган әкиятләрендә табигатьнең бөтен матурлыгы һәм серлелеге сыйдырылган. Автор үзенә генә хас алым һәм зур осталык белән балаларны табигать дөньясына алып керә, матурлыкны тоя белергә һәм күрергә өйрәтә.

Шагыйрь хайваннар дөньясына да битараф түгел, аларны ул дуслары, ярдәмчеләре дип саный. Һәркемгә билгеле булган “Гали белән кәҗә” шигыре генә чын дуслыкның үрнәге булып тора. Үсеп килүче буында табигатькә, аның тере почмагына карата мәрхәмәт иясе тәрбияләргә омтыла.

Табигатьне саклау темасына язылган әсәрләр исемлеге бай һәм төрле. Г. Тукай күп кенә шигырьләрендә җәнлекләрне, кошларны, бөҗәкләрне яратырга, аларга мәрхәмәтле, шәфкатьле булырга өнди, үзенең шигъри бизәкләре белән табигатьнең гүзәллеген ача. Табигатьне саклау – милләтебезне, туган телебезне, гореф-гадәтләрне, рухи һәм тарихи байлыкларны саклау белән тыгыз бәйләнгән. Чөнки туган тел, әдәби һәм тарихи мирас газиз җиребездә барлыкка килгән. Шуңа күрә балаларны татар халкының рухи тамырлары, ерак бабаларыбызның яшәү рәвеше, һөнәрләре белән таныштыру, аларда милли горурлык тәрбияләү мөһим. Табигатьнең матурлыгын, серлелеген Тукаебыз үзенең җаны, саф күңеле, йөрәк җылысы салынган шигъри юллары белән укучы җанына, аның күңеленә салучы, ныгытучы, мәңгеләштерүче.Шагыйрь үзенең шигырьләре әкиятләре аша сабыйларны туган телне, туган якны яратырга. Аның табигатенең гүзәллеген күрергә, аңа хозурланырга. Аны сакларга. Шигырләрендә тасвирланган табигать күренешләре аша . күзәтүчәнлек тәрбияли, бай мәгълүмәт бирә.

Кечкенәдән белем алырга , эш сөяргә, олыларга мәрхәмәтле, кечеләргә шәфкатьле булырга өйрәтә.

Литература:

1. Тукай Г. Сайланма әсәрләр: . - Казан: Татар.кит. нәшр., 2006.

2.Сайланма әсәрләр. Шагыйрь турында истәлекләр.- Казан:
Татарстан Республикасы ”Хәтер нәшрияты” (ТаРИХ), 2002.

3. Рәсүлова З. Тукай эзләреннән.-Казан,Тат.кит.нәшр., 1985

4. Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе.К.В.Закирова,Казан,2013

**Милли тел язмышы - милләт язмышы.**

*Шайхатарова Эльмира Гафуряновна,*
*преподаватель татарского языка и литературы*
*ГБПОУ «Мензелинский*
*сельскохозяйственный техникум»*

Татар теле язмышы турында соңгы дистә ел эчендә күпме язылды, күпме сөйләнде... Милләт телен югалта икән, ул милләт булудан туктый, дип юкка гына әйтмиләр бит. Туган телне саклау - ул һәрбер милләтнең бурычы. “Туган телне яклау, ана телен саклау - искиткеч четерекле мәсьәлә. Бүген Татарстан хөкүмәте, Мәгариф һәм фән министрлыгы туган телләрне яклау, саклау һәм үстерү буенча дәүләт программасының яңа вариантын булдыруга көч куя”,- дип билгеләп үтте үзенең чыгышында Татарстан Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Рәзил Вәлиев**.**

90 нчы еллар башында бездә шактый күп эш эшләнде кебек – милли мәктәпләр, балалар бакчалары ачылды, телгә игътибар да артты, киләчәккә өмет белән карарга нигезләр дә барлыкка килгән иде шикелле. Ләкин, ни кызаныч, борчыган мәсьәләләр күп кала. Белгәнебезчә, җир шарында бик күп телләргә бетү, яшәештән туктау куркынычы яный. Тел юкка чыктымы, шул телдә сөйләшкән халык та юкка чыга дигән сүз. 2002 нче елның 21 февралендә Парижда ЮНЕСКО штаб – квартирасында “Дөньяның юкка чыгу куркынычы алдында булган телләре атласы”ның киңәйтелгән яңа басмасы тәкъдир ителде. Планетабызда телләр яшәешенә иң зур куркыныч яный торган нокталар Россиянең төньяк өлешендә, Себердә, Кавказда да билгеләнгән. ЮНЕСКОның генераль директоры Коитиро Мацуура: “Барлык телләргә караганда, безгә дөньяны танып белүдә иң әһәмиятле ярдәмчебез булган тел, ягъни ана тел барыннан да мөһимрәк. Ул безнең балачагыбыз, гаилә тәҗрибәсе белән бәйләнгән. Алар – кадерле мирас һәм без аны сакларга тиешбез”, - дип кисәтә.

Тел сәясәтендә төгәл максат булып татар кешесендә милли горурлык, үзаң һәм җаваплылык тәрбияләү куелырга тиеш. Телебезне саклап калу өчен, мин шушы юнәлешләрдә хәрәкәт итәргә мөмкин дип саныйм.

1. Шәһәрдә чын татар мохитен булдыру. Татар мохитен булдыруны, нигездә, гади нәрсәләрдән башларга кирәктер. Шәһәрдәге барлык белдерүләр, барлык язмалар, Татарстанда җитештерелгән барлык әйберләрнең язулары ике телдә булырга тиеш. Кемдер әйтер: «Бу бит бары тик матди чыгымнарга гына китерәчәк, без барыбыз да русча яхшы аңлыйбыз», – дип. Кеше минем тирәдә ике тел яши, ул ике тел дә тормышта бертигез файдаланыла, дип уйлый башлый. Шул юл белән генә татар теле шәһәрдә үз урынын алып калачак, аның аерылгысыз элементына әвереләчәк.

2. Шәһәр халкына да, авыл халкына да кызыклы, яхшы татар телевидениесен булдыру – телне саклауда зарури бер шарт. Хәзерге көндә «Татарстан Яңа Гасыр» бу юнәлештә эшли, «ТНВ-Планета» дигән канал да барлыкка килде. Сыйфатлы, төрле темаларга багышланган, бар кеше кызыксынып карарлык тапшыруларны булдыру өчен, гыйлемле, үз эшләрен яхшы белгән журналистлар булырга тиеш. Дәүләт бер төркем яшьләрне шундый максат белән чит илләргә, Европага, Америкага берничә елга җибәрсә, телевидениедә уңай якка үзгәрешләр озак көттермәс иде. Ләкин бирегә бары тик сәләтле, эшләрлек кешеләр җибәрелергә тиеш. Телевидениенең хәзерге кешеләр тормышында тоткан урыны үлчәп бетергесез. Халкыбызның күпчелеге хәзер телевидение экраны аша тәрбияләнә, аның фикере экран аша формалаша.

3. Тагын бер актив үсә торган юнәлеш – интернет һәм компьютер технологияләре. Татар телен саклауда интернет гаҗәеп роль уйнарга мөмкин, чөнки яшьләрнең күбесе көне-төне интернетта аралаша. Инде үзгәрешләр дә күренә шикелле: татарча Twitter яки Facebook кебек иҗтимагый челтәрләр булдыру көн тәртибенә басты, хөкүмәт оешмалары, күбесе «үле» булса да, татарча рәсми сайтлар ача. Интернет челтәрендә татар телен саклауда максатчан эш-гамәлләр булырга тиеш. Анда татар телен пропагандалау, өйрәтүне киңрәк оештырсак, яшьләр өчен яңа мавыктыргыч сайтлар арттырылса, һәрбер татар газетасы, журналы, массакүләм мәгълүмат чарасы

үз сайтларын актив яшәтсә, татарча форумнар саны артса, интернет татар телен саклау һәм үстерү өчен алыштыргысыз бер мәйдан булыр иде.

4. Милли мәгариф һәм милли мәктәп язмышы һәр татарны борчыйдыр, мөгаен. Кызганыч, тулы канлы, нәтиҗәле эшли торган, балаларны һәм ата-аналарны җәлеп итәрлек татар мәгариф системасын булдыру барып чыкмады. Биредә төп ике сәбәпне атарга мөмкин. Беренчесе – милли мәгариф системасының балалар бакчасы, башлангыч, урта һәм югары мәктәптән торган барлык баскычлары булдырылмады. Татарча югары мәктәп юк һәм, күрәсең, булмаячак та. Милли университет проекты шактый кызыклы булса да, тормышка ашырылмады. Татар телен һәм әдәбиятын өйрәтә торган фәнни үзәкләрнең саны да киметелде. Икенче сәбәп – татар мәктәбенең яшәеше Россия дәүләте кысаларында алып барыла торган сәясәткә турыдан-туры бәйләнгән. Бердәм дәүләт имтиханнарын татарча тапшыруны тыю, милли телләрне, тарихны, мәдәниятне укытуга чик куя торган 309 нчы законны кабул итү – болар күп ата-ананы сагайтты. Милли телләр аңлы рәвештә мәктәп системасыннан кысрыклап чыгарыла.

5. Татар телен оныткан, ләкин татар үзаңын югалтмаган, үзләрен татар дип саный торган милләттәшләребез белән эш алып бару бик тә актуаль бурыч булып күренә. Татар телен белмәүчеләр саны бездә арта бара, ә без аларны кирегә борырга, яңадан татар мохитенә кайтару турында уйланырга тиеш. Кызыксынучылар өчен татар теле курслары оештырырга, рус телендә татар тарихы, теле, әдәбияты, мәдәни казанышларыбыз, бөек шәхесләребез турында сөйләп торырга мөмкин.

6. Татар теле, тарихы, мәдәнияте абруен арттыру өчен, тагын бер юл булып чит өлкәләрдә, чит илләрдә татар тематикасы белән шөгыльләнә торган галимнәргә игътибарны юнәлтү тора. Татар теле, әдәбияты, тарихы белән кызыксынучы галимнәр дөньяда аз түгел. Аларны Татарстан Республикасы чыгыш ясар өчен Казанга чакырса, безнең телевидение, газета-журналлар аша гыйльми эшчәнлекләре турында сөйләп торсалар, комачау итмәс иде.

Һәр кеше, бигрәк тә гаилә, татар шәхесләре булып, ана телен саклауда үзенең индивидуальлеген, йөзен сакласа, телне саклап калу, үстерү өлкәсендә үзеннән өлеш кертсә, милләт һәм телнең киләчәге ышанычлы булыр иде.

Әдәбият исемлеге

1. Абдуллина Р.С. Сөйләм культурасы. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2012. – 527 б.

2. ”Мәдәни җомга” газеталары №29, №30, №33 2014 ел.

3. Сафиуллина Ф.С. Тел гыйлеменә кереш. – Казан: “Хәтер”, 2001.

4. интернет чыганак :matbugat.ru

## Әдәбият дәресләрендә балаларга әхлакый-экологик белем һәм тәрбия бирү

***Шәйдуллина Фәндия Камил кызы, I кв.категорияле***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы,33нче мәктәп,***
***Шәйдуллина Рима Әхсән кызы,***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы,33нче мәктәп***

Безнең табигатебез матур. Киң кырлар, яшел, хәтфә болыннар, калын урманнар, саф сулы чишмәләр - болар барысы да безнең табигый байлыгыбыз. Җәен болыннарда төрле үләннәр, матур чәчәкләр үсә.Урманнарда гөмбә, җиләк, чикләвек. Рәхәтләнеп җый, файдалан. Кеше гомер буе табигать белән тыгыз элемтәдә яши. Табигатьнең язмышын хәл итә. Ул табигатькә төрлечә йогынты ясый. Уңай йогынты ясауга агачлар утырту, сулыкларны чистарту, хайваннар үрчетү керсә, кире йогынты ясауга агачларны кисү, сулыкларны, һаваны пычрату, үсемлекләрне, хайваннарны юкка чыгару керә. Табигатьне саклау–төп бурычыбыз.Заман алга бара дип сөенәбез.Промышленность үсә. Тик бу табигатькә зыян сала. Һава, сулыкларыбыз пычрана. Болар барысы да кеше сәламәтлегенә начар тәэсир итә. Безнең Түбән Кама шәһәре - нефть химиясе һәм нефть эшкәртү үзәге булып тора. Бу экологиягә зур йогынты ясый. Экологияне яхшырту мәсьәләсендә шәһәрдә елдан-ел күп эшләр эшләнә. Аның урамнарын, паркларын ел да яшелләндерү өстендә эшлиләр. Түбән Каманың 50 еллыгына бик матур “Гаилә паркы” барлыкка килде. Аннан тыш

Тукай паркыбыз, Кояшлы аланыбыз бар. Шәһәр матур, яшел. Язын шәһәр урамнарында ап-ак булып алмагачлар чәчәк ата. Без шушы матурлыкны саклый, балаларыбызга моны аңлата белергә тиешбез. Киләчәк буынга экологик белем бирүдә мәктәп зур роль уйный. Шәһәребездә Балалар экология һәм биология үзәге эшли, анда күп кенә экологик чаралар үткәрелә. Балалар интернет челтәрләрдә, телефонда утырырга яраталар. Кече яшьтән үк компьютерда уйнап үскән бала- агрессив, ә йорт хайваннары арасында үскәне тыныч холыклы була, диләр галимнәр.Табигать белән аралашуны кече яшьтән үк тәрбияләргә кирәк. Укучыны табигатьне яратучы гына түгел, ә аны саклаучы һәм яклаучы итеп тәрбияләү-төп бурычыбыз. Дәресләрдә экологик материал куллану - укытучының мөһим мәсьәләсе. Экологик бәйләнешләрне өйрәнү балаларның сөйләмен, логик фикерләү сәләтен үстерә, табигатькә сакчыл караш тәрбияли. Уку һәм татар теле дәресләрендә моның өчен мөмкинлекләр күп. Табигатькә багышлаган хикәяләр төзү, сочинениелар, изложениелар язу туган як табигатенә мәхәббәт тәрбияләргә булыша. Шулай ук картиналар белән эшләү дә туган як табигатен сакларга омтылу һәм экологик культура тәрбияләүгә ярдәм итә.Экологик тәрбия бирүдә табышмаклар, мәкальләр, сынамышлар, тизәйткечләр куллану да бик отышлы. Әхлакый-экологик белем һәм тәрбия бирүдә әдәби әсәрләрнең әһәмияте зур. Табигать ул-безнең өебез. Без чисталык, тәртип булдырырга тиешбез. Менә шул турда балаларга аңлатырга кирәк. Башлангыч сыйныфларның уку китапларында табигатьне саклауга караган материаллар бик күп. Мәсәлән, 4нче сыйныфта без герой-шагыйрь Муса Җәлилнең “Болында”,” Чишмә” дигән шигырьләрен укыйбыз. Муса Җәлил шигырьләрендә табигатьне ярату, соклану чагыла. Ул үзенең әсәрләре аша табигатебезнең байлыкларын арттырырга, сакларга куша. Шигырьдә саф сулы чишмәләребезне саклау проблемасы күтәрелгән. Дәрестә балалар белән үзебезнең яктагы чишмәләр турында әңгәмә үткәрелә. Нинди чишмәләр бар? Исемнәре ничек? Халык ни өчен шундый исемнәр биргән? Балаларны чишмәләр белән таныштырырга, ничек килеп чыгуларын аңлатырга кирәк. Чишмәләребезнең табигый байлык икәнен төшендерергә кирәк. Чишмә-

су һәм гүзәллек чыганагы, ял итү урыны. Су- могҗиза ул. Әби - бабаларыбыз чишмәләрнең байтагын изге дип санаган. Чөнки су кешеләрне авырудан коткарган, сәламәтлекләрен арттырган. Түбән Камада Изге чишмә дип аталган чишмәбез бар. Исеме җисеменә бик туры килеп тора. Бик матур урында урнашкан. Ял итү өчен уңайлыклар бар. Түбән Каманың туган көненә чишмә тагын да матурланды, төзекләндерелде, яңартылды. Укучылар белән бу урыннарга экскурсияләр оештырыла. Табигать белән якыннан аралашмыйча, табигатькә мәхәббәт тәрбияләп булмый. Бала мөстәкыйль рәвештә табигатьнең серләренә төшенергә тиеш. Ул табигатькә никадәр якынрак торса, аның күңеле шулкадәр үк чиста һәм сафрак була. Дөньядагы барлык җан иясенең дә яшәргә хаклы икәнен белеп үссен бала. Аларны яратырга, аларга мәрхәмәтле, шәфкатьле булырга өйрәнергә тиеш. 4нче сыйныф уку китабында табигатькә багышланган әсәрләр күп. Мәсәлән, Габдулла Тукайның "Шүрәле " әкиятен алыйк. Тукай баланы матур табигать дөньясына алып керә. Беренче юлларыннан табигатьнең никадәр матур, бай икәнен күрә укучы. Шул 4нче сыйныф уку китабында Рәшит Бәшәрнең "Сандугачлы ак инеш" шигырендә табигатьне, әйләнә - тирәне саклау темасы күтәрелгән. Балалар Ак инешкә нинди куркыныч янаганын әйтәләр, бу куркынычны булдырмау өчен нишләргә кирәклеген китереп чыгаралар. Шагыйрь ак сүзен кулланган. Ак ул чисталыкны, сафлыкны аңлата. Эчәр суыбыз чиста булу кирәк. Сулыкларны пычратмаска, агачларны сындырмаска кирәк дип гомуми сүзләр сөйләп йөрү генә әллә ни нәтиҗә бирми. Моның өчен үзеңә үрнәк күрсәтергә, ягъни агач утыртырга, су буйларын чистартырга кирәк. Сания Әхмәтҗанованың "Саклыйк, әйдә Җир-Ананы"дигән шигырендә табигатьне саклау проблемасы күтәрелгәне балалар белән китереп чыгарыла.Табигатьне нәрсәдән сакларга кирәк дигән сорауга җавап эзләнелә. Укучылар белән экологик проблеманы чишү юллары теләге дә уяныргa тиеш. Табигать темасына караган картиналар белән эшләү дә табигатькә мәхәббәт хисләре тәрбияли. 4нче сыйныфта Федор Александрович Васильевның ике картинасы белән эш алып барыла: "Яңгыр алдыннан" һәм "Юеш болын". Рәссам табигатьнең искиткеч матур якларын

күрсәтә. Картиналар аша укучылар табигатьнең матурлыгын күрергә өйрәнәләр. Игорь Эммануил Грабарьның “Февраль зәңгәрле” исемле картинасында кышкы табигатьнең матурлыгы тасвирланган. Агачлар җәен генә түгел, кышын да бик матур. Рәссам кышкы урманның бөтен матурлыгын күрсәтергә тырышкан. Уку дәресләрендә табигать темасына багышланган табышмаклар, мәкальләр, әкиятләр, мәзәкләр, мәсәлләр, сынамышлар шәфкатьлелек, миһербанлылык хисләре тәрбиялиләр. Дәресләрдә тестлар үткәрү,”Без табигать баласы” дигән темага проект эше эшләү дә бик файдалы. Кешегә яшәү өчен саф һава, чиста су, җир, кояш кирәк.

**Әдәбият**

1. “ Ватаным Татарстан” газетасы,2009 ел,16 ноябрь.

2. Интернет ресурслар.

3. Нижнекамск =Түбән Кама: альбом / [сос.В.Винников и др.; авт. Текста Г. Суздальцева]. – Казань: Идел-Пресс,2006.-143с.-Текст на рус. и татар яз.

4. “Туган як” газетасы,2008 ,26 ноябрь.

5. Ф.Ш.Гарифуллина, И.Х. Миассарова. “Әдәби уку” рус телендә башлангыч гомуми белем бирү оешмаларында белем бирү өчен дәреслеге (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 4 нче сыйныф, 1 - 2 нче кисәк. Казан, “Мәгариф - вакыт” нәшрияты, 2014 ел.

## Әдәби уку дәресләрендә әхлакый-экологик тәрбия

*Шәйхелмәрданова Чулпан Тавил кызы,*
*Минзәлә шәһәре 1нче урта мәктәбенең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы.*

Экологик проблемалар – кешелекнең иң мөһим проблемаларының берсе. Экологик тәрбиянең төп максаты – әйләнә-тирәне яратучы, аңа сакчыл караучы, гуманлы, иҗади шәхес тәрбияләү. Әхлакый- экологик белем һәм тәрбия бирүдә әдәби әсәрләрнең әһәмияте бик зур. Башлангыч сыйныфлар өчен уку китапларына табигатьне саклауга багышланган бай материал тупланган. Р.Х.Ягъфәрованың 2-3нче сыйныф өчен төзегән ”Уку китабы” нда һәр ел

фасылына караган бүлекләр бар. Ел фасыллары, аларның бер-берсеннән аерылып торуы, кабатланмавы, тере һәм тере булмаган табигать арасындагы бәйләнешләр турында ел дәвамында сөйләшәбез. Р.Х.Ягъфәрованың 4нче сыйныф өчен төзегән дәреслегендә "Табигать һәм без" бүлеге урын алган. Табигатьне саклауга багышланган әсәрләр баланың эмоция үсешенә йогынты ясый, тере организмнарга теләктәшлек белдерү,гаҗәпләнү, кызгану тойгылары, аларны үзенең кече туганнары итеп тою, әйләнә-тирәлекнең матурлыгын күрү хисләрен үстерә. Укучыларны дәресләрдә табигать күренешләре, үсемлек һәм җәнлекләр дөньясы белән таныштырабыз. Мәсәлән, Гарәфи Хәсәновның "Көзне инде җәнлекләр дә сизә..." , "Август" текстлары аша кайсы кошның кайчан җылы якка китүе һәм җәнлекләрнең кышка әзерләнү, әзеләнмәүләре турында мәгълүмат бирелә. "Кем көчле?" исемле татар халык әкиятендә кеше иң көчле, иң акыллы булып кала. Ләкин кешенең көчлелеге табигатьне буйсындыруында түгел, ә аның табигатьне яклый һәм саклый белүендә. Безнең бурыч: менә шушыны укучының аңына җиткерү. Р.Хафизованың "Песнәк", "Күгәрчен һәм малай", К.Тәхауның "Гыйнвар" хикәяләре кошларга сакчыл караш, ярдәм итү теләге уята. Яраткан шагыйребез Г.Тукай бик күп шигырьләрендә җәнлекләрне, кошларны, бөҗәкләрне яратырга, аларга мәрхәмәтле, шәфкатьле булырга өнди, үзенең шигъри бизәкләре белән табигатьнең гүзәллеген ача. "Яз галәмәтләре", "Җир йокысы", "Бала белән күбәләк", "Карлыгач" , "Фатыйма белән Сандугач" һ.б. шигырьләрендә бу ачык чагыла. Аның "Кояш", "Һава", "Су", "Җир", "Елның дүрт фасылы" исемле кечкенә хикәяләрендә табигать турында шактый мәгълүмат тупланган. Герой-шагыйрь Муса Җәлилнең "Көз җитте", "Күке", "Әтәч", "Маэмай" шигырьләре дә кош-кортларга, хайваннарга, туган як табигатенә мәхәббәт тәрбияли. Дәреслектә бирелгән Р.Вәлиеваның – "Кыңгырау чәчәк", Ф.Монасыйповның – "Табиблар", Л.Зөлкәрнәнең "Бичаралар һәм бичуралар" әсәрләрен эхлакый-экологик белем бирүдә уңышлы файдаланырга кирәк.

Кайсы авторның дәреслеген алсаң да, халык авыз иҗатын өйрәнүгә зур урын бирелгән. Әкият, мәкаль, әйтем, сынамыш һәм табышмакларда күп кенә

экологик мәгълүмат бирелгән. Бу чыганакның төп өстенлеге шунда: белемнәр балаларга мавыктыргыч рәвештә җиткерелә. Мәсәлән, кече яшьтәге мәктәп балалары ярата торган бер табышмак:

Җәен – соры, кышын – ак,

Аңа шулай яхшырак.

Бу табышмакта куянның ел фасыллары алмашуына карап,табигатьтә ничек җайлашуын күрергә була. Табышмакларны теләсә кайсы дәреснең уңайлы моментын табып файдаланырга була. Аларны кулланып, кроссвордлар төзергә мөмкин. Халык авыз иҗатының икенче бер төре - мәкаль. Мәкальләр арасында табигатькә багышланган һәм экологик тәрбияне күз алдында тотканнарын сайлап, дәресләрдә куллану, аларның асылын укучыларга җиткерү дәреснең нәтиҗәлелеген күтәрә, аларда игелекле эшләр башкарырга омтылыш уята. Мәсәлән, ”Суга сусаган - чишмә әрчегән”, “Агач утырткан - ага булган”, ”Кул пычранса, су белән юарсың, су пычранса ни белән юарсың?” һ.б. шундый мәкальләрдән уңышлы файдаланабыз.

Л.Зөлкәрнәйнең “Бичуралар һәм бичаралар” тексты белән танышканда татар халкында булган төрле табынулар, ышанулар белән дә таныштырып китәргә кирәк. Чөнки халкыбыз төрле табынулар, ышанулар ярдәмендә кешеләрнең табигатьтә үз-үзләрен тоту кагыйдәләрен эшләгән.Мәсәлән, мондый әйтем бар: ”Кош оясын туздырсаң, башың авыртыр”. Кем инде үз башының авыртуын теләсен. Бала-чагалар, күктә очучы кошларны күреп, саный башлыйлар.Монда да әби-бабаларыбыз кисәтә: ”Кыр казларын санасаң, алар аерылып кала”. Кыр казларының аерылып адашып йөрүе кызгану хисе уята, шунда ук санаудан туктыйсың. Урман-суларны, мал-туарны, йортны саклаучы ияләргә ышанулары да табигатькә зарар китерүдән саклаган.Үз халкыңның яхшы гадәтләрен оныту табигатькә зур зыян сала. Укучыларга түбән сыйныфларда ук әби-бабаларыбызның табигать байлыкларыннан бик сак файдаланулары турында аңлатырга кирәк. ”Әгәр дә кешеләр табигатькә, мохиткә зыян китермичә генә матди байлыклар тудырырга өйрәнмәсә, җир йөзеннән кеше үзе дә юкка чыгарга мөмкин” дигән хакыйкатьне күптән аңлаган

әби-бабайлар беркайчан да үз ихтыяҗларыннан артык җәнлек ауламаганнар, балык тотмаганнар. Ау вакыты башланганнан соң, беренче тотылган җәнлекне яки балыкны “Урман иясенә”, “Су иясенә”атап, кире җибәргәннәр, яшь агачларны кисмәгәннәр.

Укучыларга экологик тәрбия биргәндә Стандарт таләпләрен күз алдында тотарга кирәк. Яңа стандартларның төп максаты – шәхес тәрбияләү, баланың сәләтен күрә белү, аны үстерүгә ярдәм итү, иҗади баскычка күтәрү. Бу максатларны тормышка ашыруда проект һәм фәнни тикшеренү эшләре бик файдалы. Уку дәресләрендә танышкан әсәрләр өстендә эшләгәндә проект эшләре өчен темалар килеп чыгып тора. Мәсәлән, К.Насыйриның “Шифалы үләннәр”, В.Монасыйповның”Табиблар” хикәяләре белән танышкач “Файдалы үсемлекләр” темасына укучылар проект эше эшләделәр. Ә.Халидовның “Кырмыскалар” әсәрен укыгач “Кырмыскалар урманга нинди файда китерә?”дигән темага, Р.Хафизованың “Песнәк” хикәясен, Г.Лотфинең “Сыерчык” шигыре белән танышкач “Кошлар- безнең дусларыбыз” темаларына проект эшләре башкардылар. Тема буенча бай мәгълумат туплап, нәтиҗәләр ясадылар. Шулай итеп, бала үзе эзлекле рәвештә белем тупларга күнегә.

Бүгенге тормышта табигатьне экологиядән, экологик проблемалардан башка гына күз алдына китерүе кыен. Шуңа күрә экологик тәрбия – уку дәресләренең аерылгысыз бер өлеше.

Кулланылган әдәбият:

1.Садыйкова М. Укучыларга эхлакый-экологик тәрбиябирү.Мәгариф, 2002.-№4.-Б.34-36.

2.Сайтлар.

## Фоат Садриевның “Таң җиле” әсәрендә ана образлары аша әхлак тәрбиясенең бирелеше

*Шәйхуллина Зилә Насыртдин кызы,татар теле һәм әдәбияты укытучысы, Мөслим*

Фоат Садриев “Таң җиле”, “Оҗмах ишеге төбендә”“Их сез, егетләр!”, “Ач тәрәзәң”, “Кондырлы кодачасы”, “Тозлы бал”, “Безнең авыл кызлары”, “Аяз көнне яшен” кебек матур сәхнә әсәрләре авторы да.  Ф.Садриев – танылган прозаик. Аның каләме белән күпсанлы хикәяләр, юморескалар, повестьлар язылган – “Шаһзаманов эше”, “Зөбәйдәнең күңел дәфтәреннән”, “Рәхмәт, этием!”, “Көлми торган кеше”шундыйлардан.

Ана — ул дөньяда иң бөек кеше. Бик күп күренекле шәхесләрне, галимнәрне, укытучылар, табибларны ана тудырган,тормыш мәгънәсен, яшәү ямен дә балаларына алар биргән.Гаиләдә әхлак тәрбиясе дә аналардан башлана. “Ана сөте белән кермәсә,тана сөте белән кермәс”.Тәрбия һәм әхлак мәсьәләсендә бу мәкаль кире кага алмаслык гыйбарәне үз эченә ала.

Тәрбия балага ана карынында ук бирелә башлый. Ана баланы тугыз ай буе үзенең карынында күтәреп йөртә, тудыра, бала тугач, ул аңа үзенең күкрәк сөтен имезеп, төн йокыларын калдырып үстерә. Кичләрен баласына бишек җырлары җырлый, әкиятләр сөйли, баланың күңеленә мәрхәмәтлелек, киң күңеллелек орлыклары сала.

Бала үсә, мәктәпкә йөри башлый. Ана аңа дәресләрен әзерләргә булыша, йорт эшләрен карарга, пешеренергә, чигәргә-бәйләргә, үз-үзен тотарга, кешеләр белән матур, ягымлы итеп сөйләшергә өйрәтә. Бала үсеп кеше була,  үз баласын шулай ук тәрбияли, бар көчен, энергиясен баласын үстерүгә бирә. Бер көнне карый, аның әнисе дә баласы кебек үк тәрбиягә мохтаҗ икән бит. Менә шушы вакыйга, шушы проблема кешеләрне икегә аера да инде: кайберләре гомере буе эти-әнисенә рәхмәтле булып, үзенә булган хөрмәтне, тәрбияне аларга да күрсәтә, аларның фатихасын ала, ә кайберләре исә моны кирәк санамый, һаман дөнья кууын белә. Бәлки оныта торганнардыр, ана рәнҗеше бетми бит ул, гомер буена эзәрлекли.

Бик күп язучыларыбыз үзләренең әсәрләрендә Ана образын ачу аша балаларда әхлаклылык сыйфатларын чагылдырганнар. Мәсәлән, Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыять», Туфан Миңнуллинның «Әниләр һәм бәбиләр», Муса Җәлилнең «Ана бәйрәме», Рәшидә Җиһаншинаның «Улларым» спектакльләрендә бу бик ачык чагыла.

Фоат Садриевның “Таң җиле” романында сүрәтләнгән тәрбияле, кешелекле балалар тәрбияләүче Нуриасма һәм әсәрдәге башка ана образларына тукталырга

Әсәрнең төп герое – Нуриасма.Ул авылның дәрәҗәле кешесе дә, тырыш колхозчы да, гаилә башы да, һәм иң мөһиме – АНА..

Бу сүзне зур хәрефләр белән белдерәм, чөнки ул моңа лаек.Тормышта үз урынын тапкан, чын мәхәббәткә ия булган Нуриасма.Беренче чиратта үзен түгел, якыннарының бәхете өчен яшәүче татар хатын – кызы.

Татар халкында шундый әйтем бар:”Ир – баш, хатын – муен”. Муендагы башны үз югарылыгында тотучы, кирәкле юнәлештә генә боручы муен.Үзе әхлак ягыннан тәрбияле, намуслы һәм тәртипле булганда гына, кемгәдер үрнәк була аласың. Ә безнең тәрбиябез, динебез хатын – кызны тыйнак, үз хисләрен йөгәнли белүче, чиста, пөхтә, зур йөрәкле итеп яраткан һәм тәрбияләгән.

Минемчә, бу сыйфатлар Нуриасмада кирәгеннән артык.Шулай булмаса, үзенең төп яшәү урыны, җылы почмагы булмаган ямь-яшь кыз бала кеше баласына, ягъни Фәриткә ана була алыр идемени?! Артык тыйнак, үз хисләрен тышка чыгармаучы, шуның нәтиҗәсен үз йөрәге аша үткәрүче(Сәгыйдулланың аны Хәдичәгә алыштыруы), гаилә иминлеге, тулылыгы өчен янучы:өч малай һәм бер кызга яраткан әни булган соклангыч татар хатыны образы. Гаиләсенең таркала баруын, иренең чит хатынга ияләшүен вакытында күреп алып, бар яратуын, хисләрен, назларын бу эшкә җигеп,тормыш иптәше Сәгыйдулланы кабат үзенеке итүче яраткан хатын ул Нуриасма. Гаилә башында шундый ана торганда гына, кешеләр алдында хөрмәткә лаек булып гомер итәргә, балаларың күзендә соклану,сиңа охшарга тырышу чаткылары күрергә була.

Тормыш матур гына, шома гына бармый . Нуриасма да, яраткан тормыш иптәшен югалта. Ул бу сынауны,балаларын тәрбияләүне дә уңышлы тапшыра: уллары һәм кызы аның йөзенә кызыллык китермичә,үсеп кеше булалар - үз юлларын табалар.

Нуриасма бик кырыс ана.Ялгыз ана өчен бу сыйфат бик мөһим: чөнки балаларны кеше итәсе бар.Нуриасма - чын тәрбия остасы. Аның балалары тырыш та, уңган да, гадел дә, туры сүзле дә, намуслы да булырга тиеш.

Әсәрдә Нуриасма – әхлаклы, ана исеменә лаеклы образ.Бу образны тулысынча ачу өчен, автор безне әсәр барышында төрле холыклы ана образлары белән очраштыра.

Нуриасма образын үз югарылыгына күтәрүче образ – күршесе, аның көндәше - Хәдичә. Бу образ Нуриасманың сабыр, олы йөрәкле икәнлеген тагын бер кат раслый.Үзенең көндәше булса да , белгәнен сиздерми , соңгы көнгә кадәр бу хыянәтне йөрәк түрендә саклаучы, үзендә бәхиллек бирерлек көч тапкан олы йөрәкле кеше бит ул Нуриасма.

Хәдичә дә үзенең улын чын күңелдән ярата, чөнки ялгыз үстергән.Тормышның мәгънәсе,бөтен яшәү яме - аның улы; кыен вакытларда яраланган йөрәкләргә дәва бирүче, күңеленне бушатырлык сердәш Гыйздениса - сабырлык йомгагы;бөтен гомерен, тырышлыгын гарип кызына багышлаган тагын бер ана – Маһинур- унике сум пенсия алуына карамастан, тормышка зарланмыйча, бар булганына сөенеп яшәүче ана;аш – суга осталык Мосаллия образы аша чагыла. Ул үзенең мәхәббәтен һәм уңганлыгын кызына да биргән.Күңеле матур кешенең генә аш – суы тәмле була.Бу юлларда Мосаллиянең бөтен тормыш юлы чагылыш тапкан.

Уртанчы буын аналары үзләренең балаларына булган мәхәббәтләре,өлкәннәрдән үрнәк итеп алган тәрбия ысулларын кулланулары белән калышмыйлар. Нәсимә - Нуриасманың олы килене, шулай ук үз баласын чын күңелдән яратучы ана,баласын тәрбияле итеп үстерәсе килә.

Тормыш гел аклыктан гына тормый.Гаиләдә яхшы тәрбияне үз тормыш юллары аша үрнәк итүче аналар белән янәшә, матур,рәхәт тормыш яратучы

җилбәзәк ана образлары да сурәтләнә.Болар: баласыннан котылучы Бәрия, якты дөньяга тудырган, ләкин аның барлыгы, исәнлеге турында уйлап та карамаган Газыялар. "Оясында ни күрсә, очканында шул булыр",-ди татар халык мәкале.Үзендә булмаган уңай сыйфатларны ничек балаңа бирә аласың? Тормышыбызда мондый мисаллар бик күп. Балалар йортлары, аларда аналы, ана назыннан, йомшак сүзеннән мәһрүм күпме ятимнәр.

Бер- берсенә хөрмәткә,ихтирамга ,игътибарга корылган гаиләләрдә бары тик тәрбияле, үзен чолгап алган мөхитне һәм кешеләрне хөрмәт итүче балалар гына туа.


Файдаланылган әдәбият.

1.Әхсән Шәрипов. Яшәү көче табарсың.

2. Галимуллин Ф. Гыйбрәтләр алсак иде… Казан утлары. – 1993.

3.Мостафин Р. Бәхетлеләр һәм бәхетсезләр . Казан утлары.– 2002..

4..Журналның Фоат Садриев иҗатына багышланган махсус саны . Мәйдан. – 2004.

5.Фоат Садриев "Таң җиле".Татарстан китап нәшрияты.1994


## Экологик белем һәм тәрбия бирүнең әһәмияте


***Шәмиева Фәридә Махубрахман кызы***
***Түбән Кама шәһәре 33 нче урта мәктәбенең***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы***


Башланып киткән 2017 ел - экология һәм әйләнә - тирә мохитне саклау билгесе астында уза.

Экология - дөньякүләм әһәмиятле, мөһим мәсьәләләрнең берсе булып тора. Ул үзенең актуальлеге, үткенлеге белән бүген бөтен кешелек алдына килеп басты, чөнки киләчәк буыннар язмышын фән-техника казанышлары түгел, ә җир-суларның экологик торышы хәл итәчәк, җитештерү эшчәнлегенен тизлеге арткан саен, экологик проблемалар күбәя бара. Күп еллар буе табигать байлыкларын аңсыз һәм аяусыз файдалану урман, болыннарның коруына,

үсемлек җәнлекләрнең юкка чыгуына, елга-суларның кибүенә яки агулануына, чүлләрнең артуына китерде.

"Кешенең борынгыдан килгән гуманлы карашларына, гореф-гадәтләренә, еллар буена сыналып килгән тормыш тәҗрибәсенә хилаф килердәй, аны рухи, әхлакый яктан рәнжетердәй башабаштаклык ахыр чиктә табигатькә дә зарар булып төшә" дип язган яраткан язучыбыз Гомәр ага Бәширов.

Җирдә тереклек бетүне бары тик ике юл белән булдырмый калырга мөмкин: берсе хөкүмәтнең катгый, кырыс кануннары ярдәмендә табигать чисталыгын саклау булса, икенчесе - кешеләрдә экологик культура тәрбияләү. Димәк, табигатьне киләчәк буыннар өчен саклап алып калу, балаларга экологик тәрбия бирү, туган җиргә, туган табигатькә мәхәббәт тәрбияләү аша аларны уртак йортыбыз - Җирнең мәрхәмәтле һәм сакчыл хуҗалары итеп үстерү - төп максат булып тора.

Бу эш табигатьне күзәтә, аның матурлыгын күрә белергә өйрәтүдән башлана һәм аңа карата сакчыл караш , мәхәббәт уятуга нигезләнә. Яшьтән үк әйләнә - тирә, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы белән таныш булмаган кешедә мондый тойгылар тәрбияләү бик кыен.

Әгәр без укытучылар, ата- аналар - балаларны кечкенәдән үк табигать күренешләре белән кызыксындырып, һәрбер тереклек иясенә мәхәббәт хисен тәрбияләсәк, аларга карата мәрхәмәтлек хисен уята алсак, балалар зур үскәч, тирә - юньгә яхшы мөнәсәбәттә булырлар дип әйтә алабыз.

Экологик тәрбия баланың җиргә тәүге тапкыр тәпи басуыннан, үзен уратып алган дөньяга  тәүге адымыннан ук башланырга тиеш. Гаилә һәм балалар бакчасында салган нигез мәктәптә ныгытыла, системага салына.

Мәктәптә туган җир, туган ил кебек изге төшенчәләр формалаштыруда туган тел һәм әдәби уку дәресләре төп роль уйный. Шуңа күрә гамәлдәге программа һәм дәреслекләрдә укучыларны безне уратып алган үсемлекләр дөньясы, җәнлекләр, кош - кортлар, йорт хайваннары һәм кошлары белән таныштыру, мәктәпкәчә булган белемнәрен арттыру, киңәйтү максатында башлангыч мәктәпнең 1-4 сыйныфлары өчен чыгарылган “Әлифба”, “Әдәби

уку” дәреслекләрендә урын алган күп кенә шагыйрьләребез әсәрләре дә экологик теманы күтәреп чыга. Шигърияттә бу темага урын бирмәгән шагыйрьне табуы кыендыр. Табигать темасына язылган шигырьләр исемлеге бай һәм төрле.Әлеге әсәрләр балаларны табигатьне аңларга, яратырга, аның байлыкларына сакчыл караш формалаштырырга, туган җирнең кадерен белергә өйрәтә. Шулай да мәктәп дәреслекләрендә зур урын бирелгән кайбер шәхесләребезне аерым әйтеп китү кирәктер: А.Алиш, Х.Туфан, Ш.Галиев, Р.Вәлиева һәм башкалар шигырьләрендә җәнлекләрне, кошларны, бөҗәкләрне яратырга, аларга мәрхәмәтле, шәфкатьле булырга өнди, нәфис сүз, сәнгать чаралары ярдәмендә Җир-анага игелек, хөрмәт хисләрен уяталар, шигъри бизәкләре белән табигатьнең гүзәллеген ачып, кешелекнең экологик һәлакәт каршында торуын да искәртәләр.

Табигатьнең матурлыгын, серлелеген Тукаебыз үзенең җаны, саф күңеле, йөрәк җылысы салынган шигъри юллары белән укучы җанына, аның күңеленә салучы, ныгытучы, мәңгеләштерүче.

"Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә,

Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем".

(Г. Тукай. "Туган авыл")

Укытучы “Экология елы” кысаларында дәресләр үткәргәндә, әлбәттә, дәреслектәге әзер материал белән генә чикләнми, табигатькә экскурсиягә чыга, вакытлы матбугаттан файдалана, халык авыз - иҗатына мөрәҗәгать итә.

Халкыбызның табигать күренешләре, ел фасыллары, бөҗәк, кош, җәнлекләр турында күпме табышмак, әйтем, сынамышлары бар. Мәсәлән:

“Бер йомгакта мең энә,

Сиңа тими, син тимә”. *(Керпе)*

Укучыларда экологик белем һәм тәрбия бирүдә мәкаль-әйтемнәрне куллану да уңай нәтиҗә бирә.

"Кул пычранса, су белән юарсың,

Су пычранса, ни белән юарсың".

Халкыбыз су турында нинди зирәк фикер әйткән.

Дәресләрдән тыш чаралар, балалар белән төрле экологик бәйрәмнәр үткәрү - табигатькә икенче төрле күз белән карарга, табигать өчен безнең дә җаваплы икәнебезне аңларга ярдәм итә. Шундый бәйрәмнәрдән:

“Урманда көзге бәйрәм”, “Уңыш бәйрәме” , “Кошлар көне”, “Нардуган”, “Нәүрүз”, “Урман – зур байлык” һ.б. әйтеп узарга мөмкин.

Гомумиләштереп әйткәндә, “Экология елы” кысаларында каралган иң мөһим эш төре - укучыларга экологик тәрбия бирү, аларда һәр чәчәкне , үләнне, һәр тереклекне кызыксынып күзәтү аша туган як табигатенә мәхәббәт, сакчыл караш тәрбияләү.

Кулланылган әдәбият:

1. Низамов А.М. Милли мәктәп тәрбия нигезләре.- Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2005ел.

2. “Мәгариф” журналы, №11,2002 ел.

3. Җәләлиев Ш.Ш. Татар халык педагогикасы. –Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2000 ел.

## Харрас Әюп шигырьләре аша балаларда әхлаклылык тәрбияләү

***Шәрипова Илсөя Насих кызы***
***1 нче квалификацион категорияле татар теле***
***һәм әдәбияты укытучысы***
***Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы***
***Дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе***
***“Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен***
***Түбән Табын мәктәп-интернаты”***

Beребезгә дә сер түгел: татарны татар итә торган, аның телен, моңын, йолаларын һәм гореф-гадәтләрен бозмыйча диярлек саклый торган төбәкләр бик аз калып бара. Гүзәл табигать кочагына һәм ямьле Ык буена сыенып урнашкан Мөслим районы шундыйлар исәбендә. Моңа ышану өчен бу төбәктән Зөлфәт, Фоат Садриев, Факил Сафин, Флүс Латыйфи, Наис Гамбәр, Шәмсия Җиһангирова, Лилия Садриева, Асия Минһаҗева кебек танылган әдипләрнең

чыгуын телгә алу да җитә торгандыр. Кечкенә Түреш авылы татар әдәбиятына 3 шагыйрь – Харрас Әюп, Ләбиб Лерон, Мөҗәһит Әхмәҗановны бирде. Түреш татар сәнгатенә Г.Камал театрында берсеннән-берсе матур, җырлы рольләр башкарган Татарстанның халык, РСФСРның атказанган артисты Наил Әюповны бирде. Минем язмамның герое якташым шагыйрь Харрас Әюп тә шушы якның бәрәкәтле туфрагыннан үсеп чыккан талант иясе. Сүземне шагыйрьнең исеме дә җисеменә туры килеп торуына игътибар юнәлдерү белән башлыйсым килә. "Харрас" дигән гарәп сүзенең мәгънәсе – саклаучы, яклаучы. Ялкынлы иҗаты белән Табигатебезне һәм Милләтебезне яклаучы Мөслим егетенә бу исемне Ходай үзе иңдергәндер кебек.

Туган як табигате сабый яшендә үк балигъ булган Харраска бөтен барлыгы белән теләктәшлек итә: "җил яшьләрен сөртә","җәйләр елаган җанын җылыта", "урман киемен салып бирә", "тугайлар җиләкле паласын җәя", "күкеләр сөю-сагыну телләренә өйрәтә". Шагыйрь булгач та табигать баласы булып калуына һәм кешене табигать белән "үлчәп" язуына гаҗәпләнергә кирәкми. Үзенең кылган һәм кылачак эшләрен дә ул табигать бизмәне белән исәпли:

Хыянәткә барсам, тау ишелер,

Нәкъ урталай ярылыр бу болын,

Имәннәрне давыл йолкып ташлар,

Барысы бергә дәшәр:

- И-и-их, улым! [1,11 б.]

Кеше белән табигать берлегенең иң көчле гәүдәләнгән формасы, әлбәттә, ике арадагы кардәшлекнең һәм гармониянең сурәтләү объекты булып әверелүендә. Шагыйрь образы безнең алга табигатьнең, туган як туфрагының телен һәм серләрен белүче тылсым иясе булып килеп баса.Үз сүзләре белән әйткәндә, ул "кояш нурларында пәрәвез тирбәлүен ишетә", "гөлләрдәге күбәләкне укый", "җилләр җырын тыңлый", "камыш белән серләшә", "сандугач кайгысыннан җылый". Ләкин әлеге шигырьләрдән бөтенләй көтелмәгән саллы нәтиҗә дә чыга: табигатьнең серен кешенең үзеннән эзләргә кирәк! Әйе, дөньяда иң зур сер булган, табигатьнең серләрен дә үзенә җыйган Кеше

галиҗәнапларыннан эзләргә. Минемчә, кешенең табигатен аңлау һәм ачу өчен Х.Әюпнең нәкъ менә табигать белән кеше мөнәсәбәтенә игътибар итүе һәм маңгай күзе белән генә түгел, ә күңел күзе белән дә ике арада ассоциатив уртаклыклар күрүе бик табигый. Мәсәлән, ул шигъри моңының беренче башлап үз авыллары очындагы “Куш чишмә төпләреннән агып чыгуы” һәм “җирдә яшәсә дә, күкрәгендә барыбер кош булуы ” турында яза, я булмаса халкы “бәгыренә еллар тигәндә агач булып агачларның да ыңгырашып авуын” тасвирлап, “адәм башларыннан йөргән кайгы йөрер икән агач башлап та” дигән көтелмәгән нәтиҗә чыгара.

Шагыйрь табигатьне гаҗәеп дәрәҗәдә авыл темасы белән бергә үреп сурәтли. Чөнки ул мөкиббән китеп туган авылына, туып-үскән җиренә гашыйк кеше. Дөрес, заманында әлеге авыл әнисе ягыннан указлы мулла булган бабасының (дәү әтисенең) нахакка кимсетелүенә, “кулак” дип үз өеннән куып чыгарылуына шаһит булган. Шулай ук өйләренең янгыннан исән калган имән капка баганалары да Харрас әнисенең “кулак нәселе” дип кыерсытылуларын күреп торган (“Капка баганасы турында баллада”). Әмма тора-бара барысы да үз урынына утырган. Укымышлы бабасы һәм соңыннан, төпләнеп, әти-әнисе яшәгән нигез Харрас өчен иң изге урын булып калган. “Ата йорты – бала өчен кыйбла”, “кыйбламны мин – туган туфрагымны бүтән кыйблаларга алмашмам” – менә шагыйрьнең горурланып белдергән хикмәтле фикер йомарламы. Авыл Харрас кебек малайларны кирпеч сукканда калыплаган, печән чапканда чарлаган, ат өйрәткәндә тезгенләгән, кичке уеннар вакытында җырга-биюгә, күңел ачарга өйрәткән. Күктәге Ай да шагыйрьнең “яшьлек сердәше”, “Кояш исә – һич тә гаҗәп түгел – аның “авылдашы”.

Әмма Харрас өчен авыл образы белән үрелгән иң җылы һәм иң якты Кояш, әлбәттә, Ана образы. Гел яхшылыкка, намуслы һәм шәфкатьле булырга өндәгән һәм өйрәткән газиз аналар – безнең барыбыз өчен дә изге җан. Менә шул бөек затны шагыйрь тере һәйкәл итеп пьедесталга менгерә һәм күңелендәге иң җылы хисләргә төреп, аңа дан һәм мәдхия җырлый. Кешелек вөжданын гәүдәләндерүче ана образы туган йорт, Ватан, халык, милләт төшенчәләре

белән кушылып китә һәм зур символик мәгънәләр ала.  Ана образы шагыйрьгә иң җете, иң тәэсирле чагыштырулар һәм гомумиләштерелгән хикмәтле-эмоциональ гыйбарәләр тудырырга мөмкинлек бирә.

Әнкәйләрнең игез сыңарыдыр

Ахрысы син, туган авылым!

яки:

Әнкәй урынына кала

Икән лә туган илләр... [2, 182 б.]

Болар гына да аз әле. Ана кеше хәтта бөтен кешелек өчен кирәкле һәм бөтен дөньяны тотып торучы киң сыйдырышлы символ дәрәҗәсенә күтәрелә: ”Төшендем мин  - безгә генә түгел, Бар дөньяга Ана икәнеңә”. Бу, мөгаен, бала кешенең үз анасына бирә ала торган иң зур бәяседер. Кешелек дөньясының гасырлар дәвамында туплана килгән рухи кыйммәтләрен, тел һәм моң байлыгын, милли йола һәм гореф-гадәтләрне түкми-чәчми балаларына тапшыручы һәм сеңдереп Кеше итүче зат – безнең газиз аналарыбыз бит!

Табигате белән Харрас Әюп тыйнак, әдәпле һәм эчкерсез булса да, кирәк чакта очар канатын яки каләмен кылычка әйләндерә дә белә. “Авыл җаны” дигән поэмасы моның классик мисалы була ала. Автор анда үзе яраткан туган як темасына авыл җирендә барган соңгы үзгәрешләр яссылыгында якын килә, интонациясе дә, шуңа ярашып, берчә җитди борчылу һәм берчә кискен гаепләү рухында яңгырый. Шагыйрьнең болай борчылу һәм усаллану сәбәбе ачык: әле кайчан гына татарлык кайнап торган авылларга да таралу, акрынлап карт-коры төбәге булып калу куркынычы яный.

Мондый аяныч хәлнең тамыр җәюе, байтак татар җанлы авылларның мөшкел хәлгә төшеп баруы, бушап калуы өчен Х.Әюп, кайберәүләр кебек, һич тә заманны гына гаепләми. Киресенчә, моның өчен ул бәхет эзләп читкә китүчеләрне,  тәне-җисеме белән шәһәрдә торса да, җаны белән туган авылында яшәүчеләрне ныграк гаепли. Соңгылар исәбенә ул, “шәһәрләшә алмаган” авыл баласы буларак, үзен дә кертә.

Ялгыз гына киткән идек тә бит

Туган өйдән чыгып киткән көздә,

Авылыбызны килер буыннардан

Бөтенләйгә мәхрүм иткәнбез лә.

Үзебезнең гаепләрне ялгыш

Бүтәннәргә япсартмагыз тагын.

Синнән-миннән башка кемнәр булсын –

Алучысы бездер авыл җанын!.. "[1,31б.],

Ә инде "Көз", "Көй эзләү" кебек күләмле әсәрләрендә-поэмаларында шагыйрь, кеше рухының чын инженеры буларак, җанының тагын да тирәнрәк катламнарына үтеп керергә омтыла. "Көй эзләү" поэмасы, миңа калса, моң мотивына корылган шигырьләренең үзенчәлекле дәвамы һәм үстерелеше булып тора. Шагыйрь иҗатында моң образы гаҗәеп күпкырлы: ул орчык җыры һәм чулпы чыңлавы да, тургай тавышы һәм каеннар шаулавы да, сагыну сагышы һәм гомер агышы да, ата-бабалардан килгән атаклы "Иске кара урман" җыры да. Әмма, ни кызганыч, ул көйне без югалтканбыз, ят көйләргә алмаштырганбыз. Хәтта "Туган тел" көе дә "газиз көй бит – нигә өзелә?" дип ачыргалана шагыйрь һәм ничә еллар буена үзенең, җан газабы кичереп, "кайчак шыбыр тиргә төшеп", шул югалган көй не эзләве турында әйтә.

Кемгә ничектер, шагыйрь җан атып эзли торган Көйне мин үзем татарның хәзерге көнгә кадәр булмаган яки табылмаган Милли идеясенә тиңләп күз алдына китерәм. Сәяси юлыбызны һәм үсеш офыкларын билгели торган милли идеябезне эшләргә кирәклеге бүген аеруча кискен булып көн тәртибендә тора.

Харрасыбыз, минемчә, кинаяле шигъри тел белән нәкъ шуны әйтергә тели дә:

Күкрәгеңдә көең исән булсын,

Халыклар да бетә көй үлсә.

Эзлик әле гармун,

Уйныйк әле –

Яшәү юктыр ул көй өзелсә!.. "[3,241б.],

Шагыйрьнең дөньяга карашы, уй-кичерешләре эпик планда һәм киң масштабта ачыла торган “Су хәтере”,  “Базарлар”, “Биш вакыт намаз”, ”Йөрәк атым”, “Авыл җаны” дигән поэмалары да бар. Тарих, Вакыт, Милләт, Яшәеш турында уйланулар рәвешендә иҗат ителгән бу әсәрләр үзара тоташкан бер чылбыр тәшкил итә.

Минемчә, Х.Әюп поэмаларының төп кыйммәте – хәзерге заманда барган гаҗәеп гыйбрәтле һәм әһәмиятле үзгәрешләрне чын сәнгать ядкәрләре югарылыгында гомумиләштерүендә. Якташыбызның соклангыч иҗатына әдәбият галимнәре игътибар итәрләр, аның турында китаплар язылыр, иҗатына тиешенчә бәя бирелер, шигырь-поэмалары мәктәп һәм югары уку йортлары программаларына кертелер дип ышанасы килә.

Кулланылган әдәбият:

1. Әюп Х.Г. Сабыр савытлары: Шигырьләр һәм поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – 207 б.

2. Әюп Х.Г. Җәяүле буран: Шигырьләр һәм поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. – 385б.

3. Әюп.Харрас. Йөз яктысы: Шигырьләр, поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 415 б.

4. Әюп Х.Г. Моңлы бер кыл: шигырьләр, балладалар, поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – 479 б.

## Муса Җәлил шигырьләренең тел һәм стиль үзенчәлекләре

***Шәфигуллига Наилә Мәкәрим кызы***
***Олы Чакмак төп гомуми белем бирү***
***мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

М. Җәлил иҗаты өчен, сурәтләү алымы буларак, күчерелмә мәгънәле сүзләрдән киң файдалану характерлы.

Чагыштыру – нинди дә булса күренешне башка күренешкә охшату ярдәмендә барлыкка килгән сурәтләү чарасы. [1,б.191]

-дай / -дәй, -рак / -рәк, -ча / -чә аффикслары:

*Болганып каралган*

*Көмештәй саф сулы;*

*Уйлары таралган,*

*Йөрәге ярсулы.*

*(“Сандугач һәм чишмә”) һ.б.[3, б.50]*

М.Җәлил әсәрләрендә чагыштыру объектларыннан иң еш кулланылганы – шагыйрь үзе, ягъни лирик герой. Ул беренче зат алмашлыгы **мин** белән бирелә. Икенчесе – шагыйрьнең җыры. Аның  әсәрләрендә җыр сүзе Ватанга турылык, җиңү һәм үлемсезлек дигән мәгънәләрне белдерә. Бу ике сүз күп предметлар белән чагыштырыла.

*Мин* һәм **җыр** сүзләреннән тыш, рухи халәтне аңлата торган *күз яше, йөрәк, кан, ирек, нәфрәт кебек* чагыштыру предметлары да актив кулланыла. Шулай ук *совет солдаты, балалар, ана, кыз, сөйгән яр кебек* җанлы предметлар *туган җир, кызыл байрак, чишмә кебек* җансыз предметлар да билгеле бер урын алып тора. Лирик геройның һәм персонажларның портреты *(йөзе, ирене, керфекләре, буе)* психологик кичерешләре *(өмете, теләге, көче, сүзе, мәхәббәте, нәфрәте)*дә төрле предметларга тинләштерелә. Алар – уңай чагыштыру предметлары. Тискәре чагыштыру субъектлары да бар. Сан ягыннан күп булмаган андый сүзләр *(Гитлер (хуҗа), фашист солдатлары, фашист төрмәсе, әсирлек һ. б.)*  берничә төрле тискәре образларга тиңләштерелә: *котырган эт (“Тел”),  котырган бүре  (“Бүләк”), шакал («Мактанчыкка сабак»),  дуңгыз («Дошманга каршы»), кандала («Кандала»), көчек («Очрашу»)* һ.б.

М.Җәлилнең сугыш чоры әсәрләрендә җыр шулай ук образ-символларга тиңләштерелә. «Әйдә, җырым» дигән шигырендә, мәсәлән, уңай мөнәсәбәтле белдерү өчен, җыр нәфис гөл, чишмә, аргамак, ант, һәйкәл һәм башка предметлар белән чагыштырыла.

*Чишмә төсле җырым тамчысыннан*

*Яшь күңелләр үсте, яшәрде. (“Әйдә, җырым”)*

Тискәре бәя бирә торган *үлемем, нәфрәт-каргыш уты, бомба* дигән сүзләр исә конкрет вакыйганы, ягъни сугыш чорын, тоткынлык газапларын тасвирлау өчен хезмәт итә.

М.Җәлил иҗатында чагыштыруларның күпчелеге символлар рәвешендәге яки күчерелмә мәгънә алган *кешеләр, халык, ана, бала, кыз, егет, сөйгән яр һ. б.* сүзләр белән белдерелә. Алар арасында кыргый яки йорт хайваннары атамалары да *(арыслан, фил, бүре, шакал, эт, аргамак һ. б.),* кошлар да *(сандугач, карлыгач, бөркет, лачын, аккош, козгын, тилгән, тавык һ. б.),* табигать һәм табигать күренешләре исемнәре дә *(җир, су, тау, елга, чишмә, ай, кояш, йолдыз, таң, томан, болыт, җил, яңгыр, яшен, агачлар, урман һ. б.)* байтак.

Шигырьгә романтик рух бирү максаты белән, шагыйрь традицион чагыштырулардан да киң файдалана: *арслан шикелле егетләр («Бүләк»), корычтай нык сафлар («Дошманга каршы»), яңгыр кебек күз яшьләре («Юллар»).* Шулай ук алар символик сүрәтләү чаралары булып китәләр: чәчәк, гл, җил, тау, яй, кояш, йолдыз, таң, алтын, көмеш, алмаз, сандугач, лачын һ. б.

М.Җәлил кулланган чагыштыруларның күбесе күчерелмә мәгънәдәге сүзләрне охшашландыру, тиңләштерү нигезләнә. Чагыштыру образы итеп шагыйрь еш кына яхшы таныш булган предметларны да куллана. Мәсәлән, төз буй – шәмгә («Кол») [3, б.76], дошманы алдында куркып билен бөгүче - көянтәгә («Кол»)[3, б.76],, шагыйрьнен әсирлектәге гомере – сукыр лампага («Авыру сызмалар») яки тузн бөртегенә («Кичер, илем!») [3,б.39], төрмә сакчысыныдң атлап йөреше – кадак кагуга («Төрмә сакчысы») [3,б.64], мамык карлар – кәфенгә, бакча түтәле – кабергә, ялгыз ак каен – кабер ташына («Гөл кабере») [3, б.103], йөрәк сере – ефәк чигешенә («Күлмәк»)[3, б.119], ,концлагерь – үлем тегермәненә яки таш капчыкка («Таш капчык»)[3, б.169], тиңләштерелә.

Шагыйрь сугышның бик күп кайгы-хәсрәт китерүенә ишарә итә.

Язгы карлар эреп аккан төсле

Кими бара Гитлер гаскәре. («Соңгы бомба»)[3, б.229],

Юк, мин сине тузан бөртегедәй

Сансыз гомерем өчен сатмадым. («Кичер, илем!») [3, б.39],

Йөрәгемә кадак каккан кебек

Аның атлап йөреше. («Төрмәдә төш» [3, б.94], күчерелмә мәгънәле сүзләр аша белдерелгән чагыштыруларның, асылда, тасвири сыйфатламаларга, бигрәк тә уңай эпитетларга нигезләнеп төзелгән булуы күренә. Мәсәлән, үч ялкыны («Кичем, илем!»), алтын иркем («Ирек»), үткен канат («Кошчык»), якты җыр («Кошчык»), мамык карлар («Гөл кабере»), йөрәк сере («Күлмәк»), лачын йөрәк («Кичер, илем!») һ. б.

**Файдаланылган әдәбият исемлеге**


1. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 191-192б.

2. Җәлил, М. Моабит дәфтәре. М. Җәлил. - Казан: Тат. кит. нәшр., 1969. – Б. 744

3. Мостафин, Р. Дүрт баламны, очар кош итеп, мин очырдым иркен далага… / Р. Мостафин // Тәрбия. – 2006. – №1. – Б. 8-9.

4. Хатипов Фәрит. Әдәбият теориясе. – Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2000.

5. Совет мәктәбе журналлары 1958, 1972


## Чишмәләр җыры тынмасын


***Шибаева Ризәлә Рафаил кызы***
***Татарстан Республикасы***
***Алабуга муниципаль районы «6 нчы урта гомуми белем мәктәбе» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы***


Елгаларга таба челтер-челтер йөгерә торган чишмәләргә карап, без хыял аша балачак иленә, үткәннәргә кайтабыз, алар халык тормышының истәлек-

хатирәләре һәм тарихы турында сөйлиләр. “*Имештер, менә бу чишмәләрне дә Алып бабай чыгарган. Элекке заманнарда илгә дошман явы ябырылгач, Алып бабай җиде улының җидесен дә сугышка озаткан. Бер улы киткән саен, тау кабыргасына бер тибә, типкән саен, бер чишмә чыгара икән.”* [1, с. 392]

**I. Авылым чишмәләре.**

Авылда туып-үсеп, читтә яшәгән кеше һәрвакыт туган җирен искә төшерә. Аны туган җиренә челтерәп аккан шул чишмәләр тарта. [2, с. 81]. Чишмә буе – җәй көне минем иң яраткан урыным. Тирә-ягы яшел чирәмлеккә күмелгән Баллы чишмә суын бик яратам. Бу исем аның җисеменә дә шундый туры килә, башкасын күңел кабул да итмәс иде. Аның суы шулкадәр чиста ки, хәтта зәңгәрләнеп, кояш нурларында, йылк-йылк килеп, ялтырап тора. [3, с. 4]

**II. Гореф-гадәтләр. Яшьләр тормышында чишмәләрнең роле.**

Чишмәләр белән безнең татар халкының гореф-гадәтләре дә тыгыз бәйләнгән. Авылга килен төшкәч, иң элек аңа чишмә юлын күрсәткәннәр. Чишмәләр кызлар һәм егетләрне таныштырган һәм кавыштырган. Картлар чишмә янына үзләренең иң изге теләкләрен әйтергә килгәннәр. Яшь киленгә су юлы күрсәтү дә авылыбызда бик борынгыдан килгән йола булган. Әбием сөйләгәнчә, авылыбызда һәр ел саен гөрләп каз өмәләре үткән. *“Кызлар һәммәсе дә көянтә башларына берәр, икешәр каз элгәннәр. Без, малайлар, тау кырыеннан мәтәлә-шуа, йомшак карга манчылып, чишмә тирәсенә тәгәрибез. Кызларның берничәсе чишмәнең җиң юанлыгы булып аккан салкын суында каз түшкәләре юа.* [1, с. 280].

**III. Чишмәләр – табиб.**

Без көн саен чәй кайната, аш пешерә, юына һәм коена торган гап-гади суның да искиткеч гаҗәеп тылсымлы сыйфатлары бар.

“*Картлар әнкәйгә күзен көненә өч тапкыр шул чишмә суы белән киңәш бирделәр...*

-*Шул тазартты, дисәң инде, ә?*

-*Юып кына төшерде, юып кына! Өч йөз туксан йортлы Җидегәндә бер генә кешенең дә сукырайганы булмады. Элек тә булмаган! Беркайчан да! Менә*

*нәрсәдә чишмәнең изгелеге! Ишеттеңме? Шифалы дип, изге дип йөртәләр икән, халыкка файдасы тигәнгә әйтәләр…*”.[ 1, с. 407].

**IV. Экология. Сулыкларның пычрануы һәм аларны саклау проблемалары.**

Ярты гасыр эчендә ике миллиардтан артык “кара алтын” биргән Татарстанның җир асты сулары үзләренең меңъеллык агымнарын үзгәртте, күп кенә сулыклар тозланды, елга-күлләрнең башы булган чишмәләр югалды. Г. Бәширов “Җидегән чишмә” романында туган якны – урманнарны, кырларны, җир-суны, кош-корт, җәнлекләрне, гомумән, бөтен тирә-якны саклау мәсъәләсен күтәрә. [1, с. 409]. Әсәрнең төп геройлары – яшь егет Гайнан, умартачы Минһаҗ бабай авылдагы табигатьне, матурлыкны саклау өчен көрәшәләр. “*Чишмә нинди соң синеңчә? Картларча, бәлкем, шифалыдыр, фәләндер. Ә яшьләрчә ул просто су гына!”* [1, с. 407].

Колхозда хәлләр коточкыч: җиләк-җимеш бакчасы көтүлеккә әверелә бара, чәчәкле болын-әрәмәлекләр чәчүлек җир итеп сөрелә, нефтьчеләр, болыннарны пычратып, авыр вышкаларын куялар, техника чирәмлекләрне таптый, чишмәләрнең юлын боза [1, с. 405-406]. Ә халык табигатькә карата ваемсыз, битараф. Язучы Камил, Гайнан һәм Минһаҗ бабай ярдәмендә халыкта табигатькә карата мәхәббәт хисләре уятырга тырыша, кешеләрне тирә-якка зыян салучыларга каршы көрәшкә өнди.

Элекке заманнарда елга буйлап, чишмә яннарында әрәмәлекләр сузылган булган. Хәзер байлык, мал-мөлкәт туплау йогышлы чиргә әверелә бара. Чишмәләр онытыла. Алар янындагы агачлар киселә, сындырыла, тирәсен мал-туар таптый. Чишмәгә суга килүчеләр машиналарындагы чүпне, һич тә чирканмыйча, сукмакка ыргытып китәләр, буялган урындыкларга аяклары белән басалар. Чишмәләр – алар изге урын. Чишмә суын пычрату, чишмә буенда кычкырып сөйләшү, көлү, хәмер эчү, әдәпсез сүзләр әйтә – мәгънәсезлек. Чишмәләрне пычратмыйк!

Ә шулай да чишмәләр исән кала. Бәхетебезгә, су фаҗигасын иң башлап, нефтьчеләр үзләре төшенде. “Татнефть” коллективы тормыш чыганагы булган

чишмәләрне чистарту һәм яңартуга кереште, “Чишмә” операциясен башлады. 500дән артык чишмә табылды һәм аларны төзекләндерү эше башланды. Чал тарих исән! Бүген дә алар безне саф сулары белән куандыра.

**V. Халык педагогикасы суның әһәмияте турында.**

*Суның кадере – чишмә корыгач.*

*Кечкенә чишмәләрдән зур елгалар була.*

*Эчмәм дигән коедан өч әйләнеп су эчәрсең.*

*Кул пычранса, су белән юарсың, су пычранса ни белән юарсың*?

Кеше – табигать баласы. Табигатьне саклау – ул үзебезне, киләчәгебезне саклау, дигән сүз. Туган табигатебезне, чишмәләребезне саклау – барыбызның да изге бурычы. Чишмәләр югалмасын, күмелмәсеннәр! Чишмәләрне саклап, яңаларын тапсак, авылларыбыз да яшәрер, матурланыр!

Кешеләр! Табигатькә мәхәмәтлерәк булыйк! Аны саклап калу өчен көчебезне кызганмыйк! Табигатьне һәм аның байлыгын саклап калу – безнең бурыч.

Кулланылган әдәбият исемлеге


1. Г. Бәширов. Сайланма әсәрләр. Казан, “Хәтер”, 2006.
2. “Көч һәм рух тамырлары”. Казан, “Мәгариф”, 2000, 78-82 бит
3. С. Тажиев “Туган авылыбыз Бәзәкә кайда да безнең йөрәктә”. Алабуга, 2000.


## Матур әдәбият аша әхлакый-экологик белем һәм тәрбия бирү


***Якупова Гөлшат Шаһәдәт кызы,***
***Мөслим муниципаль районы,***
***Баланлы төп гомуми белем бирү***
***мәктәбенең 1нче категорияле***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы.***

**Кереш өлеше**

Мин дә кечкенәдән ук әни назын тоеп, аның сүзләренә колак салып үстем. Әнкәемнең: “Туган-үскән җиреңә мәрхәмәтле бул, аны булдыра алганча ярат,сакла, пычратма. Ата-баба нигезен онытма!” дигән сүзләре хәтеремә бик тирәнтен уелып калган. Ничек соң инде шундый гүзәл табигатьле, газиз туган ягыңны яратмаска, сакламаска мөмкин!?

Мөслим районы, халкыбызның җырларында җырлана торган ямьле Ык елгасы буена урнашкан. Ул төньяктан республикабызның Актаныш, төньяк-көнбатыштан Минзәлә, көньяк һәм көньяк-көнбатыштан Азнакай һәм Сарман районнары, көнчыгыштан Башкортстан Республикасының Бакалы районы белән чикләнә. Мин авыл кызы. Элек-электән үк авылда яшәүче һәр кеше укый-яза белмәгән очракта да, табигать телен яхшы аңлаган, күзәтүләр нигезендә табигать серләрен ачыклый алган. Бу белемнәр атадан балага, бер буыннан икенче буынга мирас итеп калдырылган. Борынгы әби-бабаларыбыздан иярә килгән халык авыз иҗатының мәкаль, табышмак, сынамыш, әкиятләрендә күп кенә экологик мәгълүмат бирелгән.

Бүгенге көндә чорыбызны глобаль проблемалар чоры дисәк, ялгышмабыз. Бу проблемаларны хәл итү җирдә яшәүче һәр кешегә кагыла. Глобаль проблемаларның берсе булып экологик проблемалар тора. Табигый байлыкларны үзләштергәндә, эшкәрткәндә һәм файдаланганда табигатьтә кирәкмәгән үзгәрешләр килеп чыга. Бу үзгәрешләр кеше сәламәтлегенә, табигатьнең үзенә зыян китерә башлыйлар һәм экологик проблемалар китереп чыгаралар. Бу хәлдән чыгу юллары бармы? Әлбәттә.....

**Төп өлеш**

Табигатькә сакчыл караш тәрбияләүдә матур әдәбиятның да роле зур.

Сер түгел, кайбер балалар әдәби әсәрләр укыганда табигать матурлыгын, аның белән кешеләр арасында барган үзара сөйләшүләрне тасвирлаган

өзекләрне укымыйча калдыралар яки игътибар белән укымыйлар. Мин укучыларга шундый тасвирлауларны ашыкмыйча, берничә тапкыр укып һәм эчтән кабатлап чыгарга киңәш итәм . “Табигатьтән башка үле без”-дигән темага әңгәмә үткәрәбез. Дәресләрендә халык авыз иҗатының бер төре булган табышмак аеруча киң кулланыла. (“Ак яулыгым төшеп калды”), яки табигый җисемнәргә хас үзенчәлекләр турында (“Җәен соры, кышын ак, аңа шулай яхшырак”).

Халык авыз иҗатының икенче бер төре-мәкаль. Мәкальләр арасында табигатькә багышланган һәм экологик тәрбияне күздә тотканнарын сайлап, табигать белемен өйрәнгәндә куллану, аларның асылын укучыларга җиткерү дәреснең нәтиҗәлелеген күтәрә.

Күпъеллык тәҗрибәләр нигезендә сынамышлар туган. Мәсәлән,ел исеменә ”Эт елы- буранлы булыр”, һава торышын алдан билгеләүгә ”Ай чалкан туса, көн салкын булыр” һәм башка сынамышларны күрсәтеп үтәргә мөмкин.

Язучыларыбыз, беренчеләдән булып, табигатьне саклау турында чаң сукты. Г. Тукай күп кенә шигырьләрендә җәнлекләрне, кошларны, бөҗәкләрне яратырга, аларга мәрхәмәтле, шәфкатьле булырга өнди, үзенең шигъри бизәкләре белән табигатьнең гүзәллеген ача.

*"Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә,*
*Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем".*

(Г. Тукай. "Туган авыл")

А. Алиш кечкенәдән тирә-як мохитне оста тоемлый белгән, аның күп әсәрләрендә табигать белән бәйләнеш кызыл җеп кебек сузылып бара.

"Нечкәбил" әкиятен генә алып карыйк. *"...Аларның йортларын мәк чәчәге кебек кызылга, үлән төсле яшелгә, кояш сыман сарыга, күк төсле зәңгәргә, төрле-төрле матур төсләргә буяганнар"*.

Мәшһүр мәгърифәтче, галим, педагог Р.Фәхреддин хезмәтләрендә дә шундый юллар бар.

*Кешенең файдасыз сүзләрне куюы – иманы гүзәл булуының билгесе.*

*Буш фикерләр вә буш сүзләр белән шөгыльләнүгә караганда берәр төрле файдалы нәрсә белән шөгыльләнү, янәшә-тирәне чолгап алган нәрсәләрне танып белү, су вә һаваны, туфрак вә утны, үлән вә агачларны, ай вә йолдызларны өйрәнү, гомумән, табигать әхвәлләре белән таныш булырга тырышу яхшырактыр.*

Табигатьне саклау проблемасы Ә. Баяновның «Сәяхәтнамә» поэмасында күтәрелә.Ул кешелек дөньясын саклап калырга чакыра. Сәяхәтнамәнең ахырын ул болай тәмамлый:

*Чаң кагам мин:*

*— Бар халыклар!*

*Барлык теләк-гадәтләрне*

*Буйсындырып бары акылга,*

*Кул бирегез бер-берегезгә*

*Җир хакына, яшәү хакына!*

Кешеләр! Әйдәгез әле, табигатькә карата бераз мәрхәмәтлерәк булыйк! Аны саклап калу өчен бар көчебезне кызганмыйк!.

Туган як турында язучылар зур күләмле әсәрләр язалар. Г. Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» дигән әсәренең исеме генә ни тора!

М. Мәһдиевнең «Торналар төшкән җирдә» әсәре туган ягы һәм аның кешеләренә багышлап язылган. Гадел Кутуй «Сагыну» нәсерендә чит илдә йөргән солдатның сагыну хисләрен сурәтли. «Аның әреме дә бүген миңа шифа булыр иде», — ди.

Дәрестә француз технологиясе кулланам. Халык авыз иҗаты һәм язучыларның шигырь-әсәрләрен өйрәнгәндә укучы тагын да тирәнрәк кабул итсен, аңласын өчен бу технология уңайлы. Бер әсәрне төрле музыка астында көйләп уку, суәткә төшерү, төсләр ярдәмендә аңлау балада кызыксыну уята. Аның психологиясенә уңай тәэсир итә.

Йомгаклау

Кеше кайларда гына йөрмәсен, нинди гүзәл җирләрдә генә яшәмәсен, ул барыбер үзенең туган ягына омтыла.

Табигатькә караш турында берничә төрле фикер бар. Беренчесе – ***табигатьне буйсындырырга,*** аннан теләгәнчә файдаланырга; икенчесе – ***табигатьне сакларга***, аңа тимәскә. Табигатьтән аңлы, рациональ файдаланырга кирәк. Заводлар табигатькә зыян китерми торган итеп эшләргә тиеш. Агач киселә икән, урынына икенчесе утыртылсын. Нефть алына икән, бу эш саклык белән, табигатькә зыян китерми торган итеп башкарылсын. Кеше җәнлекләргә, кошларга да дустанә мөнәсәбәттә булырга тиеш. ***Татарстан Республикасы Конституциясенең 55нче матдәсендә "Табигатькә сакчыл караш – Татарстан Республикасының һәр гражданы бурычы"*** диелгән.

Табигать – кешенең яшәү урыны. Без табигатьне яратабыз, аннан җаныбызга ямь, күңелебезгә тынычлык алабыз. Табигатьне саклау – ул үзебезне, киләчәгебезне, өебезне саклау дигән сүз. Үз-үзеңә, туган җиргә тугры булып калу, аның кадерен белү элек-электән яшәү мәгънәсенең асылын аңлаткан. Безгә аны югалтмыйча, тагын да баетып, килер буыннарга мирас итү бурычы йөкләнгән.

Без табигать балалары, ә табигать безнең хуҗабыз! Моны беркайчан да истән чыгармыйк һәм табигатьнең кагыйдәләренә, кануннарына каршы килмичә аңа буйсыныйк!

# Башлангыч сыйныф укучыларына татар теле дәресләрендә экологик тәрбия бирү

***Яппарова Рәмзилә Билус кызы,***
***Минзәлә шәһәре, 1нче урта мәктәп***

Кеше гомере буе табигать белән тыгыз элемтәдә яши. Бүген кеше табигатькә бәйле дип әйтү генә дөрес булмас иде,чөнки табигатьнең язмышын кеше дә хәл итә, ул экологик тотрыклылыкны саклап калырга бурычлы.

Мәктәп һәм экологик культура –бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә булган төшенчәләр. Укытучылар алдында укучыларга экологик белем бирү: укучыларның дөньяга караш даирәләрен киңәйтү, аларны табигатьне сакларга, аңа мәрхәмәтле, игътибарлы булырга өйрәтү, туган җиребезне ярату, аның белән горурлана белү хисе тәрбияләү - иң төп максатларның берсе. Аларны тормышка ашыру өчен, нәтиҗәле алымнар һәм ышандырырлык фактлар кулланып, эзлекле эш алып барырга кирәк.

Кеше табигатькә никадәр якынрак торса, аның күңеле дә шулкадәр сафрак була. Балалар белән эшләүче мөгаллим бу хакыйкатьне һәрвакыт исендә тотарга тиеш. Сабый баланың әйләнә-тирәдәге үзгәрешләргә карап соклануы, кошлар сайравын тыңлап тәэсирләнүе аның табигать белән кызыксынуын күрсәтә. Менә шул матурлыкны күрә, соклана белү сәләтен, нечкә хис-тойгыларны кечкенәдән үк үстерергә, ныгытырга кирәк.

Табигать турындагы белемнәр халык авыз иҗатында киң чагылыш тапкан.Әкият, мәкаль,әйтем, сынамыш һәм табышмакларда күп кенә экологик мәгълүмат бирелгән. Бу чыганакның төп өстенлеге шунда: белемнәр балаларга мавыктыргыч рәвештә җиткерелә.

Дәресләрдә халык авыз иҗатының бер төре булган табышмакларны еш кулланабыз. Аларның күбесе еш очрый торган табигать күренешләренә багышланган(“Ак яулыгым төшеп калды”...), яки табигый җисемнәргә хас үзенчәлекләр турында( “Җәен соры, кышын ак, аңа шулай яхшырак”).Табышмаклар балаларда зирәклек, күзәтүчәнлек кебек сыйфатлар

тәрбияли, дәресне җанландыра, укучыларның активлыгын күтәрергә ярдәм итә.Табышмакларны теләсә кайсы дәреснең уңайлы моментын табып файдаланырга була.Аларны кулланып, кроссвордлар төзергә мөмкин.

Халык авыз иҗатының икенче бер төре - мәкаль.Кыска, ләкин хикмәтле сүзләр белән халык бик тирән мәгънәле фикерләрне бер буыннан икенче буынга җиткергән; шуңа күрә күпчелек аны “ата-баба сүзе” дип йөрткән.Мәкальләр арасында табигатькә багышланган һәм экологик тәрбияне күз алдында тотканнарын сайлап, дәресләрдә куллану, аларның асылын укучыларга җиткерү дәреснең нәтиҗәлелеген күтәрә, аларда игелекле эшләр башкарырга омтылыш уята. Мәсәлән,”Суга сусаган - чишмә әрчегән”, “Агач утырткан - ага булган”,”Кул пычранса, су белән юарсың,су пычранса ни белән юарсың?” һ.б. шундый мәкальләрдән файдаланабыз.

Сынамышларны да шулай ук киң кулланырга була.Әйтем һәм сынамышларны балаларның хәтеренә сеңдерү өчен, бу эшне экологик лото рәвешендә дә оештырабыз. Мәкаль, әйтем , сынамыш ике өлешкә бүленә.(Мәсәлән, беренчесе – “урман утырткан”, икенчесе – “ачлык күрмәс”), һәр өлеш аерым карточкага теркәлә,укытучы кушуы буенча, укучылар мәгънә ягыннан туры килүче өлешләрне эзлиләр.

Халкыбыз төрле табынулар, ырымнар ярдәмендә кешеләрнең табигатьтә үз-үзләрен тоту кагыйдәләрен эшләгән.Мәсәлән, мондый әйтем бар:”Кош оясын туздырсаң, башың авыртыр”. Кем инде үз башының авыртуын теләсен. Бала-чагалар, күктә очучы кошларны күреп, саный башлыйлар.Монда да әби-бабаларыбыз кисәтә:”Кыр казларын санасаң, алар аерылып кала”. Кыр казларының аерылып адашып йөрүе кызгану хисе уята, шунда ук санаудан туктыйсың.

Әдәбият дәреслекләрендә урын алган күп кенә шагыйрьләребез әсәрләре дә экологик теманы күтәреп чыга. Шигърияттә бу темага урын бирмәгән шагыйрьне табуы кыендыр. Табигать темасына язылган шигырьләр исемлеге бай һәм төрле.Әлеге әсәрләр балаларны табигатьне аңларга, яратырга, аның байлыкларына сакчыл караш формалаштырырга, туган җирнең кадерен белергә

өйрәтә. Шулай да мәктәп дәреслекләрендә зур урын бирелгән кайбер шәхесләребезне аерым әйтеп китү кирәктер: Г.Тукай, А.Алиш, Х.Туфан, Ш.Галиев, Р.Вәлиева һәм башкаларның шигырьләрендә җәнлекләрне, кошларны, бөҗәкләрне яратырга, аларга мәрхәмәтле, шәфкатьле булырга өнди, нәфис сүз, сәнгать чаралары ярдәмендә Җир-анага игелек, хөрмәт хисләрен уяталар, шигъри бизәкләре белән табигатьнең гүзәллеген ачып, кешелекнең экологик һәлакәт каршында торуын да искәртәләр.

Рус мәктәпләрендәге татар балалары өчен Р.Ягъфәрова төзегән дәреслекләрдә Р.Вәлиеваның «Кыңгырау чәчәк», Р.Низамиевның «Яралы керпе», В.Монасыйповның «Табиблар», Л.Зөлкарнәйнең «Бичаралар һәм бичуралар» әсәрләрен, мәсәлән, әхлакый-экологик белем бирүдә отышлы файдаланырга була.

Язучыларыбыз табигатьне саклау турында еш язалар. Әйләнә-тирәне, кеше сәламәтлеген, аның рухын, туган телен саклау аларны иң борчыган проблемага әйләнде. Кешедә югалып бара торган иң изге әхлакый-рухи кыйммәтләрне торгызу, Җир-анага игелек-хөрмәт хисләрен уяту, кешелекнең экологик һәлакәт каршында торуын нәфис сүз, сәнгать чаралары ярдәмендә искәртү кирәк булды.

Табигатьне саклау темасына язылган әсәрләр исемлеге бай һәм төрле. Укучыларның яшь үзенчәлекләрен искә алып, аларны һәр сыйныфта кулланырга мөмкин.

Кече яшьтәге мәктәп балаларына табигатьтә һәр күренеш серле һәм кызыклы, һәрнәрсә – яңалык. Ел фасыллары, кошлар, җәнлекләр тормышы шушы чорда аеруча файдалы. Бу максатларда кайбер халык әкиятләрен дә кулланырга була. «Кем нәрсә ярата?», «Кем көчле?» әкиятләрендә кеше иң көчле, иң акыллы булып кала. Ләкин укучыларның шуны аңлап калуы мөһим кешенең көче аның табигатьне буйсындыруында түгел, бәлки аны яклый һәм саклый белүендә.

Сөекле шагыйребез Габдулла Тукай күп шигырьләрендә җәнлекләрне, кошларны, бөҗәкләрне яратырга, аларга мәрхәмәтле, шәфкатьле булырга өнди,

үзенең шигъри бизәкләре белән табигатьнең гүзәллеген ача. «Җир йокысы», «Яз галәмәтләре», «Карлыгач», «Бичара куян», «Бала белән күбәләк» кебек шигырьләрендә бу ачык чагыла. Ә «Кояш», «Һава», «Су», «Җир», «Елның дүрт фасылы» исемле кечкенә хикәләрендә табигать турында шактый мәгълүмат тупланган.

Балалар өчен әкиятләр язып калдырган Абдулла Алиш иҗаты да игътибарга лаек. Аның «Нечкәбил», «Кем көчле?», «Койрыклар» әкиятләрендә кайбер тереклек ияләренең бөтен гадәтләре, яшәү рәвешләре, үрчү ысуллары һ. б. чагыла. Аларны фәнни әкиятләр дияргә дә нигез бар.

Кулланылган әдәбият:


1. Җәләлиев Ш.Ш. Татар халык педагогикасы. –Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2000.
2. Заһидуллина Д.Ф. Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2000.
3. Низамов А.М. Милли мәктәп тәрбия нигезләре.- Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2005.
4. Сәхипова Р.Ә. Халык педагогикасы нигезендә укыту һәм тәрбия бирү. –Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2005.


## Татар әдәбияты дәресләрендә экологик тәрбия


***Ясавиева Г.М.югары категорияле татар теле укытучысы***
***МБГБУ «Песәй урта гомуми белем бирү мәктәбе»***


Экологик проблемалар-кешелекнең иң мөһим проблемаларының берсе. Еш кына “экология” сүзе “табигать” һәм “тирә-як яшәеше” дигән сүзтезмәләр белән бергә тора. Соңгы вакытта “экология” сүзе һәлакәт сүзе белән күбрәк кулланыла башлады. Табигать экологиясе һәм җир экологиясен бер- берсеннән

башка күз алдына китерергә мөмкин түгел. Без котычкыч рәвештә җирнең үсемлекләр дөньясын, горур һәм бәйсез хайваннарын, тормышның бөтен матурлыгы булган , гүзәллекне үз кулларыбыз белән харап итәбез.

Ни өчен балалар һәм яшүсмерләр арасында кош ояларын туздыручы, елгаларны һәм чишмәләрне пычратучы, агачларны сындыручылар саны елдан-ел күбәя. Ә безнең кечкенә дусларыбыз- рәнҗетелгән песи һәм этләр? Алар да табигать балалары ич...

Табигатьне яратырга, табигатькә сак караш тәрбияләүне ничек оештырырга соң? XXI гасыр балаларына табигать байлыкларының чиксез түгел икәнен ничек аңлатырга? Бу авыр мәсьәлә.

Кешедә экологик дөрес гадәтләрне тәрбияләү җиңел эш түгел. Матур чәчәкне өзгәч, аның һәлак булуы турында белү барыбыз өчен дә аңлаешлы хәл түгел шул. Чәчәк гомере бик кыска. Безнең урманнар һәм кырлар, безнең кечкенә туганнарыбыз- хайваннар кыргый аучылар- браконьерлар кулыннан һәлак булмасын өчен безгә нишләргә? Балаларны уйланылмаган эшләрдән ничек туктатырга? Сораулар күп. Бу ялгыш кына эшләнгән эшләр нәтиҗәсендә кеше үзе җәфа чигә ич!

Республиканың табигый байлыкларының чын хуҗасын тәрбияләү- безнең иң кирәкле бурычларыбызның берсе. Безнең әби-бабаларыбыз табигать байлыкларыннан бик сак файдаланганнар. Җәнлек балаларын ауламаганнар, кечкенә балыкларны да суга кире җибәргәннәр, яшь агачларны кисмәгәннәр.

Мең еллар дәвамында халыкның аңына сеңгән, аның яшәешенең үзәген тәшкил иткән табигатькә сакчыл караш буыннан- буынга күчеп килгән. Баласын табигатьне саклаучы, яклаучы, хөрмәт итүче итеп тәрбияләү һәрбер әти-әнинең, әби-бабайның изге бурычы саналган. Мондый тәрбия төрле йола, риваять, җыр, бәет аша бирелгән. Табигатькә сакчыл караш тәрбияләүдә, халык педагогикасы белән беррәттән, матур әдәбиятның да роле зур.

“... Туган җир, дисәм, беренче мәртәбә кояш нурында коенуым искә төшә, туган җир, дисәм, салават күперенең җиде төсе җитмеш төскә кереп балкый башлый, туган җир, дисәм, җилләр телен аңлыйм мин, тын гына очкан кар

бөртекләренең үзара сөйләшкәннәрен ишетәм...” (Ф. Шәфигуллин. “Туган җир – туган ана”)

Кеше күңелен табигатькә якынайта торган искиткеч сүзләр. Сер түгел, кайбер балалар әдәби әсәрләр укыганда табигать матурлыгын, аның белән кешеләр арасында барган үзара сөйләшүләрне тасвирлаган өзекләрне укымыйча калдыралар яки игътибар белән укымыйлар. Мин укучыларга шундый тасвирлауларны ашыкмыйча, берничә тапкыр укып чыгарга һәм бөтен тулылыгы белән күз алдына китереп, эчтән кабатлап чыгарга киңәш итәм һәм өйдә рәсемен ясап килергә тәкъдим итәм. Икенче дәрестә укылган өзекләр һәм рәсемнәр буенча нәтиҗә ясыйбыз: “Табигать ни чаклы көчле булса, шулкадәр үк самими һәм безнең тарафтан яклауга, саклауга мохтаҗ икән!” Татар балалар язучылары арасында табигать темасына мөрәҗәгать иткәннәре байтак. Гарәфи Хәсәнов иҗаты бу өлкәдә аерым урын алып тора.

Язучы үзенең хикәяләрендә туган як табигатен, аңа хас булган күренешләрне, үзгәрешләрне сурәтли. Кайсы ел фасылы турында гына язмасын, авторның туган як табигатен чын күңелдән сөюен тоясың.

Г. Хәсәнов хикәяләрендә балаларга таныш кош-корт һәм хайваннарның моңарчы игътибар ителмәгән сыйфатлары зур осталык белән сурәтләнә. Язучының күңеленә торнаның гади генә тавышы да, туган якны яратып, “монда торрыйк, монда оя коррыйк” дип әйткән төсле тоела.

Язучы хикәяләре аша укучылар туган якның аларга берникадәр таныш булган һәм моңарчы бөтенләй белмәгән күп кош-кортларын, үсемлекләре һәм башка тереклек ияләрен өйрәнәләр. “Сандугач дисеңме, төн күгәрчене, ләкләк, шөпшә кошы, уткойрык, чырайсыз ябалак, күке, миләш чыпчыгы, кыр һәм саз карлыгачлары, чебенче дисеңме...” – һәрберсенең туган як табигатендә урыны бар.

Укучылар үзләренә таныш булган кырмыскалар турында гына укысалар да, аларның табигатькә нинди зур файда китерүләре турында белсәләр, тагын да зуррак кызыксыну һәм өйрәнү теләге туар. Мондый хикәяләр укыган бала һичкайчан да, кырмыска ояларын туздырып, табигатькә зыян салмас. Г.

Хәсәнов хикәяләре туган ягыбыз табигатенә, аның байлыгына һәм күптөрлелегенә дан җырлый, шул табигатьне сөяргә, сакларга һәм һәрьяклап үстерергә өнди.,

Югары сыйныфларда исә әлеге темага багышланган әсәрләрнең берсен “Туган ягым- яшел бишек” автобиографик әсәрен үтәбез. Дәресебезгә мин түбәндәге эпиграфны сайладым:”Мин дә табигатьнең бер баласы,әнә песнәк тә хәлемне белеп китә дим, кошлар минем өчен сайрый”. Кеше һәм табигать. Аларның бер-берсенә мөнәсәбәте нинди соң?

Туган илкәй...
Ни аһәңле,назлы исем!
Сизәм анда болыннарның татлы исен,
Ишетәм анда яфракларның серле шавын,
Тау астында салкын чишмә чылтыравын,
Саклыйм аңа чын мәхәббәт,сөю хисен,
Алам аннан мәңге сүнмәс яшәү көчен.

Бу юллар Г.Бәшировның”Туган ягым- яшел бишек” әсәрендә тасвирланган туган як табигатен, аның күркәмлеген,табигать белән тыгыз бәйләнештә торган адәм баласы-кешенең аңа мөнәсәбәтен ачык чагылдыра.

Әсәрдә тормыш,авылдагы хезмәт табигать кануннарына көйләнгән булуы берничә кат искә төшерелә.Табигать кешенең кәефе белән идарә итә . Табигать белән кешене аерып карап булмый,чөнки алар бербөтен.Әсәрдә беренче күк-күкрәгәнгә,кыр казлары кайтуга,шаулап аккан ташуга карата кешеләрнең мөнәсәбәтләре,шатлык-куанычлары чагылыш тапкан.Автор гади авыл баласы буларак туган як табигатен бик яраткан, табигатьне тасвирлаганда төрле сурәтләү чараларын кулланган.

Гомәр ага -Яңасала табигатенә мөкиббән киткән язучы. Әсәрендә су буйларын, болыннарны, чишмә буйларын тасвирлауга күп урын бирелгән.

Кешеләр беренче урынга матди яктан яхшы торуны, акчаны, престижлы эш урынын куялар, экология турында уйламыйлар яки уйлаудан

туктыйлар.Кырыс тормыш кануннары җир йөзенең киләчәге турында уйларга вакыт калдырмый.

Г.Бәширов “Ялкын” журналына биргән интервьюда болай ди:”Табигатьне яратам.Минем өчен табигать-бик зур байлык,илһам чыганагы. Менә карагыз әле бу гади генә тәрәзәгә.Шунда песнәк килә дә,миңа карап, чукыр-чукыр сәлам бирә.Минем өчен зур сөенеч,вакыйга була ул.Мин дә табигатьнең бер баласы,әнә песнәк тә хәлемне белеп китә дим, кошлар минем өчен сайрый.Хәзер менә оялары да юк.Кошлар кими.Табигать ярлыланы бара.Бик фәкыйрь дөньяга калып барабыз, дип борчылам.

-“...Менә кояш баеп шәфәкъ нурлары да сүнде.Аның урынына кояш баешыннан, җир белән күк белән җир арасында эленеп торган киң бер нур булып,Казан өстендәге кечке яктылык балкый башлады...Без бер-беребезнең иңнәренә таянып,әнә шул нур балкыган якка карап барабыз.Безнең күңелләрне,бәйрәм көннәрдәге шикелле, зур куаныч рәхәтләндереп тора...”(“Туган ягым –яшел бишек”әсәреннән өзек)

Шулай итеп, әлеге нур барчабызның да җанында балкысын иде.Күңелендә нуры булган кеше табигатькә зыян сала алмый.Г.Бәширов туган як гүзәллеген тасвирлаган кебек,без дә бик күп еллар буена үз ягыбызның табигате белән соклансак иде,хәлебездән килгәнчә аңа ярдәм кыла алсак иде.Әгәр дә инде песнәк адәм баласының хәлен белеп, курыкмыйча янына куна ала икән, бу могҗиза аларның бербөтенлегенә, икесе дә табигать балалары икәнлегенә дәлил.

Табигатьне саклау – һәркемнең изге бурычы ул. Табигатьне ярата, аның матурлыгын тоя, күрә белгән кеше беркайчан да каты бәгырьле була алмый. Балаларыбыз шәфкатьле, миһербанлы, мәрхәмәтле булып үссә иде.

Кулланылган әдәбият:

1.”Казан утлары” журналы:1979 ел,3 нче сан.

2.”Ялкын” журналы:2011 нче ел



Безнең адрес:
423700, Татарстан Рспубликасы,
Минзәлә шәһәре, М. Җәлил урамы, 18нче йорт
Телефоннар: (8-5555) 3-21-36, Факс: (8-5555) 3-21-36
Электронная почта: menzk@mail.ru
Лицензия серии 16 Л 01 № 0003110
Регистрационный № 7217 от 18.09.2015
Аккредитация серии 16 А 01 № 0000113
Рег. № 3663 от 18.07.2016г.
Без сезне көтәбез! Рәхим итегез!